ISSN 0206—41

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.1990





## ТАТАРСТАН СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА

# ДЕКЛАРАЦИЯ

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югары Советы,

— республиканың күпмилләтле халкы язмышы өчен тарихи җаваплылыкны аңлап;

— Россия Федерациясендә һәм Совет Социалистик Республикалар Союзында яшәүче барлык халыкларның суверен хокукларына ихтирам белдереп;

— автономияле республика статусының аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, экономик, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен күрсәтеп үтеп;

— татар милләтенең, республикада яшәүче бөтен халыкның үзбилгеләнүгә булган аерылгысыз хокукын тормышка ашырып;

— демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып,

1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны **Татарстан Совет Социалистик Республикасы — Татарстан Республикасы** итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга, нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, политик инануларының нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, кешегә тигез хокуклар һәм ирекләр гарантияли, Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең дәүләт теле сыйфатында тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.

4. Киләчәктә Конституциядә, башка хокукый норматив актларда, дәүләт тормышында дәүләтнең рәсми исемен **«Татарстан Совет Социалистик Республикасы» (Татарстан ССР яки Татарстан Республикасы)** дип кулланырга.

Республика дәүләт властеның югары органын — **«Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы»** дип, ә ул кабул итә торган актларны — **Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы актлары** дип исемләргә.

5. Бу Декларация Татарстан ССР Конституциясен эшләү, Татарстан ССР законнарын үстерү өчен, Татарстан ССРның Союз договорын, РСФСР һәм башка республикалар белән договорлар әзерләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен, Татарстан ССР дәүләт төзелешенең аеруча мөһим мәсьәләләрен һәм аның ССР Союзы, РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсәбәтләрен аның халкы тикшерүенә чыгару өчен нигез булып тора.

Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле.

6. Татарстан ССРның яңа Конституциясен, башка законнарны һәм норматив актларны кабул иткәнгә кадәр Татарстан ССР территориясендә Татарстан ССРның, РСФСР һәм ССР Союзының Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә каршы килми торган законнары һәм закон актлары гамәлдә булуны дәвам иттерә.

Бу Декларация аны кабул итү вакытыннан көченә керә.

Татарстан Совет Социалистик Республикасы
Югары Советы рәисе — М. ШӘЙМИЕВ.

Казан. 1990 ел, 30 август.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1990

9

(815)

## Бу санда

Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация

ШИГЪРИЯТ

Г. РӘХИМ. Татар кешесе. *Шигырьләр* . . . . 3
Н. АРСЛАН. Көз. *Шигырьләр* . . . . . . . 6
Ш. МАННАП. Сабырлык. *Шигырьләр* . . . . 79
Л. ШАГЫЙРҖАН. Вакыт. *Шигырьләр* . . . . 83

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Н. АКМАЛ. Күгәрчен сөте. *Повесть* . . . . . 8
Н. ГЫЙМАТДИНОВА. Сихерче. *Повесть* . . . 86

ӘДӘБИ МИРАС

М. РАФИКОВ. Алар өчен юк мин... *Шигырьләр* 138

ПУБЛИЦИСТИКА

А. ХӘСӘНОВ. Җидегән чишмәләрдә — җиде улак . . . . . . . . . . . . . . . 141
Җ. РӘХИМОВ. Кем син, Нәдер Үрәзмәтов? . . . 150
М. ӘХМӘТҖАНОВ. Бар бер авыл Урал итәгендә . . . . . . . . . . . . . . . 154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

З. МАНСУРОВ. Сиксәненче елларны озатканда . . . . . . . . . . . . . . . 158

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Ш. САРЫМСАКОВ. Әйбәт кеше, олы драматург . . . . . . . . . . . . . . . 169
М. МӘҺДИЕВ. Безнең күңелләрдә ташкыннар . . . . . . . . . . . . . . . 172

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Суоми иленең татар китаплары . . . . . . . . . . . . . . . 177
Ф. ВӘЛИЕВ. Себердә белем учаклары . . . 184

Югалмаска һәм югалтмаска! *(татар укытучыларына мөрәҗәгать)* . . . . . . . . . . 188

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . .149
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . .189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . .192

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркатип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-07-09,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Декларация о государственном суверенитете Татарской Советской Социалистической Республики.
«Проза и поэзия»: окончание повести Н. АКМАЛА «Птичье молоко»; повесть Н. ГИМАТДИНОВОЙ «Колдунья». Стихи Г. РАХИМА, Н. АРСЛАНА, Ш. МАННАПА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ.
«Литературное наследие»: стихи М. РАФИКОВА.
«Публицистика»: статья А. ХАСАНОВА об экологических проблемах нефтяных районов Татарии; статьи Дж. РАХИМОВА «Кто ты, Надир Уразметов?» и М. АХМЕТЗЯНОВА «Есть деревня на Урале».
«Литературная критика»: статья З. МАНСУРОВА о проблемах современности и поэзии.
«К истории культуры»: статьи А. КАРИМУЛЛИНА «Татарские книги страны Суоми», Ф. ВАЛИЕВА «Очаги просвещения в Сибири».
К 95-летию драматурга Т. ГИЗЗАТА посвящены статьи Ш. САРЫМСАКОВА и М. МАГДЕЕВА.
В номере отмечается 80-летие композитора З. Хабибуллина.
Обращение учителей татарского языка и литературы ко всем татарским учителям и воспитателям СССР и мира.
Хроника культурной жизни.
На первой странице обложки: Азимовская мечеть Казани.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 12.07.1990 ел. Басарга кул куелды 6.09.1990 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-333. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Гәрәй Рәхим

### Татар кешесе

Болгарында болганган,
Уралында уралган,
Сараеңда саргайган,
Суварында сызланган —
Синдер, татар кешесе.

Себергә себерелгән,
Чиләбедә чиләнгән,
Оренбурда орылган,
Каргалыда каргалган —
Синдер, татар кешесе.

Петербуры, пытырдап,
Тукаеңны куркыткан,
Кытайдагы кытлыклар
Мөһаҗиреңкырдырткан
Синең, татар кешесе.

Өргәнечтә өркегән,
Уфасында уфырган,
Касыймында кысылган,
Рязаньда разбой салган —
Син ул, татар кешесе.

Мәкәрҗәдә мекердәп,
Истамбулда ысланып,
Үзбәкләрдә үзгәреп,
Кырымнарда кырылып
Беттең, татар кешесе.

Французга яу чаптың,
Германга да яу чаптың,
Ул илләрдә ни таптың?
Күп вакытта үз җиреңнән,
Иделеңнән, үз өеңнән,
Илеңнән колак кактың,
Яугир татар кешесе.

Рудасын да син чаптың,
Күмерен дә син чаптың,
Балыгын да син тоттың,
Нефтен дә син таптың.
Үз-үзеңә суыгаяк,
Зимагур дип ат тактың,
Шаян татар кешесе.

Мәскәүдә бар үз өең,
Киевта бар үз көең.
Балтыйгында балкыйсың.
Чит җирдә дә туган телне,
Туган көйне ятлыйсың,
Моңлы татар кешесе.

Фин иле, япон иле,
Болгар һәм румын иле —
Барында да килмешәк,
Күчемсәк һәм йөремсәк
Булдың, татар кешесе.

Болай каңгырып йөрмә,
Кайт син туган илеңә,
Борынгылар түренә.
Бит куй Идел җиленә,
Баш куй Болгар җиренә,
Әйдә, татар кешесе!

---

Гәрәй РӘХИМ *(1941) — шагыйрь, прозаик; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык китап авторы. Ул — ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

# Идиллия

(БАЛЛАДА ДИЯРЛЕК)

Eрактан ук карап киләм,
Әйтерсең лә серле бер көй:
Ай яктысы...
Моржасыннан
Төтен бөркеп торган бер өй.
Чорның нинди бәхетлесе
Яшәп ята икән монда?!.
Ап-ак карлар урап алган
Ап-ак ялан уртасында!
Шушы шаулы бер заманда,
Күрче, ничек оста гына
Идиллия качып яши
Дөньяның тын почмагына!
Бу бәхетле хуҗаны мин
Белим, дидем, күрим, дидем —
Әдәп белән ишек шакып,
Бусаганы атлап кердем.
Өй эчендә карт бер әби
Ята иде түшәгендә.
Сәлам алмый, сәлам бирми —
Карап ята түшәменә.
«И әби,— дим,— бу дөньяда
Синдер иң-иң бәхетле зат —
Өең тыныч, көнең тыныч,
Үзең ялгыз, үзең азат...»

Шунда әби миңа табан
Бер өздереп карады да:
«Балам,— диде,— инде ун ел
Ялгыз мин бу каралтыда.
Ун баламның унысын да
Комсыз заман тотып йотты —
Бар да, шәһәр... шәһәр, диеп
Ташлап китте туган йортны.
Авылдашлар күмәкләшеп
Күченделәр Зур авылга.
Ирем гүрдә...
Калдым гүя
Каберлектә каравылда.
Син сокланган бу яланда
Минем өй дә, зират кына.
Сез яшәгән бу заманнан
Минем өем ерак тора.
Бар, кит син дә...
Матурлыкны
Фаҗигадән эзләп йөрмә.
Аңла шуны: бер үк хәят —
Кемгә җәннәт, кемгә төрмә...»

Ерак китеп карап тордым,
Әйтерсең лә шомлы бер көй:
Ай яктысы...
Моржасыннан
Сагыш бөркеп торган бер өй.

# Чорлар рухание

*Татарстан халык язучысы, галим Нәкый Исәнбәткә 90 яшь тулган көннәрдә дә (1989 елның декабре) аның әдәби фәнни эшенә бәйле суд процессы тәмамланмаган иде.*

Һәкый Исәнбәтнең эш бүлмәсе...
Монда мохит сабыр... салмак... тын...
Гүя мең ел элеккеге бер көн
Сулап ята тарих һавасын.

Эпохалар исе сеңгән дивар...
Чуен һәйкәл сыман хуҗасы
Еллар буе уйлап утыра да
Язып куя чорның догасын.

Юк, ул инде җәһәт-җәһәт кенә
Атлап йөрми ишекле-түрле.
Гәүлек буе тып-тын уйлана ул
Чорлар рухание шикелле.

Ә урамда әнә — сәясәттә
Селкенүгә сыңар бер яфрак,—
Үзгәрә дә ультра яңа заман
Руханига эзли компромат.

Хәтта шыксыз ГУЛАГ әһелләре
Ягалмаган «яман» эшләрне
Аңа тагар өчен тырышалар
 Япь-яшь «дәүләт эшлекле»ләре.

Әмма чуен һәйкәл, тайпылмыйча,
Басып тора туган җиренә,—
Халкыбызның рухи мәйданында —
Тарихларны алып иңенә.

Күр, һәйкәлнең маңгаена куна
(Тешләмәкчеме ул чуенны?!.)
Мескен черки...
...Шигырькаем, тизрәк
Ташлап кит тә мондый уенны...

һәм кереп кач горур Исәнбәтнең
Бүлмәсенә.
Анда сафлык...
Тын...
Диванында әнә карт могикан
Сулап ята тарих һавасын.

## Язга керәм

Язга керәм...
Һиктер хәвефләргә,
Борчуларга сала яз ае.
Беләм, юкса, яз ул яшәрүләр,
Саф мәхәббәт, сөю, наз ае.

Тик мин инде шактый өлкән кеше,
Күпме генә гүзәл дисеннәр —
Язның иң-иң матур көннәрендә
Арта илдә үлем-җитемнәр.

Язга керәм...

## Ут күзе

Балачакта яккан һәр учактан
Сер дә сихер белән миңа табан
Карап тора иде ут күзе...
...Учакларым калды ул чакларда.
Сихерләре чишелделәр бар да,
Хәзер серсез хәтта сер үзе...

Тик ни булды?!.
Әнә каршы якта,
Мин автобус көтеп торган чакта,
(Әй йөрәккәй, үзең бул түзем!)
Бер төркем шук яшьләр арасында
Сылу, чая бер кыз карашында
Карап тора миңа ут күзе.

## Тагын

Низаглы, шаулы заман,
Дәгъвалы, даулы заман.
Чуалчык, норсыз заман,
Тыйнаксыз, котсыз заман.

Әхлагы киткән заман,
Тәртибе беткән заман.
Яңасын төземәсә дә
Искесен сүткән заман.

Җете кызыл төсләрне дә
Уңдыра торган заман.
«Бөек»ләрнең яңагына
Гондыра торган заман.

Үч алырга әвәсләрне
Котырта торган заман.
Үз братын төп башына
Утырта торган заман.

Забастовка заманы,
Эшне ташлау заманы.
Кемдер — шуннан файдаланып —
Байый башлау заманы.

Ә ил бөлү заманы,
Шуны белү заманы,
Шуны белеп, шуны күреп,
Шуннан көлү заманы.

Әй заманы, заманы,
Азау ярды заманы...
Тагын безгә туры килде
Заманының яманы!

# Нури Арслан

## Көз

*«Үксез бозау асрасаң,—*
*Авызың-борының май итәр...»*

Халык сүзе.

Яфраклар ява, яфраклар,
Сап-сары.
Житте көзгә ачар чаклар
Капканы.

Пар атларың белән, Көзем,
Кер дә кит,
Үз сыйларың белән үзең
Кунак ит.

Тук бул, Илем, имин-сау бул
Бу көз дә:

Әкиятле «Үксез бозау» бул,
Көз, безгә.

Авыз-борынны әйдә әле
Май ит син.
Хезмәт сөйгән һәр бәндәне
Бай ит син.

Көз килгән, пар атлар жигеп,
Сап-сары.
Яле, ачып жибәр киереп
Капканы!

*1988.*

## Толлык турында

Кем кайчан тол калачагын белә?
Белерсең, бар! дөнья хәлләрен:
Туган көннән башлап күкрәгеңә
Терәп торгач язмыш хәнжәрен...

Нәрсә килер димсез минем кулдан,
Тол калдырса әгәр күрәчәк?
Лирикам бар, һич ташламый торган!
Егәр бирсә тик ул бирәчәк.

Ә лирикаң китсә, ул чагында
Кем үз итәр жырсыз толыңны?

Жырсыз шагыйрь — утсыз учак кына...
Үзең коткар, тәңрем, колыңны!

Сүрелә икән учак — жылытмый ул,
Күмерләре балкып торса да.
Шуңа, шагыйрь, булсаң ялкынлы бул,
Шунда сиңа алтын бусага!

Ташлап китмәс шунда лирикаң да,
Ялгыз итмәс тугры сөйгәнең,—
Юкса тол итсәң дә, тол калсаң да
Аямый ул дөнья дигәнең...

*1990.*

## Карлыгачлар

Карлыгачлар! Бик ярата идем
Зифа сынлы дала кошларын.
Аз булмады бала чакта минем
Алар белән бергә очканым.

Иксез-чиксез бит ул казакъ иле!
Очар өчен дала тар сыман —
Карлыгачлар атылып чыга иде
Жилеп барган атлар астыннан.

Тәгәрмәчләр арасыннан үтеп,
Житезлеген уйнап күрсәтеп
Оча иде алар, кызык итеп,
Берсен-берсе гүя үртәшеп.

Арбаларда инде дала кичмим
Карлыгачлар белән бергәләп:
Алар күренмиләр, мин дә очмыйм,
Талпынса да күңел-күбәләк.

1989.

## Алматы[1] кызына

Айналаен, Гөл-Хәдичә, сүзләрең бал,—
Авыз итәр өчен балдан җаным комар:
Тыңлыйм сине,— бетә бөтен кайгыларым,
Әйтерсең лә күкрәгемә тактың томар.[2]

Тауларында боздан бәллүр балкып тора,
Итәгендә ак чәчәкләр атып тора.
Ике битең Алматының алмасыдай,
Пәризаттай тылсымың гел тартып тора.

Ни кадәрле уен-көлке, калҗының[3] бар!
Калҗыныңны тыңлый-тыңлый алҗуым бар;
Алҗымаслык акын бармы сине күреп,
Һәр чичәнгә илһам бирер җан җылың бар!

Ала-Таудан, Идел дигән торактан син:
Татар, казакъ кабызган ал чырактан син,
Үскәнсең киң далада иркен сулап,
Тугансың толпар белән поректан син!

Нектарыңнан акылым җуеп, Гөл-Хәдичә,
Очар идем бал кортыдай көндез-кичә...
Син чәчәкләр алиһәсе ил багында!
Я раббым! Килә икән бәхет килсә!

*1989.*

## Гамадрил

Тимер читлек. Егермеләп маймыл.
Иңе-буе ун ат камар җир.
Кайгыртасы түгел — ризыклар мул...
Хуҗа монда ата гамадрил.[4]

Хатыннары, барча бала-чага
Бер-берсенең арка тирәсен
Кашый торгач, күпме рәхәт таба!
Тату алар,— тик күз тимәсен.

Үзләренә күпме шатлык иңгән!
Кайгылы тик ялгыз карт ана,—
Күпме маймыл аның сөтен имгән:
Ә хәзер күз салсын кем аңа?!.

Хәрәкәтсез утыра бер почмакта
Шул таш булып каткан мумия...
Кайчандыр барчасын сөйгән-баккан,
Хәзер аңа чит-ят бу оя...

И кызгандым мескен бу маймылны,
Уртаклашыр идем хәсрәтен:
Мөмкин түгел тик коткару моны
Каргап кына картлык зәхмәтен.

Җан тетрәткеч яман маймыл хәле,—
Безгә дә хас булса бу әгәр!..
Кызганычка каршы бар шул әле
Гамадрилга охшаш бәндәләр...

1989.

---

1. Алма-Ата — җырда, гади сөйләшкәндә Алматы дип әйтелә.
2 Томар — бөти, талисман.
3 Калҗың — тапкыр, шаян сүз.
4 Гамадрил — павиан маймылларының бер төре.

## Нияз Акмал

# КҮГӘРЧЕН СӨТЕ

ПОВЕСТЬ

### IX



Төштән соң Таһирга шалтыратып әйттеләр: билетлар алынган, алар иртәгә юлга чыгарга тиеш. Бу хәбәргә Таһир шатланды гына. Димәк, ул инде иртәгә шәһәрдә булмаячак, Хәбирне ул үз өендә каршы алмаячак. Ә бүген... Бүген ул, һичшиксез, соңлап кайтыр. Хәбир килсә дә, аның өйдә түгеллеген белгәч, кире борылып китәр. Ә иртәгә... Иртәгә — юлга! Өйдән, өйдәге өнсез бушлыктан, икеләнүләрдән, әрнүле халәттән аерылып тору Таһирга күптәннән кирәк иде инде. Ул хәтта үзен өлкә комитеты комиссиясенә кертүчеләргә эчтән генә рәхмәт укыды.

Ул төнге унберләрдә генә кайтты. Өйдә беркемнең дә юклыгын белгәч, күршеләргә ишек шакыды: Минзилә, үзе соңлап кайтасы булса, Рөстәмне еш кына шуларга кертеп калдыра иде.

— Бала йоклый, ярар, бездә генә кунып чыксын инде, уятып тормыйк,— дип пышылдады ишек ачкан күрше хатын. Аннан соң Таһирга карап торды. «Икегез тиң төнозын кайтмый йөрисез бит, әй, исәрбашлар, исәрбашлар!..» — ди иде аның бу карашы. Өйдә тавышгауга ишетелмәгәч, бу хатын аларның хәлен белергә тиеш түгел иде түгелен. Ләкин уллары Рөстәм бар бит. Ул еш кына монда кала. Ә бала булган җирдә сер торамыни?!.

Минзилә кайтканда Таһир яткан иде инде. Ишек янында әкрен генә чишенде. Ни сәбәптәндер, кухня ягына кереп чыкты. Аннан соң ишек янагына килеп сөялде.

— Йоклыйсыңмы? — диде ул бераздан. Таһир моны үзенчә аңлады:

— Кергән идем күршегә. Әйтте: йокласын инде, йоклап чыксын, диде. Алмадым малайны, анда калдырдым.

Минзилә һаман урыныннан кузгалмады. Таһир сәерсенде: хатыны күптән инде аның бүлмәсенә якын килми, юньләп сөйләшми, үзе башлап сүз катмый иде.

---

Ахыры. Башы журналның 8 нче санында.

— Син нишләп минем кайда йөрүем турында сорамыйсың? — диде Минзилә. Таһир, гаҗәпләнеп, башын күтәрде.

— Ә миңа барыбер, Минзилә. Кызыксынудан ни мәгънә? — диде ул, йөзенә искитмәгән кыяфәт салып.— Син беләсең бит... Мин әле синең өйдә булмавыңа шатландым гына бүген.

— Нишләп?

— Шулай... Бүген мин...— Таһир Хәбирне күрүе турында әйтеп ычкындыра язуын, сүзне бүтәнгә борды: — Бүген мин үзем дә соң кайттым.

Минзилә якынрак килде, Таһирның янәшәсенә утырды:

— Берәр сөяркә таптыңмы әллә? — дип, исәрләнеп көлде, иренең чәченнән сыйпады. Таһир аның кулын читкә этәрде:

— Синнән аракы исе килә, бар ят, йокла, аргансыңдыр...

«Үртәшә белә башлаган бу...» — дип уйлады Минзилә, иренең тавышында мәсхәрә төсмере тоеп. Аннан соң кинәт тагын шуны сизде: үзеңнеке дип исәпләгән, синеке булган, сиңа бәйле булган, синең өчен яши торган кешене югалту, ни генә әйтсәң дә, кыен икән... Менә көннәрдән бер көнне алар инде бергә тормый башларлар. Таһир инде Минзилә өчен чит бер кешегә әйләнер... Кем булыр ул шул чакта Минзилә өчен? Ә Минзилә аның өчен кем булыр?

Ни гаҗәп, үзе күптән инде бүтән бер кешене тапкан булса да, Таһирны көнли иде ул. Аның үзен түгел, ә бәлки иренең читтә булачагын, башка хатын-кызларның аңа буйдак ир дип караячагын, күзкаш уйнатачагын уйлап-кузаллап көнли иде. «Ни хакың бар синең? — дип тынычландырырыга тырыша иде Минзилә үзен әнә шул сәер һәм астыртын көнчелеге кузгалган чакта.— Син бит инде аңа үзеңнең аерылышачагыңны, Саттар янына күчеп китәчәгеңне әйттең. Син бит инде үзең үк башка кеше янына — Саттар янына ашкынасың. Хәзер инде син Таһир өчен түгел, Таһир синең өчен түгел...» Минзилә үз көнләшүен аңларга тырышканда бер нәрсәне тоя язды: ул шуннан — нәкъ менә Таһирның үзе өчен булмавыннан көнләшә икән бит. Дөресрәге, Таһирның да бүтән бер кеше белән очрашу ихтималы булуы, шуны төгәл генә белмәве, билгесезлек пәрдәсе көнләштерә, васвасәгә сала иде бугай аны. «Шулай да, беләсе иде,— дип үртәлә иде Минзилә еш кына.— Башка бер хатын-кыз белән булды микән ул берәр тапкыр? Юктыр! Юктыр, Таһир андыйга бара алмас.»

— Таһир...— диде Минзилә, иренең юрганын тартып.— Без инде аерылышабыз, үзең беләсең. Тик син миңа әйт әле: хыянәт иттеңме син миңа берәр тапкыр, юкмы?

— Синнән аракы исе килә, Минзилә,— диде Таһир коры гына.— Сүзләрең дә — исерек сүзләре. Борчыма, үртәмә мине. Бар, ят. Без хәзер чит кешеләр синең белән.

— Ә без әле законлы рәвештә аерылышмаган.

— Табигатьнең үз законы бар.

— Димәк, әйтмисең инде? Ә әйтсәң ни була? Шуны гына әйт син: үбештеңме миннән башка берәр хатын-кыз белән, юкмы?

— Үбештем. Булды андый хәл.

— Кем белән? — Минзиләнең тавышы ук үзгәреп куйды.— Кем белән икәнен генә әйт!

— Син аны белмисең. Яшь кыз иде, унҗидесен тутырган. Яр буенда үбештек, Казан елгасы буенда.

— Унҗиде яшьлек кыз беләнме?! — Минзилә шаркылдап көлеп җибәрде, тыела алмыйча көлде.— Алдыйсың! Булмаган, булмаган! Юк сүз сөйлисең, ышанмыйм!..

Шулай көлде Минзилә, ә үзенең йөрәге чәнчеп куйды. Таһир аның соравына җавап бирде, ә билгесезлек — аны көнләшергә мәҗбүр иткән билгесезлек калды.

Хатыны чыгып киткәч тә Таһир уйланып ятты. Ни өчен сүз баш-

лады ул бүген? Ни өчен әллә нинди тузга язмаган нәрсәләр сораштыра? Унҗиде яшьлек кыз белән... Таһир әлеге кызны аермачык күз алдына китерде. Әйе, булды андый хәл, үбеште Таһир аның белән.

Минзиләне югалта баруын авыр кичерде Таһир. Аның үзеннән суынганын, каядыр читкә ашкынганын тоеп әрнеде. Бигрәк тә авыр, бигрәк тә ямансу булган чакларда ресторанга кереп утыра, ялгызы гына шәраб белән юана торган булып китте. Август ае, җылы август ае кергән иде. Беркөнне ул, Минзиләнең беренче тапкыр төн уртасында кайтып керүеннән соң, эшен эшли алмый, фикерен туплый алмый йөрде. Минзиләнең карашы белән очрашу, аның кызганулы һәм гаепле бер караш белән үтеп-сүтеп киткән күзләрен күрү авыр булачагын алдан тоеп интекте.

Юк, өйгә кайтасы килми иде аның ул көнне. Минзилә белән бер өйдә булу, аны күреп тору коточкыч бер нәрсә булып тоелды.

— Әйдә, Таһир,— диде ул үз-үзенә.— Синең хәзер «юар» нәрсәләрең күп. Хатыныңны югалтуны да, улыңны югалтуны да бергә юарсың,— диде. Ресторанга берүзе, иптәшсез-дуссыз, ялгызы гына кереп китте.

Залда буш өстәлләр күп. Таһир аулаграк урынны сайлады.

Аңа уйларга кирәк иде. Дөресрәге, уйларга кирәклеген ул инде күптән аңлап, тоеп, сизенеп йөри, әмма шул хакта ныклап уйланырга әлегә кадәр куркып тора иде. Ни өчен шулай килеп чыкты? Ни өчен Минзилә кинәт кенә үзгәреп куйды? Әллә кинәттән генә түгелме? Алай дисәң... Аралар электән үк суына, электән үк катлаулана башлаган иде түгелме? Нәрсә булды Минзиләгә, нәрсә булды?

Аның сеңлесен, Сәрияне күз алдына китерде Таһир. Сәрия әле июль аенда гына аларда торган, институтка керергә, имтиханнар бирергә, имтиханнарга әзерләнергә килгән иде. Ул имтиханга әзерләнгәндә Минзилә шактый ашады Таһирның колак итен:

— Үзең, галим мин, дип йөрисең, үзең шул кызга ярдәм дә итә алмыйсың! Кем соң, син?! — дип бәйләнде.— Күрәсең бит, тәмам ябыкты бала укый-укый. Шулай укып та керәлмәса, ояты ни тора!

— Укыса, керер,— диде Таһир.— Сәрия башлы кыз ул.

— Ә син аны шулай интектереп кенә кертергә уйлыйсыңмы? Синең бит анда, университетта, танышларың муеннан ашкан! Сөйләшсәң ни була?! Телең корырмы?

Таһир бераздан балдызы әзерләнеп яткан бүлмәгә керде. Әйтте:

— Балдыз,— диде,— дөресен генә әйт әле, минем ярдәмем кирәкме сиңа, юкмы? Әллә үзем дә укып керә алам, дип ышанасыңмы?

— Җизни,— диде балдызы.— Әгәр син анда, университетта, минем өчен сөйләшеп куйсаң, бер генә имтиханны да биреп тормыйм, шундук кайтып китәм!..

Таһир инде шактый эчте, әмма исерәлмый интекте.

— Әйе, балдыз акыллырак шул,— дип куйды ул, тагын рюмкасын тотырып. Ресторанда бу ирнең берьялгызы сөйләнеп утыруына беркем дә игътибар итмәде шикелле.

Сәрия ялгызы гына килмәгән иде укырга керергә. Авылдашы, классташы Тәлгать исемле бер яшүсмер егет белән бергә килгән иде. Тарих факультетына кермәкчеләр иде икесе дә. Менә шул Тәлгать, тулай торакка урнашкан булса да, гел килеп йөрде Таһирларга. Сизде инде Таһир: араларында нидер бар иде егет белән кызның. Тик Минзилә генә өнәп бетермәде егетне. Ул китүгә үк: «Бозау бит бу, этисе Борһан абый да шундый иде!» — диде.

Апасы белән сеңлесе арасында шактый бәхәсләр барды Тәлгать өчен. Шул бәхәс, шул тарткалашларның берсен Таһирга ныклап ишетергә туры килде. Тегеләр нык кызган, күрше бүлмәдә Таһир барлыгын тәмам онытканнар иде.

— Аның бит этисен мачы Борһан дип йөртәләр авылда. Бура

бураганда да бүрәнәне «Мрау, икяу, өчяу...» дип саный икән бит ул, мачы! — дип үчекләде Минзилә сеңлесен.— Әә син шуның малае белән авызга-авыз килгәнсең. Йә, тиңмени инде ул сиңа?

— Апа! — диде Сэрия сулышы кысылып. Таһир сизде: балдызының бу сүзе әллә каян, йөрәк түреннән үк чыкты.— Ник яратмыйсың син Тәлгатьне, дөресен генә әйт әле?!

— Минме? Ни өченме? — дип кабатлап сорады Минзилә.— Мин, сеңелкәем, беләсең килсә, синең бәхетсез булуыңны теләмим. Син инде минем ялгышымны кабатлама!

— Нинди ялгышны?

— Минем яшьлек юләрлегемне. Кешене сайлаганда, сеңелкәчкәем, дөньяның мең төрле ягын карап, уйлап сайларга кирәк.

— Ни җитми сиңа, апа? Җизни шундый әйбәт кеше, ул сине ярата, үлеп тора синең өчен. Тагын ни кирәк?!

— Ярата, имеш! Ярату белән генә барса икән бу дөнья!

— Син, апа, кешене генә түгел, үзеңне дә яратмый башлагансың икән. Син инде, шулай булгач, иң элек үзең өчен кайгыр, минем өчен кайгырма!

Минзилә, сеңлесен җитәкләп, көзге каршына тартып китерде:

— Әнә, карале, кем ул анда, йә әйт, кем?

— Мин,— диде көзгегә карап аптырашка калган Сәрия.— Мин — Сәрия...

— Юк, сеңелкәм, син түгел бу көзгедә. Анда — синең апаңның яшь чагы, юләрдән дә юләр чагы. Кайчандыр, мин дә нәкъ менә шундый идем. Мин әнә шундый чакларымны юкка әрәм иттем. Бернинди рәхәт тә күрмәдем мин үз яшьлегемдә. Синең өчен генә түгел, әнә шул әрәм үткән яшьлегем өчен дә кайгырам...

Таһир, бу сөйләшүдән соң, балдызын тулай торакка озатып куйды.

— Монда калмыйм,— дип тузынып чыгып китте ул чакта Сәрия,— анда иптәш кызлар бар, шулар белән торам, әзерләнергә дә җайлырак.

Сәрия конкурстан үтә алмады. Тәлгать тә... Икесе бергә авылга кайтып киттеләр. Сәрия әйтте: «Икенче елга киләбез, барыбер керәбез»,— диде.

Таһир, рюмкасына шәраб агызды, башын артка ташлап эчте һәм кинәт, сискәнеп, аптырап калды. Каршысында балдызы Сәрия утыра иде. Күзгә күренә мәллә?.. Таһир башын чайкап куйды: күз алдындагы томан пәрдәсе юкаргандай булды. Юк, Сәрия түгел, ләкин аңа бик охшаган, сап-сары чәчле, зур зәңгәр күзле бер яшь кенә кыз иде аның каршында.

— Син гел шулай караңгы чырайлымы, абый кеше? — диде кыз. Аның бу тупас сөйләшүендә, искитмәгән кыяфәт белән утыруында әллә нинди бер кыргый матурлык бар иде.— Ресторанга кара көеп утырыр өчен керәләрмени? Күңел ачар өчен керәләр ресторанга. Кыстасагыз, эчәм бераз...

— Гафу ит... Гафу итегез...— бу көтелмәгән яңалыктан чак кына каушап калган, үз уйларыннан әле аерылып кына килгән Таһир, ашыгып, кыз алдындагы рюмкага да шәраб салды.— Мин бит, уйга батып, сезне бөтенләй шәйләмәгәнмен, гафу...

— Әә юкка уйланып утырасыз. Уйлану хәзер модада түгел.

Кыз, Таһир эчемлек салган рюмканы иреннәренә тигереп, вак-вак йотымнар белән тәмләп кенә эчте. Таһирга күңеллерәк булып китте. Ялгызы гына, күпме эчеп тә исерә алмыйча, күңелсез уйларга тарып утырганнан соң, янәшәңдә бер сөйләшер җан иясе булу рәхәт иде.

— Син миңа ачуланма, абый кеше, бу минем өлешемә керде,— дип. Кәеф юграк чак иде. Туган көнем минем бүген.

— Ничә яшь тулды инде сиңа? — диде Таһир, үзе дә шунда ук «син»гә күчеп.

— Унҗиде. Өйдә минем туган көнне бәйрәм итеп калдылар. Ә мин чыгып качтым менә... Тәм-томнары күп иде, кызганыч...

Таһир ит белән бәрәңге салынган тәлинкәне кызның алдынарак этте:

— Син аша, кабып куй. Бәлки тагын китертербез?

— Кесәң рөхсәт итсә.

— Рөхсәт итә,— дип елмайды Таһир.— Ә син нигә алай, уйламаска кирәк, дисең?

— Ә син кем булып эшлисең? Начальникмы? Әллә...

— Мин — галим,— диде Таһир, аның бу кыз белән ни өчендер ачылып сөйләшәсе килә иде.— Син фән кешеләренә ничегрәк карыйсың?

— Бармак арасыннан. Ә нинди фән белән шөгыльләнәсең?

— Философия, иҗтимагый фәннәр тарихы, социаль психология һәм дә башка нәрсәләр инде шунда.

— Миңа ошый,— диде кыз.— Современно! Җәмгыять законнары, аралашу проблемалары, гаилә, мәхәббәт... Гомумән, кызыклы нәрсәләр. Тормышның нәкъ үзе.

— Ләкин тормыш без уйлаганга караганда шактый катлаулырак шул, сеңел.

— Беләм. Өйрәнгән саен, яңа кануннар ачкан саен, тормышны аңлау катлаулана гына бара. Шуңа күрә, өйрәнмәскә кирәк аны. Бөтенләй кагылмаска. Ничек булса, шулай бара бирсен.

— Ярамый. Алай итсәң, хаос килеп чыгачак.

— Чыксын. Хаос кайбер кануннарга караганда күп тапкырлар кызыклырак.

— Син, сеңел, шундый итеп сөйлисең, әйтерсең, үзеңнең әзер теорияң бар?

— Ә ул теория, чыннан да, бар! Мин аны үзем уйлап чыгардым. Кайберәүләргә каршы куяр өчен...

— Кызык. Кемнәргә каршы куясың инде син аны?

— Әтигә. Тагын бик күпләргә. Әйдә, эчик лутчы!

Бу юлы алар рюмкаларын чәкештерделәр.

— Яраткан кешең бармы, абый?

— Мин өйләнгән кеше.

— Өйләнгәнме, юкмы дип сорамыйм мин синнән. Яраткан кешең бармы дим? Аерманы тоймыйсыңмыни?

— Ә синең? Бармы соң яраткан кешең?

— Мин яратуга ышанмыйм. Ярату кешенең аяк-кулын бәйли. Ә хәзерге заманда кеше иректә булырга тиеш. Хистән арынган саен, кеше көчлерәк була бара, үзенең бар игътибарын үзенә генә юнәлтә, максатына таба бара. Ә ярату — әле тагын кемгәдер табынып яшәү, кемгәдер бәйле булу — ирегеңне җую дигән сүз.

— Үз-үзеңә генә төбәлеп яшәү кешене ярлы итә.Бу бит — кеше бөтенләй ялгыз, япа-ялгыз дигән сүз!

— Киресенчә, үзенә генә төбәлеп яшәгән кеше үз-үзен күбрәк аңлый. Димәк, үзе аша, дөньяны да тирәннәнрәк танып яши. Телисеңме, мин сиңа биеп күрсәтәм?! — Кыз җәһәт кенә урыныннан кузгалды.— Карап тор, абый! — дип, залда биеп йөрүчеләр арасына барып кушылды. Аның сары чәч толымнары кинәт кенә алга таба сирпелде. Алланып күренгән йөзе, шул чәч толымнары астында күмелеп, нindидер серле матурлыкка төренде. Сыгылмалы буй-сыны, дәртле көй агышына кушылып, тибрәнә башлады.

Таһир аны гаҗәпләнеп, исе итеп күзәтте. Кызның хәрәкәтләрендә аңа һич тә таныш булмаган, ул аңлап, тоеп бетерә алмаган нindидер бер гүзәллек, серле һәм тылсымлы мәгънә бар сыман иде.

Аның бию хәрәкәтләре янәшәдә биеп йөргәннәрнең хәрәкәтеннән аерылып тора. Таһир кызның биюендә үзенчәлеккә, кабатланмауга омтылыш, тарсынмау, ирекле булырга теләүне тоеп алды. «Син күбрәк эчкәнсең, Таһир!» — диде ул үз-үзенә, шушы кызның буй-сынына, кыяфәтенә чын күңелдән сокланып утыруын аңлап. Ләкин әлеге уйны шунда ук башкасы алыштырды: «Ә бит нindидер сихри, серле дөнья бар шушы биюдә! Үз фәлсәфәсенә үзе ышанып, үз ышанганын дөрес дип яшәве чагыла түгелме аның бу биюендә?! Ул — бәйсез! Ул монда беркемгә дә, хәтта үзенә сокланып утыручыларга да бәйле түгел! Бу карашлардан ул оялмый да, чирканмый да. Ул — көчле...

Таһир тагын шуңа игътибар итте: залда биючеләрнең төрле яшьтәгесе төрлечә бии иде. Ә кыз... Кыз исә үзе белән янәшәдә кара-каршы биегән егетне бөтенләй күрмәде, хәтта игътибар да итмәде. Ул үзенә төбәлгән, бары тик үзенә генә төбәлгән иде...

— Йә, ничек? — дип елмайды кыз, кире әйләнеп килгәч.

— Әйе...— дип сузды Таһир.— Синең белән бәхәсләшүе авыр, сеңел.

— Борчылма! Әти дә миңа гел шулай ди. «Синең белән бәхәсләшкәнче, багана белән сөйләшеп торуың артык»,— ди.

— Әтиең кем булып эшли синең?

— Юк, кирәкми, әйтмим. Зур кеше ул. Һәрхәлдә, ул үзе шулай дип саный. Һәм тагын — аның янәшәсендәге кайберәүләр шулай уйлый. Мин бит әтине бөтенләй диярлек күрми үстем. Өйдә булган чагын хәтерләмим дә кебек. Шул ял көннәрендә генә күрешкәли идек. Бервакыт, алтынчыда укыганда микән, дәрестән качып киттем дә әти янына чаптым. Ул анда — политик мәгариф йортында — ниндидер зур җыелышта доклад сөйләргә тиеш иде. Арткы рәткә кереп утырдым. Тыңлыйм. Ул сөйләде, ялкынланып, дәртләнеп сөйләде. Зур-зур абзыйларга, җитди абзыйларга акыл өйрәтте. Барысын да ачуланды, эшләмисез, эшли белмисез, диде. Ниндидер бер философның сүзләрен мисал итеп китерде. Яшь буынны заманга лаек итеп тәрбиялик дисәк, иң элек без һәркайсыбыз үз улыннан, үз кызыннан башларга тиеш, диде. Минем шулчак урынымнан торып: «Әти! Мин сине бик сагындым, мин сине кайчан күрермен икән?!» — дип кычкырасым килде. Ул — бит өзмәс-куймас җыелышларда йөри. Мин әнә шулай үстем. Ә беркөнне, үсә төшкәч, аның белән бер талаштым. Вак кына нәрсә өчен инде шунда... Ул миңа бык нык җикеренде: «Әһә! әтиеңә каршы әйтәсеңме?!» — ди. Инде син үсеп җиттеңмени. Мин дә әйттем: «Әйе, үсеп җиттем. Синнән башка үстем, хәзер дә синнән башка яшәрмен!» — дидем. Хәзер, шуннан соң, ул минем белән сирәк сөйләшә. Минем өчен әнине генә ачулана.

— Алай... Димәк, синең бүгенге сүзләрең — әтиеңә ачу килүдән?

— Юк,— кыз иреннәрен тешләде.— Бу ачу килү янында хәзер әти чүп кенә... Мин хәзер күп нәрсәне кабул итә алмыйм. Әти әйтә: «Мин бит синең өчен тырышам, бар эшләгәнем, бар тапканым — синең өчен», ди. Ә мин аның шул тырышлыгын кире кагам. Туган көн мәҗлесеннән дә юри качып киттем. Анда алар үзләре, үз ишләре җыелган. Яратмыйм. Күңелсез алар белән.

— Әйе шул, сеңел,— дип баш селкеде Таһир. Үзенең исерә башлаганын сизеп, җитдиләнергә тырышты.— Сезнең буын шулайрак күп нәрсәне кире кага, ләкин шуның урынына бернәрсә дә тәкъдим итми.

— Нәрсәнедер тәкъдим итәчәк буын алдыннан һәммәсен дә кире кага торган буын килүе кирәк бит әле башта! Барысын да, барысын да кире кагарга кирәк! Барысын берьюлы!

— Кире кагу җиңел... Ә менә нәрсәдер тәкъдим итү, юл күрсәтү авыр.

— Ә авыр икән, нигә юл күрсәтәсез? Менә син, философ, үзең дә

белмәгән килеш, нигә кешеләргә юл күрсәтергә алындың? Кем кушты, кем сорады синнән? Минем эти дә әйтә: «Без әле моңарчы үтелмәгән, тапталмаган сукмактан атлыйбыз, шуңа күрә ялгышлар да булгалый. Әмма без халыкны дөрес юлга алып чыгарга тырышабыз, безнең эш бик авыр»,— ди. Үзе зарлана, үзе борчыла, көн-төн чаба. Ә кем кушкан аңа халыкның башына менеп утырырга. Кем әле аннан юл күрсәтүне, тапталмаган сукмактан йөрүне сораган? Үзләре белмиләр, үзләре кеше өйрәтергә алынганнар.

— Кызык кыз син...

— Кызык! Миңа эти дә шулай ди. Үзенә охшамаганым өчен үртәлә. Ә мин аны өйрәтәм: Гегельнең фәлсәфәсен аңлатам. Ул миңа аптырый: мине юләргә саный.

Таһир елмайды. Аның бәхәсләшәсе килми, кызны тыңлап утырасы килә иде. Кызып сөйләшкәндә кызның күзләре зур булып ачылып китә, кашлары уйнап-уйнап ала, иреннәре — чия кебек алсу иреннәре — мең төрле әверелеш ясый.

Кыз дәвам итте:

— Ни өчен хәзерге яшьләрнең күбесе үз ата-аналарын гаепли? Чөнки алар сизә: ата белән ана кайчандыр, яшь чакларында, үзләренең эгоистик хисләре — җенси хисләре нәтиҗәсендә гаилә корган. Гаилә туган, ата белән ананың шул ук эгоистик хисе — нәсел калдыру теләге — дөньяга бала тудырган. Бары тик шул гына. Ә инде зуррак итеп аңласак, буыннар арасында да шундый ук эгоистик хисләр ята: бер буын икенчесенә нәсел калдыра. Нәсел — бары тик нәсел, ә тормыш калдырмый. Әгәр дә бер буын икенчесенә тормыш калдыра торган булса, ничәмә-ничә еллар буена тереклек иткән кешелек мондый мәгънәсез тормышта яшәмәс иде, дөнья күптән инде матурланыр, яшәү дә күп тапкырлар күңеллерәк булыр иде.

Таһир бу кыздан мондый сүзне көтмәгән иде.

«Ә бит ул минем студентым булырлык бер кеше,— дип уйлады Таһир.— Мине өйрәтә бит...» Үзенең шушы көчсезлеген тою, үз фәлсәфәсенә нык ышанган шушы кызга кайтарып әйтерлек сүз таба алмавы ошап бетмәде аңа.

— Ярар, сеңел,— диде ул.— Фәлсәфәгә тирән кермик әле. Дөресен генә әйткәндә, минем болай да кәефсез йөргән чаклар бу арада. Чынлап әйтәм.

— Нәрсә, әчеп айныткычка эләктеңме әллә? Эшеңә язу килгәнме? — дип үртәште кыз. Хәбирнең баш чайкавыннан соң, янә тезеп китте: — Туганнарың авырыймы? Юкмы? Алайса, абзый, синең кайгың бер генә инде: хатының белән бозылышкансың син!

Таһир сискәнеп киткәндәй булды. Кыз, аның күзләренә туры карап, зәһәр елмая иде.

— Менә син, абый,— диде кыз, каушап калган Таһир белән рюмка чәкештереп,— мине гел кире кага торган, берни дә тәкъдим итә белмәгән буын вәкиле дип әйттең инде. Юк, ялгыштың. Тәкъдим итә беләм мин. Тик башта бер нәрсәне ачыклыйсы бар: син куркакмы?

— Белмим. Мөгаен, юктыр...— диде Таһир, бу көтелмәгән сорауга гаҗәпләнеп. Чыннан да, куркакмы, юкмы икәнне ачыклыйсы бар түгелме? — Юк, сеңел, мин куркак түгел!

— Алайса, киттек минем белән!

— Кая?!

— Куркак булмаган кеше шундый сорау бирәме? — кыз, Таһирны җитәкләп, үзе белән алып чыгып китте. Таһир тулысы белән аның иркенә буйсынды.

— Менә, безнең оҗмах та, тәмуг та бүген шушында булачак! — диде кыз, «такси» машинасы аларны Казан елгасы ярында калдырып киткәч.— Шулай абый, куркак булмасаң, монда калыйк.

— Калыйк! — диде Таһир, үзенең дә өйгә кайтмаска җай чыгуы-

на шатланып. Ул инде «куркаклык» сүзенә ярсып өлгергән, башындагы хәмер аны кузгаткан, үзенең куркак булмавын исбатлар дәрәҗәгә җиткергән иде.

— Учак ягыйк! — диде кыз. Бергәләп чыбык-чабык җыйдылар, үзләре дә белмичә, тиктомалдан көлештеләр. Таһир шырпы кабызды, тырышты, бер сүндереп, бер яндырып, ниһаять, учак тергезде. Учак янына утыргач, кыз Таһирга елышты:

— Сиңа рәхмәт, абый,— дип аның куенына керде.— Миңа бик рәхәт бүген...

Вот и встретились два одиночества,
Развели у дороги костер.
А костру разгораться не хочется —
Вот и весь, вот и весь разговор...

Кызның тавышы матур иде. «Ә ни өчен соң сөйләшкәндә аның тавышы бу кадәр үк матур яңгырамый? — дип уйлады үзалдына Таһир.— Шулай, җырда ачыла шул кеше күңеле...»

— Ә мин кызык иттем! — дип талпынды кыз, кычкырып көлеп, яр буен яңгыратты.— Син сизденме, мин күрше өстәлдәге бер шешәне сумкама тыктым бит!..

Чиратлашып, шешә авызыннан эчтеләр. Таһирга рәхәт, җылы иде. Ул үз куенында шушы яшь кызның кайнар тәнен тойды, нинди дер иркенлектән, аерымлыктан, төн белән һәм шушы сәер кыз белән ялгыз калудан исерде.

— Ә шулай да синең башта бүген нинди кайгы? — диде кыз, аның тезләренә башын салып.

— Сөйләп кенә аңлатырлык түгел...— дип көрсенде Таһир.

Кыз, күтәрелә төшеп, аның иреннәреннән үк үбеп алды:

— Кайгы иясе син бүген, абый...

Кыз, озак кына, күккә карап ятты. Аннан соң ак кофтасының өске төймәләрен әкрен генә ычкындырды.

— Әйбәт кеше син, абый!.. Мин бүген синеке!..

Таһир шул мәлдә кызның кочагында калды. Аның дәртле, кайнар сулышыннан Таһирның башы әйләнде, тыны кысылды. Үзенә чакырган, үзенә тарткан назлы куллар, ашыгып пышылдаган иркә сүзләр, күкрәккә һәм тәнгә кереп сыенган сыгылмалы тыгыз гәүдә, сирпелеп төшкән, авызга-иренгә кергән чәчләр, хушбуй һәм яшь тән исе — болар барысы да бергә җыелып, Таһирны каядыр ләззәтле бушлыкка, томанга батыра иде. Һәм Таһир, әлеге бушлыкта таяныр урын таба алмыйча, кинәт сискәнеп, кызның йөзенә карады. Аларның күз карашы бер генә мизгелгә, әмма бик якыннан очрашты. Алар — бер-берсе белән очраклы гына күрешкән, кителмәгәндә генә танышып якынайган ике зат — бу мизгелдә бер-беренә ике яктан, ике караңгылыктан карап торалар кебек иде. Шуны, шушы халәтне тоеп өлгергән Таһирның башына кинәт кан саугандай булды. «Менә ул, менә ул синең бәхетең һәм бәхетсезлегең! — Әлеге уйлар, кан агышы белән бергә, аның баш миенә кереп тулды.— Менә ул — синең ише галимнәрне уйландырып, калын-калын китаплар яздырган буынның бер вәкиле. Аны бүген бернәрсә дә куркытмый. Ул бүген синеке булырга тели. Ләкин иртәгә инде ул синеке булмаячак. Ул үз юлы белән китәчәк. Ул үзен азат һәм ирекле итеп тоя. Ул үзенең ялгызын да үз азатлыгына кайтарып калдыра, аклый. Аһ, аның бу нәфис, йомшак куллары нинди көчле! Ах, аның бу серле карашы ничек тирән! Ә син?.. Син — көчсез. Син үз фәлсәфәңне, ышанганыңны бары тик телдә, кәгазьдә генә яклау мөмкинлеге белән яшисең. Син аны эштә күрсәтә алмыйсың! Бүген син — көчсез адәм — менә шушы ирекле һәм көчле зат алдында җиңелеп калачаксың. Син, сүздә бер төрле сөйләп, эштә аның фәлсәфәсенә буйсыначаксың!..

Таһир, үзенең карашын яшерер өчен, ашыгып-ашыгып кызның маңгаеннан, битеннән, күзләреннән үпте. Һәм шулай ук ашыгып:

— Кирәкми!.. Кирәкми, сеңелкәш!.. Син нәрсә? Без мондый эштән югарырак булырга тиеш! Кирәкми, сеңелкәш...— дип кабатлады.

Кыз озак елады. Таһирның күкрәгенә капланып, бер үксеп, бер тынып, озак сулкылдады. Таһир сизде: чистарта торган, савыктыра торган керсез күз яшьләре иде бу.

— Синең яраткан кешең бар идеме? — диде кыз, елап туйгач. Һәм бу юлы ул Таһирның күзенә туры карамады.

— Бар иде, сеңлем.

— Минем дә бар иде...

Таһир, әгәр бүтән чак булса, кызның бу сүзләреннән көлгән булыр, йә булмаса, үгет-нәсыйхәт биреп: «Кит инде, синең кебек яшь кызга шулай сөйләү ярыймы? Синең әле бөтен яшьлегең алда бит»,— дип юаткан булыр иде. Ләкин ул көлмәде. Юатмады да. Алар бүген икесе дә бер үк хәлдә, бертигез дәрәҗәдә, бер үк бәхетсезлеккә юлыккан кеше иделәр.

— Су коенасым килә! — диде кыз кинәт.— Син коенасыңмы?!

Таһирның җавабын да көтеп тормастан, кыз яр буена таба китте, тар чалбарын, юка кофтасын салып ташлады, әкрен генә су эченә кереп китте. Аның гәүдәсе, буй-сыны, иңнәренә җәелеп төшкән толымнары — барысы бергә кушылып, шәүлә сыман гына булып күренә иде. Таһирның күңелендә ниндидер бер рәхәтлек, чаялык, малайлык, шатлык калкып чыкты.

— Әй, Су анасы! — дип кычкырды ул әлеге шәүлә артыннан.— Кайда минем алтын тарак?!.

Һәм Таһир, малайларча сикерә-сикерә, кулларын болгый-болгый, суны чәчрәтә-чәчрәтә, кыз артыннан елгага ташланды.

Коенып чыккач, учак янында җылынып утырдылар. Икесе дә дер-дер калтырыйлар, икесе дә бәхетле елмаялар иде. Тузанга, чүпкә батып, аунап-җимерелеп яткан бүлмәне чистартып-юып чыккан кеше идәнгә аяк басарга ничек куркып торса, алар да шулай, бер-берсенә дәшәргә, кагылырга кыймыйча шактый озак утырдылар.

— Утка табындык, суга табындык — без бүген мәҗүсиләр! — дип елмайды кыз, ниһаять.

Таһир һаман да калтыранып-туңып утырган кызның иңнәреннән алды, үзенә якынрак тартты:

— Мәҗүсиләр...

Таң алдыннан шәһәргә күтәрелделәр. «Такси» тоттылар. Кыз шәһәр үзәгендә төшеп калды.

— Исемең ничек булды синең? — дип кычкырды Таһир, кузгалып китәр алдыннан гына.— Сорамадым да бит!..

— Мин сине үзем эзләп табармын! — дип җавап кайтарды кыз һәм аны кул болгап озатып калды.

Минзиләгә унҗиде яшьлек кыз белән үбешүен әйткәндә әнә шул хәлне искә төшерде Таһир. Әлеге кызны ул бүтән очратмады, күрмәде, сөйләшмәде. Әмма ул — Таһир исемен дә белә алмый калган кыз — кайдадыр шушында, якын тирәдә генә йөри кебек тоела. Таһир кайчак урамда артына борылып карый — артыннан әлеге кыз күзәтә сыман. Бер төркем яшьләр узып барса — шунда текәлә, кызны алар арасыннан эзли. Таныш төсмер күреп, башкаларның йөзенә текәлә... Бу юктан гына түгел, нидер җитми, нидер җитенкерәми Таһирга. Бәлки нәкъ менә шул кыз белән сөйләшкәндәй ачылып сөйләшү, иптәшлек, дуслык җитмидер?.. Бар иде аның җан дусты... Хәбир бар иде. Югалтты аны Таһир. Очраштылар — әмма Таһир аны үз өендә каршыларга куркып тора. Нилектән шулай соң бу дөнья?

Таһир, үртәлеп, озак уйланып ятты. Үзен тынычландырыр өчен, каян булса да бер-бер шатлыклырак уй табарга теләде. Һәм тапты:

иртәгә ул обком комиссиясе белән кайсыдыр бер районга китәргә, өйдәге бу киеренкелектән, Хәбирнең килеп чыгу мөмкинлеге турындагы уйлардан берьюлы котылырга тиеш иде...

## X

Минзиләне дә бу көннәрдә борчып торган нәрсәләр шактый иде. Аның әле Таһир белән үзара квартираны бүлешү турында сөйләшәсе бар. Башта ул, кызган хәлдә, әйтеп ташлады: «Безгә квартира да, җиһаз да кирәкми! Үзеңә булсын. Без улым белән күченеп кенә китәбез. Тик кара аны, Рөстәм мәсьәләсендә судлашып-нитеп йөрмә тагын!» — диде. Юк, кызган баштан гына түгел, уйлап-үлчәп тә әйткән булгандыр Минзилә квартира мәсьәләсен. Саттарның зур, киң квартирасы аларны тулысынча сыйдыра ала кебек иде. Шулай ук җиһаз-мазары да әзер, дип уйлады ул. Ничектер болар барысы да үзеннән-үзе шулай аңлашыла: Минзилә, Таһирны элекке ире буларак җәлләп, квартираны аңа калдырып китәргә тиеш кебек иде. Әлбәттә, шулай итсәләр, Минзиләнең үзенә дә бик күпкә җиңелрәк буласы. Әмма Саттар бит... Ул бүтәнчәрәк тели.

— Мөмкинлек барында — бүлешергә кирәк,— диде ул, бу турыда сүз чыккач. Чөнки ул бүлмә, иртәме-соңмы, Рөстәмгә кирәк булачак.

Әйе, Саттар бераз кырысрак кеше шул. Ә менә Таһир Минзиләгә беркайчан да авыр сүз әйтмәде. Бер уйласаң, Минзилә алдында гаебе дә юк Таһирның. «Ә минем, Рөстәмнең ни гаебе бар? — дип үрталде Минзилә.— Без бит Таһирның үзен түгел, ә бәлки аның үзенчә яшәвен яратмыйча ташлап китәбез. Ә безнең бәхетле булырга хакыбыз бар, бар!..» Таһир шуны аңламый, аңларга да теләми. Ул бары тик үзенең фәненә кереп чумган, ул бу дөньяда, әйтерсең, яшәми. Ни эшли, ни яза, ник яза — белгән юк. Ә гомер бер генә килә. Үтә дә китә ул гомер дигәнең. Таһир шуны аңламый, аңлый белми. Ә бит, югыйсә, илле генә ел үткәч тә шундый сорау куелырга мөмкин: булганмы бу дөньяда Таһир Корбанов дигән кеше? Әллә юкмы? Булганмы аның гыйльми эшләре? Кирәкме алар бу дөньяга? Кемгә кирәк булыр? Кем кызыксыныр? «Мин фән өчен яшим, халык өчен эшлим»,— ди Таһир үзе. Кирәкме соң ул халыкка аның эше, юкмы — бу турыда уйламый. Аның ул язган-сызганнары калса да, шул тузанлы архивларда гына калыр. Кешеләрнең тормышы үзенчә барыр. Һәркем, дөньяга килгәненә шатланып, бәхетле тормышта яшәп калырга тырышыр. Шуны аңламый Таһир. Шуны аңламавы белән үзе дә газап чигә, башкаларны да интектерә. Ә бит кеше җирдә яшәп тә калырга тиеш әле. Их, Таһир, Таһир!..

Саттар бераз дорфарак. Әлбәттә, анысы инде характер эше. Әмма ул хатын-кызның да, тормышның да кадерен, дәрәҗәсен нык аңлый торган кеше. Аның белән бергә чакта Минзилә бернинди авырлык кичерми, борчылмый, хафаланмый, тулысынча ир кешегә таяна. Минзиләгә еш кына шулай тоела: әйтерсең, Саттар өчен бу дөньяда бер генә дә хәл ителмәслек, чишелмәслек мәсьәлә юк.

Минзилә Саттар белән узган ел, сентябрь аенда көньякта ял иткәндә танышты. Аның өчен башта очраклылык булып тоелган бу танышу, тора-бара, үзеннән-үзе шулай булырга тиешле бер вакыйга, язмыш кушуы булып тоела башлады.

Ул елны Таһир үзенең диссертациясен яклаган, куанып, очынып, ару-талуларын онытып йөри иде. Минзилә, җәйге ялын алмыйча, аның барлык эшләре тәгәлләнгәнен көтеп йөрде. Моның сәбәбе бар иде: ул мең мәртәбә үгетләп, мең тапкыр каргап, Таһирны көньякка ялга барырга күндерде. Рөстәмне дә алып, бергәләп ял итеп кайтырга иде исәпләре. Хатын-кыз тырышса, кәсебенә керешсә — барысын да

булдыра, диләр. Ял дигән нәрсәнең, бигрәк тә көньякта ял итүнең ни икәнен дә белмәгән Таһир көнне, тырышты: әллә ничә тапкыр гариза язып, әллә нинди ишекләрне кагып, көньякка путевкалар юллады.

Ләкин аларга бергә ял итәргә язмаган булган икән. Инде путевкаларны тотырып йөргән бер вакытта, Таһирны партиянең өлкә комитетына чакырдылар. Алма-Атада озачак семинарга — әлеге дә баягы атеистлар киңәшмәсенә барырга тәкъдим иттеләр. Карышып, аклanып маташкан Таһирның юлын берничә сүз белән кистеләр: «Сездән башка кеше юк, ялыгызны кайтуга ук алырсыз, без сезгә үзебез үк путевка табып бирербез»,— диделәр.

Бу хәбәрне каргыш сүзләре һәм күз яшьләре белән каршылаган Минзиләне Таһир үзе дә кызганды:

— Уйлаганны өзмик инде, алайса, үзең генә булса да барырсың. Кайгырма, Рөстәм белән бит, ярдәмчең була,— диде.

Таһир семинарга киткәч, Минзилә үзенчә хәл итте: «Рөстәм нәрсә? Юлда авырып китәргә мөмкин. Аннан соң көньяк һавасына ияләшү дә бала өчен җиңел булмас»,— дип уйлады. Шулай уйлады да, улын авылга кайтарып куйды, көньякка үзе генә китте.

Әнә шулай итеп, үзе, үз теләге белән озатып җибәрде Таһир аны язмыш кочагына.

Ләкин мондый очрашу булачагын Таһир түгел, хәтта Минзилә үзе дә белми иде әле.

Ул көнне Минзилә шәһәргә чыгып кайтырга булды. Ял йортында ул әле беркем белән дә танышмаган, аралашып өлгермәгән иде. Шәһәргә барып, шәһәрне күреп, кибетләрендә йөреп кайту иде теләге.

Әнә шулай шәһәрдә йөреп, арып-талып, тәмам хәлсезләнеп кайтып килгәндә ял йортыннан ерак булмаган бер кафега керде. Кичке ашка ул инде соңарган иде, шунда гына тамак ялгап чыгарга уйлады. Өстәл янында үзенчә уйланып, онытылып утырганда аның өстәленә бер шешә «Шампанское» һәм тартмалы «Птичье молоко» конфеты китереп куйдылар. Минзилә, аптырап, як-ягына каранды. Өстәл янында ул үзе генә утыра иде. Гаҗәпләнеп, официантка текәлде:

— Гафу итегез... Мин боларны сорамадым бит?..

Официант дәшмәде. Шешәне җайлы гына ачып, Минзилә алдындагы рюмкага шәраб агызды.

— Мин сезне аңламыйм! — диде бөтенләй каушап калган Минзилә.— Сез ялгыштыгыз! Мин моңа заказ бирмәгән идем!

Официант елмайды:

— Бу — сезне чын күңелдән ихтирам иткән бер ир-егеттән,— дип пышылдады, ым кагып, күрше өстәлгә күрсәтте. Минзилә ялт итеп шунда карады. Анда берничә ир, гамьсез генә сөйләшеп, ашап-эчеп утыралар иде. Әлеге ирләрнең берсе, Минзиләнең бу якка каравын сизеп, елмаеп баш какты.

Минзилә нык каушады, курыкты. Аның әле мондый хәлләрне күргәне юк иде. Үзе дә сизмәстән, дөресрәге, нишләргә белмәстән, әлеге кешегә ым кагып җавап кайтарды. Эчемлеккә дә, конфетка да кагылмады. Тиз-тиз генә тамак ялгады да, ишеккә таба юнәлде.

Ишек катында аны әлеге ир куып җитте, юлына аркылы төште:

— Гафу үтенәм,— диде ул ягымлы һәм ачык, көр тавыш белән.— Мин үземнең бу рөхсәтсез эшем белән сезне үпкәләттем бугай. Тик ышаныгыз: теләгем рәнҗетү түгел иде. Безнең дус-ишләр арасында шундый гадәт инде: күңеленә хуш килгән берәр кешегә сюрприз-күчтәнәч ясау... Үпкәләткән булсам, гафу итегез...

— Зарар юк, зарар юк...— Минзилә, тагын да ныграк каушап, китәргә ашыкты.

— Гафу итегез... Күчтәнәчне кире кагу матур эш түгел. «Шампанское» теләмәсәгез, конфетлардан гына булса да баш тартмагыз. Зинһар...— Ир кулын изәп ишарә ясауга, официант өстәлдәге конфет

тартмасын аңа китереп тоттырды.— Алыгыз, зинһар... Бу — сезнеке!

Шул көннән соң алар тагын очраштылар. Саттар Үтәбаев та Казан кешесе булып чыкты. Ул да монда ял йортына килгән икән. Якташлар, димәк. Бәлки шуңадыр, икенче очрашуда Минзилә үзен иркенрәк тотты.

Саттар аны көн саен үзе белән йөртте. Курорт шәһәренә әллә ни зур байлык белән килмәгән Минзилә өчен Саттар алып барган урыннарда йөрү, әлбәттә, төштә дә тәтемәс иде. Саттар акчаны жәлләмичә, кызганмыйча тота. Минзилә үзен ниндидер кабалага, әҗәткә кереп барган кеше кебек итеп тоя иде кайчак. Әмма шушы көтелмәгән муллык, иркенлек аны һаман-һаман үзенә тарта барды. Ә теге кабала һәм әҗәт мәсьәләсендә Минзилә үзен шулай дип тынычландырды: «Ә нәрсә?.. Ул бит үзе сорап алмый аның акчасын. Ул барган җирләргә, иптәш буларак, якташ буларак йөри. Гомумән, берни начар уе да юк бу кешенең Минзиләгә карата. Яше дә инде шактый гына, иллегә таба йөз тоткан. Кешегә һәрчак янәшәдә бер иптәш булу кирәк, шуңа йөртәдер ул Минзиләне үзе белән...» Әмма Минзилә ялгышты һәм үзенең бу ялгышын Саттар аңа кыйммәтле муенса бүләк иткән көнне тойды. Шул кичне Саттар аны төнге елгада су коенырга чакырды. Минзилә өчен бу ир белән төнлә су коену да оят, шул ук вакытта баш тарту да читен иде. Елга ярына ул үз икеләнүләрен җиңә-җиңә төште. «Юк-юк, ярамый! — дип карышты ул үз-үзенә.— Ни генә булмасын, Таһир — синең ирең! Бу бит Таһир алдында хыянәт булачак!..» Менә шушы коточкыч уйда тукталып, Минзилә шулай хәл итте: юк, су коенмаячак ул, Саттарның коенып чыкканын көтеп, яр буенда гына утырачак...

— Суы салкын,— диде ул, аягын суга тыгып карап.— Мин коенмыйм, салкын судан куркам мин...

Саттар шулчак аны биленнән эләктереп алды:

— Юк ла!.. Башта гына шулай салкын тоела ул... Бер чирканчык алгач, үтә дә китә,— дип, аны елга эченә таба сөйрәде...

Су коенып чыккач, Минзилә комга капланып ятты. Саттарның юеш тәнен дә чәчләре, иңнәре, җилкәсе, аяклары буйлап узган кулын да бөтенләй тоймады. Әйтерсең, бөтен гәүдәсе тораташка әйләнгән, күкрәгенә сап-салкын кургаш утырган иде аның. «Хыянәт бит бу, хыянәт!..» — дип иреннәрен тешләде Минзилә. Ләкин иреннәреннән саркып чыккан кан тәме дә, күзләреннән бәреп чыккан кайнар яшь тә күкрәктәге кургашны эретә алмады. Саттар, аның бу салкынлыгыннан ризасызланып, һаман котырынды, һаман әйдәде, күкрәгеннән үпте, ыңгырашып-ыңгырашып, аны кузгатырга, уятырга, үзенә теләктәш итәргә тырышты. Минзиләнең теләксез генә бирелүе, җавапсыз калуы аны котырта, ярсыта иде.

Ниһаять, Саттар тынды. Авыр ыңгырашып, чалкан әйләнеп ятты.

Минзилә беренче чирканчыкны әнә шулай алды. Һәм, чыннан да, Саттарның сүзләре дөрескә чыкты: әнә шул беренче чирканчыктан соң, барысы да узды — курорт шәһәренең май кебек җылы кичләре Минзиләне үзенә бөтереп алды.

Алар инде бер-беренә үзләренең гаилә хәлләрен сөйләп ташладылар, якынайдылар. Саттар үзенең аерылышкан кеше булуы, ышанычлы бер кеше табып, яңа гаилә корырга өметләнеп йөрүе турында сөйләде. Ир кадерен белгән хатын-кызларның сирәк булуыннан зарланды. Минзилә дә, ни өчендер, үз чиратында зарланып алуны кирәк тапты. Таһир белән бик авыр яшәүләрен, иренең гаиләгә бик игътибарсыз булуын әйтте.

— Ир кеше — әгәр ул чын ир булса,— диде Саттар бу урында үзенең фикерен белдереп,— ат урынына эшләсен, хатынын, гаиләсен тәрбияләсен. Хатын-кыз — гаилә күрке. Алтыннан гына киендерсәң дә аз әле аны. Кайдадыр, кайсыдыр бер урында әчмуха хезмәт хакы-

НИЯЗ АКМАЛ ◆ КҮГӘРЧЕН СОТЕ ◆

на эшләп көн үткәргәнче, үз иренә илһам биреп кенә яшәсә, хатынкыздан күбрәк файда булыр иде. Иргә дә, гаиләгә дә, җәмгыятькә дә. Чөнки андый хатынның ире икеләтә эшли ала. Әгәр мөмкинлек бирсәләр...

Минзилә бу уңайдан янә зарланып алды. Ире аспирант чакта бала белән утыруын, институтны тәмамлый алмый калуын, хәзер балалар бакчасында тәрбияче булып эшләп, түбән хезмәт хакына көн күрүен әйтте.

— Шундый гүзәл хатыннар була,— дип эләктереп алды аның сүзен Саттар. Һәм Минзилә тойды: хәзер ул нәкъ менә аның үзенә киная ясап әйтәчәк иде.— Аларны башка хатыннар белән бер дәрәҗәгә кую — ирләр тарафыннан кешелек алдында, гомумән, табигать алдында зур җинаять. Андый хатыннарны кулда гына күтәреп йөртергә кирәк!

Бу сүзләр Минзиләнең күңеленә сары май булып ягылды. Һәм ул, әкренләп-әкренләп, Саттарның һәр сүзенә игътибар итәргә, ул сүзләрнең мәгънәсе турында төннәр буе уйланырга күнегеп китте. Таһирның сүзләре белән чагыштырырга, ул гына да түгел, Таһирның үзен Саттар белән чагыштырып карарга гадәтләнеп китте ул.

Казанга кайтып, Саттар белән очрашуларны дәвам иткәч, бу кешенең сүзләренә генә түгел, тормышына, яшәү рәвешенә соклана башлады Минзилә.

— Менә бу Сарай безнеке булачак! — диде аңа Саттар, беренче тапкыр квартирасына алып кайткач. Минзилә инде үзен башка бер дөньяда яши дип хис итә башлаган иде. Һәм ул, күптән инде, үзенүзе шуңа ышандырды: бу бәхетне аңа беркем дә алып килмәде, бу бәхетне аңа бары тик язмыш, мәрхәмәтле һәм рәхимле язмыш кына китерде. Минзилә үзен ышандырды: бу яңа тормышны — алдагы уңайлыклары, кызыктырып торган рәшәләре белән балкыган шушы тормышны ул, Саттар кулыннан алынган муенса, алтын алкалар һәм асыл ташлар кебек үк, үзенә тиң бер бүләк итеп кабул итә иде.

Минзилә Таһир турында уйлаудан узды. Аны бары тик бер генә нәрсә — ул да булса Рөстәмнең язмышы гына борчый иде. Чит кешене эти итә алырмы ул? Ничек үсәр? Алдагы тормышы ничегрәк булыр? Бу хактагы икеләнүле, газаплы уйларны алда көтеп, ышандырып торган яңа бәхет җиңде. Саттар аны үз янына бала белән күчеп килергә күндерде.

— Тик башта син аерылыш,— диде ул.— Гаугасы чыкмаслык булсын. Квартираны бүлергә кирәк. Анысы Рөстәм өчен булыр. Сез шунда пропискада торырсыз, бездә яшәрбез...

Һәм менә Минзилә үз йортында соңгы көннәрен яши. Дөрес, бу соңгы көннең әле кайчан булачагы билгесез. Аерылышасы бар, законлы рәвештә... Саттар шуны таләп итә. Рөстәмне дә какмам, чит-ят итмәм, ди... Хәер, бу сөйләшү инде күптән, бер ай элек булган иде. Минзилә аны исендә калдырды. Гадәтенчә, Саттарның һәр сүзе турында һәр көнне йоклар алдыннан уйлап ята иде ул, ятлап бетерә иде.

— Эшләмәссең,— диде аңа Саттар.— Мин үзем табармын малны. Анысы өчен кайгырма...

Бүген ресторанда чакта Саттар бераз кәефсезрәк иде, күп эчте, исерми интекте. Минзиләнең сорауларына артык кырыс җавап кайтарды. Ни булганын, аның ник шулай үзгәргәнен аңлап бетермәде Минзилә. Хәер, аның да шөгыле катлаулы бит, сәүдә эшеннән дә авыр эш юк, диләр бит.

Күрше бүлмәдә Таһир боргаланып, уфтанып куйды. «Йокламый бугай һаман...— дип уйлады Минзилә.— Ул да кызганыч, бер уйласаң. Ярата иде бит ул мине, мескенкәем...» Ләкин ул үзеннән бу уйларны куарга тырышты. «Юк-юк,— дип ышандырды ул үзен.—

Мин аңа ияләшкәнмен, аны үземнеке итеп санарга күнеккәнмен. Шуңа күрә генә көнләшәм, шуңа күрә кызганам мин аны...» Минзилә Рөстәмнең тач Таһир булуын, аңа бик тә охшавын уйлап куйды. Таһир аңа, гел китмәгәндә, кинәт кенә якын булып китте. Ирен соңгы мәртәбә булса да иркәлисе, назлыйсы, юатасы килде Минзиләнең. Һәм ул, урыныннан кузгалып, Таһир йоклаган бүлмәгә чыкты.

— Таһир... Таһир дим?!

Таһир юрганын күтәрде, гаҗәпләнде.

— Синең янга ятасым килә, Таһир!..

Таһир дәшмәде. Юрганын ачып, урын бирде, хатынын кинәт кенә үзенә тартты. Ир белән хатынның бу кавышуы бары тик бик нык сагынышкан, чарасызлыктан интеккән, бер-берен озак көтешеп алган кешеләрдә генә була алыр сыман иде.

— Таһир!.. Син бик кайгырма, яме?..

— Минзилә! Җуләрем...

Таһир хатынының күзләреннән, ап-ак муеныннан, иңнәреннән үпте. Ул аны сагынган, нык сагынган һәм бу сагыну яраткан кешеңне югалтуны тоюу газабы булып әверелгән иде.

— Йә, булды, булды!.. Ашап бтерәсең бит син мине!..— дип иренең кочагыннан чыкты Минзилә.— Менә шулай, тып-тын гына ятыйк, Таһир. Сөйләшеп ятыйк.

Таһир чалкан ятты, кулларын баш астына салды. Киң сулыш алып, тын калды.

— Мин белгән идем,— диде ул бераздан.— Белгән идем, ышанган идем.

— Нәрсәгә?

— Синең китмәсеңә...

Минзилә аңлады: Таһир янына килеп, ул аны тагын бер кат алдаган, рәхимсез рәвештә алдаган, үсендереп алдаган иде.

— Юк, Таһир, син мине дөрес аңламагансың,— диярга ашыкты ул.— Китәм мин. Хәл ителде бит инде...

Таһир ыңгырашып куйды, башы белән мендәргә капланды.

— Гафу ит, Таһир... Минем синең белән соңгы тапкыр ныклап сөйләшеп каласым килгән иде. Квартира турында да... Безгә аны бүлешергә туры килер инде... Алыштырырга аннары. Син ачуланма, шулай кирәк бит.

— Син аны яратасыңмыни соң шулкадәр?

Минзилә аңлады: сүз Саттар турында бара иде. Ирексездән нәкъ шул турыда уйлап куйды: яратамы соң ул чынлап та Саттарны? Уйлады да, иренә чын күңеленнән җавап бирде:

— Ә син әле һаман да ярату белән генә яшәп була, дип уйлыйсыңмы?

— Мин сиңа әйтергә теләгән идем...— Таһир бер мәл икеләнеп торды.— Без бүген урамда очраштык... Күрештек... Минзилә сискәнеп китте:

— Саттар беләнме?!

— Хәбир белән. Урамда күрештек. Хәбир кайткан. Ул безгә килеп чыгарга тиеш. Мин, юләр, үзем дә уйламыйча, аны кунакка чакырдым...

— Хәбир?! — Минзилә үзе дә сизмәстән калтыранып куйды.— Ул безгә килеп чыгарга тиеш?..

Бу аның өчен көтелмәгән, коточкыч бер яңалык иде. Әгәр Таһир үзенең Саттар белән очрашуы турында әйтсә дә, бу кадәр каушамас, югалып калмас иде Минзилә.

— Кунакка чакырдыңмы?

— Әйе. Хәзер үкенәм. Болай әле бер оят булса, Хәбир алдында мең тапкыр оят...

«Оят! Оят! Оят!..» дип сулкылдады Минзиләнең дә күкрәге.

— Таһир!.. Таһир дим!? Әгәр ул килсә... Хәбир килсә, аңа белдермәскә кирәк! Бу хәлне...

Таһир мәсхәрәле елмаеп куйды:

— Ул килгәндә син минем хатыным булып торасыңмы?

— Соң, шулай инде!

— Белмим. Син үзеңә кара. Мин бит Хәбирне бүген чакырган идем. Ул килмәде. Мин шатландым моңа соңыннан. Ә иртәгә? Иртәгә — барыбер. Мин иртәгә районга китәм, командировкага...

Бүлмәдә тынлык урнашты. Хатын да, ир дә бу минутта Хәбир турында, аның Казанда булуы турында уйлый иде...

## XI

Әхсән Сабирҗановның кулыннан эш төште. Үзенең нинди уйлар белән йөргәнен, нинди борчулар белән яшәгәнен шулай да өйдәгеләргә сиздермәскә тырышты. Аның чырае караңгыланганны Айсылу апасы белән Мәҗит җизнәсе сизәргә тиеш түгел иде. Җизнәсе болай да сүз арасында кыстырып куярга тырыша:

— Кунак озакка китте...— ди. Алар инде, түземсезләнеп, Хәбирне көтәләр. «Юлга чыктык, кайтабыз» дип килгән телеграммасыннан башка бер генә хәбәр дә юк Хәбирдән.

Әхмәтгали карт сабырлыгын җуймый, әллә үзен, әллә башкаларны юата:

— Мәскәүдә тоткарланганнардыр, әле бит аның Мәскәвендә дә эш тулып ята,— ди.Гөлчирәтти үзенекен әйтә:

— Бүген иртәнге намазда дога кылдым, исән-имин генә кайтып җитүләрен теләп,— ди. Саҗидә килендәшен төштә күргән икән: көянтә-чиләген күтәреп су ташый ди Лиза. Инде бөтен ләгәннәр, савыт-чиләкләр су белән тулып беткән, ә ул һаман ташый да ташый, ди. «Җитте инде, булды инде, бөтен кисмәкләр тулды бит инде!» — дип үгетләгәч тә, «Юк, тагын бергә генә булса да барып кайтыйм әле»,— дип, кире борыла икән.

Мәҗит Әхсәннән эш таптырып йөдәтте. Абзар-курада инде кагылмаган койма, урыныннан купмаган әйбер калмады: Мәҗиткә һаман эш кирәк, аның күңеле тыныч түгел.

Менә шундый чакта Әхсәнгә үз кайгысын, үз хәсрәтен күрсәтү һич тә ярамый иде.

Аны, моннан ике көн элек, райкомның идеология секретаре Бикташев янына чакыртып алдылар. «Шул, Әмирхан абый әйткәнчә, партия оешмасы эшен тикшерү өчен чакыралардыр»,— дип уйлады Әхсән. Үзе сайланганнан соң булган хәлләрне, үткәрелгән, башкарылган эшләрне күз алдыннан кичерде. Колхоздагы барлык эшләрендә председатель Әмирхан абыйсының уң кулы булды Әхсән. Уң кулы?.. Бу турыда уйлагач, Әхмәтнәҗип абыйсы белән сөйләшүе искә төште.

— Син менә, сүзләреңнән үк күреп торам, үзеңне колхозда кемнеңдер ярдәмчесе итеп тоясың. Турысын әйткәндә — Әмирханның уң кулы итеп. Ә нәрсә, Әмирхан үзе бер генә куллы мәллә? Аңа тагын икенче уң кул нигә кирәк?

— Син мине гел сүздә тотасың, Әхмәтнәҗип абый! — дип көлде ул чакта Әхсән.— Колхозда бит бөтенесе өчен — ит өчен дә, сөт өчен дә Әмирхан абый җавап бирә. Шулай булгач, ул инде монда һәрчак беренче кеше булырга тиеш. Җаваплылык кемдә — җитәкчелек тә шуның кулында. Мин — аның уң кулы, авыл советы — сул кулы!..

Әхмәтнәҗип абыйсы тиз генә җавап кайтармады, көрсенеп куйды. Аннан соң әйтте:

— Менә шулай, берегез — уң кулы, берегез сул кулы булып, ике

кулсыз итәсез инде сез колхозны. Ни үзегез ике куллап эшләмисез, ни колхозның кулын җибәрмисез...

Әхсән укытучыга үпкәләмәде. Бары тик шуны гына әйтте:

— Мин бит, Әхмәтнәҗип абый, председатель белән килешеп эшлим. Бәхәсләшкән чак та була, билгеле.

— Юкны сөйләмә син, Әхсән энем,— дип кырт кисте бу юлы укытучы.— Баш белән кул бәхәсләшми!

Райком секретаре янына барганда, үзе башкарган эшләр турында уйланып, аларны барлап-барлап чыкканда әнә шул сөйләшүне тагын бер кат күздән кичерде Әхсән. «Баш белән кул бәхәсләшми». Кызык, гаҗәеп кызык кеше бу Әхмәтнәҗип абый...

Бикташев аны шактый көттереп кабул итте. Аның бүлмәсендә ниндидер кешеләр бар икән. Әлеге кешеләр — өч ир кеше һәм бер хатын-кыз чыгып киткәч секретарь аны үзенә чакырды. Коры гына исәнләште.

— Казан телевидениесеннән килгәннәр,— диде ул, ишеккә таба ымлап.— Менә бит сезнең колхозга җибәргәндә әйбәт булыр иде дә... Ярамый хәзер. Синең эш аркасында... Әйбәт бер ферманы төшерергә уйлыйлар.

Әхсән искә алды: моннан берничә ел элек, әле ул ферма мөдире булып эшләгән чакта, алар янына телевидение кешеләре килгән иде. Аларны райком машинасында Бикташев үзе алып килде. Шуларның берсе — кулына кинокамера тоткан җирән сакаллы бер урыс егете — җәйләүдәге матур урыннарны, тал-тирәкләрне, яр буйларын төшереп йөрде, ферма үгезе алдында бик озак басып торды. Кулына каләм белән куен дәфтәре тоткан хәбәрче исә Әхсәннән төрле саннарны санатты.

— Узган айда сөтне иң күп сауган савучы кем булды? — диде ул соңыннан.

— Фәтхиятти,— диде Әхсән, узган ай нәтиҗәләрен күзаллап.

— Аның фамилиясе ничек? Кайда ул хәзер? Чакырсагыз иде.

— Ул бүген юк иде әле... Өендә ул.

— Ничек өендә? Безгә аны төшереп алырга кирәк. Чакырыгыз!— дип сүзгә кушылды Бикташев.

Фәтхияттине, райком машинасына утыртып, өеннән алып килделәр. Алдан дәфтәр битенә язып, сөйлисе сүзен ятлаттылар, аннан соң төшереп тә алдылар.

Фәтхияттинең кайгысы зур иде: берничә көн элек кенә ирен җирләде, кичә өчесен үткәрде. Эшнең тыгыз вакыты булса да, Әхсән аңа, бераз хәл алсын, тынычлансын дип, ял биргән иде.

Телевидение кешеләре шуннан соң эшне тәгалләде. Әмирхан белән Хәмәт Мортазинны алып, колхоз ашханәсенә таба юл тоттылар.

— Ну, Фәтхиятти, Казаннан күрсәтәләр инде үзеңне болай булгач! Эләктең бит экранга! — дип шаулашып көлешкән кызларга Фәтхиятти аптырап карап торды. Аннары телевидение кешеләре кидерткән ак халатын салып, бер читкә куйды. Әйтте:

— Сөт сорадылар, хәлемне сорамадылар,— диде.

Бикташев өстәл янына килеп утырды.

— Синең өстән жалоба бар,— диде ул, Әхсәнгә дә урын күрсәтеп.— Берсе күптән килгән иде инде, ә менә монысын — кичә генә алдык. Безгә синең белән ныклап сөйләшергә кирәк, иптәш Сабирҗанов. Бюрога кадәр...

— Жалоба?.. Нәрсә турында? — диде аптырап калган Әхсән.

— Ашыкма,— диде Бикташев, аны билгесезлектә тотудан тәм тапкандай.— Син башта берничә сорауга җавап бир. Быел йортыгыз янган иде, әйеме?

— Янды...— дип баш какты Әхсән, үзе янә сорау белән төбәлде:

тагын нәрсәләр бар бу шикаять-хатта?..

— Сез яңа йортны ике айда җиткереп кергәнсез... Йә, ярар, монысы безне әллә ни кызыксындырмый. Тәк... Әхмәтнәҗип исемле пенсионер-укытучы сезнең чыбык очы туганыгыз икән, шулаймы?

— Әйе, әти ягыннан туган.

— Тәк. Аңлашылды... Йорт җиткергәндә балаларны шул Әхмәтнәҗип Сәлимовларга чыгарып торгансыз. Шуның өчен, балаларны карап торган өчен, аларга колхоз исәбеннән утын кайтарткансыз?

«Әһә, аңлашылды! — дип уйлап алды Әхсән һәм җиңел сулап куйды.— Менә бит эш нәрсәдә икән!..» Әйе шул, Әхмәтнәҗип абыйсы янына бер кергәч, сүз иярә сүз чыгып, утынсыз калуларын белгән иде аларның. Мәктәп, кайтарырга вәгъдә итеп тә, һаман-һаман сузып килгән.

— Менә бит, үзебезнең якта күпме нефть, күпме газ чыга, газ торбаларын Урта диңгезгә кадәр суздык, ә монда утынга да тилмереп яшибез, шулмы гаделлек? — дигән иде аңа Әхмәтнәҗип абыйсы. Зарланып түгел, үзара бәхәс чыкканда әйткән иде. Әхсән икенче көнне үк Әмирхан абыйсы белән сөйләште. Председательнең бер яхшы ягы: Әхсән әйткәнне һәрчак тотып ала, куәтләп куя, шунда ук хәл итәргә керешә. Берничә көннән карт укытучыга колхоз ике машина утын кайтарды...

— Колхоздан сыер алгансыз икән?..— диде Бикташев, укытучы Әхмәтнәҗип турында нәрсәдер аңлатырга омтылган Әхсәнне бүлдереп.— Дәүләт бәясеннән. Йорт салганда үзегезнең сыерны кыйбат хакка, базар хакыннан җибәргәнсез... Ярар, анысын мин Әмирхан Фәттахович белән шалтыратышып сөйләштем, анысы пүчтәк мәсьәлә...

«Ә эш нәрсәдә соң?» — дип уйлады Әхсән, тәмам аптырашта калып. Ул инде, колхоздан алынган сыер турында сүз чыккач, иң төп сүз шушы хакта барыр дип исәпләгән иде. Әйе, Әмирхан абыйсы аңа үзе тәкъдим итте. Мәҗбүри рәвештә. Хәтта бик нык ачуланды да әле: «Мин өендә сыеры булмаган парторг белән сөйләшергә дә теләмим! — диде.— Андый парторг сыер асраган колхозчының хәлен дөрес аңлый белми»,— диде.

— Ә эш нәрсәдә соң? — дип кабатлап сорады Әхсән.

— Эш шунда, иптәш Сабирҗанов,— Бикташевның йөзендә гадәттән тыш бер җитдилек пәйда булды.— Сезнең инициатива белән авыл клубында «Каз өмәсе» дигән бәйрәм үткәрелгән. Бу кичәдә сез, авыл картларын һәм авыл яшьләрен бергә җыеп, милли йолалар турында сөйләгәнсез, халыкның милли хисләрендә уйнагансыз. Ул гына да түгел, сез анда милли йола белән дини йола дигән нәрсәләрне аерып куя белмәгәнсез, икесен бергә бутагансыз...

— Кичә бик матур үтте,— дип бүлдерде Әхсән, инде тәмам үртәлә башлап.— Без анда милли дә, дини дә йолалар турында түгел, авылның үз йолалары турында сөйләштек. Концерт куйдык, картлар, өлкәннәр чыгып сөйләде. Минемчә, моның бернинди начарлыгы да юк!..

— Сезнең өчен бик матур, ә менә безнең өчен — матур түгел! — Бикташев, урыныннан торып, әрле-бирле йөренә башлады.— Сез әле барысын да аңлап җиткермәдегез бугай, иптәш Сабирҗанов. Сез — партиянең башлангыч оешмасы секретаре — клубта милли һәм дини йолалар турында кичә үткәргәнсез, авыл халкы күңелендә вәсвәсә куптаргансыз. Ә сезнең әтиегез — авыл картларының мулласы — шул кичәдән соң аштан-ашка йөргән, дини вәгазь укыган. Сез — партиянең башлангыч оешмасы секретаре — авылның мулласы белән бер йортта торасыз, бер нигездә яшисез! Менә эш нәрсәдә, иптәш Сабирҗанов! Обкомнан шалтыраттылар инде: аларны да башкасы түгел, нәкъ менә шунысы — соңгысы кызыксындыра! Әле тагын, менә

бу икенче хатта әйтелгән: Ильяс дигән егеткә анда, механизатор малайга, туй үткәрер өчен аракы түләргә вәгъдә иткәнсез. Бөтен халык алдында. Авылда нишләп аракы юк, дип кычкырган малайга җавап бирә белмәгән парторг дини йолалар турында бик шәпләп сөйләгән. Бу фактларның обкомда нинди реакция тудырачагын беләсезме сез? Сизенәсезме әзрәк?!

— Сизенәм,— дип кырт кисте үзенең ярсый башлавын сизгән Әхсән. Авылда үткән кичәдәге хәлләрне Бикташевның гел башкача аңлавы аны чын-чынлап үрти иде. Сизенәм... Нәрсә эшләргә тиеш мин шуны сизенеп? Төшерегез парторглыктан!

— Төшерегез, имеш... Төшерү җиңел. Тик әле менә авыл халкы бар, кешеләр бар бит. Аларга ничек аңлатырга? Обкомга ничек аңлатырга?

Әхсән сизде: Бикташевның кызуы сүрелде; ул, мөгаен, бу хәлдә үзен ничек тотарга, нинди карарга килергә белми, кемнеңдер тәгаен сүзен көтә иде.

— Берсекөнгә бюро,— диде, ниһаять, райком секретаре.— Обкомнар килгәнче мәсьәләне хәл итеп куярга кирәк. Әтиегез белән дә сөйләшеп килегез. Аңлагыз, иптәш Сабирҗанов: мулла белән парторг бер йортта яши алмый!..

Бу сөйләшү турында бары тик Әхмәтхан абыйсына гына белдерде Әхсән. Башкаларга ләм-мим сүз катмады. Хәтта Әхмәтнәҗип абыйсы белән дә киңәшмәде: укытучы белән бу хакта сүз йөртү оят иде аның өчен...

Әйе, өйдәгеләр аның бу үзгәрешен сизмәделәр кебек. Һәрхәлдә, Әхсән үзе шулай дип өметләнде. Тик менә хатыны...

Сажидә бервакыт төн уртасында әкрен генә елый башлады. Әхсән башта аңламыйча, ышанмыйча, аптырап ятты. Аннан соң, урыныннан күтәрелә төшеп, хатынын кузгатты:

— Ни булды сиңа?

Сажидә, тавышын күрше бүлмәдәгеләргә ишеттерүдән куркып, арта барган үксүен көч белән тыеп сулкылдады:

— Ә сиңа?.. Ә синең үзеңә ни булды?! Ни булды!..— дип, мендәрне төйде.— Мине сизми дип уйлыйсыңмы әллә?.. Кара көеп йөрисең, юньләп эндәшмисең... Миннән, балалардан туйсаң, турысын әйт... Кунаклар барында бит, әткәй-әнкәй алдында! Миңа бик җиңел дип беләсеңме әллә?..

— Ни сөйлисең син, Сажидә? — Әхсән хатынының җилкәсеннән кысты.— Ни сөйлисең, бәгырькәем?! Нишләп синнән түйыйм ди мин?! Исәрләндеңме әллә? Каян алдың мондый сүзне?

— Әлек син болай түгел идең, түгел идең! — дип, тагы да үкседе Сажидә.— Мин сизәм бит, үзгәрдең, нык үзгәрдең син, Әхсән. Олы эшкә күчкән ит-ат хатыныннан туя, аңа матурраклар, яшьрәкләр кирәк була, диләр иде, хак икән. Мин бит моңа ышанмаган идем, сиңа ышанган идем. Менә күрдем инде: соңгы көннәрдә бөтенләй икенче син, Әхсән! Башканы тапкансың син. Шуңа мине күргән саен, кара көясең, үртәләсең, беләм бит мин, сизәм!..

Ни дип юатырга, ни дип җавап бирергә белмәде Әхсән. Хатынының чын күңелдән үртәлеп, әрнеп, көнләшеп елавын аңлап алды ул. Беренче уй — гаҗәпләнү булды. Аларның яшьлектән үк килгән яратуы — озак көтеп алулар, сыналулар аша узган, инде соңыннан кавышуга тоташып, гаилә тигезлеге, гаилә татулыгы, гаилә бәхете булып әверелгән мәхәббәт хисләре — моңарчы теләсә нинди көнләшүләрдән дә өстен кебек иде...

Ә көнләшү — бер-береңә ышанмауның башы.

Аңлады Әхсән үз хәлен. Сажидәсенең дә хәлен аңлады. Өйгә кай-

чан ныклап кайтып күренгәне булды аның бу соңгы айларда? Кая ул соңгы айларда гына?! Элек, фермада чагында, алар көндез дә көнгә бер күрешмичә калмый торганнар иде бит. Ә менә парторг булып сайланганнан бирле, аларның очрашу вакытлары санаулы сәгатьләргә генә кайтып калган түгелме? Әхсән иртән нарядтан кайтып керсә, Сажидә иртәнге савымнан кайтмаган була. Сажидә кичке савымнан кайтканда Әхсән каядыр ашыгып чыгып китә. Ул районддагы киңәшмәләр күпме? Шул бу, шул — Сажидә элек тә аның өйдә булмавын авыр кичергән, әрнегән, көнләшкән, сиздермәгән. Башкасын үткәрә алган, ә менә монысын — соңгысын күтәреп бетерә алмаган: иренең йөзендә ниндидер кара шәүлә барын, шуны үзеннән яшергәнлеген, күрсәтмәскә тырышуын күңеле белән сизгән ул. Сизгән... Сәбәбен эзләп җәфаланган, үртәлгән, аңлый алмый интеккән. Нишләргә? Ничек юатырга, ничек тынычландырырга хатынының күңелен?

— Син инде бигрәк,— диде ул, тавышына кырыслык чыгарырга тырышып.— Әллә ниләр уйлап табасың. Ташлале... Кеше көлдерерсең.

— Ә нигә соң?.. Нигә алай үзгәрдең син? Бер мин генәмени, әткәй дә сизә синең үзгәргәнне?

— Әткәй? Ул нәрсә, берәр сүз әйттеме?

— Юк, әйтмәде,— Сажидә, тирән сулап, читкә таба борылды.— Әткәйне беләсең бит, әйтми-сиздерми ул. Тик мин күрәм бит, ул да борчыла. Башта мин аны Хәбирнең озаклавына гына борчылып йөри дип уйлаган идем. Юк, синең өчен дә икән...

— Сез нәрсә, барыгыз да минем өчен борчыла башладыгыз әле? Нәрсә булган миңа? Үзегез җыен тузга язмаганны уйлап чыгарасыз да...— Әхсән сүзен таба алмый, дәвам итә алмый торды. Чыннан да, ни өчен әле тузга язмаганны булсын? Димәк, әтисе дә шәйләгән аның борчылып йөргәнен. Сажидәнең күңеле сизгер, ул алдамас. Шулай уйлап, Әхсән хатынының иңнәреннән сыйпады.— Карале, карчык... Син ни... Әйдә, бала-чага булма, яме... Аңла инде син мине, эштә бит төрлесе була. Синнән башка, балаларымнан башка беркемем дә юк минем. Эштә бераз кыенлык чыккан иде.

Сажидә дәшмәде. Әхсән аның тынычланганын, үз сүзләренә ышанганын тойды. Әллә ышанырга теләп, ышанырга тырышып ята иде микән Сажидә?

— Әтигә белдермәскә кирәк, болай да инде йорт салганда нык биреште. Син инде, Сажидә, аларга аны-моны әйтә күрмә.

— Нәрсәне ул «аны-моны»?

— Юк-бар уй уйлап, күңелсез кыяфәт белән йөри күрмә дим.

— Ә минем андый кыяфәт белән йөргәнем юк, Әхсән. Әле үзеңә дә сиздерми идем, түзмәдем, күңелем йомшарып китте. Кичтән бирле түшәмгә карап, йоклый алмый боргаланып яттың бит. Җәлләдем үзеңне. Кем аркасында шулай өзгәләнә икән бу, минәйтәм.

Әхсән хатынын үзенәрәк тартты:

— Һы, кем аркасында, имеш... Эш аркасында, эш.

— Эш аркасында гына шулай ничә көн буена өзмәс-куймас кара көяме кеше? Эшеңнән алалар икән — бүтән җирдә эш бетмәгән. Әнә, безнең фермада сине һаман сагыналар.

Әхсән сискәнеп китте:

— Нишләп әле син мине бу эшемнән алырга җыенасың?

— Мин җыенмыйм. Фәтхияттидән ишеттем. Сер итеп кенә әйтте. Үзе кемнән ишеткәнен белдермәде. «Иреңнең өстеннән җалу язганнар икән»,— ди. Ул чакта аның сүзен колакка да элмәгән идем, менә хәзер исемә килеп төште. Сине дә шулай кара кайгыга салырлык булгач, нәрсәдер бардыр. Бардыр, Әхсән. Яшерәсең генәдер... Миннән. Хатыныңнан.

Сажидә тыныч итеп, үз сүзләре артыннан үзе үк уйланып сөйли

иде. Әхсәннең күңеле тулып китте. Чыннан да, кайгы дигән нәрсәне хатыныннан яшереп ир кеше дөрес эшлиме, әллә ялгышамы? Көчсезлекме хәсрәтеңне хатыныңа сөйләү, әллә киресенчәме? Синең белән бер уртак ятакны, уртак төнне, уртак таңны бүлешкән, балаларыңның анасы булган, авырлыкның теләсә кайсын синең белән бергә күтәрә алган, әмма синең йөзеңдәге сүрәнлекне, борчылуны күреп, бары тик шушы билгесезлекне генә күтәрәлмый җәфаланган хатынны ничек юатырга?

— Дөрес әйткән Фәтхияттй,— диде ул, ниһаять, авыр сулап.— Жалоба бар минем өстән. Берәү генә дә түгел, икәү.

— Ничек? Нинди жалоба? Кем язган? Кая?

— Райкомга да, обкомга да. Башта — беренчесен, аннан — тагын берсен. Кем язганы әйтелмәгән...

Сәҗидә сүзсез калды. Сорарга кыймыйча, иренең дәвам итүен көтә иде булса кирәк. Әллә инде әле генә ишеткәннәрен башына сыйдырып бетерә алмый интегә идеме?

— Ничек уйлыйсың, Мортазин абый язмады микән? — диде ул бераздан.— Ул бит, хәтерлисеңдер, теге вакытта да нindидер сүзләр сөйләп йөргән иде, син парторг булып сайлангач...

— Белмичә-нитмичә кешегә яла якма,— дип кырт кисте Әхсән.

— Болай гына әйтәм лә... Аптыраганнан. Нәрсә язганнар соң ул жалобада? Колхоздан сыер алганны түгелдер бит?

— Анысы да бар. Тик райкомны аны, сизәм, сыер кызыксындырмый. Колхоздан бер сыер түгел, унны алган булсам да бу кадәр купмаслар иде.

— Сыер да ул кадәр кызыксындырмагач, тагын нәрсә төпченәләр соң алар, Әхсән? Ә?

Әхсәннең тамак төбенә төер утырды. Дәшмәде. Уздырды.

— Әхсән, дим?

— Әткәй белән бер өйдә яшәвемә аптырыйлар. Менә шул.

— Ничек инде? Бергә яшәмичә, тагын кайда яшик? Төпчек малай Хәбир — читкә китте. Син инде аны алыштырдың. Әткәй-әнкәй янында кемдер булырга тиештер бит. Картлык көннәрендә. Райкомның моңа ни катышы бар?

— Бар икән шул менә... Мин парторг кеше. Ә әткәй... Ул — авыл мулласы. Эш менә шунда, Сәҗидә...

Сәҗидә урыныннан сикереп торды. Әхсәннең беләгенә ябышып, ашыгып-ашыгып пышылдарга кереште:

— Булса соң! Аңа карап, ул бит ата кеше булудан туктамый, Әхсән! Ни генә булса да, синең атаң бит ул! Картларның аның үз дөньясы. Ничек инде син аның белән бергә тормаска тиеш? Алайга китсә, бабай мулла дип, балалар да аннан йөз чөерергә, аның белән бергә яшәмәскә тиешмени?! Әнә, олысын бит мәктәптә отряд советы председателе иткәннәр. Аның өстеннән дә жалоба язсыннармыни?!

Әхсән хатынын бүлдермәде. Киресенчә, гаҗәпләнеп, аптырап, аның ярсулы пышылдавын тыңлады. Һәм ул аны бу минутларда бердәнбер киңәшер кешесе, таяныр терәге итеп тойды.

## XII

Хәбир соң уянды. Аның әле болай үз-үзен белештермичә йоклап калганы юк иде. Кичә ресторанда Ахо белән утырганнан соң, бүлмәгә кереп яткач та йоклый алмый интегүдән иде аның бу соң уянуы.

Торып юынырга өлгермәде, ишек шакыдылар.

— Мин бер генә минутка, туган,— диде ишектә күренгән Ахо. Башка чактагы кебек ачылып елмаймады. «Башы авырта, кәефе юктыр»,— дип уйлап куйды Хәбир. Ахо исә кулындагы күн сумкасын

аңа сузды.— Зинһар, алып куй, синдә торып торсын. Кич алла бирсә, кереп алырмын...

— Киченме?...— диде Хәбир, икеләнеп.— Гафу ит, Ахо, минем бит кичен монда булмавым бар бүген. Бер дусны очраткан идем. Өенә чакырган иде...

— Бүген булмаса, иртәгә сугылырмын,— дип, ашыгып бүлдерде аны Ахо.— Синдә торып торсын... Ачуланмыйсыңдыр ич?

— Ачулану кая?! Ни сөйлисең син, Ахо?! Кич белән өйдә булмавым бар, дип кенә әйтәм.

Ахо, сумкасын калдырды да, ашыгып чыгып китте. Хәбир аның болай кабалануын: сәер генә чыгып китүен үзенчә юрады: кичә күп сөйләшеп ташлаганына читенсенә бу, шуңа тизрәк саубуллашу ягын карый. Әллә соң кич өйдә була алмыйм дип әйткәнгә үпкәләвеме?

Юк, ул турыда әйтеп Ахоны һич тә алдамады Хәбир. Кичә ресторанда Минзиләне ниндидер ир белән күргәч, ул төне буе уйланып, үртәлеп, икеләнеп чыкты. Ахоның сүзләрен исенә төшереп, фикер җебенең югалган очын табарга тырышты. «Менә шулар кулында совет сәүдәсе...— дип теш арасыннан ысылдап сүгенгән иде Ахо.— Саттар Үтәбаев... Сәүдәне болар кулына биргән дәүләт — үзе үк иң зур спекулянт!..» Төнлә ул Таһир белән очрашуы турында уйлап ятты. Шунда гына аның агарган, талчыккан йөзендәге курку шәүләсен аңлап алгандай булды... «Димәк, Таһир да бәхетсез. Әллә? Әллә башкачамы? Бәлки, бу гади бер очраклылык кынадыр? Бәлки, Минзилә бу ресторанга очраклы рәвештә генә кергәндер? Бер-бер бәйрәм уңае белән?..» Хәбир шулай дип ышанырга тырышты. Әмма башында калган аек күзәнәкләрнең берсе аңа катгый җавап кайтарды: юк, очраклылык белән генә килмәгән Минзилә бу ресторанга. Юкка гына очрашмаган ул теге бәндә белән... Димәк, шулай: Таһир белән Минзилә дә бәхетсезлеккә тарган... Кем белә, бәлки аларга Хәбирнең каргышы төшкәндер? Хыянәт иткән дустан һәм хыянәт иткән ярдан язмыш үзенчә үч алгандыр? Табигатьтә бер генә нәрсә дә эзсез үтми, бер ялгыш җибәрдеңме, кайчан да булса аның үзеңә урап, бәла булып кайтачагын көт тә тор, диләр бит. Хыянәт табигатьнең үзе алдында ясалган ялгыш түгелме? Юк-юк, болай уйларга ярамый! Таһир... Аның янына, һичшиксез, барырга кирәк. Бәлки, ул да бүген бик авыр хәлдәдер? Бәлки, ул теге көнне, үзләренә чакырганда, Хәбирдән бербер ярдәм өмет иткәндер, киңәш көткәндер, әйтергә генә кыймагандыр...

Төне буена әнә шуларны кат-кат уйлап, үз-үзе белән бәхәсләшеп ятты Хәбир. Ахоны алдамады ул: кызы янында булганнан соң, аның белән күрешкәннән соң, кич Таһирларга барып кайтмакчы иде исәбе.

Тик ул бу көнне Таһирларга гына түгел, хәтта кызы Розалия янына да бара алмый калачагын белми иде әле. Шулай ук Таһир Корбановның нәкъ менә шушы иртәнге сәгатьләрдә аэропортка таба ашыкканын да белми иде Хәбир.

Әйе, Таһир бу көнне иртүк уянды. Иркенләп юынды, ашыкмыйча гына капкалап алды. Киемнәрен юлга әзерләде.

Минзилә йоклый иде әле. Әмма Таһир ул йоклаган бүлмәгә таба күз төшермәде, хәтта игътибар да итмәде. Кичәге, үткән көннәрдәге газаплардан, уйлану һәм үртәлүләрдән берни дә калмаган кебек иде. Әйтерсең, Таһир яшәп яткан катлаулы, тузанлы, эсселе-салкынлы дөнья өстеннән ниндидер бер зилзилә үткән дә, аннан соң инде җылы, рәхәт бер яңгыр яуган. Әйтерсең, аның бөтен тирә-юне чистарып, сафланып калган. Таһир шул саф һаваны күкрәк тутырып сулаган, тирә-якка карап, беренче тапкыр хозурланган. Үзен кеше итеп сизә башлаган...

Әлеге үзгәрешнең төп сәбәбе Хәбир белән очрашу икәнне Таһир тоя, сизеп тора иде. Хәбир белән очрашып, аның турында уйла-

ныр-көтеп алҗыган кичәге төнне беренче тапкыр үз язмышына читтән карап, аек бер акыл белән фикер йөртте Таһир.

«Менә Хәбир...— дип сөйләште ул үз-үзе белән.— Күпме кыенлык күрде, хыянәт күрде. Сыгылып төшмәде. Оят... Ә син менә үзеңә хыянәт иткән хатын белән бер өйдә бер үк һава сулап яшисең, синең ир булып исәпләнерлегең дә калмаган. Беткәнсең син, беткәнсең...»

Шулай үз-үзен битәрләде, оялтты, гарьлеккә күмде Таһир. Шулай йоклап китте.

Иртән уянуга ук, үзендә ниндидер җиңеллек, иркенлек, сафлык тойды. Нәрсәдер булган, нәрсәдер үзгәргән, нидер кире кайткан, нидер юкка чыккан кебек иде.

Билгеләнгән сәгатькә кадәр шактый вакыт бар иде әле. Аэропортка иркенләп, ашыкмыйча барды. Өлкә комитетының кадрлар бүлеге инструкторы Овчинников һәм пропаганда бүлеге вәкиле Төхфәтуллин белән ул «Депутатлар бүлмәсе» янында очрашырга тиеш иде. Алар Таһирдан да алдарак килгән булып чыкты.

— Менә монысы сезгә, иптәш Корбанов.— Исәнләшеп күрешкәннән соң, Төхфәтуллин аңа самолет билетын тоттырды.— Регистрация игълан итмиләр әле һаман.

— Тәртип юк,— диде Овчинников.— Самолет очар алдыннан ашыктыралар кешене. Менә күрерсез. Тәртип юк.

Таһир кулындагы билетка күз салды, үзе дә сизмәстән, гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде:

— Минем районга очабыз икән ләбаса. Күптән кайткан юк иде!..

— Менә, берочтан туган ягыгызны да күреп килерсез,— Төхфәтуллин ачылып елмайды. Тиздән аның бу елмаюы ирен читенә күчте.— Командировка алып, туган якка кунакка йөрүчеләр азмыни?! Әби-бабай янында сыйланырга!

— Тик бу иптәш Корбановка кагылмый,— дип, шаяртуга кушылды Овчинников.— Ул бит әле билетларның кайсы районга алынганын да белми иде.— Аннан соң, җитдиләнеп, Таһирдан сорады.— Балтамак авылы сездән еракмы соң? Шул авылда яшәгән партком секретарен тикшерергә барабыз.

— Балтамак?..— Таһирга эсселе-суыклы булып китте.— Ничек инде Балтамак?..— шушы сүзләрне кабатлаганда мең төрле уй үтте аның башыннан. Алар барачак авылда Мортазин дигән кеше яшәгәнен, аның партком секретаре булып эшләгәнен, ә инде Мортазинның кызы Минзилә булуын, ягъни үзенең хатыны булуын, бу тикшерүдә аңа һич тә катнашырга ярамавын боларга белдерергәме, юкмы дигән рәхимсез сорауга килеп төртелде.— Балтамак... Беләсезме, иптәш Овчинников... Иптәш Төхфәтуллин... Миңа сезнең белән барырга ярамый!

— ...?!

— Ничек инде?

— Анда... Партком секретаре... Мортазин... Ул минем хатынның әтисе. Шулай булгач... Бу тикшерүдә катнашырга минем юридик яктан да, мораль яктан да хакым юк.

— Кызык...— дип сузды Овчинников, кесәсеннән кызыл тышлы дәфтәрен чыгарып.— Кызык... Менә монда язылган: «Әтисе — мулла, Әхмәтгали Әхмәтгалиевич Сабирҗанов. Улы — парторг, Әхсән Әхмәтгалиевич Сабирҗанов». Монда сезнең хатыныгызның әтисе... Һ-м-м... Мортазин дидегезме әле? Монда андый кеше турында берниндн сүз дә юк!

Таһир бер генә мәлгә җиңел сулыш алды, әмма шунда ук янә калтыранып куйды: «Әхсән Сабирҗанов та минем авылдашым, дустымның абыйсы лабаса!» — дип чак кына кычкырып җибәрмәде. «Әтисе — мулла... Улы — парторг...» — дигән сүзләр аның башына бераз соңрак барып җитте. Әхсән абыйсын, дустының абыйсын тикшерергә, Әхмәтгали абыйсын тикшерергә кайта, үзенең туган авылы-

на кайта түгелме соң ул?! «Йа хода!..» — бу сүз аның күңелендә беренче тапкыр пәйда булды. Кемдер ярдәм итәр, кемдер бу хәлдән коткара алыр сыман тоелды аңа. Ярдәм булмаячагын аңлагач, котылу юлын үзе эзләргә кереште:

— Беләсезме...— диде ул, фикерен тупларга ашыгып.— Бу авыл... Ул бит минем туган авылым. Миңа анда тикшерү белән кайту кыен...

— Ә нигә? — Овчинников аның сүзен эләктереп кенә алды.— Мин бернинди кыенлыгын да күрмим моның. Сез, димәк, ул авылдагы кешеләрне яхшы беләсез. Мәсьәләне хәл итү безгә җиңелрәк булачак! Шулай бит, иптәш Төхфәтуллин?!

— Әлбәттә, шулай.

— Мин дә шулай дип уйлыйм! — Овчинников, эш хәл ителдегәнне белдереп, куен дәфтәрен кесәсенә кире тыкты. Каядыр читкә, регистрация кассаларына таба борылды.— Әйтәм бит, тәртип юк, тәртип. Самолетка утырыр алдыннан ашыктыра-куа башлаячаклар, менә күрерсез!..

Таһир сизде: ул инде «Андагы парторг минем балачак дустымның абыйсы бит», дип кенә котыла алмаячак иде...

Ул арада, аңа бөтенләй икеләнү җаен калдырмаслык итеп, алар очачак самолетка билетлар теркәүне игълан иттеләр.

Әйе, Хәбир бу көнне Таһирның туган якларга таба юл тотуын белми һәм белә дә алмый иде. Кичен аларга, Таһирларга барачагын төгәл хәл итеп, күңеленнән җөпләп, бүлмә ишеген бикләде. Базарга барып, анда нинди алмалар сайлап алачагын, кызына нинди җимешләр алып барачагын, Розалиянең ничек шатланачагын уйлап, үзалдына елмаеп куйды. Ачкычны калдырырга дип баскыч ягына таба атлауга, аның янына ике ир килеп басты.

— Гафу итегез, кире борыла алмассызмы? Бүлмәгезгә кире керергә кирәк, дип әйтүем.

Хәбир шул мәлдә Ахо калдырган сумка турында уйлап алды. Ачкычны монда тапшырып китү уе юләрлек булган түгелме, карале?! Бүлмәдә кеше әйбере кала лабаса!..

— Мин бик ашыгам,— диде ул, ачкычын кесәсенә тыгып. Аннан соң, кинәт туктап калды.— Ә минем бүлмәгә керү сезгә ник кирәк?

— Кирәк,— диде ирләрнең икенчесе һәм кесәсеннән кызыл тышлы таныклык чыгарды, Хәбирнең маңгаена ук терәп диярлек күрсәтте. «Лейтенант... Уголовный розыск» дигән сүзләр Хәбирнең күз алдында биешеп тора кебек иде.

— Мин ашыгам,— диде Хәбир, хәлне ачыграк төшенергә теләп.

— Бүлмәгә керик. Шунда сөйләшербез!

Хәбир икеләнеп торды. Аннан соң, баш чайкап, бүлмәсенә таба китте. Әлеге ирләрнең берсе, Хәбиргә таныклык чыгарып күрсәткәне, ишек ачылуга ук, бүлмә эченә ташланды.

— Монда! — дип, кош тоткандай шатланып, кабаланып, Ахо калдырган сумканы эләктерде, эчен ачып, актарырга да кереште.

— Кеше әйберсе бит ул, нишлисез?! Кагылмагыз! — Ләкин тегеләр Хәбирнең сүзенә илтифат итмәделәр.

— Монда! Әйе, монда, табылды бит, анасын сатыйм!

— Кеше әйбере... Зинһар, актармагыз,— Хәбир инде, нидер хәл итәргә теләп, алгарак тартылган иде. Артында торган ир аны җәһәт кенә эләктереп алды, стенага таба кысты:

— Тик кенә тор! Кузгаласы булма! Күрсәтермен мин сиңа «кеше әйберен»!..— дип кычкырды ул, шунда ук «син»гә күчеп.

Лейтенант сумканы кире япты.

— Сезгә безнең белән барырга туры килер,— диде ул, Хәбиргә үтәли карап.— Анда якыннанрак танышырбыз.

— Мин ашыгам, минем кызым янына барасым бар. Ул — больницада! Миңа аның янына бармый калырга ярамый! — Хәбир, үзенең хәлен берьюлы аңлатырга теләп, ашыга-ашыга сөйләде.— Мин... Без чит илдән кайтып киләбез. Сез мине кем беләндер бутыйсыз, ялгышасыз бугай!..

— Ялгышасыз, диме?! — Хәбирнең беләгеннән эләктереп алган милиционер мыскыллап елмайды.— Без сирәк ялгышабыз, агайне... Ялгышсак та, бик белеп ялгышабыз!..

Урамга Хәбирне култыклап алып чыктылар. Анда аларны машина көтеп тора иде инде.

## XIII

Кичке якта Сабирҗановлар өенә Ильяс килеп керде. Янәшәсендә укытучы кыз Нурия иде. Кыз, арттарак калып, ишек төбендә таптанды. Ильяс исә, үзе алып кергән суык белән бергә, өй түренә таба узды, өйне яңгыратты:

— Әхсән абый! Әхмәтгали абзый! Ишетәсезме?! Гөлчирәтти дим! Сәҗидә апа?! Өйләнәм бит мин, ишетәсезме?!.

Өйдәгеләр урыннан кузгалды. Аргы бүлмәдән балалар йөгерешеп чыкты. Ильяс аз гына кызмача идеме, әллә инде бәхетеннән артык һаваланган идеме, Нуриясе аны тарткаларга керešте:

— Ярар ла инде, Ильяс... Кеше өендә тавыш күтәрмә сәнә. Рөхсәт сорарга, фатиха алырга гына кердек лә инде...

Ильяс аның саен очынды, Әхмәтгали картның янына ук барып утырды:

— Аягымны салып-кагып тормадым, Әхмәтгали абзый, сез — үз кешеләр, гаеп итмәссез. Син безгә фатихаңны бир, Әхмәтгали абзый? Без бит, минә Нурия белән тормыш корырга, өйләнешергә булдык!..

— Алай-й...— Әхмәтгали карт каядыр аска, үзалдына төбәлде, аның шушы бер сүзеннән бөтен өй эче тынып калды. Очынып-һаваланып килеп кергән Ильясны да алыштырып куйган кебек булды: ул, картның шушы сүзендә нинди мәгънә ятуын аңларга теләгәндәй, башын бераз кырын салып, аңа төбәлде.

— Бергә тору, гаилә кору, өйләнешеп туй итү — алла тарафыннан фарыз ителгән, макталган эш,— дип әкрен генә көйләде, үзалдына карап сөйләде Әхмәтгали карт. Аннан соң, кулы белән генә ишарәләп, Нуриягә дә утырырга кушты.— Вәләкин тормыш корганда алдагысын да уйлап эш итәргә кирәктер, оланнар. Ата-аналарыгызның җанын борчуга салмаенча, кадерләрен белеп, үз балаларыгызны ят итмәенчә, тәуфыйк белән яшәү насыйп булсын.

Әхмәтгали карт чал башын күтәрде, Ильяска таба иелде:

— Ильяс улым, сүземне авырга алма, сине бераз теге шайтан суы белән шаяргалый, диләр. Гаилә корганда монысы турында ныклап уйла. Сезгә — бергә торасы, балалар үстерәсе.

— Әлек булды инде ул, Әхмәтгали абзый!.. Хәзер юк, алай шаярмыйм инде. Әнә, ышанмасаң, Нуриядән сора: ай буе сүземдә тордым — авызга да алмадым!

— Анысы яраган, улым. Алга таба да, иншалла, шулай булсын,— Әхмәтгали карт кызга таба борылды.— Нурия кызым, тормышка чыгу — уен эш түгел. Саваплы да, җаваплы да эш. Ата-аналарыңның ризалыгын алдыгызмы?

— Алар риза, Әхмәтгали абзый.

— Анысы әйбәт. Ирнең кадерен белеп, аның һәр көнен уртаклашып яшәргә кирәк. Шуңа син ризамы, үзең ныклап уйладыңмы?

— Риза, Әхмәтгали абзый. Ныклап уйладым.

— Анысы әйбәт. Бәхет-шатлыклар белән гомер кичерергә, мату

балалар үстерергә насыйп итсен. Рәхмәтеннән ташламасын. Амин, шулай булсын... Миннән фатиха сезгә, балалар!

Әхмәтгали карт урыныннан салмак кына кузгалды.— Кечкенә намазымда сезнең өчен дога кылырмын. Хак тәгаләдән хәер-фатиха сорармын.

— Рәхмәт, Әхмәтгали абзый! Рәхмәт!..

Әхмәтгали карт олы якка кереп китте. Әхсән аның артыннан, этисен беренче тапкыр күргәндәй, гаҗәпләнеп, төбәлеп карап калды. Беренче тапкыр күргәндәй... Этисе аның күз алдында олыгайды, күз алдында картайды. Сиздермичә... Сизелмичә...

Әхсән аның яшь чакларын хәтерли: атын җигә, печәнен чаба, эшнең теләсә кайсысын эшли торган таза бәдәнле ир иде. Басудан салам алып кайтсалар, кышкы кичнең соңына тикле аларда ут яна: басу җилендә куырылып кайткан Әхмәтгали идарә конюхы Әхәт белән «җылынып» утыра. Алларында — бер ярты «Московская». Сургуч белән пичәтләнгән бөкесен кадерләп кенә ачалар. Балаларга күрсәтмәскә тырышалар. Ә Әхсән — ишегалдына кайтарып аударылган саламны лапаска таба ташып йөргән олы малай — боларны барыбер күрә, күрмәгәнгә генә салыша. Бераздан болар шешәнең нәкъ яртысына җитәләр. Шуннан соң инде Әхмәтгали малайны эштән туктата, ишегалдына чыгып, чакырып ала:

— Булды, улым, маладис, нык эшләгәнсең, калганын иртәгә икәү ташып өярбез,— ди.

Инде тагын бераз утыргач, этисе Әхәт агайны да озата, төбендә ике бармак калынлыгы аракысы калган шешәне аның кесәсенә тыга: монысы — саламга барырга ат биреп торган өчен. Әле саубуллашканчыга кадәр, баскыч төбендә тәмәке тартып торалар, кич буе өстәл янында барган әңгәмәне үзләренчә йомгаклыйлар...

Өйләнеп кергәч, этисе һич тә тиз генә тынмый әле. Балаларның берсен — гадәттә, эшсез йөргәнен, дәрес әзерләп утырмаганын сайлап ала, сөйли... Этисенең ул вакыйгаларын — сугышта күргән хәлләрне балаларның инде күп тапкырлар ишеткәне бар. Әмма барыбер кызык. Кайчак, этиләре сөйли башлауга, китапларын, дәресләрен ташлап, җыелышып утыралар. Этиләре моңа бик канәгать: күзләрен кыса төшеп, кайсыдыр вакыйганы искә төшерергә тырыша. «Фамилиясе ничек иде соң әле?» — дип, «ротный старшина» турында сөйлисе вакыйгасын сузып, көттереп тора.

— Әһә, әйе, Шувалов дигән урыс малае иде. Көне буе атыштык— ашарга китермәде бу. Нимес кыса. Бер тапкыр чак рукапашныйга кермәдек. Минем взвуд сул як флангада иде. Шуннан кыса нимес. Кичкә таба тынды. Берзаман, минсиңайтим, отделениеләрдән хәбәр килә: «Ашарга давай! — диләр.— Тамак үтерә, «Урта авыл этләре» өрә!» — диләр. Атыш вакытында элемтә өзелгән иде. Ротный комндирга кеше җибәрдем: «Егетләрнең хәле бетте, минәйтәм, алар өч көн буена тәгам-ризык капмаган, нишләп, минәйтәм, ашарга китерүче юк?! Фриц тагын күтәрелсә, ач килеш ничек сугышыр солдат, минәйтәм...»

Әхсән, олы малай буларак белә инде: бу урында этисе кулын селтәп куя, тавышын күтәрә төшә. Моны ул үзенең рота командирыннан һич тә калыша торган кеше булмаганлыгын белдерер өчен шулай итә. Бу вакытта малайларның гына түгел, олы кызның да күзләре очкынланып куя: этиләре өчен горурланалар. Ә инде төпчек малай Хәбир бөтенләй рәхәт чигә:

— Шулай дип әйттеңме, эткәй!?

— Әйт-те-е-м! — дип суза этиләре, башын чайкап.— Ә нигә әйтмәскә?!

Нәкъ менә шул иң кызык вакытта, каяндыр эшеннән бүленеп, эниләре килеп керә.

— Балаларның йоклыйсы бар ла инде, атасы, үзеңнең дә эшең

иртә таңнан, җитәр, бүтән вакытта сөйләп бетерерсең, йокларга кирәк,— ди.

— Әйт-те-е-м! — дип кабатлый ул, хатынына усал карап алып, янә үзенекен сөйләп китә: — Шуннан соң, ярты сәгать тә үтми, үзенең службасы белән старшина килеп җитә. Ботка китергән бу, сухой паек китергән. Моның егетләре бушаткан-өләшкән арада, үзенә әзрәк акыл өйрәтмәкче булдым. Анда бер җимерек таш стена бар иде. Каршыда гына окоп башлана. Шул стенага ышыкланып сүгәм мин моны: «Син нәрсә, минәйтәм, фәлән-фәсмәтән, нишләп минем взводны ач тотасың?!» — дип.— Беләсеңме, минәйтәм, Суворов солдатны ашату турында ни дигән?!» Шул сүзне әйтеп бетерүем булды, бух-х!.. Янда гына мина төшеп шартлады. Старшина окопка капланып төште. Күтәреп карыйм, корсагын ертып үткән мина ярчыгы. Эчәгеләре окоп эченә салынган, аларына зыян тимәгән. Күтәреп алдым старшинаны, бөтен әгъзаларын кире тутырдым. Ярасын бәйләгәч, тылга озаттырдым. Үзем дә, шул төнне яраланып, госпитальгә эләктем. Шунда ишеттем: эчен теккәннәр дә моның, ике атнадан терелеп, чыгып та киткән. Ә мин менә кул белән өч ай яттым. Сөяк чәрдәкләнгән иде.

Ә Днепрны кичкәндә миңа чак кына герой бирмәделәр!..— нәкъ менә шушы урында әтисе, күрәсең, үзенең шактый исерә төшкәнен сизеп ала иде. Башын селкеп тора-тора да, үз-үзенә сөйләгәндәй әйтеп куя: — Сугышка киткәнче тамчы да авызга алган кеше түгел идем мин, сугышта кар өстендә ятканда спирт бирәләр иде, шунда өйрәндем, каһәргә...

— Әткәй сөйлә инде, тагын сөйлә инде? — дип аптыраткан төпчек малайга әйтә:

— Ярар, бүген йоклыйк инде, бүтән вакытта сөйләп бетерермен,— ди.

Иртән ул иртүк торып эшкә китә. Сугыш турында сөйләтер өчен, аның тагын шулай берәр тапкыр «төшереп» алганын көтәргә кала.

Әтисе күз алдында олыгайды Әхсәннең. Хәер, Әхсән үзе моны сизмәде, искәрмәде. Гел янәшәңдә булган кешенең үзгәрүен дә, яше арта баруын да тоймыйсың икән. Хәбир генә, кунакка-ялга кайтып киткән чакларында, абыйсы белән икәүдән-икәү генә калгач, әйтә иде:

— Әткәй олыгайган инде, абый, нык олыгайган...

Чит илгә китәр алдыннан Лиза белән бергәләп кайткач та әйтте:

— Әткәй картаеп бара инде...— диде.

Андый чакларда Әхсән дә Хәбир белән килешеп куя, гомернең тиз үтүе турында уйлана. Әмма көндәлек тормышта, көндәлек эш мәшәкатьләрендә барысы да онытыла, яңадан үз агымына кайта. Әтисе дә аның өчен һаман бер үк төрле, бер үк яшьтә булып кала; әйтерсең, шулай булган, шулай булып калачак...

Әтисе дини картлар арасында йөри башлады. Әхсән монысын да гадәти бер нәрсә итеп кабул итте. Дөресрәге, бөтенләй искәрмәде дә. Нигә?! Әтисе белән бергә ашка йөргән, җомгага җыелган картлар барысы да бер авыл кешеләре, бер чор кешеләре — сугышка бергә китеп, сугыштан соң бергә эшләп, авылның шатлыгын-кайгысын бергә уртаклашкан кешеләр түгелмени?!

Әтисенең тәмәкене ташлаганын Әхсән сизми калды.

— Сәламәтлекне бетерә,— диде әтисе, аракы-эчемлек кебек нәрсәләрдән авыз өзгәч. Савабы да, шифасы да бар, дип, умартага тотынды. Бакчада кыяр, помидор кебек нәрсәләр күренде, Сабирҗановлар бакчасында алар иң алдан өлгерә торган булып китте.

Әхсән әтисен намазлык өстендә күрде: картларча үзенә күрә бер килештерү, әни-карчык белән бергә-бер картаю галәмәте итеп кенә карады. Чөнки әтисе, намазлыктан кузгалуга ук, янә дөнья мәшәкатьләренә, йорт-җир эшенә чума, уй-фикере белән дә, сөйләгән сүзе,

эшләгән эше белән дә нәкъ элекке булып, ата кеше булып, гаилә башлыгы булып кала бирә иде.

Үзләре өстеннән килгән шикаять хаты турында белгәч, Әхсән иң беренче булып этисе өчен борчылды. Бу хат иң беренче чиратта аның үзен түгел, ә бәлки этисен рәнҗетә, этисен мәсхәрәли кебек иде аңа. Бу мәгънәсез хат турында өйдә белүләреннән, өйдә ишетүләреннән курыкты Әхсән. Курыкты... Әмма, үзе дә сизмәстән һәм сиздермәстән генә, этисенең ахшам намазына утырган чакларына күз салгалады...

Менә бүген, Ильяс белән Нуриягә фатиха биргән этисе олы якка чыгып киткән чакта, Әхсәннең миен ниндидер кайнар уй, утлы фикер көйдереп алды. Әйе-әйе, олыгаю, картларча бер килештерү галәмәте генә түгел, ә бәлки үзе генә аңлаган, үзе генә тойган инану, ышану килгән бит аның этисенә. Менә әле хәзер дә, фатиха сорап кергән шушы яшьләр белән гади генә итеп, дөньяви мөгамәләдә сөйләшеп утырганнан соң, үзенең хуплау сүзләрен белдергәннән соң, аның этисе чын-чынлап алар өчен алладан бәхет сорарга, бәхет яларырга кереп китте. Әхсән сизде: этисе бу эшне чын күңеленнән, ышанып һәм инанып, бөтен җаны белән бирелеп, теләкләренең кабул буласына өметләнеп, яшьләр хакына һәм кешеләр хакына дип, савaплы гамәлләр һәм сират күперен кичәсе барлыгы турында уйлап, алланың бердәнбер булуы һәм аның кодрәте чиксез булуына тирәнтен ышанып башкарачак.

Ильяс белән сөйләшкәндә Әхсән үзенең әнә шул көтелмәгән ачышы тәэсирендә иде әле. Ильяс исә бертуктаусыз сөйләнде, күңелендәге шатлыгын тыя алмыйча, әле абыйсына, әле апасына килеп бәйләнде:

— Әхсән абый!.. Саҗидә апа! Берсекөнгә — туй. Башта яшьләр табынын үткәрәбез, аннан картларны җыябыз. Сезне инде яшьләрнекенә чакырабыз, Саҗидә апа! Килми калмыйсыз инде, әйе бит?!

Саҗидә әле өзеп кенә берни дә әйтергә ашыкмый, Әхсәнгә карый. Ә аның ире... Әгәр дә Ильяс бу кадәр очынмаса, җилкенгән күңелен тыя алмыйча һаваланмаса, һичшиксез, Әхсән абыйсының күзләрендәге икеләнүне, сәер газаплануны, борчылуны күргән булыр иде. Юк шул, Ильясның күңеле җиде кат күктә, Әхсәннең һаман дәшми торуын, икеле-микеле генә сүзләр әйтеп куюын ул үзенчә аңлый: туйга бармаска маташулары түгелме соң боларның?

— Карале, карале син боларны! — ди ул, булачак кәләшеннән ярдәм эзләп.— Карале, син боларны, Нурия! Әдәм көлкесе бит, ә?! Сез дә килмәсәгез инде, Әхсән абый, мин ул туйны бөтенләй уздырып та тормыйм. Әнә, Әхмәтгали абзыйдан никах кына укытам да, әнкәйдән мунча яктырам. Бетте китте, вәссәлам!

«Әхмәтгали абзыйдан никах укытам...» — шушы сүзләрне ишеткәч, Әхсән дерт итеп сискәнеп китте:

— Җүләр сүз сөйләмә! — дип кистерде ул һәм, аңына килеп, суына төште.— Нинди никах укыту ди ул? Нурия — мәктәптә эшли, педагог кеше. Син нәрсә, энекәем, аны балалар алдында хур итмәкче буласыңмы әллә?

— Шаяртып кына әйтәм лә инде, Әхсән абый! Парторг булгач, эреләндең әле син. Шаяртканны да аңламыйсың. Йә, сүзеңне бер ныклап, кистереп кенә әйт тә инде, аннан без киттек. Йөреп чыгасы кешеләр шактый бит әле!

Нурия тыйнак кына басып торса да, аның да күңеле җилкенгән:

— Саҗидә апа, Әхсән абый! Килегез инде, яме?! Айсылу апа белән Мәҗит абыйны да калдырмагыз. Берүк калдырмагыз, яме?!

— Ярый, сеңелем, ярый.— Саҗидә инде түзмәде, ризалыгын әйтеп ташлады, үзе һаман Әхсәнгә карады: «Йә, нишләп дәшмисең инде, нигә яшьләрне интектерәсең, туй бит гомергә бер генә була?!»

ди иде аның күзләре.

— Ярый... Чакыруыгыз өчен рәхмәт, уйларбыз... Барырга тырышырбыз...— диде Әхсән, ниһаять.

— Вәйт рәхмәт, Әхсән абый! Көтәбез! Ярый исәнлек-саулык, без киттек! — дип кабаланды Ильяс.

Алар чыгып киткәч, Әхсән үзендә ниндидер бер җиңеллек тойды. Бүген көне буе уйлап йөргән уйлары, әле әтисе намаз укырга кереп киткәндә ясаган сискәнүле ачышы бераз кечерәеп калгандай булды. Чыннан да, тормыш дәвам итә. Кешеләр өйләнешә, туй ясыйлар. Һәр кешенең үз язмышы, үз тормышы бар. Үз гаиләсе... Гаиләсе? Шушы сүз Әхсәнне янә сискәндерде. Аның да үз тормышы, үз гаиләсе, үз нигезе бар түгелме? Әхмәтгали исемле бер авыл карты — ул да аның әтисе, аның тормышының аерылгысыз бер өлеше түгелме? Ни өчен әле шушы бер нигездәге гаилә бүген кем өчендер ике өлешкә, капма-каршы өлешкә бүленеп күренергә тиеш?

Әхсән, инде ничәнче мәртәбә, пыяла тәрәзле ишек янына килеп, бераз гына ачылып торган ике пәрдә арасыннан олы якка күз төшерде. Әтисе, таш сын кебек, намазлык өстендә утыра, авыз эченнән генә нидер пышылдый, ул ходай белән сөйләшә иде бугай.

Әхсән ишекле-түрле йөреп килде. Өстәл артына барып утырды. Аннан соң янә сикереп торды:

— Мин Әхмәтнәҗип абыйларга барып кайтыйм әле...

Иренең җанын кая куярга белми йөрүен баядан бирле күзәтеп торган, әмма беренче сүз башларга кыймаган Сәҗидә авыр сулап куйды:

— Айсылу апалар мунчадан кайтканда өйдә булырга иде инде сиңа, Әхсән?.. Җизнинең бу көннәрдә болай да эче пошып йөри. Юньләп күрешә, сөйләшә алганыгыз да юк бит. Син энтә чакта бер хәл инде... Бүген бит синең өйдә икәнеңне белә ул...

— Сәҗидә-ә!..— дип кискен генә эндәште Әхсән.— Аңла, миңа Әхмәтнәҗип абыйны күрергә кирәк.

— Үзең әйтмәгәч, мин сорашмадым инде. Бүген районда... Ниләр булды соң? Бюрога чакыралар дигән идең бит.

— Бюро булмады.

— Ничек?

— Шулай. Комиссия алданрак килеп җиткән. Бюро ясарга өлгерә алмый калдылар.

— Комиссия? Казаннан укмы? Нәрсә диделәр, ни әйттеләр соң?

— Нәрсә әйтсеннәр... Шул инде...

Әхсән сүзен әйтеп бетермәсә дә, Сәҗидә аңлады. Авыр сулап куйды:

— Җизнәй сине сораса, ни дип әйтим соң? Озак торырсың микән соң?

— Әйт, эше бар икән аның Әхмәтнәҗип абыйда, диген. Ә болай... Озак тормаска тырышырмын...

Көн шактый салкынайткан иде. Әхсән тукталып, пәлтә якасын күтәрде. Болай иткәч, әйтерсең, җылырак кына түгел, хәтта уйларга да уңайлырак иде.

Бюрога алар Әхмәтхан абыйсы белән бергәләп бардылар. Башта, идарәдә икәү генә калып, сөйләшеп-киңәшеп утырдылар. Әхмәтхан абыйсы әйтмешли, итәк-җиңне җыя төштеләр.

— Күңелем сизә,— диде колхоз рәисе район үзәгенә барганда.— Аларны бүтән нәрсә түгел, шул... синең әтиең мәсьәләсе кызыксындыра...

Аларны райкомда Бикташев каршы алды.

— Бюро булмаячак,— диде ул, ниндидер олы сер ачкан кебек пышылдап. Һәм каушаган, ашыккан тавыш белән өстәп куйды: — Обкомнан килеп җиттеләр. Сезне көтәләр...

Бу яңа хәбәр Әхсәнне каушатмады да, гаҗәпләндермәде дә. Тик, Казаннан килгән кешеләр утырган бүлмәгә килеп кергәч, сискәнеп китте: комиссия членнары арасында мәрхүм Шәкүр абыйның малае, Хәмәт Мортазинның Казанда эшләүче кияве Таһир да утыра иде. «Әллә соң... Хәмәт Мортазин бу эшне махсус рәвештә кияве аша эшләгәнме?» — бу сорау аның уенда ирексездән туды.

Тик соңыннан, комиссия әгъзалары белән күрешкәндә, Әхсән баягы уеннан кире кайтты: «Юк, булмас,— диде ул үз-үзенә.— Шәкүр абзыйның малае андый эшкә бармас. Әгәр шулай булса, күзгә туры карап исәнләшә алмас иде...»

Танышып чыкканнан соң, сүзне Овчинников башлады:

— Иптәшләр, безгә бүген бик җитди мәсьәлә турында сөйләшергә кирәк булачак... Һәммәгезгә мәгълүм булганча, бу сөйләшү КПСС өлкә комитетына килгән хат һәм, шуңа бәйле рәвештә, коммунист иптәш Сабирҗанов Әхсән Әхмәтгалиевичнең шәхси эше турында.

Бүлмә бер мәлгә тынып калды.

— Дөрес, бу аноним хатта иптәш Сабирҗановның шәхесен каралтып күрсәтергә тырышу ярылып ята,— дип дәвам итте Овчинников.— Без монда кайбер материаллар белән танышып өлгердек инде өлгерүен... Тик безгә бергәләп сөйләшергә, мәсьәләне уртага салып аңлашырга кирәк. Иптәшләр, принципиаль булырга тырышыйк. Вактөяк нәрсәләргә артык тукталып тормыйк. Әйтик, нindидер пенсионер укытучыга утын кайтару мәсьәләсе. Вак нәрсә, иптәшләр. Мин үзем монда бернинди дә гаеп эш күрмим. Минемчә, пенсионерларга ярдәм кулы сузу һәр намуслы коммунистның бурычы. Тәк-к... Йорт салу... Колхоздан сыер алу... Болары да, минемчә, монда — урында сөйләшеп хәл ителә торган вак мәсьәләләр. Алар турында сүз куертып тормыйк. Без инде бу хакта иптәш Бикташев белән киңәшеп тә алдык, ачыклык керттек. Тәк-к... Колхозның бер механизаторына аракы табып бирергә вәгъдә итү. Ягъни булган әҗәтне кайтарырга вәгъдә бирү... Монысын мин аңламыйм. Эш нәрсәдә, иптәш Сабирҗанов?

Әхсән, сабырсызланып, урыныннан күтәрелде.

Теге вакытта урак тәмамланганда механизаторлар белән булган вакыйганы сөйләп бирде. Ашыкмыйча, каушамыйча сөйләде. Әмма шул ук вакытта үзенең нәрсәдәндер акланганын, үз-үзен акларга тырышканын тоеп, үртәлә башлады. «Авыл җирендә механизаторлар белән эшләп караганыгыз бармы сезнең? — дип эчтән генә үчекләде ул шушы үзенә бөтенләй таныш булмаган, әле нинди максат, нинди уй белән килгәнен дә белгертергә өлгермәгән Овчинниковны.— Мөгаен, юктыр. Эшләп караган булсагыз, сорап-нитеп тормыйча да аңлар идегез...»

— Әлбәттә, сез ул кичәдә тиешле җавапны таба алмый калгансыз,— диде Овчинников, Әхсән сөйләп бетергәч.— Халык алдында, кичә барышында көтмәгәндә әҗәт сораулары да каушаткандыр, бәлки. Ә болай... Башкасын исәпкә алмаганда, парторг кешенең вәгъдәдә тора белүен күрсәтүе начар түгел кебек. Шулай бит, Тәлгать Ахунович?

Берөзлексез нидер язып утырган Төхфәтуллин ашыгып баш какты:

— Әлбәттә, шулай. Әлбәттә...

Овчинников сораулы карашын Таһирга төбәде.

— Әйе... Дөрес... Шулай...— дип үзалдына гына сөйләнеп баш какты Таһир. Бу юлы ул күзләрен каядыр аска, читкә яшерә иде.

— Иптәшләр, без бик катлаулы мәсьәлә алдында калдык. Минем обком аппаратында алты ел эшләп мондый фактка тарганым юк иде әле. Күз алдыгызга китерегез: колхозның партия оешмасы секретаре авыл мулласы белән бер йортта яши. Бу бит башка сыймаслык хәл,

иптәшләр! Партком секретаре партиянең тарихи карарларын тормышка ашырырга, яшьләрне коммунистик инану юлына әйдәргә тиеш. Ә шул ук вакытта аның этисе — мулла — авыл яшьләре арасында ислам динен тарата, дини тәрбия алып бара. Безгә бу мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Чөнки без,— Овчинников янәшәсендә утырган Төхфәтуллинга һәм Таһирга ишарәләп алды,— бу хакта обкомга тулы справка тапшырырга тиеш булабыз. Йә, кемнәрдә нинди фикер-тәкъдимнәр бар?

Бүлмә янә тынып калды.

— Бәлки, иптәш Сабирҗановның үзенә сүз бирү кулайрак булыр? — Төхфәтуллин Әхсәнгә төбәлеп карады.— Сез бүгенге хәлегез турында ни уйлыйсыз?

Әйе, Әхсән уйлый иде. Ләкин ул үзенең бүгенге хәле турында түгел, этисе турында уйлый иде бу минутта. Менә шушы бүлмәдә булган сөйләшүнең, мондагы сүзләрнең этисенә барып ишетелүе мөмкин икәнлеген күз алдына китереп, ул кинәт сискәнеп куйды. Мондый хәлне, мондый хәбәрне этисе ничек кабул итәр? Ничек күтәрер?

— Иптәш Сабирҗанов,— дип ашыктырды аны Бикташев.— Комиссия членнары сезнең сүзне көтә!

Әхсән янә урыныннан күтәрелде. Бер кулы белән икенче кулын нык кысып, бармакларын каты итеп уды. Ниһаять, авыр итеп сулыш алды, аннан соң әйтте:

— Мин элек фермада эшли идем. Эшем әйбәт иде. Фермада эшләүчеләр болай үземне хөрмәт итә иде кебек. Әгәр инде миңа парторг булып эшләргә ярамый икән, ул чакта миннән бу вазифаны алуыгызны сорыйм. Минем сүз шул...

Овчинниковка, күрәсең, мондый җавап ошамады. Йөзе чытылып, ризасызлык билгесе күзләренә үк чыкты. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды һәм гаҗәпләнгәндәй итеп елмайды:

— Иптәш Сабирҗанов!.. Сез инде бигрәк, ни... Алай ярамый бит, ярамый! Без кызыксындык: сезне колхоздагы коммунистлар да, авыл халкы да ярата, хөрмәт итә. Алар, сезгә ышаныч күрсәтеп, сезне үзләренең партия оешмасы секретаре итеп сайлап куйганнар. Шулайдыр бит, иптәш Шакиров?

— Шулай. Авылда Әхсән Сабирҗановка ышаналар. Аның колхозчылар алдында абруе зур. Үзе шушы халык арасында эшләп үсте.

— Күрдегезме?! — дип елмайды Овчинников һәм Әхсән аның бу елмаюында нindидер сәер бер ясалмалык тойды. Нәкъ менә шул ясалма елмаю аның янә ачуын кабартты, рәнҗетте, эчтән ярсытты.— Күрдегезме, иптәш Сабирҗанов?! Колхозда сезне хөрмәт итәләр. Ә сез тиз генә койрыкны сыртка салмакчы буласыз. Әлбәттә, мин аңлыйм: этиегез турында сүз алып бару сезгә җиңел түгел. Ләкин уйлап карагыз: әйтик, райком секретареның этисе поплык хезмәтен башкарса? Ничек булыр иде сезнеңчә? Ә?! Җитмәсә, әгәр алар икесе дә бер йортта яшәсәләр — тагын да көлкелерәк,, шулаймы? Сезгә этиегез турында уйларга кирәк, иптәш Сабирҗанов.

— Мин, нәрсә, әткәйне өйдән куып чыгарырга тиешме, сезнеңчә?

— Юк, сез дөрес аңламадыгыз! Бу инде бөтенләй мөмкин эш түгел!

— Ә миңа нишләргә кушасыз? Хатынны, балаларны алып, мунчага чыгып торыргамы? Әгәр кирәк икән, мунча киң минем, аерылам да чыгам! — Әхсән инде бу сүзләрен юри үчекләшеп әйтте. Янында утырган Әмирхан абыйсы моны сизде, әкрен генә пинжәк итәгеннән тартты.— Ул чагында инде миңа беркем дә, мулла белән бер йортта яшисең, дип бәйләнә алмаячак!

Бикташев карандашы белән өстәлгә шакылдатып алды. Бу аның «Артыгын кыланасың, Сабирҗанов!..» — дигәнен аңлата иде. Овчинников, киресенчә, Әхсәннең ироиниясен дә, үчекләшеп әйтүен дә сиз-

мәде. Күрәсең, ул үзе хәл итәсе мәсьәлә өчен борчыла, бары тик шул хакта гына уйлый иде.

— Иптәшләр, без болай итеп хәлне катлауландырабыз гына бугай. Минемчә, акыл белән эш иткәндә, мәсьәлә хәл ителмәслек түгел. Ни өчен, мәсәлән, сезгә әтиегез белән сөйләшеп карамаска, иптәш Сабирҗанов? Әгәр дә ул муллалыгын ташласа, бу очракта каршылык үзеннән-үзе юкка чыга...

— Мин әткәй өчен җавап бирә алмыйм. «Тегеләй ит, болай ит»,— дип тә боера алмыйм аңа. Хакым да юк. Ул миңа ата кеше, миннән олы кеше...

— Сезгә кыен булса, бәлки, әтиегез белән үзебез сөйләшеп карарбыз, иптәш Сабирҗанов? — Овчинников бу сорауны шулкадәр көтелмәгәндә бирде ки, хәтта Әхсән үзенең кычкырып җибәргәнен дә сизми калды:

— Сез нәрсә?! Әткәйне нинди хәлгә куймакчы буласыз? Мин аның алдында нинди хәлдә калам?!

— Юк, сез мине бик үк дөрес аңлап бетермәдегез бугай. Мин бит әтиегезгә нинди дә булса нажим ясау турында әйтмим. Болай, күрешеп, танышып, үзара сөйләшеп кайту турында әйтәм. Һәм, әлбәттә, безнең сөйләшү сездән башка булырга тиеш дип уйлыйм...

Овчинников шуннан соң да әле шактый озак сөйләде. Сер итеп кенә әйтәм, диде: обкомга Мәскәүдән яшерен хат килгән икән. Анда ислам диненең көчәя баруы, яшьләр арасында киң таралу куркынычы барлыгы әйтелгән. Шул хат килгәннән соң, махсус бер төркем Норлат районында булып кайткан. Әлеге районда эшләп торган дүрт мәчет бар икән...

Овчинниковтан соң Төхфәтуллин да сөйләде. Аның сүзе дә, соңгы чиктә, кире Әхсән Сабирҗановка әйләнеп кайтты:

— Әгәр дә без, үзебезнең идеологиягә битараф яшьләр күбәйде, дибез икән, бу бер дә яшерен-батырын нәрсә түгел, иптәшләр. Турысын әйтергә кирәк, андый яшьләр, чыннан да, күп. Алар безгә ышанмыйлар икән, димәк, ышанычны каяндыр бүтән урыннан эзләячәкләр. Ә дин инде андый кешенең күңелен яулап алуда беренчелеккә омтылачак. Шуңа күрә дә, иптәш Сабирҗанов, сезгә бүгенге мәсьәлә турында ныклап, коммунистларча уйларга киңәш итәбез...

Районнан кайтканда Әмирхан да, Әхсән дә бер-берсенә сүз катмадылар. Авылга җитәрәк бер урында машина чокыр-чакырлы җирдә сикереп алгач, Әхмәтхан теш арасыннан гына сүгенде. Ләкин аның бу сүгенүе чокырлы юлга карата булмаган икән:

— Яшьләр дингә тартыла, диләрме? Анасын корт чаккыры!.. Бүтән ышаныр нәрсә калмагач, кая барсыннар?!

Әхсән дәшмәде. Авылга керер алдыннан гына сорап куйды:

— Әхмәтхан абый... Бу Овчинниковның нindирәк кеше булуын аңлап бетермәдем мин.

— Нәрсәсен аңламыйсың аның! Сарык тиресе ябынган төлке — менә шул. Әйдә, безгә тукталыйк лутчы. Өйдә алып куйган нәрсә бар, мондый чакта бераз җиңеләеп алу кирәк ул...

Әхсән баш тартты: өйдә кунаклар бар, алар янына көннәр буе кайтып күренмичә йөреп, үзең генә күз ялтыратып кайту дөрес булмас иде...

...Укытучының капка төбенә җиткәч, Әхсән якасын төшерде. Җылыга ияләшкән колакларны шунда ук суык куырып алды. Капка тоткасына кагылгач, Әхсән кинәт кенә тукталып калды. Чыннан да, ник килде соң әле ул монда? Ярдәм эзләпме? Әхмәтнәҗип абыйсы аңа ярдәм итә аламы соң? Бер-бер киңәш ишетергә теләдеме ул укытучыдан? Ләкин эш инде киңәштән узган. Зарланырга дип, бераз шыңшып алырга дип килдеме? Монысын гына инде ул Сәҗидәсе

янына кайтып та эшли ала иде. Шулай уйлады, шулай дип үз-мәсхәрәләде Әхсән. Бер урында таптанып, нишләргә белми озаклап торды. Укытучыны күз алдына китерде. Йә, менә хәзер керде ди ул аның янына. «Их, Әхсән, Әхсән...— дияр Әхмәт абыйсы.— Әйткән идемме мин сиңа, улым? Шулай бит, әйткән иде бит?..»

Бервакыт үзара бәхәсләшкәндә, чыннан да әйткән иде укытучы:

— Юк, Әхсән, эшли алмассың, дип әйтмим мин сиңе... Син эшли торган кеше. Тик менә эшләттермәсләр, эшләргә ирек бирмәсләр...

Әхсән ул чакта көлгән генә иде бу сүзләрдән.

Капка төбендә таптанып-таптанып торды да, кире борылды. Якасын яңадан күтәреп куйды. Әкрен генә, теләр-теләмәс кенә атлап китте. Аргы якка илтә торган сукмакка чыккач, кинәт кенә туктап калды.

— Ә бит кем беләндер сөйләшергә кирәк! Сөйләшергә!..— дип эндәште ул үз-үзенә. Ниһаять, аңлады: укытучы белән сөйләшмичә кала алмый иде ул бүген.

Укытучы протезын салып куйган, култык таягы белән генә тыйтаклап йөри иде.

— Әйдә-әйдә, уз,— дип каршылады ул Әхсәнне.— Карчык та күршеләргә кереп китте. Өйдә берүзем кукраеп тик утырам.

Әхсән кул биреп күреште, өстен-башын салды. Өстәл янына барып утырды.

— Чәй куеп җибәримме?

— Син йөрмә, үзем куям, абый,— Әхсән, чәйнекне алып, газ плитәсенә таба китте.

— Анда түгел, әнә, электрныкына куй,— укытучы култык таягы белән почмак якка төртеп күрсәтте.— Газ бетебрәк киткән әле безнең.

Әхсән өстәл янына утыргач, укытучы аңа төбәлеп карады:

— Хәбирдән һаман бер хәбәр дә юкмы?

— Юк. Үзебез де аптырап беттек инде. Әнкәй бик борчыла. Әткәй сиздерми, эчтән генә сыза.

— Синең дә йөзеңә чыккан. Хәбирләр өчен борчыласыңмы?

— Алар өчен дә, Әхмәтнәҗип абый. Аннан... башкасы да чыгып кына тора...

Әхсән, берничә сүз белән генә, бүген райкомда булган хәлләр турында сөйләп бирде.

— Үзем өчен түгел, әткәй өчен күбрәк кайгырам мин, абый. Сүзе чыкмый калмас инде бу вакыйганың. Әткәйгә дә бер ишетеләчәк бу хәбәр. Авыр, бик авыр кабул итәчәк ул моны,— дип, башын иеп, тынып калды. Аннан соң, өстәп куйды: —Әткәйне гаепли дә, аңа үпкәли дә алмыйм мин. Ул һәрнәрсәдә безнең өчен үрнәк булды. Тәрбия бирде, кеше итте. Тик шуңа гына гаҗәпләнәм: теге дөнья белән дә, алла белән дә берниндн алыш-биреше булмаган бер кеше иде бит. Ә менә олыгаеп барган бер көнендә...

— Әлмәттән бер танышымны очраттым мин. Өченче ел булса кирәк. Яшь вакытта шактый аралашкан дуслар идек. Теге, кем әйтмешли, ата коммунист иде. Комсомол эшендә башлап йөрде. Менә шуны очраттым. Безнең район үзәгенә килгән иде. Әлмәттә мәчет салдырырга йөрибез, ди бу. Менә мин шул Әлмәт кешесеннән сорадым, рәнҗетмәслек итеп чын күңелдән сорау бирдем: «Карале, туган, син бит коммунист кеше идең, нишләп болай алла юлына киттең?» — дидем. Ул да миңа чын күңелдән җавап бирде: «Әйе, шулай, яшьти, башта кеше октябрят булырга тиеш. Аннан, үсә төшкәч, пионерга керергә тиеш. Комсомол сафларын үтәргә, акылы, аңы үскәч — коммунист булырга, ә инде бөтенләй камилләшкәч — мөселман кешесе мөселман булырга тиеш»,— диде. Мин аның чын күңелдән сөйләгәненә ышандым. Ә кешене инанган өчен хөкем итәргә ярамый. Олы-

гаюның, картлыкның үз кануннары бар. Әтиеңне әнә шулай аңларга тырыш син...

Әхсән кайтканда өйдә йоклаганнар иде инде. Бары тик Саҗидә генә, төнге утны яндырып, аны көтеп торган.

— Ашап аласыңмы? — дип пышылдады ул, табынга таба ымлап.— Озак көттек сине. Мунча да суынгандыр инде.

— Ничава! — дип елмайды Әхсән, хатынын кочаклап.— Мин бүген районда чакта бер эссе мунча кердем инде...

## XIV

Тәбәнәк кенә буйлы, түгәрәк йөзле, иртә пеләшләнгән кизү офицер, майор, Хәбиргә гаҗәпләнеп карады. Аннан соң, сораулы карашын Хәбирне алып керүчеләргә төбәде.

— Тикшерүче килгәнчегә кадәр кабул итеп торыгыз,— диде милиционерларның өлкәне, Хәбиргә үзенең таныклыгын күрсәткән лейтенант.— Зур кош булырга охшый...

— Эшне кем алып бара? — майор янә Хәбиргә карап алды, ә сорауны лейтенантка бирде.

— Капитан Әбдрәҗәкова.

Бүлмәгә кереп-чыгып йөрүче милиционерларның һәммәсе Хәбиргә кызысынулы караш ташлады. Хәбир хәтта аларның монда юри тукталуларын, ниндидер сәбәп табып, озаграк булырга тырышуларын сизеп алды. Һәрхәлдә, аңа шулай тоелды.

Ул инде аңлашырга, аңлатырга теләп арган иде. Ләкин юлда аны тыңларга да, теләмәделәр. Үтенеп, ялварып әйткән сүзләренә мәсхәрәле бер елмаю, төрткеле сүз белән генә җавап кайтардылар. Бу ыгы-зыгыда беркемгә дә, бернәрсә дә төшендерә алмаячагы көн кебек ачык иде. Шуңа күрә: «Тикшерүче килгәнчегә кадәр...» — дигән сүз аны бераз тынычландырды. Әйе, чыннан да, тикшерүче белән очрашуны көтәргә, эшнең нәрсәдә икәнен сорарга, барысын да әйбәтләп аңлатырга кирәк. Үзенең көтмәгәндә мондый хәлгә юлыгуын Хәбир, әлбәттә, Аходан күрә иде: «Ул калдырып киткән сумка урланган булды микәнни? Әллә Ахо аны юри калдырганмы? Ни өчен теге милиционерлар нәкъ шул сумка табылганга бик шатландылар?»

Аны эчкәрерәк бүлмәгә алып керделәр.

— Чишенегез,— диде өстәл артында утырган старшина.

— Сез... Сез нәрсә?!

— Чишенегез!

Янәшәгә килеп баскан сержант Хәбирнең беләгеннән кысты.

— Булышыргамы әллә?

Хәбирнең барлык документларын алып, өстәл тартмасына салдылар. Сәгатен, подтяжкаларын агач тартмага тыктылар. Исемлек төзеп, шуңа кул куйдырдылар, кесәләрен кат-кат актардылар.

— Киенегез!

— Тикшерүче кайчан килә? — диде Хәбир, киенеп беткәч. Аның инде түземлеге шактый кими башлаган иде.

— Килгәч әйтерләр,— старшина сержантка ымлады.— Өченчегә!

Сержант, Хәбирне кулыннан электереп, тимер ишеккә таба алып килде, ишекнең биген шакылдатып-каерып ачты, караңгы бүлмәгә таба этәрде.

Үзе артыннан ишек ябылгач, Хәбир башта берни дә күрми торды. Бераздан гына тонык кына ут барлыгын шәйләде. Тар камераның ике ягында агач эскәмияләр куелган иде. Шуларның берсендә, пәлтәсе белән башыннан ук бөркәнеп, ниндидер кеше ята. Хәбир кергәндә ул хәтта кузгалмады да.

Хәбир икенче буш эскәмиягә килеп утырды. Кулындагы пәлтәсен

бер читкә куйды. «Нишләргә?..» Бу сорауга җавап бер генә иде: тикшерүче килгәнне көтәргә.

— За что взяли браток?

Хәбир сискәнеп китте. Каршыда яткан кеше кузгалып куйды, аннан соң торып ук утырды.

— За что, говорю, взяли?..

— Белмим,— дип русчалатып җавап кайтарды Хәбир.— Үзем дә белмим әле...

— Ха! Ха-ха!..— дип кычкырып көлде әлеге кеше. Бу көлүеннән Хәбир аның яшь кенә бер егет икәнен чамалап алды.— Белми, имеш! Башта барыгыз да шулай сайрыйсыз сез! Бер гаепсез, имеш ни өчен кулга алынганын да белми! Фәрештә, диярсең! Ярый. Тәмәкең юкмы, абзый?

— Юк шул. Тартмыйм.

— Син бәхетле. Тартырга эзләп интекмисең. Мин монда барча почмакларны актарып бетердем инде. Кесәдәге тәмәкене алып калдылар бит, сабакылар!..

Егет йөгереп барып, ишекне кага-типкәли башлады.— Сержант!.. Сержант дим, иманыңны!.. Тәмәкене алып калдың, берне генә булса да бир ичмасам!..

Теге якта аяк тавышлары, кемнеңдер сүгенеп карганганы ишетелде. Бик шалтырап куйды, ишек ачылып, милиционерның ачулы йөзе күренде:

— Хәзер бирәм мин сиңа, алай бик сорасаң! Стенага үрмәләтәм! — Сержант ишекне каты итеп кире япмакчы иде, егет ике арага аягын тыгып өлгерде:

— Куркытма! Үрмәләгән бар! — диде ул, кинаяле тавыш белән.— Ач ишекне, чыгып керәсе бар, йомыш белән...

Сержант икеләнеп торды. Аннан соң Хәбиргә кычкырды:

— Әй, син дә чык әйдә! Берьюлы йомышлап керегез! Аллы-артлы шакылдатмагыз!

Хәбир баш чайкады, урыныннан кузгалмады.

— Соңыннан шакылдатып йөрисе булма алайса! — дип, сержант егетнең үзен генә чыгарды. Хәбир урыннан сикереп торды:

— Карагыз әле, иптәш милиционер!.. Мине монда озак тотачаклармы? Тикшерүче кайчан киләчәк? Минем бит... Минем кызым больницада ята! Ул... Мин аның янына, һичшиксез, барырга тиеш, аңлыйсызмы?

— Вакыты җиткәч чакырырлар! — дип кырт кисте сержант һәм тимер ишек Хәбирнең борын төбендә шалтырап ябылды.

Камерада ул берүзе калды. Менә шушы вакытлыча ялгызлыкта калу аңа үзенең коточкыч хәлдә булуын, нииндидер аңлатып, әйтеп бетерә алмаслык мәгънәсезлеккә таруын бөтен барлыгы, бөтен аянычлыгы белән сиздерде. Шуны сизү һәм шушы минутта үзенең бөтенләй көчсез һәм ярдәмсез икәнен тою аны хәлсезләндерде. Эскәмиягә килеп утырды, аннан соң сузылып ук ятты.Күзен йомуга, кызы Розалиянең куркынган, шомланган йөзен күргәндәй булды.

— Кызым-м-м, бәгырькәем-м!..— дип ыңгырашты Хәбир һәм ике күз кырыеннан кайнар яшь тамчысы атылып чыкты.— Әтиең синең янына килергә тиеш иде. Тик ул синең алда алдакчы булып калды. Алдакчы... Нишли икән, ни уйлый икән бала бу минутта? Очып кына барасы иде... Ишек бикле...

Хәбир гомер буе бикле ишекләрдән курыкты. Бервакыт, балачакта ук, әтиләре каядыр кунакка киткәч, кич клубка ашыккан Айсылу апалары аларның икесен — Әхсәнне һәм Хәбирне тышкы яктан бикләп киткән иде.

— Ә хәзер, пожар чыкса, син нишләр иең? — дип юри куркытты аны Әхсән абыйсы. Ул үзе инде куркырлык түгел, алтынчы класс-

ларда укый иде. Ә менә җиде яшьлек Хәбир шул чакта дер калтырап төште, чын курку белән курыкты.

— Тәрәзәне ватам,— диде ул һәм, йөгереп барып, мич аралыгында торган табагачны эләктерде.

— Ә мин тәрәзәне ватып тормыйм. Пыяласы әрәм була. Мичкә керәм дә, морҗа юлыннан гына чыгам,— дип көлде Әхсән абыйсы. Әйе, бу аның шаяртуы, энесен бераз гына куркытып алуы булган. Бу шаяртуны ул үзе шунда ук онытты. Ә менә Хәбир, апасы кайтканчыга кадәр эчтән калтыранып утырды.

Шушы караңгы камерада да Хәбир үзендә балачактан калган таныш бер калтырану тойды.

Ишек биге шалтырады. Ачык ишектән көн яктысына охшаш бер яктылык күренеп алды. Әмма шул мәлдә үк бу яктылыкны кара шәүлә каплады, ишек янә шалтырап ябылды.

— Наканец!..— диде егет, Хәбирнең каршысына килеп утыргач.— Тәки ике тәмәкесен алдым тегенең...

Кесәсен актарып, сындырылган шырпы кабының күкертле кисәген алды. Сакланып кына сызды, авызына капкан тәмәкесен кабызды. Озак итеп суырды, эчкә алган төтенне күкрәгендә тотты, аннан соң гына өреп чыгарды да иркенләп сулыш алды.

— Дөнья рәхәте!.. Күпме бирми интектерде бит...

Егет тагын суырды, тагын рәхәт чикте. Шуннан соң Хәбиргә карады:

— Исемең ничек, абзый?

— Хәбир булам.

— Татарин икән, алайса. Мин үзем дә татарин. Эдик дип йөртә руслар. Ә болай, бәләкәй чакта, әти белән әни Әдип дип дәшәләр иде.

— Син монда ничек эләктең соң, Әдип?

— Һәй, абзый!.. Минекен сөйли китсәң... Без синең белән бергә утырасы өч көн генә түгел, айлар да җитмәс. Башта мотоцикл белән эләктем мин. Ачу килгән иде. Бөтен малайларның мотоциклы бар, минеке юк. Суктым бер «Волга»ны... Уздым мин мондый камераларны, күп уздым. Анысында утыртмадылар. Малолетка, диделәр. Икенчесендә... машинада шәһәр әйләндек. Анысы инде — салган баштан. Тагын шушындый камера. КПЗ га барып җитте эш. Прокурор санкция бирде. Изоляторга эләктем. Аннан инде — суд. Тагын әйттеләр, малолетка, диделәр, хөкем карарын бер елга кичектереп торырга, диделәр. Имеш, бер ел эчендә тәртип бозмасам, андый-мондый кыек эш эшләп ташламасам — барысы да әйбәт булачак. Һа!.. Бер ел бит ул! Бер ел эчендә кеше нәрсә эшләмәс?! Минем дә шулай килеп чыкты инде. Туйга чакырганнар иде. Шуннан салып кайтып килгәндә күрәбез — подъезд төбендә өр-яңа «Жигули» тора. Машина җене кагылган булгандыр инде миңа. Малайларны утыртып, «Аккош күле»нә алып бардым. Учак яктык. Күңел ачтык... Ә аннан соң инде — зонага ук эләктем. Элекке срокны да өстәп бирделәр. Кайтканга ярты гына ел... Эшкә урнаша алган юк. Ә кичә... Сыраханәдә артыграк җибәрелгән. Айныткычка алып килделәр. «Кайда эшлисең?» — диләр. «Эшләмим» — минәйтәм. Шуннан бәйләнергә тотындылар. Тегендә-монда шалтыраттылар. Монда кертеп тыктылар шуннан соң. Тикшерүче сорау алачак инде хәзер. «Нигә эшкә урнашмыйсың?» — дип бәйләнәчәк. Ә ник эшләргә тиеш әле мин? Кемгә бил бөгәргә тиеш? Мин инде бу дөньяны аңладым: безне эшләтеп, үзләре рәхәт чигеп яшәргә теләүчеләр белән тулган бу дөнья. Үзләре эшләсен!

— Тагын утыртып куйсалар? Хезмәттән баш тартканың өчен.

— Пычагым да утырта алмыйлар. Прокурор санкция бирми аларга мине утыртырга. Чөнки миндәйләр белән дә тулган бит әле бу дөнья. Шул, судка алып барырлар да, судья унбиш тәүлек чәпер инде миңа. Ял итәрмен бераз, бөер белән бавыр аракыдан хәл алыр. Юкса,

күпкә китте бу арада.

— Әйе, энекәш... Күпне күргән малай икәнсең инде син. Әйтәм аны сержант белән дә бик батыр сөйләштең.

— Ә нәрсәсеннән куркыйм мин аның? Алар шул сезнең кебек интеллигентларны гына куркытырга өйрәнгән. Ә миңа нәрсә? Теге, кем әйтмешли, ничего терять, кроме своих цепей!

— Без шулай икебез кайчанга тикле көтеп утырырбыз икән соң инде? — Хәбир, урыннан торып, камера буйлап йөреп килде. Егетнең нәкъ каршында тукталды.— Болай кертеп ябулары бер дә законлы эш түгел бит инде боларның?

— Абзый, жаныкаем! Нинди закон турында сөйлисең син?! Бер генә нәрсәне бел син: без монда чагында — аларныкы закон, без иректә чакта — безнеке закон! Бары тик шул гына. Юкса, син гел күктән төшкән кеше кебек сөйләшәсең. Имеш, сине монда бер гаепсезгә кертеп япканнар! Гөнаһсыз кыз кебек кыланып маташасың...

— Күктән төшмәдем мин, энекәш,— дип авыр сулады Хәбир. Шушы егет алдында акланып тору кыен иде аңа. Ләкин бердәнбер сөйләшер чарасыздан туган кайгысын уртаклашыр кешесе бары тик ул гына иде.— Чит илдән кайтып килешем иде минем. Әфганнан. Кызым юлда авырып китте. Аны больницага салдым. Ул мине көтә инде бүген, мескенкәем. Ә мин — менә монда...

— Ничек?! — дип гаҗәпләнде егет. Урыныннан кузгалып, яңадан тәмәке кабызды.— Ни дип бәйләнәләр соң алар сиңа?

— Әйтәм бит, белмим. Сизенүен сизенәм инде: поездда бер кеше белән бергә кайткан идек. Соңыннан да очраштык. Кунакханәдә. Спекуляция белән шөгыльләнә торганрак кеше булса кирәк. Кунакханәгә урнашырга ярдәм итте. Ресторанда бергә булдык. Бүген иртән миндә сумкасын калдырып торган иде. Артыннан ук килеп керделәр, сумкасын алдылар, мине монда китереп тыктылар. Менә шул. Бернәрсә аңлатмадылар, бернәрсә сорашмадылар...

— Аңлаттылар лабаса! — дип үчекләп көлде егет.— Тикшерүчене көт, диделәр.

Хәбир аның ирониясен колак читеннән уздырды:

— Кайчан килер икән соң ул? Кайчан чакырыр?

— Чакырыр! Ә хәзергә ул әле синең теге спекулянтың артыннан чабадыр. Ә синдә аның хәзергә кайгысы юк. Син — ышанычлы урында.

— Өсләреннән жалоба бирер дип тә курыкмыйлар микәнни соң алар? Бөтенләй кешеләрчә түгел бит инде бу.

— Кешеләрчә... Аларны жалоба белән куркыту кыен. Карга күзен карга чукымый, диләрме әле? Зонадан кайткач, участковый интектерде мине. Атнага өч тапкыр өйгә килә. Надзор ясый, имеш, анасын сатыйм! Кайчан эшкә урнашасың, фәлән-фәсмәтән, ди, нишләп эчеп йөрисең, дип бәйләнә. Тәмам туйдырды! Синең миндә ни эшең бар, минәйтәм. Кайткан — ял итәргә хакым бар. Шуннан соң яңый башлады бу: илтеп тыгам мин сине яңадан, ди. Әни карчыкны аптыратып бетерде. Шуннан әйттем мин моңа: өстеңнән жалоба белән барам, килеп йөрмә безгә бүтән, дидем.Кычкырып көлде. Бар, барган җиреңдә шундук алып калырлар, ди. Аптырагач, до конца киттем мин, ни булса да булыр, дидем. Беркөн, сиздермичә генә, артыннан озата кайттым тегенең. Кайсы йортта торганын, кайсы подъездда яшәгәнен белдем. Икенче көнне күрше карчыкларыннан барып сораштым, квартирасын белдем. Ике баласы бар икән, кечкенәләр әле, башлангыч класста укыйлар. Шулай, эшеннән кайтканын көтеп, квартирасы төбендә баскычта утырдым. Кайта бу. «Нишләп утырасың монда?» — ди. «Утырам әле, минәйтәм, бер иптәшне көтә идем»,— дип. Нәрсә эшли ала ул? Баскычта утырган өчен генә мине илтеп яба алмый лабаса! Икенче көнне тагын эшеннән каршы алдым

моны. Күзеннән күрдем: шикләнүе йөзенә чыккан моның. Шуннан әйттем: «Сезнең квартирагызның номеры фәлән-фәләнме әле? — дидем.— Бер кызыгыз белән бер малаегыз бар икән, иеме?» — дидем. «Ник сорыйсың, ник кирәк алар сиңа?» — ди бу. Тәмам коты очты. «Болай гына,— минәйтәм,— на всякий случай...» Шуннан соң безгә килеп йөрүдән туктады бу. Шулай... Аларның да үз тормышлары, гаиләләре бар, дигәндәй... Балалары бар. Менә бу сержант та майлап куйгандай булды бит. Тәмәкене йөгереп китереп бирде. Бер генә сүз әйттем, югыйсә: «Сержант, мин бер унбиш көннән чыгармын инде, сине күрәсе килә, кайсы урамда яшисең әле син?» — дидем. Аңлады, сизде...

Кинәт ишек биге шалтырап куйды. Ишек ачылып, камерага кемнедер төртеп керттеләр. Алтмыш яшьләрдән узган, зур көрәк сакаллы урыс карты иде бу. Керүгә үк, авыр уфылдап, Хәбир янына килеп утырды. Башын ике кулы белән кысып, үзалдына нидер сөйләнеп, аска иелеп төште.

— За что взяли батюшка?

Карт әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә сорауга игътибар итмәде, һаман уфтанды, нидер сөйләнде, кулларын башыннан алмады. Аннан соң, ике кулы белән тезләренә сукты, сулкылдап елап җибәрде:

— Гөнаһлы мин, балакайлар, нык гөнаһлы... Харап иттем... Үземне дә харап иттем, аны да харап иттем... Гөнаһлы...

Егет дәшмәде. Ул, чыннан да, күпне күргән, кешеләрне бер-ике сүздән таный, аңлый белә иде булса кирәк: карт үз хәлен инде беркемнән сораусыз да сөйләячәк иде.

— Гөнаһлы мин, балалар... Нык гөнаһлы... Зур гөнаһ алдым мин үз өстемә... Ай-й!..

— Нәрсә булды соң, бабай? — диде Хәбир, аның бу сызлануыннан арып.— Бер-бер начар хәл булдымы әллә?

— Ай, улым!.. Нинди начар хәл генә ди ул! Үтердем мин, хатынны, хатын булырга тиешле кешене үтердем...

Егет сызгырып җибәрде. Сикереп үк торды:

— Китсәнә, бабай?! Үтердем диген, ә?! Ну, була икән бүген хәлләр! Ник үтердең соң карчыгыңны?

Карт тагын авыр сулап уфылдады.

— Карчык түгел, яшь кеше иде әле. Кырыкны гына тутырган. Үзе дә гаепле, мескенкәем, тыңламады, аңламады әйткәнне.

— Яшь нәрсә булган икән шул. Каян таптың андыйны, бабай?

— Үз башыма таптым, үз башыма... Үземнең карчык үлде минем, ялгызымны калдырып китте. Әйбәт яшәдек болай, рәнҗеп киткәндер. Биш ел берүзем яшәдем. Балалар... Алар инде таралып бетте, үз тормышлары. Оныттылар мине. Ялгызыма авыр булды. Өйләнермен дип, үземә тиң бер карчык эзләп йөрдем. Ә монысына... Шайтан котыртты, балакайларым, шайтан котыртты.

— Яшьрәкне чамаларга уйладым диген инде! — егет картны әллә үчекли, әллә аның күңелен юатырга тырыша иде.

— Яшь дип түгел, кызганып алып кайткан идем мин аны өйгә. Беркөн шулай кибеткә чыктым. Кибет ишеге төбендә тора бәрәү. Күзләре моңсу... «Бабай, зинһар, илле тиен акча бирче?» — ди. Туктадым мин моның янына: карыйм — чибәр үзе, үзе яшь кенә, күзләре шундый моңсу... «Ни булды сиңа, кызым?» — дим. «Кичә күп эчелгән, баш авырта, бер кружка сыралык кына булса да бирче, бабай? — ди. Өтермәннән чыктым мин, условныйдан,— ди.— Торыр урыным да юк, кая барырга да белмим»,— ди. Әллә ни булды миңа. «Әйдә, наным, йөрмә болай, кайтыйк миңа, сөйләшербез, уйлашырбыз. Син бит чибәр, яшь хатын, сиңа болай йөрү килешми»,— дим. Рәхмәтләр укый-укый ияреп кайтты. «Түлке,— ди,— баш төзәтергә бе-

рәр нәрсә алыйк инде, баш чатный минем, шуннан соң бүтән авызга алмам»,— ди. Сырасын да, виносын да сатып алдым мин моңа.

— Ну, юмарт та картны эләктергән соң, ә! Миңа шундыйрак бер юләре очрасын иде!

— Юмартлыктан түгел, кызганудан. Кызгандым мин аны, чын йөрәгем белән кызгандым. Яшь кенә бит үзе... Пенсияне болай әйбәт алам мин, җәлләп тотарлык түгел. Өч көн буе баш төзәтергә сорады. Өч көн буе шешә ташыдым, сыра ташыдым мин моңа. Өч көннән соң туктады. Юынды, таранды, кеше булды. Шуннан соң күрдем: чибәрләрнең дә чибәре...

Ишек биге шалтырап куйды. Камерадагылар барысы да тынып, сагаеп, көтеп калды. «Мине чакырырлар!..» дигән яшерен өмет үтте Хәбирнең башыннан. Ләкин аңа эндәшүче булмады. Ишектән озын буйлы, өстенә күн пинҗәк кигән егетне керттеләр.

— За что взяли? — дип, гадәтенчә кызыксынып каршылады аны Эдип-Эдик. Керүче кулын гына селтәде, авыз эченнән сүгенеп куйды.

— Тартырга калдырмаганнардыр? Алганнардыр?

Яңа кергән егет, эчке күкрәк кесәсенә кулын тыкты, озак кына актарынганнан соң, башланган «Беломорканал» кабын чыгарды.

— Oho! Болай булгач, яшибез! Ну, молодец, яшереп кала белгәнсең! Нәрсә белән эләктең соң?

— Мин сиңа тәмәке бирдем, тартуыңны бел! — дип кырт кисте яңа егет. Тәмәке кабызганда аның куллары калтыранды, чиктән тыш нервланганы күренеп тора иде.

— Ярар соң,— дип, исе китмәгәндәй, читкә төтен өрде Эдик.— Мин бит болай гына, хәлеңә кереп кенә... Әйдә, бабай, син сөйләп бетер лутчы!.. Чибәр иде дисең инде, ә?

Карт тагын уфылдап алды, тагын ике кулы белән башына ябышты:

— Алла каргышы төште миңа, балакайлар, алла каргышы... Үзем мин аракы эчмәдем, тәмәке тартмадым. Хатын-кыз белән дә чуалмадым ул кадәр... Ләкин картаймыш көнемдә дә чиркәүгә йөрмәдем мин. Аллага ышанмадым. Шуның каргышы гына төште миңа. Каргагандыр ул мине, картлык көннәрен өтермәндә утырып үткәрсен, дигәндер.— Карт бер мәлгә тынып торды, күзеннән бәреп чыккан яшьләрен сөртте.— Теге вакытта бик әйбәт торып киттек. Тик бер атнадан кинәт юкка чыкты бу. Кайгырдым. Бер-бер хәл булгандыр, дидем, бөтен больницалардан эзләттем... Дүрт көн үткәч, кайтып керде. Ниндидер мужикны ияртеп. Кайтып керде: ләх исерек. Миңа әйтә: «Картлач!» ди. Шулай ди: «Картлач! Бу минем бергә утырганда бергә эшләгән иптәш кешем, ул әле күптән түгел генә чыкты, син аны кунак ит, аннан соң ул китәр»,— ди. Нишлисең, өч көн буе сыйладым, өч көн буе кунак иттем боларның икесен. Әй, кыландылар, әй узындылар да соң. Миннән тәмам адәм көлкесе ясадылар. Минем алда үбешәләр, минем алда шәрәтән йөриләр. Түздем. Бозыклыгы чыгып бетмәгәндер әле, өтермәннәрдә йөреп нык бозылгандыр, үтәр, тора башлагач уйланыр, кеше булыр, дидем, шуның хакына түздем. Өч көннән соң икесе бергә чыгып югалды болар. Шул көнне иртән пучтадан пенсия акчасын алып кайткан идем, шкафка куйган идем, шуны эләктереп киткәннәр.

Ун көн югалып йөрде. Шуннан кайтып керде янә. Исерек. Тагын кара янган. Үзе елый, үзе кычкыра: «Акча бир! Башым авырта, үләм, шуны гына эчәм дә, туктыйм, синең янга кайтам»,— ди. «Наталья,— минәйтәм, чыгып йөрмә баркая да, хәзер кибеткә үзем генә барып кайтам, йөрмә»,— дим. «Юк,— ди бу,— үзем барам, үзем алып кайтам, акчаңны бир»,— ди. Кычкыра, ялына, ялвара. Янымда вак акча юк иде. Егерме биш лек бирдем моңа ышанып. «Хәзер кайтам»,— дип

чыгып китте. Тәрәзәдән карап калдым: тыкрыкта теге мужикгы көтеп торган икән... Ике көннән кайтып керде. Карар җире калмаган, беткән... Кайтуга ук әйттем: «Син,— дидем,— оятсыз икәнсең, чын бозык икәнсең!» — дидем. «Монда синең шәлперәйгән нәрсәңә карап ятыйммыни! — ди бу, оятсыз,— Базарда сатсалар, чиләген бер тәңкәгә дә алмыйм мин андый нәрсәнең»,— ди. Шуннан үземне хәтерләмим. Идәндә бәләкәй балта ята иде...»

Хәбир бу хәлләрне коты очып тыңлады. Нинди генә язмышлар юк бу дөньяда... Чит илдә, Әфганстанда чакта ул кара кайгыга баткан хатыннарны, чәчен йолкып үксегән ирләрне аз күрмәде. Анда бәхетсезлек иде, анда сугыш иде... Ә монда? Туган-үскән илдә?

— Тварь!..— бу сүзне камерага яңа кергән егет, күн курткалы егет әйтте.— Син аны кеше итәргә теләгәнсең, ә ул?! Шлюха! Урам ястыгы! Бөтен әшәкелек шулардан. Бөтенесен тимер казыкка утыртып чыгарга кирәк аларның!

— Менә монысы дөрес! — дип куәтләде Эдик.— Дөрес әйттең, брат. Нәрсә, син дә хатын үтереп әләктеңме әллә?

— Причем монда хатын! — дип кистерде егет, кулын селтәп.— Өйләнмәгән әле мин. Өлгермәдем. Ә эләгүем шулар — шлюхалар аркасында!

— Көчләүме?! — Эдикның күзләре ялтырап китте.

— Нинди көчләү! Нинди көчләү ди ул! Көчләрсең, аларны, бар! Үзеңне тотып көчләмәсәләр, рәхмәт әйтерсең!

— Нәрсә булды соң, алайса?

Курткалы егет папиросын чыгарды, бүлмәдәшләренә тәкъдим итте. Карт та, Эдик та алгач, тәмәкегә Хәбир дә үрелде. Шуны тартып караса, җиңелрәк булып китәр сыман иде.

— Өйгә кайтып барыш иде минем...— диде курткалы егет.— Начальникны йөртәм мин, «Волга»да. Шулай, шефны илтеп куйдым да, гаражга барыр алдыннан өйгә кереп чыкмакчы булдым. Тамак ачкан иде. Шунда бер таныш очрады. Безнең урамныкы. «Карале, Сашка,— ди бу, кулындагы сумкасын шалтырата.— Эчәргә бар, капкаларга бар, кызлар бар, бер күңел ачып алыйк»,— ди. Карыйм, артында ике кыз басып тора моның. «Кемнәр соң болар?» — минәйтәм. Ну, баш тартырга инде исәп. Шуннан кызлары да ялына башлады, шлюхалар! Кем уйлаган аны?! Уйларга да өлгермәдем, арткы утыргычка кереп тә ояладылар. «Дачага киттек! Куала, әйдә, машинаңны Васильевога!» — диләр. Таныш егет пышылдап өлгерде. Боларның берсе зур кешенең кызы икән. Дачалары әйбәт,— ди.

Ну, бардык. Эчтек, йокладык. Иртән беренче булып тордым. Машинаны кабызып җылытасы бар бит. Чыгуым булды, күрәм, минем «Волга» тирәсендә милиция кайнаша. ГАИ. Күрделәр мине. «Нишләп йөреш монда?» — диләр, документларны карадылар. «Шефны алып килгән идем, машина ватылды, монда кундым»,— дип алдашам боларга. Инде ышанып китеп баралар иде. Шунда бер сержант, тәмугта терелгәй янасы нәрсә, кире борылды бит. «Ә анда, дачада, тагын кемнәр бар?» — ди. «Беркем дә юк»,— минәйтәм. «Барыбер, карыйк әле»,— диләр. Менә шулай каптым мин...

— Ничек?! ГАИның монда ни катнашы бар? Машинаны гаражга илтмәгән өчен генә монда китермиләр, брат!

— Причем монда машина! Теге сержант керүгә үк сораштыра башлады кызлардан: «Нишләп йөрисез, ничә яшь сезгә», фәлән-фәсмәтән... Тегеләрнең берсе: «Уналты яшь, ә нәрсә?!» — дип әйтеп ташламасынмы шунда. Ишетүләре булды, милиционерлар безгә ябырылды. «Ә-ә, малолеткалар белән маташасыз, яшүсмерләрне бозасызмы?! Нинди статья икәнен беләсезме?!» — дип акыралар. Алып киттеләр барыбызны да туп-туры тикшерүче янына. Анысы, сволочь, кыскан тегеләрне: «Гариза языгыз, мәҗбүр итеп алып киттеләр,

эчертеп көчләделәр, дип, язмасагыз — мәктәбегезгә хәбәр итәбез»,— дигән. Очный ставка ясадылар. Тегеләрне алыштырып куйганнармыни — тикшерүче әйткән һәр сүзгә сайрап кына җавап биреп торалар, сволочьлар! Без аларны эчерткән, мәҗбүр иткән булып чыктык...

— Да, брат, зонада авыр булачак сиңа... Синең статья белән барган кешене бик өнәп бетермиләр анда. Ачуланма, мин сиңа дөресен әйтәм: өч ел ярым как штык обеспечен сиңа. Инде дә котылырга уйлыйсың икән, давай, йә записка яз, йә телдән әйт: кая барырга, кемне күрергә? Миңа унбиш суткадан артык бирмәячәкләр. Ә син судка тикле карантинда ятачаксың әле. Уйла... Ну... Хәбәреңне җиткергән өчен, туганнарың-дусларың мине дә буш итмәсләр инде...

Курткалы егеткә бераз җан керде. Каяндыр гел көтмәгәндә килеп туган өмет чаткысы аның күңелен йомшартты. Тавышындагы кырыслык юкка чыкты, Эдикка йомшак итеп, үтенеп кенә дәште, әнисенең адресын, дачада бергә булган иптәш малаеның адресын әйтте. «Берүк, аның әти-әнисенә дә сугыл, алар ярдәм итмәсме?» — дип кат-кат ялварды.

Хәбир инде үзен бу көнне чакыруларыннан өмет өзде. Вакыт узган саен, ишектәге бик тавышы еш рак яңгырады, камерага әледән-әле кеше кертеп тордылар, әмма аны чакыручы булмады. Бүлмә бөтенләй тынчуланды. Хәбир инде, ничек тә онытылырга теләп, күзләрен йомды. Башта ничектер зур бер яңалык булып тоелган нәрсә — яңа кеше килеп керү дә хәзер сискәндерми, гаҗәпләндерми, кызыксындырмый иде. Бары тик Эдикның гына: «За что взяли? За что попал, браток?» — дигән бер төрле сораулары ишетелеп торды. Үзара сөйләшүләргә, аклануларга, тәүбә кылуларга, янауларга, сүгенүләргә Хәбир инде хәзер тәмам битараф иде. Куе төтен, тәмәке исе борынга-күзгә кереп ачыттыра, үрти, әрнетә. Хәбир, башын якасы белән каплап, мондагы сүзләрдән, сасы истән, төтеннән качарга тырышты. Кинәт аның хәтеренә Муса Җәлилнең бер шигыре килеп төште. Әйе-әйе... «Төрмәдә төш» дип атала түгелме соң әле ул шигырь?

Төштә миңа нәни кызым килде...

Ул башта: «Әллә чынлап та төш күрәм инде?» — дип сискәнеп китте: кызы, кулларын сузып, аңа карап тора, аңа тартыла, бәргәләнә сыман иде. Юк, төш түгел икән, бары тик күз алдына гына шулай аермачык булып килеп баса икән. Хәбир аның йөзен, күзләрен, ирен читендә сизелер-сизелмәс кенә булып торган миңен күргәндәй булды. Кызын шулай якыннан күргәндә эндәшмичә кала алмый иде ул:

— Менә, кызым...— дип пышылдады Хәбир.— Менә без туган илгә кайтып җиттек, кызым... Үзебезнең илгә...

## XV

Таһир юл буе сүзсез барды. Машина олы юлдан чыгып, Балтамак күренгәч, ул утырган урынында берөзлексез боргалана, кыбырсый башлады.

Район үзәгендә чакта, Овчинников һәм Төхфәтуллин белән кунакханәдә сөйләшеп утырганда ук инде Таһир үз авылына ничегрәк кайтачагын күзаллап газапланган, борчылган, интеккән иде. Овчинников кичә кич аларга әйтте:

— Сабирҗановның этисе белән барып сөйләшергә, күзгә-күз карап аңлашырга кирәк, шунсыз булмый,— диде.— Улы хакына ул муллалыгын ташларга тиеш. Аңлатырбыз, үгетләрбез. Тик бу вакытта Әхсән Сабирҗанов үзе авылда булмаса яхшы. Без аны районга

чакыртырбыз. Бикташев янына.

Шушы сүзне ишеткәч, эчтән калтыранып куйды Таһир. Күзалдына Әхмәтгали карт килеп басты. Менә ул, комиссия членнары белән бергә. Әхмәтгали картның өенә керә. Әхмәтгали абзый... Хәбирнең этисе... Балачакта күпме булды Таһир бу өйдә, Гөлчирәтти пешергән кабартмаларны күпме ашады?! Әхмәтгали абзый кырыс кеше иде, әмма ул малайларны тыймады, кумады: печәнлеккә менеп печән таптасалар да, койма башын сындырсалар да, бакчадагы шомырт агачына үрмәләп менсәләр дә каты сүз әйтмәде. Әхмәтгали абзый... Хәзер менә Таһир аның өенә зур кеше, Казаннан килгән тикшерүче булып барып керергә, аңа акыл өйрәтергә, иманыңнан яз, дип үгетләргә тиеш...

Таһир төне буе шушы хакта уйланып чыкты.Бу комиссиядә катнашырга ризалык бирүе өчен үзен кат-кат тиргәде. Иртәгә Балтамакка кайту аның җанын телгәли, йөрәген авырттыра, күкрәген кысып тора иде. Таһирга хәтта шулай тоелды: Минзилә белән ике арада килеп чыккан хәлләр, гаиләсенең кинәт җимерелеп китүе, хатынын, улын югалтуы иртәгә булачак вакыйгалар янында ваграк, бәләкәйрәк бер кайгы кебек иде.

Таһирны куркыткан тагын бер нәрсә — Хәбирнең инде өйдә булуы. Казаннан кайтып җиткән булуы иде. Ул үзен башта тынычландырды: Хәбир бит кызының больницада икәнен әйткән иде аңа. Ләкин тора-бара, Балтамакка барасы сәгать якынлашкан саен, Таһирның да күңеленә төрле шик керә башлады. Кыен, бик кыен хәлдә калды Таһир... Һәм ул моны бары тик үзе генә аңлый, үзе генә белә иде.

— Шушымы синең туган авылың, иптәш Корбанов?

Таһир сискәнеп китте. Авылын чынлап та танырга теләгәндәй, алгарак иелә төште, ерактан каралып күренгән йортларга төбәлде.

— Шушы...

— Туган якка, туган авылга кайту һәркем өчен зур шатлык,— Овчинников, хисләнеп, хыялга чумып, күзләрен йомды, утыргычка киерелеп ятты.— Авылыңа алып кайткан өчен әҗере синнән тиеш, иптәш Корбанов!..

Төхфәтуллин да аңа кушылып көлде. Әмма бу шаярту мыскыллап көлү булып тоелды Таһирга. Чөнки ул, бер генә минут элек, тагын бер яңа уй белән сискәнеп, тәрәзәдән күренмәскә тырышкандай, утыргычка сеңгән иде. «Шәкүр малае тикшерү белән кайткан! Тамагын туйдырган, үстергән авылына комиссия алып килгән, Шәкүр малае ашаган табагына төкергән!..» — авылда үзе киткәч үк таралачак шушы сүзләрне ул аермачык ишеткәндәй булды.

Машина урамга килеп керде. Райком шоферы Әхсәннәр торган йортны белә икән: беркемнән сорашмады-нитмәде, авыл үзәгенә таба юл тотты.

— Анатолий Петрович...— Таһир, юл буе әзерләнеп килгәндәй, кисәк кенә Овчинниковка таба борылды: — Мин Сабирҗановларга керә алмыйм, Анатолий Петрович.

— Мин сезне аңламадым. Эш нәрсәдә?

— Аңлагыз. Бу — минем туган авылым. Әхсән Сабирҗанов — минем балачак дустымның абыйсы. Әхмәтгали Сабирҗанов — аның этисе...

— Шуннан ни булган?

— Мин... Мин Әхмәтгали абзый белән сөйләшә алмаячакмын!

— Сез бик кызык кеше икән, иптәш Корбанов! Безне монда, вәкаләтле комиссия итеп, партия өлкә комитеты исеменнән җибәрделәр. Комиссиянең җитәкчесе мин булсам да, эшнең нәтиҗәсе өчен без барыбыз да бергәләп җавап бирәбез. Сез дә, мин дә, Тәлгать Ахунович та.— Овчинниковның йөзе кырысланды, яңакларында кызгылт

тимгелләр калкып чыкты.— Безгә бит карт белән аңлашырга кирәк. Мин татарча белмим. Тәлгать Ахунович, үзегез күреп торасыз, ярым-йорты гына сөйләшә. Безнең бөтен ышаныч сездә, ике арада сез тылмач булырга тиеш! Дөрес бит, Тәлгать Ахунович?

— Әлбәттә, шулай!

Таһир аңлады: аңа инде артка чигенү юлы юк иде. Шулай да ул, бөтен күңеле белән карышып, Әхмәтгали картларга керүне ничек тә кичектерергә, соңартырга, ерагайтып торырга тырышты:

— Бәлки, башта минем әни янына тукталырбыз? Юкса, бик уңайсыз бит, авылга кайтып та, иң элек аның янына кермәгәч. Күптән күрешкән юк лабаса...— диде.

— Башта эшне тегәлләргә кирәк, дип кырт кисте Овчинников.— Әни карчыкны күрергә соңыннан да өлгерербез. Көн безнеке, үзебезнеке бит!..

Машина капка төбенә килеп туктауга, кайдадыр эчтә ишек шапылдаганы ишетелде. Капкада яланөс килеш шәл бөркәнгән Гөлчирәтти күренде.

— Бәрәкалла!.. Әллә соң Хәбир улым кайттымы?!

— Исәнмесез, апа!

— Здравствуйте!

— Исәнме, Гөлчирәтти...

Гөлчирәтти бу көтелмәгән кунакларга бик гаҗәпләнде, әле берсенә, әле икенчесенә карап, сәламнәренә каршы сәлам белән җавап кайтарды:

— Бик шөкер... Аллага шөкер! Исән-саулармысыз! Здрачте!...

«Танымады...» — дип уйлады Таһир. Гөлчирәттинең үзенә аерым игътибар итмәвен күреп. Һәм ул бу танымауга шатланырга да, кайгырырга да белмәде.

Әхмәтгали карт кияве Мәҗит белән абзар-кура тирәсендә кайнаша иде. Капкадан керүчеләрне күргәч, икесе дә каршыга ашыктылар.

— Шәкүрнең улы түгелме соң бу?..— Әхмәтгали карт күрешкән чакта аңа текәлеп карады.

— Әйе, Әхмәтгали абзый, дөрес әйтәсең. Шәкүр малае мин... Таһир.

— Танымый да торам! — дип, үзенә-үзе гаҗәпләнде Гөлчирәтти.— Менә сиңа кирәк булса! Үзебезнең Таһир икән ләбаса! Мин тагын әллә нинди зур нәчәлникләр килде дип торам! Әйдәгез, кунаклар, өйгә керик, әйдәгез... Озакка кайттыңмы? Әниеңнең хәле ничек, аны да күргән юк бу соңгы араларда...

Ни диярга белми торган Таһирны Әхмәтгали карт коткарды:

— Карчык, син кунакларны өйгә чакыр, өйгә. Аяк өсте сөйләшүдә мәгънә юк. Өйгә керик, оланнар...

Чәйне бал белән, яңа аерткан каймак белән, вак-төяк сүз белән эчтеләр. Гөлчирәттинең кунакларны кат-кат кыставы гына сүз араларындагы бушлыкны тутырып торды.

Әхмәтгали карт артык сүз сөйләшми. Машинада утырып килгән бу кешеләрнең йомышын тәгаен генә белмәсә дә, күңеле нидер сизенә, борчыла иде шикелле. Тагын шуны сизде карт: «Әниеңне күрдеңме соң әле?» — дигән сорауга килделе-киттеле җавап кайтарды мәрхүм Шәкүр улы. Болар туп-туры шушы өйгә килгәннәр. Әхсән янына килсәләр, иң элек аны сорарлар, аны белешерләр иде. Әхсәннең районга киткәнен инде белделәр, тик бу хәбәргә кунаклар әлләни илтифат итмәде. Димәк... Ни йомыш белән йөри болар?? Шәкүрнең улы ни өчен аларны нәкъ менә шушы йортка алып кергән? Әллә соң?.. Әллә Хәбирдән бер-бер хәбәр алып кайтканнармы? Башка бер йомыш белән йөрүләреме? Шулай уйлады карт. Шуларны уйлап, әйтеп куйды:

— Әхсәннең өйдә туры килмәве әйбәт булмады шул...

Аның бу сүзе, күрәсең, кунакларның тел төбен чишәр вакытына туры килде:

— Безнең өчен Әхсән Әхмәтгалиевичның өйдә булмавы яхшырак та,— диде Төхфәтуллин, я ıəшәдә утырган Овчинников белән күзгә-күз карашып алгач.— Без сезнең үзегез белән генә сөйләшеп булмасмы дип килгән идек, Әхмәтгали агай...

Мәҗит сүзнең җитди нәрсә турында барачагын бары тик хәзер генә аңлап алды.

— Бабай, башлаган эш — беткән эш, диләр, мин үзем генә чыгып маташтыра торыйм әле,— дип, чөйдәге киеменә үрелде. Әхмәтгали карт сүз әйтмәде. Чынаягын чәй тәлинкәсенә каплап, ике кулы белән битен сыпырды; аннан соң гына Гөлчирәттигә таба борылды:

— Карчык, бүген җомга көн, киленнең төп йортына барып, энисен күреп кайт, савабы булыр,— диде.

Өйдә алар дүртәү генә калды. Башта бер мәлгә тынлык урнашты. Авыр тынлык, кешене басып, изеп, кысып торган тынлык иде бу.

— Әхмәтгали агай,— диде, ниһаять, Төхфәтуллин.— Безнең Казан тикле Казаннан сезне күрергә дип килүебез юкка гына түгел. Сезнең гаилә өстеннән, дөресрәге сезнең улыгыз Әхсән өстеннән обкомга җалоба хаты бар...

Әхмәтгали карт тетрәнеп куйды. Әмма үзендәге бу үзгәрешне тышка чыгармады, сиздермәде. Бары тик җиңелчә калтыранган куллары гына аның чиктән тыш дулкынланганын күрсәтеп тора иде: табындагы ипи валчыкларын сыпырган булып, карт монысын да яшерергә тырышты.

— Дөресен генә әйткәндә, шул: сезнең мулла булып йөрүегез улыгызның парторглык эшенә нык комачаулый, Әхмәтгали агай. Сез аңларга тиеш безне...

Әхмәтгали карт башта Төхфәтуллинга, аннан соң Овчинниковка карады. Овчинников баш какты. Шуннан соң Әхмәтгалинең сораулы, гаҗәпләнүле карашы Таһирга күчте: «Аңлат, улым... Ничек? Эш нәрсәдә? Ничек комачаулыйм мин Әхсән улыма?» — дип карый иде аның күзләре. Таһир башын читкә борды, тәрәзәдән урамны күзәткән атлы булып кыланды.

— Улыма... Мин аның эшенә нинди зыян салам? — диде карт, ниһаять. Бу сорауны ул нигәдер Овчинниковка карап бирде. Төхфәтуллин аның сүзләрен тәрҗемә итте.

— Без сезнең улыгыз белән дә сөйләштек,— дип җавап кайтарды Овчинников һәм, картның русча аңлавын сизеп, дәвам итте: — Беләсезме, аңа кыен. Күз алдыгызга китерегез: сез — мулла, улыгыз — партиянең башлангыч оешмасы секретаре. Идеолог. Ә сез аталы-уллы бер йортта торасыз. Халык арасында чыш-пыш китә. Гомумән, бу безнең эшкә бик нык зыян китерә. Әхсән Әхмәтгалиевичнең үзенә дә бик кыен. Әлбәттә, ул үзе бу хакта сезгә әйтми, сиздермидер. Чөнки сез — аның әтисе. Сездә, татарларда, ата кешегә каршы әйтмәү, аның сүзенә колак салу кебек гадәт бар. Начар гадәт димәс идем мин моны. Но... Бу очракта сез безне аңларга тиеш, Әхмәтгали Сабирҗанович...

— Әхсән сезгә минем белән сөйләшү турында үзе әйттеме?

— Юк, ул үзе әйтмәде,— дип сүзгә катышты Төхфәтуллин.— Тик безгә шулай тоелды: ул сезнең дин юлында йөрүегезгә бик нык борчыла, бу хакта сезгә әйтергә кыймый...

Әхмәтгали карт дәшмәде. Башын аска иеп, тын гына уйланып торды. Аның инде куллары калтырамый, йөзендәге аптырау, чиктән тыш гаҗәпләнү галәмәте дә юкка чыккан иде.

— Таһир улым,— дип дәште ул кинәт. Таһир, күзләрен тәрәзәдән алып, ялт итеп аңа таба борылды. Әхмәтгали карт аның бу сискәнүен әллә күрмәде, әллә күреп тә игътибар итмәде.— Синең гәҗиттәге язганнарыңны укыштырып барам мин. Үзең кайткач, бер сорармын

да әле,дип йөри идем. Гөнаһка батмасын бу бала, дип, синең өчен дога кылган чакларым да булды. Коръән шәрифләренә нахакка тел тигерәсең син, улым...

Сүз әллә ничек кире якка китте. Моны Төхфәтуллин да, аның тәрҗемәләвеннән чамалаган Овчинников та сизеп алды. Ул инде сүзне яңадан үз эзенә кайтарырга, элекке юнәлешенә борырга ашыкты.

— Сезгә бер сорау бирәсем килә минем, Әхмәтгали Сабирҗанович,— дип бүлдерде ул нәрсәдер әйтеп акланырга, җавап кайтарырга тырышкан Таһирны.— Минә сез, ишетеп белүемчә, озын һәм катлаулы гомер юлы үткән кеше. Сугышка кадәр комсомол активисты булгансыз. Сугышта катнашкансыз, илнең бер батыр солдаты буларак, җиңеп кайткансыз. Неужели минә хәзер инде сез аллага ышанасыз, табынасыз? Мин моны аңлап бетермим. Сездәге бу үзгәрешне дип әйтүем...

— Руслар дини кешеләрне верующий дип атый, кем, улым,— дип салмак кына җавап кайтарды Әхмәтгали карт.— Верующий булгач, ышанучы кеше булып чыга инде ул. Минә шул яктан карасаң, сез үзегез дә верующий түгелме соң? Сез дә бит нәрсәгәдер ышанасыз. Димәк ки, улым, сез дә нәкъ минем кебек үк верующий кеше.

Овчинников елмайды. Дөресрәге, аның бу елмаюы картның сүзеннән канәгать калуыннан түгел, ә бәлки аларның мәгънәсенә төшенеп, җавап табып өлгерергә тырышудан иде.

— Ләкин ышану белән ышану арасында зур аерма бар, Әхмәтгали Сабирҗанович. Без, мәсәлән, балачактан бирле бер идеология белән тәрбияләндек, үстек. Безнең материалистик карашлар яшь вакыттан формалашты. Һәм ул үзгәрми, гел бер төрле булып кала бирә. Ә минә сезнең — яшьлектә бер төрле, олыгайгач — икенче төрлерәк. Хәтта капма-каршы, дип әйтимме...

— Кеше дигәнең, улым, дөньяны төрле яшьтә төрлечә аңлый. Бала бу тирә-юньне үзенчә кабул итә. Яшүсмер — үзенчә. Карт кеше исә шулай ук үз акылы, үз тәҗрибәсе аша күрә хәятны. Дөньяны гел бер төрле генә кабул иткән, яше үзгәреп тә, карашы үзгәрмәгән кеше үсми, җитлекми калган дигән сүз. Аның акылы да, рухы да гел бер төрле булып, алла тарафыннан яратылган шушы җиһанны танып-белүе бер дәрәҗәдәрәк кала.

Овчинников янә елмайды. Нишлисең бит, дигәндәй, Төхфәтуллинга һәм Таһирга карап, кулларын җәйде.

— Сезнең белән сөйләшүе кызык,— диде ул, һаман да елмайган килеш.— Ләкин, Әхмәтгали Сабирҗанович, безнең бу бәхәс чисто теоретически бара. Ә инде практик мәсьәләгә килсәк, безгә ныклап аңлашырга кирәк. Сез бит акыллы, тәҗрибәле кеше, улыгыз Әхсәннең юлына аркылы төшмәгез. Ул өметле, яшь партия работнигы. Без аңа зур өметләр баглыйбыз, аны үстерергә телибез. Партиягә Әхсән Сабирҗанов кебек намуслы, гадел, тырыш кешеләр кирәк. Халык та аны бик хөрмәт итә икән. Без бу турыда сораштырдык. Үзегез уйлап карагыз: мулла белән партком секретаре бер йортта яши алмыйлар бит инде?!

— Безнең улым белән бер йортта яшәвебез, кем, олан, аның эшенә дә, кем булуына да бәйле түгел. Әхсән минем нәселем: шушы нигездә туып, үскән шушы нигезне дәвам итәчәк балам.

— Ләкин ул — партия кешесе! Мулла белән парторг бер нигезгә, бер йортка берничек тә сыеша алмый!

— Гаилә — дәүләтнең бер кечкенә кисәге, өлеше дип әйтәләр иде без яшь чакта. Гаилә дәүләтнең бер өлеше булгач, димәк, безнең йорт та, безнең нигез дә дәүләтнең бер күзәнәге була инде. Ә дәүләттә — сезнең партия дә, чиркәү дә, мәсҗет тә үзара тыныч яши, үз эшен эшли, кешеләрнең күңелен, рухын изгелеккә өнди. Моһысы ил күлә-

мендә. Безнең йорт та үзебезнең нәсел өчен бер ил кебек инде ул, олан.

— Әхмәтгали Сабиржанович!.. Сез безне һаман аңлап бетермәдегез. Без бит зур үтенеч белән килдек. Һәм бу үтенеч үзебез өчен түгел, сезнең улыгыз өчен. Неужели сез улыгыз хакына, аның киләчәге хакына шул муллалыктан баш тарта алмыйсыз?! — Овчинниковның бу сүзләрендә гаҗәпләнү генә түгел, ниндидер ризасызлык, түземсезлек чаткылары күренде.— Улыгыз хакына бит, үз балагыз хакына, аңлыйсызмы?!

Әхмәтгали карт озак кына җавапсыз торды. Аның җилкәсе бөкерәеп, юкарып калгандай булды.

— Олан,— диде ул Овчинниковка туп-туры күтәрелеп карап.— бала хакына малыңны биреп була. Бала хакына ата кеше гомерен бирә ала. Әмма иманыңны хәтта бала хакына да биреп булмый...

Урамга чыккач, Төхфәтуллин башын селкеп елмайды:

— Ай-һай, үҗәт кеше булып чыкты бу карт...

Овчинников кулына перчатка-бияләен кия алмый азаплана иде.

— Үҗәт кенә түгел, бөтенләй ычкынган кеше бу! Аңламыйм, аңлый алмыйм мин мондый кешеләрне!

Шофер аларны көтеп зарыккан иде инде. Ашыгып, моторны кабызды: аның җылынганын көтептер инде, урыннан кузгалмый торды.

— Ник монда торабыз һаман?! — дип кырыс кына эндәште аңа Овчинников.— Кузгал әйдә, киттек тизрәк!

Өлкә комитет инструкторының болай кызган чагын Таһирның әле күргәне юк иде. «Минем үз өемә, әни янына кереп чыгасы барын оныттымы әллә?» — дип уйлады ул. Һәм, машина авылдан чыгып киткәнче әйтеп калырга дип, ашыгып эндәште:

— Анатолий Петрович... Миңа бит, ни... Әнине күреп чыгарга кирәк иде...

— Сез калырга булдыгызмы? Ул чакта, иптәш Корбанов, сез Казанга үзегез генә кайтырсыз.— Ул сәгатенә күз төшереп алды.— Ә без, мөгаен, әгәр өлгерә алсак, икенче рейс белән очарбыз да.

— Өлгерә алмабыз, Анатолий Петрович,— дип сүзгә кушылды Төхфәтуллин.— Безгә бит әле иптәш Бикташевны күрергә, тагын бер мәртәбә ныклап сөйләшергә кирәк.

— Сөйләшербез. Әмма анда безнең сүз бик кыска булачак!

Таһир машинаны тау өстенә менеп күздән югалганчы озатып калды. Аннан соң, борылып, урам буйлап китте. Аяк астында кар шыгырдавын ул бары тик шушы мәлдә генә ишетте. Бу карның шыгырдавы артык таныш та, артык ят та сыман иде аңа...

## XVI

Иртәннән башлап, камерадагыларны берәм-берәм каядыр чакыра башладылар.

— КПЗ га озаттылар,— диде Эдик беренче булып чакырылган кеше кире кайтмагач.— Прокурордан санкция көтәчәк бу хәзер.

Яшь хатынын харап иткән картны да чакырып алдылар. Шуннан ул да кире кермәде.

— Монысы нәрсә? — дип пышылдады Хәбир Эдикка, аксыл гына чәчле ябык чырайлы бер егет суд тикшерүчесенә чакырылган җиреннән кире әйләнеп кергәч.— Кеше чәнчедем, дигән иде бит. Аны озатмыйлармы?

Егет тә шулай ук пышылдап кына җавап кайтарды:

— Юк, абзый, моны озатмыйлар. Бу әле көне буе утырачак монда бүген. Кеше җанын савып. Стукач бу, абзый. Мин аны кичә үк

раскусил.

Ишек шалтырап ачылды:

— Сабирҗанов! На выход!

Хәбиргә җан керде: ниһаять! Инде хәзер ул үзенең рәнҗү сүзен кирәкле кешенең йөзенә бәреп әйтә алачак!

— Ярый, абзый, көрешмәсәк, исән-сау бул... — Эдик аның кулын кысты.— Эч пошканнан сөйләп яткан сүзләрем өчен ачуланма. Шундый гадәт бар минем, кешедән бераз көлә торган...

Милиционер аны икенче катка — зур һәм иркен бер бүлмәгә алып менде. Бүлмә түрендә капитан дәрәҗәсендәге хатын-кыз милиционер утыра иде. Ул Хәбиргә урын тәкъдим итте. Сержантка «Китәргә мөмкин» дип ишарәләде.

— Мине бу шайтан абзарыннан кайчан чыгарып җибәрәсез?! — Хәбир камерада чакта уйлап-әзерләп куйган сүзләрен шул мәлдә онытты.— Сезнең бу эшегез эзсез-җавапсыз узар дип уйлыйсызмы?!

Капитан дәшмәде, алдындагы кәгазьләренә иелеп, нәрсәдер актарды, нәрсәдер эзләде. Хәбир аның йөзенә ныклабрак игътибар итте: арган, йончыган кыяфәт, яше утыздан шактый өстә булса кирәк, кысылган иреннәре нәрсәнедер өнәп бетермәвен күрсәтеп тора.

— Сез, гражданин Сабирҗанов, мине куркытмагыз. Мин инде ун елдан артык ишетәм мондый сүзләрне. Һәр җинаятьче миңа үзенчә яный. Берсе төрмәдән әйләнеп кайтачагына ишарәли. Икенчесенең, ачуым килмәгәе, туганы юстиция министры булып чыга. Янаучылар күп... Ләкин минем кулга эләккән кешенең янап кына котылып кала алганы әлегә юк. Аңладыгызмы?

— Мин сезгә янамыйм. Мин, гомумән, үземнең ни өчен монда килеп эләгүемне аңламыйм! Сез бит мине законсыз рәвештә кулга алуыгызны үзегез дә белеп торасыз! Минем кызым больницада ята. Хәтта миңа анда шалтыратып әйтергә дә рөхсәт итмәделәр!

— Анысын тикшердек. Кызыгыз, чыннан да, больницада. Әмма сезгә, гражданин Сабирҗанов, каядыр шалтыратырга ирек бирмәүләре законга бик тә сыя торган эш. Сез — үзегезнең следователь күзәтүе астында икәнегезне онытмагыз. Әйдәгез, бәхәсләрне бер читкә куеп, эшкә күчик. Сез, Мәскәүдән кайтып төшкәннән соң, «Казан» кунакханәсенә урнаштыгыз, шулаймы?

— Әйе. Кызымны больницада калдырганнан соң... Казанда вакытлыча тукталырга туры килде.

— Кичә сезнең кунакханәдәге бүлмәгездән бер сумка табылган, шулаймы?

— Әйе, миңа аны иртән Ахо калдырып чыккан иде. Кичкә кадәр торып торсын, дип.

— Димәк, сез Ахо Давыдов белән таныш булуыгызны яшермисез? Монысы әйбәт. Хәер, яшерүдән файда да юк.— Тикшерүче Хәбир алдына фоторәсемнәр этәрде.— Сезнең Ахо белән, ягъни «Лимон» белән ресторанда гәпләшеп утырган чагыгыз бу.

Хәбир, гадәттән тыш гаҗәпләнеп, алдында яткан рәсемнәрне карады:

— Безне кемдер күзәтеп, фотога төшереп йөргән!?

— Дөрес аңладыгыз, гражданин Сабирҗанов. Без инде «Лимон»-ны күптән күзәтә идек. «Татарстан» поездыннан да күтәреп алдык. Тик ул, соңыннан белүебезчә, сезнең белән бергә китеп өлгергән икән. Кыскасы, гражданин Сабирҗанов, «Лимон» калдырган сумкадагы алтынның каян килүен, кемнеке булуын, үзегезнең арадагы элемтәләрне яшермичә сөйләп бирергә тиеш буласыз. Күреп торасыз, тел яшерүдән сезгә файда юк...

— Нинди алтын? — дип гаҗәпләнде Хәбир һәм, эшнең катлаулана баруын сизеп, аңлатырга ашыкты: — Беләсезме, мин бит Ахо

белән поездда гына таныштым. Аннан соң очраклы рәвештә кунакханәдә күрештек. Ул миңа ярдәм итте, кунакханәгә урнашырга. Бары тик шул гына. Без бит кызым белән чит илдән кайтып килә идек, Әфганстаннан...

— Чит илдән кайтып килүегезне беләбез. Алтын каян килде, дип сорыйм мин сездән. Алтын кемнеке? Ничек итеп ул сезнең кулга килеп керде. Ни өчен «Лимон» аны нәкъ менә сезгә китерде?

— Белмим. Ул бары тик миндә үзенең сумкасын гына калдырып торды. Кич белән кереп алам, диде.

— Бу сүзегезне мин ишеттем инде. Без аны кичә көттек, ләкин ул кире әйләнеп кермәде?

— Чөнки мин аңа өйдә була алмавымны әйттем. Больницадан соң мин үземнең бер танышыма кунакка барырга тиеш идем.

— Кем янына? Ул танышыгызның адресы, исеме?

Хәбир тикшерүчегә гаҗәпләнеп карап торды:

— Сез нәрсә? Инде минем танышларым белән дә кызыксына башладыгызмы?

— Ә нигә кызыксынмаска? «Лимон» сезгә алтын китергән. Ә сез кич белән әлеге дә баягы танышларыгызга барырга тиеш булгансыз. Үзара бәйләнеш юкмыни монда? Монысы бер... Икенчедән, әгәр сез аларның чыннан да булуын, танышларыгызның барлыгын курыкмыйча әйтәсез икән, димәк, гаепсез икәнлегегезне исбат итәргә тырышасыз дигән сүз. Шулай түгелмени?!

Хәбир үзен ниндидер чытырманлыкка кереп уралган, шуннан котылу юлын эзләп чәбәләнгән кеше сыман итеп тойды. Бу тикшерүче аның гаепсез икәнен болай да ачыктан-ачык күреп тора, ләкин күрәләтә аны чытырманлык эченә этеп кертергә, адаштырырга тырыша кебек иде.

— Мин... Ул танышларымның адресы минем кесәмдә, блокнотымда иде. Аны кичә алып калдылар...

— Адресны табарбыз. Танышыгызның исеме ничек?

— Таһир... Таһир Корбанов. Хатыны — Минзилә...

Тикшерүче өстәл читендәге төймәгә басты. Бүлмәгә кергән сержантның каршына барып, нәрсәнедер озаклап аңлатты.

— Сез безгә әлеге адресны табып бирерсез,— диде ул сержант чыгып киткәч.— Ә хәзер «Лимон» турында сөйләшик. Сез танышларыгызга баруыгызны әйттегез аңа. Ә сумка артыннан кайчан керергә тиеш иде соң ул?

— Бүген... Мөгаен, кичкә таба. Иртәнге якта минем больницага китәсемне белә ул.

— Кичке яктамы? Бик яхшы! Аны көтәләр кунакханәдә, көтәләр!

Ишектән баягы сержант керде. Аның кулында Хәбирнең кесәсеннән алынган кәгазьләр, куен дәфтәре иде.

— Бая әйткән адресыгызны табып бирегез безгә, гражданин Сабирҗанов...

Хәбир ашыгып актарынды, Таһир калдырган язуны таба алмый азапланды. Ниһаять, адреслы кәгазьне тикшерүчегә сузды. Тикшерүче, Таһирның адресын күчереп язганнан соң, сержантка ым какты:

— Бая сөйләшкәнчә эш итегез!

Сержант чыгып киткәч, тикшерүче кулларын уып куйды, өстәл тартмасын ачып, сигарет алды. Хәбирнең каршына утырды да, күзләрен кысып, аңа төбәлде:

— Тартасызмы?

— Мине кайчан чыгарып җибәрәсез?

— Ә мин үзем тартам. Йә бик кайгырганда, йә шатланганда. Әлбәттә, хатын-кызның тартуын ирләр өнәп бетерми бугай...

— Сез минем сорауга җавап бирмәдегез.

Тикшеручe тәмәке төтенен Хәбиргә таба өрде.

— Сез, гражданин Сабирҗанов, әллә юри простак булып кыланасыз, әллә чынлап та үзегезнең хәлне аңлап бетермисез. Нәрсәгә ышанасыз сез? «Лимон»ның дәшмәвенәме? Ялгышасыз, бик нык ялгышасыз. Мин бит «Лимон»ны биш бармагым кебек беләм. Ничә тапкыр үтте инде ул минем кулдан! «Лимон» — вак спекулянт, алтын һәм валюта кебек әйберләр белән эш итү аның кулыннан килми. Менә бу юлы да ул, кулына алтын керүгә, кая барырга белмичә чәбәләнгән, шуның аркасында эзенә төштек тә инде без аның. Ә бит, югыйсә, без аны шул һинд* чәе өчен бер акылга утыртып алырга уйлаган идек. Азды ул соңгы вакытта. Мәскәүдән без аны күтәп алдык, прокурордан тентү өчен санкция алып, иртүк барып кердек өенә. Ә ул, шельма, этисенең машинасына утырып, таң алдыннан ук каядыр чыгып тайган. Чәен яшереп өлгергән. Тынычланып, барысы да тәртиптә дип кайтып керсә, тентү белән килүебезне әйтәләр тегеңә. Ә ул, юләр баш, артыннан күзәтү барын да уйламыйча, өеннән сумка күтәреп чыгып йөгерә! Бер уйласаң гаҗәп түгел: аның моңарчы алтын эше нәрсә белән эш иткәне юк, ул инде куркуыннан астын юешли һәм, әлбәттә, сезнең янга чаба. Сез тәкъдим иткән алтынны кире тапшырырга... Логика бармы минем сүзләрдә? Әллә юкмы, гражданин Сабирҗанов?!

— Сез миңа күрәләтә яла ягасыз! Ничек инде мин тәкъдим иткән алтын?! Миндә каян килеп алтын булсын?! Акылыгыздамы сез? Мин Ахо белән бары тик поездда гына таныштым. Мин аны бары тик берничә тапкыр гына күрдем. Телисез икән, ул моны үзе аңлатып әйтеп бирә ала!

— Әлбәттә, әлбәттә!.. Менә шулай уйлап ялгышасыз да инде сез, гражданин Сабирҗанов. «Лимон»ны сез, чынлап та берничә тапкыр гына күргәнсез шул, аз беләсез әле сез аны. Шуңа күрә, аңа өметләнеп, ачыктан-ачык сөйләшергә ашыкмыйсыз. Тик мин сезне алдан ук кисәтеп куям: «Лимон» төрмәгә эләгүдән уттан курыккан кебек курка. Мин инде аны әллә кайчан рәшәткә артына озата ала идем. Ләкин ул, төрмә сүзен ишетүгә үк, сабый бала кебек елый башлый, антлар эчә, сүз бирә... Сүзендә генә тормый үзе, имансыз. Кыскасы, «Лимон»га сез юкка ышанасыз.

Хәбир тикшерүчегә чын-чынлап гаҗәпләнеп карап торды.

— Карагыз әле...— диде ул, урындыгын алгарак тарта төшеп.— Мин... Мин сезнең исемегезне белмим...

— Минем фамилиям Әбдрәҗәкова. Гражданин следователь дип кенә эндәшсәгез дә була.

— Иптәш гражданин Әбдрәҗәкова... Сез бит минем бер гаебем дә юк икәнне бик белеп торасыз. Нигә дип үзегезнең дә, минем дә башны бутыйсыз сез? Мине больницада кызым көтә. Сез бит хатын-кыз, аз гына булса да аңларга тиешсез кеше хәлен!

— Мин хатын-кыз гына түгел, гражданин Сабирҗанов! Мин — тикшерүче! Әгәр гаебегез юк икән, сез аны исбат итәргә тиеш буласыз.

— Минем белүемчә, закон шулай куша: иң элек сез минем гаепле булуымны исбат итәргә, аннан соң гына кулга алырга тиеш!

Әбдрәҗәкова усал итеп елмайды:

— Закон... Законны белүегез яхшы анысы... Тик сез, гражданин Сабирҗанов, бер нәрсәне онытасыз: закон ул — намуслы, күңеле чиста кешеләр өчен. Ә менә алтын белән эш йөртүчеләргә бездә законның «з» хәрефе дә юк! Аңладыгызмы?!

— Аңладым,— Хәбир урыныннан күтәрелде.— Мине, зинһар, прокурор белән элемтәгә кертегез. Мин бүтән сезнең белән сөйләшергә дә, бәхәсләшергә дә теләмим. Законны саклаучы берәр кеше бардыр бит бу шәһәрдә?

— Прокурор белән без үзебез керербез элемтәгә, гражданин Сабирҗанов! Сезне кулга алыр өчен санкция сорап. Ләкин аңынчы әле «Лимон»ны табарга кирәк. «Лимон»ны!.. Аннан соң инде без сезнең белән бүтәнчәрәк сөйләшербез! — Әбдрәҗәкова чакыру төймәсенә басты. Ишектә күренгән милиционерга кул селтәде: — Алып чыгыгыз!

Камерада кеше сирәгәйгән иде. Эдик, күптәнге танышын каршылагандай, Хәбирне кочак җәеп каршы алды:

— О-о!.. Мин инде, абзый, сине КПЗга олактырдылар дип торам. Йә, ничек? Кысалармы?

Хәбир, сүзсез генә эскәмиягә килеп утырды. Бик каты итеп сүгенәсе, кычкырасы килде аның, әмма сүгенер сүз тапмады.

— Тикшеручекең кайсысы эләккән соң сиңа?

— Хатын-кыз. Әбдрәҗәкова фамилияле.

— Ха! Ну, эләккән икәнсең кешесенә! Мунчала урынына сыгачак, киптереп элачәк ул сине!

— Мәкерле кешегә охшаган шул.

— Мәкерле генәме соң?! Мин аның белән бер эләгешеп карадым инде! Теге вакытта, туйдан соң «Аккош күле»ндә типтергәч. Озак «иркәләде» ул мине шул чакта. Бер угон буенча эшне моңа тапшырганнар да, ача алмый калган, тапмаган машина урлаучыларны. Җитмәсә, машинасы килде-китте кешенеке түгел икән. Оренбург трактыннан тапканнар, чокыр төбеннән. Э тегеләре — тю-тю!.. Шул эшне миңа сыларга тырышты ул, анасын сатыйм! «Әгәр монысын да үз өстеңә алсаң, мин сиңа ярдәм итәм, «условный»дан да артыкка тартмассың»,— ди. Ягымлы сөйләшә. Юмалый. Аларның бит шулай, месгеннәрнең: ачылган җинаять — плюс, ачылмаганы — минус. Шуңа күрә бу, теге эшне дә берьюлы ябып куярга маташа. Э нишләп әле мин булмаган эшне булды дип расларга тиеш?! «Юк,— минәйтәм,— үзем куган машина өчен күпме дә утырырга риза, кеше өлешенә кермим түлке»,— дим. Ачуы килде тегенең. Өч көн буе мена шушында асрады. Шуннан соң, тагын чакырта бу мине: «Йә, аласыңмы гаепне үз өстеңә,— ди.— Алсаң — «условный»га көйлим, алмасаң — башыңны усиленный режимда черетәм»,— ди. Үзем дә икеләнеп калдым шул сүздән. «Уйлап карыйм әле»,— дим. Әй, үзгәрде бу шуннан. Өстәл астыннан шешә чыгарып, йөз грамм аракы салып бирде. «Син, акыллым, минем сүзне генә тыңла, калганы өчен мин үзем җавап бирәм»,— ди. Тартырга тәмәке бирде, бераздан ашарга колбаса белән ипи кертте. Дөнья рәхәте, минсиңайтим! Әй, камерадагы егетләр рәхәтләнде инде тәмәкегә! Шунда бер абзый әйтте миңа: «Син, браток,— диде,— башыңны юләргә салма, үз өстеңә кеше эшен алма. Син алып киткән машина исән-сау, бер җире дә ватылмаган-күгәрмәгән, ә инде теге чокыр төбеннән табылганы — чәлпәрәмә килгән, аның хакын түләргә, хуҗасына хак кайтарырга кирәк булачак. Ул акчаны син төрмәдә генә эшләп кайтара аласың. Сине ул хатын сабый бала урынына алдалап йөртә, ышанма аңа, әле син, киресенчә, үзең урлап киткән машина өчен «условный»га тартасың, ә монысы синең башны өч-дүрт елга тыгачак». Әбдрәҗәкова чакыргач, тагын баш тарттым шул эшне өстемә алудан. Әй, тузынды, карганды, сүгенде дә соң инде?! Ике милиционер, аерым бүлмәгә алып кереп, туйганчы ярдылар мине шуннан соң. Ярдылар... Ну, черт с ними, барыбер үкенмим!..

— Каян килә кешегә шундый усаллык, ә? Әбдрәҗәкованы әйтәм.

— Каян килә, дисеңме? Синең, абзыкаем, артык надан, артык көнчел, артык хөсетле кешеләрне дөньяга үчле бәндәләрне күргәнең бармы?

— Бар, әлбәттә. Ләкин бит...

—Ә-ә-ә!.. Алайса, син инде белергә тиеш: кияүгә чыкмый картайган хатын-кызда мена шушы нәрсәләрнең барысы бергә тупланган

була. Тәк что сохариларыңны киптерә тор!

Хәбирнең ачуы чыкты:

— Ни сөйлисең син, телеңә тилчә чыккыры! — диде ул, урыныннан сикереп торып.— Авызыңнан җил алсын! Бер гаепсез кешене кем төрмәгә тыксын?!

— Әй, абзый җаныкаем, абзый җаныкаем!.. Сабый булып кыланма, зинһар өчен. Безнең илдә гаепсез кеше юк, беләсең килсә! Бездә кеше үзенең дөньяга тууы белән үк гаепле!

Хәбир ишеккә таба атылып барды. Йодрыклары белән төя-төя, бар көченә дөбердәтте:

— Ачыгыз! Ачыгыз!.. Чакырыгыз Әбдрәҗәкованы!..

Ишекнең теге ягында ачкыч шалтыраганы, кемнеңдер бик яман итеп сүгенгәне ишетелде. Хәбир аның саен ныграк дөбердәтте, аның саен ныграк кычкырды. Бу минутта аны бер генә көч тә тыеп тора алмас, шушы тынчу бүлмәдә — тәмәке төтене, күңелсез һәм өметсез уйлар, каргышлар һәм җимерелгән язмышлар белән тулган камерада калдыра алмас кебек иде...



## XVII

Әхмәтгали карт Казаннан килгән кунакларны озата чыга алмады. Бу соңгы көннәрдә ул, ниндидер хәвеф буласын сизенгәндәй, әчтән борчылып, әчтән көеп йөрде. Буыннары сызлаганын, йөрәге кысканын үзе генә белде: «Йортны син ашыктырдың, картлач,— дип сөйләште ул үзе белән.— Хәзер инде шул вакытта күтәргән йөгең сырхау булып кайта...»

Әйе, күңеле сизенгән иде картның. Ләкин ул бу кадәресен үк көтмәгән иде. Күңеле өзмәс-куймас борчылып торуны ул бер-бер чиргә, авырып урынга егылуга юрады. Хәбирнең кайтып җитмәвенә аптыраудан күрде. Адым саен аллага ялварды, дога укыды, бисмилласын әйтте. Әмма тәңре үзе ярлыкасын, ул Әхмәтгали картны көтмәгәндә-уйламаганда иңгән хәсрәттән коткарып калмады: Казаннан килгән кешеләрнең сүзе Әхмәтгали карт өчен аяз көнне яшен суккандай булды.

— Кунакларны озаттыңдамыни, бабай?! — Мәҗит, карга баткан итекләрен каккалап, ишекне каерып ачып керде.— Эшне генә бүлдерде болар. Әйдә, бабай, рамның үлчәвен күрсәт тә, калганын үзем эшлим. Әхсән белән Айсылу кайтканчы хет аларга күрсәтерлек нәрсә әмәлләргә тиештер бит инде мин!

Әхмәтгали карт эшсезлектән интеккән киявенә шөгыль тапкан — яңа умарталар ясарга керешкәннәр иде.

— Әйдә, бабай, ялкауланма, югыйсә, Айсылу кайткач, икебезгә дә эләгәчәк. Көне буе трай тибеп йөргәнсез дип, күзне дә ачырмас аннары!..

Кияве күпме генә шаяртмасын, Әхмәтгали карт урыныннан кузгалмады. Гаҗәпләнеп, беренче кат күргәндәй итеп, Мәҗиткә карап торды.

— Син нәрсә, бабай, авырыйсыңмы әллә?

— Кияү... Мин бераз ял итмәкче. Ничектер хәлем бетеп тора. Син дә үзең генә йөрмә, эш качмас... Мин ятып торыйм әле...

— Соң... Мин алайса башка эш караштыра торам.— Мәҗит инде чыгарга борылган җиреннән туктап алды.— Бабай, син авырып-нитеп китмәдеңме соң? Кәефсез күренәсең, дип әйтимме...

— Юк, кияү, юк... Бераз гына хәл алыйм. Бераз гына.

Әхмәтгали карт олы якка керде. Килене Сажидә җыеп куйган зур, йомшак мендәрләрне бер кырыйга этеп төшерде. Чәчәкле җәймәне урындыкка шудырды, караватка кулы белән таянып нидер уйла-

ды, нидер сөйләнде.

Мендәргә баш куйгач, җиңелрәк булып китте. Ләкин кайдадыр эчтә, йөрәк турысында нидер бик каты әрни, сыкрый иде. «Ни өчен алар минем улыма хуҗа булып сөйләшәләр? — дип уйлады карт, бөтен җаны-тәне белән сызланып.— Ни өчен мин үз улым белән дөнья бүлешергә тиеш?..»

Өйне яңгыратып, күкеле сәгать сукты. Әхмәтгали аның тавышын тыңлап, санап ятты: унбиш мәртәбә сукты, димәк, сәгать инде өч тулган...

«Ник кайтмый бу Гөлчирә?» — дип уйлады Әхмәтгали карт һәм, кинәт исенә төшерде: Гөлчирә белән өйләнешкән елны, печән чабарга баргач, күке тавышын тыңлаганнар иде.

— Әйдә, саныйк әле,— дигән иде Гөлчирә.— Безгә күпме гомер әйтә икән бу күке?!

Әхмәтгали ул чакта Гөлчирәсен печән чүмәләсенә аударды, аны кычкырта-кычкырта шашып үпте.

— Безнең нәсел озын гомерле булган! — диде ул, уенын-чынын бергә кушып.— Күкедән санатмасам да беләм: йөзнең теге ягына чыкмый торып, китәсем юк бу дөньядан. Сине дә җибәрәсем юк!..

Әллә соң шул сүзе өчен көферлегенә төштеме соң әле? Әтисе кырык алты яшендә үлде Әхмәтгалинең. Бу хәбәрне фронтта ишетте ул. Әнисе язды: атаңа кәгазь килде, балакаем, кайгыдан чәчләрем агарды, син дә кайтмасаң, хәсрәттән үләрмен».— дигән иде хатында. Әхмәтгали әтисе каберен белми калды.

Нигә кайтмый бу Гөлчирә? Балалар сабактан ник кайтмый? Ә-ә... Озынайтылган көндә кала бит әле бүген алар... Юләрләр... Көнне озынайтып буламыни?! Көнне дә, гомерне дә озынайтып булмый. Барысы да алла тарафыннан куелганча бара. Аның әмереннән башка салам да селкенмәс, ди...

Әхмәтгали каты авыртудан ыңгырашып куйды, тәне куырылганын тоеп, күтәрелергә теләде. Кулы белән таянып, башын калкытты, сулышын кысып, башын артка ташлады. Күкрәгендәге авырту кимеде. Ул янә башын мендәргә салды.

«Минем Хәбир улым яза иде,— дип бәхәсләште ул Казаннан килеп китүчеләр белән.— Ул анда, Әфган дигән җирдә, мәсҗетләр карап, аларны төзекләндереп йөргән. Хәбир улым да коммунист. Әле шулай, коммунист була торып, чит ил халкына мәсҗет торгызырга булышкан... Хәзер инде ул да Әхсән белән бер нигездә торырга, бертуган булырга тиеш түгелмени? Әхсән, парторг булгач, Хәбирне үз энесе итәргә тиеш түгелмени?..»

Нигә кайтмый бу Хәбир? Сагынды аларны Әхмәтгали карт. Килене Лизаны сагынды. Оныклары Розалияне, әле бер тапкыр да күрмәгән килеш, рәсеменә карап сагынды. Хәбир кайтса...

Ә Әхсән нигә шулай озаклады? Әхсән... Ул кайтып керсә, Әхмәтгали аңа нәрсә дип әйтер? Улым, мине үгетләргә килгәннәр иде, мин аларны кире бордым, дипме? Әхсән үпкәләр микәнни аңа бу эше өчен. Тегеләр әйтте бит: «Балагыз, улыгыз хакына...» — диделәр. Әхсән үпкәләр инде...

Күрше бүлмәдә кемнеңдер тавышы ишетелде:

— Бәрәч, өйдә бер кеше юк!

Айсылу түгелме соң бу?! Айсылу бит!

— Качып беткәннәр болар! Таралышканнар!..

Әхсән тавышы бит бу... Әхсән!.. Әхмәтгали карт кинәт урыныннан кузгалды:

— Әхсән!.. Улым... Мин...

Әхмәтгали карт төнге сәгать дүрттә җан бирде. Районнан чакыртылган «Ашыгыч ярдәм», төне буе көттереп, иртәнге якта гына килеп җитте.

— Инфаркт булганга охшый... — врач бары тик шуны гына әйтә алды.

...Әхмәтгали картның үлем хәбәрен Таһирга әнисе алып кайтты.

— Бөтен авыл җыелып төшкән, улым. Кайчан күмәселәрен тәгаен сорашмадым. Кабер казышырга син дә төшәрсең инде. Дөнья бәһасе кеше иде Әхмәтгали абзый. Әй, ходаем, урыны җәннәттә булсын мәрхүмнең...

Таһир яткан урыныннан сикереп торды. Торды да баскан җирендә катып калды.

— Ничек? Ничек үлгән?..

— Врачлар килеп киткән инде. Йөрәк белән егылган, дип әйтәләр, ди.— Хәлимә карчык, күз яшен яулык очына сөртте.— Хәбирләре кайтып җитәлмаганга да бик борчылалар. Ничә ел көттеләр, инде кайту хәбәре килгәч кенә... Әй, ходаем, ни язса, шуны күрерсең, дип әйтүләре хактыр инде!

Иртәнге чәй янында Таһир сүзсез калып, таш сын кебек утырды.

— Синең дустың иде бит Хәбир. Төшеп кайт балам аларга. Хәлләренә кереп, кайгыларын бүлешеп чыгарсың.

— Әни...— диде Таһир, кинәт урыныннан кузгалып.— Миңа ашыгыч рәвештә юлга чыгарга кирәк!

Хәлимә карчыкның кулыннан чынаягы төшеп китә язды:

— Ничек инде, балам?..

— Шулай, әни... Мин бөтенләй истән чыгарганмын бит... Бүген бит минем... Ашыгыч эшем бар. Кич белән, институтта...

Әнисе әкрен генә кире урынына чүкте:

— Әй, бала, бала... Эш-эш дип, бөтен нәрсәне онытасыз шул сез. Авыл туфрагын да, кардәшлекне дә, туган нигезне дә, дөньяның фанилыгын да... Дустыңның этисе, синең авылдашың дөнья куйган. Ә син шул көнне, эш бар дип, ашыгып юлга чыгасың. Юлым уңмас, дип бер дә уйланмыйсыңмыни, гөнаһысыннан бер дә курыкмыйсыңмыни соң, балакаем?..

Районнан килгән врачлар китеп баруга, Сабирҗановлар капка төбенә тагын бер машина килеп туктады. Аннан хәрби киемдәге ир кеше төште. Капка төбенә җыелган, ишегалдына тулган халыкны күреп, бераз аптырап-гаҗәпләнеп торды.

— Нәрсә, хәбәре монда да килеп ишетелгәнме инде әллә? — дип эндәште ул янәшәдәге төркемгә.

— Ишетелмичә соң?! Бөтен авыл җыелган бит, күрмисезмени? Кутәрде Әхмәтгали абзый авылны, бөтен кешене аякка бастырды...

Хәрби киемдәге кеше капкадан эчкә үтте. Башындагы бүреген салып, өйгә узды. Колхоз председателе Әхмәтхан Шакировны күреп, аңа таба атлады. Әхмәтхан, баш кагып, сүзсез генә исәнләште. Аннан соң:

— Килүегез әйбәт булган, иптәш военком. Әхмәтгали абзый сугыш үткән, илне саклаган кеше, ветеран иде бит...— дип пышылдады.

— Ә-ә... Сабирҗановның этисе үлдемени? — диде хәрби комиссар һәм аның калын кара кашлары ни өчендер тартышып куйды. Бераздан ул яңадан Әхмәтханга таба борылды: — Монда Мәҗит Хәсәнов дигән кеше булырга тиеш. Хатыны — Айсылу...

— Әхмәтгали абзыйның кияве белән кызы. Менә бит, кунакка дип кайттылар да, этиләрен җирләп китәләр. Авыр хәл, бик авыр...

Хәрби комиссар баш какты.

— Иптәш Шакиров,— диде ул бераз сүзсез торгач,— син миңа Мәҗитне, кияү кешене күрсәт әле?

Әхмәтхан өйнең түренә таба ымлады. Анда, кулларын ике тезе өстенә салып, беркемне күрмичә, беркемгә бер сүз катмыйча, Мәҗит утыра иде. «Бабайны мин генә калдырып чыгып киттем, мин генә

гаепле!..» — Мәҗитнең соңгы тапкыр әйткән сүзе шул булды. Аның бу сүзен әллә ишеттеләр, әллә юк — өй эче кергән-чыккан, саубуллашырга ашыккан кешеләр белән тулган, үлем кергән өйнең сәер һәм табигый мәшәкатенә чумган иде.

Хәрби комиссар мәрхүм яткан сәке янына килде. Әхмәтгали картның йөзенә озаклап карап торды. Бу вакытта ул ниләр уйлаган, ниләр кичергәндер — әйтүе кыен. Комиссарның хәлен мәет кергән йортка үлем хәбәрен алып килгән кеше үзе генә аңлый алыр иде.

— Иптәш Хәсәнов,— диде хәрби комиссар, Мәҗит утырган урынга якын ук килеп.— Минем белән урамга чыгып керә алмассызмы?

Мәҗит аңа гаҗәпләнеп карады. Ул, әйтерсең, хәрби киемдәге кешене беренче тапкыр күрә иде.

— Минме? — дип кабатлап сорады ул, урыныннан кузгалып.— Мин... Әйдәгез соң...

— Сез монда, бу авылга китүегез турында күршеләрегезгә әйтеп калдыргансыз икән...— диде комиссар урамга чыккач.

— Әйе шул, калдырган идек, адресны да. Дөньяда ни булмас?! Эштән эзләүләре бар, тегесе-монысы дигәндәй... Минем хатын ул яктан бик булган...

— Әйе...— Комиссар тәмәке кабызды, Мәҗиткә дә сузды. Икесе дә, сүзсез калып, төтен суырдылар. Мәҗит, күрәсең, үзен ник чакырганнарын да, үзенә нинди дер эш, йомыш булуын да аңлап бетерерлек хәлдә түгел иде әле. Комиссар моны сизде.

— Беләсезме, иптәш Хәсәнов... Сез — ир кеше... Аңларга, күтәрергә тиеш... Югалту зур, әлбәттә...

— Шулай-й,— дип сузды Мәҗит.— Алтын кеше иде минем бабай. Вакытсыз китте, бик вакытсыз. Кайниш тә кайтып җитмәде ичмасам. Ничә ел күрешмәделәр... Кайниш Әфганстанда иде бит. Хәбәре килде, кайтабыз дигән иде, өлгермәде кайниш. Һай, үкенечкә калды...

— Иптәш Хәсәнов,— диде комиссар.— Сезнең улыгыз да Әфганстанда хезмәт итә иде бит?

Мәҗит сагайды:

— Әйе шул... Ул да шунда... Ә сез?.. Каян беләсез?

— Миңа сезнең военкоматтан хәбәр иттеләр... Сезне эзләп табуымны үтенделәр. Аңлыйсызмы?.. Сез анда кайтып җитәргә тиеш... Анда... Улыгызны алып кайтканнар. Гәүдәсен... Аны хөрмәтләп күмәргә уйлыйлар...

Мәҗит коймага сөялде, зур булып ачылган күзләрен комиссарга төбәде. Аннан соң, кинәт аңына килеп, ике кулы белән аның изүеннән эләктереп алды:

— Син нәрсә?! Нәрсә сөйлисең син?! Мин... Минем улым?!

Комиссар Мәҗитнең иңеннән тотты:

— Иптәш Хәсәнов!.. Мәҗит! Сабыр бул!

Мәҗит комиссарның изүен йомшартты, әмма ычкындырмады. Аның зур, көчле куллары дер-дер калтырый иде:

— Айсылуга... Айсылуга әйтәсе булмагыз... Хатынга...

— Сезгә китәргә кирәк, Мәҗит. Юлга чыгарга. Минем машина сезнең карамакта. Самолетка билетны үзем алып бирәм, военкомат исеменнән. Ишетәсеңме, анда инде сезне генә көтәләр. Юлга ашыгырга кирәк!

...Таһир иң элек райкомга сугылды. Бикташев үзендә юк иде. Оештыру бүлегенә кереп, командировка кәгазенә билге суктырды. Аннан соң туп-туры аэропортка ашыкты. Район үзәгеннән чыгып, шактый ара киткәч кенә тукталып тын алды. Үзе дә сизде; аның бу ашыгуы кемнәндер качып бару сыманрак иде. Әйтерсең, кемдер аны

куалый, артыннан эзәрлекләп килә. Эзәрлекли... Кем шулай эзәрлекли Таһирны? Өйләнде — юньле тормыш кора алмады. Авылына кайтты — качып диярлек китәргә мәҗбүр. Әнисен күрде — янында була да алмады. Ник эзәрлеклисең син Таһирны, язмыш?!

Аэропортта кеше күп иде. Казанга очачак соңгы самолетка ышанып җыелган халык касса янына өелгән, тынгысызлана, кайный. Таһир бу халык төркеме аша кассага якынлаша алмаячагын шунда ук сизде. Бераз уйлап торганнан соң, «Аэропорт начальнигы» дигән язулы ишекне табып, шул бүлмәгә кереп китте. Бүлмә хуҗасын урынында күреп, шатланып куйды.

— Исәнмесез! — диде ул, беренче булып кул сузды.— Минем фамилиям — Корбанов. Командировкага килгән идем. Безнең иптәшләр кичә китте. Мин бераз тоткарландым. Менә райкомның кәгазе: алар калдырган броньне файдаланырмын инде мин?

Аэропорт начальнигы бронь кәгазен алды. Игътибар белән карап чыкты. Аннан соң авыр сулады:

— Сезгә ярдәм итә алмыйм бит мин, иптәш Корбанов. Билетлар сатылып бетте, халык күп булды бүген. Үзегез беләсез, якшәмбе көн, һәркем ашыга...

— Ничек инде? Миңа бит райкомда төгәл әйттеләр: алар калдырган урын бары тик шушы кәгазь белән генә бирелә!

— Анысы шулай... Тик ни бит... Военком шалтыратты: ике урын калдырырга дип. Хәрбиләрнең дә үз законы...

— Сез нәрсә?! — дип тавышын күтәрә төште Таһир. Китә алмый калу куркынычы аны кискен хәрәкәткә этәрде. Ул куен кесәсеннән командировка таныклыгын чыгарды.— Мин бит обком кушуы буенча килгән кеше. Минем кулымда — райкомның бронь кәгазе. Ә сез миңа военкомат сүзен китереп куясыз!

Аэропорт начальнигы җавап биреп өлгерә алмады, ишек киң ачылып китте. Иң алдан хәрби комиссар, аның артыннан Айсылу белән Мәҗит күренде.

— Соңга калмадыкмы? — диде комиссар, туп-туры өстәл янына узып.— Сез, әгәр мөмкин булса, транзит билет ясагыз бу иптәшләргә. Аларның әле шактый юл үтәсе бар, Казанда тукталып калмасыннар дим.

— Бик теләп шулай эшләр идем дә, иптәш военком, тик безнең андый мөмкинлек юк шул. Үзегез беләсез: провинция...

— Шулай шул, провинция,— дип кабатлады комиссар.— Провинция. Ну, ничава, мин аларга үзебезнең белешмәне бирдем. Аның белән любой кассада билет бирәчәкләр. Хәрбиләр өчен дип язылган кассага барсагыз, тагын да әйбәт...

Аэропорт начальнигы Мәҗиткә язулы кәгазь сузды:

— Шушы язу белән кассага үтегез, анда халык беткәндер инде хәзер...— Айсылу белән Мәҗит чыгып киткәч, комиссарга эндәште: — Уллары үлгән дидегезме? Әйе... Кырыла безнең егетләр чит җирләрдә...

— Әле кичә авылда этиләре үлгән. Бүген баргач, кайгы өстенә килеп төштем. Балтамактагы Әхсән Сабирҗановны беләсеңдер бит? Партком секретарен?

— Беләм-беләм, Әхсәнне белмәскә...

— Шул Әхсәннең этисен әйтәм. Менә бит, аны да җирли алмыйча китеп бара инде болар...

Таһир әле ни эшләргә белмичә тора иде. Кинәт сизде: язмыш кылана, язмыш аны хәтта шушы кабинетта да Әхмәтгали карт исеме белән эзәрлекли. Ул әкрен генә кабинеттан чыкты. Аэропорт ишегенә җиткәч, борылып карады: почмакта Хәбирнең апасы Айсылу басып тора, йөзе таш катыгы кебек ак иде. «Ә бит мин аны танымаган да булыр идем»,— дип уйлады Таһир һәм карашын тиз генә читкә кү-

черде. Айсылуның бу якка таба борылуыннан, үзен танып алуыннан курыкты.

Ә китәргә кирәк иде. Таһир бер генә мәлгә икеләнеп торды. Аннан соң олы юлга илтә торган сукмак буйлап китте. Ул бүген барыбер китәчәк, юлны урап булса да барачак, мәгәр монда калмаячак иде.

## XVIII

Хәбир таң алдыннан йоклап киткән иде. Яман төш күреп, бастырылып, саташып уянды.

Үзе күргән төш турында озак уйлап утырды. Каян керә шундый тузга язмаган нәрсәләр төшкә? Имеш, ул авылда, туган йортында яши икән. Сизә: этисе нәрсәгәдер ачулана Хәбирне, ник ачулана — һич аңлый алмый. Ниһаять, Хәбир сорады: «Эткәй, ник ачуланасың син мине? Нигә йөзең бик кырыс шулай?» Этисенең сүзе аңлашылмый, үзе һаман ачулы карый Хәбиргә. Шунда кинәт Лиза пәйда булды. «Эткәй,— ди.— Хәбирне ачуланма, ул сиңа акча бирәлмаган. Менә, мин үзем сиңа күп итеп акча бирәм, эткәй!..» Лиза, каяндыр кәгазь акчалар алып, өстәлгә өя башлады. Өстәл өсте дә, идән дә кәгазь акча белән тулды. Ә Хәбирнең этисе һаман ачулана, һаман усал карый. «Миңа бу акчалар кирәкми, миңа Хәбир биргән акча кирәк!» — ди. Ә Хәбир үзе нишләргә дә белми басып тора, имеш. Газаплана, интегә, аңлатырга тели... Әнә шулай интеккән чакта уянып китте ул. Үзе ишеткәннәрнең, үзе күргәннәрнең бары тик төш кенә булуына шатланып та куйды хәтта. Ләкин бу шатлык, үзенең камерада икәнен аңлауга, янә әрнүле газапка әверелде.

Хәбир үзе күргән төшне нәрсә дип тә юрарга белмәде. Әгәр дә Хәбир үзенең туган авылына бу минутта күз чите белән генә карап ала алса, бу мәхшәрле төшнең серенә тиз төшенер, шундук аңлап алыр иде. Әмма табигать кешегә андый мөмкинлек бирмәгән, табигать кешегә тою һәм төш күрү сәләтен биргән, бары тик шуны гына биргән...

— Сабирҗанов! К следователю!

Хәбир әкрен генә кузгалды. Әбдрәҗәкованың мыскыллы елмайган йөзен күргәндәй булды. Кичә Эдикның сөйләгәнен тыңлаганнан соң, милиция формасы кигән бу хатын-кыз ниндидер бер яңа сурәттә, яңа кыяфәттә — күңел берничек тә кабул итә алмас рәвештә калыкты аның күз алдында.

Ишек ачылуга ук, кабинетның түрендә Ахоның калын җилкәсен күреп алды Хәбир.

— Узыгыз, гражданин Сабирҗанов! — Әбдрәҗәкова шулай дип эндәшүгә, Ахо ялт итеп артына борылды, урыныннан кузгалып каршы килде:

— Йа хода! Хәбир! Сине дә монда алып килделәрмени? Минем аркада бу, туганкаем, минем аркада гына...

— Сөйләшмәскә! — Әбдрәҗәкова аларның арасына килеп керде.— Сержант! Аерым утыртыгыз боларны! «Лимон», син бит монда беренче тапкыр түгел, тәртипне беләсең! Бары тик минем сорауларга гына җавап бирәсез, аңлашылдымы?

— Аңлашылды, иптәш капитан! Аңлашылмыймы соң?!

— Иптәш капитан түгел, гражданин капитан, «Лимон»! Һәм, зинһар өчен, бу тозсыз шаяртуларыңны ташла! Югыйсә, үзеңә авырга туры килүе мөмкин...

— Баш өсте, гражданин нәчәлник!..

Әбдрәҗәкова өстәл өстендәге магнитофонны кабызды:

— Очная ставканы башлыйбыз. Беренче сорау сезгә, гражданин Давыдов: сез Сабирҗанов Әхсән Әхмәтгалиевичне каян беләсез, кайчан, нинди шартларда таныштыгыз?

— Соң... иптәш Әбдрәҗәкова... Гражданин начальник! Бу кешенең минем эшкә бернинди катнашы юк, валлаһи, дип әйтәм. Ул сезгә үзе аңлаткандыр лабаса?!

— Сорауларга гына җавап бирәбез, гражданин Давыдов.

— Поездда таныштык. Бер купеда кайттык! Мәскәүдән...

— Бик яхшы. Бер купеда кайттыгыз. Дөресен генә әйтегез: нәрсә алып кайттыгыз?

— Гражданин начальник!.. Мәскәүгә барган кеше нәрсә алып кайта инде?! Вак-төяк, кирәк-ярак шунда...

— Кыскасы, чәйне сез каядыр олактырып өлгердегез, гражданин Давыдов. Чәйне яшерәм дип, алтын белән каптыгыз. Монысы инде уен эш түгел, аңлыйсыздыр. Ул алтын сезнең кулга каян килеп керде, аны сезгә кем тапшырды?

Ахоның гәүдәсе бөрешеп, кечерәеп калды. Йөзе мескенләнде, күзләре кызарып чыкты. Аны күзәтеп торган Хәбир нәкъ шушы минутта үзенең коточкыч хәлдә булуын аңлады: әгәр хәзер Ахо алтынны аннан алдым дип әйтсә, буталчык бу вакыйгалар өр-яңадан чуалачак, өр-яңадан төенләнәчәк иде. «Лимон»га юкка өметләнәсез...» — тикшерүченең шушы янаулы сүзләрен әле генә чынлап аңлап алды ул. Менә бит нәрсәгә ишарәләгән икән Әбдрәҗәкова...

— Алтын — бабайныкы,— диде Ахо, ниһаять. Аның гәүдәсе яңадан турайды, йөзенә төшкән сукбайлык каядыр юкка чыкты.

— Нинди бабай? Кличкамы бу?

— Иптәш гражданин Әбдрәҗәкова!.. Неужели сез инде минем бабайны белмисез? Хатынның әтисен әйтәм. Алтын шуныкы. Хатын белән бергә торган чакта... Ну, бабай аны миңа биреп торды... Сакларга дип.

Ахоның бу соңгы хәбәре, күрәсең, тикшерүченең барлык уй-фикерләрен бутап ташлады. Ул инде алтын белән бәйле зур җинаятьнең эзенә төштем дип тәгаен ышанган иде. Җитмәсә, бу эштә чит илдән кайтып килүче кеше катнашкан... Кызыксындырган, нык кызыксындырган иде бу кеше Әбдрәҗәкованы.

Тикшерүче сигарет кабызды.

— Тартырга мөмкинме, гражданин начальник?

Әбдрәҗәкова ым кагып кына рөхсәт бирде. Ахо аның сигаретын үрелеп алды, Хәбиргә дә тәкъдим итте:

— Тартып-суырып җибәр, туганкаем, йөрәккә ял булсын!

Хәбир сигаретны алды, кабызды. Бу аның Ахога сүзсез генә әйтелгән рәхмәте, дулкынлануын басарга тырышуы иде.

Алар өчәү, сүзсез калып, тәмәке көйрәттеләр. Ниһаять, тикшерүче урыныннан торды:

— Әй бит моны башта исбатларга кирәк, гражданин Давыдов! Бәлки, сез кешегә яла ягасыздыр? Сез инде аның кызы белән араны өзгән, аерылышкан. Бу бер үч алу сыманрак нәрсә булып чыгуы мөмкин түгелме? Аннан соң... Әз яшерү өчен дә бик кулай адым бу. Шулай түгелме?

— Гражданин начальник!..— Ахо, елмаеп, кулларын җәйде.— Моны исбатлау сезгә берни тормый. Үз алтынын күрү белән бабай аңа чат ябышачак!

Әбдрәҗәкова баш чайкады:

— Ну, хәйләкәр дә кеше син, «Лимон», артык хәйләкәр. Ну, чамала, кара аны...

Хәбир белән Ахоның һәр икесен аерым бүлмәгә кертеп тордылар.

— Күрешкәнчегә кадәр, туган! — диде Ахо тикшерүче бүлмәсеннән чыкканда.— Хәзер алар минем бабайны йолкып китерәчәкләр. Аннан тагын очраштыралар алар безне. Ну, кәмит булачак, менә күрерсең...

Ахо дөрес әйткән икән: бер сәгать тә үтмәде. Хәбирне яңадан

тикшерүче бүлмәсенә алып керделәр. Анда Әбдрәҗәкова каршында киң чырайлы, юан гәүдәле бер кеше утыра иде. Аның йөзе агарган, күзләре зур булып ачылган, кулындагы кан тамырлары бүртеп-бүртеп чыккан иде. Үзе әледән-әле Ахо утырган якка борылып карый, ачу белән ыңгырашып ала. Тикшерүче Хәбиргә урын күрсәтеп ымлады.

— Димәк, Хәйдәр Юнусович, сез дә бу алтынның үзегезнеке булуыннан баш тартасыз?

— Хөрмәтлем минем... Каян килеп инде миндә андый алтын ише нәрсә булсын?! Кемгә ышанып мыскыллыйсыз мине?! Әрәмтамакка, спекулянтка ышанасызмы? Менә шушы чәнти бармагым хәтле дә ялганламыйм: бу алтын минеке түгел, минеке булганы да юк!

— Ярый ул чакта,— Әбдрәҗәкова кулларын өстәл өстендә уйнатты.— Гражданин Давыдов аны сездән алдым ди, сез баш тартасыз. Күрәм, гражданин Сабирҗанов та бу алтынга дәгъва кылмый. Хөкүмәтнеке булыр ул, алайса... Ничек уйлыйсың, «Лимон»?

— Миңа барыбер. Үзем тапкан мал түгел, бабайныкы җәл түгел.

Юан гәүдәле кеше урыныннан сикереп торды:

— Оятсыз!..— дип кычкырды ул, Ахога төкереп.— Әрәмтамак! Спекулянт калдыгы!.. Җир бит! Ни хакың бар миннән көләргә?! Атаң кебек олы кешедән?! Мин... Мин гомер буена намуслы хезмәттә булдым. Халыкны ашаттым. Мин... Мин бары тик үзем тапканны гына ашадым. Синең кебек әрәмтамак булмадым!..

— Ә нигә соң син, бабакай, бу юлы үзең тапканнан баш тартасың? Алтын бит — синеке.

— Минеке түгел, түгел!

— Бабай... Мин бит барысын да алып китмәдем... Сакларга дип... Әле бит анда, өйдә, тагын калгандыр? Мин бит бик азын гына алдым. Калды бит әле анда!..

— Аһ-һ!..— юан гәүдәле кинәт йөрәген тотты. Аның гәүдәсе бер якка чалшаеп китте. Каядыр тотынып калырга теләгәндәй, кулларын бутады, гөрселдәп идәнгә ауды.

— Скорый чакырыгыз! — дип кычкырды тикшерүче ишектән башын тыккан милиционерга.— Тиз булыгыз!

Хәбиргә, инде өченче тапкыр, камерага кайтырга туры килде. Тик бу юлы аны озак тотмадылар. Икенче катка күтәрелгәч, ул галәпләнде: аны Әбдрәҗәкова кабинетына түгел, башка бер ишеккә таба алып киттеләр.

Бүлмәдә аны шактый өлкән яшьләрдәге подполковник каршы алды.

— Рәхим итеп узыгыз, утырыгыз,— диде ул Хәбиргә һәм аны алып кергән сержантка чыгып китәргә ишарә ясады.— Миңа калса, иптәш Сабирҗанов, сезне кулга алуда ялгышлык килеп чыккан бугай. Хәзер документларыгызны алып килерләр. Без сезне азат итәчәкбез.

Хәбир җиңел сулап куйды.

— Әгәр сезнең белән монда артык дорфа кыланган булсалар, аларны гафу итегез инде. Нишлисең бит, кешеләр белән һәрвакыт ипле генә итеп сөйләшә белүче кадрларны каян табып бетерәсең. Аннан соң, эше дә шул: көне-төне җинаятьчеләр арасында. Ә бу психикага суга, һәр кешене җинаятьче итеп күрә башлыйсың...

Ишек ачылды.

— Мөмкинме, иптәш подполковник?

— Узыгыз, иптәш Әбдрәҗәкова. Сабирҗановның документларын алып кердегезме? Яхшы булган. Йә, алтын белән эшләр ничек тора анда?

— Хәйдәр Юнусовичны больницада алып калганнар, иптәш подполковник. Кияве өйдә калган алтын турында әйткәч, бик нык бор-

чылды ул. Бәлки, иптәш подполковник, аның өендә тентү ясарга рөхсәт алырбыз?

Моңарчы ягымлы гына сөйләшкән подполковникның кашы җыерылып куйды:

— Ашыкмагыз, ашыкмагыз, капитан. Үзегез беләсез, Хәйдәр Юнусович малай-шалай түгел. Могътәбәр кеше. Аның өенә теләсә ничек барып кереп булмый. Югарыдагы иптәшләр белән киңәшмичә ярамас...

— Ә миңа бу эш белән нишләргә соң?

— Хәзергә калдырып торыгыз. Алтын хәтле алтын дәүләткә кире кайтарылган. Тагын нәрсә кирәк?..

— Давыдов белән нишләргә?

— Бераз өркетегез дә, җибәрегез. Бу мәсьәләгә кире әйләнеп кайтуны билгеле бер вакытка тикле калдырып торырга кирәк.

Әбдерәҗәкова чыгып киткәч, Хәбиргә киемнәрен кертеп бирделәр. Подполковник аны ишек төбенә кадәр озата барды.

— Зинһар, барысы өчен дә гафу итегез инде,— диде ул, Хәбирнең кулын кысып. Аннан соң, якынрак иелеп пышылдады: — Саттар Кыямовичка миннән бик күп сәлам җиткерегез!..

Хәбир подполковникның бу соңгы сүзләренә урамга чыккач кына игътибар итте. Тукта!.. Нинди Саттар Кыямович ул? Ни өчен Хәбир абый, үзе белмәгән кешегә сәлам әйтергә тиеш? Кем белән бутадылар монда Хәбирне?

Юк, Хәбир ялгышты. Аны беркем белән дә бутамаганнар иде. Әбдерәҗәкова җибәргән яшь сержант Корбановлар квартирасын Хәбир үзе биргән адрес буенча эзләп тапты. Сержант, чыннан да, яшь иде, үзен каршы алган чибәр хатын алдында каушап калды.

— Иремме? — диде аңа Минзилә, бераз гаҗәпләнеп, бераз курка калып.— Ул командировкада...

— Ә сезгә... Сезгә бер-бер танышыгыз килеп чыгарга тиеш түгел идеме кичә? Безнең өчен моны төгәл белү бик мөһим, аңлыйсызмы?

— Кичәме? Әйе-әйе, ирем әйткән иде... Безнең дустыбыз килергә тиеш иде. Хәбир...

Сержант яшь иде. Үзе генә белеп китәсе урында, ул Минзиләгә дә байтак хәбәр әйтеп калдырды.

Минзилә төнен йоклый алмыйча чыкты. Хәбирнең бүген кайдадыр ябылып утыруы аның башына сыймый, әледән-әле йөдәтә, өзмәс-куймас уйландыра иде.

Эшенә — балалар бакчасына баргач та, онытылып китеп, урынына куйган әйберен табалмый, барасы-керәсе җирен аңлый алмый интекте. Ниһаять, эштән кайтып, караватына ауды. Үзенең эштән түгел, уйдан арганлыгын аңлап, күзләрен йомды. Һәм шундук сикереп торды: ничек соң моңарчы башына килмәгән?!

Минзилә ашыгып киенде, Рөстәмен күршеләргә кертеп куйды. Урамга атылып чыгып, такси машинасын тотты.

Саттар яшәгән өченче катка ул чабып-йөгереп менде. Кыңгырау төймәсенә бармаклары арганчы, агарганчы басты.

— Ничек бу вакытта? — дип гаҗәпләнде ишек ачкан Саттар.— Без бит бүген күрешергә дип сөйләшмәгән идек?..

Минзилә, аны күрәләтә этеп диярлек, бүлмәгә атылып керде:

— Миңа синең белән сөйләшергә кирәк, Саттар!

Сулышы капкан хатынны тыңлап бетергәч, Саттарның каушаган йөзе үзгәреп куйды, канәгать төс алды, кире үз хәленә кайтты.

— Хәзер соң, ачыклыйбыз, хәл итәбез аны! — дип елмайды ул. Каяндыр бер куен дәфтәре алып, телефон янына килеп утырды. Ашыкмыйча гына номерны җыйды. Күзләрен кысып, көтеп торды.— Картлач кына өйдә булсын. Эшеннән кайтып киткәндер инде...

«Өйдә генә булсын, өйдә генә булса ярар иде!..» — дип эчтән ка-

батлады Минзилә. Күрәсең, телефонда җавап бирделәр.

— Сәлам, картлач! — диде Саттар, үзалдына елмаеп. Аннан соң, озаклап хәл-әхвәл сорашты. Инде Минзилә көтә, сүзнең тизрәк эшкә күчүенә өмет итә иде. Ләкин Саттар гына һаман ашыкмады.— Балыкка йөрисеңме соң, картлач? Чиртәме?.. Ә-ә, сез балыкчыларны беләм мин... Карале, синнән сорыйсым бар иде: җәтмәгә кирәкмәгән балык керсә, балыкчы нишли? Ә, шулаймы, кире суга ыргытамы?! Менә синең егетләргә дә шундыйрак бер балык эләккән бугай анда. Әйе... Иртәгә кызыксын әле, яме? Фамилиясеме? Исеме — Хәбир. Фамилиясе?..

— Сабирҗанов! — дип әйтеп өлгерде Минзилә.

— Әйе-әйе, Сабирҗанов. Кызыксын әле, яме? Нәтиҗәсен соңыннан сөйләшербез...

Минзилә җиңел сулап куйды. Шунда ук борчылып сорады:

— Ә ул, син сөйләшкән «картлач», ышанычлы кешеме соң? Ярдәм итә алачакмы?

— Әйткән сүз — аткан ук, җаныкаем. Бездә ике сөйләшмиләр.

Минзилә тынычланды. Бүреген, пәлтә якасын, чәчләрен рәтләп куйды. Бүлмәгә күз салды. Өстәлдә җыйнак кына табын әзерләнгән, затлы шәраб шешәсе, рюмкалар куелган иде.

— Синдә кунак бармы әллә?

— Юк, беркем дә юк. Нигә алай дисең? Мин бүген, берүзем генә калып, уйланып утырыйм дигән идем. Арытты, эш күп...

— Мин киттем алайса?

— Үзем шалтыратырмын сиңа, шушы араларда...

Минзилә ишек катына җитте, сискәнеп туктап калды: ишек янындагы элгечтә хатын-кыз пәлтәсе эленеп тора, ә аста аяк киемнәре аунап ята иде.

Минзилә Саттарга үрелеп карады.

— Мин сиңа үзем шалтыратырмын, иртәгә үк...— дип ашыктырды аны Саттар.

Артыннан ишек ябылуга ук кузгалып китә алмады Минзилә. Ничектер эчтән әрнеп, җаны үртәлеп, ишек яңагына сөялде. Һәм аермачык ишетте:

— А кто она была такая?! — дип кычкырып көлде эчке якта кыланчык бер хатын-кыз тавышы.

— Знакомая по работе,— дип тоныклык кына җавап кайтарды Саттар.— За помощью пришла, муж у нее в милицию попал...

Үзенең болай тиз котылуына әнә шул хәлләр сәбәп булуын Хәбир белми һәм, әлбәттә, белә дә алмый иде. Ул ашыкты, чаба-чаба кунакханәгә кайтып җитте. Аңа тиз генә өс-башын алыштырырга, юынып-кырынып алырга, кызы янына больницага китәргә кирәк иде.

— Минем бүлмә ачкычларын бирегезче? — диде ул дежур ханымга. Хатын аңа гаҗәпләнеп карап торды:

— Ә анда кеше бар инде. Анда кеше урнашкан.

— Ничек?

— Шулай. Сезне бит милиция алып китте. Сез инде ничә тәүлек кайтмый йөрдегез! Без бит бүлмәне буш тота алмыйбыз. Торыр урын башкаларга да кирәк!

— Соң, ул бүлмәдә әйберләрем калды бит минем!

— Әйберләрегезне горничнаядан алырсыз.

— Миңа хәзер юынып алырга, чистарынырга кирәк. Бүлмә кирәк миңа!

— Белмим, берни дә белмим. Бездә урыннар юк. Кем белә, мөжет сез милициядән качып кайткансыздыр?! Справкагыз кая? Барыгыз, бар, әйберләрегезне алыгыз да, китегез. Атуса, милиция чакырам!

Декабрь уртасында җепшек кар катыш яңгыр ява. Мәскәүдәге начар һава Казанга да килеп җиткән иде инде.

Больницага аны кертмәделәр.

— Передача вакыты чыкты,— дип каршылады аны ишек төбендә утырган юан бер карчык.

— Апа, җаным! Минем кызым ята монда, мин аны күрергә тиеш, аңлыйсызмы, күрергә тиеш!

— Иртәгә килерсең, алай бик күрәсең килгәч! Үзе баласы янына килгән, үзенең кулында күчтәнәче дә юк оятсызның. Кыяфәтеңә кара син иң элек. Баланның котын алыр өчен килдеңме, исерек баш!

Хәбир шунда гына үзенең өс-башы, кыяфәте турында уйлап алды. Залның бер читендә, тышкы ишек янында торган зур көзгегә таба атлады: көзгедән аңа ябык чырайлы, йөзен сакал-мыек баскан, таушалган киемле бер кеше чекерәеп карап тора иде.

— Ну, что, смену кончаем, Семеновна?! — Больницадан чыгып барган яшь кенә кызның сүзе Хәбирнең колагына эләгеп калды.

— Скоро... Час замена мне придет...

Хәбир көзгедән күзен алмады. Ә колагында хатынның сүзе яңгырап торды: «Час замена придет...» Китәчәк бит бу хатын! Китәчәк!.. Хәбир кызы янына керергә тиеш. Ничек тә күрергә тиеш ул аны, юатырга тиеш. Кирәк икән, бүген үк, хәзер үк алып чыгып китә ул аны моннан!..

Хәбир урамга чыгып йөреп керде. Күреп торды: аны кертмәгән теге җен карчыгы әкрен генә әйберләрен җыйды. Аның урынына башка бер хатын килеп утырды. Хәбир, әлеге карчыкның китеп барганын көтеп, тагын бер әйләнеп килде. Аның бөкре гәүдәсе күздән югалуга, ашыгып ишеккә таба йөгерде.

Аңа алга таба үтәргә., әчкә, больницага керергә, дүртенче катка күтәрелергә кирәк иде. Һәм ул, ишек төбендә тукталып тормастан, ашыгып-йөгереп атлады:

— Эй, куда вы, молодой человек? Куда вы, откуда вы?!

Юлына аркылы төшкән бу хатынга Хәбир нидер аңлатырга, барысын берьюлы, бер сүз белән төшендереп бирергә теләде:

— Апа! Поймите, я только что из милиции! Мне нужно пройти!..

Хатын татар карчыгы булып чыкты:

— Ә-ә, милициядәнмени?.. Баштук шулай диләр аны!..

Хәбир дүртенче катка менеп җитте, тукталып сулыш алды. Коридорда тынлык. Утлар тонык. Хәбир караңгы коридор буйлап тавышсыз-тынсыз гына атлады. Аны монда беркем дә күрмәскә, аның юлын бүлдермәскә тиеш иде. Кызы яткан палатага якынлашкач, ул тукталып калды. Палата каршындагы зал сыман бер урында ак халатлы берәү утыра иде. Хәбир шактый озак басып торды. Ак халатлы кеше кузгалмады: «Йоклыймы әллә?..» Ничек тә булса алгарак үтәргә, сиздермичә генә палатага керергә кирәк иде. Түзмәде Хәбир, тагын атлап китте. Ишек тоткасына үрелгәч, әкрен генә борылып карады, һәм таныды: кечкенә диванның бер почмагына сыенып, башын чак кына кырын салып, Фәридә Рәшитовна йоклап утыра иде. Тәрәзәдән төшкән тонык яктылык аның йөзен чак кына яктырта.

Хәбир, гаҗәпләнеп, аңа таба бер адым атлады. Янә тукталып калды. Нишләргә белмичә, бер урында таптанды.

Врач кинәт сискәнде. Күзләрен ачып, шулай ук гаҗәпләнеп, Хәбиргә карап торды.

— Сез?.. Сез кайда йөрдегез моңарчы?!

Врачның тавышында шатлану бар идеме, әллә ачулану, рәнҗү, үпкәләү идеме — монысын Хәбир аңламады.

Кайдадыр якында аяк тавышлары ишетелде. Фәридә Рәшитовна Хәбиргә утырып торырга ишарә ясады.

— Ә-ә, сестра бу, Әлфия...

Кыз алар янына якынлашты.

— Бүген дә кунасызмы, Фәридә апа? — диде ул һәм, Хәбирне шәйләп, чак кычкырып җибәрмәде: — Әбәү, Фәридә апа, кем бу сезнең янда?!

— Розалиянең этисе бу, Әлфия. Килде бит менә, көтә торгач...

Кыз шул мәлдә кабынып китте:

— Йә инде, шундый эти кеше буламы? Кайда югалып йөрдегез соң сез? Фәридә апа инде өченче төнен больницада үткәрә, сезнең кызыгызны саклый, борчылмасын дип. Ә сез?!

— Әлфия!.. Ни сөйлисең син, җанычкаем?! Ярамый кешегә алай бәрелергә...

— Ә аңа ярыймы, Фәридә апа?!

Хәбир берничә сүз белән генә үзенең хәлен сөйләп аңлатты. Шушы ак халатлы ике кеше алдында кыен да, оят та иде аңа.

— Сез мине гафу итегез, инде, Фәридә Рәшитовна... Хәтта сезгә шалтыратып әйтергә дә ирек бирмәделәр.

Врач дәшмәде. Башын түбән иеп, нәрсә турындадыр уйланып утырды.

— Сез миңа ышанмыйсыз бугай, Фәридә Рәшитовна. Аңлагыз, әгәр шулай килеп чыкмаса, кайдадыр адашып йөрер идеммени, кызым янына килми калыр идеммени мин?!

— Нигә ышанмаска...мин инде күптән... Теләсә нинди яманлыкның барлыгына ышанам,— врач шәфкать туташына карады.— Әлфия, бирәр ак халат табып килче абыеңа. Югыйсә, күреп алсалар...

— Розалиянең хәле ничек? Мин аны алып чыга аламмы, Фәридә Рәшитовна? — диде Хәбир, сестра кыз киткәч.— Ул мине көткәндер, елагандыр, шулай бит?

— Көтте, нык көтте,— диде врач.— Әмма, ышаныгыз, тамчы да еламады...

— Хәле ничек аның?

— Хәле әйбәт, Хәбир Әхмәтгалиевич. Тик сез хәзер үз хәлегез турында уйларга тиеш. Розалиягә бу килеш күренү ярап бетмәс бит. Сакал баскан үзегезне...

Хәбир, елмаеп, яңакларын сыпырып куйды.

Врач тумбочка өстенә ачкычлар чыгарып салды. Аннан соң, кесәсеннән кәгазь алып, ашыгып нидер язды, кәгазьне Хәбиргә сузды:

— Менә адрес. Моннан ерак түгел... Җәяү барсагыз, ике генә квартал. Ванна бүлмәсендә кырынгыч бар. Иремнән калган...

— Ничек?! — Хәбир, бөтенләй каушап, үзенә сузылган кәгазьне алырга да, алмаска да белми торды.— Сез мине... үз өегезгә?.. Килешерме соң?

— Сезгә бит ял итәргә, үзегезне тәртипкә китерергә кирәк, Хәбир Әхмәтгалиевич. Барыгыз, бар... Ә мин, әгәр Розалия уянса, сезнең килгәнне әйтермен аңа. Ул төнлә уянгалый.

Хәбир врачның кулыннан алды:

— Нинди рәхмәтләр әйтим мин сезгә, Фәридә Рәшитовна?!

— Рәхмәт кирәкми. Сүземне генә тыңлагыз. Барыгыз. Монда күренергә ярамый сезгә, аңлыйсызмы? Төн уртасы җитеп килә бит...

— Аңлыйм, аңлыйм, Фәридә Рәшитовна... Тик бер генә тапкыр... Розалиянең бүлмәсенә генә күз төшереп алыйм, зинһар?!

Врач баш чайкап елмайды. Һәм Хәбирне үзе артыннан әйдәде. Алар, аяк очларына гына басып, тоныкяктылык эченнән сак кына атладылар.

Врачның ишекне чак кына ачуы булды, бүлмә эченнән сискәнүле тавыш ишетелде:

— Әтие-ем!..

Розалия караватында торып утырган, күзләрен ишеккә төбәгән иде.

## XIX

Әхмәтгали картны икенче көнне генә җирләделәр. Көннең җепшеклеге тагы да арткан, кар катыш яуган яңгыр үз эшен эшләгән иде.

Мәрхүмнең баш очында җеназа укуны картлар Әхмәтнәҗип абзыйга тапшырдылар. Искечә язуны укый белүчеләрдән авылда ул бердәнбер ир-ат санала иде.

Авыл күңелсезләнеп калды. Эрегән кар астыннан чыккан тау түбәләре каралды, ап-ак булып, матур булып башланган кышның яме китте. Олы мал суйган кешеләр итне кар өеменә күмеп саклаграга тырыштылар.

Әхмәтгали картның кабере зиратта берьялгызы каралып күренеп тора иде. Күмүчеләр таралышкач, Әхсән зиратта үзе генә калды. Әтисе кабере янында башын иеп басып торган кеше нәрсә турында уйлый?.. Әхсәннең уйлары аның бары тик үзенә генә билгеле иде...

Икенче көнне Әхсәнне райкомга, Бикташев янына чакырдылар. Әхсән бу хәбәргә бөтенләй битараф иде. Юлда барганда кинәт Әхмәтнәҗип абыйсының сүзләрен искә төшерде. Теге көнне, өлкә комитетыннан килгән кешеләр белән сөйләшкәннән соң, укытучы янында чакта ишетте ул сүзләрне Әхсән.

— Аптырыйсыңмы? «Нигә мине эштән генә алмыйлар, нигә төрле сораулар белән тинтерәтәләр?» — дисеңме? Артык беркатлы бала син, Әхсән улым... Аларга бит син бик кирәк. Синең кебек кешеләр кирәк аларга. Ә ни өчен кирәк икәнең беләсеңме соң?

— Ни өчен кирәк, Әхмәтнәҗип абый?

— Их-х! Шуны да аңламыйсың... Халыкка күрсәтер өчен кирәк, менә безнең арада да намуслы, гадел, эшчән кешеләр бар, дип әйтә алыр өчен...

Шул сөйләшүне исенә төшереп, уйлап барды Әхсән. Юк, әгәр Әхсән кемгәдер бары тик шуның өчен генә кирәк икән, аннан инде бүтән берни дә өмет итмәсеннәр. Илдә чыпчык үлми... Әхсәннең әле үз тормышы, үз гаиләсе, үз нигезе бар. Әтисеннән калган нигез...

Бикташев аны кочаклап диярлек каршы алды.

— Кайгыңны уртаклашам, Әхсән... Чын күңелдән,— диде ул, күрешкәннән соң.— Мин инде шалтыраттым, район газетасында матур гына некролог урнаштырырга куштым. Әтиеңнең исталеге кешеләр күңелендә калырлык булсын.

— Мине ник чакырдыгыз, иптәш Бикташев?

— Синең белән киңәшләшәсе бар. Миңа калса, обком комиссиясе ничектер тәгаен генә фикер туплый алмыйча китте. Ул иптәшләр хәзер, мөгаен, белешмә әзерлиләрдер. Мин әле генә иптәш Овчинников белән сөйләшергә заказ бирдем. Телефон көтәм. Мин аңа аңлатачакмын: Әхсән Сабирҗановның әтисе вафат булды, димәк, сезне борчыган мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде, диячәкмен. Сез дә үзегезчә аңлатырсыз: мин әтине күп тапкырлар үгетләдем, ләкин ул картайган иде инде, үгеткә бирелүдән узган иде, дип әйтерсез.

— Мин әткәйне беркайчан да бернәрсәгә дә үгетләмәдем, иптәш Бикташев.

— Һы!.. Эш үгетләүдә-үгетләмәүдәмени?! Эш алар язган справкада сезнең хакта нинди сүзләр әйтелүдә! Монда бер нәрсә ачык бит: әтиегез үлгән, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителгән?

— Юк, хәл ителмәгән шул әле, иптәш Бикташев. Минем әнием исән. Ә ул карчыклар арасында абыстай булып йөри...

Бикташевның телефонга үрелгән кулы катып калгандай булды.

— Ничек инде? Ни сөйләгәнеңне беләсеңме син, Сабирҗанов?!

— Миңа тагын нинди сүзегез бар, иптәш Бикташев?

Райком секретаре башын чайкап күрсәнде:

— Һай-й!.. Ә бит мин синең өчен тырышып йөрим. Район партия оешмасына тап төшмәсен дип тырышам. Ә син?! Нинди үҗәт кеше син, Сабирҗанов?

Кичке якта Әхсән янына колхоз рәисе Әхмәтхан Шакиров сугылды.

— Ишеттем, ишеттем,— диде ул, килеп керүгә үк.— Синең кыланмышларыңны Бикташев шалтыратып әйтте инде. Ә Казанга барыбер шалтыратам, мәсьәлә уңай хәл ителде, дип әйтәм, диде. Тәк что юлың уңачак...

— Нигә киләсең син миннән, Әхмәтхан абый?

— Синнән түгел, энекәш, үземнән, үземнең көчсезлегемнән киләм. Кеше булып яшибез бит инде без бу Җирдә, икмәк үстерәбез, мал карыйбыз, адәм балалары әйбәт яшәсен, бәхетле булсын, дип тырышабыз. Һәм белмичә түгел, белеп тырышабыз: җир безне аңлый, без җирне аңлыйбыз. Ә менә берәү тегендә, кулына телефонны ала да: «Алай яшәмәгез, болай яшәгез!» — дип өйрәтергә тотына. Борын асты кипмәгән үзенең, ә үзе халык исеменнән сөйли, халык исеменнән өйрәтә, халыкны калкан итә. Юк, Әхсән энекәш, күп тырыштым мин, җитәр... Тәк что син мине котлый аласың: лаеклы пенсионер булырга җыена Әхмәтхан абыең. Менә, шуны әтмичәйт итәргә исәп синең белән...

Әхмәтхан өстәлгә «тук» иттереп «Столичная» шешәсе чыгарып утыртты.

— Менә бит, элек «Московская» дип атала иде. Заман гел үзгәреп тора: хәзер инде — «Столичная». Менә шулай... «Столичная» булгач, башкалада гына эчәргә тиешләр дә инде моны, югыйсә. Юк бит, менә без дә шуны синең белән караңгы бер авылда рәхәтләнеп эчеп утырабыз. Менә бит нинди тигезлек башкала белән авыл арасында!

Әхмәтханның күңеле уйный иде, ахрысы. Гел сөйләнде, сүзен һаман кинаяләп тә, шаярып та әйтә торды. Эчеп куйгач, хәмер пары башына йөгергәч кенә тынычланды.

— Сиңа ике яңалык әйтәсем бар, Әхсән энекәш,— диде ул, бераз тынып торганнан соң.— Икесен дә күңеленә авыр алма... Беренчесе: Ильясны күргән идем мин, «Әхмәтгали абзыйның җидесе булса да үтсен инде, туйны кичектереп торабыз»,— ди. Мин моңа каршы килдем. Тиргәп үк ташладым әле үзен. «Син нәрсә, шайтан мөгезе, үзең турында гына уйлыйсың? Булачак килен турында уйла! Аның,— минәйтәм,— самый тулган чагы, ул синең кебек түгел, туй көнен көтеп зарыгып йөри,— дим.— Ә син кичектерик дисең! Аннан тагын авыл турында уйла,— дим.— Авыл турында уйласаң, туйны озакка сузма, тизрәк өйләнешегез дә, өй тулы бала үстерегез! Авылга кирәк!» — дим. Дөрес әйткәнменме, юкмы, ә?

— Шулай, Әхмәтхан абый. Үлгән артыннан үлеп булмый, диләр бит. Яшьләрнең яшисе бар...

— Колхоздан шәп бүләк әзерләрбез үзләренә. Син ачуланма, атаңны хөрмәт итәм мин. Мәгәр туйны сузарга кирәкмәс. Менә, иртәгә Әхмәтгали абзыйның өчесен уздырыйк та берсекөнгә — туй. Ильяска мин шулай дип әйттем.

— Дөрес эшләгәнсең, Әхмәтхан абый.— Әхсән үзенә ничектер җиңелрәк булып киткәнен тойды. Бу мәхшәрле көннәрдән соң, беренче тапкыр иркенәюе, хәл алуы иде аның. Әхмәтхан абыйсы да акыллы әңгәмәдәш: «Күңеленә авыр алма»,— дип башлаган сүзе дә яхшы яңалык булып чыкты. Яхшы яңалык — туй...

— Син ике яңалык әйтәм дигән идең, Әхмәтхан абый?

— Әйтәм, анысын да әйтәм. Хәлиматтине күрдем беркөнне. Сөйләшеп тордык. Шул әйтә: «Чишмәдә тоз тәме бар, Әхмәтхан, нәрсәдән икән ул?» — ди. «Каян беләсең, синең бит чишмәгә йөрмәгәнеңә биш-

былтыр инде, Хәлиматти.»— дигән булам. «Улым Таһир кайткач, теләнә авыл тәме йокмасмы дип, чишмә суы алып мендем. Шуннан беләм, Әхмәтхан, чишмә суында тоз тәме бар.»— ди. Яшьләр-яшьләр, дигән булабыз без менә. Яшьләр алар. Әхсән энем, чуртым да бернәрсә белми. Тәҗрибә юк аларның, тартып-йолкып алынган. Аларга чишмә суына хет кислота салып бир, тәмле дип эчәчәкләр. Ә менә карт кеше искәргән: чишмә суында тоз тәме бар, ди.

— Каян килгән тәм икән соң ул, Әхмәтхан абый? Нинди тоз тәме?

— Ә син, энекәш, шуны сизенмисеңме? Хәлиматтидән ишетүгә, йөгереп барып чишмәгә төштем. Татып карадым суын. Дөрес әйткән карчык: тәм бар суда. Моннан биш ел элек Әлмәт ягындагы бер авылда шундый су эчкән идем мин. Тәме авызда калган... Нефть кудырган сулар чыга чишмәгә, Әхсән, агулы сулар... Авылга суны читтән ташыйсы була, йә бөтенләй күчерәсе була авылны. Ә кая күчерәсең аны? Кая күчерәсең? Мәскәү читенә илтеп салып булмый ич аны!..

Әхсән туйга хатынын алдан җибәрде, соңыннанрак барырмын, диде. Әтисенең өчен үткәрүгә үк, хатынын култыклап туйга йөрү бер дә килешә торган эш түгел булып тоелды аңа. Сәҗидә, күрәсең, аны аңлады: аны-моны әйтмичә, ялгызы гына китте.

Әхсән килеп кергәндә мәҗлес башланган, туй кызып өлгергән иде инде. Туйны алып баручы итеп Хәмәт Мортазинны билгеләгәннәр икән. Ул, Әхсәннең кергәнен күреп алып, табындагыларның игътибарын аңа юнәлтте:

— Иптәшләр! Җәмәгать! Әхсән Әхмәтгалиевич соңарып килде. Аңа штраф бирергә тәкъдим итәм! Яшьләр бәхете өчен тамчысын да калдырмаска, төбенә тикле бетерергә!

Әхсән сизде: карышкан саен игътибар гына артачак иде. Алдына куелганны күтәреп эчеп куйды. Ильяс белән Нуриягә күз кысып алды. Туй моны хуплады, шау-гөр килде. Инде үзалдына тынычланган, туй агымына кушылган иде Әхсән. Тик янә үзенең исемен ишетте:

— Җәмәгать! Яшьләр хөрмәтенә Әхмәтгалиевичне җырлатыйк! Әхсән Әхмәтгалиевичнең җырлаганын кайсыгызның күргәне бар? Минем күргәнем юк. Әйдәгез, җырлатыйк Әхсән Әхмәтгалиевичне! Җырлатыйк!

Туйдагыларга кызык: Мортазинның һәр яңа сүзен куәтләп, кул чабып каршылыйлар. Тукта!.. Юри кыланамы соң бу Мортазин? Исереп киткәнме әллә?

Җырлаудан котылып калган иде Әхсән. Яңадан тынычлана башлаган иде. Әмма Мортазин янә сикереп торды:

— Иптәшләр! Әхсән Әхмәтгалиевичнең бүген кайгылы көне. Мәрхүм әтисен дә җирләде. Аннан комиссия дә килеп, эшен тикшереп китте. Әхсән Әхмәтгалиевичнең кайгысын уртаклашып, эчеп куйыйк, иптәшләр!..

Тәнәфес игълан ителгәндә туй гөрләп күтәрелгән иде инде. Яшьләр биергә тотынды. Кемдер Әхсәнне дә чакырып интектерде. Ә ул, бер почмакка басып, тормыш турында уйлады. «Менә, кешеләр туй итә,— диде ул үз-үзенә.— Бәйрәм бит инде бу. Тик бәйрәм бик тиз генә уза да китә, ә калган гомер борчу-хәсрәттә үтә. Бәлки, без бәйрәм итә дә белмибездер? Бәлки без, гомумән, яши дә белмибездер? Ни өчен соң яшәү үзе бәйрәм түгел?..»

Аның янына инде Сәҗидәсе килеп китте, «Берүземә кыен, әйдә, кереп утырыйк,»— диде. Әхсән дәшмәде, «хәзер, хәзер» дигәнне аңлатып, кул гына изәде. Ул уйлый иде. Бу уйларның тыпырчынуын ул аңлый, башка киткәч хәмер нәтиҗәсе икәнен белеп тора, сизә, әмма үзе шулардан арына алмый иде: «Бүген бердәнбер бәйрәм, чын

бәйрәм — Ильяс белән Нурия. Чөнки алар бер-беренә кирәк. Кешеләр бер-беренә кирәк булганда — алар өчен һәрчак бәйрәм була, көнел бәйрәме була. Кешеләр бер-беренә кирәк булмаган җирдә бәйрәм бетә, әшәкелек, хөсетлек, мәгънәсезлек, ялагайлык, дошманлык калкып чыга. Кешеләр бер-беренә кирәк булганда гына һәркемнең кадере була...»

Әхсән янына Нурия чыкты:

— Туйны сез алып бармассыз микән, Әхсән абый? Нишләргә инде, Хәмәт абый бөтенләй исерде бит...

— Мин ул эшне булдыра алмам, Нурия үскәнем. Син аны бүтән берәүгә куш инде. Яшьрәкләрне кара...

Нурия кереп китүгә, чайкала-чайкала, Хәмәт Мортазин килеп басты:

— Оһо-о, Әхсән Әхмәтгалиевич!.. Ниш-ш-ләп с-син ялгызың? Ниш-ш-ләп мине чакырмыйсың янына? Ә?!

— Хәмәт абый, син бераз артыграк тоткансың, ахры,— диде Әхсән, аны тынычландырырга теләп.— Минем исем белән дә, зинһар, бик каты уйнама. Югыйсә, гел бер нәрсәне кабатлыйсың, һаман минем исемне кычкырасың. Болай килешми.

— Аңлыйм, аңлыйм, Әхсән Әхмәтгалиевич! С-сине дә аңлыйм, баш-шкаларны да аңлыйм, барыгызны да аңлыйм мин. Хәмәт Мортазин бөтен дөньяны аңлый! Син, брат, дөресен әйткәнгә ачулана күрмә, эш-шли алмыйсың син бу эш-шеңдә. Юк! Син бит кара крестьян! Сиңа бит фермада эшләү күбрәк килешә! Мин шулай уйлыйм. Ә партия ул, брат, ул ш-шундый нәрсә — сыйныф бит ул беләсең килсә! Сый-ныф! Дворяннар үз араларына теләсә кемне кертмәгән кебек, партия дә теләсә кемне үзенә алмый. Ә с-син...

— Нәрсә сөйлисең син, Хәмәт абый?!

— Ә мин белеп сөйлим. Партия ул — сыйныф! Ә син ул сыйныфтан түгел. Түгел! Менә шул...

Әхсән үзен кочакларга үрелгән кулларны бер читкә этәрде, биючеләрне аралап, табын бүлмәсенә кереп китте. Өстәлдә торган стаканга тутырып аракы салды. Бер селтәнүдә күтәреп эчеп җибәрде. Баш миенә шаулап кан йөгергәнен тойды.

— Эчәргә кирәк! Онытылырга, үлгәнче эчәргә кирәк миңа бүген! — дип кабатлады ул...

Әхсән Сабирҗановның юкка чыкканын табындагылар соңыннан, Сәҗидә тавыш чыгаргач кына тойдылар.

— Өйгә дә кайтып килдем, юк. Әхмәтнәҗип абыйларга сугылдым, Әхмәтхан абыйларга кердем, беркайда да юк! — Сәҗидә инде еларга җитешкән иде.— Эчеп утырганын күрдем, «эчмә» дип әйтәлмадым, телем бармады. Кайларга гына китте икән соң, кайларга гына?!

Ильяс яшьрәк егетләрне авыл буенча йөгертте. Әхсәнне сарай һәм лапас әчләреннән, мунча алларыннан эзләделәр — табалмадылар.

Ниһаять, эзләп киткән егетләрнең берсе кайтып әйтте:

— Таптык Әхсән абыйны! Ул фермага төшкән, тирес өеме өстендә утыра!

— Әй, ходаем! Нигә соң алып кайтмадыгыз аны?

— Кереп булмый аның янына! Тирә-якта пычрак су, тезгә җитәрлек. Күреп торасыз бит, туйга дип кигән чалбар белән мин...

Ильяс туй костюмы өстеннән кара халат киеп алды да, урамга чыгып, тракторын кабызды. Халык аның тракторы артыннан иярде.

Әхсәннең гәүдәсе багана башыннан төшкән яктылыкта аермачык булып күренә иде. Сәҗидә үкси-үкси ялварды:

— Әхсән! Әхсән дим! Нишләп барып кердең анда, бәгырькәем?! Чык, зинһар, кире! Нишләп утырасың анда? Әхсән дим!..

— Чык, Әхсән! — дип кычкырды башкалар да.

— Юк, чыкмыйм... Монда рәхәт! Мин монда үзем хуҗа! Мин сыйныф түгел! Мин — җир кешесе, кара крестьян!..

Сәҗидә нишләргә белми әрле-бирле йөренде:

— Әхсән, нигә дип үзеңне-үзең оятка калдырасың, бәгырькәем?! Чык, дим, туйның ямен җибәрмә!..

Ильяс, тракторын бер үкертеп алды да, тиреслеккә таба китте. Пычрак су трактор тәгәрмәчләрен күмә язды. Ильяс янына утырып кергән егетләр Әхсәнне күтәреп алдылар да, кабинага кертеп утырттылар.

— Ә, нигә алып чыгасыз мине моннан?! Нигә дип мине аерасыз бу тиреслектән?! Миңа монда ошый! Миңа монда рәхәт! Мин — сыйныф түгел! Мин — җир кешесе...— Әхсән үкси-үкси бер үк сүзләрне кабатлады.

— Аракы сөйләтә инде моны,— диде өлкәнрәкләр.— Әтисенең үлеме дә кисәк булды бит. Җыелып килгәнне чыгара инде бу...

— Туйда шунсыз күңелсез була ул! — диде яшьрәкләр.

Әхсәнне өенә илтеп куйдылар. Туй әле ярты төнгә тикле дәвам итәчәк, Әхсән белән булган вакыйга онытылачак, аны бүтән вакыйгалар күмеп китәчәк иде...

## XX

Самолетка билет алынган иде инде. Хәбир башта аэропортка барды, «Казан» кунакханәсенең горничнаясыннан юллап алынган чемодан-сумкаларын саклау камерасына тапшырды. Аның әйберләре актарылган, Әфганистаннан истәлеккә һәм күчтәнәчкә дип алынган кайбер вак-төяк юкка чыккан иде. Хәбир моңа кул гына селтәде: соңгы көннәрдә булган бу вакыйгалардан соң, әлеге югалту чүп кенә булып тоелды.

Бүлмәне тапшырып, инде баскычтан төшеп барганда Розалия боргалана, көйсезләнә башлады.

— Ни булды, кызым? Китабез, әйдә, ашыгырга кирәк бит безгә!

— Ә курчак?..— дип еламсырады кыз.— Курчак калды?..

— Нинди курчак? Безнең курчак юк иде бит! Йә, ярый, мин сиңа юлда бүтән курчак алып бирермен.

— Юк, кирәк түгел!... Миңа теге курчак кирәк, врач апа биргән курчак!..— Розалия киреләнеп елый ук башлады.— Ул калды... Курчак калды!..

Хәбир, аптырагач, бүлмәгә кире кереп чыкты — Розалия әйткән курчак анда юк иде.

— Без бит больницадан бернинди курчак та алмадык,— диде ул, аптырагач.— Шунда калгандыр ул, кызым, больницада ук. Елама, тагын шундый ук курчак алырмын мин сиңа...

Хәбир үзе кызын юатты, үзе кинәт искә төшерде: «Ә аңа еларга кирәк,— диген иде бит Фәридә Рәшитовна теге көнне.— Мине Розалиянең еламавы күбрәк борчый. Бала еласа һәм көлсә генә сәламәт була...» Кабулда әнисе каберен калдырып киткәннән бирле болай күз яше белән елаганы юк иде түгелме соң кызының?! Әйе шул, еламый, бары тик сулкылдый гына иде бит ул!..

Розалияне көч-хәл белән тынычландырып, урамга алып чыкты Хәбир. Аэропортка кадәр берничә генә тукталыш барасы иде.

«Фәридә Рәшитовнага шалтыратып, тагын бер кат рәхмәт әйтергә кирәк,» — дип уйлады Хәбир. Кызын больницадан алып чыкканда ул артык каударланды, каушады, ашыкты — юньләп саубуллаша да, ныклап рәхмәт тә әйтә алмый калды.

Кулындагы әйберләрне аэропорт залына кертеп куйгач, кызын

уэнаштыргач, иң беренче эш итеп, телефонга китте. Хәбир ашыгып шалтыратты, әмма Фәридә Рәшитовнаны таба алмадылар.

— Сеңлем!..— диде Хәбир, врачны эзләп килгән сестра кызга.— Зинһар, аңа күп итеп рәхмәт тапшырыгыз!.. Сабирҗановтан, аның кызы Розалиядән дип әйтегез!

— Ә, бу сезмени әле, Хәбир абый?! — диде телефондагы тавыш.— Мине танымадыгызмы? Әлфия мин, Әлфия!.. Фәридә апаны таба алмадым шул, авырулар янындадыр ул, мөгаен. Ә сез кайдан шалтыратасыз?

— Безнең китеп барыш,— диде Хәбир, үзенең тавышы начар ишетелгәнен сизеп, кычкырыбрак эндәште: — Аэропорттан без, иске аэропорттан!..

— Самолет кайчан?

— Озакламый регистрация башланыр инде, сәгатьтән азрак вакыт калып бара самолет очарга!.. Әлфия! Күп итеп рәхмәт тапшыр безнең исемнән, яме? Мин бит юньләп саубуллаша да алмадым...

Фәридә Рәшитовнаның үзе белән сөйләшә алмаса да, сүзен сестра кыз аша тапшыргач, өстеннән ниндидер бер йөк төшкәндәй булды Хәбирнең. «Мин инде теләсә нинди яманлыкка ышанам...» — врачның әнә шул сүзләре, ничектер йөрәгенә уелып, тетрәндереп калдырган иде Хәбирне. Теге көнне Фәридә Рәшитовнаның квартирасына кайтып, юнып-кырынып, өс-башын тәртипкә китергәннән соң, иртән ачкычларны илтергә баргач, шул турыда сорарга теләде. Эчкерсез рәвештә ярдәм итә белгән, эш сәгатеннән соң төн йокысын калдырып авыру бала янында — бөтенләй чит кеше кызы янында утыра алган игелекле бу хатынның әлеге сүзе уйландырган, нык уйландырган иде Хәбирне. Ләкин ул, күпме генә теләсә дә, бу хакта сүз башлый алмады. Хәер, үзе башлап сорамавы да әйбәт кенә булган икән. Барысы да үзеннән-үзе килеп чыкты...

Алар бүлмәдә сөйләшеп утырганда, ашыгып-кабаланып, Әлфия килеп керде. Йөзләре алсуланган, сулышы кабынган иде:

— Фәридә апа, җаныкаем,— диде ул, Хәбиргә күз генә салып алып.— Зинһар, илле генә сум акча биреп торчы?.. Бик кирәк иде.... Аванска кадәр генә...

— Нәрсә, тагын теге егетең килгәнме әллә? — диде врач, нәрсәнедер өнәп бетермәве йөзенә чыккан иде.— Сүземне тыңламыйсың син, кызый. Алма шуның әйберләрен! Юньле егет булса, ул кызына бүләк итәр иде, болай сатып йөрмәс иде!..

— Соң, Фәридә апа, ул бит аны минем өчен эзләп тапкан! Кулдан алдым, ди. Шундый матур свитер, Фәридә апа! Менә, күргәч, үзең дә шаккатырсың!

— Юк, Әлфия, үзеңә күбрәк шаккатам мин синең. Ничә әйттем мин, ничә кат әйттем сиңа, барыбер аңламыйсың икән...— врач өстәл тартмасындагы сумкадан акча алды.— Бер акылга керерсең син, терсәгеңне тешләрсең — соң булыр...

Әлфия чыгып киткәч, Хәбир әкрен генә сорады:

— Нәрсә, егете аламамыни?

Врач көрсенде:

— Белмим, никтер ошап бетми ул миңа. Ничә тапкыр инде шулай: каяндыр юллап, дефицит әйбер алып килә. Кызның күңелен шулай яулыйлармы?! Күреп торам бит, сатып бирә ул аларны Әлфиягә, акча эшли... Яраткан кызына шулай әйбер саталармы? Хәзерге яшьләрне аңламассың, аның Әлфиясе дә шуны яклый. «Акча кадерен белә торган кеше ул, андый белән яшәп була!» — дип шаяртып кына куя. Юк, Хәбир Әхмәтгалиевич, акча яраткан кеше беркайчан да акча өчен генә йөрми, мин монысын төгәл беләм...

— Ә нәрсә өчен йөри?

— Нәрсә өченме? Власть өчен... Акча кешегә власть бирә — баш-

калар өстеннән... Бүтән кешеләр белән исәпләшеп тормау мөмкинлеген бирә. Акчалы булуның түбән бер белгән кеше әхлак дигән нәрсәне дә, кеше хакын да оныта. Идеалы да, иманы да калмый. Теләсә нинди әшәкелеккә бара. Яманлыкның иң әшәкесе — әнә шундый кешеләрдән...

— Сез андый кешеләрне күп күргән кебек сөйлисез...

— Хәбир Әхмәтгалиевич!..— диде врач, сәер генә елмаеп.— Сез мине Әлфия өчен тиктомалдан гына кайгыра, әше юктан борчыла дип уйлыйсызмы әллә?! Мин үзем шундый кешегә килеп эләктем... Мин бит... Юләрләнә яздым шуның аркасында...

Хәбир үз колагына үзе ышанмыйча тыңлады. Фәридә Рәшитовнаның булачак ире официант булып эшләгән, читтән торып финанс-экономика институтында укыган. Әле өйләнешкәнче үк, акчага хирыс кеше икәнен сизгән ул аның, ләкин игътибар итмәгән, гаилә өчен әйбәт кенә булыр, дип уйлаган. Эчмәгән, тартмаган аның ире. Өйне караган, җиһаз белән тутырган. Монда, Казанда, рестораннар трестының җитәкчесе булып алгач, кинәт үзгәргән: хатынын эшләтмәгән, хезмәтче урынына тота башлаган. Ә бервакыт, бала белән авылга, әниләре янына кайтып, шуннан гына килеп төшкән хатын иренең өстенә килеп керә: квартира тәтенгә уралган, өстәлгә коньяк шешәләре тезелгән, иренең муенына яшь бер кыз уралган...

— Мин ул чакта бөтенләй коелып төштем. Аннан соң инде үземне кулга алдым: бөтен горурлыгым уянды, аерылышырга гариза бирдем. Тик ул... Әйткән иде ул: «Тавышыңны чыгарма, үзеңә генә бала табарсың»,— дигән иде... Судта ук сиздем. Гаилә таркатуда мине гаепләделәр, баланы аңа калдырдылар. Мин Верховный судка яздым. Аннан эшне, яңадан карарга дип, район судына кайтардылар. Ел буе шулай йөрттеләр. Ә бала ул вакытта, беренче суд хәл иткән килеш, аның белән торды... Миңа аны күрсәтмәделәр, янына җибәрмәделәр...— Врач кинәт үзгәрде, иреннәре дерелдәп китте.— Ә бер судта ул, беләсезме, мине бөтенләй танымый, мине үз әнисе дип белми...

Мин юләрләнә яздым ул чакта. Судлашып эш барып чыкмагач, партия органнарына яздым, Мәскәүгә яздым — файдасыз... Бервакыт миңа әйтте ул: «Юкка йөрмә, барыбер синеңчә булмаячак, без бик күп, ә син — берүзең»,— диде. Аңлатты ул миңа, аңлатты: мин аларның — судының да, башкасының да бер яклы булуын аңладым... «Тагын шулай йөрсәң, психбольницага илтеп тыгам мин сине,»— ди. Шуннан соң, мин нишлим инде, әйттем үзенә: «Саттар, синең каршы көрәшә алмыйм мин, тик шуны бел, каргыйм мин сине, каргышым төшми калмас,» — дидем. Юк, каргыш та төшми икән андый кешеләргә, каргышның да көче җитми...

— Саттар? — дип кабатлап сорады шунда Хәбир үзе дә сизмәстән. Врачның тетрәнеп куюын күреп, сүзен икенчегә борды: — Әллә нинди исемнәр була дөньяда...

Регистрация игълан иттеләр. Хәбир, кешеләр сирәгәйгәч, паспортын һәм билетын сузды. Кассада утырган кыз аның паспортына гаҗәпләнеп карады: могаен, чит илгә чыгу өчен бирелгән паспортларны ул сирәк күрәдер.

— Сез чит илдән кайтып киләсез,— дигән иде Фәридә Рәшитовна Хәбиргә.— Әйтегез әле, анда — Әфганстанда — сез нәрсә белән шөгыльләндегез? Әллә бу әйтергә ярамый торган серме?

— Сер түгел,— дип елмайды Хәбир. Мин бит һөнәрем буенча — рәссам-реставратор. Шартлатылган биналарны төзекләндердек. Күбрәк — тарихи истәлеккә ия булган биналарны. Мәчетләрне...

— Реставратор...— дип кабатлады врач. Аннан соң елмаеп куйды.— Мин бу сүзне әлек гел начар мәгънәсендә аңлый идем. Бөтенләй башка мәгънәдә.

— Ничек инде?
— Тарих китабында язылганча. Мәсәлән, француз революциясенә каршы булган көчләрне, монархияне кире кайтарырга тырышучыларны реставраторлар дип атаганнар түгелме соң?
— Юк, без андый түгел, без яхшы әйберләрне генә, кешеләргә кирәк булганнарын гына кире кайтарабыз.— Хәбир сүзне шаяртуга борырга тырышты. Үзе турында сүз алып бару кыен иде аңа.
— Их, Хәбир Әхмәтгалиевич...— дип көрсенде врач шул чакта.— Сез генә кайтара алсагыз икән ул яхшылыкны кешеләргә...
Пассажирларны самолетка озатучы кыз инде билетларны тикшерә башлады. Хәбир, кызын җитәкләп, бер кулына әйберләрен күтәреп, алгарак чыкты.
— Курчак кала!.. Ләйлә кала...— дип көйсезләнде Розалия, янәдан исенә төшереп. Ул әле бераз онытылыбрак торган, кузгала башлагач кына көйсезләнергә керешкән иде.— Әти-ем, дим!.. Курчагым кала, врач апа биргән курчак...
Кешеләр ашыга, самолетка илтәчәк автобуска тула, берсен-берсе этә-тертә ишеккә тыгыла иде. Хәбир кызын ничек юатырга белми, кулына күтәрергә тырыша, кулындагы чемодан-сумкалары моңа комачаулый иде. Инде автобуска кердем дигәндә, Розалия кинәт аның кулыннан атылып чыкты, каядыр кирегә, койма ягына чапты:
— Врач апа!.. Курчагым!..— дип кычкырып җибәрде кыз. Хәбир шул мәлдә күреп алды: аэропортның алгы ягына ук «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктаган; аннан, яланбаш килеш, ак халатын җилфердәтеп, Фәридә Рәшитовна монда таба йөгерә иде.
Розалия рәшәткә янына беренче булып килеп җитте, башын аратага тыгып, түземсезләнеп, нидер кычкырып, врач апасына кул изи башлады.
— Кая китте тагын бу бала?! Кемнең кызы? Алып килегез, кузгалабыз! — дип кычкырды пассажирларны озатучы кыз. Хәбир кызы артыннан ташланган иде инде.
— Онытып калдыргансыз ич!..— Фәридә Рәшитовнаның сулышы кабынган иде, сүзен әйтә алмый торды.— Исән бул... Розалия... Терел... Бүтән авырма, яме!..
Кыз аның кулларыннан курчагын алды, күкрәгенә кысты.
— Фәридә апа!.. Рәхмәт сезгә!..
— Исән-сау кайтып җитегез!.. Исән бул, Розалия!
Хәбир врачның кулыннан алды:
— Рәхмәт сезгә...
Автобус кычкыртты. Хәбир, кызын алып, кычкырышкан, ризасызлык белдереп шаулашкан пассажирлар ягына йөгерде.
Самолетка кереп утыргач, Розалия иллюминаторга сыланды: бер кулы белән курчагын кысып, икенче кулын изәде дә изәде, аргач, бер генә ара хәл җыеп, тагын изәргә кереште.
Хәбир, кызы аша үрелеп, Фәридә Рәшитовнаны күрергә тырышты. Карашы белән эзләп тапты: врач һаман да шунда, аларны озатып калган урында, рәшәткә янында басып тора, аның чәчләре җилдә уйный, ак халат итәге җилферди, үзе бу якка кул изи иде.
Самолет ярсып үкерде. Борылыш ясап, очу юлына таба чыкты. Пассажирларны да, Хәбир белән Розалияне дә, аларның күз алдында калган врачның якты сурәтен дә болытларга таба алып менеп китте.

## Кыйссадан хыйсса

Хәбир этисе кабере янында басып тора. Аның монда килгәненә инде шактый вакыт үтте. Ә ул һаман урыныннан кузгалмый...

Нindидер кош яман ачы тавыш белән аваз салды. Хәбир сискәнде. Кошның тавышында кеше авазы белән охшашлык бар сыман тоелды аңа. Тынлыкка колак салып, теге тавыш кабатланмасмы дип тыңлап торды. Юк, кабатланмый... Ләкин нинди таныш аваз булды соң ул?

Хәбир, әкрен генә атлап, шул кошны эзләп китте. Ишеткәне бар: кеше вафат булгач, аның җаны бүтән бер җан иясенә әверелә, кошларга, күбәләкләргә, үсемлекләргә күчә икән...

Хәбир зират буйлап озак йөрде. Теге кошны барыбер таба алмады, күрмәде, очратмады ул. Ә бит нәрсәдер әйтергә теләде кебек ул Хәбиргә?..

— Һ-у-у!..

Хәбир сискәнде. Кайдадыр якында теге кошның тавышы кабат яңгырап китте. «Әһә!.. Кайттыңмы?!. Атаң каберенә килдеңме?.. Ул исән чакта син кайда идең? Син бит читтә йөрдең, читтә!..» — дип кычкыра сыман иде кош.

«Читтә...» — дип үзалдына кабатлады Хәбир һәм бу сүзне әле кичә генә ишеткән булуын исенә төшерде. Әйе, кичә, самолетта очканда...

Хәбир юл буе күзәтеп карап кайтты. Аста, самолет канатларыннан бик күпкә түбәндәрәк, аның туган ягы, туган җире җәйрәп ята иде. Башка бер вакыт булса, Хәбир шатлыгыннан нишләргә белмичә канатланыр, кызына барысын да күрсәтә-күрсәтә сөйләр, сөйләп туймас иде. Ләкин ул бүген ниндидер битарафлык белән өретелгән, хиссез бер кешегә охшап калган иде. Хәбир бу биеклектән аска карап фикер йөртә һәм үзен, туган җир өстеннән түгел, урманнар, басу-кырлар, елга-сулар өстеннән түгел, ә бәлки кителгән күңелләр, җимерелгән язмышлар өстеннән очып бара кебек хис итә иде...

Туган районы җирләренә якынлаша башлагач, Хәбир кызына эндәште:

— Кызым, кара әле: ә-әнә аста — Чаллы шәһәре!.. Хәзер, шуны гына узабыз да, җиргә төшәбез...— Аннан соң, шикләнерлек урын калдырмаска теләп, каршыдагы күзлекле иргә эндәште: — Чаллы шәһәре бит бу, әйеме?

— Юк, энекәш,— диде ир, әйткән сүзенә киная ясап.— Бу Чаллы шәһәре түгел, Брежнев шәһәре!

— Ничек инде?! — дип гаҗәпләнде Хәбир.— Мин ялгыштым микәнни? Ә ничек? Каян килеп Брежнев шәһәре?..

— Син, энем, йә күктән төшкәнсең, йә Җир читендә йөргәнсең,— диде күзлекле ир.— Икенче ел бит инде — Брежнев шәһәре дип язабыз, Брежнев шәһәре дип укыйбыз. Белми идеңмени? Алайса, читтә йөргәнсең син, энем, чынлап та...

— У-һу-у!.. дип аваз салды теге кош тагын бер мәртәбә. Хәбир тавыш килгән якны табарга, кошның үзен күреп калырга тырышты. Күзләре белән күпме генә эзләсә дә, табалмады.

— Һ-у-у!.. У-һу-у-у!..— бу аваз Хәбирнең артыннан йөри, аны эзәрлекләп бара сыман иде.

Зираттан чыккач, өйләренә таба китмәде Хәбир. Аның әле тагын ике урында буласы, тукталып уйланасы, күрешеп исәнләшәсе, серләшәсе бар иде. Чит илдә чакта уйлап-уйлап йөргән хыялы шул иде: берсе — авылга кайтып, җиргә ятып, Балтамак чишмәсенең суын туйганчы эчү; икенчесе — Кала тауга күтәрелеп, анда үсмер чакта ташка язып калдырган язуларны уку, тау түбәсеннән туган авылга күз салу...

Кичә аңа Әмирхан абыйсы әйткән иде:

— Авылга кыен, энекәш, миңа. Балтамакка нефть сулары төшкән, сусыз калырга торабыз,— дигән иде.— Чишмәгә төшкәч, арте-

зиан коеларына да керә инде ул тозлы су. Колонкалардан да шундый су килә башлаячак озакламый. Ә бит нинди чишмә иде Балтамак! Баллы тамак дигән сүздән алынган дип сөйлиләр иде бит исемен!..

Хәбир чишмә буена төшеп тукталды. Суы нәкъ элеккечә челтери иде Балтамакның. Хәбир аның суын учы белән үрелеп алды, иреннәренә тигерергә теләде, әмма тукталып калды... Менә шул мәлдә суны татып карар да, читтә-еракларда йөргәндә дә тәме авыздан китмәгән чишмәнең тәме югалыр кебек тоелды аңа...

Хәбир челтерәп сикерешкән тамчыларны учында уйнатты, шушы көмеш суның агулы булуына ышанасы килми торды. Күрер күзгә нинди саф, нинди чиста булып тора, ә үзендә агу... «Эх, саклый алмадык шул...» дип көенеп уйлады Хәбир.

— У-һу-у-у!..— дип расләды кош зират ягыннан. Хәбир урыныннан күтәрелде. Әкрен генә атлап, Кала тауга таба китте. «Менә, Хәбир,— дип уйлады ул.— Син зур-зур эшләр башкарырга хыялланган идең. Син белем алдың, чит якларда йөрдең, чит илләрнең йөзен күрдең, анда җимерелгән йортларны төзекләндердең. Ә бит шул вакыт эчендә синең туган ягың, үз авылың, үз илең күзгә күренми генә җимерелгән... Аны инде хәзер төзекләндереп булырмы?..»

Хәбир тауга таба атлады, аның итәгенә килеп җиткәч, тукталып, башын югары күтәрде: юк, менеп булмас, ахры, бүген монда... Малай чакта узыша-узыша менә торганнар иде бу тауга. Хәзер инде менүләре кыен булачак.

Ниһаять, ул тауның түбәсенә менеп җитте. Арган аякларын көчхәл белән сөйрәп, кар ятмаган таш өстенә утырды. Беренче кат авылга өстән, тау түбәсеннән карады.

— Менә, без авылга кайтып җиттек, кызым,— диде ул, үзалдына пышылдап.— Туган якка кайтып җиттек, кызым... Илгә кайттык...

Нигә әле ул кинәт кенә шулай кызын — Розалияне искә төшерде? Бала чагында үрмәләгән шушы тауга менгәнгәме? Балачак... Ул чактан бирле инде күпме сулар аккан, гомер үтелгән... Ә гомерне яңадан башлап булмый. Гомер бер генә... Розалия... Аның гомер юлы нинди булачак?.. Хәбир аны авылга — чишмәсе агуланган авылга, язмышлар кат-кат җимерелгән якка алып кайтты. «Кеше, әгәр дә ул чын кеше булса, гаилә корганчыга, балалар үстергәнчегә кадәр иң элек шуны уйларга тиеш: нинди тормыш әзерли ул үз балаларына?.. Нинди тормыш бүләк итә? Илдә кадере ни дәрәҗәдә була ул сабыйның?..» Хәбир күтәрелеп басты. Авыл өстеннән күз йөртеп, читкәрәк, каралып-зәңгәрләнеп күренгән зиратка төбәлде.

— Шулай, әткәй, шулай...— диде ул, әтисе белән киңәшкәндәй.— Шулай булмаса, яшәүнең дә кадере юк. Әгәр шулай түгел икән, кыз бала туса — кайгы да хәсрәт, ир бала туса — хәсрәт тә кайгы гына көтәчәк...

Хәбир үзе әле генә утырган таш өстенә менеп басты. Әйтерсең, моннан ул ераккарак карый ала, офыкны киңәйтә төшә иде. Кулларын югары күтәреп, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Әһә-һә-ә-ә-й!..

Колак салып торды: тавышының кайтавазы ишетелер сыман иде. Юк, ишетелми икән... Хәбир тагын сулыш алды, тагын бер кат бар көченә аваз салды:

— Әһә-һә-ә-әй!...

Тукта! Кайтаваз түгелме соң бу?.. Хәбир, тыны кысылып, каяндыр килгән тоңык тавышка колак салды. Һәм аңлады: юк, кайтаваз түгел икән... Бары тик ферма ягыннан бәрәннәр, сарыклар кычкырганы гына ишетелә иде...

*1982—1985.*

# ШИГЪРИЯТ

## Шамил Маннап

## САБЫРЛЫК

### «Ахырзаман»

«Ахырзаман җиткәндә, бер
өскә чыгар хаклык, иман».—
Борынгылар әйткән бу сүз,
ахры, чыннан дөрес булган? —
Күңелебез ишеген ачты
Тукайлардан калган азан:
бәйрәм алып килде безгә
унбер гасырлык рамазан!

Манарасыз мәчетләрнең
нигезе корый, дигәндә,
имансыз вә кыйбласызлар
хакыйкатькә төкергәндә,
«Ана — улны, ата — кызны
белми башлаган» бер мәлдә,
нәселен, динен, милләтен
онытып барганда бәндә;

Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ, ашап җирне,
безгә үлем түшәгәндә,
Җир-суыбыз, һавабызны
агулап, нәҗесләгәндә,
газиз дәвамчыларыбыз
ияргәндә Газазилгә...—
Нур сипте изге рамазан,
сабырлыклар теләп илгә.

Сур мөгезен өрделәрме? —
Ишетелә моңлы азан!
Рух-җан кирә адәмнәргә,—
изге вә мәрхәмәтле җан!

Йөзебез бордык кыйблага,—
чыксын өскә хаклык, иман.
Иман булганда, иншалла,
килмәс Җиргә ахырзаман...

### Дөнья бу!

*(Тукайга ияреп)*

Культ вә торгынлык авыруын кичергән дөнья бу,
Ниһаять, яңарыш җилләрен истергән дөнья бу!

Күп ашап яткач, талагач халыкның йөрәк маен,
Хәтта ки, Чурбановларны костырган дөнья бу!

...Рухи ярлы яшьләрне һич тотар әмәл калмагач,
Фиркалене дингә сыеныр хәлгә төшергән дөнья бу!

---

Шамил МАННАП *(1938) — шагыйрь, «Тамырлар», «Тугрылык алиһәсе», «Кайту» һ. б. татар, рус телләрендә дөнья күргән дистәгә якын китап авторы. Проза әсәрләре дә яза. Казанда яши.*

...Аракыны «бетерсәк» тә, эчкечелек бетмәгәч,
Тагын бер чират арттырып, ким-хур иткән дөнья бу.

...Ары барып, бире килеп, юкны бушка аударган
Бәндәне эшләп ашарга мәҗбүр иткән дөнья бу.

Үзенә көн бетәчәген күргән бюрократны да:
«Мин яңарышларны яклыйм!» дип әйттергән дөнья бу.

Нинди анадан туганын оныткан манкортларны
«Ана телен белү ул — фарыз!» дидерткән дөнья бу.

Һай, боларны бер дә сүкмәс, бер дә рәнҗетмәс идем! —
Күпләребез яңарышны күктән көткән дөнья бу...

## Чишмә

Әтием тапкан чишмә
әйтте челтерәп: «Китмә!..»
Һәм мөлдерәп карап калды,
мин чыгып киттем читкә.

Кайттым. Чишмә челтерәми,—
(калгандыр сүзләре — күп...)
Томаланган,—
әтиемнең
йомылган күзләре күк...

## Манарасыз мәчет сөйли

Манарама элгән аем белән
Күңелләргә якты биргәнгә,
Мин халыкның юанычы идем,
Ышанычы — нурлы көннәргә.

Белмим, нигә миңа каныктылар? —
Манарамнан мәхрүм калдырып.
Хакыйкатьтә алар үзләренең
Кистеләр бит өмет тамырын.

Мин үпкәләп, эшсез утырмадым,—
Манарасыз-нисез булсам да,
Мәктәп, клуб, яки... амбар булып,
Игелек иттем барыбер инсанга.

Ул вакытта җан азыгы түгел,
Өстен иде тамак туклыгы.
Соңра сиздә бәндә
Үз күңелендә
Бик кирәк бер нурның юклыгын.

Сиздә бәндә кызып киткәнлеген,
Эзләгәндә хаклык кыйбласын.
Ачлы-туклы яшәп булганда да
Яшәп булмый изге нурларсыз.

Борчылмагыз,
Ай — үз мөнбәрендә!
(Манарам да кайтыр көн килер!)
...Нурларны соң өзеп буламыни —
Манараны кискән шикелле?!

## Сызгырабыз...

Хәтеремдә, бала вакытта без
Сызгыргалап куйган чакларны:
«Сызгырмагыз, давыл чыгарырсыз!» —
Дия иде авыл картлары.

Хәзер ничек кенә сызгырмыйлар:
Ракеталар оча сызгырып.
Артларыннан Җирнең күк күлмәге
Теткәләнеп кала, ертылып.

«Сынагыз, ут белән уйнагыз!» — дип,
Җир астында атом сызгыра.
Сызгырышып ага торбалардан
Химикатлар елга суына.

Чернобыльнең атом давылыннан
Сыкрап типкән чакта йөрәкләр,
Кемнәр ясый яңа куркынычны
Без яшәгән матур төбәктә?

...Әнә шулай сызгырабыз бүген,
Афәт-давыл чыгар, димибез.
«Сызгырмагыз!» — диеп картлар түгел,
Әйтә кебек газиз Җиребез.

«Сызгырмагыз,— ди ул,— шаярмагыз,—
Галәмдә юк минем тиңдәшем.
И кешеләр, бер көн гаҗизлектән
Сызгырырга туры килмәсен...»

## Җитми...

Кемнәргәдер алтын-көмеш,
сервиз җитми;
ә кемгәдер җан җылытыр
бер сүз җитми.

Кемнәргәдер оньк-олан,
ул-кыз җитми;
ә кемнәргәдер якты йөз...
йә тоз җитми.

Кемнәргәдер аракы йә
сыра җитми;
кемнәргәдер сугышырга
корал җитми.

Барлык та бар... Әмма нидер
һаман җитми,—
бераз җитми.

...Аяксыз яшь солдатларга
протез җитми...

## Шәһәрдә яшәп картайган авыл кешесенең васыяте

Туган якка еш булмады кайтып,
Табылмады һаман иркен вакыт.
Юлы ерак, күперләре ватык,—
Ял йортларын кулай күрдем инде.

Нигә генә табалмадым вакыт?!
Хәзер вакыт җитә, җитми саулык.
Иңнәремә басты авыр картлык,
Үкенергә генә калды инде.

Начар түгел, яшим болай ару,
Фатирымда тартма тулы дару,
Тик җирсүдән тими шифалары,
Хет асфальтка ятып ела инде.

Ярый әле дачага җир алдым,
Яшьрәк чакта өен салып калдым.
Шунда барып һаман казынамын,
Җир исләре җанга шифа инде.

Оныкларым туган телен белми,
Бабай дими миңа, дедуля ди.
Кем булырлар болар үскәч, димен,
Каберемне белсә ярый инде...

Акылы булган туган җирдән китми,
Яшь вакытта кешегә акыл җитми.
Васыятем шул: үлгәч, бу җисемемне
Авылыма җирләсәгез иде...

Күз күрмәгән якка адаланып,
Чыгып киткән идем бер көнне.
Шуннан бирле —
Ничек калса авылым,
Яшидер күк һаман шул көе.
Болынында — кыңгыраулы тайлар,
Урамында — яшел чирәмнәр.
Бергә уйнап үскән шук малайлар
Шулай калган — төшкә керәләр.
«Кайтырсың да танымассың диеп,
Үзгәрмәдек, диләр, син юкта.
Тик кайтмадың, ә без.. үсми калдык...—
Без ышанган идек син дуска...»
Әллә ничек моңсу тавышлары:
«Без ышанган идек син дуска...»
Кырда яшел килеш арышлары:
«Өлгералмый калдык син юкка...»

Өйләр һаман элеккечә сабыр:
«Без үзгәрдек... Тик син күрмәдең.
Сине озатып калган иске авыл
Кайтыр юлың озак күзләде...»

Бер юаныч булып, хыялымда
Исән килеш яши карт анам.
Моңсу тавышы тора колагымда:
«Син кайтмыйча, балам, үлалмам!..»

## Ә бу язлар безнең язлар түгел...

Иске яраларны яңартырга
Очрашулар нигә эзләргә?
Нинди мәгънә инде наз эзләүдән,
Яз эзләүдән суык күзләрдә?

Очрашсак та, нәүмиз булырбыз тик:
Мин дә бүтән, син дә бүтәндер.
Җанга якын яшьлек язларыбыз
Чит ярларга агып киткәндер.

Ә бу язлар безгә — назлар түгел,
Алып килә бары сырхаулар.
Иске яраларны кузгатырга,
Юк, эзләмик инде сылтаулар.

Узган белән көрешү мөмкин түгел,
Үргә акмас елга сулары.
Үкенә-үкенә искә алып кына,
Сагынып кына була узганны...

Узганнан тик кайта үкенечләр,
Белә моны тормыш кичкәннәр.
Үкенечләр кайта,
Үкенмәслек
Яшәсеннәр өчен бүтәннәр...

# Лена Шагыйрҗан

## Вакыт

Вакыт — алтын, диләр...
Вакыт — гомер,
үзең белән генә түләрлек
Мизгел белән Мәңгелекне үлчи
бер үк бизмән, бер үк берәмлек...

Вакыт — көтү, түзү, сабыр итү...
Вакыт — өмет, алга ышану.
Барга гына түгел, югына да
ышанырга һәр көн куша ул...

Вакыт белән түлим һәр дәвага,
вакыт белән түлим чынлыкка...
Вакыт кыры аша узган чакта
бер без генәмени чыныккан...

Вакыт — яңартырга, төзәтергә,
вакыт — яратырга, түзәргә...
Вакыт — язгы чәчәк бөреләрен
көзен алма итеп өзәргә...

Вакыт — сыналырга, сынмый калып,
вакыт — яшәү тәмен тоярга...
Вакыт — изге китап өйрәткәнчә,
«чәчкән ташларны да җыярга...»

Вакыт — өмет.  Вакыт — туу,  үлү...
Вакыт — көн дә тулып-бушану...
Барга гына түгел, югына да
ышанырга һәр көн куша ул...

*1987*

## Мәхәббәт һәм политика

Һай, сусадым мәхәббәткә...
Туйдым политикадан.
Мәхәббәт гыйлемен укып,
Булып «политик надан».

Яшисем килә, ачыгыз
Дәрелфөнүнегездә
Бер мәхәббәт факультеты —
Укып йөрербез без дә...

Политик укулар белән
Башлар әйләнгән иде,
Политик тукулар белән
Телләр бәйләнгән иде.

Мәхәббәт шигырьләрен дә
Куркып йөрдек укырга.
Өйрәттеләр кешеләрне
Мәхәббәттән куркырга.

---

Лена **ШАГЫЙРҖАН** *(Шакирҗанова) — шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Бишектән үк өркеп үстек
Политик аталардан:
Берүк, ходай саклый күрсен
Сәяси хаталардан!..

Хәер, сәяси тояклар
Шәп дагаланган безнең.
Сәяси чирләр, озаклап,
Шәп дәваланган безнең...

Политик көрәшләр үтеп,
Без корычтай чыныккан.
Безнең сәяси карашлар
«Сөрелгән бер чыбыктан...»

Белмисездер, без иң сизгер
Политик булып беттек.
Һәр ишектән, һәр ишектән
Политик шымчы көттек.

Чик йөрергә гыйшык тотып,
Мәхәббәттән олы без.
Тибә бездә сыйнфый йөрәк,
Сәясәтнең колы без...

Чын мәхәббәт эзләп йөрсәң,
Сабышырсың җүләргә.
Әйләнсәк — әйләник инде
Сәяси мәҗнүннәргә...

Зур йортларда укып йөрдек
Зур белем алган булып.
Мәхәббәттә калдык... хәтта
Политик надан булып...

*1990*

## Язмыш җыры

Кеше язмышлары туп түгел лә —
Бер уйныйлар тибеп, бер — чөеп...
Сорашсалар кайчак, нихәл, диеп,
Ярый, дигән булам, бер көе...

...Язмыш җырын соң бер көйгә генә
Була микән җырлап бетереп...
Текә ярдан язмыш ташкынына
Ташландым мин — алды бөтереп...

Язмыш җыры — мең дә бер көй икән,
Сыймый икән әле аңа да...
Искерми дә үзе, туйдырмый да,
Яңарганнан бара яңара...

Сәхнәләргә сыймый язмыш җыры,
Сыймый икән авыл-каръяга...
Калаларга сыймый, белмим инде,
Сыяр микән диңгез-дәрьяга...

Язмыш җыры — җилләр ирегендә...
Җилнең хәлен үзең бел инде...
Җырлый-җырлый беркөн ела үксеп,
Җырлый-җырлый беркөн көл инде.

Язмыш җыры белән җыр язмышы
Икесе ике нәрсә, күрәсең...
Язмыш сүзләренә көй табасың,
Язмыш көенә сүзләр үрәсең...

Язмыш җыры — ата-бабаң җыры,
Язмыш җыры — нәсел-тамырдан.
Калыйм дисәң җырда үзең булып,
Үз көнеңә килә авырга...

Язмыш җирәбәсен салышканда,
Ялгышыпмы, мин җыр «отканмын»...
Ул җырны мин гүя яттан беләм,
Кайдан ишетеп, кемнән отканмын?

Тәңре язган — без укыйбыз гына,
Тәкъдир белән инде ярышмыйм...
Ядкарь булып калсын җирдә моңым
Язмышлардан узып барышлый...

*1990*

## Бер канатым ак, бер канатым кара...

Аерылып җирдән,
Әверелеп кошка,
Без китәсе бер көн —
Тәңре шулай кушкан.
Соңгы очыш безнең
Булыр йолдызара —
Бер канатым ак,
Бер канатым кара...

Бәргәләнеп очам
Чиксезлеккә таба,
Өмет җемелдәгән
Йолдызларга карап,
Очам язмыш белән
Хөкем арасында:
Ак канатым — оҗмах,
Гәмугъ — карасында...

Галәм дингезендә
Мин бер кече кораб.
Бетмәсәң дә Җирдә
Күпләренә ярап,
Озатып калыр дөнья
Күкләренә карап:
— Бер канаты ак,
Бер канаты кара...

Мин җәяүле идем,
Ук-җәяле идем,
Ут-ядрәләр алмас
Сүзләр барын белдем.
Соңгы җырым — дуска
Соңгы сәлам булыр,
Соңгы дошманыма
Сөңгем — каләм булыр...

Кала болганышлар,
Кала кылган эшләр
Галәм утравында —
Җирнең күкрәгендә.

Без кайтырбыз кабат
Җир күзенә карап,
Яшен яшьнәвендә,
Күкләр күкрәвендә...

Яшәешнең бөек
Ике серле көчен,
Җан-көрәшкә шаһит
Ике төрле төсен,
Гыйбрәт итеп, мәңге
Саклап барыр өчен —
Бер канатым ак,
Бер канатым кара...

Таңнар атып килә,
Төннәр үтеп бара
Тик йөрәктә яна
Җәрәхәт тә яра...
Соңгы очыш безнең
Булыр йолдызара:
Бер канатым ак,
Бер канатым кара...

*1990*

## Бәйрәмнәре безнең урамның

Чәчләремә гөлләр кададым,
Иңнәремә шәлләр урадым,
Күрми калмас әле кешеләр
Бәйрәмнәрен безнең урамның.
Булмасын дип өе караңгы,
Тәрәзәмнән кояш карады.
Гөзәтергә ул да ярады
Күңел төбендәге яраны...
Гади генә чыпчык сайрады —
Баласына булсын савабы.
Ә без асыл кошлар сайладык...
Шушы икән тормыш сабагы.
Ак эскәтер җәйдем өстәлгә,
Табын әзерләдем, шикләнеп:
Килми калмас, бәлки, берәрсе,
Утырмыйм ич качып, бикләнеп.
Ялгызлыкка яшим мин күнеп,
Салышуым түгел изгегә —
Карасам да бераз үкенеп,
Үпкәләмим инде көзгемә.
Җиңнәремә түктем яшемне,
Яшермичә барсын сөйләдем.
Минме соң ул янып көймәдем дә
Минме соң ул шашып сөймәдем?
Узды язлар, җәйләр авышты,
Гүй күлмәгем калды кимичә.
Үтте еллар, юмарт яшьлекнең
Хәләл өлешләре тимичә.
Җәйләремдә кышка сусадым,
Көзләремдә язлар эзләдем.
Кирәк кадәрен дә язмыштан
Сорамадым шунда тезләнеп.
Ә шулай да кызык яшәдем.
Үткән гомер әрәм түгел лә...
Шау-гөр килеп торган мәҗлесләр,
Туйлар гына бәйрәм түгел лә...
Хисләр ташый, хисләр түгелә,
Җырларымны дәшәм түремә.
Менә-менә менеп җитәм күк
Хыялымның зәңгәр үренә...
Тәрәзәмне ачтым киереп,
Ярсу җилләр, әйдә, керегез!
Минем белән бергә биегез,
Сиреньнәрне ләкин сөегез!..
Әнә, ишегемә кагылды,
Кемдер килгән мине сагынып.
Бик вакытлы әле йөрүе,
Суынса да күптән табыным...
Җырларыма дуслар кушылды,
Кунагыма кунак өстәлде.
Утырыштык гадәттәгечә,
Кыл уртага куеп өстәлне.
Сүз күп булды. Нокта шушында...
Бер җыр җырлыйм, әгәр яраса...
Бәйрәмнәре безнең урамның
Шаулап тора икән ләбаса...

*1980*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Нәбирә Гыйматдинова

# СИХЕРЧЕ

ПОВЕСТЬ

1



Нәзер дигән бу елга кая таба ага, Тәминдар? Ишетәсеңме, сиңа эндәшәм, Тәминдар! Аның кайчан булса да бер туктап ял иткән чагын хәтерлисеңме?

Агымсулар туктамый шул, Тәминдар. Яшьле күзләрен болытларга төбәп ага да ага...

Бүген хатының зәңгәр шакмаклы күлмәгеңне юып кер бавына элгән иде, ә мин тоттым да урладым аны! Карак түгел мин, ачуланма, Тәминдар. Ачуланма, зинһар. Сырхауның кигән киемен суларга салып агызсаң, тәненнән чир китә, ди. «Безнеке бетмәс бер чир белән җәфалана»,— диде бит Мәликә апа. Нинди чир ул? Синдәме, Тәминдар? Ярар, ярар, әйтмә, яшер. Тик Нәзердән яшермә... Ул сер саклар; михнәт чигүләреңне юып алып, ерак-еракларга илтеп ташлар...»

Бер күмелеп, бер калкып йөзгән күлмәкне күздән җуймас өчен, кыз яр буйлап йөгерде. Балтырын корыган тигәнәк сыдырды, аяк табанын кычыткан өтте, ул авырту тоймады, хәлдән таеп, елый-елый йөгерде дә йөгерде. Су агымы көчле иде, аның белән ярышу мөмкин түгел; җитмәсә, алда — елганың текә борылыш ясаган җире.

Кыз кире борылды. Күз яшьләрен сөртте. Йөгереп барган шәпкә искәрмәгән икән: камышлык янында, малайлардан качып, кыз-кыркын су коена иде. Яшьтәшләрен күргәч, аңа тагын да ямансу булып китте. Ул аларның туктаусыз чыркылдашуын, ул да түгел, шүрәле кытыклаган сыман, дәррәү шаркылдап көлүен ничектер аңламады, дөресрәге, аңларга теләмәде. Көтү-көтү булып, оешып йөрүнең ни кызыгы бар икән? Бер төсле көлеп, бер төсле шаярып, бер төсле уйнап ничек яшәмәк кирәк! Алай дисәң, туганда ук кешеләрнең барысы да бер төсле елый, көлә... Ләкин бу уртак уй-гамь белән генә яшәргә дигән сүз түгел бит әле. Мөгаен, кешеләр ялгыз калып тереклек итәргә иренәдер. Әйе-әйе, кешеләр уй уйлап яшәүдән курка, шуңа төркемгә елыша. Аның өчен бүтәннәр уйласын янәсе. Ә көчле шәхес һәрвакыт аерым яши. Мәгарәдәге акыл иясе кебек... Сәвилә төркем тормышын яратмый, ят

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) — *язучы, «Су хикаяте», «Бердәнберем» һәм башка китаплар авторы, Казанда яши.*

ул аңа, чит. Мәктәптә дә күп изелде инде. Әле тагын ике ел изеләчәкләр. Кырык баланы шыплап бер бүлмәгә тутыралар, бер үк сүзләрне ятлаталар, бер үк мәсьәлә чиштерәләр. Туйды Сәвилә уртак нәрсәләрдән, гарык булды. Ичмасам, каникулда үзеңчә кыланасы иде...

Кинәт кемдер әче тавыш белән кычкырды:

— Убыр килә, качыгыз!

Кызлар, судан чыгып, киемнәренә ябырылды. Яр өсте «ә» дигәнче бушап калды, су коенучылар камышлыкка кереп посты. Кара, нинди тынлык! Дулкыннар гына уйнаклап чупырдый. Кайда икән бу Убыр? Кызык, кыяфәтен күрәсе иде шуның. «Убыр, Убыр»,— дип күпме сөйлиләр авылда, ә Сәвиләнең аны бер дә очратканы юк әле. Кыз, әсәренеп, уңга-сулга карады. Һәм чак кына егылып китмәде, тотынырга теләгәндәй, кулы белән бушлыкны капшап алды: аның каршысында яртылаш җиргә иелгән бөкре карчык басып тора иде! Абау! Бигрәк котсыз бәндә! Төнлә төшеңә керсә, акылдан язарсың, билләһи! Нигә күзен очландырып карый ул Сәвиләгә? Үзе явыз убырга да охшамаган икән, арттырып сөйләгәннәр, күпертеп. Әлбәттә, ак яулыклы авыл әбиләренә дә охшамаган ул: әллә нинди җан иясе шунда, төгәл генә аеруы да кыен, яшен сугып корыткан агач төсле, кара һәм куркыныч зат. Әнә калтырана башлады. Ныграк җил иссә, гәүдәсе кисәкләргә таркалыр сыман... Йә, ни кирәк сиңа, Убыр, үтеп кит...

Кыз, юл биреп, читкә тайпылды. Табаны белән җиргә кадаклангансы әллә, нишләп кузгалмый бу карчык? Нишләп, яшел күзләре белән һаман Сәвиләне бораулый?

— Син Убыр димә, олан. Син алар сыңары тегелдер,— «алар» дигәч, карчык авыл ягына ишарәләп күрсәтте.

— Мин алай әйтмәдем ич! — диде Сәвилә, карчыкның сөйләшүенә сәерсенеп. «Теле черегән, авызы куыш, дигәннәр иде ләбаса!»

— Телең ауыз эчендә, кыймылдамыйдыр да, күңелең сүлидер. Җә, күреш, олан.

— Синең беләнме, уб... әбекәй?!

— Төкеренмә,— диде карчык.— Адәмнең барчасы лач-лоч төкерсә, җир битендә нә чисталык калыр. Җә, күрешик.

Карчыкның салкын бармагына кулын тидергәч, тәненә чиркангыч дулкын таралса да, Сәвилә сискәнмәде, киресенчә, камышлыкка качкан кызларга горур караш ташлап:

— Мин синнән тамчы да курыкмыйм, әбекәй,— диде.

— Нәмә сиңа куркырга,— диде карчык һәм сөякчел бармагын кызның ак беләгенә батырды.— Гаиптән хәбәр инде, олан. Бу — мин, ходайның рәхмәте, тач мин, минем шәүләмдер... Без, җаныбызны икегә бүлеп җөрибездер. Беребезгә җомылырга уакыт, мәңгелеккә күчеп җомылырга, беребезгә — арык, карт гәүдәлесенә.

Сәвилә өнсез иде. Нинди гаип, нинди хәбәр? Беләген күр инде: кара янып чыкты. Шул төшкә карчык янә орынган иде, әз бетте.

— Алла кодрәте илә җанымның икенче яртысы пәйда булмыш,— диде карчык пышылдап.— Тәмуг казаннарында кайнаган бар тылсымым бу ак тәнгә күчәр... Гыйлемем дә, боерса, күчәр. Ут аша тапшырырмын, иншалла...

Нинди тәмуг казаны? Нинди ут? Саташа бугай бөкре карчык!

Кызның башы җиңелчә генә әйләнде, яр буе чайкалып китте... Карчык аның беләгеннән сыпыра-сыпыра пышылдаган саен, тән ойыйми күзәнәкләренә сәер дулкын агыла иде. Ул инде аягүрә басып йоклый, моны үзе дә тоя, тик әлеге сәер көчкә каршы тора алмый. Үзенең ни эшләгәнен читтән күрә кебек: менә тез буыннары йомшарып җиргә чүкте, маңгае белән комга төртелде, борын тишегенә ком бөртекләре тулды... Татлы, рәхәт изрәү иде бу. Ләкин тән сорап алган табигый, тансык йокы түгел.

— Син — мин, мин — син,— диде карчык.

Чуен кебек авырайган башын күтәргәндә янында карчык юк иде

инде. Сәер һәм серле әби! Нишләтте ул Сәвиләне? Нигә йоклатып калдырды? Әллә сихерләде микән? Йә алла, әфсенләп боздырса?! Булмаганны! Ул бит чүп-чар өемендә актарынып пычрак ашап йөрүче карчык кына, исеме дә Убыр ич! Әнә, Сәвиләнең апасы юынтык суны ишегалдына түктерми, убыр ияләшер, ди.

Сәвиләләр үткән елда гына килеп төпләнгән бу авылда соңгы убыр калдыгы яши, имеш. Әйдә яшәсен. Аның кемгә зыяны тигән! Кешеләр әкият уйлап табалар да, аннан шул уйдырманы чын дип, хыялланып, шикләнеп йөриләр.

Ләкин баягы хәл әкияттән ерак иде. Карчыкның пышылдап йоклатуы хак иде. Гел «ут» диде ул. Әйтерсең йөрәкне ут элде шулчак, аяк-куллар кайнарлана башлады. Әле дә Сәвиләнең тәне чамасыз кайнар иде. Нәзердә коенгач кына суына төште.

Өйгә кайткач, апасыннан төпченде:

— Апа, Убыр яши икән бу авылда, син аны күрдеңме?

— Шөкер, юк,— диде апасы.— Бик карт диләр аны, дөнья белән алыш-биреше беткән, диләр. Көндез урамга да чыкмый, диләр. Очраса, зәхмәте суга икән. Син гел урамда буталасың, күрсәң-нитсәң, берүк әйләнеп уз, якын килмә.

— Нигә, апа?

— Зәхмәте суга дим, чукрак!

— Көлдермә, апа.

— Сез, яшьләр, пычагым да белмисез,— дип ачуланды апасы, бәхәсләшкәнне яратмады. Ул Сәвиләне бервакытта да хаклы санамый иде.

Кыз артыгын сорашмады. Аның үз уе уй иде. Ул яр буендагы очрашуны кат-кат хәтер иләгендә иләде, карчыкның сүзләрен берәм-берәм барлап чыкты, алардан бер-бер киная эзләде. Төне саташып, бәргәләнеп узды.

Таң атмаган иде әле, кызның күңелендә сәер теләк уянды: Нәзернең сул як ярында ташландык чишмә бар иде, менә шул чишмә аны үзенә чакыра! Нәкъ җанлы кебек, колак төбендә челтер-челтер тавыш чыгарып чакыра. Аның суы хәрәм саналганын, Убыр чишмәсе икәнен белеп тә барасы, иелеп салкын суын эчәсе килә!

Ул юрганын башыннан ук бөркәнеп ятты, ишетелмәсен дип, колагын томалады, әмма чишмә чылтыравы тынмады... Сәвилә түзмәде, юрганын атып бәреп, урамга ыргылды.

Таш белән бастырылган чишмә янында юлаучы бер әби утыра иде. Якынрак килгәч, кыз адымын әкренәйтте. Бәрәч! Кичәге карчык! Ләкин ул инде өсте-башы тузган, шөкәтсез Убыр түгел, гап-гади авыл әбие иде! Ак яулыгын башына чөеп бәйләгән, ап-ак күлмәк кигән, ә үзе яланаяк.

Карчык оеп утыра иде, Сәвилә килгәч тә селкенмәде.

— Гумер капкасын шакылдатып ардым, үзкисәгем,— диде ул, кызга карамыйча гына.— Таш та тоталмый буынсыз бармаклар, картлык галәмәтедер. Сине уяттым, үзкисәгем... Чистарт Изгеләр чишмәсен, олан, савабы зурдыр чишмә карауның. Ыргыт монау ташларны читкә. Тар зиндан эчендә нә газап чигәдер, бахыркай. Илаһым аяк-куллары корысын бәдбәхетләрнең!

— Кемне каргыйсың, әби?

— Адәм баласын, үзкисәгем. Өстенә таш бәрә анау. Нә гөнаһысын тапкан! Элгәре аның аты Изгеләр чишмәсе иде.

— Убыр чишмәсе түгелмени, әби?!

— Җир-сулар — ходайныкы, үзкисәгем. Ходай, җәннәтеннән бүлеп, җир өстенә изге суын агызган. Адәм шуны кулы белән быкырдатадыр. Минем бу чишмәне тәрбия кылуым күңеленә җарамый адәмнең, ул «Убыр чишмәсе», дип тәхкыйрьли. Җә, олан, селкен. Агач та селкенеп үсәдер.

— Хәзер, әби, хәзер!

«Хәзер» дип бик тиз генә эш башлаган кызның, авыр-авыр таш-

ларны яр астына тәгәрәтә-тәгәрәтә, беләкләре талды. Чак кына тын аласы иде, билне турайтып баскан килеш кенә.

Ә карчык, дөньясын онытып, чишмә белән сөйләшә иде.

— Әби, ул сине аңлыймыни?

— Аңышмаса җавап бирмәс иде, үзкисәгем. Дикъкать берлә тыңласаңчы...

Сәвилә колак салды. Каядыр төптә, җиде кат җир астында, якында гына да кебек, су тавышы ишетелә. Тавыш йә челтерәү, йә ярсу шарлавык белән чиратлашкач, тынып кала...

— Урман-сулар, күк-җирләр, киек кошлар, киек җанварлар теленең житмеш җиде серен ходай сиңа да ирештерер, боерса, үзкисәгем,— дип дәвам итте карчык.— Якты дөнҗада дистә дә дүрт кенә җыл гумер чигүеңдер, пырдымсызланмасаң вә күңел саутың сабырлык илә тулмыш булса, йәнә дә ходай жаныңа могҗиза капкасының туксан бер ачкычын бирер. Нә яман сизәрсең, ачмаска диптер карышырсың — ачтырырлар. Нә сөенеч бар диптер, куанып ачкычыңны борырсың, куаныч илә куандырырсың адәмне, иллә аның мәнсезе тиз онытыр изгелегеңне. Синең кылмышың кайберәүсенең күңеленә хуш җатмас, андые тәшәккер итү урынына сүз берлә маңгаеңа орыр. Сүзе таш күек каты тияр. Бәндә яман, бәндә бозык, бәндә азгын, үзкисәгем! Аның кулына яуыз көчләр кара таяк тоттырган. Дөнҗаны шул таяк илә болгатмыштыр бәндә...

Карчыкның тавышы шомлы иде. Сәвилә, аңа карагач, имәнеп китте: карчыкның күзләре ямьсез, күз агы зураеп, карашын ак томан сарган иде... Ул куркуын җиңеп сорады:

— Кешеләр нишләп бозылды, әби? — диде.

— Иман кыйбласын җуйды адәм, үзкисәгем. Хак юлдан читкә тайпылды, хәрәм ризык ашады. Шәйхеләхмәт өммәтләре җазуына төкерде. Шәйхеләхмәт мөфти васыятендә болай дир: «Кыямәт алды Җәбраил фирештәмез җир йөзенә ун кат иңәрмен диган. Тәү иңгәндә — бәрәкәтне алырмын, ике кат иңгәндә — шәфкатьне, өч кат иңгәндә — хәятне, дүрт кат иңгәндә — байларның байлыгын, биш кат иңгәндә — галимнәрнең галимлеген, алты кат иңгәндә — кыз-хатыннарның гыйффәтлеген, җиде кат иңгәндә — авыз ләззәтен, сигез кат иңгәндә — тәүбәне, тугыз кат иңгәндә — тәйбә капугын, ун кат иңгәндә Коръәнне алырмын»,— дир. Җәбраил сигез кат иңде, ике иңәсе калды... Васыятьне күчереп таратырга өндәгән Шәйхеләхмәт, тәйбә капугы бикләнгәнче тәүбә кылырга кушкан. Кыямәт кубасы ласа, ахырзаман җитәсе. Бак, адәм ашлыкмыйдыр, һаман начар уйдадыр. Гөнаһсыз чишмәне кем рәнҗетте димсең? Ул, ул, ул! Чат саен тимер кое казытты да, суга туенды. Тимер коеның тимере бәгыренә юшкын булыплар утырды. Нәгъләт орсын!

Карчыкның һәммә сүзен дә аңлап бетермәде Сәвилә, кешеләрне каргарга тотынгач кына инәлеп ялварды:

— Каргама, әби, җитәр! Синең шаукымың да тия, диләр. Әнә Фатыйма апа яныннан узып кына киткәнсең, ул ишек төбендә егылып үлгән.

— Патыйма атлы катын көнчелектән җан тәслим кылды, олан,— дип төзәтте бөкре.— Гумер күршесенең мал-мөлкәтеннән көнләде. Көнчелек, олан, бауырны ашый. Бауыры челтәрләнгән ие Патыйманың...

Монысы Сәвиләгә көлке тоелды:

— Эчен ярып карадыңмыни, әби?

Карчык аны ишетмәде:

— Алар — нәселләре берлә алла каргаган гуҗ нәсел,— диде.— Анасы Маһинур комсыз бичә ие. Кабер ишеп бәрәңге чүпләгән катыннан нә көтәсең? Ходай шаһит, җалганнасам — чәчрәп китим, ходай шаһит хикәятемә, ачлык җылны бер урыс карты аулалар буйлап хәер

сорашып җөрде. Бә-әк сәләмә киемнән ие, аркасына аскан җәнчеге дә кырык ямаулы, җәлләгәне бәрәңге бирде шуңар, бае бушкул борып чыгарды. Биш бәрәңге җыйгандыр урыс, артыгы тәтемәгәндер. Аның да насыйп тегел пешерергә, мескен, аулны чыккач, читән коймага сөяләп бафат булмыштыр. Тоттылар да киеме-ние, теләнгән ризыгы илә җул кырыена җирләделәр. И-и, язын чыкты кабере өстенә бәрәңге тишелеп! Аллы-гөлле чәчәк атты, ходай! Нә кызыккан бала-чага тимәде чәчкәсенә, чирканды. Патыйма анасы көзге кара төндә казыплар алды бәрәңгене. «Чуплеккә түк, хәләл ризык тегел, бирән чире йогар», — дидем үзенә. Тыңламады, гуҗ чиреннән үлде Маһинур. Балаларына әйтеп үлде: «Анау убыр калдыгы мине боздырып гүргә тыкты, илләрендә рәхәт йәшәтмәгез», — дип. Ул нәсел — үчле-тешле нәсел, гелән минем белән булашты, ил-көнгә яманатым таратты, гаепсез башкаема гаеп такты — түздем, йортыма ут салды — түздем, инде дә кара йөрәкле нәселнең бер тамыры — Галимҗан түрә, чишмә суларын күмдереп, урман-болынны издереп, тимер атлар илә җирнең тамыр-куәтен өздереп башбаштак кылырга керешкәч, сабырлыгым ташыды, бу нәселгә каргыш җулладым. Тәүмәлдән иясен табар, боерса...

Иясен табар диме? Сәвиләнең йөрәген берьюлы йөз энә чәнечте. Тәминдар да Галимҗаннар нәселе белән туганлашкан лабаса! Ул — Галимҗан кияве! Әгәр бу карчыкның каргышы ялгыш аның башына да төшсә?!

— Әби дим, ал каргышыңны, кире ал...

Еларга җитешкән кызның ялваруына карчыкның исе китмәде. Күк йөзенә кәкре бармагы белән төртеп:

— Ул ерак, җидегән җылдыз чатында,— диде.— Ул таш күек укмашкандыр...

— Синң үзең дә явыз бит! — дип кычкырды Сәвилә.

— Һә! — дип, көлүгә охшаш аваз чыгарды карчык.— Былчыранган җир-суларым хакына Аллаһ тәгаләдән җәза сорауның нә гаебе? Кылган гөнаһсына карап, һәр адәм заты җәзага тарса, дөнҗаның төсе уңмас ие. Төс саклар ие дөнҗа. Үләне — җәшел, суы — көмеш, җылдызы нурлы булмыштыр ие.

— Ул каһәр ташның бер гаепсез кеше башын тишүе дә мөмкин бит, әби?!

«Алайса Тәминдар исән кала! Тәминда-а-ар! Син — яшисең. Йөз ел, мең ел яшисең!»

— Чү, олан, әкрен, чишмәне өркетәсең.

— Мин кычкырмыйм лабаса, әби!

— Күңелең шәрран җара.

— Син, әби, минем уйларыма хәтле сизеп-күреп торасың. Син Убыр түгел, син — могҗиза!

— Минем кушамат синдә кабатланмас, үзкисәгем. Җан кабатланыр, кушамат җуелыр. Сине икенчеләй атап йөртерләр...

Тагын «син — мин»! Нишләп әле бу карчык язмышын Сәвилә кабатларга тиеш?! Һәркемнең үз язмышы түгелмени?! Әйбәтләп аңлат, дип үтенсәң, йоклатып китәргә дә күп сорамас ул. Әнә, бар күзәнәкләрне йомшартып, тәннән ниндидер исерткеч дулкын йөгерә... Кыз урыныннан кузгалып китә алмый... гәүдәсенең ярты өлеше карчыкка берегеп үскән төсле. Шунысы гаҗәп: карчык янында рәхәт тә, куркыныч та. Бөкре карчык, томан сарган караш, бәддога, каргыш, күкне айкап очкан һәм көннәрдән бер көнне Галимҗан нәселенә төшәчәк таш... Чәчләрең үрә торыр! Мондый куркыныч халәтне Сәвиләнең моңарчы кичергәне юк иде.

— Әби, йоклатма мине...

— Сыныймдыр, үзкисәгем, сыныймдыр...

— Нигә, әби?

— Сыналсаң — сынып калырсың. Имгәктән нә файда?

Сәвилә гарьләнде. Сыный, имеш! «Үзкисәгем» дип сөйләнә тагын! Кисәгең, чуртым! Менә сыналмый гына торсын әле!

Ул ачу-гайрәт белән ташларны читкә томырды. Ару онытылды, көч артты. Чишмә дәртләнеп өскә ургылгач, иманга өеган карчык та кымшанды, яратып, үз итеп, Сәвиләгә эндәште:

— Үзкисәгем, эчең-тышың каты микән дип, өч сынамыш уздырмак ием, ике сынау биреп туктыймдыр, калганын дөнья сынар. Инде дә бире кил, тизлән Изгеләр чишмәсе алдына.— Ул, бисмилласын укып, чишмә суында кулын чайкады да Сәвиләнең битен сыпырды.— Йөзең тулган ай күек нурлы булсын, олан. Иманлы йөз берлә кояшка бак, күккә бак, җиргә бак, аккан суларга бак. Син баккан дәвердә олуг хәяттә — җәм, җир-туфракта — бәрәкәт, күл-елгаларда тәм артсын. Амин!

Карчыкның кипшенгән имән кайрысына охшаш йөзе яктырып, күзләрендәге ак томан эрегән иде, ул итәкләрен җыеп торып басты, бу тамашадан айнып өлгермәгән кызның башыннан сыйпады, аннан:

— Адәм аяклары тынгач, төннә кил,— диде дә җил-җил атлап китеп барды. Ул шул хәтле тиз атлады ки, хәтта ерактан бөкресе тураеп күренде.

Сәвилә, иелеп, чишмә суы белән янә битен чылатты. Шулчак, авырттырып, аның кабыргасына төрттеләр. Аны кызлар уратып алган иде.

— Без, җиләккә барышлый, таллыкка посып карап тордык, син Убыр чишмәсен ачтың,— диде Сәвиләнең классташы Кәримә.

— Әйе, ачтың,— дип җөпләде кызлар.

— Сине Убыр үз кубызында биетә, тилебәрән! — Кәримә аяк астында аунаган ташны чишмәгә тибеп төшерде.— Тыңлама аны! Без чишмәне кире томалыйбыз!

— Нишлисез, кызлар! Изгеләр чишмәсен күмәсезме?!

Аны берәү дә тыңламады, ишетмәде, кемдер кәлә-кәлә этеп екты. Сәвилә җайсыз егылды, маңгае белән ташка бәрелде...

Күзен ачканда чигәсеннән саркыган кан колак төбенә укмашып каткан иде. Ул авырту тоймады. Авыртудан битәр, җанын әрнү телде. Чишмәне тәки күмгәннәр, явызлар! Изгеләр чишмәсен! Ә үзләре качканнар. Кәримә котырткан. Кәримә — Галимҗан оныгы. Теге алагаем рәнҗеш ташы аның башына төшмәгәе әле. Куркаклар, мескеннәр. Карчыкның үчен чишмәдән аласыз. Сәвилә барыбер коткарачак изге суны, үрмәләп булса да, ташларны каерып атачак...

Сәвилә кайтып кергәндә уртак ишегалдында мәхшәр купкан иде. Сул якта — Тәминдарлар, уң якта Сәвиләләр йорты. Уртада — ун ат биетерлек кыр хәтле ишегалды. Ничектер уртага койма ясап, икегә бүленергә Тәминдарның вакыты да, теләге дә юк.

Тәминдар янып-пешеп утын яра, ә Сәвиләнең апасы белән Мәликә кара сыерны абзар ишегенә таба кысрыклап маташалар. Икесенең дә кулында таяк, хайван башын читкә борды исә, сыртына китереп сугалар, бигрәк тә Мәликә нык тырыша, шап та шоп сыерның аркасын каезлый.

Кыз, йөгереп барып, Мәликәнең таягына ябышты.

— Муенын сындырасың ич, Мәликә апа! Кеше сыеры дигәч тә!

Хатыннар тәмам ярсыган иде.

— Ә-ә, биләмче, эт куучы! — дип апасы аңа ябырылды.— Кайда йөрдең таңнан бирле?! Сыерны абзардан чыгарма, бакчадан чүп үләне йолкып алдына сал дидемме, юкмы?

Аңа тәмам бүртенгән Мәликә дә кушылды:

— Трай тибә ул күсәк башы белән, Сәрвәр апа! — дип, Сәвиләгә таба атлады.— Әнә, сыерыгыз Тәминдарның юып элгән күлмәген ашаган. Өр-яңа иде, бүген туйга кияр дигән идем. Туйга чакырулы без.

— Бозаулагач, иткә тапшырам. Чүпрәк чәйни торган гадәте бар иде, һаман шул гадәтен куа, мәхлук хәйван,— диде апасы.

— Әнә теге булдыксызның миен бораулырга кирәк,— дип, Тәминдарга төртеп күрсәтте Мәликә.— Койма ясамады инде, тилмертте. Калхуз двуры кебек яшибез, адәм көлкесе. Тавык-чебеш бергә, гел тамга да салып бетерә алмыйсың. Син үпкәләмә, Сәрвәр апа, Тәминдарга ачуым килеп әйтәм, һәркемнең үз тормышы сана! Бүленәсе дә куясы инде!

Шулчак кемдер урамнан кычкырды:

— Кибеткә сабын китерделәр!

Ике хатын, сыер һәм койманы онытып, кибеткә йөгерде...

Сәвилә, борылып, Тәминдарга эндәште.

— Исәнме, Тәминдар?!

Укытучы, балтасын түмгәккә чабып, утын өеменә утырды:

— Исәнме, исәнме! Нинди Тәминдар ул?! Тәминдар абый дип әйт. Мин синнән олырак түгелме соң?

— Белмим, яшеңне санамадым. Мин дә борынгы бит, Тәминдар. Күптән яшим мин җирдә, дөнья яралганнан бирле...

Тәминдар рәхәтләнеп көлде:

— Һәй, хыялый! Мин институтта укып авылга кайтканда сиңа ун яшь тә тулмаган иде.

— Син туганчы, мин җиһанда бар идем, Тәминдар...

— Сәер кыз син. Уйнап сөйлисеңме, уйлапмы — укытучы башым белән аералмыйм. Иртәгә мәктәп бакчасында җәйге практикаң башлана. Зинһар өчен, әллә ниткән сәбәпләр табып, бармыйча калма.

— Тәминдар...

— Әү!

— Мәликә апага әйт, безнең сыерны бүтән кыйнамасын. Синең күлмәкне мин суга салып агыздым...

— Ә? Нәрсә?!

— Балтаңны куй, Тәминдар. Ялгыш аягыңа чабарсың,— диде кыз, ирнең агарган чыраен күреп.

— Ә? Күлмәкне нишләттем дисең әле? — Укытучы, балтасын ташлап, Сәвиләгә текәлде.

— Нәзергә агыздым, Тәминдар.

— Тфү, Тәминдар да Тәминдар! Абый дисәң телең чериме әллә?

— Ачуланма, сиңа усал булу килешми.

— Йәле, йә, җаваптан качма! Нигә алай эшләдең? Бүген күлмәкне, иртәгә чалбарны, берсекөнгә тунны илтеп агызырсың. Шыр-ялангач калдырырсың син мине, сәер кыз!

— Берәр киемеңне агымсуга салсаң, чирең китә, ди...

— Кемнең чире?

— Синеке, Тәминдар...

— Каян уйлап таптың мондый ахмак нәрсәләрне? Кем өйрәтте юк-бар ырымнарга? Мин сау-сәламәт! Күрәсеңме, эшләп ятам! — Тәминдар кызып китте.— Әүвәлгесе-актыккысы булсын урлашуларының!

— Мин урламадым, мин...

Юк, ул әйтә алмады. Мәликә апаның зарлануын үз колакларым белән ишеттем, дип әйтә алмады, күңеле йомшарып, тамагына утлы төер бөялде. Зарланды бит, чәчрәп китсен менә. «Чире узмас инде, шулай картаербыз, Сәрвәр апа»,— диде, елап та күрсәтте... Ә Тәминдар аңламый. Тәминдар Сәвиләне тирги.

— Ярар, узган эшкә салават,— диде ачуы басыла төшкән укытучы.— Мәликә апаңа ләм-мим. Сыерыңа тимәс, борчылма. Килештекме?

Килешкән кебек булдылар. Кыз каш астыннан гына Тәминдарның утын яруын карап торды. Моңарчы ничек искәрмәде икән, Тәминдар аюга охшаган лабаса! Килеш-килбәте, атлап йөрүләре нәкъ аюныкы!

Төннәрен ул карурманны сагынадыр, төш күреп саташып уянадыр. Китәргә дип талпынса, Мәликә җибәрмидер. Ә анда, аланда, дөнья рәхәте: берәү дә сине орышмый, берәү дә ишегалды бүләргә кушмый. Баш очында төпсез күк дәрьясы, дүрт ягында — дүрт офык, аяк астында куе яшел үлән... Җиргә ятып ауна, көл, ела.

— Тәминдар...

— Нәрсә бар?

— Синең тамырыңда аю каны ага.

— Әле һаман үчекләшеп торасыңмы? Сыерыңа үлән йолкып ашатыр идең.

— Кара сыерның сөте нигә ак, Тәминдар?

— Ала сыерның да сөте ак, кызыл сыерның да. Юкка башыңны ватма.

— Аның хикмәте бар: ак төс — дөнья яратылганда беренчел төс булган. Тикмәгә генә ак юл димиләр ич! Югыйсә, юл бит кара, тузанлы! Бәхет теләгәндә дә ак бәхет телим диләр. Хайван булып хайван да сөте белән баласына аклык күчерә. Бәлки нәсел дәвамы ак төстәдер?

Тәминдар эшеннән туктады. Сәвиләгә үзенең укытучы икәнлеген тагын бер мәртәбә исенә төшермәкче булдымы — дәрестәге кебек тураеп басты:

— Яшь дустым, соңгы вакытта мин сине гел күз уңында тотам. Бер кайгысыз көннәрең, әйеме? Бар, яшьтәшләрең белән су коен, җиләк җый. Йөрмә болай башыңны мәгънәсез сораулар белән тутырып. Син бөтен мәктәптә ялгыз, ни дустың, ни сердәшең юк. Үз дөньяңа бикләнмә, кызлар белән аралаш. Бүтәннәрдән аерылып читтә йөрү — ул бит үзеңне классташларыңа каршы кую дигән сүз! Йә, мин дөрес әйтәмме?

— Син ялгыш сөйлисең, Тәминдар. Бу — синең сүзләр түгел, бу — укытучы сүзләре. Мин үземне төркемгә каршы куймыйм, мин үземчә яшәргә телим. Ул кызлар янында эчем поша, күңелсез...

## 2

Төн якынлашты. Тәрәзәнең зур өлгесендә кара төс куерды. Күк йөзендә йолдызның әсәре дә юк. Күк — хиссез, уйсыз, күңел төсле буш. Ичмасам, бер йолдыз булса да чәчрәп кабынсын иде! Юлдаш булыр иде ул, карчыкның авыл читендәге өенә хәтле озата барыр иде.

Әллә Сәвиләнең җанын курку билиме? Бу караңгы төн һәм Убырның нәкъ шушы айсыз-йолдызсыз төндә чакыруы аның йөрәген калтыратамы?

Бераздан курку кимеде. Кызыксыну куркудан көчлерәк иде. Нигә төнлә чакырды аны Убыр? Беләсе иде бит... Инде кире чигенеп булмый. Бүген бармыйча калсаң, иртәгә соң булуы мөмкин.

Кыз абына-сөртенә урамнан атлады. Баягы курку әз-мәз генә йөрәкне дерелдәтеп алгалый иде. Этләре дә өрми бит, койрыкларын кысып йоклый. Ара-тирә өргәләп куйсалар, Сәвиләне ураган шом таралыр иде. Төн уртасында җен-пәри туй ясый, имеш. Беренче әтәчләр кычкырганчы бииләр, ди. Биесәләр ни! Ни пычагыма аларның туе! Әкият бу, чеп-чи әкият! Чын булса? Йә, чын булса? Ул туйга адашып кешеләр дә килеп эләгә, ди. Үзләре шуны сизми, ди, чөнки җен-пәри бәйрәмендә икәнлекләрен белмиләр, ди. Әнә, бер тол хатын янына узгынчы ир кунарга кергән. Төне буе назлап, иркәләп чыккан хатынны, мендәр астына уч тутырып көмеш йөзек, көмеш алкалар салган. Иртән, ир киткәч, хатын мендәрне күтәреп караса... акылдан язып, чәчәнә ябышкан ди. Теге көмешләр юк, ди, күгәргән калай кисәкләре генә ята ди.

Әллә бөкре карчык аны җен-пәри бәйрәменә чакырды микән? Әкиятләр дә чынбарлыктан туа лабаса. Кайчандыр шулай булган...

Әйе, булган. Дөнья әкият белән башланган. Аны җәннәт дип йөрткәннәр. Тора-бара бу җәннәткә кешеләр кереп тулган. Үзгәртәбез дип, алар җәннәт илен пыран-заран китерә башлаган: сандугач ояларын туздырган, чәчәген ботарлаган, чишмәсен корыткан... Җир-күкне тимер белән күмгән... Ул илнең хуҗалары кайсы кая качып беткәннәр, ахырда, илйортсыз калдырган адәм затларына үч итеп, җен-пәригә, убыр-шайтанга әверелгәннәр, ди. Һәм кешеләрне юлдан яздырып, алдап-йолдап, төнлә чабышалар, имеш.

Тыкрыкка борылгач, кыз эчендәге утлы өермәне басар өчен туктап торды. Булды инде, җитте! Каян килеп керә уйга җыен уйдырма нәрсәләр? Әбиләр сөйләгән әкият кенә ич болар!

Кинәт аягына бер җылы әйбер килеп сарылды. Абау! Җен бит, бәләкәй җен! Сәвилә коты очып читкә сикерде. Шул мәлдә генә, койма өстендә тырмашкан, чинашкан авазлар чыгарып, кара йомгаклар тәгәрәште... Алар берәм-берәм җиргә коела иде... Мәчеләр түгелме соң? Мәчеләр икән, мәчеләр! Мәче туена эләксәң дә эш харап.

Сәвилә бар көченә алга таба йөгерде. Алабута баскан җимерек өйнең баскыч төбенә килеп егылганда ул ярты җан иде. Капшанып ишек тоткасын эзләде. Тапмады. Әллә ишексез өйме бу? Кая ишек? Йөрәге шартлап ярыла ич хәзер.

— Уңга борыл! — дигән боерулы тавыш ишеткәч, ул чак артына утырмады. Убыр! Аңа эндәште. Уңда нәрсә бар соң? Бәрәч, янәшәдә генә мунча бугай. Парланган себерке исе килә... Корым исе...

Карчык сукыр лампа яктысында тәрәшле тарак белән чәчен тарап утыра иде.

— Уз, чишен,— диде.— Күзең төнгә ияләшмәгән, көн өчен жаратылган. Куркып киләсең, күңелеңдә — вәсвәсә, шом. Мәчедән дә өркәсең. Инде тынычлан. Анау, комганда ару су, коен...

— Без кичә мунча яккан иек, әби!

— Җә, жаксаң? Син гөнаһлылар җиргән юлдан атлап килдең. Аякларыңа гөнаһ тузаны кунган. Җаның берлә тәнең пакь булсын.

Диварның сыек ут сирпелгән ягында төрле шәүләләр биеште. Карчык хәрәкәтләнгән саен, аның әгъзалары таралып китеп бии сыман иде. «Юк, бу чын кеше хәрәкәте, җен-пәри туе түгел»,— дип үз-үзен юатты кыз. Мунчага тәмам ияләшкәч, ул әкрен генә үз хәленә кайтты. Бөтенесе дә табигый иде: карчык та, сукыр лампа да, ләүкәдәге себерке дә, ләгәндәге су да... Әмма шушы чынбарлык эчендә күзгә күренмичә генә могҗиза яши иде. Җен-пәринең барлыгына ышанмаса да, җирдә могҗиза яшәвенә җаны-тәне белән ышана иде кыз.

— Коендыңмы, олан? Ашык, ашык!

— Нигә ашыктырасың, әби?

— Эссе мунчага аяк баскач та, түбәңә су тидерү фарыздыр. Эссе мине кайнатадыр.

— Оркыя апа да шулай әйтәдер иде. Үлде бит ул Оркыя апа, бәбиләгәч үлде. Нишләп үлде соң ул, әби? Япь-яшь килеш, авырмыйча, ә? Могҗиза белән коткарып булмый идеме соң?

— Җаныңда уй җертәсең, олан, хуп. Могҗиза дигәнең җиде тау артында, җиде дәрья буенда, җиде кат җир астындадыр. Оркыяга андук барасы юк ие. Үз кулында ие могҗизасы. Ата-бабаларның гореф-гадәтләрен санга сукмый яшьләр. Буыннар чылбыры өзелде, олан. Чир-зәхмәт шуңа азды...

Карчык чүмеч белән ташка су томырды. Чыжлап пар күтәрелде.

— Ләүкәгә мен,— диде ул Сәвиләгә.— Бәбиләгән хатынның буыны буыннан аерыла. Кайберәүсенең, алла кушып, үзеннән үзе утыра, кайберәүсенең шулай кала. Аны кайнар ләүкәгә жаткырып чәнчә бармагына тиклем уарга кирәк. Хәзер сине үрәтәм, сузылып җат. Киндек турыннан башла, бозык кан агып чыксын, аннан билгә күч, аннан килеп күкрәкне у, сөт тамырларындагы шеш таралсын. Соңынтын гына

кулбашына, аякларга орын. Пар өстәргә онытма, пар тәнне җомшарта, файда бирә. Тырнак турыларына тиклем иренмичә у! Кулың тигән һәр төштә сөякләр сөяккә йәбешсен, буыннар буын савытынаберексен. Кан җөгертү бәк шифалыдыр, оланкай. Кан кайтса, җан кайта. Оркыяның анасына әйттем: «Мунча җак, кызыңны сауыктырам» дидем. «Кит, убыр»,— диде.— Синнән баламны үтерткәнче, духтырлар карасын»,— диде. Табагач белән куды мине. Терелтмәде кана духтырлары. Буыннары ычкынган ие Оркыяның, буыннары...

Сәвилә тәнендә йөгергән бармаклар хәрәкәтен хәтеренә сала барды.

— Җә, олан, киен дә ызбаңа кайт.

— Рәхмәт, әби. Тагын килимме?

— Күктә ай калкыр, көт. Ай тугач, урман аузындагы имән төбенә кил.

— Нигә, әби, без гел төнлә генә очрашабыз?

— Ябалак та төн берлә яшидер. Караңгыдан курыккан — шәүләсеннән өреккән.

Ай-һай, япа-ялгызың урман хәтле урманга барыр өчен батыр йөрәк кирәк! Ул сиңа авыл урамы түгел. Әнә кабан дуңгызы балалаган, ди. Төнлә азыкка чыга, ди. Очрасаң, ботарлап ташлый, ди. Көндез, ярый ла, күз күрә, агачка менеп тә качарсың. Тәминдарны чакырырга микән әллә? Аңа ни, көләр, җүләргә санар. Карчык та килештермәс, серне дөньяга чәчәсең, дияр. Тәминдарның иң-иң якын кешесе икәнен беләмени ул!

Иртәгесен апасы Сәвиләне ачуланып, төрткәләп уятты.

— Төн ката кайда йөрдең, җүнсез кыз?

— Урамда.

— Нәрсә эзләдең, җан көеге? Интернатка озатырмын, бел!

— Озат, озат, апа.

— Телеңә салынма! Хет күзле-башлы итсәм, атаң йортында калыр идең.

— Ә син кая барырсың, апа?

— Үз авылыма, үз нигеземә кайтам. Анаң гозере генә тота, бүген баш алып качар идем. Кияүгә бирмичә ташлама, диде анаң. Бер сүземне тыңламыйча үсәсең, алла колы! Убыр чишмәсен тазарттыңмыни? Кибеттә күземне ачырмады хатыннар... И хурландым да соң! Кычытмаганны кашып йөрисең? Ул чишмә ниемә кирәк, йә? Көчеңне кая куярга белмисеңдер, көчең ташыйдыр. Тәминдар практикагыз башлана, диде. Аша да мәктәбеңә сыпырт!

Аһ, шул мәктәп бакчасы! Кыш буе интегеп укулар гына җитмәгән, җәй көне дә тинтерәтәләр. Фәлән сәгатькә барып җит, фәлән әйбер эшлә, фәләнне тыңла... Китә-китә тезелеп! Ә еракта — күңелне ымсындырган урман-болыннар! Җанда — кысаларга сыймаган ирек! Һәм, ниһаять, карчыкның серле сабагы... Көне-төне ятласаң да, ул сабаклар укытучы дәресе кебек ялыктырмый.

...Яшелчә бакчасында Тәминдар арлы-бирле йөри иде. Ул Сәвиләне шелтәләп каршы алды:

— Кызлар күптән бакчада. Ярты сәгатькә соңардың.

— Җәяүлелең хәле чамалы, Тәминдар. Ә алар велосипедта җилдерә.

— Ә синеке кая? Төзәтеп бирдем ич!

Сәвилә елмайды:

— Мин велосипедта йөри белмим.

— Ах, шайтан кыз! Алайса нигә төзәттерден?

— Әйбернең төзек торуы әйбәт.

Укытучы сүз көрәштерүнең мәгънәсен тапмады:

— Кәбестәләргә күлдән су ташып сибәрсең.

— Бәлки чүп утаргадыр, ә? — диде кыз.

— Юк! — дип, кырт кисте Тәминдар.

Юк, икән, юк... Тәминдар көшты дип кенә, көлдән су сибәсе юк. Тиздән күктән сытылып җылы яңгыр явар. Әнә, болытлар яшь килен-нәр мендәре күк кабара. Урман авызында туктап күзәтте инде Сәвилә: яшенләп яңгыр явачак. Кабарган болытлар оешып тыгызлансын гына, дөнья мунча керәчәк! Яңгырдан соң салават күпере чыгар. Яшеле сиңа, Тәминдар! Сиңа яшәргә дә яшәргә, ак сакаллы карт булганчы, онык-ларыңның оныкларын күргәнче яшәргә, Тәминдар. Яшәү матур, тоя-сыңмы, Тәминдар? Тик кеше гомере кыска, бик кыска, нигә алай икән? Без җир йөзенә үләр өчен туабыз, көн саен үлемгә таба барабыз. Нәрсә генә үлемсез соң, Тәминдар? Җавап бир, зинһар...

— Сәвилә!

— Абау! Куркыттың. Уйланып тора идем.

— Кызлар эшләрен бетереп өйләренә таралды. Ә син кыл да кый-мылдатмадың. Кәбестәләрнең төбе шартлап ярылган, оял азрак!

— Хәзер яңгыр ява.

Шуны гына көткән кебек, күк күкрәде. Әһә, Таукыя ягыннан ишетелә! Аннан килгән яңгыр дәһшәтле була. Укытучы да, шикләнеп, Таукыя ягына күз ташлады. Ышан көнгә! Әле генә чалт аяз иде, болытның исе дә юк иде, баксаң, дөнья яшертен генә яңгырга көйлә-неп ята икән.

— Радиодан яңгыр көтелми, диделәр.

— Радиода әүлияләр утырмый ич, Тәминдар.

— Ә син әүлияме?

— Мин табигать баласы...

— Без барыбыз да табигать балалары,— диде укытучы.

— Юк, барыбыз да түгел. Күкне ертып, һаваны агулап, җирне актарып, үлән-чәчәкләрне таптап бетергән адәм — ничек табигать баласы булсын ди!?

— Их, яшь дустым, күп нәрсәне аңламыйсың шул әле.

— Алайса, аңлат, аңлат!

— Гади генә итеп аңлатканда болай ул. Әйтик, үзебезнең авыл мисалында. Совхоз дәүләткә фәлән хәтле сөт, ит, икмәк такшырырга тиеш. Югарыдан бирелгән план буенча. Галимҗан, минем бабай, район җитәкчеләренә өстәл сугып: «Планыгызны үтәмим!» — дия ал-мый, шүрли. Хәер, аның өстәл сугуыннан файда да юк, чөнки район-ның үзендә дә өстән килгән кәгазь ята. Нишләсен Галимҗан бабай, күрсәтмә үтим дип, басу-кырларны киңәйтер өчен Батма болынын сөрдереп ташлый; ит өчен симертелгән терлек-туарга яфрак әзерлим дип, урманны чишендерә, әрәмәлеккә көтүлек кертә.

— Ә иртәгәсе көн турында кем уйлый? Йолкынган-таланган, изелгән-тапталган табигать көннәрдән бер көнне бездән үч алыр бит!

— Көрәшергә кирәк, Сәвилә. Менә хәзер шул гүзәллекне терелтү өчен көрәшергә кирәк.

— Мәетне ничек терелтәсең!? Аннан соң, кешеләргә кирәкме ул матурлык? Алар бит сукырайды. Байлык артыннан куа-куа күз-ләрен кара элпә каплады. Сокланмый кеше табигатькә, һаман күбрәк эләктерү ягын гына карый.— Сәвиләнең тавышы калтырады.— Быел энә карагын күрдеңме, Тәминдар?

Тәминдар:

— Күрдем, Сәвилә,— дияргә ашыкты.

— Алдыйсың,— диде кыз, күңелсезләнеп.— Басу-кырларга сип-кән агудан көйде алар, алдыйсың... Син юри алдыйсың... Энә карагы — энә урлый дип, безне бәләкәй чакта, әбиләр алдый иде. Ә мин шуңа ышана идем, шул канатлы бөҗәкне күрсәм, өйдәге энәләрне яшерә идем.

— Шулай, яшь дустым, дөньяның ямьйсы тишек-тошыгы күп. Бер рәткә салыныр инде ул, җайланыр.— Тәминдар шалдор-шолдыр

чиләкләрне җыеп каплады.— Яңгырга өлгергәнче кайтыйкмы әллә, яшь дустым?

Өлгерә алмадылар, давыллы яңгыр аларны урман аланында куып тотты. Тәминдар, Сәвиләне кулыннан өлтереп, печәнчеләр куышына йөгерде. Юка ситса күлмәге кызның ябык тәненә сыланган иде, ул тизрәк почмакка елышты. Абау, моңарчы чүпрәк кенә каплап харап иткән, аның да тәне бар икән! Ул бит үзен җаннан гына тора дип уйлый иде. Алайса бу гәүдәсен күтәреп ничек оча икән ул?! Аяклары җирдән аерып, әкрен генә очканы бар ич! Юктыр аның тәне, юктыр! Тәминдар да күрер иде... Бәлки күрмәс тә иде...

— Тәминдар... Син мине күрәсеңме?

— Нәрсә, әллә абага чәчәге каптыңмы?

— Күрәсеңме, дим? Күрәсеңме?

— Йә, шуннан?

— Әгәр күрмәсәң, кочаклап кара. Бу минем тән микән, тоясым килә... Борыл да кочакла...

Укытучы җилкә аша гына йодрык күрсәтте.

— Телең нәрсә сөйләгәнне колагың ишетәме, кызый!

— Ачуланасың, әйеме, Тәминдар?

— Ачуланып кына калмам, тал чыбыгы белән суктырырмын.

— Миңа барыбер. Суктыр. Ул хәтле нәрсә эшләдем әле? Тәнем бармы-юкмы, шуны беләсем килгән иде.

— Чеметеп кара.

— Көлмә. Мин чынлап сөйләшәм.

— Укытучы белән алай сөйләшмиләр. Кияүгә чыккач, ирең белән икәү барысын да ачыкларсыз...

«Кырыс кеше син, Тәминдар. Ә күңелең искиткеч матур! Сиңа үпкәләп тә булмый. Тик син мине юкка тиргисең. Минем теләктә нинди яманлык, нинди мәкер бар?! Урлашыйк димәдем ич!»

— Сәвилә!

— Әү, Тәминдар.

— Син ничек яңгыр яудырдың соң әле?

— Яңгыр алдыннан эт эчәгесе чәчәге йомыла...

— Молодец, синнән шәп биолог чыгар. Тырышып укысаң, институтка керер идең. Тик мәнә мәктәпкә мөнәсәбәтең начар синең. Бөтен укытучыларны үзеңә каршы куеп бетердең.

«Ялгышасың, Тәминдар. Берсен калдырдым... Сине беренче мәртәбә күргән көнемне хәтерлим әле. Әни үлгәч, өч яшьлек Сәвиләне күрше авылда яшәүче апасы үзенә алып китә. Кызга ун яшь тулгач, янә әйләнеп кайталар. Ә уң якта — яңа күршеләр, уртак ишегалды һәм... син. Болдырга чыгып баскан бөркет карашлы ир... Синең: «У-у, Сәвилә шулай зур үстеме!» — дигән тавышыңа ятсынып каравым. «Теге абый кем?» — дип сорагач, апаның исе китмичә генә: «Тәминдар ул, син укыйсы мәктәптә укыта»,— дип әйтүе...»

— Ишетәсеңме, Сәвилә, нигә тындың?

— Ишетәм, Тәминдар, күк күкри.

— Минем сүземә дә бераз колак сал әле. Быел тугызга барасың... Күңел биреп укырга тырыш. Син сәләтле кыз. Килделе-киттеле сорауларың белән бәйләнмә укытучыларга. Инде, эчең пошса, миннән сора... Синең сәер гадәтләреңә ияләшеп киләм бугай.

— Чынлапмы? Телисеңме, күбәләк кебек канатланып биим? Аланда, яңгырга коенып, ә? Яшен сукмый миңа, курыкма!

Укытучының җилкәсенә ышкылып шуып кына чыкты Сәвилә. Тәминдар каушап, югалып калды. «Тукта» дияргә соң иде инде, күбәләктәй бөтерелеп очкан кыз табигать белән бер бөтенгә әверелгән, аларны аерып алырлык түгел иде.

Ир, кызарып, башын түбән иде. Кызга карап сокленуын үзеннән дә яшереп маташмавыннан оялa иде ул. Яшерә алмады, әсәрләнеп

яшь, сылу тәнгә карады. Көлә-көлә яуган яңгырдан көнләште. Табигать үз баласын җылы тамчылары белән назлый, иркәли сыман иде. Әллә күз алышынды, әллә могҗиза булды, берзаман кызның гәүдәсе югалды, алан уртасында бары тик гүзәл сын гына торып калды. Инде оят та качты, укытучы исемле хөкемдар да онытылды, күңелдә аңлаешсыз, сәер теләк уянды: аның да, тамчы кебек яратып, шул сынга кагыласы, кагыласы, бик-бик кагыласы килә иде! Бу кыргый, әмма табигый теләктән кинәт җаны сафланып, дөньясы нурланып китте. Җанда нидер бар икән әле, үлмәгән... Нидер бар, яши, өметләнә, көтә... Үлмәгән икән, үлмәгән. Тик болай ярамый... Чикне узып бара. Ул олы кеше, ул укытучы...

Тәминдар, борылмыйча гына, кулы белән капшанып Сәвиләнең киемнәрен эзләде. Киптерергә теләгән сыман, юеш ситса күлмәкне учына йомарлап кысты.

— Киен! — диде ул һәм үз тавышын үзе танымады. Тамагы карлыккан иде.— Киен! Кеше күрер...

## 3

Урман шомлы иде. Шом аяк табаныннан йөрәккә таба үрмәли дә кире төшә. Мәктәпкә гел урман аша йөрелә. Төнге урман белән көндезге урманның ни аермасы бар? Икесе дә бер инде...

Бу төндә әби кәефсез иде. Шуңа күрәдер, Сәвиләне битәрләп каршылады:

— Кеше салган сукмактан җөгермә, яңа сукмак тап,— диде.

— Мин алны-артны карамыйча чаптым, әби.

— Курку чаптырамы? Үрән, төн берлә яшәргә үрән. Ул гына чаптырмый сине, олан. Пырдымсыз җөрәгең куалый. Тизрәк сер җыймакчы син... Һәйт, кабаланма! Йөз җыл җыйдым дөнҗа серен, иллә җыеп бетерә алмадым, гумерем җитмәде. Ашыгып эшне бозма, сабырсыздан сер кача! Адәм күңеле карурман күек чытырманлы, тоба күек төпсез, төн күек караңгы, абага чәчәге күек күренми торган нәстәкәй ул... Төшсәң, күзләр аша гына төшәрсең адәм күңеленә. Нә җаман асрый адәм, нә җакшы саклый — күздән укырсың.

— Кайчан, әби, кайчан?

— Тс-с, пырдымсыз! Аллаһы тәгаләнең сәгате сугар, көт. Бүлдермә карт сөякне! — Имән төбенә җәелеп утырган карчык таягы белән селтәнеп алды.— Нә күрерсең ул бәндә күңелендә — кычкырма, ауызың җом!

— Ник, әби, ник?!

— Хатамны кабатлама...

— Нинди хатаны?

— Кешеләрне үзеңнән биздерсәң, гумерең җалгыз узар. Җалгызлыкның нә бәягә торганны үлчәү тәлинкәләренә салып кына үлчәп булмый, олан. Минем дә Маһруй дигән атым бар ие. Адәм күзенә багып, күңел серен белер ием. Белсәм, ул ил-йортка чәчелә, иясенә барып ирешә ие. Күрше Минап кызы Сәрия зина кылып көмәнле булды. Урак урганда, җарып салдым шул, катыннар шаһит ие. Сәрия, дидем, малай табарсың, таш калага аппарып, туар җанны тураклатма дидем. Анасы көмәне беленгәнче калага озатмакчы ие. Миңлегайшә астай, ике малаен өстереп, абзарында кыйнатты үземне. Синең күек сөяксез җәшь нәстәкәй ием, тәнем-битемне күмерләндереп чыгардылар, чак үлемгә тармадым. Инде дә моннан зур сабак кирәкмәс ие. Юк бит, Ибраһим атлы бәндәгә барып: «Синнән көн яктысы бизәр»,— дидем, бизде, сукырайды. Тавык Сарасына: «Ирең марҗа хәстәрләгән тилерткеч эчеп кайтыр да, асылыныр»,— дидем, тәге көмешкә дигәнне коядыр иде бер марҗа, сакламады Бикмулла-

сын Сара, бауга башын тыкты Бикмулла... И-и, бу дилбегә телне! Берзаман халык миннән читләшә башлады. Урамга чыксам, кеше кача, юлда очраса, йөзен каплап, читкә карап үтә, күз җәшерә. Күз... Күз — Алла күзгесе. Аллаһы тәгалә кулыма тоттырган көзгедә нә күрсәм, шуны әйттем, тынмадым шул. Артымда нә генә әйтеп хурламадылар. Калмады сихерче дигән сүз, калмады пәри, калмады убыр. Убыр атым берлә җан бирергә язгандыр, ходай... Убырны телдән куймады халык, чат җәбеште. Күршеләр, нигез туздырып, арырак күчте, сихер җогар, имеш, бәлагә тарырлар. Сул як күршем, мәрхүм Гыйбадулла, күченеп өч көн җәшәмәде, җорты җанып көл булды. Аны да миннән күрделәр, зыян салган, диделәр. Аллаһы тәгаләнең кодрәте киң, и шаулап җаңгыр койды, и койды, гөрләп акты урамнан ташкын, тавык-чебеш, каз-үрдәген, әммәсен агызып акты. Монысын да миннән диде кара халык. Төннә өч бәндә, башыма киндер капчык кидереп, үләт базына ташладылар. Эрнепләр җыладым, капчык тоткан кулы корысын, дидем, җыл үтмәде, Сабирҗанның кулы корыды. Каргышым төшкәндер димим, бә-әк мәрхәмәтсез ие Сабирҗан, анасын чоланда бикләп ач тотар ие. Ана каргышы — дәү каргыш, җир күтәрмәс, дидер изге китап. Таш атканга — аш ат, диләр. Ашымны аш итмәде, таш итте адәм. Якты көнгә чырай күрсәтмичә, төн белән төндәш булдым, сүздәш булдым... Син бак, үзкисәгем, бак могҗизалы җиһанга. Айның кояштан кай төше ким? Рәсүлебез йөзе күек нурлы айдыр ул, миһербанлыдыр, шөкер, төннең уңайлыклары чиксез, өстеңә былчырак атмыйлар, яманатың сатмыйлар, куркучы да җук синнән, өркүче дә... Ходай кичерсен, көн күзендә чишмәмә килдем. Аягым тартты, үзкисәгемне күрергә насыйп булгандыр.

Шунда карчык кинәт сорады:

— Гыйбрәт өчен тел тибрәттем, аңыштыңмы, олан?

— Юк, әби.

— Нә аңышмадың, олан?

— Күздән укып белгән дөреслекне яшерергә кушасың бит син! Ялганларга кушасың!

— Бәндә — зәһәр, бәндә — усал, саклан, дим, хараплар булма, дим.— Карчык уфтанып куйды. Аннан соң әйтте.— Иртәгә килерсең, кайт, олан, кайт. Ардымдыр, башым түнгәндер... Гайрәтем сүнгәндер...

Кыз чакрым ераклыктагы каенлыкка таба борылды. Чү, аның алдында уйламаган-көтмәгән киртә корылган түгелме соң?! Нәкъ ул үтәсе урында машина! Эрҗәсендә мыгыр-мыгыр икәү сөйләшә... Эһә, Кибәк Данияры тавышы! Мөгаен, хатыны белән печән урларга килгәндер.

Сәвилә кушкаен артына посты. Килүен килгәндер дә, нишләп урламыйлар? Тукта, Кибәк Даниярының хатыны телсез бит! Ә бу хатын шүрәле кытыклаган сыман кыһ-кыһ көлә. Кем көлүе бу? Кем көлүе? Таныш та кебек... Бәрәч, Мәликә апа шулай кылтая бит! Тач аңарга охшатып көлә эрҗәдәге хатын! Булмас, булмас! Аның менә дигән асыл ире бар.

Йә, нигә кытыклана икән болар? Нинди уен уйный? Кыз, мәче адымнары белән машина янына килде, көпчәккә басып, эрҗә эченә үрелеп карады. Ай нәкъ баш очында иде. Кирәгеннән артык яктырта иде. Ул башта андагы хәлне аңламады. Андый яшерен нәрсәләрнең шулайрак буласын чамалый иде, ләкин... Җиргә ничек сикереп төшүен сизмәде ул.

— Кеше йөри! — диде хатын, чәбәләнеп.

Сәвилә кушкаенга чак посып өлгерде, колак яныннан гына выжылдап тимер кисәге очты.

— Кабыз машинаңны, беттек, тотылдык,— дип, өтәләнде хатын.

— Күзеңә күренгәндер, кара пәри! — диде Кибәк Данияры.— Тотсам, урталай өзәм, үтерәм!

— Тоттыра, ди. Кабыз тизрәк!

Шүрләде бугай Данияр, фарасын сүндергән килеш кенә, машинасын урманга табан куалады. Сәвилә дә каенлык эченә ыргылды. Ул үзенең ахмаклыгына шаккатты. Нигә дип әрҗәгә үрмәләде соң ул? Нигә кирәкмәс урынга борын тыкты? Шайтаныма олаксыннар! Шул Мәликә дип... Таныйм дип. Тәминдарга хыянәт итсә, җир йотар имансызны. Тәминдарны берәрсе белән алыштырырга ярыймы соң?! Ул бит — бердәнбер! Авылда гына түгел, җир шарында бердәнбер! Аңа тиңләшерлек ир-егет йә тумаган, йә тугач та үлеп беткән. Кара, Мәликә апа, әгәр әрҗәдәге хатын син булсаң... Убыр кушканны үтәп авызына су капмас Сәвилә, күргәннәрен тотар да иреңә сөйләр.

Төнге күренеш, җанын айкап, таңга хәтле тынгылык бирмәде. Иртән тәрәзәне ачты да, башын тыгып, ишегалдында кайнашкан Мәликәне күзәтте. Мәликә бер сарыгын җиргә егып салган да, өстенә атланып черт тә черт йон кырка. Сарык ычкынмакчы булып тыпырчына, тоягы белән җиргә тибә, ул тибенгән саен Мәликә урам ярып кычкыра:

— Тик ят, аңгыра! Суймыйлар сине! Ни йоның, ни итең! Быел бәрәнләмәдең дә, кысыр бет! Муеныңнан пычак шудырырмын, ачуымны кабартсаң. Түшкәңне этләргә ташлармын! — Хатын Сәвиләгә дә ук җибәрде.— Нәстә карыйсың? Булыш әзрәк!

Кыз, чыгып, сарыкның аягын тотты.

— Йонны май аенда кыркалар, Мәликә апа.

— Бу зимагур хайван җәй буе качып йөрде, җимешем. Кичә Тәминдар табып кайтты.

— Син өйдә түгел идең бит, Мәликә апа.

— Кунакта идем шул, җимешем. Апалар авылына бардым.

— Кунакта шәптер, әйеме, Мәликә апа?

— Шәп, шәп, җимешем? Нәстә төпченәсең әле? — Хатын каушады, йөзе тимгел-тимгел булды.— Күзеңне алартма, яме. Күзләрең әллә нинди синең, чәнчи торган, сихерче күзләре. Кунакта шәп, күбенгәнче ашаталар, йомшак түшәккә салып йоклаталар. Сиңа ни, төпченәсең... Башың яшь, күп белергә. Карама дим төбәп!

Каны кызган Мәликәнең кулыннан кайчысы ычкынды, хуҗасының тавышыннан куркып, яртылаш кыркылган сарык та үрә сикереп торды, ачык капкадан урамга атылды.

Мәликәне инде тыярлык түгел иде, ул кычкыра-кычкыра Сәвилә өстенә килә башлады:

— Карама үтәли тишеп! Гаебемне тапкан төсле! Атаңны суйган мәллә?! Карама!

Апасы йөгереп чыкмаса, ишегалдында хәлләр буласы иде.

— Нишлисез, алла бәндәләре? Сугышмыйсыздыр бит?

— Сеңелеңне тый? — диде күркә сыман кабарынган Мәликә.— Бәгыремә төшә, Сәрвәр апа, үл-ләм!

Хатын башын чайкый-чайкый тилереп еларга кереште.

— Әйдә, әле, кер.— Апасы Сәвиләне җилтерәтеп өйгә алып керде.— Нишләдең тагын, ә? Монда да күрше-күлән белән талашып бетикме инде, адәм ыстырамы? Теге авылда яшәрлегемне калдырмадың, тиктормас телең белән чәчтең, урдың. Аптырагач, әниең авылына күчендек ләса. Йә, нишләттең аны, бер-бер яман сүз ычкындырдыңмы?

Кызның зиһене чуалды. Әле генә нәрсә булды соң? Нигә аны апасы бастырып орыша? Ул беркемне дә үтермәде, беркемгә дә начар сүз әйтмәде, ул бары тик Мәликәнең серен генә үтәли күрергә теләде!..

— Мин аңа сынап карадым, апа, шул гына.

— И алла, тегесе дә юк өчен авыл җыя икән.— Апасы ишектән башын тыгып баскыч төбендә шыңшып утырган Мәликәгә ялварды: — Күршекәем, җир җимертеп елама сана, тукта. Күзеңә генә карадым ди ич, аннан кителмәссең бит, уалып төшмәссең.

Мәликә, алъяпкыч итәген күтәреп, күз яшьләрен ашык-пошык сөртте:

— Сәвилә, җимешем,— диде ул, тәмле телләнеп.— Сүзем бар, чык әле.

Хатынның минут эчендә икегә төрләнүе кызны аптырашта калдырды. Елавы да чынлап түгелдер аның, ясалмадыр. Уйныйдыр ул шулай, хәйләкәр төлке.

— Бакчага керикче, җимешем, аулакка.

Керделәр, алмагач төбенә чүгәләделәр.

— Син идеңмени теге каенлыкта? — диде хатын пышылдап.

— Әйе.

— Әйтәм аны чекерәясең! Андук сизендем, мыскыл итеп каравыңнан ук. Артымнан иснәнеп йөрергә Тәминдар абыең куштымы?

Тәминдар?! Авызыңнан җил алсын, Мәликә хатын! Ул мондый түбәнлеккә төшәме соң?! Ул — Тәминдар атлы ир, горур, мәһабәт җан, синең төнге уеннарыңнан мең баш югары тора!

— Йә, йә, болай гына соравым, төсең китмәсен. Тәминдар кушмаса, бик һәйбәт, икебезнең сер булып калыр, яме, җимешем? — Сөенеп, балкып киткән Мәликә аның битеннән үпте.— Мең яшә, мең яшә, җимешем.

— Мин яшәрмен, Мәликә апа. Ә син нишләрсең? Кибәк Данияры белән тагын әрҗәдә аунарсыңмы?

— Әкрен! Ишетмәсеннәр! — Хатын як-ягына каранды.— Әкрен, бала, шаулама. Ни бит ул...

Мәликә тиктормас кулларын бер тезләренә куйды, бер чәчен рәтләде; күрәсең, аның ахыргача акланасы килә иде:

— Ни бит ул, җимешем, тормыш катлаулы нәстәкәй, сиңа караңгы бер ягы бар аның, ир белән хатын арасында дим, йоклаганда дим. Тәминдар абыең йоклый алмый шул минем белән...— Хатын, киракле сүз эзләп, күзләрен тәгәрәтеп йөртте.— Ирлеге мәрткә киткән аның, уянмый, вәт дөресе шул, җимешем!

Сәвиләнең уңайсызланып кызаруын күргәч, хатын янә теленә салынды:

— Бульниста терелтәләр ди аны, кала бульнисендә. Бармый, нәләт. Миңа ни! Әллә чукыныймы ир дип! Башым авырта минем ир күрмәсәм, чигәм кыса.

Аһ, Тәминдар, Тәминдар! Бәхетсез Тәминдар! Йортыңда карак яшәп ятканда, йөрәкләрең ничек түзәр!? Ул синең җылыңны, синең хисләреңне урлап, чит-ят кочакларга илтеп сала. Ул синең бәяңне белми, Тәминдар...

Бытбылдык хатын тәмам гайрәтен чигергән иде, миңгерәү төсле чайкалып бакчадан чыкты Сәвилә, шунда күзе бауда җилфердәгән Тәминдар күлмәгенә төште, ул уянып киткәндәй булды, җәһәт кенә барып баудан күлмәкне йолкып алды һәм Нәзергә йөгерде. Бәхетенә кырау суккан иргә теләк тели-тели Сәвилә тагын күлмәк агызды... Елга рухы да ярдәм итмәсә, кем терелтер Тәминдарны?! Агымсу! Чарасын күр, агымсу-у!..

Ярның сөзәк төшендә машина юып маташкан Кибәк Даниярын күргәч, адымын акрынайтты.

— Әй, әрәмә сандугачы, бире кил! — диде Кибәк кул изәп.

Сәвилә, батыраеп, аңа якынлашты. Әллә Мәликә әләкләп тә өлгергәнме? Юктыр, алмагач төбендә җәелеп калды ич ул.

— Кил, кил, булыш абзаңа. Әнәгенәк тәрәзә пыяласын сөрт.

Сәвилә, юеш чүпрәк тотып, кабина борынына үрмәләде. Кибәк

Данияры шат иде, уйнап-көлеп кызга эндәште:

— Ялтырыймы минем айгыр, ялтырый бит, ә, әрәмә сандугачы?

— Машинаңны тузанлы юлдан куагансың, Данияр абый.

— Болыт өстеннән кумам кәнишне.

— Бүген төнле Мәликә апа кунакка бармыйм, диде. Әрҗәгә салам җәймә.

Сәвилә нәрсә әйткәнен сизмичә дә калды.

— А ну, расмы? — Кибәк Даниярның күзләре маңгаена сикереп менде. Ул, очлы борыны белән кызның кабыргасына төртердәй булып, якын ук килеп, кабатлап сорады.— Расмы?

— Рас, рас, Данияр абый.

— Мәликә апаң җибәрдеме сине?

— Ие, ул җибәрде. Данияр гына аздырды, мин хур кызлары кебек гөнаһсыз хатын идем, ди, үкенеп елый.

— Ха-ха! Данияр аздырды диме? Ана эт! Ул эт миңа Казан шоферларыннан күчте, безнең авылга килгән шоферлардан. Кулдан кулга йөрттеләр аны, кара пәрине. Хәзер Данияр гаепле! Машина белән арт ягыннан эттерәсе иде очратып! — Данияр әче сүгенде, сүгенгән саен черт тә черт комга төкерде.— Алар нәселләре белән азгын халык. Атасы, прид Галимҗан, беләсеңме, сугыштан качып нишләп яткан? Ипи сорап кергән яшь хатыннарны, икмәк өстендә... Тьфү, имансыз! Хәзер изге булып йөри! Бар, әйт пәригә, Данияр сиңа төкерә диң!

Данияр хәйләгә тиз капты. Инде икенче якны — Мәликә ягын көйлисе бар иде. Сүз башларга җай чыгып торуын күр син! Кичкырын, сер саклаучыны бәхилләтәм дип, Мәликә өрфия яулык тотып керде.

— Үсә төш әле, җимешем, үсә төш, биек үкчәле туфлиләремне дә бирәм.— Хатын ике арадагы мөнәсәбәтләрне бик каты ныгытып куймакчы иде. Дөнья хәлләрен белмәссең, кызны тизрәк үзеңә авыштырып куярга кирәк.

— Мәликә апа, көндез Данияр абыйны күрдем, елгада машина юа иде. Кил әле, ди, чакырып алды. Син Мәликәләр күршесе, ди, шуңа әйт әле, кунакка бармасын, ди.

— Гупчим диме?!

— Кеше калдыгы ул, Мәликә, ничу аның белән машина көпчәге туздырырга, ди.

— Һәй, чабата сыңары. Көмешкә капкандыр, бирән!

Зәһәр ачуын йөрәгенә төен итеп төйнәгән Мәликә ишегалдында пыр тузынды. Чиләкне тибеп очырды, бала-чага кебек тавык-чебеш куды, берочтан капкадан килеп керүче Тәминдарга да җикеренде:

— Мәктәптә генә яшәргә инде сиңа! Китәсең дә олагасың, җәфа! Ул утынны мин ярыр дисеңме әллә? Кеше ирләре йорт җанлы була, юлда яткан кадакны да кесәсенә алып тыга, ә син мәктәп хәтле мәктәптән ике кулыңны селкеп буш кайтасың!

— Җитештә яшибез, Мәликә, комсызланма.

— Бабаң олау белән китереп аударгач, яшибез, ник яшәмәскә!

«Кибәк Даниярының үчен гаепсез ireннән ала, аҗгыр хатын. Кичер, Тәминдар, мин бутадым дөньягызны. Хакым юк, беләм, алай да тыкшынам, кичер...» — дип, сызланды Сәвилә.— Сине галим булырлык акыл иясе, диләр, калада зур укуларга кыстап караганнар, ди, имеш. Шунда калсаң, кайтмасаң, Мәликәнең әрләүләрен ишетмәс идең...»

Мәликә дулады-дулады да, көянтә-чиләген асып, суга китте. Дөньяның кыл уртасындагы ишегалдында Сәвилә белән Тәминдар гына калды.

— Ардыңмы, Тәминдар?

— Ә-ә, синмени әле? — Тәминдар моңарчы кызны искәрмәгән бу-

гай, аңа карап елмая.— Армадым. Эш чыныктыра ул. Нигә бакчага килмәдең?
— Вакыт чамалы бит.
— Тагын Нәзердә күлмәк агыздыңмы, сәер кыз? Шыр-ялангач калдырасың инде.
— Яфрактан тегәрмен, борчылма.
Ир көлемсерәде. Күзләре сагышлы иде аның. Ул сагыш артында ниләр бар — билгесез иде...



## 4

Карчык аны ят дөньяга алып керде... Үләннәр иле дип атала иде ул дөнья. «Сиңа белү тиеш,— диде белекче.— Тән шифасы үләндәдер, үләндә, балакай. Нәмәгә басканыңны белеп бас: аяк астыңда бер сырхауга биш сихәт бирердәй кодрәт үсә».
Кодрәт, кодрәт! Менә кайда икән могҗизалар ачкычының бер кисәге. Ул ачкычны кулыңа әзер килеш тоттырмыйлар икән. Җиркүкне танып-белү аша килә икән ул.
Үләннәр иленә аяк басты да гаҗәпкә калды кыз: бу садәлек, бу матурлык, бу камиллек чәчәк белән яфракка гына хас микән әллә?! Ул моңарчы ваемсыз гына басып йөргән яшел тереклек иясенең бөек исеме — Галиҗәнаб үсемлек икән ләбаса. Җирдә чүп үләне үсми икән, чүп үләне дип йолкып ташлау — наданлык, аның асылын белмәү, ди карчык. Табигать үз дөньясын бик оста көйләгән, иллә дә артык нәрсәсе юк аның, ди. Убыр ялган сөйләмәс, убыр ялгышмас! Рәхмәт аңа, ул Сәвиләгә күпме сер ачты, күпме тылсым өйрәтте. Кыз, һәр үләннең серенә төшенгән саен, күңел офыкларының киңәеп китүен тойды. Әйе, бу хәзинә иде. Берәмтекләп җыйган хәзинә иде. «Ят кул тисә, үлән карыша,— диде карчык,— аның хикмәтен аңламаган бәндәгә әрем йолкырга да ярамый. Узган-барганда тиктомалдан ашык-пошык умырырга да ярамый»,— диде. Үлән җыю сәгате сукканны төгәл белергә кирәк икән. Кеше сыман, аларның да туу, картаю, үлү чоры була. Үләнгә дә гомер бирелгән. Әгәр белеп өзсәң, белеп эчсәң, үз гомере белән ул синең гомереңне дә озайтачак икән.
Үлән җыю чоры төрле, диде карчык. Ул айларга, көннәргә, сәгатьләргә һәм минутларга бүленә икән. Бер генә минутка соңар, яки бер генә минутка ашык, ул сиңа шифа түгел, чуртым да бирми икән. Хәтта көн белән төннең дә тәэсире зур, ди. Бер иш нәзберек үсемлек көндез кагылганны яратмый, ди, шифалы матдәсен тамырларына яшереп кала, ди.
Кешеләр сыман, үләннәр дә нәсел дәвамы турында кайгырта. Тик Галиҗәнаб үсемлек, нәселен күпме генә сакларга теләсә дә, кешеләр, нәкъ менә акыллы, тапкыр кешеләр басып алып, аның илен үлемгә дучар итә. Кан коелмыйча гына җан кыела... Җансыз тугайлар, җансыз болыннар, әрәмә-су буйлары арта. Таптады, изде кеше, рәхимсез изде. Карчык исемен атап та, төртеп күрсәтеп күрсәтә алмаган үләнчәчәкләр күп иде, алар җир өстеннән эзсез югалган иде. «Тагын да югалыр»,— диде карчык шомлы тавыш белән,— тагын да югалыр. Адәм туфрагы-ние белән йотадыр, адәм — аждаһадыр».
Соңгы көннәрдә карчык аягын көч-хәл белән генә шудырып атлый иде. Ул бик бетерешкән иде: алай да, таралырга торган гәүдәсен сөйрәп, урман-кырларны айкады. Иң ахырдан гына ул Сәвиләне урман артындагы сазлыкка алып килде.
— Бак,— диде ул сазлык кырыенда берән-сәрән күренгән ниндидер үләнгә ымлап.— Бак! Тугыз көч бирүче бу, үзкисәгем. Андыз. Яфрагы илә чәчәге — бөергә шифа, тамыры — ашказанына. Тамырын көз аенда гына казып ал, имгәтмичә генә. Салкын суда чайкап кип-

тер, кайнарга тыкма, канын бөрештерерсең. Онытма, андыз дым сулап үсә, аның төпләнгән җире шушыдыр. Сазлык кипсә, андыз да корыр...

— Эрекмәнгә охшаган, әйеме, әби?

— Эрекмән үзгә, олан, җакшы бак! Андыз иңгә тар, буйга озын, чәчәге сары. Өз! Көн күзендә җәнә багарсың.

— Эрекмән нәрсәдән әби, эрекмән? Койма буйларын, бакчаларны сарган ич ул! Бигрәк әрсез!

— Әрсез дип битәрләмә, олан. Аның суын ясап яман шештән эчү фарыз. Ач карынга, әз-әз капкалап. Сабира атлы катынны булнис дигәненнән кайтардылар, гумере беткән дип. Кызы җылап килде, сихер белән терелт дип. Көн дә эрекмән төнәтеп, шешәгә тутырып җибәрә идем. Сихер суы дип эчте Сабира, ай җәшәселәрен санаусыз ел җәшәде, картаеп гүргә иңде. Алланың кодрәте киң, әлһәмделиллаһ шөкер.— Карчык кулын күтәреп дога кылды.— Савыкты Сабира, аннан җаманатым сатты. Һә, бәндә оныта, бәндәнең хәтере тишек! — Кинәт аның тавышы үзгәрде, калтырап китте, ул әллә мәнсез Сабираны тирги, әллә, күрсәткән изгелегеңә адәм заты әнә ни рәвешле җавап бирә, исеңдә тот, дип Сәвиләне кисәтә иде.

Хәл җыйган арада карчык сөйләнде дә сөйләнде. Сәвилә күңеленә ул сүзләр сеңә барды. Нәрсә диде белекче әби? Нәкъ ул уйлаган нәрсәләрне әйтте түгелме соң?! Җирдә начарлык белән изгелек тартыша... Соңра изгелек җиңәр... Җир-сулар, урман-болыннар әүвәлге җәннәт чагына кайтса, иман да кайтыр. Табигатьтән аерылганга күрә адәмнең иманы юк, күңелендә шуңа кара уй, кара фикер. Җирне тимер басты. Кая карама, тимер атлар үкерә, тимер гәүдәләр йөгерешә, күктә дә болыт кисеп тимер кош оча... Тимер дигән нәрсә кешене сыта, изә, таптый...

Гавам җиде чир уздырыр... Җиде чирдән кырылган халыкның исәбе булмас! Адәмнең бик сирәге түшәгендә ятып үләр... Ул үз куллары белән тудырган афәттән һәм гарасаттан кырылыр. Җир өстендә үле күбәер, тере азаер...

Азактан, бик-бик азактан, җиһан савыгып калыр. Ул бала күңеле сыман пакь булыр, чиста булыр. Адәмнәр дә чистарыр. Җәннәттә яшим, дияр, дога кылыр, рәхмәт укыр. Андый заман житәр... Карчык күрер аны, чөнки аның ярты җаны Сәвиләдә калачак, ә Сәвилә үзеннән соң килгән белекчегә күчерер аны. Әлегә тумаган, яралмаган белекчегә. Анысы ир бала булыр. Сәйяр. Дөм-сукыр малай, дөм-сукыр егет, дөм-сукыр карт. Даны ерак таралыр. Аның катына им-том эзләп чит мәмләкәтләрдән дә халык агылыр...

— Нигә сукыр итеп күзаллыйсың Сәйярне, әби?!

Карчык сөйләнүеннән туктады, сәер генә иреннәрен ялап куйды. Тәмләп сөйләп утырганда, нигә бүләсең диюеме икән? Бүтәннәре белән килешә Сәвилә. Убыр уе — аның уе, ә менә Сәйярне һич тә сукыр итеп күрәсе килми!

— Сәйяр — күзледән кайтыш күрмәс... Тәкъдирдә шулай җазылган, олан... Тоемы бармак очында булыр. Бармак илә тәнеңә орынса, җиде зәхмәтеңне табар.

Карчык бераз тынып торды. Аннан соң әйтте:

— Ардым, олан,— диде.— Бар, кайт. Сиңа җитмеш җиде сырхаудан дәва үрәттем, җитмеш сигезенчесе — Алтай дигән далада, Байкал дигән зур су читендә... Шуның тамырын казып алырга кирәк... Иртә хәсрәтләнәсең, кыз бала. Чит ир хәсрәте күдерә җаныңны.

Тәминдар өчен шелтәле карчык! Тәминдарны терелтәм дип үлән эзләвен сизгән!

Кыз оялды. Үлән тулы капчыгын бер алды, бер җиргә куйды. Карчык киная белән генә әйтте:

— Ир-уланның тәне җоклыйдыр, шаять, уяныр,— диде.— Дәрте

вә гыйшкы берлә аңа кыз-катын якынаер, ул төнне алмагач, өч рәт чәчәк коеп, өч рәт чәчәк аткач, җир-күк үзе бирмештер,— диде.

Дару үләннәрен Сәвилә өйалды идәненә таратып салды. Иртән көтү куарга чыккан апасы, сукрана-сукрана, барысын да ишегалдына сибереп түкте.

— Кеше балалары басудан башак чүпли, бу тилене кара инде, җыен чүп үләне ташып куйган бит.— Апасы ишегалдында кайнашкан Тәминдарга зарын түгә башлады: — Син укыган, акыллы кеше, энем. Бер-бер киңәш бирче. Әллә дим, бүлнискә аппарып брачка күрсәтимме шул баланы? Акылга зәгыйфь түгел микән алай-болай, ә, энем Тәминдар?

— Борчылма, Сәрвәр апа. Сәвилә ул дару үләннәре җыйган, файдалы үләннәр.

— Кычыткан белән әрекмән дә дару үләне булдымы, кит, энем, көлдермә!

— Сәвилә — зиһенле кыз, безне чолгап алган мохит белән кызыксына, моны хупларга гына кирәк, Сәрвәр апа!

— Ул мохитың нидер, энем, миңа караңгы, аппарам, аппарам брачка, башында аның чире, башында! Камил бала бер әшсез елга буйларында киләп сарып йөрми ул. Хәзер төннәрен дә китеп югала, җәһәннәмгә олагамыни! Зыян-зәүрәт тә китерә икән әле, ат караучы Сибай зарланды үзеннән. Бабаң Галимҗанның кара айгырын бик астыннан чыгарган, ди. И котырды ди. Галимҗан прсидәтел, җир тишегеннән табыгыз айгырны, дип әйтеп әйтә, ди. Иманыңны укытыр ул Галимҗан, башыңны бетерер!

— Сәвилә белән үзем сөйләшермен, Сәрвәр апа. Врачка ашыкма син.

Боларны келәттә ишетеп яткан Сәвилә бәхетле елмайды. Шатлыгыңнан үрле-кырлы сикерерсең! Аны Тәминдар аңлый икән ләбаса! Шул җитмәгәнмени?! Тәминдар бит ул йөз кешегә тора!

Кыз, бичара апасы белән сүз озайтмас өчен, ул көтү куган арада келәттән чыгып, тиз-тиз генә капкалады да кырга тайды. Исәбе — мәктәп бакчасына баручы Тәминдарны олы юл читендә көтеп тору иде. Йә, нәрсә турында сөйләшмәкче була икән укытучы? Юкка гына Сәвиләнең апасына вәгъдә бирмәгәндер ич. Тик нишләп озаклады әле ул? Әнә кояш һаман югары күтәрелә, кояш артыннан тургай да күтәрелә. Чәчәк таҗларында күз яшедәй елтырап күренгән чык бөртекләрен кояш нуры үрелеп-үрелеп эчә башлый. Һава җылынган саен керфекләр йомыла, тән изрәп, йокыга тарта...

Юл читендә песи баласыдай йомарланып йоклаган кызны Тәминдар тавышы уятты.

— Сәвилә!

— Тәминдар! — Сәвилә, сикереп торып, тузанга буялган өс-башын какты.

— Ярый әле су өстенә ятып йокламагансың, дулкын белән агып китәр идең.

Укытучы бик сирәк шаярта, ләкин ул шаяртулар ихлас була иде.

— Әйдә, мәктәпкә җиткәнче гел җитди итеп сөйләшеп барыйк әле,— дип тәкъдим ясады Тәминдар.

— Нәрсә турында сөйләшәбез соң?

— Яшәү, тормыш турында. Менә әйт әле, син нәрсә өчен яшисең?

— Дөньяга туган һәрбер җан иясе үләр өчен яши.

— Үлгәнче яшисе дә бар бит әле. Туу белән үлем арасы ерак.

— Ул арага кем нинди күпер сала бит. Берәүләр өйләнә, бала үстерә һәм шушы минем күпер — яшәү, ди. Икенче берәүләр яшәүне байлык җыюда күрә, өченче берәүләр — кеше рәнҗетүдә, талауда, типтереп калуда.

— Ә син?

— Минме? Туу белән үлем арасында ни эш кырырга телимме? Дөньямны санламаучы корткычлар белән көрәшәм! Минем дөньям — табигать.

— Ул корткычлар кем инде?

— Кешеләр.

— Һай, Сәвилә, Сәвилә! Халыкка күсәк күтәрмә, халыкның башын ярырсың, диләр.

— Чишмә кимгән халык — халыкмыни ул?! Бәлки, син Галимҗанны да корткыч түгел диярсең?!

— Шуңа күрә син аның айгырын качырдыңмы?

— Ул миннән ялварып сорады.

— Галимҗанмы?

— Юк, кара айгыр. Хайваннарның да теле бар. Сыер мөгрәп, ат кешнәп, кош сайрап сөйләшә.

— Шуннан, шуннан?

— Галимҗан аны аранга ябып тота, ач килеш. Ни печән бирдерми, ни су. Һәр кичне чыбыркы белән кыйный. Айгыр бабаңнан җиктерми икән, шуңар үч ала икән, кансыз. Сибайның әбәткә китүен сагалап тордым да айгырны иреккә очырдым. Чын мәгәр, ялларын тузгытып урманга таба очты ул. Менә болай итеп, канатланып очты!

Укытучы адымын тизләтте, йөгереп киткән Сәвиләгә иярмәкче булды. Әкәмәт! Кызның дәртле шаукымы аңа да кагылды бугай, укытучы икәнен онытып, очасы, очасы килә!.. Чү! Яңгыр яуган алан-дагы халәт тагын җанга үрмәли. Ярамый... Вакытында басылырга, чама белергә кирәк...

— Тукта, Сәвилә! Уенга бордык, әңгәмәне, дим. Апаңны хөрмәт итәсеңме син? Ул синең өчен гел борчыла. Аны рәнҗетмә, яме? Киңәш-табыш ит, күңеле булсын. Әнә бер кочак дару үләннәре җыйгансың, ә апаңа әйтмәгәнсең. Кем өйрәтте үлән җыярга?

— Белекче әби.

— Кем, кем?!

— Белекче өйрәтте, дим. Нигә гаҗәпләнәсең?

Кашын-күзен җыерды! Әһә, ошамый Тәминдарга!

— Карчык-корчык белән аралашу яшьтәшләреңнән биздермәсме соң? Иртә картайгансың түгелме?

— Көлмә, зинһар.

— Көлмим, сез ике буын — картлык белән яшьлек, бер-берегезне аңламаска тиеш.

— Юк, бу — фаҗига. Яшьләр белән картларның бер-берсен аңламавы аркасында буыннар чылбыры өзелде. Мин аны ялгарга азапланам. Белекче белән кабергә үләннәр сере, җиһан сере китмәсен дим, гореф-гадәтләр онытылмасын дим! Мин шуңа карчыкка тартылам.

— Каты өйрәтә сине белекче әбиең, каты өйрәтә.

— Убыр — минем яшьтәшем дә, остазым да, Тәминдар!

5

Карчык күренмәде. Күк гөмбәзе йолдыз белән чуарланган иде. Туачак баланың язмышы йолдызлыкка бәйле, диде белекче. Сәвилә Игезәкләр йолдызлыгы астында туган. Ул кешеләр белән килешеп яши алмаячак, аңа шундый чуар холык насыйп иткән Игезәкләр...

Йолдызлар да, төнге урманны сискәндереп кычкырган байгыш тавышы да кызның борчылуын арттырды гына. Нигә килми әбиҗан? Соңга кала торган гадәте юк иде. Бик төгәл иде ул, бик пөхтә иде. Әллә бер-бер хәл булды микән? Бу араларда «ардым» сүзен еш кабатлый башлаган иде. Мөгаен, чирләп киткәндер. Их, мактап бакча-

сыннан кайтышлый өенә кереп хәлен белергә булган! Ул бит япаялгыз! Аның беркеме дә юк!

Кызның юраганы юш килде, карчык хәл эчендә ята иде. Ишектән керүче Сәвиләне ул, күзе белән генә ымлап, янына чакырды.

— Утыр,— диде, сәке кырыендагы тәбәнәк урындыкка күрсәтте.— Мин сине көттем, үзкисәгем.

Сәвилә бер очы идәнгә шуып төшкән юрганны рәтләп япты. Сүз таба алмады.

— Табалама җаныңны,— дип пышылдады карчык.— Син житештең. Әҗәлемне чигерә-чигерә көттем үзеңне, син житештең. Уң җилкәңә бак, уңына...

Сәвилә карчык әйткән якка борылды. Такта киштәләр саргаеп беткән китаплар белән тулган иде. Шул ук мәлдә кыз тиз-тиз генә өй эченә күз йөртеп чыкты. Һәм таң калды: әле генә яшь килен юыпҗыештырган диярсең, һәр җирдә тәртип, пөхтәлек иде. Тәрәзә кашагалары, өстәл җәймәсе ап-ак, идән сары балавыз төсле...

— Бактым, әби,— диде кыз.

— Борынгы китаплар, үзкисәгем... Төсем итеп сакла... Җазуын үрән... Инде дә түргә бак... Анысы — аятелкөрси... Әни чүлпыларын сатып бер карттан алды. Ызба саен кереп сәвит кешеләре җандырып та бакты. Апчыкты да урамда ут төртте сәвит, апчыкты да ут төртте. Әни яшерде, бирмәде. «Бир, бирмәсәң, башыңны өтерманга тыгабыз»,— дия-дия эзләделәр, идән такталарын куптардылар, асты-өскә килде ызбаның... Иман җазуын да сакла, үзкисәгем...

— Үлмә, әби, үлмә! — диде кыз, өзгәләнеп. Яңагын кайнар күз яшьләре чылатты.

— Ары таба дөнҗа үрәтер,— диде карчык.— Утны гына кичәсең бар, утны...

— Нинди ут соң ул, әби?! Син аны миңа гел әйтәсең бит!

Белекче дәшмәде, керфексез күзен йомды. Бераздан ул күзен ачты:

— Инде дә мине фани дөнҗадан озатырга әзерлән,— диде.— Мич башында өсте тастымал белән җапкан дүрт чиләк ару су булыр. Кәфенлек сандыкта... Чаклап үзем кистем, үзем тектем, ходай кичерсен... Бәбиләгән хатын белән үлгән бәндәдән курыкма. Берсендә җан иңәдер тәнгә, икенчесендә җан очып чыгадыр тәннән... Күземне йомдыр да, җуып кәфенлә. Аласым-бирәсем юк, тынычлап китәм дөнҗадан. Укыйсын укыдым, телисе теләкләремне теләдем, бер аллага тапшырам, амин...

Таң алдыннан карчык җан бирде. Елый-елый шешенгән кыз урыныннан торды. Башта, мәет янында әз генә утырса да, йөрәге шартлап ярылыр, карчык кушканнарның берсен дә булдыра алмас кебек иде.

«Әллә ярдәмгә кешеләр чакырыйм микән?» — дип тә уйлады ул, ләкин шунда ук акылы моны кире какты: Сәвилә үзе генә башкарып чыгачак, карчыкның соңгы үтенече шул иде. Күмүен ирләр күмәр. Хатын-кызны зиратка кертмиләр.

Калтыравык узды, күз яшьләре кипте. Дөньяның өйрәтә башлавы шушы микәнни?! Һай, авырдан башлады! Карчык үзе нинди жиңел... Юып кәфенләгәч, биләүсәгә төреп салган бәби хәтле генә булып күренә... Күтәреп кенә илтәсе зиратка...

...Ахырдан ул Тәминдарны барып чакырды. Укытучы йоклый иде, тәрәзәгә чиертеп уятты.

— Кабер казырга кирәк, Тәминдар.

— Нинди кабер?!

— Убыр-белекче... үлде, Тәминдар.

— Чү, сеңелкәем, төсең качкан синең, бар әле, кереп ят өеңә. Мин хәзер! Тиз генә киенәм дә, барам. Мәет күмү — зурлар эше, бар.

бар, ияреп йөрмә!

Чыраен җимереп, күзен йодрыгы белән уа-уа, баскычка Мәликә дә чыгып басты:

— Әче таңнан ни сайрыйсыз?

Тәминдар хатынына җавап бирмәде, көрәген күтәреп, капкага юнәлде.

— Кая бара иртүк, җәфа кисәге?

— Син йокла, Мәликә апа,— диде кыз, «эшең булмасын» дигәндәй.

— Мин йокладым, җимешем, менә син төн катакайда өстерәлеп йөрдең? Сәрвәр апаның агармаган чәчләрен агартып, ә? Теге чакта безне сагаладың инде, хәзер кемне гөнаһтан саклыйсың, фәрештәкәй?

— Кайткач, Тәминдар абыйны талкыма, Мәликә апа. Ул кабер казышырга китте!

— Абау, авылда үлем-китем бармыни?!

— Йөз яшьлек әби вафат...

— Убырмы? Фу, бөрәр җүнле кешеме дисәм, котны алдың. Дөмексен! Үлгәнче безнең нәселне каргады, козгын!

Хатын бөгелә-сыгыла киерелде:

— Әти ишетте микән? Сөенче алыйм әле.— Мәликә, халат чабуларына абына язып, Галимҗаннарга йөгерде. Сәвилә дә урамга чыкты. Ул томан эчендә йөзә иде, кая басканын, кая таба атлаганын сизмәде, йорт саен кереп, капка-ишекләрне шакып йөри башлады.

— Белекче үлде,— дип ыңгыраштьы үзе.

— Кем, кем? — дип сорадылар аңардан, ул һаман шул бер сүзне кабатлады.

— Белекче...

Ниһаять, аңыштылар. Капка төбенә халык җыелды, сүз китте, сүз таралды:

— Ишеттеңме. Сәрвәр апаның кызы ни ди? Теге Убыр үлгән, ди.

— Ул кызның башында бар, ди. Дөрес микән?

— Галимҗан сөенәдер. Аның кыңгыр эшләрен Убыр гел әйтә булган, ди, шуңа персидәтел ачулы бит аңа.

Аннан дәррәү Убыр өенә юнәлделәр. Иң кызыгы бала-чага өчен иде. Алар:

— Убырны күмәләр! — дип, «ура» кычкырып, җеназа артыннан чапты.

Барысының да тавышын күмеп, кемдер кычкырды:

— Зиратка күмдермәскә иде убыр карчыгын!

Зәһәр тавыш иясенең үзенә дә «өлеш» чыкты:

— Майт сине! Бу патша заманы түгел. Тәминдар олан үзе кабер казытты.

Тагын шаулаштылар:

— Ызбасын сүтсеннәр иде. Бала-чаганы өркетеп тормасын иде.

— Сүтәрлеге калса! Җиргә сеңгән ич. Үзе белән бер яшьтәдер, билләһи.

— Галимҗан килә!

— Ну чаптыра атын!

— Таптатмасын, кыргый айгырын җиккән!

Халык икегә аерылып юл бирде. Галимҗан айгырдан да битәр ярсыган иде.

— Аю биетәләрме? Нигә җыелдыгыз?! — диде ул, төркемгә җикеренеп.— Ферма буш, ындыр табагы буш, кибетләр ябык. Сездән сорыйм, аю биетәләрме?! Марш эшкә! Кая Сәләх?

Сәләх — янгын сүндерүче ир, әйтерсең, халыкны ул җыйган, гаепле сыман башын иеп, колхоз рәисе каршысына килеп басты.

— Без монда, Галимҗан абзый.

— Кирәкле нәстәң үзең беләнме?

— Ул нәстә йоклаганда да үзем белән, Галимҗан абзый.

— Багорыңны әйтәм, ата каз! Бу карчыкның йорты авылның ямен җибәреп тормасын, яндырырга кирәк. Кисәве пыскып-нитеп калмасын!

— Була ул, Галимҗан абзый!

Халык гөж килде. Берәүләр Галимҗан фикерен куәтләде: ул сәламә йортка хуҗа табылмас, табылса да, анда яшәмәс, карчыкның өрәге куркытыр. Әйдә, янсын! Икенче берәүләр аның ниятен килештермәде: артыгын кылана, сүттерсә бер хәл, утынга ярар иде...

Сәләх икеләнде. Багорын сөйрәгән килеш, бер өйгә табан атлады, бер кире чигенде. Бәхәс куерган саен, халык кызды гына.

— Җәмәгать! — диде, чабулап йөргән Галимҗан.— Мин бу урынга яңа мәктәп салдырам!

— Үзең пинсәгә тайгачмы? Моңарчы ни карадың?

— Әйдә, салдырсын! Балалар күрше авылга йөреп интекмәс.

— Салдыра, карга әкияте!

— Мәктәп өчен бүтән урын тап!

Төркем күрмичә дә калды: Галимҗан, җебеп төшкән Сәләхне ачу белән читкә этәрде дә, шырпы сызып түбәгә ыргытты. Коры саламга ут тиз эленде, болытларны ялмарга теләгән сыман, һавага ялкын көлтәсе ургылды.

Сәвилә, күмеп кайтучы ирләрне көтеп, тыкрык башында тора иде, кулында картларга бирәсе хәер акчалары иде, янгынны күргәч, кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кешеләр! Анда бит изге китаплар!

Халык тораташ булып каткан иде, кызның йөгереп килгән шәпкә йорт эченә сикерүен беркем дә искәрмәде...

Сәвилә күкрәгенә нәрсәдер кадалуын тойды. Тик моны ачыкларга өлгермәде, тәтенгә буылды. Тәнен ут көйдерде. Эссе иде, чамасыз эссе иде, бу — карчык сөйләгән тәмугка охшаган иде... Нәрсә яна? Чытыр-чытыр агач янамы, әллә улмы? Күлмәкне саласы иде... Ут... ут... Тукта... Сүн, ут... Яндырма, яндырма! Кайда соң теге яңгырлы алан? Тәминдар! Алып кит шул аланга, зинһар, дим...

Кыз үзенең ыңгырашуын ишетте. Үзе ыңгыраша, үзе шуны ишетә, ни хәл бу? Янып бетмәдемени әле ул? Чытыр-чытыр итте ич, агач түгел, сөяге янды... Җелегенең эреп агуын тойды бит ул... Тәмугта кайна да, үлмә, имеш!

— Күзеңне ач, нарасыем,— диде, өстенә иелгән апасы.— Айдан артык саташып ятасың инде. Аңыңа килсәң, ярар иде, ходаем.

— Апа... мин тереме? Мин исәнме?.. Нигә тәнем бу тиклем әрни соң?

— Тыныч ят, бала.— Апасы юеш мамык белән аның иренен чылатты.

— Торгыз әле мине, апа.

— Селкенмә! Бәйләвең чишелмәсен! Син бүлнистә, бала. Синең өчен хәсрәтләнеп елый-елый сукыраям инде. Үлеп терелдең, раббем!

— Елама, апа.

— Бу хәлләрдән соң да акылга утырмасаң, белмим, нишләрмен. Ах итте халык, телендә гелән син булдың.

— Мине ут эченнән кем алып чыкты?

— Тәминдар апчыккан, бала! Үзем күрмәдем.

— Нишләп ул хәлемне белергә килми, чакыр, апа.

— Тәминдармы? — Апасы көрсенде.— Тиз генә килмәс шул укытучы абыең... Ни бит... өтерманга яптылар аны, балам! Алай бәргәләнмә әле син, тыңла. Мәликәгә дә әрнү өстенә әрнү өнәтерәк. Тәминдар күтәреп чыккач, җан әсәре сизелмәгән бит, «үлде» дип уйлаган-

нар сине. Хәбәр китергәч, мин дә һуштан язып егылдым. «Син үтердең, бабай»,— дип Тәминдар кызулык белән Галимҗанның аяк астына кундырган. Тегесенең дуга рәтләп торган чагы икән, ат астына мәтәлгән. Айгыры да үзе сыман дәҗҗал иде, бичара хайван уттан да өреккәндер, гөпелдәп төшкән персидәтелнең күкрәгенә кушаяклап типкән. Сулышсыз калды, ди Галимҗан, «ә» дияргә җитешмәде, ди. Тикшерделәр дә, Тәминдарны бинават ясадылар шул.

— Димәк, ул ташның җиле Тәминдарга да бәрелгән...

— Нинди таш ул, балам?

— Сорама, апа...

Сәвилә күзен йомды. Күкрәгенә кадалган әйбер авырттырып чәнчеп алды. Ул саташмый иде, ул чынбарлыкта иде. Карчык әйткән ут аша үтте ләбаса, хәзер кызның җаны белән янәшә белекченең җаны урнашып маташа. Теге кадалган әйбер — карчык җаны икән! Ике җанга берләшү өчен нинди тәмуг газабы кичерергә кирәк булган! Ут кына куша алган, ут кына!

Кинәт ул үзен Убыр итеп күрде. Ул нәкъ Убыр төсле уйлый, сөйләшә, ыңгыраша иде...

— Апа... Сигезенче ятактагы кыз миңа карый.— Сәвилә иелгән апасының колагына пышылдады: — Күзендә үлем аның... Бөерләре кипкән.

— Әстәгыфирулла! Тәүбә диң! Төнә генә салдылар аны, брач «рәтләнер» диде әнкәсенә.

Бөерләре кипкән кыз төнлә үлде...

## 6

Әстерхан агае белән апасы рәшәткә ясый. Ишегалдын бүләләр. Базарда чикләвек сатучы агай белән танышуына нибарысы өч кенә көн, нинди елгыр хатын, кулына балта-чүкеч тә тоттырды.

Агай кысык күзләрен җемелдәтеп елмая, үзе сораштыра, төпченә:

— Ул бичә ирдәме, чәчәгем?

— Мәликәме? — Хәзер апасының Мәликәне җене сөйми, ишегалдын да аны күрмәс өчен генә бүлдерә ул.— Ирдә, ирдә! Тик капкасы гына шыр ачык, керәләр дә чыгалар... Тәминдар күрше һәйбәт кеше иде, кайтыр, боерса, срогы тула.

— Вай, шаян бичә, вай шаян!

— Тәминдарга әрәм ул, Батыр әкә.

Чират Сәвиләгә җитә. Базар агае бер ноктага карап утырган кызга төртеп күрсәтә:

— Теле авызындамы аның? Ник сүләшми?

— Ял итә,— ди апасы, сүз тапмыйча.

— Вай, гел ял итеп, баемас ул! Барсын базарга, сатсын чикләүек, хезмәтенә карап акча бирәем.

— Күндерә алсаң, үзең күндер, Батыр әкә. Өч ел инде ачылып сөйләшкәне юк. Пешкән иде, бүлнистә ятты, аннан мәктәптә укыды, яхшы укыды, гел «биш»кә бетерде. Җәллим дә, тиргим дә үзен. Тән җәрәхәтенә түзәргә кирәк бит, Батыр әкә. Ичмасам, бер зарланмады! Юрганын башыннан ук бөркәнер ие дә, тик исәплән ятыр ие. Әле дә уй уйлый ул, безне ишетми. Бүлнистән кайткач, әллә ниткән үлән сулары сөртә ие тәненә. Ышансаң ышан, ышанмасаң юк, җәрәхәте күзгә күренеп төзәлде. Холкы гына керделе-чыктылы шул. Әле күрше авылда эшли, брач пунктында. Брач язган даруларны сырхауларга өләшүче, укол кайнатучы кебегрәк эш, зур эш, баш эше.

— Чикләүек сатсын, гәпләш кыз балаң белән, чәчәгем. Җиде тәңкәнең бер тәңкәсе, шалт, үзенә.

«Тәлинкәнең икенче ягын әйләндер, агай. Апаны туйдырдың. Аның да холкы яман, зәһәре килеп, мыегыңны йолкымасын!»

— Син эшлә, Батыр әкә. Мин казан асыйм. Карт сыер ите озак пешә.— Апасы, сылтау табып, чикләвек мажарасыннан котылгач, Сәвилә агайга эндәште:

— Чикләвек кан басымыннан файдалы, агай. Хатыныңа ашат, сатма, ул авыру бит.

— Вай, теле ачылды кыз баланың! Карт бичә ул, аерып, яшьне алаем. Апаң, вай, күңелемә ярап тора.

— Минем апаның бәясе — чикләвек бәясе генә түгел шул, агай. Калым түләргә акчаң җитмәс.

— Вай! Бушлай килер.

— Юк, агай, мин аны сатам!

Сәвиләгә бу шаярту ошый башлады. Акча дигәч, агайның кулыннан эш китте, ул тотлыга-тотлыга:

— Вай, ни хакка? — диде.

— Ун мең тәңкә! Ә синең, агай, биш кенә мең.

— Вай, санадыңмы?

— Син аны чүпрәккә тегеп биленә бәйләгәнсең.

Рәшәткәгә сөялгән карт, аяк буыннары йомшарып, лып итеп артына утырды.

— Вай, кыз бала, чишенгәндә күрдеңме? Хакын апаң үзе куйдымы?

— Үзе, нәкъ үзе!

Мәзәкнең ахыры кызык тәмамланды. Апасы чыккач, Әстерхан агае бер алдына, бер артына төшеп, хатынның буй-сынын тикшерә башлады.

— Билең юан, бер меңне чигерәем, борының тукмак, ике меңне, тешең сынык, өчне. Күтәр, чәчәгем, итәгеңне, аякларың турымы, кәкреме, кәкре тек, бәяң төшә, кала ничә мең?..

— Нишли бу чукынган? Тилергәнме әллә? — Апасының күзләре акайды.

— Тилерерсең, чәчәгем, биш меңлек товарны ун меңгә күтәргәч!

— Нинди товар турында сөйлисең, Батыр әкә?

— Ун меңгә сатасың үзеңне, күп сорыйсың, төшер бәяңне.

— Нишләп сатылыйм ди мин, карт җүләр?!

— Кыз балаң әйтә, чәчәгем.

Бу кәмитне оештырган өчен апасы Сәвиләне ачуланмады.

— Шаярсын инде, әзрәк күңеле күтәрелер. Бигрәкләр дә үз эченә бикләнгән ие,— диде.— Сиңа, чикләвек корты, шул сүз җитә калдымы? Әнә, рәшәткәңне тигез тотсаң, бүтән исәп-хисап ясарбыз.

Их, апа, апа... Ялгыз хатын. Сәвилә булмаса, рәшәткә башы кебек тип-тигез гаилә корыр идең син. Китәр иде эреле-вaклы бала-чага! Син тыныч яшәргә яратасың. Гаугаларсыз, тавыш-тынсыз гына. Ә Сәвилә, киресенчә, давылсыз яши алмый. Ул инде авыл фельдшеры Сәкинә апасы белән чәкәләшеп тә өлгерде. Шул дару аркасында. Фельдшер хатын рецепт сырларга ярата. Район аптекасында нинди үтмәс дару кала, аңа китерәләр, ул сүз әйтми, чөнки кая шудырырга икәнен белә, чирдән зарланып килгән һәр кешегә, яраса да, ярамаса да, дару билгели. Авыл кешесе «брач кушкач» шулай тиеш дип уйлый.

Эшкә урнашуының өченчеме, дүртенчеме көнендә, ат арбасына салып бер хатынны китерделәр. Иелеп сулы ләгән күтәргәндә, уң ягыма күсәк белән орган кебек булды, ди, басалмый, авырта, ди.

Сәкинә апасы авыруның аягын капшап та карамады:

— Утәр, утәр,— диде.— Хәзер аналгин язам, төнгә икесен кап, табаныңа горчица сыла.

Ул рецепт этмәлләгән арада, Сәвилә хатынны сәкегә яткырырга

кушты. Уң аякның баш бармагы озынрак иде. Дөрес, моны гади күз белән искәреп булмый...

— Буының чыккан, апа. Кисәк әйбер күтәрмә, икенчеләй сак бул.— Һәм кыз шешенгән аякны үзенә таба тартты.

— Үләм! — диде хатын, авыртудан куырылып.

— Бас апа, үләргә иртә әле,— дигәч елый-елый рәхмәтләр яудырды.

Фельдшер гына ачулы иде. Ул моңа сөенмәде.

— Минем эшемә кысыласың, сеңлем,— диде.— Синең бурыч — рецепт буенча дару бирү, шприц кайнату, идән юу!

Шуннан бирле мөнәсәбәтләр кискенләште: өченче көн Сәкинә апасы аңа дарулар сатарга кушкан иде, кыз аларны өстәл тартмасына салды да куйды. Ә фельдшер акчасын сорагач:

— Даруларның бирәүгә дә кирәге булмады,— диде.— Эч кибүдән, тамак шешүдән зарланып килмәделәр. Сез югында мин Фәридә Әхтәмова исемле сыер савучыны районга җибәрдем. Бүсер аңарда.

Фельдшерга бәйләнер өчен бу җитә калды.

— Кем диагноз куйды?!

— Мин, Сәкинә апа.

— Син?! Син дипломлы белгечмени?! Нигә минем вазифама борын тыгасың?

— Сез ул хатынга ике ел буена дару ашаткансыз, ә аңа операция ясарга кирәк.

— Алайса үзең ясарга иде! Ипи пычагы белән тотарга да эчен ярырга иде! Син әле шулай эшләрсең дә, ә җавабын Сәкинә бирер! Кызганыч, эшкә алганда синең турыңда белешмә тупламадым. Әле соң түгел, авылыгызга барып энәсеннән-җебенә хәтле сорашам, бәләм әле кемлегеңне!

Хатын сүзен җилгә очырмады, Сәвиләләр авылыннан бер кочак гайбәт җыеп кайтты.

— Мин синең шәхесеңне тәки ачыкладым бит,— дип, кояштай балкып каршы алды ул беркөнне кызны.— Син бер авылга сыймыйча, икенчесенә күчеп килгәнсең, апаң белән.

— Дөрес, күчтем,— дип раслады Сәвилә.

— Синең кушаматың «Җүләр» икән ләбаса!

— Әйе, монысы да дөрес,— диде кыз, һич тә исе китмичә. Һәм хатынның үзенә дә сорау бирде: — Ә нигә мин җүләр, беләсезме?

— Әйт, ну, әйт!

— Сезнең кебек «акыллылар» арасында яшәгәнгә күрә җүләр мин!

— Абау! Тамаша икән! Җүләр инде син, җүләр, гүзәлкәем.

— Йә, мин — җүләр, сез — акыллы, ди. Шуннан нинди нәтиҗә ясадыгыз?

— Җүләр белән җүләр булмаска кирәк, дидем. Эштән кумыйм, эшлә. Тора-бара мөгез чыгармасаң, күз күрер тагын. Урта ишекне ябам, шакымыйча аягыңны да атлама!

«Бигайбә», диде Сәвилә эчтән генә. Җир шары бүленгәндә, ике бүлмәле медпунктны бүлү нәрсә ул. Моңа акыл кирәкми. Әнә бит, үз өлешен ничек каерып ала адәм баласы! Тиздән Тәминдарлар белән уртак ишегалды да икегә аерылыр...

— Вай, кыз бала дим, кыз бала! Ник яланаяк син? Башмак алырга акчаң юкмы?

— Табан тузмый, башмак туза, агай.

— Җиткән кызга яланаяк йөрү — гөнаһ.

— Тиен ризыгын — урман чикләвеген җыеп базарда сату савапмы, агай?

— Вай теле! Әрем тел.

— Сүз катма шуңа,— диде апасы, Әстерхан агайны беләгеннән

чеметеп.— Туганнан бирле яланаяк ул. Аяк табаны җир белән орынырга тиеш, ди, җирдән аңа дулкын бирелә, ди. Яшьләр бит, уйлап табалар. Син дә, Сәвилә, утырмасана баскычка береккән төсле. Ял көнне каядыр барам дип сөйләнгән идең түгелме соң?

«Беректем шул, апа. Мин чыгып китсәм, Тәминдар кайтып керер сыман. Тар ишегалдына сыяр микән аның җаны? Ник кенә ике арага киртә корасыңдыр, апа! Кайткач нәрсә дияр ул? «Синең өчен нисә ел төрмәдә интектем».— дип тетрәндерерме күңелне?! Әллә үзенең дөньясын минем дөньямнан аерып, уртага биек койма корырмы? Ачу да юк, шелтә дә юк, битарафлык, бары тик үтергеч битарафлык... Яшисеңме син җир йөзендә Сәвилә атлы кыз бала, яшәмисеңме — аңа барыбер! Менә нәрсә куркыта мине, апа. Өч ел тоташ җаным шуңа илереп елый... Хат язмакчы идем бит Тәминдарга сагынуымны яшермичә, хат язмакчы идем, иренең адресын сорагач, Мәликәнең шашуын күрсәң!

— Бирермен, тот! Синең аркада йортка бәхетсезлек килде. Күзең тондырып утка кермәсәң, ирем төрмәдә утырмас, газиз атам кабердә ятмас иде! Тәминдар дип авыз ачма, бәреп үтерәм! —диде.

Ә Тәминдар башлап үзе язмады. Язмады...»

Әйе, Сәвилә күлгә бармакчы иде, рәхмәт, апасы искә төшерде. Ул, торып, сумкасына пыяла савытлар тутырды.

Авылны чыккач, кызны бер атлы куып тотты. Ул, сизенеп, ялт итеп артына борылды. Кара айгыр! Аны Галимҗанның олы малае бәреп үтергән, имеш, диделәр авылда, әнә ич, әкрен генә юыртып чаба, арбасында яңа председатель, шулай ук Галимҗан малае, монысы төпчеге...

Сәвиләнең нишләптер тыны кысылды, сумка күтәргән кулының хәле китте. Ул, читкә тайпылып, яшь председательгә юл бирмәкче булды.

— Тр-р, Көмеш Тояк, чибәр кызны узасың,— диде егет, айгырны янәшә туктатып.

«Аны авылда мактыйлар, иплe кеше диләр. Ләкин аның тамырларында Галимҗан каны ага,— дип уйлады кыз.— Ул мине танымый, таныса, таптап үтәр иде».

— Мин — Сәвилә,— диде ул, үзе башлады.— Әтиеңнең үлемендә мине дә гаепләделәр.

— Беләм,— диде егет һәм, сикереп төшеп, арба төбенә салынган печәнне кабартты.— Утыр, чибәр кыз.

«Мин бит Сәвилә! Әллә күзең сукырмы?!,— дип сискәндереп кычкырасы килде кызның.— Мин сезнең нәселне күралмыйм».

— Көмеш Тояк, әйт инде чибәр кызга, ялындырмасын,— диде егет, шаяртып. Айгыр, чынлап та, башын чайкап кешнәп җибәрде.

«Көмеш Тояк... Чибәр кыз... Нинди төчеләнү бу! Тапкан исем! Гаҗәп, ул минем нәфрәтемне сизми. Югыйсә, мин нәфрәттән бишкә ярылырга әзер. Гаҗәп, аның күзләрендә мәкер дә юк! Күзләре якты нур белән мөлдерәмә тулган. Минем дә хаталануым мөмкин ич...»

Сәвилә сумкасын егеткә сузды.

— Җайлап урнаштыр, зинһар, әйберләр ватылмасын.

— Әллә гөмбәне урманда ук тозлыйсыңмы, Сәвилә?

— Мин күлгә барам.

— Бик шәп! Безгә юл уңае, илтеп куярбыз, әйеме, Көмеш Тояк?

«Атаңны тибеп үтергән хайванга ничек шулай яратып эндәшергә мөмкин?! Әллә аның Сәвилә алдында кылануымы?»

— Мин синең турыңда ишетеп беләм, Сәвилә.— Яшь председатель җиңелчә генә дилбегәне какты.— Әйдә, таныш булыйк. Исемем — Рияз. Үткән ел авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Өйләнмәгән, буйдак.

— Әтиең кулындагы чыбыркыны, алайса, синең кулга тоттыр-

лар? — дип көлемсерәде кыз.

— Мин, этинең малае булсам да, аның эшен дәвам итүче түгел. Эти яшәгән, эти эшләгән заман аңлаешсыз, буталчык заман. «Яңа тормыш корабыз»,— дип, алар кешелек мең еллар буе төзегән зиннәтле сарайны җимерделәр. Яңалык дигәнең гел ватудан гыйбарәт булган.

— Кемнәр җимерде соң ул сарайны? Синең этиең кебек кансызлар бит!

— Кансызлар идарә итүенә халык үзе риза иде. Сарык көтүен хәтерләтә иде бермәлне халык.

— Сарык көтүенә кушылмаучылар да бар иде. Тик алар берән-сәрән генә иде, этиеңә аларны буйсындыру бернигә дә тормады. Ул фәкать Убырдан гына шүрли иде.

— М-да, бөкре карчыктан барыбыз да шүрли идек. Аның яшәү рәвеше табигый түгел, ясалма иде. Шул нәрсә безне куркыткандыр, бәлки.

Сәвилә сагайды:

— Нинди ясалмалык турында әйтәсең, аңламадым? — диде.

— Аштан ашка йөреп, карчык-корчык белән чүкердәшеп яшисе әби йә бәддога укый-укый чишмә чистарта, йә аркасына капчык асып, урманда саташып йөри. Бервакыт, малай чак иде, бүрәнә өеме артына посып карап торам. Убыр сукыр карга тотып өенә кереп бара. Үзе мыгыр-мыгыр сөйләнә, алла ризалыгы белән күзеңне ачармын, ди, сәхрага очарсың, ди, иркенгә, ди. Нәрсә белән ачмакчы ул карга күзен, башым җитми! Ышандырмый әбинең кыланышы хет үтер! Ясалма, бер сүз белән әйткәндә!

Сәвиләнең җавапсыз каласы килмәде:

— Борын заманнарда канлы үлән белән дәвалап, сукырайган кошкортның күзен ачканнар,— диде ул.

— Әкият! Өч яшьлек баланы ышандырсаң гына.— Егет башын артка чөеп, рәхәтләнеп көлде.— Мөгаен, ул аны пешереп ашагандыр, ә? Тик менә теше үтте микән? Ике йөз ел яшәгән карганың ите каты буладыр, шулаймы?

Арбада селкенеп бару Сәвиләне болай да туйдырган иде. Җитмәсә, яшь председатель туктаусыз авыз ера. Йә җәяү атларга, йә аның мәнсез шаяртуына кушылырга кирәк.

— Бәлки яшел бавырын кыздырып ашагандыр.

— Карганың бавыры яшел буламыни? — диде егет, көлүеннән туктап.

— Әйдә, ярып карыйбыз! Әнә багана башында бер карга утыра. Тот шуны!

— Син миннән көләсең, Сәвилә.— Егет кисәктән атын туктатты.— Көләсең,— диде ул, җитдиләнә барып, аннан балчык кисәге алып каргага томырды. Кош, яман каркылдап һавага күтәрелде, тик очып китмәде, чыбыкка ипле генә килеп кунды.

— Бигрәк матур кош! — диде Сәвилә сокланып.— Чем-кара, әйе бит? Томшыгы нинди очлы. Киек-җанварларда өч нәрсә: көч, матурлык, җитезлек кешене һәрвакыт кызыктырган. Элек аучылар, болан мөгезен кайнатып, суын эчкәннәр. Мөгездәге көчне үзләренә күчермәкче булганнар.

— Һаман көләсең, Сәвилә. Йә, булды, сүземне кире алам. Убыр карганы ашамаган, дәвалап кире очырган! Әнә ул, чыбыкта тирбәлә. Син бик сәер кыз икән,— диде яшь председатель.

— Моңарчы ишетмәгән иденмени? Чыбыксыз телефон шалтырагандыр ич!

— Хатын-кыз гайбәте нишләптер колакка чалынмый. Тыңларга вакыт та юк. Күмәк хуҗалыкның зарарын үз җилкәбездә татыдык. Үңган белән ялкауны берләштереп, көчләп оештырылган союзлар

таркала. Берәү йоклап, берәү тир түгеп яшәгәндә, авылны саклап калам димә! Булдыклысы, уңганы кача бит аның җирдән, умырып эшләп тә, чеметеп алганга кача. Тегесе китми, эт ялкавы, көн үтсенгә селкенеп йөри шунда.

— Болыннарны, елга-чишмәләрне дә бүлеп таратасыңмы, Рияз?

— Анысы икенче хәсрәт. Табигать уртак, аның хуҗасы — халык. «Син ялкау, печән чапма»,— дип, Хөрмәт абзыйны болыннан куарга, «Син йокы хөрәсәне»,— дип, Сабирга елгада коенмаска кушарга безнең хакыбыз юк.

— Алайса, хуҗасыз табигатьне рәхимсез таларга мөмкин?! — Сәвиләнең йөрәгеннән әрнүле аваз бәреп чыкты. Егет аның канап торган ярасына кушучлап тоз сипте. Галиҗәнаб үләннәр иле, бөҗәкләр иле.— Адәм баласы нәрсә өзгәненә, нәрсә сындырганына хисап биреп бармаса, ялангач җир шарын кочаклап упкынга тәгәрәячәк. Дөньяга гарип-гораба туа, әшәке чир аза, им табылмый торганы... Мин, синең урында булсам, җир язмышын да, табигать язмышын да бертигез кайгыртыр идем. Әйдә, җәренгә болынны терелтәбез! Кыргый чәчәк орлыклары табабыз да, өмә ясап чәчәбез! Карчык әйтә иде, күбәләк чәчәктән ярала, чәчәк корыган саен, ул да үлә, ди иде. Күпме күбәләк очар чәчәкле болында! Әйдә, «Изгеләр чишмәсе»н дә терелтик. Чистартып бура ясыйк. Улактан челтер-челтер су агар, кызык бит!

Яшь председатель бүлдермичә тыңлады. Йөзендә үзгәреш сизелмәде. Сәвилә аңа очрашканнан бирле текәлеп карамаска тырыша иде. Нур тулган ике күздән башка, егетнең йөзендә җәлеп итәрдәй нәрсә юк иде. Җәенке борын, дугаланып тоташкан каш, кабартма ирен, маңгаена алкаланып төшкән кара чәч.

Шушы йөз, пөхтә, матур йөз, Сәвиләнең ачыргалануына әүвәлгечә битараф иде. Ул тизрәк бәхәстән качарга ашыкты.

— Болында көтү йөртмәсәң — сөт юк. Урманда агач кисмәсәң — утын. Йә — табигать, йә — кеше, икесенең берсен сайлыйсың, Сәвилә. Күсәк тоттырып, табигать сакларга каравылчы куеп булмый бит инде! Болынны кызгануың әйбәт. Әгәр, синең сыман, халыкка сөйләп бирсәм, безнең председатель акылдан язган, диярләр. Ә йодрык белән өркетәсе килми, беләсеңме.

— Абруй саклыйсың, әйеме?

— Әтине «кансыз», дип сүктеләр. Мине «җүләр» дисәләр? Мин бит инде бер урталык табарга тиеш!

Кыз арбадан сумкасын җилтерәтеп тартып алды. «Галимҗан төпчеге! Бушкуык! Сиңа тел әрәм иткән мин җүләр!»

— Сәвилә! Күлгә хәтле ике чакрым, кая барасың?! Хәзер илтәм.

— Рәхмәт, юлыңа ашык.

— Әле кичкә хәтле вакыт күп, утыр, китмә! Мин стансага җизнине каршыларга барам.

— Кемне, кемне?! — Кыз атлап киткән җиреннән сөрлегә язды. Ялгыш ишетәме әллә, кемне диде ул?

— Тәминдар җизни кайта, синең күршең.

Бу хәбәрдән Сәвилә чак егылмады. Тәминдар кайта! Ябраббем, сабырлык бир, Тәминдар кайта!..

## 7

Урта ишек ябылгач, халык, фельдшерга чират көтеп, Сәвилә янында утыра башлады. Иртән бигрәк тә хатын-кыз күп җыела иде. Сөйләшәләр, чирдән зарланалар. Чаршау артында кайнашкан Сәвилә ара-тирә аларның сүзенә колак сала, аеруча сары чәчле хатынның тавышын бүтәннәрдән аерып алмакчы була. Атна буена инде ул Сә-

кинә янына йөри, үзе авыру да түгел, сәламәт кешегә дә охшамаган. Шул хатын:

— Сәкинә апа биргән төймә белән генә йоклыйм. Иллә тәмле йоклата, көтүгә чак уянам,— дип серен ачкач, Сәвилә чаршауны этәреп хатынга карады. Яшь икән үзе, утызлар чамасы булыр.

— Апа, синең ике айлык көмәнең бар,— диде кыз.— Бүтән дару ашама? Юкса балаң гарип туар.

Хатыннарның колаклары тырпайды: бәрәч, Галия иреннән бер ел элек үк аерылды түгелме соң?

— Ашасам, синең ни эшең бар?! — диде Сары чәч, бүртенеп.— Башымның авыртуына түзеп булмагач кабам мин аны, йоклатмый аптыраткач.

— Мендәреңне алмаштыр, апа. Син чирле каз йонынннан ясалган мендәрдә йоклыйсың.

— Кит, каян беләсең? Казым чирләгәч суйдым да, йонын йолкып алдым шул.

— Син үлгән казны йолкыгансың апа. Комсызлык аздырган.

Сары чәч сикереп торды. Тынып калган хатыннарга карап:

— Нәстә бәбәкләрегезне акайттыгыз! Табам шул, табам бала, җилдән табам! — дип кычкырды. Зәһәрнең иң куесы Сәвиләгә тамды: — Әй син, тутый кош, кем әйтте үлгән каз йолкыганны. Сиртмә койрык Әлфияме? Ул гына күргән иде, чепи күз! Җиде бабасын хәтерләтәм әле чукынчыкның!

Сәвилә оеп басып торды. Их, шушы тиктормас теле! Югыйсә, Убыр күпме тукыды аңа, дәшмә, диде, кычкырма диде, башыңа каргыш яудырырлар, диде...

Медпунктка йөрүчеләр сирәгәйде. Капыл кимеде авырулар, Сәвилә моңа үзе дә бик аптырады. Дөрес, карчык-корчык сөлек салдырырга килә иде. Мактап та китә иде. Әмма бүтәннәр күренмәде. Хәзер Сәкинәнең абруй куагын җил селкетә башлаган иде инде, дару сатып көн үткәрүен беләләр иде. Фельдшерга ышанмыйлар, сәер кыздан шикләнәләр. «Чиреңне күзеңә карап белә икән, берочтан кылган гөнаһларыңны да әйтә, ди. Йә, кеше алдында йөзеңне кызартыр, алла сакласын»,— дип, күбесе Сәвиләнең күзенә чалынмауны хуп күрә иде.

Тәминдар, Тәминдар!.. Ул нәрсә дияр иде икән? Каенәнесе Риязда сыенып яткан ирнең Сәвиләне юатырдай җылы сүзе бар микән? Кайтканына өч көн, өч төн, «саумы» юк, «ни хәл» юк... Бик барыр иде Сәвилә аның янына, очып барыр иде, аягы тартмый. Югыйсә ул: «Тәминдар, нишләп кешеләр миннән шикләнә?» — дип сорар иде.

«Кеше үзе аңламаган нәрсәләрдән курка, Сәвилә...»

«Чү, Тәминдар! Без синең белән чакрым аралардан торып сөйләшәбез түгелме соң?!»

«Үзең мине эзләп таптың, үзең сорау бирдең ич!»

«Кайттыңмы, Тәминдар?..»

«Кайттым төсле, Сәвилә...»

«Нигә син моңсу, Тәминдар?»

«Сындым бугай мин, Сәвилә. Әллә нишләп, яшәүнең ямен тапмыйм. Рухым төшенке, аңлыйсыңмы?»

«Аңлыйм, Тәминдар...»

«Рәхмәт, ярый син бар...»

«Юк, юк! Мин бу авылга күчеп килмәсәм, син бәлагә тармас идең, син шат күңелле Тәминдар булып яшәр идең дә яшәр идең».

Тәминдар белән җан сөйләшсә дә, бу өндә төсле иде. Әнә Тәминдар ишек яңагына сөялгән... Коңгырт күзләрендә, чынлап та, сагыш төсмерләнә. Киң җилкәләре салынган. Ул боек, ул күңелсез...

Аны шулай бик якында, каршында гына тотар өчен, күзеңне

йомарга кирәк икән. Менә кыз чытырдатып күзен йома. Күз кабаклары авыртып кысыла. Инде ачарга ярамый, ачса, Тәминдар китәр, югалыр төсле. Кинәт, керфекләреннән сытылып чыккан яшь бөртеге аны сискәндереп җибәрә. Ул җанының елый-елый Тәминдар белән сөйләшүенә башта ышанмый, кул аркасы белән яшен сөртеп ала...

— Нигә елыйсың? — Ят, кырыс тавыш, хыялыннан аерып, ике арага кысылгач, Сәвилә башын күтәрде. Алдында Сәкинә апасы басып тора иде.— Нигә елыйсың? — диде ул, кабатлап.— Сиңамы соң бәбәгеңне юешләтергә?! Ни кайгың бар!

Фельдшер хатын дөбер-шатыр китереп шкаф тартмаларын ачып карады. Йөзе тагын да каралды. Ул бәйләнергә сәбәп эзли иде.

— Нәрсә болар? Ниткән печән чүмәләсе?

— Үләннәр, Сәкинә апа.— Сәвилә, иске шкафны чистартып, үзенең кирәк-ярагын тутырган иде.

— Бу банкада нәрсә? Әлләү, хәшәрәтләр кыймылдый!

— Сөлек ул, тимәгез!

— Сөлек!? — Фельдшер мыскыллап авызын чалшайтты.— Чыгарып ташла! Чүп-чар җыйма монда!

Хатын, җенләнеп, шкафтагы әйберләрне берәм-берәм идәнгә сыпырып төшермәкче иде, Сәвиләнең бәхете, ишектән яртылаш бөгелеп, бер ир килеп керде.

— Янам, әчем яна...

Фельдшер белән икәүләп аны сәкегә яткырдылар.

— Эчкәнсең икән, Дамир абый, ничу минем янга килергә иде,— диде Сәкинә.— Бар, хәл ал да, рөнә сыптыр.

— Янам, янам,— дип ыңгырашты абзый.— Теге кызның карасын, Сәкинә, сиңа килмәдем, кызның дим карасын, янам...

Абзый агуланган иде. Йөрәге дә зәгыйфь иде. Әнә иреннәре күгәреп чыккан. Сәвилә тиз генә ләгән алып килде, абзыйның башын идереп, косарга кушты. Эчтә агу, бәләкәй генә зәһәр агу кыймылдый. Әгәр бер генә минутка соңарсаң да, ул ашказанын теткәләп бетерәчәк. Сәкинә булышырга уйламый да, ике кулын кесәсенә тыгып, тәрәзәдән урамга карап тора. Ул моны уен дип белә.

Абзыйның укшырлык хәле дә юк иде. Сәвилә бармагын аның авызына тыкты... Борынны әчеттереп ис таралды. Чебен даруы эчкән! Их, ахмак ир, ахмак ир! Инде йөрәк тибеше дә әкренәйде.

— Ләгәнеңне түк, сасытма медпунктны! — дип бер яктан фельдшер кычкыра, бер яктан — «үләм» дип абзый ыңгыраша. Ашказанын юдыргач, кыз, йөрәккә массаж ясарга кереште.

— Күкрәген изгәнче, валидол каптыр, тинтәк! — дип мыгырданды Сәкинә. Кыз аны ишетмәде. Ул хәзер бары тик үзенә генә таянырга тиеш. Йөрәккә якынаерга ике кабырга комачаулый иде, үе белән ул аларны урталай сындырды, үе белән йөрәккә орынды. Әйтерсең, учында салкыннан бөрешеп туңган кош баласы ята иде, менә ул селкенде, менә канатын җәйде, менә тыпырчына башлады. Кызның бармаклары җылы хәрәкәт тойды...

Иртәгесен Сәвиләне авыл советына чакырдылар. Эчке тоем юлда ук куркыныч янавын сиздергән иде, өстәл артында филтәле лампа кебек кукраеп утырган фельдшерны күргәч, кыз барысын да аңлады. Чаккан! Аның янында колга буйлы хатын. Теге агайның хатыны.

— Уз, сеңлем! — диде рәис, табак битле ир. Һәм мич кырыендагы урындыкка ымлады.

Хатын кулын селки-селки Сәкинәгә нәрсәдер сөйли иде, сүзен кисәк бүлеп, Сәвиләгә ябырылды:

— Нишләттең иремне, әпчи тәре! Кирәгеңне бирәм бит хәзер! Нишләттең?!

— Утыр, Фәгыйлә.— Рәис хатынны тынычландырырга ашыкты: — Башта тәртибе белән сөйләп бир.

— Шамил Хатыйпович, алдан мине тыңлагыз.— Сәкинә сүз сорады. Ул, бәла йомгагының Сәвиләгә таба тәгәрәвен күреп, эчтән генә сөенә иде. Сөенечен яшереп тә маташмады.— Мин шаһит ул хәлләргә. Дамир, эчем яна, дип керде. Йөрәк иде аның, приступ иде. Андый чакта эчкә бәрә ул. Валидол бир, дидем Сәвиләгә, ә ул тотты да болганчык су эчерде. Дамирын әйтер идем, ир башы белән әфсентөфсенгә ышанып гомер хәтле гомер белән уйнарга ирек куя!

— Мин аны әфсенләмәдем, Сәкинә апа, ялганлыйсыз.

— Ә ниткән су эчердең соң, апаем?!

— Суның да зыяны юк.

— Алайса, нишләп Дамир агуланган?

— Анысын үзеннән сорагыз. Мин аны терелтеп чыгардым.

— Сорарсың, күзен мәңгегә йоммаса! — Хатын үзен кызгандырып еларга тотынды.— Төнлә... төнлә эчен тотып тәгәри идәндә атабыз. Нәстә ашадың дим, ашамадым ди, аптиктагы кыз яшел су эчергәние ди. Күрше Рафис машинасы белән районга илтте, үлә иде, малайгынам! Биш бала атасы бит ул, үлсә, кем сабыйларымны туйдырыр.

Сәкинә дә кара буяуны өсти торды:

— Шәт, үлгәндер дә инде, бичара...

— Судка бирәм, судка! — дип чәрелдәде колга хатын.

— Әкрен, әкрен, ызгышмагыз, — дип, өстәл сукты рәис.—Инде килеп Сәвиләне тыңлыйк.

— Сүзем юк...

— Гафу үтен,— диде Сәкинә. Аның ничек тә баш идерәсе, буйсындырасы килә иде. Ул соңгы айларда абруеның ник төшкәнен чамалый иде. Шушы кыз тез астына сукты... Җүләр кыз, сәер кыз!

Сәвиләгә җәза көткән Сәкинәнең өмете акланмады: ашказанын юдыртып, өч тәүлектән соң Дамир өенә кайтты һәм, гаебен танып, медпунктка керде.

— Минем аждаһа пыр тузынган икән, кһым... Ачуланма, олан. Син йөрәкне майлап-җайлап җибәргәч, Салиха бетчәгә сугылган идем, көмешкә тамызган ие шунда, әз-мәз тот, дип. Утынымны кисәрсең, дип эчертүе, бушлай дисеңме әллә аның. Сине тыңламадым шул, чуртым да булмас дидем дә, җиффәрдем ярты банкы. Духтыр сразы әйтте аны районда, бозык көмешкә эчкәнсең, анализ күрсәтә, дип. Минем аждаһа, кара син зәһәрне, бөтен авылны шаулаткан! Үзенә дә әләкте, ярдым тотып, бер телеңне тый, дидем.

— Ярар, абзый, ачуланмыйм. Эчкәч, миннән бүтән ярдәм сорамасин.

— Үлем бугаздан каптырса дамы?

— Тәгәрәп үл, килмә!

— Вәт сиңа брач! — Абзый башын чайкады.— Вәт сиңа брач! Үләргә куша ул, ди. Синең ачуыңны теге аждаһа күперткән инде. Җен катынын, әллә дим, тагын тукмарга микән?

— Тимә, агай, аннан ни файда?

— Тавышлы йорттан бәрәкәт кача, ди шул китап. Нәрсә күргән соң ул Фәгыйлә апаң бу дөньяда? Хет мин үзем армиядә чакта ят илләр, ят җирләр күрдем. Аның бит, олан, әйләнчек сарыкныкы төсле тормышы: өй дә ферма, ферма да өй. Утыз ел сыер койрыгы астында чүмәшеп утырган катынның эче пошадыр, шуңар тел чарлыйдыр. Авыл катыннары бары да усал, олан. Мал-туар кыйнап явызлана алар, мал-туар кыйнап. Ачу саклама Фәгыйлә апаңа.

Абзый әллә хатынны, әллә аны яклый иде, аңламады Сәвилә.

Печәнлеккә менеп йоклаган кызны апасы төрткәләп уятты.

— Тәминдар абыең кайтты, Сәвилә.

— Нәрсә, апа?!

— Тәминдар абыең үз йортына кайтты дим! Шыр сөяк. Кутәрәмгә калдырганнар ябулы йорт эчендә бичараны. Мәликә кая басканын да белми, бик сөенә. Ирсез гомер — нурсыз гомер, аерым яшәгәндә, шәт, аңлагандыр. Кайтасы да килмәгән ди Мәликә янына, каенэнесе үгетләгән, ди. Теге яшь персидәтел, Галимҗан төпчеге инде... Ачык малай, узган-барганда: «Исәнме, апа?!» дип, исәнләшеп уза.— Апасы аягын бөкләп, җайлап ук утырды.— Мин дә хәл белергә кердем Тәминдарларга. Ишегалдын бүлдергәнсең икән, ди. Әллә ничек рәнҗебрәк әйтте. Сүзен йотып кына сөйләшә. Үзгәртә икән кайгы адәм баласын! Нишләп сүзгә катышмыйсың, Сәвилә?

— Уйлап ятам, апа. Карчыкның өендә бөтен нәрсә янып беткән, ә аятелкөрси исән. Бераз читләре генә көйгән...

— Исеңә төшермә, куй әле шул хәерсез көнне! Тәминдар турында әйтәләр бит сиңа!

— Әй, апа, апа, бөтенесе дә шул хәерсез көннән башланды лабаса! Мин янып тереләдем инде, ә Тәминдар юк, юк! Ул һаман яна, ут аның җанына күчкән! Ә болай өчебез дә бәхетле кебек: ул да, мин дә, аятелкөрси дә...

— Мәликә — чая хатын, сүндерер ялкынын. Менә урман кисәргә җибәрер. Диләнке алдым, ди. Син дә печәнлектә аунап ятма, кер, нихәл Тәминдар абый диң, күреш. Артыңнан утка ташланды бит. Әзрәк күңеле булыр кешенең.

— Үзе керсен, апа. Күршедә генә ич, ерак ара түгел.

— Абау, олы башын кече итепме? Ничек оялмыйсың?!

— Мин — кыз кеше, апа.

— Бу тәкәбберлегең белән кияүсез дә калырсың әле, кызый.

— Мин алламны үзем сайлыйм, апа.

— Нинди алланы?!

— Мин яраткан кеше — ул минем аллам була.

— Тьфү! — Апасы читкә төкерде.— Аяз көнне яшен сугар, алла исемен кушып сөйләмә, юньсез!

— Син, апа, бернәрсә дә аңламыйсың.

— Аңламыйм шул, балакаем. Чуртым да аңламыйм. Холкың холыкмы соң! Ике дистәне тутырасың, ике мыскал акылың юк. Бүтәнен әйтеп тә тормыйм инде, менә шул эрекмән-кычытканнарыңны гына әйтәм. Ниемә хаҗәт алар? Җыясың да киптерәсең, киптерәсең дә эптигеңә ташыйсың. Рәхмәт ишеткәнең бармы бирәрсеннән? Акча түлиләрме сиңа?!

— Мин бүтән кешеләр кебек яши белмим, апа.

— Йөрәгемне әрнетәсең бит, бала. Мин мәрхүмә әнкәңә сүз бирдем, кеше ясармын, дидем. Сүземдә тордыммы соң инде, күр! Ирек куйдым, артык ирек куйдым, шул нәрсә генә харап итте үзеңне. Һәр адымыңны күзәтеп-барлап йөрисе булган икән, һәй, башсыз хатын! Кечкенәдән үк сәер якларың белән теңкәне корыта идең бит.— Апасы еламсырап урыныннан торды. Оегына ябышкан үлән бөртекләрен сыпырып төшерде.— Аунама печәнлектә, төш,— диде.— Әнәтерәк капкада кеше бар. Мәликә кергәндер. Сәвиләгә йомышым бар дигән иде.

Нәрсә кирәк ул хатынга? Сәвиләне күрсә йөзе карала иде. Ә бүген үзе эзләп кергән. Нәрсә кирәк? Елан кебек чагарга җай эзлиме һаман?

— Көпә-көндез йокы симертәсең икән, күршекәем!

Кыска җиңле күлмәк киеп, яулыгын артка чөеп бәйләгән Мәли-

кәнең теленнән бал тама, тик күзләре генә әүвәлгечә салкын, ягымсыз иде. Җүнлегә йөрми бу! Аңа нәрсәдер кирәк. Менә ул Сәviләне култыклап ук алды. Иң якын ахирәтемени?!

— Ишегалды сүзе түгел, өеңә керик, җимешем. Йомышым бә-әк зур.

Кыз читкә тартылды.

— Капкаларны бутамадыңмы, Мәликә апа? Өченче көн генә койма аша төкергән идең, әле төкерегең дә кибеп бетмәгәндер!

— Ярар инде, төрле чак булгандыр, күршекәем, ачуланма,— дип юмалады хатын.

— Йә, ни йомыш алайса, Мәликә апа?

— Соң йомыш дип... Үтенеч инде ул, зур үтенеч, җимешем. Син бит безнең Тәминдар белән ничекләр итеп яшәүне күрә идең. Бергә ятсак, гел стенага таба елышты ир тәресе! Җылысы юк иде аның миңа, алланың хикмәте. Мин дә бик аптырап ятканнардан түгел идем, теге ни бит ул... хуҗасы сыерын ач тотса, бичара хайван көтүдән туры абзарга кайтмый, гел читкә каера. Башлар каерылды безнең, җимешем. Җүнлегә илтмәде ул качып-посып йөрүләр. Ходай каргышы төште миңа, ничә ел иремнән аерып тотты. Картаям бит инде, җимешем. Элеккеләрне кабатлар чак уза. Кемгә кирәк миндәй карт сөяк! Хет иремне саклап, кадерләп торасы иде. Инде башкасы кирәкми, аркасын куеп кына йокласын да, хатын күреп, санлап яшәсен генә иде, шул җитә, җимешем. Кайтканнан бирле уртак түшәк җәйдерми әнәтерәк, чоланда йоклый... Бер атна чамасы әнемдә яшәп интектерде...

Мәликә хәсрәтен бер тында сөйләп чыкты. Йә, Сәвилә аларны татуландырырга тиешме инде? Булмаганны!

— Син, җимешем, сихер-михер белән кайнашасың, кешеләр сөйли әнәтерәк, ясап бир, зинһар, берәр сөйдергеч сыман нәрсәкәй!

— Ярат син ireңне, Мәликә апа. Бөтен җылыңны биреп ярат. Иң әйбәт сөйдергеч шул бит инде.

— Һәй, җимешем! Сөйләдең сүз! Мин яратып кына көпчәк майланса иде! Ясап бир, зинһар теге әйбереңне. Буш итмәм, әҗерен түләрмен. Күземә генә карап тора торган ит Тәминдарны!

Нәрсә тели бу хатын?! Нигә өзгәләнеп-өзгәләнеп ялвара? Яшәгән ич моңарчы... Күбәләк сыман чәчәктән-чәчәккә кунып яшәгән. Кодрәтеннән килгән очракта да, Сәвилә Тәминдарның күңел дөньясына тыкшынмас иде. Аның хакы юк! Мәхәббәт болай да сихердән көчле ул. Аны көчләп такмыйлар, ялварып сорамыйлар. Ул — бердәнбер ирекле, бәйсез хис. Ул, кош төсле, кунып сайрар куагын үзе сайлый.

— Син, Мәликә апа, булмастай нәрсәләр сорыйсың.

— Ничек инде булмастай? Җиде ятлар синең дәваны күрә ич! Күрше хакы өчен, бушкул борма, җимешем, кызган бичара хатынны!

Мәликәнең кыяфәте кызганыч иде. Берәр хәйлә тапмасаң, теләнеп, сoранып үзәгеңә үтәчәк ул.

— Ярар,— диде кыз.— Төнәтмә бирәм. Шуны һәр көнне өчәр тамчы эчсәң, Тәминдар күзеңә мәхәббәтле булып күренә башларсың.

— Валлаһи диң, җимешем! — Хатын җиңел сулап куйды.

— Тик бер шартны үтәргә кирәк, Мәликә апа. Үтәмәсәң — төнәтмәнең көче бетә.

— Үтим, үтим, җимешем, баш өсте! Әйт, нинди шарт ул?

— Ирeңә ягымлы бул, көл, елмай. Тупас сүз әйтмә, тәмле-тәмле ризыклар пешереп сыйла, иркәлә, юат, акча сорама.

— Чү, чү, җимешем! — Мәликә ашыгып бүлдерде: — Җитәр! Тау хәтле эш кушасың лабаса! Елмай да, иркәлә дә, акча да сорама!

— Тыңлап бетер, Мәликә апа. Иң мөһиме — ireген кысма. Ул синең ireң генә түгел, ул — кеше.

— Уф, алла, пычаксыз суясың, җимешем. Тәминдар да кеше

булдымы?

«Елан,— диде Сәвилә.— Елан! Тәминдар беркайчан да синең алдыңа тезләнмәячәк. Син әле генә мескен идең, шешә кулыңа килеп кергәч, гайрәт чәчә башладыңмы? Яратмыйсың син аны... Бәясен белмисең. Кадерен белмисең...»

Шешәне култык астына кыстырып, баскычтан төшеп барган Мәликә, янә борылып, өйгә керде.

— Әллә дим, күршекәем-җимешем, сихер шартын бераз җиңеләйтәсеңме? Ничек инде ул көн саен, минут саен иргә теш агартып елмаймак кирәк! Патша малае мәллә ул?

— Җә, Мәликә апа, кирәкми бугай сиңа төнәтмә, китер!

— Тьфү, тьфү! Елмаермын, ыржаермын алайса. Бетте, бетте!

Күзенә ак-кара күренмичә, капкага йөгергән Мәликә артыннан апасы шикләнеп карап калды.

— Нәрсә бирдең аңа, Сәвилә?

— Сөйдергеч сорагач, сиңа ясап куйган әрем төнәтмәсен бирдем, апа.

— Ник алдыйсың кешене, алла бәндәсе? Әппитит уятыр өчен бит ул!

— Шаулама, апа.

— Әрем телне әрем юа димени, кит!

— Юмаса да, басылыр ичмасам. Тәминдарга каныкмас.

— Син тагы, булышам дип, арба тартып тау менгән ир белән хатынның көпчәгенә таяк кыстырма, үзләре белер нишләсен!

Сәвилә кинәт күңелсезләнеп калды. Җанын кая куярга белмәде. Бер сәбәпсезгә эчпошу хәерлегә түгел иде: кыз, юаныч эзләп, сахрага китте. Сахраның җиле йомшак иде. Ул хәзер табигатьтә генә җан тынычлыгы таба, күңеле дә, гөл бөресе сыман, табигатьтә генә ачыла иде. Шуңа күрә ул аның таза һәм сәламәт булуын теләде. Ләкин теләк бер нәрсә, ә менә ялангач, шыксыз урман-болыннарны терелтү — икенче нәрсә. Элек болын мондый хурлыкка төшмәгән: Сәвилә аны күз алдына китерә. Бил тиңентен печән үскән анда, үлән арасында җиләк кызарып пешкән. Чәчәкләрнең исәбе-хисабы булмаган, аларның санын йолдызлар белән генә исәпләгәннәр. Авыл халкына печәнгә хәтле болынга керү, болынны таптау — гөнаһ саналган. Күңел ирексездән шул елларга тартыла. Ә үткәнгә юл бикле, үткәннәр үткәндә кала... Ә бит Сәвилә болынны элеккеге хәленә кайтару өчен күпме тырышты! Идарәгә барды, кат-кат барды, Рияз белән сөйләште. Яшь председатель аны «иртәгә кил» дип җибәрә, ул тагын бара, тагын — «иртәгә»... Ахырдан Сәвилә аңлап алды: Рияз аны юри шулай чакыра иде. Сәер кызга битараф түгел иде егет, килгән саен ул аны озаграк тотмакчы була, сөйләндерә, үзе кызыксынып тыңлый, әгәр урыныннан кузгала башласа: «Йә инде, әз генә утыр»,— дип ялына. Ничек кенә ялынса да, яшь председательгә күңеле ятмый Сәвиләнең.

Идарәгә соңгы килүендә Рияз икенче покос өлгергәнче болынга терлек-туар кертмәскә вәгъдә биргәч, Сәвилә очынып йөргән иде. «Ниһаять, миңа теләктәш кеше табылды»,— дип уйлаган иде. Ә бүген, тояк эзләреннән чуарланып беткән болынны күргәч, ул чак кына егылып китмәде. Көтү таптап узган! Шушымы егетнең вәгъдәсе!

Кыз утырып елады. Кешеләрнең әшәкелеген җиңәрлек хәле юк иде аның. Шундый бер тылсымлы көч кирәк иде хәзер.

Кызның аяк битенә чикерткә үрмәләп азаплана иде, ул елавыннан туктады, берара сәерсенеп карап торды. Чикерткә хәлсез иде, алай да үрмәләргә тырыша. Сәвилә аны учына алып салды. Тәне ак тимгелле иде бичараның. Мөгаен, ул авырыйдыр. Димәк, басуларга сиптергән агу җил белән болынга да тарала. «Мин сине ур-

ман аланына күчерәм,— диде кыз.— сусыл үлән ашап, чык тамчысы эчеп терелерсең. Ә менә йөзәрләп-йөзәрләп кырылган күбәләкләрне мин инде терелтә алмам».

Чикерткә, ишеткән төсле, озын сыйрагын корсак астына таба бөгеп, хәрәкәтсез калды.

Сәвилә чикерткәне әрекмән яфрагына төреп кесәсенә салды. Аланга хәтле башбаштак көтүчеләрне күрәсе бар иде. Нәкъ әбәт вакытында алар сыерларны «Табор» дип аталган яр буена куып китерә. Өлкән көтүче комда күшәп ятучы кара сыерга аркасын терәп, черем итә иде. Башына күлмәген япкан. Арырак, тал төбендә, ике егет кызып-кызып кәрт суга.

— Уян әле, абзый,— диде кыз, черем иткән көтүченең иңбашына төрткәләп.— Ни җаның белән йокы симертәсең! Болынны үтергәнсез бит!

Көтүче иренеп кенә күзен ачты. Кояш җылысыннан ул тәмам изрәгән иде. Сәвиләне күргәч, мыегы да селкенмәде. Була бит шундый кешеләр: каршысына аю атылып чыкса да, артка чигенми, тик карап тора.

— Кемне?!

— Болынны, дим, болынны!

— Фу, боланны үтергәнсез дип ишеттем. Бездә ниткән болан, мәйтәм, шыр урманда. Мин бер нәмәгә дә кысылмыйм.

— Син — көтүче лабаса!

— Әнә теге такыр башлар көтүче.— Абзый егетләр ягына ымлады.— Мин пинсәгә тикле ияреп кенә йөрүче. Әй, килегез әле сез, балыклар!

Егетләрнең берсе авылның калай этәче иде. Ул Сәвиләне танып авыз ерды:

— Ни йомыш, матур түти, җүләр чыпчык,— диде ул.— Ник дәшмисең? — Егет ачы итеп сүгенде.

Яшьрәге, малай кисәге, калай этәчкә ярарга тырышып шаркылдый иде.

— Җегетләр, тәмсезләнмәгез алай,— дип сүзгә катышкан абзыйга егет йодрык иснәтте:

— Тик ят, кызма, Фәһим абзый! Авызын ямап килгән бу җүләр чыпчык, сүзен әйтми.

Сәвилә, чынлап та, коелып төшкән иде. «Калай этәч»нең ертлачлыгы аны соң дәрәҗәдә тетрәндереп җибәрде. Кызлар белән шулай сөйләшергә ничек җөрьәт итә ул?! Үкенәчәк бит, затсыз...

Җил исеп куйды, кояш әллә кайдан гына кабарып чыккан болыт артына чумды.

— Рөхсәтсез-нисез болынга син терлек керттеңме? — диде кыз, нәфрәтен тыеп.

— Ну мин, матур түти, җүләр чыпчык, ну? — Егет мыскыллап ботын аерып басты.

— Рияз сезгә күл ягын биргән ич.

— Ну, ышту? Төкерәм синең Риязыңа, юеш танауга. Пред, имеш! Миңа болын ошый, ясно? Демократия хәзер. Пред та, көтүче дә тигез. Тигезлек безнең илдә! Мин шәһәрдә урам себерә идем, прафисырның арт чүмеченә дыңкылдатып типкән бар. Патамушты барыбыз да гражданин, ясно, матур түти?

— Аның кай төше матур соң, Җәмил абый? — дип хихылдады икенчесе. Оятсыз күз Сәвиләнең тәнен капшады.

— Син, маңка, хатын-кызны белмисең әле.— Егет малайның борынына чиертте.

Сәвиләгә борылып китәргә кирәк иде. Кесәсендә чикерткә кымырҗый. Аңа кысан, аңа һава җитми, ул үлән арасында сикермәкче. Ләкин кызның аяклары җиргә кадакланган төсле, куптарып булмый.

Нахакка рәнҗетелү аның җанында өермә кузгаткан, өермә көчәйгән саен җил дә катырак исә, ком бөртекләрен себереп алып һавага очыра иде. Сәвилә хәзер үз-үзен тыя алмый. Ул үз-үзенә хуҗа түгел... Аның җаны — табигать җаны, аның күзләре — болын күзе...

Кыз егеткә бер генә карап алды. Җил кинәт басылды. Яр буйлап йөгергән Сәвилә артыннан малай актыгы тизәк ыргытып калды...

Атна-ун көннән көтүче егетнең авызы чалшаер. Халык моны төрлечә сөйләр:

— Тел әшәке иде Сафа малаеның.

— Анасын аты-юлы белән сүгә иде, ана каргышы төшкән.

— Байтак кызны елатты, алдый да ташлый, алдый да ташлый иде, шул кирәк имансызга.

Бүльнистән бүльнискә йөреп чалыш авызын турайта алмаган «Калай этәч» шешәдәш дустына күз яше агызып болай дияр:

— Теге җүләр Сәвилә бозды, малай. Бер генә карады, шундук авыз турысы өшеде, сиңайтим. Иманын тарар идем, өстәп кулны да кәкрәйтер дим. Матым сүккәнне яратмады, каһәр!..

Урман аланында кыз чикерткәне үлән арасына җибәрде, иелеп, күзәтергә тотынды. Бөҗәккә бераз җан керде, мыегын алмаш-тилмәш селкетеп «төзәтенде».

Сәвилә үлән кыштырдаган тавышка башын күтәрде. Алан уртасыннан чалгы тотып Тәминдар килә иде.

9

Ул аны танымады... Җанында әрнүле хис кузгалды. Тәминдар әүвәлге Тәминдар түгел. Тәминдар бүтән иде. Ят һәм салкын иде ул. Багыре каткан кешегә охшаган иде. Төрмә шулай үзгәрткәнме укытучыны?

Кыз аның янында үзен җайсыз сизде. Әллә ничек, Тәминдар килеп туктагач та, үзен үлемнән йолып калган иргә ни рәхмәт әйтә алмады, ни «исәнме» дип кул бирмәде. Каушады Сәвилә. Ничек каушамасын, ди! Аның каршында шәүлә иде ләбаса! Шәүлә! Йа ходай, Тәминдарның күңелендә бушлык, карашында бушлык, төпсез бушлык... Аның чалгы күтәреп аланга төшүе дә — аптыраганнан, барыр урын тапмаганнан гына! Яки аны Мәликә куып җибәргән.

Нәрсә сөйләштеләр — бер генә сүз дә хәтерендә калмаган, борчак сыман җиргә коелган. Иртәгәсен кыз хыялы белән кат-кат шул аланга очып килде. Үлән кыштырдаган тавыш ишетте, Тәминдарны күрде, әмма шуннан башкасын һич тә хәтерли алмады. Хыял куркыныч бушлыкка барып бәрелә иде. Үзе дә тәкәббер инде! Якын итеп эндәшмәде Тәминдарга. Эндәшергә иде юкса. Аның салкын йөрәгенә килеп сыенырга да бозын эретергә иде. Ул бит Тәминдарга кирәк! Бик тә кирәк! Сәвиләдән дә артыграк кем аңлар аның җанын?..

Сәкинә ялда иде. Сәвилә иДәннәрне юып чыгарды, гөлләргә су сипте, кая гына тотынса да, нәрсә генә эшләсә дә, кулы калтырый иде. Ул калтырау, кинәт кенә табан астыннан үрмәләп менде дә, йөрәккә тиеп үтте. Хәерлегә түгел бу... Медпунктны бикләп авылга кайтырга кирәк. Тәминдар ишегалдында ниндидер уй корып йөри... Нәрсә майтармакчы ул? Күзләре пыялаланган... Төсе качкан... Чайкалып атлый... Бау алды... Нишлисең, Тәминдар?! Ярабби, акылыңа кил! Кайда син, Мәликә?! Мәликә! Коткар иреңне, Мәликә!

Кыз медпункт баскычына сөяп куйган велосипедына ничек утырганын да, җиде чакрым араны ничек узганын да белмәде. Сорасалар — вакыт исәбен дә, чакрым озынлыгын да хәтерләмәс иде.

Апасы капка төбендә иде. Аның шомлы сүзләре йөрәк әрнүен

көчәйтте генә.

— И балам, укытучы абыең асылынган ие бит! Мәликәсе күреп баудан төшергән. Бер исәбенә керсә, харап итәр инде үзен! Атасы да шулай үлде аның...

Хәле киткән кыз чирәмгә ауды. Бәла узган алайса... Их, Тәминдар, Тәминдар! Челтерәп аккан чишмәләре, сайрар кошлары белән сокландырган якты дөньяга кул селтәү — ахмаклык! Моның өчен батырлык кирәкми, нибарысы куркаклык җитә. Нәрсә этәрде сине бу адымга, Тәминдар?! Нәрсә?

— Апа, мә, велосипедны кертеп куй.

Сәвилә Тәминдар йортына таба атлады. Капка шар ачык. Тавыш-гауга тынган. Мәликә ире асылынырга дип элгән бауны балта белән тураклап ташлаган, ишегалдына сибелгән сүс җеп җил белән шаярып уйный. Ә Тәминдар, бәхетсез Тәминдар, арыш капчыгы төсле, баскычка ишелеп төшкән. Аяк табышларын ишетсә дә, ул күтәрелеп карамый. Аңа барыбер...

«Юк, ашыкма, Тәминдар... Минем җанымнан агылган дулкын тиздән синең җан белән очрашыр... Башыңны күтәр... Миңа кара... Менә әйбәт... Минем күзләр сине чакыра, тоясыңмы? Әлбәттә, тоясың, кадерле кешем... Чигәң кысмыймы инде?.. Авыр уйлардан арындыңмы?.. Сиңа рәхәт, әйеме?.. Бас, бас... Гәүдәң мамык төсле, шулаймы?.. Син кош бит, Тәминдар... Кош син!.. Әнә сиңа канатлар үскән... Җилпе канатыңны... Хәзер капкадан чыгабыз да кыр ягына очабыз... Очабыз, очабыз, Тәминда-а-ар!..»

Ир ничек торып басканын сизмәде. Аяклары таушалган гәүдәсен капкага таба сөйри иде. Ул чынлап та кош икән! Әнә алар, басу уртасыннан салынган тар сукмакка җиткәч, җирдән аерылып, оча башладылар. Алда — Сәвилә, зәңгәр күлмәкле кыз бала... Канат җилпегән саен, күкрәк читлеге йомшарып, сулыш алуы җиңеләя бара... Нинди рәхәт очу! Аңа бу халәт таныш та кебек. Әйе, әйе, балачакта, бер кайгысыз, бәхетле малай чакта, ул шулай оча иде. Аяклары җиргә тими иде аның. Ул аруның нәрсә икәнен белми иде... Менә тагын беркатлы малай чагына әйләнеп кайтты! Югыйсә, чама белергә вакыт... Аның бу кыланышын күрсәләр, бот чабып көләчәкләр. Икенче көнне авылга: «Тәминдар акылдан язган»,— дигән хәбәр таралачак. Тик нишләптер туктый алмый ул. Сәвилә белән куышып оча да оча, оча да оча!.. Мәңге-мәңге кош булып биеклектә каласы иде... Мәңге-мәңге... Нинди рәхәт! Чү, теге аланга борылды кыз... Ул түбәнәя, кыйгачлап шунда төшмәкче бугай...

Аяк табанын йомшак үлән кытыклады. Тәминдар исенә килде. Сихерләп ни ара йөгерткән кызны ачуланмакчы иде, Сәвиләнең риясыз, җылы карашын тоеп, дәшмәде, чабылган үлән кебек җиргә ауды. Җанын биләгән караңгы бушлык кимеде төсле... Инде тәгәри-тәгәри елыйсы килә... Ләкин ир кешегә балавыз сыгу килешми. Бәгырь каткан, ташка әверелгән, ул таш һаман күкрәкне изә... Нишләргә, нишләргә?!

— Ела, Тәминдар?

— Нәрсә?!

— Ела, дим...

— Син әллә минем уйларымны да укыйсыңмы? Убыр түгелсеңдер бит, теге безнең авылның?

Сәвилә аның баш очына утырды. Бармакларын Тәминдарның бөдрә чәчләренә тидерде.

— Синнән сорыйм! — диде Тәминдар, боерып.

— Сора, сора! — диде кыз.— Мин барыбер сиңа җавап бирмәм, Тәминдар! Мин үземнең кем икәнемне белмим, үтер, белмим, Тәминдар.

— Кулың йомшак,— диде Тәминдар.— Песи баласын гына шулай иркәлиләр.

— Тәминдар... Ни булды сиңа, сөйлә...
— Яшәрлек көчем калмады, акыллым.
— Җаның авыру икән синең, Тәминдар,— диде кыз.— Чирең куркыныч икән...
— Һәрхәлдә, рак түгелдер ич! — Укытучының сүзләрендә кинаяле көлү сизелде.
— Рак күзәнәкләрдә була, Тәминдар, җанда бүтәне аның... Бир әле кулыңны.

Кыз Тәминдарның учына текәлде.
— Әйтеп бар, нәрсә таптың анда,— дип көлемсерәде ир.
— Менә яшәү сызыгы, Тәминдар... Озак яшәрсең, өч тапкыр асылынсаң да үлмәссең, бау әрәм итмә.— Монысы шаярту иде.— Картаеп үләрсең, үз түшәгеңдә. Акыл сызыгың да озын, тирән, Тәминдар, аны бер генә тамга да чуарламый, фән кешесе булырсың киләчәктә... Имән бармагыңның нигезендәге калку җир артык күпереп тора, гафу ит, бөдрә чәчләрең коелып, түбәңә ялтырап кояш чыгар... Аның каравы, алда бәхетле юл көтә сине. Ул моңа кадәр ирешмәгән теләкләреңә таба сузылган... Тик син ул юлга бик газапланып кузгалырсың...
Сәвилә тиз генә аның бармакларын бөгеп, кулын этәрде. Чү, Тәминдарны җентекләп өйрәнә башлады түгелме соң?! Ярамый болай, ярамый. Бу ир мәңге ачылмаган сер булып калырга тиеш. Белгән хәтлесе җитәр, әйе, җитәр! Уч төбендәге язмышны алдан белүнең ни кызыгы бар.
— Йә, дәвам ит, нигә туктадың әле?
— Булды, җитәр...
— Каян өйрәндең кулдан багарга? Кем өйрәтте?
— Белмим... Мин бернәрсә дә белмим... Сорама, зинһар!
— Шайтан алгыры! — Укытучы янә кулын баш астына кыстырды.— Кызык бит, ә! Синең юл юравың кызык дим! Кая таба диң әле! Ирешмәгән теләкләргә таба! Шәп! Ул теләкләр күптән җилгә очты инде, Сәвиләкәй! Институтны тәмамлагач, аспирантурада укыйсы егет идем мин. Студентларга лекция укырга хыяллана идем. Тиле, буш хыяллар! Профессор агай үзе күндергән иде аспирантурага, «Син фән кешесе булырсың, синдә талант һәм омтылыш зур»,— дигән иде. Аспирантурага сайлап алганда минем кандидатура үтмәде: бер бушкуыкны калдырдылар. Ул әрсезләнеп, мескенләнеп яулады бу урынны. Имеш, фән өчен, халык өчен янып йөрүче бердәнбер студент икән. Хаклык өчен көрәшкәндә аны гел кыйнаганнар, имеш. Хәтта профессор да аңа аяк чалырга маташа, аны аспирантурага үткәрми, үз кешесен әзерли, имеш. Ә бит андый мескеннәрне нишләптер җәллиләр. Чынлап та, талантлы иптәшкә юл бирмисез икән, дип уйлыйлар.
— Син аның бушкуык икәнен белеп тә дәшмәдеңме?
— «Ул хаксызга рәнҗетелгән кеше түгел, ул битлек кигән бәндә!» дип исбатлап кара, бар! Аның ягына баскан төркем сытып үтәчәк сине, ул гынамы — дипломыңнан мәхрүм итәчәк.
— Әле сиңа соң түгел, Тәминдар.
— Нәрсә соң түгел?
— Өр-яңадан башларга кирәк, аңлыйсыңмы?
— Гайсә яшен узып барам бит инде, акыллым.
— Ирләр илле яшьтә генә өлгерә. Җитмештә картая.
— Ә мин утыз дүрттә картайдым. Үзең әйтеп торасың, ич, пеләшләнәсең дип!
— Җаның сау булсын... Яшьтәмени хикмәт. Җансыз калган гәүдәнең ташка әверелүен, шәт, таң алдыннан сизәсеңдер. Йоклаганда җан гәүдәдән очып чыга бит. Кеше таш кебек катып кала. Ә җан

каядыр очып китә, ниндидер юллар урап кайта, нәрсәдер күрә. Ул күргәнне төш дибез инде... Җаның кире гәүдәңә кайтып иңгәч, аяк-кулларыңның «дерт» итеп селкенеп куюын тоясыңмы? Тән һәркөнне шулай үлеп терелә, Тәминдар...

— Саташасың син, акыллым. Матур гына гәпләшеп утырганда килделе-киттеле сүзләр сөйләп ташлыйсың. Ләкин, шайтан алгыры, рәхәт миңа сине тыңлавы! Билләһи, рәхәт! Үземнең дә синең кебек саташып йөрисем килә!

Укытучы, малайлар кебек, мәтәлчек атарга керешә, аннан туктап аланны яңгыратып көлде.

— Иртәгә дә чакыр мине, яме?

«Мин чакырмасам да, аякларың үзеннән-үзе тартып китерер, Тәминдар»,— дип уйлады кыз.

## 10

Кайчагында әкияткә дә ышаналар икән. Нәкъ әкияттәге кебек бәхетле азак көтә адәм баласы. Аның янына дәва эзләп килүчеләр шундый төргә керә иде. Башта алар берән-сәрән генә күренә башлады. Сәвиләнең «белекче» дигән исеменә «күз буяучы» дигән дан да өстәлгән иде. Соңгысын, тырыша-тырыша, Сәкинә таратты.

Бүген дә аның килешенә медпункт ишегалдын кеше чуарлаган. Сәвиләне көтәләр... Ә Сәкинә һаман шул гадәтен куа икән: баскычка чыгып баскан да, кулын селки-селки авыруларны битәрли:

— Кем янына килдегез, аңгыра сарыклар?! Шырлатан бит ул, күзгә төтен җибәрүче! Андыйларны элекке елларда җыеп атканнар!

Сәвиләне күргәч, гөберле бака кебек кабарынган хатын, шапылдатып ишекне япты. Ишегалды тынып калды. Кыз эшкә тотынды. Төркем өстеннән күз йөртеп чыгу белән, ун кешене сайлап алып, чирәмгә тезеп утыртты. Калган бише — сау-сәламәт, «могҗиза» күрергә теләүчеләр генә иде. Ул аларга китәргә кушты.

Баядан бирле кыбырсып йөргән бер чая хатын, сорап та тормыйча, унберенче булып чирәмгә төртелде.

— Кума әле, наный. Безнең могҗиза күргән юк ла! Күрик бер! — диде ул, күзләрен елтыратып. Һәм терсәге белән күршесенә кадап алды: — Хәзер сиңа миең черегән дисә, нишлисең, Дамира? Шәлеңне сатасыңмы миңа, җүнгә генә? Башыңның авыртуы хәерлегә түгелдер, үләргәдер ул.

— Яшәү — үзе могҗиза,— диде Сәвилә сабыр гына.— Нигә аны эзләп йөрергә? Синең өеңдә дә биш балаң — биш могҗизаң бар. Тик алар ач утыра. Кайтып аш пешер, апа,— диде.

Чая хатын җиргә сеңде. Ник әйткәненә үкенгән сыман, учы белән авызын каплады. Ләкин аның каушап калуы озакка сузылмады, ул:

— Сөйләгән ие аны духтыр Сәкинә, бер мәгънәсез дип, хак икән,— дип, чәчрәп аякка басты. Чирәмгә тезелешеп утырган авыруларга төртеп көлде: — Карагыз, кара бу томаналарны! Сезне төп башына утырткannар, торыгыз, тор! Ул сездән акча суыра, ялганлап, алдалап, мисезләр!

Хатынның әче тавышы урамның икенче башында да яңгырап торды...

Сәвиләнең зиһене болай да чуалган иде. Кемгә генә караса да, кем белән генә сөйләшсә дә, уйлары Тәминдарга таба йөгерә... Йа алла! Нишләде соң алар кичә? Әйе кичә, төнгә каршы, урман аланында? Юк! Моны күз алдына китерү түгел, уйлавы да оят. Нигә оят, нигә оят?! Шул тиклем зур гөнаһка баттымыни алар? Бүтәннәр өлешенә үрелдеме? Юк, юк... Дөньяда үлемсез өч нәрсә бар: табигать, җан, мәхәббәт. Ахырзаман җитеп, дөньяның асты-өскә килсә дә,

туфракта яңадан орлык шытар, үлән үсәр. Ә яшеллектә, һичшиксез, тере җан иясе яралыр. Ә җан яралгач, анда мәңгелек хис туар. Ул хис — мәхәббәт дип аталыр.

Әнә Тәминдар да аны уйлый... Уйлый Тәминдар. Көтә, юксына. Ә көн — чамасыз озын, төн — чамасыз ерак... Ир газаплана: кичәге төн тагын кабатланырмы, юкмы? Кабатланмаса? Учагың сүнсә? Йолдызлар да кыска гомерле ич, атылып сүнә. Мәңге янмый, мәңге балкымый...

Әлбәттә, ул төн кабатланмас, Тәминдар! Бернәрсә дә кабатланмый дөньяда! Икенче очрашу сине йә бәхетле, йә бәхетсез итәр. Хисләр йә сүрән, йә көчле булыр. Шуңа һәр күрешүнең кадерен белергә кирәк, Тәминдар!

Сәвилә көчкә Тәминдарга бәйле уйларыннан арынды. Аны күңеленнән куды.

Авырулар өмет белән аңа карый иде. Җилдә тирбәлгән чәчәк сыман әкрен генә селкенеп утыручы карчыкка ул дәва тапмады. Соң иде, чире азган иде. Яман шешне Убыр өйрәтүе буенча гына җиңәрлек түгел иде.

Кыз, әбине озата килүче ир белән хатынны бер читкә чакырып, пышылдады:

— Кадер-хөрмәт күрсәтеп, әниегезнең күңелен күреп калыгыз, аның актыккы көннәре җитә,— диде.

Ир дә, хатын да рәхмәт әйтмәделәр. Йөзләрен болыт сарды. Яман хәбәргә, гәрчә ул дөреслекне ачса да, рәхмәт әйтмиләр. Сәвилә моны белә, шуңа күрә рәнҗеми. Әбине ике ягыннан култыклап торгыздылар. Сәвиләнең күзләре яшьләнде.

Унөч яшьләр чамасындагы кызны Сәвилә чиратның иң ахырына куйды. Кызның ике кулы да терсәктән югары күтәрелгән һәм шул хәлендә катып калган иде. Әнисе әледән-әле аның кулына япкан җәймәне рәтләп куя, ә җил аны җилфердәтеп өскә күтәрә.

— Ирең белән тату яшәмәгәнсең, апа,— диде Сәвилә, алар өчәү генә калгач.— Ул пычак белән сиңа ташланганда, ике арага кызың керә...

— Шулай, шулай, балам,— диде хатын, гаҗәпләнеп, башын селкеп раслады.— Каян белдең син моны, и ходай?! Күрше авылдан бит без, ерак торабыз. Җеннәрең хәбәр сала мәллә?! Ике тапкыр өстемә пычак белән килде аждаһа ир, дөрес балам! Ни суймады, ни рәхәт яшәтмәде, эчә ул, ыстырам эчә. Кызым гына жәлке. Кыз бала, гомере кимсенеп үтәр... Берүк мәрхәмәтеңнән ташлама. Актык сыерымны сатып түләрмен.

— Акча диясе булма, апа!

Сәвилә кешеләргә күтәрелеп карарга да читенсенгән кызга кагылмады, гел читтән генә күзәтте. Кул куркудан күтәрелгән... Курку кызчыкны мизгел эчендә тораташ иткән. Ни генә юк бу дөньяда... Тагын кемнәр белән очраштырыр язмыш Сәвиләне, кемнәрне каршысына китереп бастырыр?..

Ул, ана белән кызны ишегалдында калдырып, янбакчага чыкты. Аннан, ымлап кына хатынны үз янына чакырды.

— Апа, хәзер тиз генә авылыңа кайт та, кызыңның классташ малайларын җыеп кил. Мәктәп директоры булышсын, аның эрҗәле машинасы бар.

Кайгыдан мие томаланган ана: «Нигә?»— дип төпченмәде, шунда ук авылына ашыкты. Төштән соң мәктәп директоры мәйданчыкта футбол типкән ун бөртек малайны медпункт ишеге төбенә китереп бушатты. Сәвилә аларны, тиз генә кызчык күзеннән яшереп, медпункт артына качырды.

— Мин классташыгызның күлмәк итәген күтәргәч, дәррәү каршына йөгерегез,— дип, кат-кат аңлатты. Ул икеләнмәде. Барсы

да Сәвилә уйлаганча барып чыгачак. Кул төшәр. Хурлыгы да бетәр. Кызчыкның иң гарьләнә торган чагы, аңа унөч яшь... Аны массаж белән дә дәваларга мөмкин иде. Сәвилә ничек тә әмәлен табар иде. Җаны кире какмый бит бу баланы, «җеннәре» булышырга әзер. Димәк, өмет бар. Ләкин кызчыкны икенче мәртәбә ышандыруы кыен булачак. Аның күңелендә, һичшиксез, малайлар алдында мыскыл иттергән апага карата нәфрәт туачак...

Ул кызны «Йөреп кайтабыз»,- дип урамга әйдәде. Әкрен генә медпункт почмагына таба юнәлделәр. Анда ун малай, ун пар күзен тасрайтып көтеп утыра. Аларга кызык. Алар аңламый, олыларның чираттагы бер шаяртуы дип кабул итә.

Сәвилә тамак кырды. Шартлы сигнал: әзер булыгыз! Һәм кисәк кенә кызның күлмәк итәген күтәрде. Каршыга көлә-көлә малайлар атылды...

— Ай! — диде кыз бала һәм, чыryйлап, ялангач ботларын капларга үрелде... Куллары белән үрелде! Аңа кушылып Сәвилә дә ыңгырашты. Тагын башлана! Күз алдын томалап тагын кара пәрдә шуып төшә! Ярабби, ничек түзәргә соң бу авыртуга?! Кемдер чигәсен телеп-телеп алган кебек. Бу — түләү, түләү! Һәр авыруның чирен дәвалаган саен язмыш, үчеккән төсле, аны нечкә кылдан уздыра, тиктомалдан гына газаплы баш өянәге кузгала иде. Ул кояш баеганга кадәр бетми, укшыта, костыра.

— Китегез, кит,— диде кыз, тирәсендә бөтерелгән шәүләләрне кугалап. — Калдырыгыз мине. Китегез, зинһар!

Сәвилә чытырдатып рәшәткәгә ябышты. Түзәргә кирәк, түзәргә! Түзәрлек әмәлең калмаса, әнә, җиргә ятып ауна, чирәм йолкыййолкый ела, язмышыңны каһәрлә. «Нигә мин бүтәннәр сыман гапгади тормыш корып яши алмыйм икән? — дип өзгәлән... Тик үкенергә ашыкма, ашыкма! Әгәр син Җан дигән серле дөньяның могҗизалы ачкычын карчыктан алып калмасаң, Тәминдарны күптән югалтыр идең. Ә бит аны терелтүче син! Син — белекче кыз!.. Аһ, башның сызлавы! Бәгырьгә үтә... Тукта, аны коткарса, уй гына коткарыр. Ә Тәминдарны уйлап юанудан да татлырак нәрсә бар?! Әйе, ул аны терелтте... Газиз анасы бу кешегә кайчандыр бер яшәү сулышы өрсә, Сәвилә икенче сулыш өрде... Шуннан бирле Тәминдар йөрәккә бигрәк тә якын! Ул Сәвиләнеке, бары тик Сәвиләнеке генә. Җанының бер өлешен дә күчерде ич кыз аңа! Хәзер ул беркемгә дә бирәчәк түгел кара сагыштан йолып калган кешесен! Әйдә, килешми дисеннәр, оятсыз, дип сүксеннәр... Ул бит яратуны үзе сорап алмады... Аларны язмыш очраштырды! Кирәк икән кушсын, кирәк икән аерсын — барсы да язмыш иркендә. Мәхәббәт, таң кебек, барыбер туар иде. Бәлки ул теге чакта ук уянгандыр әле. Теге чакта... Кыз яңгырга коенып биегәндә Тәминдар аңа ничек карады?! Әйе, теге чакта... Серле иде Тәминдарның карашы... Ара да якын иде. Тәминдар белән Сәвиләне нибарысы яңгыр тамчылары гына бүлеп тора иде... Ниндидер затлы көч саклаганмы әллә аларны? Бәлки, бәлки...

...Бу юлы да ике арада киртә бар иде. Еллар ята иде сузылып. Тик ир аны сизмәде... Аланда биюче кыз сурәте хәтерен яндырып үтте. Татлы, бәхетле мизгелләр кире әйләнеп кайтты...

Төннең кара буявы урманга җәелгән иде. Алар, сабый балалар кебек кулга-кул тотынышып, Нәзергә табан атладылар. «Кулың нинди кайнар...»,— диде Тәминдар, кызның бармакларын учына кысып. Сәвилә җавап бирмәде. Ул бәхетле иде. Тик бу хакта кызның Тәминдар хәтле Тәминдарга да белгертәсе килми иде. Ә күңел нәрсәдер тели! Күңел мөлдерәмә тулы! Чайпалдырып сагышын түкмәкчеме ул?! Әллә шушы ирнең күкрәгенә сыенмакчымы?

Су тавышы аны айнытып җибәрде. Ул үзенең әрсезлегеннән бик оялды. Ике бите ут сыман кызышты. Ничек Тәминдардан

кулын тартып алуын, ничек ярдан елгага сикерүен белмәде, салып ташлаган күлмәге тигәнәккә эләгеп калды. Артыннан укытучының:

— Сәвилә! — дип кычкырганы ишетелде.

Су чәчрәтеп йөзеп киткәч кенә тынычланды ул. Бака яфракларын изә-таптый, Тәминдар да яр астына төште. Әһә, йөрәге ярылды! Сәвилә бата, дип курыкты.

— Сәвилә, су салкын, чык! — диде ир.

Ай нуры ком бөртеген табарлык итеп бөтен яр буйларын яктырта. Чык, имеш! Ул бит инде аланда биюче сылу кыз түгел... Утта пешкәннән соң җәрәхәтләре ямау-ямау булып төзәлде. Хәзер тәне корама юрган төсле.

— Чык дим!

— Башта күлмәгемне алып кил...

— Синеке яр башында, чык, икәү эзләрбез. Мә, үземнекен бирәм...

— Ыргыт!

— Юк инде, әүвәл ярга чыгып бас. Йә монысын да агызырсың.

— Алайса күзеңне йом.

Зур күлмәк эченә чумган кызны кинәт Тәминдар кочаклап алды.

— Тәнең дә кайнар икән,— диде ул, сулышы белән колак яфрагын кытыклап. Сәвилә кире тартылмады. Аның киң күкрәгенә йөзен яшерде. Аңа рәхәт тә, ямансу да иде. Менә шулай гомер буе сыенып басып торсаң иде! Ай, язмыш! Нигә ул һаман яңа сынаулар әзерли икән?! Алда Сәвилә юл күрә ич... Озын-озын юл. Тәминдар китеп барасы юл бит инде ул! Якын кешесенә бакмаска дип үз-үзенә сүз биргән иде, хәзер, юк-юк та, шөбһәләнеп аның күзләренә карый... Ул күзләрдә ярату да, хәерсез юл да бар. Икесе бергә! Ләкин алар тигез түгел: юл мәхәббәттән көчлерәк. Икесенең берсен сайлаганда юл җиңәр, ул Сәвиләне Тәминдардан аерыр.

— Кайнар, кайнар син, Сәвилә! Минем моңарчы хатын-кызны болай яратып кочаклаганым юк иде...

— Дәшмә, мин беләм,— диде Сәвилә, ирне сагайтып.

— Нәрсә беләсең?

— Юкка суларга салып агыздыммыни күлмәкләреңне! Син авыру, син хатының белән йокларга сәләтсез идең.

— Акылсыз кызый! — Тәминдар аны кочагыннан ычкындырды. Аннан, уфылдап, ком өстенә сузылып ятты. Үпкәләде. Ирлек горурлыгына тиде.

— Ачуланма, Тәминдар...

— Ярар, ачуланмам. Билләһи, сәер син.

«Нигә сәер, нигә? Яратуның тәмен тоймыйча дөньядан китәргә хакың юк синең! Шуны искәргән өчен мин сәер, мин акылсыз, әйеме, Тәминдар?» — дип өзгәләнде Сәвилә, ләкин күңелендәге ярсуын тышка чыгармады. Иелеп Тәминдарның маңгаеннан сыйпады. Шуны гына көткән сыман, ир аны үзенә тартты һәм, шашынып, ачык муеныннан үбәргә тотынды.

— Әгәр тәнемне уятучы син булсаң, ә? Бердәнберем булсаң? Нишләрбез соң, акыллым, ничек түзәрбез? — диде ул, киңәш сораган төсле.

— Карчык баккан иде аны... Синең насыйбың миндер, Тәминдар...

— Әле соң түгел, нәкъ вакыты, куып җибәр мине...

— Юк, юк! Карчык әйтте бит, дәрте вә гыйшкы белән сиңа хатын-кыз якынаер, диде. Мин, ул, мин!

Нәрсә аңласын Тәминдар! Карчыкның ни дип юраганын беләмени ул?! Әнә үзе куарга куша, үзе кайнар сулышы белән исертеп үбә, иркәли. Көчең җитсә, арала җаныңны мәхәббәт давылын-

нан, кодрәтле ир! Ирек куйма хисләреңә. Сүндер учагыңны, сүндер дә көлен тузгытып ташла.

Тәминдар аның күлмәк изүен ачты. Әмма... кагылмады. Таза, сау-сәламәт тәне башка тән белән табигый бербөтенлеккә омтылганда, тыелып калу авыр иде. Йокымсыраган күзәнәкләрне уятып тыпырчынган теләген ул ничек тә басарга тырышты, кызны күтәреп алып яр өстенә менгезеп бастырды, күлмәген табып кидерде.

— Кем син? Фәрештәме, изгеме? — диде Тәминдар, кайтыр юлга чыккач.

— Син моны сорадың инде, Тәминдар,— диде Сәвилә.— Белмим дидем бит, белмим...

...Әкрен генә кара пәрдә артка шуышты. Кыз, керфекләрен күтәреп, офыкка карады. Кояш баеп бара иде. «Рәхмәт, Тәминдар,— диде Сәвилә, уй белән юаткан иргә,— рәхмәт...»

Сәкинә апасы китмәгән иде.

— Нәрсә, үзчирең тотамы? — диде ул, мыскыллап.— Теге ниөянәгең. Яшермә, яшермә! Тәрәзәдән күрдем, баядан бирле башың тотып, калтыранып утырдың. Медпункт яныннан күпме кеше узып йөри, хурланмыйсың да әзрәк. Өянәк чире синдә, кадерлем.

— Юкка борчыласыз, Сәкинә апа, сез куйган диагноз дөрес түгел.

— Синеке генә дөрес инде, ә! — Фельдшер хатын һөҗүмгә күчте. Аның бүген иркенләп талашырга иде исәбе.— Җитәр, кадерлем! Медпункт янында халык җыеп кәмит уйнавыңнан тукта! Жалоба белән районга барачакмын. Мин — дипломлы белгеч! Барыбер кудыртам сине эштән!

Эштән куылу, әлбәттә, күңелсез хәл иде. Апасы кызганыч. Тагын: «Дөньяга сыймыйсың»,— дип елар. Тик бу хатынга горур башыңны иеп: «Кумагыз»,— дип ялвару да артык.

— Ихтыярыгыз,— диде кыз, бәхәсне озайтып маташмады, чыгып китте. Аланда аны Тәминдар көтә иде, ул шунда ашыкты. Ләкин, урман авызында Рияз очрап, юлы бүленде.

Очраклы гына күрешкән кебек кыланса да, урман хәтле урманда Рияз аны бер-бер максат белән көтә иде, әлбәттә.

— Нихәл, Сәвилә?!

— Минем хәлне урманга килеп сорашмасаң да ярый,— диде кыз, салкын гына.— Сөйгән кызыңны көнләштерерсең.

— Юк бит әле ул.

— Булыр, булыр.

— Кайчан?

— Җаның кайчан тели инде.

— Әгәр ул сине теләсә?

— Мин бүтәннеке,— диде Сәвилә, егетне шаккатырып. Аның кистереп «бүтәннеке» диюен ишеткәч, Риязның йөзеннән кан качты.

— Йә, шаяртма! — диде ул билгесез тарафка бармак янап.— Безнең өлешкә кем тия анда, башын кисәм! Син минем көчле канат астына сыенырга тиеш, Сәвилә.

Егет уйнап сөйләшми иде. Ул үзенә бик нык ышана иде.

— Рәхмәт, мин көчле канатлар ярдәменә мохтаҗ түгел, Рияз.

— Мохтаҗ булырсың, ашыкма. Сиңа кырын карыйлар, җүләр диләр, күрмисеңмени?!

— Минем тирәдә буталган егетне дә җүләр димәсләр микән соң?

— Сине дә, үземне дә якларлык көч табармын, авызлары тиз капланыр,— ди яшь председатель эре генә.

Урман юлыннан атлап киттеләр. Аз гына баргач, сул якта — тар сукмак. Аланга таба илтә. Ә сукмакның теге очында Тәминдар кө-

тә. Менә шулай: юлында очраклы кешеләр очрый да, син томырылып үтәсе күпме сукмаклар ятим булып читтә кала.

Рияз аяк астындагы ботак-санакны типкәли-типкәли барды. Ул ачулы иде. Сәвиләнең караңгы чырай күрсәтүе аны бик гарьләндергән, күрәсең.

— Сиңа атап махсус дәвалау йорты салдырырмын,— диде ул.— Рәхәтләнеп сеанслар уздыр. Акча эшлә, кесәңне калынайт. Күзгә Казанга алып барырмын. Зур белгечләрдән баш миеңне тикшертербез.

Кыз сабырлыгын саклап әйтте:

— Ул сүзләреңне кире ал, мин акчага дәваламыйм,— диде.— Әнә, серен ачам дип, кеше табигатьне нишләтте? Күкрәгеннән ярып, йөрәгеннән алды. Бүген аның сулышы кысыла, кан тамырлары кибә.

— Кара әле, җанкисәк,— егет, атлаган җиреннән туктап, кызның алдына чыгып басты да, мыскыллап: — Куй шул табигатеңне,— диде.— Кирәкми ул миңа! Шушы минутта нәрсә теләгәнемне сизмисеңмени?! Билгеле, түләп, бушлай димим.

Ярабби, тагын ниләр күрәсе бар икән! Нинди хурлык, нинди түбәнлек! Ул шушы бәндәгә тәнен сатсын, имеш.

— Тимә миңа! — диде кыз йөрәкләнеп.— Юкса, юкса... Кара айгыр синең дә башыңа җитәр!

— Менә монысы булмастай эш.— Яшь хуҗа шаркылдап көлде: — Кара айгыр аранны җимереп качты. Ни эзләтеп тапмадым. Хәзере белән инде. Ул айгыр югалганнан гына колхоз бөлмәс әле. Ирек ярата иде бичара хайван.

«Бичара хайван?..» Ә нишләп «Көмеш Тояк» түгел? Алдаша! Кара айгырның җан дулап иректә чапкан көннәре узган иде инде, ул үз хәленә ияләшеп, күнегеп бара иде.

— Сине дә ярата иде кара шайтан. Кил, күрсәтәм ничек ятратканын.— Сәвилә читенергә дә өлгермәде, Рияз аны биленнән эләктереп куак ешлыгына таба сөйри башлады.— Карышма, барыбер урталай сындырам,— дип колак төбендә мышнаган егетнең тимер кебек салкын бармаклары тәненә орынуга, гәүдәсенең куырылып килүен сизде кыз, тик кочактан суырылып чыгарга көч тапмады, ботакка эләгеп күлмәк итәге ертылгач кына исен җыйды: кулын Риязның күкрәгенә терәде. Бу каршылык егетне ярсытып кына җибәрде. Ул корбанын җиргә күтәреп салырга дип кулларын бушаткан арада, Сәвилә бер читкә сикерде. Тагын күлмәге ботакка эләкте, аны ычкындырам дигәндә генә үзе дә абынып егылды. Тагын сикереп торды, аннан каядыр йөгерде, йөгерде... Ферма янында аран сүтеп маташкан картның күзләрендә үзенең сурәтен күргәч кенә иманеп китте: күлмәге ертылган, чәчләре тузган, тез башлары канаган...

— Кара айгыр качмаган,— диде кыз, шаккатып үзенә карап торган ат карауч белән сөйләшкән төсле.— Аны иткә озаттырган Галимҗан малае. Мин бит беләм...— ул сөйләнә-сөйләнә җиргә чүгәләде.— Мин бит беләм... Җаным әрни, җаным елый шуңа... Әбекәй, кайда син? Ишетәсеңме? Кулларымны күккә сузып ялварам, ишет мине... Мин бүген беренче тапкыр кеше каргыйм, мин Галимҗан төпчеген каргыйм, түзә алмыйм, әбекәй, гафу ит, түзә алмыйм!

Кинәт күк йөзендә, болытларга кушылып, карчык шәүләсе шуып үтте сыман. Ул да түгел, ялларын тузгытып Кара айгыр чапты...

Кыз башын күтәргәндә ат карауч карт, куркуыннан балтасын ташлап, фермага таба йөгерә иде.

Капка төбендә Мәликә җенләнә.

— Кая гына олакты шул пошмас! Тәминдар абыеңны күрмәдеңме, Сәвилә? Аңа бит прафиссыры хат язган, чакыра бит, тиз, ди. Иртүк юлга җыенсын иде, пошмас.

«Ул аланда»,— димәкче иде кыз, телен тешләде. Алан — Тә-

миндар белән икесенең яшерен почмагы. Анда өченче берәүнең аяк эзләре төшмәскә тиеш.

Ярты төн уртасында ул сискәнеп, төш күреп уянды. «Илаһи көч! Син бармы? Барлыгыңны расла»,— дип күккә ялвара, имеш. Һәм аны кемдер югары күтәрә, күтәрә, күтәрә... Кыз түбәсе белән йоп-йомшак болытларга орынганын тоя, Ә аста... аның Тәминдары. Кулларын сузган да, төшкән уңайга кочаклап алмакчы. «Кил инде кил»,— дип ялвара үзе...

Сәвилә, төш белән саташып, йокылы-уяулы хәлдә караңгы ишегалдына чыкты. Иңрәеп күккә карады. Чынлап та, баш очында гына, гөмбәздән аерылып, ап-ак болыт кисәге эленгән иде. Кыз җиргә чүкте, пышылдап әйтте: «Син бар, бар,— диде.— Син минем яраткан кешем, син — Тәминдар»,— диде. Аннан, куркып, сынын турайтты. Илаһи көч тегендә, югарыда, болыт артында... Ә Тәминдар җирдә, койма белән бүленгән йортта. Аларны буташтырырга ярыймы соң?! Саташу лабаса бу! Саташу гынамы, тилерүнең азагы! Барыбер, барыбер Тәминдар — илаһи көч. Үзенә табындырган, баш идергән икән, әлбәттә шулай! Әнә ул, болытка әверелеп, аның караңгы төнен яктырта.

Сәвилә капканы ачты. Йотылып тыңлады. Авыл йоклый иде. Күңеле аланга тартылды. Мөгаен, Тәминдар көтәдер, йөрәк болай авыртып чәнчемәс иде. Ир дә, аның сыман, ябалак тормышына күчте.

— Мин сине кич белән бик озак көттем. Төн буе да көтәр идем, хушлашмыйча ничек юлга чыгасың,— дип, каршылады аны Тәминдар һәм ипләп кенә имән төбенә түшәлгән чәчәк мендәренә утыртты.

— Дөнья без уйлаганча гына бармый икән, Тәминдар...

— Нишләп акыллым?

— Болай гына әйтүем.— Кыз ромашкаларны капшады.— Син әллә болындагы бөтен чәчәкне җыйдыңмы? Ой, йомшак икән! — Ул күзләрен йомып чалкан ятты.— Әнә теге ак болытны өстемә юрган итеп яп хәзер...

— Исәр болыт ул, төн белән көнне бутап йөри.

— Син ул, Тәминдар...

Ир аны ишетмәде, шул мәлдә генә җил имән яфракларын шыбырдатып алды.

— Яңгырга көйли,— диде Тәминдар иснәнеп.— Һава дымланды. Сәвилә, мин синең белән әлегә саубуллашам, озакка китәм бит, өч атнага.

— Саубуллашыйк алайса...

Тәминдар аның янына елышып ятты.

— Нигә тавышың бик моңсу, Сәвилә?

— Китәрсең дә югалырсың кебек...

— Җүләркәем, нишләп югалыйм ди. Шәһәрдә адашыр дисеңме әллә?

— Юк, җанымнан югалырсың дим. Иң куркынычы шул бит аның.

— Ә син сакла мине, акыллым. Югалта күрмә, оныта күрмә,— Тәминдар тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, туктап калды. Күрәсең, артык нечкәреп китүдән курка иде. Ә хатын-кыз йөрәгенә башкача ничек үтмәк кирәк, Тәминдар! Чама хисен белеп кенә сөйлә син, сөйлә. Синең ихлас сүзләреңне тыңлавы рәхәт!

Ак болыт соры болыт белән аралашкан иде. Алар бер-берсенең тән җылысын тоеп яттылар. Нигә бу кадәр якын соң шушы ир? Нигә, нигә?! Гомер аның белән узган төсле. Әле башланмаган гомер.

— Сәвилә...

— Дәшмә, Тәминдар, төнне уятасың. Әнә офыкта ак сызык сузылды, тиздән таң атар.

— Шуңа күрә мин дә ашыгам. Хәлләр үзгәрергә тора бит әле монда. Хат килде, мине чакыралар. Юл диган, идең, рас икән. Барып-күреп кайтсам... сине дә алып китәм, калдырмыйм...

— Ә Мәликә апа? Хатының?

— Булмады инде, яшәп карадык бит.

Әйе, әйе, яшәп карадылар, әйе! Барып чыкмады, уңмады, Тәминдар.

— Белмим шул.

— Нәрсә белмисең? Мине ничек акылдан яздыруыңны белмисеңме? Син дип шашам бит инде.— Ир аны үбә-үбә тәмам куенына сеңдерде.— Синсез яшәп кара хәзер...

Ромашка таҗларының тәненә сыланунн тойды кыз, ул үзе дә шул чәчәкләр арасында эреп таралды бугай...

## 11

«Хуш, сау бул, Тәминдар, исән-сау йөреп кайт... Мин сине авыл башына хәтле генә озатмакчы идем, бер хатын юлымны кисте. Баласы авыру икән. Менә ул сабый белән яр буена төштек (җилкәмә утыртып төштем), икәү комда кызынабыз. Ә мин, ничарадан бичара, кояшта янам...»

Сәвилә кызчыкның баш түбәсенә япкан эрекмән яфрагын рәтләп куйды. Август кояшы рәхимсез кыздыра иде. Эссе коры һава тынга каба, йөрәкне әлсерәтә. Их, баш-аяк белән суга чумасы иде. Ул күптән Нәзергә сикерер иде, кызчыктан уңайсыз: бала түзгәнне, Сәвилә дә түзәргә тиеш.

— Мин бая Тәминдар белән сөйләштем, ишеттеңме? — диде кыз, олылар белән сер бүлешкән кебек.— Тәминдар беләсеңме кем? Минем яраткан кешем. Мин — аны, син әниеңне сагынырсың. Тик син алай ук ямансулама, аппагым! Терел генә, тәпи-тәпи басып өеңә кайтырсың. Кешеләр калыр өчен килми белекче йортына, китәр өчен килә. Әниең юкка пырылдады синең, әйе бит? Хәтерлисеңме ул көнне?

...Капкадан керүче хатын капчык итеп аркасына бала аскан иде.

— Уф, үләм, синдер инде белекче,—диде ул, сәлам дә бирмичә.— Яшь нәстә дигәннәрие, иртән генә тотарсың, аннан җеңгә әверелеп урманга кача, җен-убырлардан сабак өйрәнергә дигәннәрие, качмый тор берүк, көмешем.

Тәминдарга кул болгарга да өлгермәде ичмасам! Нинди үкенеч.

— Ярар, апа, әкият сөйләмә,— диде ул, бераз ачуы чыгып.— Сез үзегез дә җен-убыр сыңары. Юлда килгәндә каккалап-суккалап баргансың оланыңны, кулың каты икән. Кызыңны иплап баскычка утырт. Әнә чүпрәк өстенә.

— Имчәк баласы түгел лә, җиргә бастырам, алты яшь аңа, көмешем.

— Мине тикшермә инде, яме, апа! Кызың йөрми бит.

— Әстәгым! — Хатын кабаланып кызчыкны баскычка аударды.— Бер карау белән чиреңне әйтә дигәннәрие, әстәгым! Унөч чакрым җәяү тыкырдауларым бушка түгел, алага шөкер. Бәргәләп алдым шул чак-чак кына, көмешем, ардым ди, әнкәсе армаганмы! Туганнан бирле йөрми ул, идәндә күте белән генә шуыша. Аппармаган бүлнис калмады, аптыраш инде, җәдәш.

Сәвилә баланың йөзенә иелде. Җитен чәчле кызчыкны сырхау тәмам боектырган иде. Ул, үзен кимсеткән дөньясына үпкәләгән төсле, күпертмә иреннәрен бүлтәйтеп, каш астыннан гына карый, ни көлми, ни еламый. Күрәсең, үз хәленә күнеккән, олылар нәрсә генә эшләсә дә риза. Сәвилә аның күлмәген салдырып, йөзтүбән әйлән-

дереп яткырганда да карышмады. Бигрәк ябык үзе, кабыргалары беленә. Сәвилә кызның аркасы буйлап бармагын йөгертте. Умыртка сөяге тере иде. Ул капшанган саен бала, кытыкланып, иңбашларын җыера, монысы да күңелле хәл, димәк, бу тирәдә яшәү уты сүнмәгән әле. Ә аяклар өметсез иде. Сәвилә бака тәне кебек салкын балтырны чеметте — кайтаваз сизелмәде, табан астын кытыклады — сабый селкенмәде, хәрәкәтсез ятты... Җиде кат тиреңне агызырга кирәк иде бу авыруны аякка бастыру өчен, атналар, айлар кирәк иде. Ул Сәвиләнең күпме кадерле вакытын алачак... Бәлки, миннән булмый, дип кире борыргадыр? Әнә, Сәкинә апасы ничек җиңел котыла иде: «Миннән булмый, районга барыгыз!» Әйтүе генә ансат шул...

— Калдыр, апа балаңны. Август азакларында килерсең.

Сәвилә тирәсендә чебеш саклаган тилгән кебек бөтерелгән хатын тигез җирдә сөрлегеп туктады:

— Нәс-тә?! Калдыр дисеңме? Юк! Өшкер, төкер, өр-сыйпа, ну хәзер үк терелт баламны. Мин кодрәт иясенә килдем, ничу!

— Бусагамда сатулашып торма, апа, бар, кит. Мин шушы минутта ук әмәленә керешәм.

— И җен мәсхәрәсе! Күрәләтә нигә җәзалыйсың мине! Йөрәгемнән өзелгән бит ул, бала бит ул, ничек ят бусага төбендә калдырып китим ди! Аллам сакласын, әйдә, кызым.

Кулын сузып сабыйга үрелгән хатынны Сәвилә җилтерәтеп урамга куып чыгарды:

— Яхшылык белән әйткәнне аңламыйсың икән, апа. Бер айсыз күземә күренмә!

Ул, кызчыкны юатып, күкрәгенә кысты.

— Елама, сабыем, кояш ызба кыегына күтәрелгәч, елга буена төшәрбез. Синең аякларыңны кайнар комга күмеп тотарга кирәк. Бәхетеңә бу ай эссе булыр. Елама, сөрт яшьләреңне!

Әнисен куган апаның изге ниятенә күбәләк җан ышанды бугай, бүтән борынын мышкылдатмады. Күренеп тора: сабый акыллы иде. Җүләрне дәвалауның файдасы юк, аның зәгыйфь акылы һәр нәрсәне кирә кага. Тагын бер ачыш ясады Сәвилә: гарип-горабаның акыл үсеше шактый югары була икән. Ул дөньяны күреп-йөреп түгел, уй аша таный. Аның бар энергиясе уйга җыелә. Ә уй уйлый белгән кеше — дәрәҗә, ул — шәхес.

Сәвилә бирелеп, кызчыкны дәвалый башлады. Дәвасы бик катлаулы иде: көндез комда тоту, кичен эссе мунча ләүкәсенә яткырып умыртка сөяген уу, баштан алып табанга хәтле массаж ясау, аннан үлән төнәтмәләре, бармак белән тәннең яшерен нокталарына тәэсир итү, кыскасы, санасаң сан җитмәс кебек иде. Хәзер, бернигә карамыйча, канны кайнарлатырга кирәк! Әчке тоем шулай әмер бирә... Бөтен хикмәт канда. Ул суына икән — тамырлары кибә, адәм баласы әкрен генә үлемгә таба юнәлә... Әгәр кан даими кайнарлыктан төшмәсә, кеше сиксән-туксан ел гына яшәр идемени, аның гомере өч тапкыр озаер иде.

Вакыт узды... Вакыт узуын ул Тәминдар киткән көннәр белән генә исәпли иде.

Унберенче көнне эштән куылып кайтты. Теләгенә иреште фельдшер хатын, куды. Сәвилә әзерләгән үлән-тамырлар, сөлек салган пыяла савытлар кадерсез булып медпункт ишегалдында ауный иде. Кыз Сәкинә апасы белән әрләшмәде, моның көчсезлек билгесе икәнен аңлый иде. Дөньяда кимсенеп яшәүче хатын бит ул фельдшер! Ә андый кешеләр явыз була. Шул явызлыгы аркасында алар үзләренә күпме зыян китерә: явызлык, көнчелек, зәһәр тел организмда яшәү өчен кирәкле мөһим күзәнәкләрне үтерә, дөресрәге «ашый» бара. Әйе, табигать синең әшәкелегеңә күз йоммый шул, үч ала.

Уникенче көнне апасы, кыенсынып кына:

— Сеңлем, көчим микәнни?..— дип яулык очын бөтерә башлаган иде, кыз: «Көч, апа»,— диде, ризалашты. Аның Әстерхан агае белән кушылып, ата-баба нигезендә яшисе килүен күптән чамалый иде.

Унөченче көнне, ниһаять, Тәминдар әйләнеп кайтты. Бу шатлыктан кыз тилерә язды. Әмма биек койма артындагы йортта аның нинди исәпләр корып йөрүен белергә ашыкмады. Якын кешенең күңелендә шымчы кебек казынуның мәгънәсе юк иде. Барысы да, тартышмыйча, үз җае белән хәл ителсен. Тәминдарның «китабез» диюләре дә, хатыны белән арасын өзүләр дә... Мәхәббәттә кеше кол булмаска тиеш. Тик язмыш кына усал шаяртмасын, аны Тәминдардан аерып бәхетсез итмәсен.

Сагынган кешесе кул сузарлык арада гына яшәсә дә, төннәрен кыз аланга барды. Очрашу, күрешү урыны — алан иде. Ә Тәминдар күренмәде, Тәминдар һаман кичекте...

Бер кичне апасы, йөрәкне шомландырып:

— Алар җыена,— диде.

Кемнәр «алар»? Тәминдарлармы? Нигә «алар»? Ул бит бераүгенә! Берәү, берәү, берәү! Кулына сыңар чемоданын тотып килеп керәчәк ул Сәвиләләргә, килеп керәчәк тә: «Әйдә, киттек»,— дип әйтәчәк! Зурдан кубып әйбер җыюның, әйбер тотыруның һич кирәге юк. Нигә шундый билгесезлек белән газаплый соң ул Сәвиләне?! Нигә аланга килми?! Әгәр инде күңел дөньясын тәртипкә салыйм дисә, өч көн вакыт җитмимени?! Кайтканына өч көн, өч төн ләбаса! Сәвилә бит аны минутларны саный-саный көтте... Әллә авылдан китмәскә уйлаганмы? Булмас, булмас! Юл бар, юл еракка сузыла. Бәлки, чакырып сөйләшергәдер үзен? Анлык кына көч бар. Теге чакта буйсынды ич... Баскычтан куптарып алгач, урманга хәтле икәү очтылар. Теге чакта, теге чакта... Теге чакта ир кайгы боҗрасы белән уратылган иде. Хәсрәтеннән тәмам боеккан иде, аңа Сәвилә бик кирәк иде. Ә хәзер аңа кыз кирәкми, кыз артык. Һәрхәлдә, җан шулай сизә. Җанның туктаусыз сулкылдап торуы да тикмәгә түгел. Аның җаны ялгышмас...

Үзеңнең артык икәнеңне белгәч, нинди сөйләшү-аңлашу ди! Әнә, үзе белән бергә туган горурлыгы койма ярыгыннан да карарга кушмый. Көчләп ярattырмыйлар. Мәхәббәт исемле бөек хис каршында да түбәнлеккә төшәсе юк Сәвиләнең...

Әйе, теге чакта рухы имгәнгән ирне ул терелтте... Моңа дәрте җитәрлек иде. Гомер буена җитәрлек иде бу тылсымлы дәрт! Үлгәнче яратып, үлгәнче табынып яшәрлек иде. Алай-болай горурлыгын җиңгән очракта да ул хәзер Тәминдарга якынаюдан курка иде. Тәминдар бүтән, мәңге үзгәрмәячәк бүтән! Бер төнне Җаны, күпме җибәрмәскә теләсә дә, гәүдәдән аерылып каядыр очты. Таң алдыннан гына кайтып керде ул. Сәвиләнең бөтен тәне авыраеп китте. Димәк, агач-куакларга ышкылып-бәрелеп,урман-кырлардан Тәминдарны эзләгән... Тапмагач, өзгәләнгәндер. Юкка бу тиклем сызланмас иде бит... Акыл гына акылсыз әнә, ирнең ят кешегә әверелүенә ышанмый. Акыл нинди беркатлы! Ул Тәминдарны хыянәт итмәс, дип уйлый. Әгәр хыянәт итә калса, төкер син аңа, ди. Сиңамы соң, табигать баласына, мескен иргә табынырга, ди! Акыл яратуның нәрсә икәнен беләмени?! Җан белән тән генә белә яратуны...

— Ызбаларын саткан Мәликәләр. Күрше авыл кешесенә, җүн генә хакка. Сөтеп апкитәр, ди,— Тәминдар тереклек иткән дөньяның хәбәрләрен өйгә апасы ташый.— Калада фатир сыман куыш бирәләр икән, кечтек кенә бүлмә шунда. Анысына рәхмәт, ди Мәликә, куана. Тора-бара Тәминдар дәүрәген сорар әле, ди. Тиз кил дип чакырган ди прафисыр дусты. Аның бит килеш-килбәте дә мужикныкына охшамаган, Тәминдарны әйтәм. Партфил генә тотып йөрердәй. Тирес

түгеп, сыер асрап яшәмәс шул, прафисыры чакыргач.

— Ул бәхетлеме, апа?

Апасы, гаҗәпләнеп, сөйләвеннән туктап калды. Бу сорау аның башына сыймый иде.

— Кем?!

— Синең күршең... Тәминдар.

Аһ, исемен әйткәндә дә үзәк өзелә!

— Ә-ә, ниткән бәхет ул тагы? Шуны уйлап утыра ди! Ду китереп җыеналар дим бит.

Атна-ун көн үтте, нишләптер Тәминдарлар кузгалмады. «Прафисыр» хатыны булып, кала урамнарында түш киереп йөрергә хыялланган Мәликәнең ачуы йортка гына сыярлык түгел иде, ул Сәвиләләргә кереп елады.

— Иртәгә дә иртәгә, ди, һаман суза. Энем Рияз әйберләрне төяп стансага озатырга дип көн дә машина җибәрә. Чистый җәфалады ир тәресе! Үзе авызына су капкан диярсең, дәшми. Көннәр буе идәнгә сузылып йөзтүбән капланып ята-а! Ир диген инде шул хайванны!

— Тукта әле, Мәликә, эчәк-бавырларын хәсрәт таламый микән?

— Әй, Сәрвәр апа, сөйләмә юкны! Каладан балкып кайткан кешенең ниткән хәсрәте булсын! Ике көн туктаусыз көлде, шаярды ич ул. Аннан капыл йомылды. Әллә дим, Сәвиләне кертәсеңме? Тыңлатыр мужыт. Әнәтерәк, сихер суы белән мине дә кеше ясады бит. Яныма ятмаса да, «хатын» дип әйтештерә бит хәзер Тәминдар...

Юк, юк! Дан баскычыннан үрмәләгәндә, комачауламасын дип, бер аягы белән мәхәббәтенә типкән иргә Сәвилә сүз табалмас. Андый чакта эндәшмиләр бугай. Әрнүдән йөрегеңә кан укмашса да, түзәләр.

Тик менә бердәнбер күреп яраткан кешеңнең «китәм» дигәндә китмичә бәгырьне телеп, үзен искә төшереп торуы коточкыч зур газап иде. Кыз әрнеде. Кайнар комга капланып үкси-үкси елаганда бер генә сүз пышылдарга кирәк иде юкса: «Кит! Кит! Кит!!!» Әмма моны әйтүгә караганда йөрәгеңне ярып алуы җиңелрәк иде. Үз ирегең, үз теләгең белән ничек Тәминдарны җаныңнан куарга?! Ничек, йә ничек? Ул синең мәхәббәтеңне дан-шөһрәткә алмаштырган тәкъдирдә дә! Ярабби, сихергә бирелмәгән бердәнбер нәрсә — ярату икән... Куа алмый Сәвилә, булдыра алмый...

Ул уйлар пәрәвезендә чәбәләнгән көннәрдә кызчык та көйсезләнә иде. Сәвилә сагышы дулкын аша аңа да йога, бала ирексездән әнисен юксына башлый. Нәзернең яр буйларына, әйтерсең, ком түгел, сары сагыш сибелгән. Кызчыкка аягына басар өчен тагын берәр атна комда аунарга кирәксә дә, Сәвилә вакытны кыскартмакчы булды.

— Тал селкенә, күрәсеңме, сабыем,— диде ул, җиде-сигез адымдагы таллыкка ымлап.— Әниең көтә сине анда, бар, йөгер!

Кызчык, күзләрен мөлдерәтеп, таллыкка карады. Елаган аваз чыгарып шыңшып куйды. Бер яктан курку, икенче яктан әни тарта иде.

— Әйем, апа, егылам.

— Алайса, торма, утыр.

Бераздан Сәвилә кулларын чәбәкләп кычкырды:

— Әниең китә! Каласың!

Кызчык мүкәләп торып басты, аның сыйраклары яңа туган бозаунык кебек дерелди иде. Хәзер йә атлап китә ул, йә баскан килеш катып кала. Аннан барысын да өр-яңадан башларга туры киләчәк...

— Әни-и! — диде сабый һәм, куркуын җиңеп, алпан-тилпән таллыкка табан теркелдәде: — Әни-и, ал мине!

Көннәр тоташ яңгырга күмелде... Урман-кырлар белән беррәттән сагыштан боеккан күңелгә дә көз төсе иңеп бара иде. Апасы күчте. Сәвиләнең риза-бәхиллеген алып, үз нигезенә күчте. Китә-

селәр — китә, каласылар кала торган исәп-хисап ае иде бу. Моңсу ай иде. Ниһаять, Тәминдар да кымшанды. Аю сыман өненнән чыгып, яңгырлы иртәдә машина әрҗәсенә җиһазларын төяде. Инде кузгалдык дигәндә генә, җәяүле кеше дә атлап үтәрлек чокырга кереп баттылар. Төшкә хәтле өч таза ир машина этте, чокыр тигезләде. Көпчәк алыштыра-алыштыра әбәтне уздырдылар. Олы юлга җитәрәк машина моторы сүнде... Ә күзге яңгыр чиләклап койды да койды.

Тәминдар үз гомерендә беренче мәртәбә ачы итеп сүгенде. Төсе качкан чыраен болыт сарды. «Аның эше! — дип мыгырданды ул.— Аның сихере! Күз алдына килеп йөдәткәне генә җитмәгән, инде юлга аркылы төшә, җибәрми! Күпме түзәргә була! Болай да үтерде бит, төшкә кереп саташтырды!»

«Кая барасың?»— дип, кулына ябышкан хатынны ир бер читкә селтәп атты да, кызу-кызу атлап авылга таба китте. «Аның эше! Җанны суырды, җелеккә үтте! Аның эше-е!»

Эчтә дөбер-дөбер ачу кайный иде. Ул капканы да, ишекне дә тибеп кенә ачты...

Лачма су булган Тәминдарны күргәч, Сәвиләнең сулышы кысылды. Шушы ирне, күкрәгеннән ут алып терелткән ирне, танырлык түгел иде: корбанына сикерергә әзерләнгән ерткыч җанварга охшаган иде ул, күзләре нәфрәт белән ялтырый иде.

— Нишләп җанымны тотып торасың, җибәр! Тотма, җибәр! — диде ул, кыргый тавыш белән. — Әйе, мин сине алып китәм дидем, артыгын лыгырдап ташладым. Ә анда һәр адымыңны тикшерәләр икән, буялмаган паспорт кирәк, буялмаган мөнәсәбәтләр! Синең дөнья түгел анда, авыл да, урман да, алан да түгел! Шәһәр, цивилизация, аңл...сыңмы?! Хатын аерып, авторитет югалтсам, төкерәчәкләр миңа!

Сәвилә дәшмәде. Йа алла! Тәненең һәр күзәнәген назлап уяткан Тәминдармы соң бу? Кайда соң аландагы Тәминдар, кайда?!

— Их сине! — диде өзгәләп ташларга җитешкән ир.— Их сине! «Кем син?»— дип сорый идем әлек, хәтереңдәдер. Сихерче икән син, сихерче!

Ят сүз кызны сискәндереп җибәрде. Кем диде ул, кем диде? Сихерче дидеме?!

Тәминдар үзе артыннан ишекне япмыйча калдырган иде, яңгыр тамчылары белән аралашып, тыштан салкын җил ажгырып керде. Сәвилә дерт итеп куйды. Яшиселәр бар бит әле, алда яшиселәр бар. Ул яшәр. Ул җирдә бер тапкыр яшәп китте бит инде... Убыр кыяфәтендә йөз ел яшәде. Тик аны аңламадылар. Әлбәттә, аны хәзер Убыр дип уйламыйлар, чөнки башыңны ташка бәрә-бәрә исбатласаң да, җанның бер тәннән икенче тәнгә күчүенә ышанмаячак кешеләр.

Көннәрдән бер көнне аның Сәвилә дигән исеме онытылыр, кушамат кына чабуына ябышып калыр. «Сихерче килә! — диярләр.— Сихерче!» Әмма берәү дә җанны Тәминдар кебек үк телеп кычкырмас. Чит-ятлардан бу сүзне ишетүе мең өлеш җиңелрәк булыр:

— Сихерче-е-е!..

1982—1989

# ӘДӘБИ МИРАС

*Танылган татар әдибе — прозаик, шагыйрь һәм тәрҗемәче Мәҗит Рафиков (1925—1986) исеме укучыларыбызга яхшы таныш: аның «Илһам авазы», «Безнең авыл мәктәбе», «Былбыл Хәбир чишмәсе» кебек лирик повесть-хикәяләре, истәлек-очерклары, мәкаләләре һәм, ниһаять, шигырьләре үзе исәндә «Казан утлары» битләрендә дөнья күрде, күп әдәбият сөючеләрнең мәхәббәтен яулады.*

*Бу санда тәкъдим ителә торган шигырьләр әдип иҗатының һәм биографиясенең укучыга таныш булмаган яңа якларын ачар дип уйлыйбыз: алар 1950—1955 елларда — авторның Сталин төрмәсе һәм лагерьларында булган авыр чорында язылып, шәхес культы тудырган тоталитар режимга нәфрәт хисе, илдә хаклыкның җиңүенә зур ышаныч белән сугарылганнар. Башка әсәрләреннән аермалы буларак, М. Рафиковның бу шигырьләре рус телендә язылганга, без аларны тәрҗемәдә бирәбез.*

## Мәҗит Рафиков

### Алар өчен юк мин...

Тоткын өстендә
Уйныйдыр камчы,
Мине — тоткын дип
Уйлыйдыр сакчы.

Ә мин монда юк,
Белми ул сакчы;
Мине кыйныйм дип,
Кыйный бушлатны.

Бушлат эчендә —
Тире дә сөяк.
Еракта минем
Шигъри йөрәк:

Өйдә ул, әйе —
Гаиләм белән,
Иректә йөргән
Гадиләр белән.

Хаклык эзләүче
Бөркетләр белән,
Исән калачак
Өметләр белән...

Мин түгеллекне
Күрми «янычар».
Аңа шул җитә:
«Номер» бармы? — бар.

*Январь, 1953*

### Өйрәт, илем

Күкрәгенә башым куяр идем,
Туган Илем — газиз әнкәем.
Беләсе иде синең күңелеңдә
Нинди яшерен уйлар икәнен...

Гаҗиз булып, син дә рәнҗисеңдер
Явызлыкка, Тәкәбберлеккә...
Өйрәт, Илем: ничек итеп сине
Алып чыгыйк икән хөрлеккә?!

*Февраль, 1953*

❀

*Минем «эш»не яңадан карауларын сорап язган үтенечемне өченче тапкыр кире кактылар...*

Сезнең кулда гаскәр, титул, чиннар,
Ялагайлар, ялган зур даннар.
Кремль сезгә — кунакханә.
Ә соң
Нигә минем урыным — зинданда?

Алып булып күренмәкчеме сез
Җилкәсенә басып халыкның?
Үзегез җинаятьче булган өчен
Кичермисез бит сез хаклыкны!

*Апрель, 1953*

❀

Әй пассажир, тыңла колак салып,
Узган чакта тайга урманын:
Ишетелер, бәлки,
Юл салганда
Түгелеп калган йөрәк җырларым...

*Сентябрь, 1953*

**Ш. Магизов** тәрҗемаләре.

❀

Сөйләмәгез! Сүз, дип, сүз куерту
Каян килеп безнең мәсләк булсын?!
Әйтсәң сүзне — әйт син: шул сүз өчен
Баш китсә дә үкенмәслек булсын!

*Январь, 1953*

## Өмет исән әле...

Үтелмәгән юллар... Шактый әле
Ачылмаган серләр шулай ук.
Бар да исән, өметләр дә исән,
Ләкин, дускай... ирек кенә юк.

*Апрель, 1953*

## Чыкты кояш, качты болыт...

Чыкты кояш, качты болыт,
Җир тоелды җәннәт булып.
Кояш! Синең көчне тоям —
Син дип яши бөтен дөньям!

Тик әйт миңа, әйт син, кояш,
Нигә җирне каплый күз-яшь? —
Төрмәләрдә сына сулыш,
Илләр буйлап дулый сугыш,
Бүре булып кайгы улый,
Ятимнәр һәм толлар елый...
Җырым! Син дә кояш булчы,
Бәхет көткән халыкларга
Кояш кебек юлдаш булчы!
Чыксын кояш, качсын болыт,
Җир тоелсын җәннәт булып...

*Март, 1953*

## Укытучыма

*М. Г. П. га*

Чәчәк бүләк итсәм, ул чәчәкләр
Шиңәр бер көн, уңар төсләре.
Җырым булсын бүләк! Аларда бит
Йөрәгемнең сулмас хисләре.

Чын ярату белән уяттыгыз,
Уйнаттыгыз күңлем кылларын.
Искә алсам Сезне — гел җыр эзлим,
Чәчәк эзли һәрчак кулларым...

*Сентябрь, 1953*

## Бакча

Кем өчендер бу бакча — кошлар җыры,
Кем өчендер бу бакча — акча чыңы.
Ә син, дускай, җаныңа хәл җый монда,
Тын гына искә төшер бакчачыны.

*Сентябрь, 1953*

❁

Уйлама да, сөйләмә дә калганын,
Иң яман эш — остазыңның ялганы!

*Август, 1954*

❁

Юлбашчыларның һәммәсе
Күз өстендә каш түгел.
Тын гына дәшми торганның
Барсы да юаш түгел...

*Май, 1953*

**Нияз АКМАЛ** тәрҗемәләре.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Альберт Хәсәнов

# ҖИДЕГӘН ЧИШМӘЛӘРДӘ — ҖИДЕ УЛАК...

Безнең якларның саф сулы, мул сулы, теш сындырырдай салкын сулы чишмәләре турында нинди генә җырлар юк?! Хәтта өлкән прозаигыбыз Гомәр ага Бәширов та:

> ...Җидегән чишмәләрдә җиде улак,
> Челтер-челтер ага көмеш су.
> Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
> Шул чакларда бигрәк ямансу,—

дип язды, гомер эчендә иҗат иткән бердәнбер җырын чишмәләргә багышлады. Халык авыз иҗатындагы бу төр җырларны исә һич санап бетерерлек түгел.

Тагын шунысы да бар: чишмәләр чылтырап аккан урын безнең халыкта изге җирдән саналган. Ару-талуны белмичә, һәрчак алга, зур дәрьяларга ашкынучы чишмәләр халык аңына, аның күңеленә ышаныч, тугрылык, сафлык-пакьлек, мәңгелек символы булып сеңгән. Кеше үзенең көндәлек тормышын чишмә суыннан башка күз алдына да китермәгән. Картлар чишмә буйларына килеп гыйбадәт кылган, тәңрегә рәхмәтен белдергән яки үтенечен ирештерергә тырышкан. Яшьләр чишмә буена уенга, матур җырлар җырларга җыелган, чишмәләрне шаһит итеп, бер-берләренә вәгъдә биргәннәр: ташлашмаска, онытмаска, хыянәт итмәскә! Бу матур йолалар кая киткән соң? Бу юлы мин чишмәләребезнең бүгенге хәле турында сүз кузгатырга җыенам. Сүз кузгату гына аз, чаң кагарга ниятлим. Сүзләрем, бәлки, кайберәүләргә ошап та бетмәс, әмма эндәшми кала алмыйм.

Моннан берничә ел элек Иркутскида совет һәм япон язучыларының, галимнәренең очрашуы булды. Безнең яктан — алты, японнар ягыннан җиде вәкил катнашты. Бу вакыйга тарихка «Байкал ярларында очрашу» булып кереп калды. Һәр ике як вәкилләре бер-берләрен дөньяның төрле почмакларында табигатьне саклау мәсьәләләренең торышы белән таныштырдылар. Бүгенге көндә җир шарында иң коточкыч мәсьәләнең берсе булып эчәргә яраклы су запасларының кимүен, зур кризис якынлашуын расладылар, шушы турыда бөтен дөньяга чаң сугуны кирәк таптылар. Бу кытлык Көнбатыш Европада үзен бүген аеруча нык сиздерә. Су! Су! Су! Бер йотым су! Ирен тел чылатырга бер кашык су! Мәсьәлә безнең каршыга әнә шундый коточкыч киерен келәге белән килеп басарга тора.

Бу хәлдән ничек котылырга? Швециянең дүрт инженеры, махсус бер проектны яклап, авторлык таныклыгы алдылар. Аларның проекты Берләшкән Милләтләр Оешмасының бүләгенә дә лаек булды. Әлеге инженерлар Балтик диңгезенең нәкъ уртасында диңгез суын тоздан арындыра торган махсус җайланма — атом станциясе салырга тәкъдим иттеләр. Әлеге җайланманы сафка бастырган тәкъдирдә, Балтик буе илләренең тәмле суга булган ихтыяҗы беркадәр хәл ителә ала. Акыллы фикер. Моны тормышка да ашырырга мөмкин. Әмма корылма миллиардларча чыгым таләп итәчәк. Димәк, проектны гамәлгә ашыруда уннарча дәүләтләрнең җиң сызганып һәм эчкерсез катнашуы кирәк. Моның өчен бу дәүләтләр арасында дуслык, бер-берләренә ышану мөнәсәбәтләре саклану зарур. Әлегә аларның төрлесе төрле хәрби блокларда булып, һәркайсының полигоннарында бер-берләренә төбәлгән ракеталар торганда, мондый килешүгә ирешү мөмкинме?

Планетабызда исә без эчәргә яраклы су запасы көн саен, сәгать саен кими бара.

Белгечләр шуны раслый, шул турыда чаң сугалар. Нишләргә? Тагын нинди мөмкинлекләр бар, нинди чаралар күрергә мөмкин? Проектлар, кыю фикерләр күп. Шуларның менә тагын берсе. Язлар җитеп, карлар эри башлау белән, Төньяк боз океанынннан Европа кыйтгасына таба айсберглар — боз таулары кузгала. Болар — гигант күләмдәге эчәргә яраклы су таулары. Ләкин материкларга җиткәнче алар эреп бетә. Бер төркем инженерлар айсбергларны океанның аргы башында ук каршылап, бозын чабып, баржаларга төяп, су кытлыгы кичерүче илләргә тарату фикерен күтәреп чыкты. Беренче карашка, бу проект өмет уята кебек. Ләкин су безгә биниһая күп кирәк. Сүз миллионнарча халкы булган күпләгән илләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерү турында бара. Аны ничек океан аръягыннан ташып җиткерәсең?!

Сүземне: «Җидегән чишмәләрдә — җиде улак»,— дип башлаган идем. Чылтырап аккан чишмәләрнең язмышы шушы төбәктә яшәгән халыкның аңына, культура һәм әдәп дәрәҗәсенә бәйле. Иркутскида узган «Байкалда очрашу» киңәшмәсендә дә бу хакта сүз барды. Әрмәнстандагы Севан, Япониядәге Бива һәм һәркайсыбыз белгән Байкал күлләре бүгенге көндә планетабыздагы иң мул сулы байлыктан санала. Америка бизнесменнары моннан унбиш-егерме еллар элек Совет хөкүмәтенә Байкал суын сатып алырга теләкләре барлыгын белдерделәр. Алар Байкалдан Мурманскига кадәр суүткәргеч сузарга әзер. Аннан инде тәмле, татлы Байкал суын махсус баллоннарда гына Америкага ташырга иде исәпләре. Суга кытлык бүгенге көндә менә ни дәрәҗәдә!

Дөньяда бердәнбер Байкал күлен күз карасы кебек сакларга иде! Әмма промышленность үзәкләренең эшчәнлеге, химия-кәгазь комбинатларының «тырышлыгы» аркасында аның суы да елдан-ел сафлыгын югалта бара. Байкалда тюленьнәрнең үлә-кырыла башлавы — шуның шаһиты. Сәбәбе — күл суына агулы матдәләр эләгү. Без табигать белән бик сак эш итәргә кирәклеген еш кына исебездән чыгарабыз. Утырган ботагыбызга балта чабабыз, үзебез эчә торган коега төкерәбез. Республикабыз авылларындагы чишмәләрнең бүгенге торышын күрегез: алар бит хәзер иң ташландык җиргә, чүплек башына әйләнде. Аларны караган, чистарткан кеше юк, өй-хуҗалыктан арткан бөтен чүп-чарны шул чишмәләр юлына китереп ташлыйлар.

«Байкалда очрашу»чы галимнәр дөнья җәмәгатьчелегенә шундый тәкъдим белән мөрәҗәгать иттеләр: нәни генә чишмә дә, кечкенә генә инеш тә — Җир шарындагы барлык халыкларның гомуми милке! Аларның сафлыгы, бөтенлеге, тереклеге, иминлеге турында туктаусыз кайгыртып тору — планетабызда яшәгән һәр кешенең, һәр адәм баласының изге бурычы!..

Инде үз җиребездәге, Татарстандагы чишмәләргә, кизләүләргә күз салыйк! Алар ни хәлдә? Бер сүз белән генә әйткәндә — тәмам ташландык хәлдә. Дөрес, кайбер авылларда, зур кунаклар килгәндә күрсәтергә, улаклары көйле берәр чишмә булдырылды. Күпчелеге — ташландык. Чишмәләргә карата мәрхәмәтсезлекнең сәбәпләрен аңларга тырышам. Шәһәр халкы суны краннан гына агызып эчә. Авыл җирләрендә дә хәзер суны торбалардан ала башладылар. Чишмәләрнең кадере бетте, аларга мәхәббәт кимеде. Ләкин сәбәп монда гына түгел. Торгынлык елларының казасы буларак, җәмгыятьтә әдәп, тәртип, шәфкать кебек сыйфатлар кимеде. Миһербансызлык чишмәләребезгә, инешләребезгә дә кагылды. Бу яман гадәттән тиз генә арына да алмыйбыз.

Без яши торган Лениногорскида, өй-нигезебез артында гына унлап чишмә бөрки. Берсеннән-берсе саф, берсеннән-берсе салкын сулы. Һәркайсының үз холкы. Сулары — мең төрле чиргә шифа. Шуларның унысына да мин үзебезнең татар кызларының матур исемнәрен куштым. Шунсыз булмый, чөнки мин алар белән туганнарча аралашып яшим. Мине хәзер өем артында Гөлнара, Гөлсара, Гөлшат, Гөлбикә, Гөлназ, Гөлкәй, Гөлсаз, Гөлнур, Гөлсирә һәм Гөлчирә исемле чишмәләр көтеп ала. Кулымнан килгәнчә, вакытым җиткәнчә, шуларның һәркайсына күз-колак булырга тырышам. Күзен дә, язын да ишелгән балчыктан, ләмнән арындырам. Шулай булышкаламасаң, барысы да инешкә юл яра алмыйлар. Читкә китсәм, мин аларны сагынам, кайтсам, тизрәк янnarына ашыгам. Яннарына төшсәм, алар миңа яңа җыр көйлиләр, әкиятләр сөйлиләр, каш сикертеп, күз кысалар кебек. Гөлшат исемлесен мин тагын да баетырга ният иттем. Буровойлар төзү идарәсенә барып, күп иттереп идән такталары яздырып кайттым. Зур гына улак ясаттым. Балта-пычкы, чүкечне үзем дә тоткалыйм. Теләгән һәр кеше чишмәгә төшә алсын өчен инеш аша басма салдым. Улакның ике ягына урындыклар ясап куйдым. Күркәм генә килеп чыккан иде ул. Туган як табигатенә шәфкать сорап мәкалә язу — бер нәрсә, кулыңа көрәк алып, чишмәгә ярдәм итү — тагын да файдалырак.

Әмма... үземчә изгелеккә санап башкарган бу эшем үкенечле булып чыкты. Кайнар күз яшем белән елый-елый, балтамны басма такталарына җен ачуым белән чаба-чаба, үз кулым белән төзегән барлык корылмаларны җимереп ташларга туры килде.

Чөнки минем бизәлгән чишмәмне шәһәрнең токсикоманнары күреп алганнар. Ошатканнар. Үзләренең «баш төзәтә» торган агулы эчемлекләрен күтәреп килгәннәр. Төр-

ледән-төрле агуларны саф чишмә суы белән бутап эчәргә өйрәнеп алганнар болар.

Әлеге минем яраткан чишмәмне менә шушы бичаралар басты. Утырырга уңай урындыклары, шешәгә агызырга җайлы улагы бар. Аек кешегә исә чишмә тирәсенә килер җай калмады. Милиция идарәсенә шалтыратып карадым. Берничә тапкыр куып тараттылар. Азга гына юк булып торалар да, янәдән сырып алалар. Милицияне көнетөне чишмә итәгендә тота алмыйсың. Тирә-юньне төрледән-төрле баллоннар, куыклар тутырды. Алар ишәя, тау булып өелә бара.

Вак ташлар өстеннән сикерә-сикерә чылтырап агып яткан чишмә каршында миңа уңайсыз була башлады. Су алырга төшкән саен йөзем кызара. Чишмәне, бу изге урынны шушы хәлгә төшерүче мин бит. Мин моңа гаепле. Инеш аша басманы мин салдым. Текә таудан төшә торган баскычны да, улакны да, урындыкларны да мин ясап куйдым. Хәзер чишмә янына килерлек тә түгел. Нинди генә шешәләр аунамый, нинди генә ят-авыр исләр килми монда?! Иа хода, үз өстемә менә нинди гөнаһлар алдым?!. Кыш урталары җитеп, «крещение» салкыннары башлангач, минем өй артындагы чишмәләр марҗа әбиләрнең дә исләренә төшә. Ул-бу була калса, хак тәгалә каршына саф чишмә суында коенып, гөнаһларыннан арынып бару икән боларның исәбе. Мондый җитди гамәлгә кухня кранынннан аккан су гына ярамый, күрәсең. Чиләкләрен күтәреп тау итәгенә җыелалар, таяклар белән төрткәләп кар астыннан чишмә эзләргә керешәләр. Чөнки сукмаклар юк, хәзер мин аларны көрәмим. Өстемә тагын гөнаһ аласым килми.

— Юк, кадерле әбекәйләр, бу чишмә суларында гына коенып, яшьлектә кылган гөнаһларыгыздан алай җиңел генә котыла алмассыз. Хак тәгалә кичермәс сезне,— дип чыгам мин боларның каршыларына.

— Нигә алай дисең, улым? — дип, аптырашта калалар.

— Беренчедән, бу чишмәләрнең суы без уйлаганча ук саф, чиста түгел. Саф булмагач, изге дә була алмый. Аларны җәй буена сезнең оныкларыгыз хурладылар, пычраттылар. Икенчедән, сез бу чишмәләрне нигә, «крещение» җиткәч кенә, исегезгә төшерәсез? Һич югында, аена бер килеп, аларны чүп-чардан арындырып, чистартып, иркәләп-барлап китмисез?

Әбекәйләр — аптырашта. Мондый вазифа турында уйлау аларның башына да кереп чыкмаган.

Күптән түгел тагын бер кызык хәл булды. Шәһәрдә көн буена су бирми тордылар. Сусүткәргечне төзәттеләр. Сусыз, үзегез беләсез, тормыш туктала кебек. Якын-тирәдәге бишәр катлы йортларда көн күрүчеләр, сыңар чиләк тотып яки чәйнек эләктереп, чишмәгә агылды. Торбадан су килми башлагач, чишмә барлыгы исләренә төшкән!

Мин әйтәм: рәхәтләнеп эчегез! Әмма янıгызда гына саф сулы чишмәләр, гөрләвек кизләүләр барын, фатирларыгызда су беткәч кенә түгел, көн дә исегезгә төшереп яшәгез! Җәен дә, килгәләп, чистартып китәргә онытмагыз! Кышын да сукмакларны көрәштергәләп торыгыз! дим. Мин, шушы форсаттан файдаланып, кулларымны болгый-болгый, авызымнан төкерек чәчеп, вәгазь сөйләп маташканда: «Су бирделәр!» — дигән хәбәр яңгырады. Әле генә минем белән гәпләшә-гәпләшә чишмәгә юл ярган халык, кырт итеп, кирегә борылып куймасынмы?! Үгетләргә тотындым:

— Килгән-килгән, бер чәйнек кенә булса да, алыгыз инде! — дим.— Белмисез генә: бу чишмәләрнең суы эчеп туйгысыз тәмле, мактап бетергесез шифалы!

— Ә-әй, дүртенче катка кадәр су күтәреп менәмме соң!? Безгә аның краннан акканы да ярый! — дип, буш чиләкләрен, чәйнекләрен шалтыратып, таралыштылар.

Чишмәләребезнең ни хәлдә булуына карап, алар тирәсенә утырган халыкның мәдәнияты, кешелек йөзе турында һич ялгышмый фикер йөртергә була. Республикабызның көньяк-көнчыгыш өлеше матур Урал тауларының итәгенә тоташа. Таулар итәгеннән исә мул сулы, саф чишмәләр тибеп ята. Сөенеп туймыйсың. Шәҗәрәләребезгә нигез салган ата-бабаларыбыз йорт-җирләрен, каралты-кураларын бик белеп, менә шушы шат күңелле, саф сулы, мул сулы чишмәләр тирәсенә корганнар. Шушы чишмәләр каршына тезләнеп гыйбадәт кылганнар, бәйрәмнәр уздырганнар, язгы сабан туйларын үткәргәннәр, атлар узыштырганнар. Ике яшь йөрәк тә берсен-берсе чишмә юлында табышкан.

Шушы гыйбрәтле хәлләр турында уйлана торгач, бала чакларым исемә төште. Малай чакта миңа сарык көтүе артыннан чабарга да туры килде. Көне буена, «бә-э» дә, «бә-э» дип тәмам колагыңны тондырган аңгыра башларны төшлеккә «Солдат чишмәсе»нә алып төшәбез. Бер якта Тугаш исемле урыс авылы, икенче якта безнең Таш-Кавал. «Солдат чишмәсе» — шушы ике аралыктагы болынлыкта.

Менә шушы ике авыл халкы «Солдат чишмәсе»н ничек кенә карый, кадерли иде! Чишмәдән читтәрәк, Чыпчык тимер юл станциясеннән олы юл уза. Әле борынгы заманнардан ук шушы олы юл буйлап, гомерләрен ак патшага хезмәткә багышлаган егетләр, гаскәри хезмәтне үтәп, туган якка кайткан. Кемгә дә булса кереп, чәй эчеп,

тамак ялгап чыгыйм, дисәң, рәхим genә ит! Тугаш урысларының капка келәсен бассаң, җәен-кышын салкын квас, тозлы кыяр, кәбестә, балык белән сыйларлар. Таш-Кавал татарларына барып керсәң, алдыңа шундук салкын сөзмә, сөтле чәй, төче коймак чыгарып куярлар. Ләкин юл кешесенең юлда булуы хәерле. Мосафирлар, күбесенчә, әлеге чишмә янына гына тукталып хәл алган.

Төрле язмышлар белән чишмә итәгенә килеп чыккан юлчыга яңгыр-давылдан ышыкланырга кечерәк кенә әвеслек бар. Әвеслек астында — җыйнак кына шүрлеге, аркалы урындыгы. Тугаш карчыклары шүрлеккә, көн аралаш диярлек, бер-ике пешкән йомырка, кәбестә, кишер бөккәннәре китереп куялар. Мин Ватан сугышы барган, бик авыр елларны хәтерлим. Бу бәлеш-бөккәннәрне пешерүче уңган әбекәйләр оның, кишерен-кәбестәсен ничек юнәткәннәрдер?! Күп йортларның җилпучларында «өф» дип өрерлек он булмас иде. Ә менә солдаттан кайтучыга тамак ялгарлык ризык табыштырганнар!

Аннары тагын, марҗа әбиләр шушы чишмә янына үзләре тукыган, берсеннән-берсе матур сөлгеләр, тастымаллар китереп эләләр. Болары да — юлчылар, сугыш кырларында яраланып кайтучы солдат-балакайлар өчен. Чишмә янына килеп, таш өстенә басып, бит-кулыңны югач, рәхәтләнеп бер сөртен! Мохтаҗлыгы бар икән, шушы сөлге белән бәйләп, яралы кулыңны муеныңа ас, солдат-балакай...

Безнең Таш-Кавал картлары исә елның-елында, бик зурдан кубып, «Солдат чишмәсе»нең бурасын алыштыралар, капкачының тупсаларын төзәтәләр. Бура алмаштыру үзенә күрә бер ямьле өмәгә әйләнә. Авылның баласы-чагасы барысы шунда була. Бу изге эшкә баручыларга әбиләр йомырка, төче коймак пешерә. Чишмә итәгенә кую өчен чынаяк кәсәләр биреп җибәрәләр. Бәлкем, алар үз өйләрендә үлән чәйләрен ярык агач җамаяктан эчкәннәрдер. Авыр еллар иде бит. Әмма чишмә янына хәл җыярга туктаган юлчы суны әнә шул чин-чынаяктан, матур кәсәләрдән эчсен! Чишмә янындагы әвеслекнең өсте ябулы шүрлегендә, чүлмәк эчендә, елның теләсә кайсы вакытында, бер кашык тоз, бер баш суган, тастымалга төргән сохари, бер кап шырпы, бер әчмуха тәмәке була.

Без, көтүче малайлар, һәрчак ач. Күңелдә туган барлык якты хыяллар, ахыр чиктә, бер туйганчы ашауга әйләнеп кайта. Әмма шүрлектәге сохарига, бер баш суганга кагылырга ярамый. Аларга кагылу — оятсызлык. Авыл урамына нинди йөз белән кайтып керерсең?!

Бу елларны хәзер зур горурлык белән искә төшерәм. Беркем тарафыннан расланмаган, гамәлгә кертелмәгән, әмма нинди кешелекле, күркәм гадәтләре бар икән халкыбызның! Каян килде икән алар безгә? Хәзер генә ник оныттык икән без аларны?

Узган җәйне, шушы язмага хәстәрлек күреп, мин үзем яши торган Лениногорск районының күпчелек авылларында булып чыктым. Чишмәләрне санап бетерерлек түгел икән! Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең туган авылы Федотовкада йомшак, тәмле сулы чишмәләр — бакча башы саен. Алардан агып чыккан вак гөрләвекләр, йөгерек инешләр, авыл урамнарына төшеп, күп кешеләрнең тәрәзә төпләреннән агып ята. Бу матурлыкны аңлатып бирерлек түгел.

Чыршылы, Керкәле, Сугышлы, Куакбаш авылларында да чишмәләргә кытлык юк. Тик шушы чишмә-кизләүләрдән хасил булган йөгерек инешләрнең өстенә карарлык түгел. Аларга нәрсә генә чыгарып ташламаганнар?! Иске комган, төпсез чиләк, кысасыз иләк, кабык арба, ватык караватъ... Кыскасы, йортта нәрсә искерсә, шуның барысын да инеш ярына ташлый барганнар. Ташлаучысы — бер җинаять кылган. Ә соң авылның түрәләре, район җитәкчеләре нәрсә карый? Алар бит шушы авыллар аша һәркөнне узып йөри. Хәер, «Волга» тәрәзәсеннән барысы да күреимидер шул. Торгынлык чорының кара сөреме аңыбызның, тормышка карашыбызның бөтен почмакларын баскан, аларны һичнәрсә белән сөртеп бетерерлек түгел кебек...

Безнең халыкта: «Нәфсеңне тыя бел!» — дигән кисәтү яши. Без исә шуны онытып барабыз. Байлык, мал-мөлкәт артыннан куу йогышлы бер чиргә әверелде шикелле. Авыл тирәләрендәге йорт-җирләргә, каралты-кураларга хәзер күз генә тимәсен! Түбәсен шифер белән япкан, стенасын ялт иттереп буяган, тимердән коеп куйган капкалар. Һәр йорт курчак өе! Эчләренә килеп керсәң дә, зиннәтле җиһазлардан күз чагыла. Әмма шушы өйләрнең янынинан егерме-утыз адым китеп кара — нәрсәләр генә чыгарып тондырмаганнар?! Койманың теге ягындагы хәлдә берәүнең дә гаме юк. Күңелгә шом сала торган күренеш!

Көзге кыр эшләре тәмамлангач мин авыл халкы белән очрашуларга йөрергә ятам. Авыл халкы күп укый, газета-журналларны да күп ала, әдәбият белән нык кызыксына. Яхшы! Әмма тагын бер «ләкин»не әйтми уза алмыйм. Колакларына алтын алка, кулларына алтын йөзек кигән киленнәр, аякларына иске галош кына эләктерәләр дә, юынтык суларын капка төпләренә чыгарып түгәләр. Һәр капка төбендә — ямьсез боз тавы хасил булган. Җәмәгать, татар авылында күрелгән, әби-бабайлар

заманында булган хәлме бу? Элек, мондый шапшаклыгың өчен, үзеңне генә түгел, нәсел-нәсәбеңне авылдан куган булырлар иде. Хәзер моны күргән кеше дә юк. Бу пычрак сулар язын инешләргә агып төшә, аларны агулый. Син шул суны мунчаңа ташыйсың, җәен балаң шунда су керә... Әле генә Зәй-Каратайда булып кайттым. Районның алга киткән, төзек авылларының берсе. Күп кенә биналарны ап-ак кирпечтән салганнар. Үзәк урамнарга асфальт түшәлгән. Ике-өч йортка бер су колонкасы. Су житеш. Шушы колонкалар янында хасил булган ерганакларга, күлләвекләргә нәрсә генә чыгарып ташламаганнар?! Иске итектән башлап борыны төшкән җиз самавырга кадәр. Бер урында «күл»нең кыл уртасына иске мотороллер кертеп ташлаганнар, икенчесендә ватык телевизор күренеп тора.

Без малай чактагы яшел чирәмле урамнар да сагынып сөйләргә генә калды. Кая бассаң, шунда шешә китеге, консерв калайлары. Авыл җирләрендә, ай-һай, шапшак, җирәнгеч яши башладык, туганнар. Бу килеш белмим кая барып чыгарбыз?

Мәсьәләнең икенче ягы да бар бит: көндәлек тормышта арткан иске-москыны, кулы сынган, башы каерылган курчакларны, ватык җиһазларны җыю белән берәрсе шөгыльләнәме соң? Аларны кая куярга? Элек сөякләр, иске самавырлар җыючы агайлар йөри торган иде. Хәзер алар картайды инде. Яшьләр исә бу эшкә алынмый.

Кайчак мәктәпләрдә тимер-томыр җыю буенча атналыклар, унконлекләр дә игълан итеп алалар. Беренчелеккә ирешкән класс җәен сәяхәткә бара. Әмма авыл малае, йорт саен кереп, иске чиләк, борыны төшкән комган җыеп башын катырмый. Зур чанасын сөйрәп механика мастерскоена менеп китә. Анда аның чанасына, кран белән күтәртеп, янып чыккан электромоторны салалар. Классның тимер ватыклары җыю планы шундук ике йөз процентка үтәлә. Димәк, бу шөгыль генә авылларны шапшаклыктан коткара алмый.

Безнең ата-бабалар бик саф, бик пакь яшәгән. Академик Вишневский үзенең көндәлекләрендә элек татар авылларында тире авырулары, ашказаны-эчәк чирләренең бик сирәк булганлыгын яза. Ул заманнарда нык таралган трахома авыруы да татар авылларында шулай ук бик сирәк очравын искәртә. Боларның барын да татар халкының чисталыкны саклавы, атна саен мунча кереп, урын-җирне алыштырып, өй-каралты тирәсен бик пөхтә, чиста, төзек тотуы белән аңлата. Ләкин без мондый гадәтләрне тиз оныттык. Хәзер песи, эт, сарык бәрәннәре, хәтта тау тикле тана үләксәләрен дә авылдан кимендә өч-дүрт чакырым читтәге үләт базына күмүләр онытылды. Аларны да инеш буйларына, тиреслекләргә генә чыгарып бәрәләр. Колхоз фермаларында бәрән, бозау, дуңгыз баласы үлсә, кеше-карага күрсәтмәс өчен, аларны тирес астына гына күмә баралар, язын тирес белән бергә басуга чыгаралар. Алар анда төрле йогышлы авырулар таратып ята. Сунарчылар республика урманнарында котырган бүреләр, төлкеләр ишәюе турында сөйли. Бу дәһшәтле чир авыл маэмайларына йога, алардан — башка малларга. Бер авылда егерме сыерның көтүдән котырып кайтуы билгеле. Мин бу саннарның берсен дә һавадан алып язмыйм. Узган җәйне туган як табигатен саклау мәсьәләсе республиканың район Советларының сессияләрендә махсус көн тәртибе итеп каралды. Бик чакырып тормасалар да, мин дүрт сессиядә катнаштым, чәчрәп чыгып, чыгышлар ясадым. Шунсыз булмый. Чирне яшереп күп яшәдек, соңгы чиккә җиттек. Хәзер чаң кагарга кирәк! Республикабызда Табигатьне саклау комитеты да төзелде. Ләкин мин бу оешмага да әллә ни зур өмет багламыйм. Чөнки шушы комитетның район бүлекчәләренә «үз кешеләр» урнашып алды. Димәк, бу инспекторлар табигатьне бозу буенча коточкыч тәртипсезлекләргә тагын күз йомачаклар. Бер карасаң, хәтта кирәге дә юк бит бу комитетларның. Республикада да, һәр кечкенә генә шәһәрдә дә, «Горно-технический надзор» дигән инспекцияләр бар. Аларга искиткеч зур хокуклар бирелгән. Бу инспекцияләр проектта күрсәтелгән шартлары үтәлмәсә, төзелеп яткан заводка йозак салдыра, бораулап яткан нефть коесын бәкеләп куйдыра ала. Әмма, кызганычка каршы, бу юлда күңел биреп эшләүчесе генә юк. Ун елы тулды дигәндә, күккә оча торган заводлар салуга юл куйдылар (Миңлебай газ-бензин заводындагы шартлау). Кемнәрнеңдер күкрәкләре орден-медальләр белән бизәлде, ә менә бүгенге буынга җимерек, таркалган нефть хуҗалыгы калды...

Сүз башым чишмәләр турында иде бит. Аларның шифалы булуы шушы җирлектә көн иткән халыкның мәдәниятына, көнкүреш дәрәҗәсенә бәйле. Әдәп белән, таләп белән, намус белән көн иткән халыкның инеш-сулары да саф була.

«Байкалда очрашучылар» чәй суы — җир шарындагы халыкның уртак байлыгы, дип игълан итте. Ә менә Татарстан чишмәләре исә бик кызганыч хәлдә. Балачагым ифрат матур, саф сулы Ашыт елгасы буенда узды. Мин аның хәтта олылар да йөзеп чыгарга шикләнгән киң, мул сулы чакларын хәтерлим. Әй, балык иде инде үзендә! Бүген исә: «Йа хода, менә нинди көннәрне дә күрәсебез бар икән!» — дип, авыр суларга гына калды. Бүген Ашыт тик географик карталарда гына яши, чөнки аны туендыручы чишмәләр, кизләүләр юкка чыкты, алардан Ашытка килеп кушылучы, аны күп

сулы, мул сулы итүче инешләр корыды.

Чишмәләрне, коеларны чистартып тору, иртән иртүк торып инешкә бәкеләр тишү — безнең халыкта борын-борыннан килгән матур гадәт инде ул. Моны, авыл халкын ихтирам йөзеннән, мөхтәрәм картлар башкарган. Инде менә заманында мәчет манараларын аударып йөргән «ярсу йөрәкләргә» дә картлык килде. Чишмә-коеларга күз-колак булып торсыннар иде дә... юк шул.

Узган җәйне безнең яклардагы Дала-Коран тау итәгенә Казан университетыннан экспедиция килеп урнашты. Тау итәгендәге нефть коесында приборлар төшереп нәрсәдер өйрәнә башладылар. Палаткалар кордылар, волейбол мәйданчыгы да ясадылар, радио нокталары да бар иде. Эчәргә сулары гына юк икән. Тик аптырап тормадылар: совхоз бүлекчәсенә барып, «Беларусь» тракторы сорап алганнар да ярты сәгать эчендә зур гына баз казытканнар. Ул исә безнең күз алдында көмештәй су белән тулды. Тауларыбызның куеннарында чишмәләр бик күп, аларны ачучылар гына юк икән ләбаса! Һич югында өч-дүрт районга бер шундый, бер трактордан, ике-өч егеттән торган махсус бригадалар булдырылса, җәй эчендә күпме чишмә ачарга булыр иде! Юк шул, чишмә ачып азапланучысы юк. Ә менә Ашытның башыннан алып, Илләткә барып кушылган тамагына хәтле, аның ярында утырган һәр колхоз, үзенең сугарулы болыннарына капка баганасы юанлыгындагы торба буенча су суырта. Болай талауга ул бичара ничек түзсен?!

Бер Ашыт елгасы гына шушы хәлдә булса икән! Шушы ук коточкыч язмыш республикабыздагы Шушма, Ык, Зәй елгаларын да көтә. Әүвәл уңган сәүдәгәрләрнең баржалары, бодай төяргә, Ык буйлап, Минзәләгә кадәр күтәрелә алган. Хәзер кая ул баржалар белән күтәрелү — бу юлдан балыкчы көймәсе дә үтә алмый.

Ык елгасы безнең республикага Башкортстанның Октябрь районы аша килеп керә. Шуннан ул, Баулы, Азнакай, Сарман, Мөслим, Минзәлә районнары аша узып, Камага кушыла. Кызганыч, бу елгабыз да чыпчык тезеннән генә калып бара. Сәбәбе шул ук: елганың ике яры буйлап утырган колхозлар, совхозлар сугарулы җирләренә, болыннарга суны көне-төне суыралар. Мелиораторларга исә хезмәт хакын үскән печән, савылган сөт хисабыннан түгел, ә инештән юлбасарларча талап суыртылган су күләменнән чыгып түлиләр. Шуңа күрә алар су суыртуны, коеп яңгыр яуганда да, туктатмый.

Җәен Чирмешән буйларында йөрдем. Район үзәгендәге кунакханәгә урнашу белән, кулга кармак эләктереп, елга ярына ашыктым. Кичке якта аеруча шәп чиертә, соңга калмагаем, янәсе.

Кармакларны бар көчкә айкап елга уртасынарак ыргыттым, сигарет кабызып җибәреп, бүкән өстенә чүктем. Сигарет исенә янына бер карт та килеп утырды. Аңа да сигарет суздым. Сорашырга да җай чыкты:

— Бабай,— мин әйтәм,— сезнең монда кызылканат нәрсәгә каба: чикерткәгәме, әллә агач кайрысы кортынамы?

— Син, улым, күреп торам, килгән кеше ахры,— диде ул көрсенүле итеп.— Бар иде монда заманында балык! Кызылканатлар, беләк буе бәртәчләр сагынып сөйләргә генә калды... Хәзер син моннан сыңар калуш йә иске итек кенә суырып чыгара аласың... Тау башында гына — нефть коесы. Елгага нефть ага...

Шунда гына игътибар иттем: җырларда мактралган Чирмешән ярлары тирес өемнәре, төрле чүпләр белән тулы. Елга эченнән чәнечкеле тимер чыбыклар, машина көпчәкләре, тагын әллә нәрсәләр калкып утыра. Җәелеп аккан су өстенә ашъяулык-ашъяулык май таплары капланган. Әй, егетләр, нишлибез?! Кая шулай узынабыз? Ахыры ниләр белән генә бетәр моның?!

Мин — СССР Язучылар берлегенең экология комиссиясендә һәм Бөтенроссия Табигатьне саклаучылар җәмгыятенең Татарстан Советында әгъза булып торам. Әле күптән түгел генә оешкан «Татарстанның Табигатьне саклау дәүләт комитеты» идарәсендә дә әгъза мин. Бу оешмаларның йомышларын бик теләп башкарам. Туган як табигатен, урман-суларны саклауга кагылышлы нинди генә җыелыш-киңәшмәләр булса да, катнашам, чәчрәп чыгып, чыгышлар ясыйм, гаеплеләрне оялтам, орышам, хөкем белән яныйм. Шунсыз булмый хәзер.

Элегрәк елларны авыл саен буа буалар иде. Хәзер бу күркәм гадәт тә онытылып бара. ПМК дип аталган оешма бер елны Сугышлы авылы янында Шушма елгасын буарга алынды. Маташулары инде ун елларга сузыладыр — буа һаман юк. Объектны файдалануга тапшырдык, дип акча алганнардыр әле. Ә беренче яңгыр ук буаларын ера да ташлый. Анда тотылган акча, шәт, миллионнарга җиткәндер?! Шушы башбаштаклык өчен берәүнең дә җавапка тартылганы юк.

Буалар авыл җирендә бик кирәк. Алар авылның күрке, бизәге, халыкның ял итү урыны була ала. Бала чакларны без су буеннан кайтып та керми идек. Җәйге бөркү кичләрне хәтта чал чәчле карчык-корткалар да буага төшеп рәхәтләнеп су керәләр иде. Алар су буена авыл тынгач кына төшеп китәләр. Еш кына, иптәшкә диган булып,

без малай-шалайны да иярталәр. Без кояш җылысында гына коенырга күнеккән нәзберек җаннар, тиз генә чумып чыгабыз да, яр буенда, әбиләрнең күлмәгенә төренеп утырабыз. Әбиләребез көндезен тәмам җылынып өлгергән суда, рәхәтләнеп, сәгать буе коеналар...

Буада атлар коендыру тагын бер бәйрәмгә әверелә торган иде. Карасаң, нәни генә буа! Үзе кешеләргә әнә нинди рәхәтлекләр биргән. Бүген исә күп авыллар шул рәхәттән мәхрүм. Дөрес, кайбер якта җиде-сигез авылга бер зур сусаклагычлар салалар. Ләкин алар һәркемне дә шатландыра алмый.

Авылларда буаларның булмавына, чишмәләрнең коруына мин колхоз председательләрен гаепле санар идем. Чөнки моңа кадәр авыл җирендә власть алар кулында булды. Киләчәктә бу көчкә авыл Советларына биреләчәк мөмкинлекләр дә кушылыр. Бергә-бергә тотынсалар, дистә еллар буе кул селтәп киленгән бу мәсьәләләр тизрәк чишелер иде.

Инде шушы ук сүз уңаеннан тагын бер яман хәлгә тукталмый китә алмыйм. Минераль ашламалар турында әйтмәкче булам. Аларны кая гына кайтарып бушатмыйлар?! Алар башта, кадерсез мал булып, аунап яталар да, язын, эреп, инешләргә агалар.

Тимер-юл идарәсе җаен тапкан: килгән вагоннарны вакытында бушатмаса, колхозларны бугазыннан ала. Ә менә минераль ашламаларны дөрес сакламаган өчен колхозларга сүз әйтүче юк. Хуҗалыкларның яртысында диярлек, минераль ашламалар ачык һавада ята. Кәгазь яисә целлофан капчыкларда кайткан ашламаларны урнаштыру өчен келәт-амбар яисә өсте ябык эвеслекләр корып кую әллә ни зур чыгымнар да сорамый. Ваемсызлык көчле.

Заманында: «Безнең Татарстан — икенче Баку!» — дип күкрәк суктык. Күп тә үтмәде, без, нефть чыгаруда иң алгы сафка бастык. Бер 1970 нче елны гына да Татарстан нефтьчеләре туган илгә йөз дә унике миллион тонна «кара алтын» чыгарып бирделәр... Ул чорларда бөтен илдә елына өч йөз миллион тонна нефть алына иде. Бу күрсәткеч, бер яктан, титаник хезмәт нәтиҗәсе булса, икенче яктан, Татарстан нефть ятмаларының ни дәрәҗәдә корткычларча, рәхимсез эксплуатацияләнүен дә дәлилли. Дөрес, бүгенге көннәрдә «Татнефть» берләшмәсе табигатьне, чәчүлекләрне, сулыкларны саклау буенча зур чаралар күрә. Берләшмәнең Табигатьне саклау бүлеге начальнигы Абрек Мөгаллимов белән без еш очрашабыз. Берләшмә, чыннан да, экология буенча зур эшләр башкара, күп чыгымнар тота. Әмма заманында, рекордлар артыннан куып, ашыгычлык белән сузылган нефть үткәргечләр, коелар бүген тәмам искерде. Бөтен берләшмә буенча исәпләгәндә, тәүлегенә йөздән артык эреле-ваклы авария, торба тишелүләр булып тора. Өстәвенә, әйтик, «Лениногорскнефть» идарәсе генә дә тәүлегенә җир куеныннан 76 мең кубметр катлам сыекчасы, игътибар итегез, нефть түгел, ә «катлам сыекчасы» чыгара. Шушы 76 мең кубметрдан артык сыекчаның 85,6 проценты — су. Тозлы, кислоталы, химик актив, агулы, бик хәтәр су бу. Алар аны кире катламнарга куалар. Ничек соң шушы күләмдәге су чишмәләребезне бозмасын?!

«Иркеннефть» идарәсендәге хәлләр тагын да хәтәррәк. Алар бер елга 34 миллион 700 мең кубметр катлам сыекчасы күтәрәләр. Шуның 2 миллион 811 мең кубметры гына нефть. Бәлки, бу нефть чыганакларына ял бирергә кирәктер? Мондый фикерне әйтсәм дә, аның тормышка ашуына мин ышанмыйм, әлбәттә. Чөнки байлыкка сакчыл караш бездә тәрбияләнмәгән. Әйтик, «Иркеннефть»тә зур хезмәт хакы алырга күнеккән геологлар, механиклар, экономистлар, бухгалтер-хисапчылар утыра. Тәүлегенә түгел, тулы ел әйләнәсенә нибары бер чиләк нефть чыгару көненә калсалар да, алар коеларны ялга туктатмау ягын каерачак. Белмим, әчәрләренә су калмаса гына, бәлки, пошаманга төшәрләр. Дөрес, болай дәвам итсә, ул көнгә дә күп калмый... Чөнки шушы «Иркеннефть» идарәсендә генә дә су һәм төрле юанлыктагы нефть үткәргечләрнең гомуми озынлыгы 763 чакрым. Узган елны гына да алар 637 тапкыр сафтан чыкты, чәчүлекләрне бозды, инешләрне пычратты. «Татнефть»нең бүгенге җитәкчеләренә бик авыр. Элекке рекордчылар аларга җимерек, таркалган хуҗалык калдырды. Туган як табигатен саклау мәсьәләсе үзен аеруча сиздерә. Берләшмә бүгенге көндә Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарындагы 294 чишмәне даими күзәтү астына алды. Алардагы су даими рәвештә сынала, лабораторияләрдә тикшерелә. Бу яктагы 235 чишмәнең суы, эчәргә яраклы, дип исәпләнә. 69 чишмәдән исә керосин тәме килә, пычрак су чыга. Соңгы ике ел эчендә, зур чыгымнар куеп, 10 чишмә хуҗаларына кайтарылды, эчәрлек хәлгә китерелде. Чишмәләрне сафландыру өчен «Татнефть» берләшмәсе 24 миллион сум акча билгеләде. Шапшак, пычрак хәлендә тагын 59 чишмә бар. Катламнарга астрономик күләмнәрдә куылган актив су сыекчасы да тик ятмый. Алар чишмәләрнең башкаларын сафтан чыгара торалар. Койрыгын алса — башы, башын алса, койрыгы ябышу бәласе шушы буладыр инде. Нибары бер чишмәне сафка бастыру да гаять кыйбатка, егерме биш-утыз, хәтта алтмыш меңнәргә төшә.

Безнең Лениногорск районында Куакбаш исемле бик матур авыл бар. Авылны җиде кисәккә бүлеп мул сулы, карап торырга, көмештәй саф сулы җиде чишмә агып ята. Әмма чишмәләрнең суын авызга алырлык түгел, ургылып керосин тәме килә. Авыл халкы чәй суын элегә нинди могҗизалар беләндер исән калган, «Халкай чишмәсе»ннән ала. Вакыт-вакыт исә ул да керосин исе бөркеп куя икән.

«Татнефть» берләшмәсе, авыллар киләчәктә дә мондый хәлдә калмасын өчен, зур тырышлык күрсәтә. Берләшмә үткәргән чаралар аркасында, Ык елгасының Азнакай районы тирәсендәге өлеше сизелерлек сафланды. Шушма елгасының Лениногорск районындагы өлешендә хлоридлар бер кубметрда 173 грамм гына калды. Берләшмә үз хезмәткәрләренең бу өлкәдә җаваплылык тоюын алга сөрә. Әгәр берәр баш геолог, үзенә тапшырылган мәйдандагы бер чишмәнең пычрануына юл куя икән, үнөченче хезмәт хакының яртысыннан колак кага. Ике чишмәне бозса, бер тиен дә алмый. Бер караганда, бик кырыс чара сыман. Әмма чишмәне сафландыру бәясен искә төшерсәк, бу җинаятьтә гаепләләрне үнөченче хезмәт хакы белән генә куркыту аз да кебек. Аз шул. Табигатьне саклау өчен бик күп тармакларда тырышасыбыз бар әле. Әйтик, бер Лениногорск РАПОсына караган хуҗалыклар гына да елына — унике мең тонна солярка, биш мең 600 тонна бензин сарыф итә. Алардан чыккан сөрем исә без сулый торган һавага тарала. Шул кадәр ягулык яндыру кирәкме соң? Механизаторларның иртән кабызган тракторны көннәр буена сүндермәвен аз күрәбезме?! Машиналарны авылның буеннан-буена, бер максатсызга, аз куабызмы? Бер Лениногорск районында гына да елына унике мең тонна дизель ягулыгы тотыла. Ә республика күләмендә ул күпме була?! Алар һавага күпме сөрем, начар газ чыгара?! Бу агулы матдәләр яңгыр тамчылары белән бергә җир-суларыбызга да төшә, чишмәләребезне тончыктыра.

Чишмәләр, кизләүләр! Тирән коелар, саф сулы инешләр, тын күлләр! Аларның киләчәге күңелне өзлексез шомландырып тора. Безнең халыкта тагын «изге чишмәләр» дә бар әле. Болары аерым шифага ия. Моны миңа таныш геолог егет раслап күрсәтте. Изгегә саналган чишмәләрнең суын аның лабораториясендә тикшереп карадык. Мондагы су составында көмеш бар икән. Ә көмеш исә судагы зарарлы бактерияләрне бетерә.

Иске Писмән авылы тау итәгеннән шаулап чыгып яткан дистәгә якын чишмәләрнең тылсымлы көчкә ия булуын халык бик күптән сиземләгән. Чишмәләрнең даны бик еракларга таралган. Күп булса, моннан ун-унбиш еллар гына элек, июльнең матур бер иртәсендә шушы чишмәләр итәгенә бихисап халык җыйнала иде. Килгәннәрнең күбесе — гарип-гораба.

Ни өчен июль аенда җыйналалар? Чөнки иң җылы вакыт. Рәхәтләнеп тышта куна аласың. Туктаган җиреңдә, учак ягып, чәй кайнатып та була. Өстәвенә, андыйлар арасында дин әһелләре дә йөреп торган. Монахы-монашкасы, шәкерте-хәзрәте, дигәндәй җыйналган халык белән бергә гыйбадәт кылып, хак тәгалә хәзрәтләренә мөрәҗәгать иткәннәр, дәваланулар шуннан соң гына башланган.

Без, шәһәрнең комсомол активы исә, изге чишмәләр бөркегән аланга тегеләрдән бер атна алда сугышчан десант булып төшә идек. Палаткалар корабыз, көчле репродукторлар урнаштырабыз. Безнең күзлектән караганда, бирегә җыйналган караңгы, томана халыкны пыр туздырып куабыз, таратабыз. Аларның «аңгыралыгы, томаналыгы» турында лекцияләр укыйбыз. Көчле прожекторлар чишмә тирәләрен төннәрен дә айкап, яктыртып тора. Ерак җирләрдән, юк мөмкинлекләрен бар итеп, авыр юл мәшәкатьләрен кичеп килгән әлеге бичараларга кая керер урын калмый. Шифалы чишмә суларында дәвалану түгел, туйганчы эчәргә дә ирек бирмибез. «Дин сөреме белән тәмам агуланып, исерешеп йөрисез, аңгыралар, бар, кире кайтып китегез!» — дип орышабыз.

Без куып тарата торабыз, әмма елның-елында халык җыйнала бирә. Ә район түрәләренең фикере бер: ярамый булгач, ярамый. Иске Писмән авыл Советы бу чишмәләрне җир йөзеннән юк итәргә карар кыла. Әлбәттә, райбашкарманың күрсәтмәсе нигезендә. Ярдәм сорап нефтьчеләргә мөрәҗәгать итәләр. Шефлар — һәрчак әзер. «Изге чишмәләр» өстенә көчле бульдозерлар җибәрәләр, болынлыкны сөреп тә куялар. Мондый вәхшилеккә, хыянәткә бичара чишмәләр ничек түзсен — тынып калдылар, барлыкларын да сиздермәделәр. Тик... ике-өч елдан алар тагын күренде, әмма элеккечә дәрт белән, мул су бөркемиләр инде. Ургылып аккан шифалы чишмәләр урынында су саркыган, бака бакылдаган сазлык кына калды...

Шушындый ук шифалы, көмеш сулы чишмәләр Ульян өлкәсенең Ундорры авылы янында да бар. Бер җәйне үзем дә шунда барып дәваланып йөрдем. Чишмәләр итәгендә «көмеш чишмәләр» исемле дүрт-бишләп ял йорты көйләнгән. Оборона министрлыгы алты катлы санаторий бинасын салып ята. Ял йортларына путевкалар табу кыен, шунлыктан машинасы булган кеше чишмәләргә үз юлы белән килеп йөри икән. Бик ерак җирләрдән, хәтта Курган өлкәсеннән килүчеләр дә бар. Бер мәрхәмәтлесе чиш-

маләрнең иң мул сулысы янына зур казан китереп куйган. Без, путервкасызлар, шул казанга суны мөлдерәмә итеп тутырабыз да учак үрләтәбез Су җылынган арада, уен-көлке сөйләшәбез, хатын-кызлар җыр сузып җибәрә...

Бервкә мин шундый мәзәккә тап булдым. Шушы чишмәләр тирәсендәге матур бер урман аланында Лениногорскиның бер автохуҗалыгы да үзенә ял йорты салып маташа. Их, егетләр! Үз чишмәләребезне әле кайчан гына күмдердек бит!?.

Безнең республикада минераль суга һәрчак кытлык. Сәүдә оешмалары аларны Кавказдан кайтарырга авырсына. Чөнки бәяләре арзан, табыш бирми. Үзебездәге чыганакларга исә игътибар юк. Сугышлы белән Шөгер арасында самавыр юанлыгы торбадан күкертле су агып ята. Узган-барган кеше, бервкә туктап, авызын чылата, савыты булса, өенә дә ала. Су күп чирләр өчен шифалы. Әле утызынчы елларда ук бу суның ашказаны, эчәк чирләре белән интегүчеләргә файдалы булуы расланган. Шушы шифадан файдалануны юлга салучы гына юк. Җыр белән башлаган сүзне халык җыры белән тәмамлыйсы килә:

Салкын чишмәнең төбеннән
Бер таш алдым беләүгә.

Халык, шатлык кичерсә дә, башына кайгы-хәсрәт килсә дә, җыр җырлап юанган. Күп җырларда төп поэтик образ булып чишмәләр алынган. Димәк, элекке чишмәләребез безнең рухи байлыгыбызны арттыруга да хезмәт иткән. Бүгенге көндә исә шул байлыгыбыз — тәмам ташландык хәлдә. Инде нишләргә соң? Чишмәләргә ничек кенә ярдәм итәргә? Соң булса да, аңлый да башладык төсле, тик тынычланырга һич тә ярамый. Чөнки әле булса, инешләребезгә, елгаларыбызга һәр елны 802 миллион кубметр юынтык су түгелә, шуның 30 проценттан артыгы бертөрле дә чистарту узмый. Республикадагы 70 биологик су чистарткычларының тик берничәсе генә тиешле таләпләргә җавап бирә. Шуңа күрә безнең алдагы бурычлар һәммәбездән фидакарьлек, туган як табигатен саклау өчен, кискен көрәш, җитди эш көтүен онытмыйк!

## *Безнең календарь*

# АНЫҢ ЯГЫМЛЫ КӨЙЛӘРЕ...

Яраткан композиторыбыз Заһит ага Хәбибуллинга бу айда 80 яшь тулган булыр иде. Татар халкы, күп меңләгән җыр сөючеләр аның үзеннән башка гына сөекле композиторның туган көнен олы ихтирам белән билгеләп үтәләр.

Заһит Хәбибуллин иҗаты үзенең халыкчан рухы һәм киң масштаблы булуы белән аерылып тора. Чыннан да, композиторның иҗат бакчасында нинди генә жанрдагы әсәрләр юк! «Яшәсен тынычлык», «Безнең кардәшлек», «Казакъ дустыма» шикелле гражданлык темасы дисеңме, «Баулы», «Безнең басу», «Сабан туе — хезмәт туе» сыман хезмәткә дан җырлаучы әсәрләрме, яки инде «Сагыну», «Бормалы су», «Сайра син, тургай» кебек тирән лирика белән сугарылган җырлармы — аның иҗатында һәммәсен дә табасың.

Композитор күләмле жанрларга да мөрәҗәгать итте: «Язгы җилләр» һәм «Сихерләнгән малай» балетларын язды; театрларыбыз сәхнәләрендә куелган бик күп санлы спектакльләргә гаҗәеп матур көйләр дә иҗат итте. Әйтик, Г. Камалның «Беренче театр», Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Р. Ишморатның «Якын дус», Г. Ахуновның «Чулпы җыры» спектакльләрен Заһит аганың көйләре бизәде.

Композитор милләтебезнең инструменталь музыка сәнгатен дә баетты. Ул торба, кларнет, скрипка һәм виолончель өчен күп санлы әсәрләр язды. Бигрәк тә аның скрипка өчен «Поэма»сы һәм «Бию»е уңышлы килеп чыккан иде. Ә инде Заһит аганың скрипкада уйнаганын бер мәртәбә күргән кеше аны һич кенә дә оныта алмый.

Кыскасы, без Заһит Хәбибуллин шәхесенең һәм иҗатының кайсы гына ягын алсак та, анда тирән халыкчанлык һәм көчле моң ташып торуын күрәбез. Әнә шуңа күрә, композитор иҗаты озак яшәячәк, дибез.

Р. ИСХАКОВА-ВАМБА.

Җәмит Рәхимов

# КЕМ СИН, НӘДЕР ҮРӘЗМӘТОВ?

Туган илебездә, бигрәк тә үзебезнең Идел-Урал төбәгендә, җир мае эзләү янсә нефть промышленносте үсеше хакындагы кайсы гына китапны кулыңа алсаң да бер исемгә тап булмый калмыйсың — Нәдер Үрәзмәтов. XVIII гасырның алтмышынчы елларында Оренбург губернасының Уфа өязендә җир өстенә үзе саркып чыккан нефтьне җыеп, аны эшкәртергә һәм товарлыклы продукциягә әверелдерергә маташкан әлеге кеше башкорт старшинасы дип телгә алына. Фәнни китапларда мәгълүматларның шуннан артыгын табуы кыен. Бу аңлашыла да. Ул китапларны язган авторларның максатлары башка. Әлеге факт аларга «Идел белән Урал арасында нефть белән күптән кызыксынганнар» дигәнне раслау өчен генә кирәк. Ә шул предприятиегә җитәкчелек иткән Нәдер Үрәзмәтовның кем булуында, каян килеп чыгуында, гамәлендә аларның эше юк. Гади укучыны исә — бигрәк тә аның туган як, милли мәдәниятебез тарихын ярата торганын — нәкъ менә Үрәзмәтовның шәхесе кызыксындыра да инде.

Дөресен әйтим, бу исем минем дә йокымны алды. Фәнни китапларда аның исеменә юлыккан саен, әлеге кеше белән кызыксынуым артканнан-арта барып, җае чыккан саен аның турында мәгълүматлар туплый башладым. Нигә дисәң, Нәдер Үрәзмәтов эшчәнлеге нәкъ менә без яши торган яклар — Зәй һәм Шушма елгаларының үрге агымнары белән бәйле булырга тиеш сыман тоелды. Дөрес, әлегә ул эшчәнлеген җәелдергән урынны төгәл генә белмим. Шулай да фәнни китаплардагы «Казан юлында» дигән сүз тынгы бирми. Безнең Бөгелмә төбәге нәкъ менә элеккеге Уфа провинциясенең Казан юлына караган да бит инде.

Эзләнә торгач, тарихи чыганакларда һәм махсус әдәбиятта Нәдер Үрәзмәтов хакында байтак кына материал барлыгы беленде. Әүвәл башлап аны Россия Фәннәр академиясенең беренче член-корреспонденты П. И. Рычков үзенең «Оренбург топографиясе» (СПБ., 1762) дигән мәшһүр китабында телгә ала.

Эзләнгән кешегә Үрәзмәтов турында архивлардан да кайбер мәгълүматлар табарга мөмкин икән. Мәсәлән, Борынгы актлар үзәк дәүләт архивы (271 ф., Берг-коллегия, 1142, 1757 эшләр, 52-68, 68-80 б.), Свердловск өлкә дәүләт архивы, Оренбург тау эшләре начальствосы (1 ф., 89 тасвир, 1757 эш, 1-6, 23-25, 44, 55 бб.). Борынгы актлар үзәк дәүләт архивында саклана торган (350 ф., 2 тасвир., 3797 эш). Өченче ревизия материаллары бигрәк тә кызыклы. Алар Нәдер Үрәзмәтовның шәхесен һәм тормышын ачыклауга шактый ачыклык кертәләр.

Шул рәвешле, булган кадәр тарихи чыганаклар һәм архив материаллары белән танышу, Нәдер Үрәзмәтов хакында системалы сөйләп бирү мөмкинлеге тудырды. Бу әле аның тулы образы түгел, билгеле. Әлеге кызыклы кешене тулысынча күз алдына китереп бастыру өчен тагы да эзләнәсе, архивларда актарынасы бар. Хәер, мәкаләне язу максаты да Үрәзмәтов хакында күбрәк белүчеләр юкмы, сүзгә алар да кушылып китмәсме, дигән өметне күздә тота.

Мәгълүм булганча, 1719 елда, Петр I указы белән, тау эшләрен идарә итү өчен махсус орган — Берг-коллегия оештырыла. Озак та үтми, шул ук елның 10 декабрендә, эшлекле патшаның тагын бер указы халыкка җиткерелә. «Берг-привилегия» дип аталган бу закон нигезендә, кемнең-кем булуына, чинына һәм дәрәҗәсенә карамастан, бөтен җирдә (үз җирләрендә һәм аннан тыш) алтын, көмеш, бакыр, аккургаш, каракургаш, тимер кебек металлар, селитра, күкерт, купорос, кварц сыман минераллар, төрле буяулар һәм ташлар эзләү, эретү һәм чистарту эшләрен башкару рөхсәт ителә. Казылма байлыкларны эзләү һәм чыгару эшенә алынучыларга ул үзе теләгән урында 250Х250 сажин зурлыгында җир бүлеп бирелә һәм әлеге кеше ике ел дәвамында төрле салымнардан азат ителә. Яңа ятмаларны эшкәртү буенча заводлар салырга теләүчеләрнең Санкт-Петербургтагы Берг-коллегиягә янсә Мәскәүдәге, Себердәге һәм Казандагы берг-офицерларга мөрәҗәгать итүләре сорала.

Петр патшаның бу җәһәттән эшчәнлеге тарихи әдәбиятта киң яктыртылган. Яңа эшкә — тау эшенә алынучылар күп була, әлбәттә. Татарлар арасыннан да бу законнан файдаланып калырга теләүчеләр табыла. Казан өязенең ясаклы крестьяны Нәдер Үрәзмәтов — шундыйларның берсе. Тарихчы-галим С. Алишев күрсәткәнчә («Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании», 30 б.) үнсигез яшьлек Үрәзмәтов, 1729 елда Берг-коллегиядән башкорт җирендә завод төзүгә рөхсәт ала. Озак та үтми, Зәй, Шушма һәм Сок елгаларының үрге агымындагы калку җирләргә күчеп килә, далада кечкенә бер авыл ни-

гезли. Ул чактагы гадәт буенча, Сок елгасы буенда барлыкка килгән бу авылны нигезләүчесе исеме белән Нәдер авылы (русларда — Надыровка) дип йөртә башлыйлар.

Нәдер Уразматовның Казан ягыннан килеп чыгуы хакында башка кайбер авторлардан укырга була. Мәсәлән, «Кинҗә» романының авторы Гали Ибраһимов эпизодик герой Нәдер Уразматовны башкорт итеп күрсәтергә бик тырышса да, аның Казан ягыннан күчеп килүен икърар итми. Хәер, Уразматовның Казан татары икәнлеге документлар белән дә раслана диярлек. 1762 елның 9 июлендә, ул чакта бөтен Бөгелмә төбәгендәге татар авыллары кергән Нәдер волостенда, Өченче ревизия булып уза. Башлап, әлбәттә, волость старшинасының үз гаиләсе теркәлә. Дөрес, бу вакытта инде Нәдер Уразматов үзе үлгән (1758 ел) була, волость белән аның баш баласы Йосыф җитәкчелек итә. Безнең бәхеттән дип әйтик, Өченче ревизиядә беренче мәртәбә хатын-кызларның да саны алына һәм исемнәре документларга теркәлә. Менә Нәдернең беренче хатыны Тутыя Мекыятуллин кызы, 43 яшендә, Казан өязенең Җөри юлы Урмәдәй авылының ясаклы татарыннан алынган. Шул ук документлардан күренгәнчә, Нәдернең икенче хатыны Зифа — Уфа өязенең Казан юлы Елан волостендагы Балык дигән башкорт авылыннан. Өченче хатыны Зая исә Уфа өязенең Нугай юлындагы Тамьян волостендагы башкорт авылыннан.

Күренә ки, беренче хатынына ул, Сок буена күчеп килгәнче үк, туган якларында өйләнгән. Әгәр дә Нәдер башкорт җирендә туып-үссә, әллә кайдагы Урмәдәй авылында Тутыя исемле кыз төшенә дә кермәс иде. Димәк, ул үзе Казан төбәгенеке, кем белә, бәлки шул ук Урмәдәй авылыннандыр.

Шунысы кызыклы, күченеп килгәнче үк Уразматов бу якларның табигатен, мондагы шартларны яхшы белә. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе юк. XVIII гасырның утызынчы-кырыгынчы еллары — Казан, Зөя, Чистай өязләрендә яшәүче татар крестьяннарының артык изүгә, царизмның руслаштыру һәм көчләп чукындыру сәясәтенә чыдый алмыйча, күпләп-күпләп Оренбург далаларына, кояш чыгышында буш яткан җирләргә күченеп китү чоры. Акылы җиткәннәр кинәт кубып, теләсә кая, күз күрмәгән җирләргә күчеп китмәгәннәр, билгеле. Алар, башта араларыннан берничә кеше җибәреп, күзәтү ясатканнар, мөгаен. Нәдер Уразматов шундый күзәтчеләрнең берсе булса кирәк, һәрхәлдә, ул Бөгелмә төбәгендәге урман-елгаларны, буш яткан җирләрне, хәтта нефте җир өстенә үзе саркып торган дегетле урыннарны да белгән. Шулай ук аңа тирә-юньдә күчмә халыклар күченеп йөрүе, бу якларга килә калганда алар белән элемтәгә керергә туры киләсе дә мәгълүм булган. Нәкъ менә шуңа да ул Мәскәүдә үк күпләп товар сатып ала һәм аларны пошлина түләми генә алып бару өчен рөхсәткә дә ирешә. Ул хакта документларда болай диелгән: «Мәгълүм булганча һәм Уразматов үзенең үтенечендә белдерүенчә, башкорт халкының төрле бүләкләрне бик яратучан икәнен һәм шуннан башка аңа, Уразматовка, завод салганда төрле кыенлыклар тудырулары мөмкинлекне күздә тотып, реестрда күрсәтелгән товарларны пошлина түләми генә алып бару өчен аңа паспорт бирергә» (С. А. Алишев, югарыда күрсәтелгән хезмәт). Димәк, Уразматов яңа җирләрдә үзен ни көтүен алдан ук белгән һәм аңа Мәскәүдә үк әзерләнгән.

Тарихи чыганаклардан һәм документлардан күренгәнчә, Уразматов кибәккә алдана торганнардан түгел. Ниятләгән зур эшенә ул очраклы күргән бер «дегет базы»на гына ышанып тотынмаган. Сок һәм Шушма буендагы дегетле чишмәләрнең байтагы билгеле булган аңа һәм эшне зурдан кубып башларга исәпләгән. Үзе белән килгән юлдашлары Сок елгасы буендагы Нәдер авылына төпләнүгә (хәзер бу авыл Куйбышев өлкәсендәге Сергиевск шәһәре эчендә калган. Крепость тавы битләвендәге урынны әле дә Надыровка дип йөртәләр), ягъни бу тирәдәге нефть коеларына ия булуга, Уразматов кешеләренең бер өлешен Сагышлы елгасының Урман Шушмасына коя торган җиренә, ягъни якындагы нефтьле чишмә янына күчереп утырта. Шулай итеп, хәзер Лениногорск районына керә торган Сугышлы (XX гасырның егерменче елларына кадәр — Иске Нәдер) авылына нигез салына. Бу шулай ук документлар белән раслана. Югарыда телгә алынган Өченче ревизия материалларында (БАУДА, 350 ф., 2 нче тасвир., 3793 эш) Шушма елгасы буендагы Нәдер авылында яшәүчеләрнең исемлеге теркәлгән. Беренче итеп зимагур Сямгунов (Шамгунов) язылган һәм аңа менә мондый аңлатма бирелгән (шул чор колоритын саклау өчен текст русча һәм бар булганынча тыныш билгеләресез китерелә): «Оной перешел той же волости из деревни Старой Надыровой что на речке Соку в деревню Надырово что на речке Шешме Шугушле тож земагур из Надырово». Күренә ки, Уразматов кешеләрен зимагур дип йөрткәннәр икән. Димәк, Нәдер Уразматов, Россиядә беренчеләрдән булып нефть промышленносте эшенә алынуы белән бергә, Бөгелмә төбәген башлап үзләштерүчеләрнең берсе дә икән әле. Соңрак аның тагын бер авыл — Зәй буендагы, дөресрәге Урсалытамак елгасы буендагы Яңа Нәдерне (хәзер Әлмәт районы) нигезләвен дә искә алсак, бу сүзнең хаклыгы ачыклана төшәр. Кыскасы, шушы төбәктәге өч авылны нигезләгән кеше ул Нәдер Уразматов.

Шул рәвешчә, бу якларда даны чыккан җир мае коеларын билән алса да, ниятләгән зур эшен башларга ашыкмый Нәдер. Моның сәбәпләре була, әлбәттә. Беренчедән, завод

хәтле завод салу өчен (гәрчә ул бүгенге күзлектән караганда кечкенә генә булса да) акча кирәк. Ясаклы крестьянда ул ишелеп яткандыр дип уйларга ярамый. Аннан килеп, зур эшне башлаганчы җиде кат үлчәп кисү хәерле. Бөтен шартларны өйрәнү, проект сыман нәрсә булдыру һәм җиһазлар табу өчен вакыт кирәк. Алай да төп тоткарлык болар гына булмаган шикелле. Бу чор, ягъни XVIII гасырның утызынчы-кырыгынчы еллары, Оренбург җирләрендә яшәүче татар-башкортларның дулкын-дулкын булып әледән-әле күтәрелеп торган еллары. Заманалар болганчык, бөтен җирдә моң-зар, кан-яшь, кырылыш. Халык гавәменнән дә, патша ягыннан да күпләргә башларын салырга туры килә бәрелеш кырында. Сугыш-яулар күп кенә гаиләләргә ятимлек, коллык, ачлык, хәерчелек алып килә. Бу якларга баерга дип килгән Нәдер Уразматов исә шушы болганчык заманны да үзенә эшләтмәкче була — ул хөкүмәт яклыларга хезмәт итә башлый. Югарыда телгә алынган «Кинҗә» романында Нәдернең үз сотнясы белән Оренбург экспедициясе начальнигы Кириллов отрядына кушылуы һәм, йөзбашы буларак, Оренбург походында катнашуы языла. Һәрхәлдә, аның сотник булып патша хәзрәтләренә хезмәт итүе мәгълүм факт.

Урәзмәтовның ихластан патшага хезмәт итүе, шулай ук бу якларда билгеле булган дегет базларын үз кулында тотуы эзсез калмый, ул баеп китә, исеме югары катлаулар теленә керә. Җитмәсә, Нәдернең бәхетеннән диярга кирәк, XVIII гасырның илленче елларында башкорт җирләрендә яңа волостьлар төзелә. Аңа кадәр башкорт волостьлары ыруг-туганлык нигезендә яшәп килсә, хәзер инде волостьлар территориаль нигездә төзелә һәм алар элеккегедән күпкә арта. Чөнки инде бу якларда халык күзгә күренеп ишәя, алар белән идарә итү көннән-көн кыенлаша. Казан губернаторы Волынский 1730 елда үзәккә болай дип хәбәр итә: «Әле моннан егерме еллар элек кенә турыдан-туры башкортлар 35 мең, күп дигәндә 40 мең санала иде. Хәзер исә, качып килүчеләр белән бергә, 100 меңнән артып китте — Казан, Сембер һәм башка өлкәләрдәге ясаклы татарларның яртысыннан күбесе башкортка күчте». Әнә шул шартларда Зәй һәм Шушма елгаларының үрге агымнарында бик күп татар авыллары барлыкка килә, булачак Бөгелмә өязендә яңа волость — Нәдер волосте оеша һәм аның старшинасы итеп Нәдер Урәзмәтов куела. Эшләр болай зурдан купкач, Урәзмәтов югалып калмый, Зәй буенда яңа авыл нигезли һәм бөтен гаиләсе белән шунда төпләнә. Шуннан инде Яңа Нәдер зур бер территориядәге татар авылларының мәркәзенә әверелә.

Әмма Нәдер зур башлык булып алгач та яшьлек хыялыннан кайтмый, киресенчә, аңа ныклап ябыша. Чөнки инде нефте җир өстенә үзе саркып чыккан урыннар ныклап өйрәнелгән, байлык та, власть та бар. Ул Әсләм һәм Хуҗа Мозяковлар белән ширкәт сыман нәрсә оештырып җибәрә, саллырак булсын диптер инде, аңа үзенең өлкән улы Йосыфны (тегесенең бу эшкә һич дәрте булмаса да) да язып куя. 1753 елда шушы кешеләр исеменнән Берг-коллегиягә кабат үтенеч языла. Үтенечләрендә алар Сок, Сагышлы, Усаклы елгалары буенда өсләренә нефть җыелып торган күлләр һәм җир мае чыккан чишмәләр барын, шулар янында нефть заводы кору өчен уңайлы урыннар булуын хәбәр итәләр, үзләренеке булган шул җирләрдә завод салырга рөхсәт сорыйлар. Үтенеч янына — «ун кадактан да күбрәк булыр»— шушы якларда җир өстенә үзе агып чыккан нефть тә куела. Берг-коллегиягә җибәрелгән бу үрнәк 1754 елның 28 январенда берг-пробирер Христиан Леманга «тикшереп карау», ягъни анализ ясау өчен тапшырыла. Шул ук елның 21 февралендә Христиан Леман, Берг-коллегиягә махсус рапорт язып, анализ нәтиҗәләрен хәбәр итә.

Нәдер Урәзмәтов һәм аның иптәшләренең үтенечен караганда (1754 ел, 16 июнь) Берг-коллегия Христиан Леман биргән нәтиҗәгә таяна, ширкәтчеләргә завод салырга рөхсәт итә, ике елга салымнардан коткара, аларны кем генә, нинди генә чиндагы кеше җәберләсә дә, яклаячагын белдерә, шулай ук табылган нефтьне ирекле бәя белән Россия империясенең бөтен почмагында сату хокукы бирә.

Бу кадәр уңыштан дәртләнгән Урәзмәтов шундук эшкә тотына, Камышлы елгасы буена завод өчен каралтылар салдыра. 1756 елда Берг-коллегия бирегә, әлеге нефть чишмәләре белән танышу өчен, «геодезия укучысы» Павел Зарубинскийны җибәрә. Зарубинский әлеге чыганакларны тасвирлап кына да калмый, аларны картага төшерә. Борынгы актлар үзәк дәүләт архивында бүгенгә кадәр сакланган ул карталар Идел белән Урал арасындагы нефть кырының беренче картографик материалы булып санала.

Шунысы аяныч, Урәзмәтовка башлаган эшенең ахырына чыгарга туры килми, ул 1756 елда бик каты чирләп китә һәм шуннан аягына баса алмый. Улы Йосыф исә «ул заводны төзергә теләми». 1757 елда Оренбургтагы тау промышленносте башлыклары Урәзмәтов заводындагы хәлләрне Берг-коллегиягә хәбәр итәләр. Шулай ук Нәдер Урәзмәтовның, терелгәч, заводны эшләтеп җибәрергә ниятләнүен җиткерәләр. Ләкин Берг-коллегия Урәзмәтов терелгәнне көтеп тормый, аны заводчиклар исемлегеннән чыгару турында да карар кабул итә. Озакламый, 1758 елда, Нәдер үлеп китә. Үзеннән соң күп кенә (ун малай, ундүрт кыз) бала калса да, әтиләренең эшен дәвам итәргә теләүчесе табылмый. Нәдернең башка фикердәшләре дә бу эштән суыналар. Шулай итеп, Россия тарихында беренче тапкыр нефтьне җыю һәм аңардан керосин алу эше уңышсыз тәмамлана.

Инде Нәдер Уразматовның үлемен телгә алганбыз икән, тагын бер нәрсәне әйтеп үтми булмый. Мәгълүм булганча, Россиядәге беренче милли-азатлык хәрәкәтенең идеологы һәм җитәкчесе Батырша, 1755 елгы восстание бастырылганнан соң, юкка чыга. Соңрак ачыкланганча, ул бер шәкерте белән Иске Нәдер (хәзер Сугышлы) авылы мәчетенең базында качып ята. Бу хәл беленгәч, Нәдер Уразматовка бик күп авыр сүзләр, янаулар ишетергә туры килә. Чөнки качкын аның иске авылында яшеренеп яткан бит. Бу хәлдән коты алынган Уразматов авырып китә, шуннан инде мантымый.

Ничек кенә уңышсыз тәмамланмасын, Уразматов башлаган нефть эшенең гаять зур әһәмияте була. Чөнки бу, әйткәнебезчә, Россиядә нефтьне җыеп, аңардан продукция алырга тырышуның башлангычы. Уразматов предприятиесенә төрле чордагы галимнәр һәм промышленниклар зур әһәмият бирәләр, аның белән кызыксыналар. Югарыда әйтелгәнчә, иң башлап бу хакта Петербург фәннәр академиясе член-корреспонденты П. И. Рычков язып чыга. Академик П. С. Паллас та үзенең «Россия империясенең төрле урыннарына сәяхәт» (1773 ел) дигән китабында аңа шактый зур урын бирә. Совет тарихчылары С. М. Лисичкин һәм А. Е. Пробест «Нәдер Уразматовның нефть заводлары товарлыклы нефть чыгару буенча чын-чынлап махсус предприятиеләр булдылар»,— дип саныйлар. Профессор К. В. Кострин исә аның турында түбәндәгене яза: «Нәдер Уразматовның уңышсызлыкка юлыгуына карамастан, аның нефть заводы төзү эшен дәвам итәргә ныклы теләге барына гаҗәпләнергә генә кала. Фактта бу Идел нефтен беренче тапкыр практикада файдаланырга тырышып карау иде» (К. В. Кострин. «Тирән тамырлар». Уфа, 1971, 130 б.).

Уразматов нефть эше галимнәреннән Б. М. Йосыпов, В. И. Троепольский һәм башкаларның хезмәтләрендә дә телгә алына. Гаҗәп тә түгел. Бу бит нефть җыю һәм аны файдалануның моңа кадәр яшәп килгән кустарь ысулларыннан баш тартып, беренче мәртәбә аны оешкан төстә промышленность ысулы белән җыю һәм эшкәртү, ягъни беренче промысел булдырырга тырышу дигән сүз.

Нәдер Уразматов эшчәнлегенең тагын бер әһәмиятен аеруча басым ясап әйтми мөмкин түгел. Бездә әле һаман да: «Татарлар элек игенчелек һәм терлекчелек белән генә шөгыльләнгәннәр»,— дигән караш яшәп килә. Уразматов эшчәнлеге мондый караштагы торучыларны уйланырга мәҗбүр итәр, дип ышанырга кирәк. Архив материалларында һәм тарихи чыганакларда күзгә чалынып-чалынып киткән Боляк Русаев, Җанкилде Сөбханкулов, Буран Йөгерекев кебек мәгъдән эзләүчеләребез, руда танучыларыбыз да булганлыгын искә төшерсәк, мәсьәләне алай беркатлы гына хәл итеп куюның ашыгычлык икәне тагын да ачыкланса кирәк.

Кыскасы, безнең халыкның әллә кемнәре, бөек шәхесләре булган һәм бар. Белеп кенә бетермибез без аларны. Белгәннәре хакында да аз һәм сай язабыз.

**Мәхмүт Әхмәтҗанов,**

педагогия фәннәре кандидаты.

# БАР БЕР АВЫЛ УРАЛ ИТӘГЕНДӘ

Туган як һәркемнең күңелен үзенә өзлексез тартып тора. Мине дә шулай. Туган җирем — Башкортстанның Салават районындагы Нәсибаш авылы. Ул аның җәнлекләргә, төрледән-төрле күбәләкләргә, чәчәкле аланнарга бай урманнары! Аның болыннарындагы хуш исле җиләкләр! Көз җитә башласа, гөмбәләр калкырга тотына! Гөмбәләр шулкадәр күп була ки, халык аларның ак гөрешдә дигәнен генә җыя, беразын, кышлыкка дип, тозлап та куя. Нигездә, гөмбә — ул урыс ашы, әйдә, алар җыйсын, безгә башкасы да җитә, дип карый. Каен җиләге, җир җиләге, кура җиләге, кара җиләк, мүк җиләге, балан, аю җиләге, карлыган (кызылы да, карасы да), бөрлегән, тау чиясе, тигезлектә өлгерә торган ничәмә төрле бик тәмле урман җиләкләрен ашаган бала-чага бик кыен елларда да рахит кебек авырулардан интекмәде. Балык исә бервакытта да нәсибашлыларның яраткан азыгы булмады. Юкса, өч зур тегермән буасы, 6-7 чакрымда гына ага торган балыкка бай Әй һәм Йөрүзән елгалары да яшь-җилкенчәкнең күңел кылларын чиртергә тиеш иде кебек. Һәр халыкның үзе аеруча хөрмәт итә торган һөнәре була, күрәсең. Нәсибаш халкын кеше иткән нәрсә — иген игү, дип нәтиҗә ясау хакыйкатьтән артык еракка китү булмас.

Инде авыл хакында берничә сүз. Татар язучысы Нәкый Исәнбәтнең хезмәтләренә мөрәҗәгать итсәк (җәя эчендә генә булса да, фикеремне әйтим әле: Татарстан союздаш республика саналса, Нәкый ага кебек бөек акыл иясен күптән академик итеп сайлап куярлар иде инде, безнең үз Академиябез юк шул...), шуны күрәбез: ул халык авыз иҗатыннан мисаллар китерә дә өтер аша «Нәсибаш», дип куя.

Бу — безнең авыл исеме. Тарихи язмаларга караганда, 1759 елның 19 мартында 11 гаилә Олы Мерәсем авылыннан Яңа Каратаулы башкортлары җиренә күчеп утыра. Бу хакта Башкортстан дәүләт архивында махсус документ саклана. Аңа Уфа губернасының вице-губернаторы һәм баш землемере кул куйган. Язма-килешү закон төсен алсын өчен, аңа мөһер дә сугылган. Бу килешү кәгазендә сүз түбәндәгечә бара: Олы Каратаулы волостеның барлык башкортлары да — иң өлкәннәреннән алып, иң кечкенәләренә кадәр — җирләренең бер өлешен (картасы китерелгән, җир чикләренең исемнәре аталган) үз теләкләре белән күчеп килүче унбер татар гаиләсенә сатып биргәннәр. Документның тел төбеннән шул аңлашыла: әлеге 11 гаилә, ниндидер күләмдә дәүләт кешеләре итеп саналган. 11 гаиләгә ике старшина һәм бер мулла булу шуңа ишарә ясый кебек... Дәүләт аларга ел саен акча биреп торган. Акчаның барысы да диярлек башкортларга, җир өчен, түләүгә китеп барган. Нәсибаш җиренең шактый зур мәйданы «Мәскәү тавы» дип атала. Бу исем болай килеп чыккан. Документлардан шул аңлашылды: татарлар әлеге җирнең хакын тулысы белән түләсәләр дә, башкортлар: «Ер ул ете катлы, өстәгеһе кат беззеке, астагыһы алты катламы татарга булһын!» — дип, ыгы-зыгы чыгарганнар. Бу мәсьәлә, Мәскәү судында каралып, татарлар файдасына хәл ителгән. Хәлбуки, мондый хәлләр еш кабатланган булса кирәк. Чөнки Бөек Октябрь революциясенә кадәр Урал татарлары иген игә, печән чаба торган урыннарны гел башкортлардан сатып алып көн иткәннәр. Мәсәлән, Нәсибаш халкы Лагыр, Шәрәк, Чыбаркул, Кадер, Мөхәммәт, Каратаулы, Урманчы авылы башкортларыннан җир сатып алып көн иткән. Өй, каралты-кура, тегермән салу, утын әзерләү дә «килмешәк татар»га шактый кыен булган. Октябрь революциясе җиңеп чыкканнан соң гына татар авыллары иркен сулыш алган. Шулай да көчләр һич тигез булмаган. Сәнәк сугышы вакытында, «Кызыл Нәсибаш»ны (бу вакытка ул шактый үсә, волость үзәге була, волостька 46 авыл һәм хуторлар кергән) шул тирәдәге 14 башкорт, рус авылының хәлле кешеләре: «Авылның эзен дә калдырмаска кирәк!» — дигән аваз салып, берничә йөз атлы кеше камап ала, әллә ничә урынга ут төртәләр. Бәхеткә, авыл Советы ревкомы рәисе бу хәлләрне алдан күрә, вакытында Усть-Катаев эшчеләр поселогыннан кызыл командир иптәш Туманов җитәкчелегендәге бер батальон (В.Блюхер оештырган Урал эшчеләре Кызыл гвардия армиясенең бер өлеше) сәнәкчеләрнең арт сабакларын укыта. Ләкин сугыш корбансыз булмый. Нәсибаш Совет ревкомының комиссарлары сыйнфый дошман тарафыннан вәхшиләрчә җәзалап үтерелә. 30 нчы еллар уртасында Мәдәният сарае янында аларга һәйкәл куелган иде. Хәзер шуның күршесендә Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә монумент калкып чыккан...

Авылымда мин шактый еш булам. Уйларым беренче нәсибашлыларга барып тоташа. Кимендә 100 чакрымга бер адәм заты күренми торган кара урманга нәрсә дип, нинди максатлар белән килеп утырдылар икән алар? Аларны бит берәү дә кочак җәеп көтеп тормаган. «Купчи кәгазе»ндә дә бик ачык әйтелгән: без, башкортлар, бу татарларга 25 тән артык өй-каралты салырга рөхсәт итмибез. Колмак җыярга ярый. Ләкин умартачылык, бөркет аулау белән шөгыльләнергә рөхсәт ителми. Бер урында тегермән корырга (сүз кечкенә Нисе елгасы хакында бара) рөхсәт.

Дөресен әйтергә кирәк: авыл утырган урын бик бай һәм матур. Урманында карагач, карагай, нарат, чыршы, каен, имән, тал, шомырт, зирек, юкә, өянке һәм тагын әллә нинләр үсә. Җанварлардан керән аю, бүре, төлке, куян, поши, кыр кәҗәсе, кыргый дуңгыз һәм сасы көзән, әрлән кебек бихисап вак җәнлекләр — урман тулы.

Халыкның көрәшчән рухлы булуын да ассызыклап китәсе килә. Моның үз сәбәпләре бар. Шуларның берсе — күп кенә яшьләрнең эшкә якындагы завод-фабрикаларга урнашуы. Кайберләре, кышын завод икмәге ашап, җәй көне крестьян хезмәте белән шөгыльләнгән. Эшчеләр белән бәйләнешкә керү авыл яшьләренә идеологик йогынтысыз калмаган. 1905-07 елларда күп кенә нәсибашлыларның казна урманын кисүдә актив катнашуы, налог түләүдән баш тартуы нәкъ шул хакта сөйли. Октябрь революциясе көннәрендә үк инде бу авылда РСДРПның башлангыч оешмасы була. Бик кыска вакыт эчендә авылда ныклап совет власте урнаша. Ревком, авыл советы ныгый башлый. Әмма болар җиңүгә беренче адым гына әле. Бик күп нәсибаш татарлары сәнәк сугышы, Колчак армиясен куган вакытта һәлак була.

Революция җиңү белән үк, Ленин идеясенә нигезләнеп, Нәсибашта беренче авыл хуҗалыгы кооперативы оештырыла. Аны «Артель» дип йөртәләр. «Артель» иген игә, терлек үрчетә, моңарчы күрелмәгән уңышларга ирешә. Ләкин, кызганычка каршы, артельнең гомере озын булмый. Аның урынына, авылны икегә бүлеп, М. И. Калинин исемендәге һәм «Восток» колхозлары оештырыла. Ул чакларны инде мин дә яхшы хәтерлим. Калинин исемендәге колхозның рәисе итеп минем әтине, Рәхимҗан Әхмәтҗановны, «Восток» колхозына авылның иң уңган кешесен — Фәсәх Зәйнетдиновны сайладылар. Кечкенә булсам да, әлеге ике колхозга мәңгелеккә җир бирү бәйрәмнәрен зур тантана белән үткәрү мәҗелесләрен хәтерлим. Халык бик шатланды. «Җир мәңгелеккә бүлгәч, барыбыз да бик нык тырышып эшләрбез, кумәк хуҗалыклар чәчәк атачак»,— дип, бик күпләрнең куанып сөйләүләре колакка кереп калган. Ләкин чынбарлык көтелгәннәрнең берсен дә раслап өлгермәде. Хәллерәк крестьяннарны, бик булдыклы гаиләләрне, кулак тамгасы тагып, ерак җирләргә сөрделәр. Кумәк хуҗалыкка тупланган ярлыларның хәле дә җиңел булмады. Чәчәргә орлык юк дәрәҗәсендә. Ашарга да онны колхоз председателе, үзе кашыклап дигәндәй, бүлеп утырды. Бу — яңа оеша башлаган хуҗалыкның иң беренче кыен адымнары иде. Моннан соң хәлләр рәтләнә төште кебек. Халык колхозга ышанды, аны үз итте. Бик тырышып эшләделәр. Хәтергә кереп калган: бер елны икмәк шул кадәр уңды ки, колхоз амбарында урын җитешми, дип, олау-олау ашлыкны хезмәт көненә тиешле санап, кешеләрнең ишегалдына, абзарларына ташыдылар.

Әмма бераздан кумәк хуҗалыклар тормышында кискен борылыш булды. Моны шул замандагы бала күзәтүе белән генә аңлап та, аңлатып та булмас иде. Бүген исә күп нәрсәләргә күз ачылды. Сталин авыл хуҗалыгында кешелексез, хәтта явыз политика алып барган һәм үзенең бөтен әшәкелеген партия оешмалары, съездлары яки Политбюро исеме белән тормышка ашырган. Мин әллә нинди мисаллар да, саннар да китереп тормыйм. Әтием җитәкчелек иткән Калинин исемендәге колхоз үрнәгенә генә бераз тукталам.

«Кулаклар» дип, иң тырышып эшли торган гаиләләрне, төбе-тамыры белән каерып, еракка озатканнан соң да халык әле югалып калмады, колхозга ышанды, көнне төнгә бәйләп эшләде. Үзәк урам уртасына Хөррият капкасы төзеделәр, аны бик матурлап бизәкләделәр. Колхоз шактый ныгып китте. Үзенең ихтыяҗларын тәэмин итәрлек электр станциясе салды. Райпотребсоюз ике зур кибет ачты һәм... бөтен алга китеш шуның белән тәмамланды дияргә була.

Чөнки ленинчыл кооператив хәрәкәте бөтенләй туктатылды, дияргә мөмкин. Кооперация мөнәсәбәтләре бары тик авыл кибетләренә карата гына сакланып калды. Анысы да дәүләт товарларына бәя өстәп сатудан узмады. Кешегә хәтта агачтан мичкә ясап, юкәдән аркан ишеп сатарга да рөхсәт ителми башлады. Янәсе, бу хәл халыкны спекуляция юлына тартачак. Хәтта өй тирәсендәге 25 сотый җирдә дә бәрәңге, кишер чөгендердән башка нәрсә утыртырга рөхсәт ителми иде. Янәсе, андый кеше колхоз хуҗалыгында начар эшләр дә, бакчасыннан алган яшелчәләрне сатып баер. Кешеләрне туктаусыз авыл советына, райфинагентка чакырулар, җәзалаулар гадәткә керде. Терлек асраучы һәр хуҗалык дәүләткә 44 кг ит, 300 литр сөт, 100 йомырка, 2 сарык тиресе, хәтта сарык сөте тапшырырга, акчалата да шактый күләмдә ясак түләргә тиеш булды. Шунлыктан кайберәүләр шәһәргә күчү турында хыяллана иде, тик моның өчен иң

әүвәл паспорт кирәк. Крестьяннарга исә паспорт бирелми. Шулай итеп, безнең оҗмахтан шәп урында тамыр җибәргән авыл, күзгә күренеп хәерчеләнә, ач-ялангач хәлгә кала бара иде. Ике кибеттә тоз, серкә, тәмәкедән башка берни күренмәде.

Әмма хәтта шул чакта бер кеше дә: «Колхоз бетсен иде!»— димәде. Бу, бер карaганда, бик аңлашыла. Халыкны, бергәләп эшләү һәрвакытта да уңышка китерә, диган уй канатландыра. Киң кырларда күкрәп ашлык өлгерә — күмәк тырышлык нәтиҗәсе. Тик... халык барыбер ач, ник дисәң, җыелган ашлык тулаем дәүләт амбарларына китә. Орлык кына калдырыла. «Бу корткычлыкмы әллә?»— дип уйлаучыларны очратсаң, әлеге кешене соңгы күрүең була: андыйларны каядыр озаталар...

Сталин политикасының иң зур зыяны, минемчә, авыл хуҗалыгында булды. Шул нәрсә хәтердә калган: яңа икмәк өлгергәнне авыл зур түземсезлек белән көтеп тора. Иң элек аны дәүләткә озаталар. Ач халыкның күңелен күтәрү өчен бераз гына ашлыкны да тегермәндә тарттырып алырга ярамый, авылның шымчылары бу хәбәрне шундук прокуратурага җиткерә. Һәм шул ук сәгатьтә минем әткәйне милициягә алып китәләр. Бер генә төрле аңлату да коткара алмый аны. Менә шулай, икмәк мөлдерәп өлгергән чакта да халыкны ач тоттылар. Хәзер мин бу мәгънәсезлеккә, аңлы рәвештә илнең үсешенә аяк чалу булгандыр, дип тә карыйм. Әмма вакытында ул хакта әйтү түгел, уйларга да мөмкин түгел иде. Кеше өстеннән яла ягучылар артты. Кулына бер генә мәртәбә дә сабан, урак, чалгы тотмаучы бушбугазлар яхшы игенчеләрне, терлекчеләрне Себер җибәрде. Андый бәндәләр кемгә теләсә, шуңа: «Патша сезнеке иде, революция безнең өчен ясалды, әйдә, мышнамый гына тырышып эшләгез! Без сезнең чичек эшләвегезне тикшереп торыйк!»— дип масаялар иде.

Никадәр генә сабыр, чыдам булмасын, бушка эшләү крестьянны нык үзгәртте. Ул: «Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын!» — дип уйлый, колхоз эшеннән суына башлады.

Кешене мыскыл иткәндәй, матбугатта бөтенләй башкача языла килде. Миллиард пот икмәк тапшыру хакында газета-журналларның беренче битләрендә кызыл рапортлар бирелә. Кыскасы, ялганлашу гөрләп чәчәк ата иде...

Мин Бөек Ватан сугышын 12 яшьлек яшүсмер хәлемдә каршы алдым. 1941 елны икмәк бик нык уңган иде. Ләкин эшчән ирләрнең сугышка китеп бетүе, кышның исә бик иртә килүе сәбәпле, тамырдагы ашлыкны кар каплады. Шулай да халык аптырап калмады. Укучылар зур агач көрәкләр белән икмәкне кардан арчыды. Хатыннар чалгы белән чапты. Ындыр табагында ашлык сугуны көйләделәр. Киптерү өчен халыкка тараттылар. Ничек кенә булмасын, икмәк дәүләт амбарына китте. 1901 елгы әтием Рәхимҗан 1941 елның 23 октябрендә, Калинин шәһәре өчен барган сугышта каты яраланып, госпитальгә эләкте. Бер-ике атнадан соң яңадан фронтның алгы сызыгында, Ржев, Торжок шәһәрләре өчен сугышларда бер кулын өздереп, туган җиренә — Көньяк Урал татарлары янына кайтты һәм тагын да озак кына еллар колхоз рәисе булып эшләде. Бик кыен булгандыр инде аңа: колхоз амбарлары буш, сыерларның сөте юк, чөнки кыш буе юк-бар белән генә җан асрыйлар. Мин ике ел бригадир булып эшләдем, шул дәвердә бер генә кеше дә ашарга юк, эшкә чыга алмыйм, димәде. Бүген шул хакта уйлыйм да, төпле генә җавап таба алмыйм. Халык, мөгаен, Ватанның язмышын үз хәленнән өстен санагандыр. Без кинофильмнардан сугыш чорында станокка буе җитмәгәч, урындыкка басып детальләр кыручы яшүсмерләрне күргәлибез. Мондый хәлләр авыл җирендә дә тулып ятты. Мәсәлән, минем кебек 16 яшьлек үсмерләрне «Сталинец-6» комбайнын йөртергә өйрәттеләр. 20 көнлек курс үттек. Миңа ярдәмче итеп каичандыр тракторчы булган башкорт хатынын билгеләделәр. Икенче елны фронттан каты яраланып кайткан Ишхуҗа агай белән эшләдек. Сугышның беренче аенда ук Нәсибашка кара кайгылы хәбәрләр килә башлады. Йөрәкләрне тетрәндерә торганы — Гайния карчык хәле. Ул биш баланы берүзе үстергән иде. Беренче бөтендөнья сугышында аның ире Гариф агай һәлак булган. Бөек Ватан сугышы исә аның өч улын һәм ике киявен «йотты». Бу сугышта ике йөзләп нәсибашлы һәлак булды. Арада үзәкне өзәрдәй истәлеккә бәйле авылдашларым да бар. Шуларның берсе — Шурка Хәсәнов...

...Кояшлы матур иртә иде, без — ун-унике яшьлек малайлар — яшел чирәм өстендә мәтәлчек ясыйбыз. Карасак, яныбызга бөтенләй таныш булмаган малай килеп баскан. Буйга әллә ни зур түгел. Түбәтәе генә бик матур да, чәчләре генә безнекенә охшамаган — нәкъ җитен. Исемен үзе әйтте: Саша, Шурка, Александр, диде. Аны Гөлсем апа белән Сабир абый Хәсәновлар Бохара шәһәрендәге балалар йортыннан тәрбиягә алганнар икән. Шурка татарча сөйләшергә бик тиз өйрәнде. Безнең колакка исә урыс сүзләре әллә ни ят булып тоелмый башлады.

Шурка тиз арада бөтен авыл халкының яраткан баласына әйләнде. Ул колхоз эшенә дә тиз ияләнде. Әмма, әлеге дә баягы, ул да безнең кебек үк ачлы-туклы иде инде. Шулай да ул авылдан беркая да китәргә уйламады. Бөек Ватан сугышы башлангач кына Шурканы беренчеләрдән булып армиягә алдылар. Аңардан бер елга якын хат килеп торды. Ләкин беркөнне: «Өлкән сержант Александр Сабирович Хәсәнов Ватан өчен барган каты сугышларда батырларча һәлак булды»,— диган кайгылы хәбәр килде. Бөтен авыл: өлкәннәр дә яшьләр дә «аһ» итте...

Кабатлап үтим, Нәсибаш революциягә кадәр үк «волостной» авыл булган. Бу волостька якын тирәдәге рус, башкорт, татар кешеләре яшәгән 46 авыл кергән. Моның картасы да саклана. Шуңа күрәдер, татар мәктәпләреннән тыш авылда ир һәм кыз балалар өчен аерым-аерым русча мәктәпләр дә ачканнар. Мәгърифәткә әһәмият бирү авыл кешеләре язмышында ачык күренә. Бу төбәктән өч татар генералы — Р. Вәлиев, Б. Әминев, Х. Ганиев, профессор Г. Сәгъди, тел белгече, «Идегәй» дастанын беренче табучы Нигъмәт Хәким һәм бөек әдибебез Нәкый Исәнбәт чыккан. Русча язучы шагыйрь Михаил Давыдович Львовның туган авылы да — Нәсибаш. Ул да гомеренең азагына кадәр, авыл кешеләре белән бәйләнешне өзмәде, туган телне онытмады. М. Львовның әтисе Дәүләтша ага Габитов Нәсибаш авылындагы революцион көрәштә актив катнаша. Тик Блюхер армиясе батырлары гына аны һәлакәттән коткара. Рәфкать абый Дәүләтшинның (М. Львовның чын исеме шулай) әнисе — укытучы, Златоустта гимназия бетергән. Мөгаллимәнең кабере — Нәсибаш зиратында. Күренекле тел белгече, профессор Ф. А. Ганиев — шулай ук Нәсибашта урта мәктәп бетергән, шуның директоры булып та эшләгән кеше. РСФСРның атказанган артисткасы Зилә Сөнгатуллинаның әтисе Нәсибашта күмелгән. Әнисе укытучы-пенсионерка. Нәсибашлылардан Уфада һәм Казанда эшләүче доцентлар да байтак. Озак еллар буена җаваплы эшләр башкарган пенсионер Р. Исмәгыйлев, отставкадагы полковник З. Нәсибуллин авыл белән әле дә даими бәйләнештә торалар.

Авылның бүгенге хәле дә яхшы, дияр идем. Йортлары юан-юан нарат бүрәнәләрдән салынган. Урта мәктәбе бар. Иң күңеллесе — уку татар телендә алып барыла. Дөрес, заманында башкортча укырга кушучылар булган, әмма халык үзенекен иткән.

Урал итәгендә Нәсибаш исемле татар авылы нигезләнгәнгә 230 ел тулып узды инде. Хәзер мондагы уңганнарга әүвәлгечә килмешәк итеп карамыйлар. Аның үз теле, мәдәнияте, матур гадәтләре бар. Экономик яктан да авыл шактый нык. Нәсибаш һәм Калмаклар авыллары Уфадагы бер производство берләшмәсенең ярдәмчел совхозы итеп оештырылган. Беренче нәтиҗәләр бу яңалыкның уңай якларын күрсәтә. Предприятие авылда үз цехларын ачкан. Авылны кирәк-ярак белән тәэмин итү буенча эшлекле чаралар күрелә. Авылга су һәм газ үткәрү күздә тотыла.

Шәһәр кешеләренең мондый ярдәменә җавап итеп, нәсибашлылар аларга үз мәйданнарында ял йорты салырга мөмкинлек тудырырга уйлыйлар. Уңган халык теләгенә ирешми калмас, дип ышаныйк!

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Зиннур Мансуров

# СИКСӘНЕНЧЕ ЕЛЛАРНЫ ОЗАТКАНДА...

Гыйбрәтле заманда яшибез. Вакыт бик тә кырыс: берәүләргә аяусызлык күрсәтә, икенчеләргә мәрхәмәтен белдерә. Сталинизм дәверенең токтыны хәтта парламентка күтәрелә. (Шагыйрь Д. Кәгелтдиновны күзаллап әйтүем.) Халыкара коммунистик хәрәкәтнең «күренекле» эшлеклесе, кәтмәгәндә-уйламаганда, диктатор буларак гомер юлын тәмамлый. (Югыйсә үзенә әле генә Ленин ордены биргән идек. Аңламассың бу дөньяны!...) Хәтта кайбер компартияләр законнан тыш дип игълан ителүгә дучар була. Тамырланган һәйкәлләр урыннарыннан кузгала. Җете кызыл хакыйкать уңарга мәҗбүр ителә. Кырыс вакыт бөек тәгълиматларга төзәтмә кертүне таләп итә. Соцреализм турындагы күпме хезмәтләр (апологет галимнәрнең гомерлек тырышлыгы) үзләренең беренчел кыйммәтен югалтты.

Рәсми нотыкларда макталган кирпеч калынлыгы китаплар әкренләп ниндидер төссез комга әйләнеп бара. Тыелган әсәрләр халыкка кайта. Скрипкә искергән саен яхшырыр, диләр. Хак сүз. Ерактарак калган саен җыры матуррак булып ишетелүче Дәрдемәнд искергән китаплары белән банкротлыкка чыкканнарга көлемсерәп карый шикелле. Шушындый чорда яшибез. Энциклопедияләр ялганчылыкта гаепләнә. Язу карасы кипкәнче, язганың искереп куя. Хәтта борынгы мәкальләрнең зирәклек дәрәҗәсе төшә. Гимннар үзгәрә. Җырлар күзгә күренеп искерә. «Данлы юлдан җиңүләргә руслар алып бара безне...» Ләббәйкә кулына эләккән каләм, русларны уңайсыз хәлгә куюын аңламыйча, ничә еллар шулай җырлады. Дөреслеккә йөз тоткан вакыт классикларны да аямый... «...Син кулыңны биреп, оялмыйча, Солтангалиевтәй этләргә, Кәрәшкәнсең һәрбер адымыңда Таяк тыгып безнең эшләргә». Революция үзенең улларын ашаган чакта беренче корбан булган сөекле шагыйребез һ. Такташның «Син дошманым минем» шигырен инде хәзер бөтенләй башкача кабул итә башладык. «Иоттырмакчы» кайбер Солженицын Идән асты әдәбиятын... Коммунизм түренә тыкшынмакчы...» Совет концлагеренда уналты ел газап чигеп кайткан атаклы әдибебез Х. Туфанның үз «богаудашы» турында әйткән әлеге сүзләренә дә вакыт төзәтмә кертүгә иреште.

Арба ватылгач, юл күрсәтүче күп булыр. Анысы бик дөрес. Классикларга тел теш тидерергә теләмимен. (Кәферлектән аллам сакласын!) Акыллы булып калуны да максат итеп куймадым. Изге Корьәннән ялгыш эзләүчедәй, зирәк ревизор буласым килми. Янәдән искәртеп үтәргә генә телим: менә нинди каршылыклы заманда яшибез.

Шигърияттнең 1989 елдагы торышын бәяләү, үтә кыен гына түгел, хәтта гайре табигый омтылыштыр. Аерым әдәби елның уникә аен үткән белән киләчәктән аерып булмый. Ноябрьдә пошиларның мөгезе төшә, марттан яңасы үсә башлый. Ә шигърият андый төгәл фасыллар кичерми шул. Мәңге яшел шигърият агачында төп-төгәл еллык бөҗраләр барлыгын ышандырып әйтә алмыйм. Һәртөрле сәнгать күчеш юлы белән түгел, ә хәзинәсен ишәйтү хисабына алга барадыр. Һәрберебез белергә тиеш хакыйкать. Шигърият үсешен бер елда басылып чыккан китаплар саны белән генә дә билгеләп булмый. (Халыкның шигъри күңеле тирәнлекләрен эхолотлар белән үлчәмиләр ләбаса.) Әмма сиксән алтынчы елны күздән кичергән хөрмәтлебез Мансур Вәлиев, басылып чыккан китапларга таянып, аждаһа елына «шигъри бушлык» тамгасы сугарга җөрьәт итте. Озын-озак бәхәскә кереп тормыйм. Әлеге мәкаләнең шау-шуы инде шактый булды. Андагы күп фикерләр белән өлешчә килешергә дә мөмкин. Азау ярган тәнкыйтьчегә шуны гына искәреп үтәсе килә: шигърият рухы исән чакта (!) «шигъри бушлык» була алмый.

*Яхшы атка камчы кирәк түгел,*
*Ул болай да чаба егылганчы.*

*Тик тормышта, начар аттан бигрәк,*
*Яхшы атка төшә күбрәк камчы.*

Тормышның ачы хакыйкатен үзенчә образлы телдә әйтеп биргән Ф. Яруллинның әлеге юллары шигъриятне гәүдәләндерүче күпне күргән канатлы тулпар язмышына да туры киләдер. Вакыт арбасының күчәр башы, әйе, һәрдаим шигърияткә тиеп үтә. Басудагы борчак ул — җиткән кыз кебек — һәр үткән бер өзеп ала дыр... Әлеге мәкальне ишеткән чакта да мин шигърият хакында уйлап куям. Һәр усаллык башы шул Таздан, дигәндәй, ярый әле гаепләргә шигърият бар. Гомумәдәби хуҗалыктагы һәртөрле торгынлыкка, әйтерсең, беренче чиратта канатлы атыбыз гаепле. Шигъриятнең «верховный» булуын, әлбәттә, инкарь итә алмыйбыз. Әмма тормыш пәйгамбәрләр телендә сөйләшүче шагыйрьләр билгеләгән юлдан гына бармый. Күңел төзек булса, эш төзек булыр. Ә җитмеш төрле чиргә дучар ителгән җәмгыятьтә күңелебез җимешләре тулаем сәламәт була аламы соң?! Үз заманыбыз балалары без. Җәмгыятьтә хөкем сөргән идеологиягә сизгеррәк булучан шигъриятне һәртөрле гайре табигый күренешләр чагыштырмача алданрак җәрәхәтли. Шагыйрьләр яза торган кәгазьгә чорның сырхауларын билгеләүче лакмус асылда күбрәк сеңдерелгән. Шуны тирәнтен аңласак иде. Соңгы еллар көндәлек матбугат, дөресен генә әйткәндә, шигъриятне почмакка бастырып алды. Академик журналыбызда дәвам иткән бәхәс тә сабан туендагы капчык сугышын хәтерләтте. Келәмнәрне, әйе, җилгәрдек. Әмма җыелган тузанын башыбыз өстендә кактык. Чукраклар театры уйнап алдык. Шушы уңайдан Әгъләметдин атлы авылдашым хәтергә килде. Зират чишмәсе юлында очрашкан чакта шундый сөйләшү булып ала иде.

— Әссәламегаләйкем, Әгъләметдин абзый!

— Ие шул, ат эчерергә төшүем...

— Исәнме, дим, Әгъләметдин абзый!

— Ие, ул да ияргән шул,— дип «җавап» кайтара картлач, аты артыннан теркелдәүче кәҗә тәкәсенә ишарәләп.

— Сәлам генә биргән идем, Әгъләметдин абзый...

— Ие шул, анысы да бер чиләкләп су эчә...

Бәхәс узып китте. Әдәбиятыбыз мәсьәләләре турында зыялыларча сөйләшә алмавыбызны бөтен халык алдында тагын раслап күрсәттек. Шул булды эш. Инде ничәнче тапкыр. Иң аянычы шул: икенчел сәбәпләр тирәсендә күбрәк әйләнеп йөрдек. Хәтта өченчел сәбәпләр тирәли... Шулай бергә әүмәкләшеп тарткалашкан арада төп хакыйкать кулыбыздан шуып чыкты. Кайберәүләр шигъриятнең бүгенге торышын консилиум объекты дәрәҗәсенә күтәрделәр. (Чынлыкта «ясин укырлык» андый хәвеф сизелми.) Әмма беренчел сәбәпләр, әйткәнемчә, барыбер читтәрәк калды. Озаккарак сузылган сүз көрәштерү, Р. Харисның бер поэмасындагыча, зәһәрләнеп ат кыйнауны хәтерләтте. Авызлык кидерелгән теге ябык елларда, кысан аранга кертелеп, шигърият болай да җитәрлек кыйналды. Инде хәзер бер-беребезгә таяк белән сабак бирүдән арынып вакыт җитте. Риялы шатлануны күңелләрдән сөрик. Бәхәсләрдә катнашучы «шигърият оппонентлары»нда оппозиция чалымнарын тоемларга язмасын. Шигърияткә мәхәббәте булмаса, тәнкыйть яши алмаячак. Шагыйрьләрнең бүгенге эшчәнлеге җәмәгатьчелекне канәгатьләндерми икән, әйдәгез, моны уртак гаебебез итеп танырга өйрәник. Әсәрне тәнкыйть итү җиңел, аңлап бәя бирү авыррак. Скептиклар да кирәктер. Әмма андый тәнкыйтьчеләр әдәбиятны җанландырыр дәрәҗәдә акыллы булсыннар иде.

Ә шигъриятнең абруе какшауда, минемчә, ике җитди сәбәп бар. Беренчесе һәркемгә мәгълүмдер. Кояш йөзендә таплар сизелеп арта икән, алар җирдәге гайре табигый хәлләрдән килә. Иҗатта да шулайрак. Совет культурасының упкын авызына якынлашуы әдәбиятка күләгә төшермичә кала алмады. Бездә ничә дистә еллар мәдәният түгел, кеше иҗатын кыскан идеология хөкем сөрде! Һәрбер заманның да үз идеологы булды. Заманасына карап дуңгызны җизни диючеләр «ләббәйкәче куштаннар әдәбияты»н барлыкка китерделәр. Ай симерсә, йолдызлар арык. Халык сынамышы дөреска чыкты. Күпләребезнең күңел түренә цензор кереп утырды. Кайбер каләм ияләре, дөрес, эзоп теленә күчте. Әмма киная белән ерак китеп булмый. Тукай турылыгы кирәк. Язучылар берлеге эзоплардан гына торса, ничек күңелсез булыр иде әдәбият... Иөрәк кушуы буенча язуны «өстән кушу» басып китте. Соцреализм методы көчләп тагылды. Гыйбрәтле бер парчадагыча:

...Бервакыт бер кәтип язу яза, артыннан аны бер кеше карап, моталәга кылып (укып — З. М.) тора. Бу язучыга уңайсыз булды да: «Әгәр артымда бу ахмак, минем язганымны карап, моталәга кылып тормаса, күңелемдә булган нәрсәне язар идем»,— дип язды.

Тимер кыршау белән әйләндереп алынган «казарма социализмы» сәясәте гасырлар буена халык канына сеңгән шигъриятне куып чыгарды. Шигърият яшәештән читләште. Крестьяннар культурасы тантана иткәндә халык, ичмасам, лирикага тартылган. Туктаусыз моңланган. Хезмәте шигъриятле булган. Һәрбер кешенең күңелендә изге

хәзинә яткан. Күзләрен иман нуры балкыткан. Халкыбыз менә нинди югалтуы кичерде! Телебезнең сакчысы булудан тайчанган аналар хәтта бишек җырларын онытa башлады лар. Халыкның милли үзаңы тирән йокыга талды. Милли нигилизм чәчәк атты. Зыялылык куркыныч дәрәҗәдә саекты. Күңелләрнең төбе күренә башлады. Узган ел һәрбер өченче япон, статистика раслаганча, сыңар гына китап та укымаган. Японнар булып японнар! Ә безнең «укымышлылык»ны ачыклаучылар бармы соң?! Президентлыктан төшкән Рейган һәрбер чыгышы өчен илле меңләп доллар ала, ә безнең «нәни гигант» Әгъләмовка нибары унсигез сум акча түлиләр. Сүзнең кадере бетте. Дан милеген нигездә саклап килүче шигърият үзе түгел, ә аңа булган мөнәсәбәт хәвефләнер дәрәҗәдә үзгәрешкә юлыкты. Шундый җәһиллек җәмгыятендә яшибез. Экономик, политик һәм әхлакый яктан кризис кичерүче сырхау җәмгыятьтә бәрәкәтле оазис булып яши алган шигърияткә рәхмәт әйтәсе урында... Без нишлибез соң? Шигъриятне яшәеш жирлегеннән аерып, ялгышкан стрелочник сыйфатында, гаепләнүче урындыгына утыртырга маташабыз. Үзен генә аерып. Әдәбиятның башка жанрында эшләүчеләр, әйтерсең, әр-яңа ренессанс ясап яталар. Шигъриятнең абруе төшүдә аерым шәхесләрне гаеплибез. Көндәлек матбугатта булган кайнар бәхәсләрне хәтерлисезме? Бу уңайдан чыккан мәкаләләрнең шактые шәхси мөнәсәбәтләрне ачыклауга корылган иде. «Үзең ахмак» дип тә әйтешү булды. Рәхәтләнеп эч бушатыштык. Үзара шелтә сүзе байтак җыелган икән. (Хөрриятка рәхмәт төшкере! Суслов идеологиясе хакимлек иткәндә болай бәргәләшә алмый идек.) Мең тармаклы мәдәният хуҗалыгының экологик зәгыйфьләнү сәбәпләре исә... Алары хакында азрак сөйләштек. Күбебез тамыр төбенә төшеп тормады. Сәбәпләр катламы тиешенчә ачылмады. Хакыйкатьне күбрәк өстән эзләдек. бәхәс үзеген ялгышрак билгеләдек. Без шигъриятнең җәмәгатьчелектәге дәрәҗәсенә суккан беренчел сәбәпне, кабатлап әйтәм, «нык үскән социализм»ның «какшамас» нигезеннән эзләргә тиеш идек.

Тагын бер сәбәп... Инде анысы, минемчә, «кадрлар»га бәйле.

«Безнең белән ул-бу була калса...» Яңа буын шагыйрьләр турындагы мәкаләсендә мәрхүм С. Хәким шулай язган иде. Безнең белән ул-бу була калса... Шактый шомлы сүзләр. Шигърияттә көчләр кимиячәген, әйтерсең, аксакал алдан сиземләгән. Сәргаскәр сыман борчылган. Шигъриятнең бу елларда сыната башлавы иҗат көчләренең азаюыннан да килмиме? Төпкә җигелеп тартучы шагыйрьләрне барлап карыйк. Әүвәл югалтулардан башлыйсым килә. Соңгы дистә елда гына күпме каләмдәшебез, шигърият сафларын сирәгәйтеп, берәм-берәм арабыздан мәңгегә китеп барды: С. Сөләйманова, Ш. Маннур, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Дәүли... Күпме сугышчылар китте. Үлем белән күзгә-күз очрашкан буын вәкилләре белән бергә, безгә үтә кирәкле «олы җанлылык» та саега төште. Тукай чире белән киткән З. Насыйбуллин буынында да бөтенләй котелмәстән гүр иясе булганнар инде шактый. Аларын санап тормыйм. Авыр туфраклары җиңел булсын. Кайтара алмаслык югалтулар. Соңгы вакытта буыннар чылбыры, күрәсез, хәвефле тестә өзелгәләп алды.

Шигърият әле бүтәнчәрәк югалтулар да кичерде. Байтак кына шагыйрьләрнең башка жанрда җигелеп эшләүләре шигърият көчләрен киметүгә китергән сәбәпләрнең берсе түгелме? Ничә еллар шигырьгә тугрылыклы булган Х. Камал хәзер бөтенләе белән диярлек роман язуга күчте. Шигърият белән гомерлеккә ярәшкән И. Юзеев үзенең көчен соңгы вакытта драматургиягә күбрәк сарыф итә шикелле. Яшьрәк буын вәкиле Р. Мингалим дә шундыйрак юлдан китте бугай. Югыйсә үзе — кабатланмый торган шагыйрь, намусны җаннан өстен санаучы шәхес. Иҗат биографиясен шагыйрь буларак башлаган Ф. Яруллин да үзенең көчен төрле жанрларга бүлгәләргә мәҗбүр. Кызыклы прозаик буларак та танылган Ә. Баянов, шөкер, шигърият өлкәсендә дә нәтиҗәле эшләргә омтыла. Әдәбиятка саф шигъри вәгъдә белән килеп кергән Г. Рәхимнең юбилей китабын проза әсәрләреннән чыгарырга җыенуы да уйландыра. Төп иҗат көчен башка жанрларга биреп, беренче хатынын оныта алмагандай, шигърияткә күңелләре нечкәргәндә кайткалап йөрүчеләр күпме!.. «Кичер мине, шигъриятле дөнья, вакытында булалмады китеп...» Үзенең хәлен М. Галиев шулай аңлата. Шигърияткә Р. Вәлиев та сирәгрәк кайткалый? һәм Р. Низамиев та... Андыйларга өметләнә аламы нәүмиз шигърият алиһәсе? Әйбәт кенә башлаган Хәйдәр дә шигырь белән арасын өзде. Тугрылыкта шик уятмаган Н. Измайлова да чит бакчаның җимешен татып караштыргалый. Алла биргән талантларын, Э. Мостафиндай, тулысынча ачмаучылар күпме?! Өлкән әдипләрдән С. Баттал, Ә. Исхак, З. Нури каләмнәренең аңлаешлы сәбәпләр аркасында талчыгуы да иҗатыбызга чираттагы торгынлык мөһерен суккан соңгы дистә елга туры килә. Алтмышынчы елларда әдәбиятка яңарыш алып килгән атаклы буын да инде акрынлап таудан төшү халәтенә күчеп бара шикелле. Элекке дәрман сүрелә төште. Ат аягына тай басар, дисәң, артта андый яшьләр юк. Ә бит аларны иҗат мәйданына хөррият дулкыны алып чыккан иде. Хрущев исеменә бәйле хөррият. Үзләреннән соңрак килгән буыннарга караганда, «алтмышынчылар» ирекне күбрәк

татып калдылар. Аларга шигырьдә Туфаннарның үчен кайтарырга мөмкинлек бирелде. Каләмнәре реверанс ясаудан яки эзопча язудан башламады. Монысы бик мөһим. Тәҗрибәләре һәрьяклап җитәрлек. Үзләре ир уртасы! Хөррият фатихасы белән килгән әлеге көчле буыннан, димәк, бүгенге яңарыш заманында күбрәкне көтәргә тулысынча хаклыбыз. Аларның башка әдәбиятлардагы кордашлары, киресенчә, шагыйрьлек гайрәтләрен арттыра баралар. Безнең рухи атасыз калган шигърияттә исә арьергардка күчкән каләм ияләре шактый. Алда аларның кайберләре аталып кителгән иде. Әйдәп баручы шагыйрьләрдән саналган Р. Харисның югары партия эшлеклесе булып китүе дә көчләрен соңгы вакытта сизелерлек югалткан шигърияткә күпмедер зыян китерми калмас. Бөтен гамәлебез нигезен билгеләүче мәдәниятнең аяныч хәлдә калуы һаман дәвам иткән чакта, әлбәттә, кеше рухы белгеченең җитәкчелек эшенә алынуы татар халкы өчен отыш кына булыр. Иншалла.

Менә шундый хәлләр. Шигъриятнең халык канәгатьсезлегенә юлыгуы, күргәнегезчә, кадрлар мәсьәләсенә дә бәйләнгән. Шагыйрьләрнең башка жанрларга күчеп эшләве, дөрес, гомум әдәбиятка файда гына китерәдер. Баетасы хәзинәбез уртак. Нинди әсәр язарга кирәклеген дә һәрбер иҗатчы үзе белә. Күрсәтмә бирү файдасыз. Табигый сайланышка тыкшынырга ярамый. Әмма... Башка жанрларга тартылган шагыйрьләрдән әдәбият күпмедер отса да, кадрлар алмашынуын ешрак кичерүче шигърият барыбер югалта.

Тагын бер мәсьәләгә кагылып үтик әле. Көтеп алынган XX съездан соң шигърият халык игътибарын кыска вакыт эчендә үзенә җәлеп итте, ә күңел дәрьясы боҗларын ерып җибәргән үзгәртеп кору исә шагыйрьләргә андый ук йогынты ясый алмады. Нилектән? Эйфориядә яшибезме? Әлеге сораулар күбебезне борчый. Бу җитди мәсьәлә дә кадрларга бәйле бугай. Илленче елларның икенче яртысында көчләребез тупланышын күзаллап карагыз. Сугыштан исән кайтып, мәйдан тоткан фронтовиклар, сөрген сиратын кичкәннәр, моңарчы тыелган иҗатлары халыкка кайтарылган шәхесләр, яуда һәлак булганнарның «урыннары»н алган яшьләр... Исемнәрен санап тормыйм. Шигъриятнең күтәрелеп китүе тәгаен шуннан киләдер. Хәзер исә... Хөрлек капусы ачылып китү вакыты, үзегез күреп торасыз, көчләр кимегән мәлгә туры килде. Шактый озак дәвам иткән торгынлык үзенең кешелексез калыбында өр-яңа буыннар тәрбияләп калырга өлгерде. Иманны имгәтте. Хәтта кайбер классикларның кыйбласына кабәхәт төзәтмәсен кертүгә иреште. Безнең бөтен фаҗигабыз тамырлары шуннан киләдер.

XX гасырдагы сигезенче дистәнең соңгы елына, ягъни 1989 елга, менә шундый халәттә аяк атлаган идек. Шигъриятнең хәлен инде күзаллыйсыз. Җәмгыятьне демократияләштерү буенча, үзебезнең күзлектән караганда, канәгатьләнерлек уңышларга ирешелде. Узган ел дәвамында милли нигилистлар катлауландырган «Г. Исхакый проблемасы»да уңай хәл ителде. Милли үзаңны үстерү юлында ни дәрәҗәдә алга бара алуыбызны шушындый мисал үзе генә дә ачык күрсәтә булса кирәк. Елан елы шундый иде. Кояш аеруча актив булды. Кискен бәхәс үзәгенә алынган шигърият әдәбиятыбыз тарихына нинди елъязма өстәде? Мондый сорауга скептиклар, илкүләм хәлне күзаллап, шулайрак җавап бирәләр: вакыйга булырдай әсәрләр күренмәде... Үзгәртеп кору чорына караган әдәбиятны, янәсе, тоткынлыктан чыккан әсәрләр генә баетты. Бездә булдымы шундый әсәрләр? Прозабызда күренгәләде. Шигърияттә исә юк дәрәҗәсендә. Бу уңайдан беренче булып, әлбәттә, «Идегәй» дастаны хәтергә килә. Узган елда ул яңадан туды. Әмма күңелдә шундый рәнҗү тойгысы утырып калды: тоткын дастанны аклау турында рәсми карар чыкмады. Ичмасам үзебезнең республика хөкүмәте күләмендә генә дә кабул итәргә мөмкин булгандыр андый карарны. Мондый очракта Балтик буе халыклары, төбенә тоз коеп, архимөһим эшне ахырына җиткерерләр иде. Нахак тагылган кара сакалны без өзеп ыргыта алмадык шул. Монголлар Сталин сыныннан бушап калган мәрмәр нигезгә, әнә, «Яшерен хикәят» исемле дастаннарына һәйкәл куярга җыеналар...

*Юк, сөйләтмә, мине җәлләсәң,*
*Җәлладларның ниләр кылганын:*
*Мин җавапның әйталам бары*
*Трибуналга илтә торганын!..*

Палач балтасы астыннан исән кайткан шагыйребез Х. Туфанның тыелган шигырьләрен яңача фикерләү чорының дүртенче елында дөньяга чыгара алдык. Кояш чыраен күрмәгән әлеге әсәрләр озак ачылмаган күңелләр читлегендә ятты. «Казан утлары», «Идел» журналларының төрле саннарында шулай ук Ф. Кәримнең төрмәдә язылган аерым шигырьләре басылып чыкты. Торгынлык тоткыны булган әсәрләргә килгәндә, Ә. Давыдов архивына яктылык иңдерүгә ирештек. Партиядән чыгарылу дәрәҗәсенә җиткерелгән С. Батталның «тозланган» шигырьләре укучылар хөкеменә тапшырылды. Русча иҗат итүче шагыйребез Р. Кутуйның моңарчы тыелып килгән әсәре — үтә милли җирлекле «Казан ятиме турында баллада»сы ирек алды. Дөньяга чыктымы тагын «иске яңа» әсәрләр? Башка күренми кебек. Азмы болар, әллә күпме? Мондый очракта, гадәтенчә, акланырга яратабыз. (Мактануга охшатыбрак.) Әллә

нинди кара елларда да, янәсе, без һөҗүмчән әсәрләр бастыра алдык. Инкарь итмим: фидаи әдипләр булды. Әмма алар азрак иде. «Трибуналга илтә торган» әсәрләргә бөтенләй дөнья чырае күрсәтелмәде. Без торгынлык шаһитләре бит. Совет цензурасының патшаныкыннан да мәрхәмәтсезрәк булганлыгын беләбез. (Колымадан кире әйләнеп кайта алган соңгы могиканнарыбызның берсе И. Салахов гаепләү карары булган әсәрен кызык өчен генә җиргә күммәгәндер.) Әле арабызда әсәрләрнең ялгышын эзләп кенә укучы каләмдәшләр никадәр иде. Үзегез беләсез: безнең халык мондый эшкә аеруча хирыс. Бөек рус теленнән «сәяси сыену» алуга ирешеп, беренче тапкыр читтә басылган поэмалар да булды. (Әлеге дә баягы «аппаратның сөйкемсез сөяге» булган С. Батталның ерактагы «Байкал» журналында чыккан мәгълүм әсәрен күздә тотам.) Кыскасы... Җәмгыять белән чын алышка чыккан әсәрләр, әлбәттә, каләм зынҗырлы чакта да байтак басылды. Себер китәрлек шигырьләргә килсәк... Бездә андыйлары чамалырак булды. Бу җәһәттән киләчәктә, әйдәгез, артыгын шапырынмыйк әле. Ирләрчә танып, чама белик.

Узган елгы шигъри әсәрләр ташкынында шушындый үзәнчәлек күзгә бәрелеп тора: сәясәтләшү... Заманга хас күренеш. Демократиянең бер сыйфатламасы. Моңарчы йокымсыраган аңыбыз күзәнәкләренә сәясәт ташкыны бәреп керде. Күбебез «политик»ка әйләнде. Илнең авызын тыгарга илле ыштаным юк, дип, нәкъ менә шушы очракта әйтә торганнардыр. Милли үзаңны уятуга юнәлдерелгән шигырьләрдә сәясәтләшү кыры аеруча көчле сизелә. Халыкның хәләль хакын даулау байтак әсәрләрдә үзәккә алына. Гасырлар буе халыклар төрмәсендә интеккән милләтнең, озак утырган тоткын кебек, руханә хөрлеккә атлыгып тормавы да искәртелә. Өлкән шагыйребез Г. Афзал язганча: «Кәгазьдә бар, гамәлдә юк хаклык Күз өстендә торган көектер. Шул вәхшәткә түзеп торган халык Түземлеге белән бөектер...» Аксакал, әйе, хаклыдыр. Инде дөнья безгә дә алдын күрсәтергә тиеш.

*Сары яфракларга ияреп оча*
*Ак кәгазьләр — кеше сурәтләре.*
*Адәмнәрнең калган үрнәкләре,*
*Гайбәтләре оча, өрәкләре.*

*Кайчан гына, бизәп диварларны,*
*Торган иде алар — мәгърур рәтләр.*

*Кылгандырбыз без, аларга багып,*
*Гыйбадәтләр бәлки, гыйбадәтләр.*

*Канобызга сеңгән ул гадәтләр —*
*Олыладык: «Яшә, яшә!» — дидек.*
*Хәзер энә таптап узды иптәш.*
*Беркем гаеп итмәс — килде хөрлек...*

Халык хак әйтә: туры сүзне баладан ишет. Әмма безнең җәмгыятьтә күпләр, үскән саен, ләббәйкәлек чиренә бирелә барды. Үзенең турылыгын балачактан бирле саклый алган шагыйрь Ә. Баяновның кызганыч язмышлы югарыгы түрәләрне элеп алуы гаҗәп түгелдер. Каләмгә ирек килгәнче дә әдибебез шундый булды. Теге елларда милли үзаңга кагылышлы темаларга гына түгел, кеше рухы мәсьәләләренең дә байтагына тыю салынган иде. Тыелганы — тыелган. Рөхсәт ителгәне... мәҗбүри куелды. Безнең арада шушы мәҗбүрине арттырып үтәүчеләр булмады дисезме? Бүрекләрен мәркәздәге мәрмәр мөнбәрдә торган көнлекчеләргә карап киючеләрнең бүгенге көндә нинди кызганыч хәлдә калуын үзегез аңлыйсыздыр. Художник буларак киләчәккә карап иҗат итүче Ә. Баянов, кайберәүләр шикелле, бәһасен югалткан акчадай искергән әсәрләрен кочаклап калмады. Үзләренең кайсыдыр чорга караган иҗатын, белгәнебезчә, күңеленнән сызып ташлаган әдипләр байтак. Андый шагыйрьләр рәтенә Ә. Баяновны кертеп булмый. Һәрнәрсәгә хакыйкый бәясен бирер заманга ул йөзен кызартмаслык китаплары белән якынлашты.

*Әллә кул чабасы, әллә тагын*
*Ярты гасыр көтеп торасы?*
*Әллә чаң сугасы:*
*— Булачакмы берчак*
*Вөҗдан, намус диктатурасы?!*

Шагыйрь көтеп яшәмәде, һәрчак чаң сукты. Шигъриятнең хакыйкате белән бүгенге заманны якынайтышты. Футлярда яшәтергә тырышучы җәмгыять белән рухи алыш хәлендә яшәүдән читләшмәде. Каләме һәрдаим эзләнде. Шушы сыйфатлары өчен ул күпме кыен ашады. Әдипнең эзләнү омтылышын аерата күрә алмадык. Безнең халык шундый инде: «Һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер». Без бертөрлелекне яратабыз шул. Кешене башкалардан аерып торучы үзенчәлекләрне бәяләү культурасы Рәсәй җирендә яшәүче халыкларга бөтенләй диярлек бирелмәгән... Исеме тирәсендә шау-шу байтак булды, эзләнү асылын ачарга омтылучылар исә... Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллинга рәхмәт: шагыйрьнең проза өлкәсендәге эшчәнлеген үзәккә алып, повесть кебек укылырдай иҗат портреты эшләде. Әдип шигърияте тирәнлеген кайсы тәнкыйтьче ачар? Исемләп әйтергә икеләнәм... Кыскасы,

моңарчы үгисетеп киленгән «җайсыз» шагыйрь Ә. Баяновны үзенә күрә «реабилитацияләү» вакыты килеп җитте. Әдипнең иҗат бакчасына атылган һәртөрле ташларны, бергә җыйнап, аның Парнасы итәгенә җылы сүзләр язу дәвере җитте. Шагыйрь гадел бәясен инде алырга тиеш.

Үзенең озын гомерендә әллә ничә «патша» күргән аксакалыбыз Н. Арслановка, әнә, яңарыш заманы ниндидер сөенеч катыш офтану хисе алып килгән: «Былбыл идем, гомер үтте инде «Ирек» дигән алтын читлектә...» Иҗат юлында гаять мөһим «үзгәртеп кору»лар ясый алган шагыйрь бихисап мөмкинлекләрне кулдан ычкындырырга мәҗбүр иткән диктатлык җәмгыятен каһәрли. Ә мөмкинлекләрне кулдан ычкындыру — гафу ителмәслек гөнаһ. Хәйям яшенә якынлашучы әдипне бүген менә нәрсә борчый һәм ул шушы үкенүе белән яшьләргә сабак та бирә төсле. Югыйсә әле безнең арада каләм иреге кадерен белеп җиткермәгән, әлегәчә йокыдан айный алмаган, яисә бүген кирәкле сүзне әйтергә ашыкмаган яшьләр дә җитәрлек. Шушы яктан өлкән шагыйрь аларга үрнәк булып тора. Атаклы «Атлантида» кебек әсәрләре белән халык улы булуын раслаган шагыйрь Н. Арсланов телләребез чишелгән заманда шагыйранә хакыйкатендәге милләтпәрварлык төшенчәсенә тирәнрәк мәгънә өстәргә омтыла. «Олы шагыйрь иләс-миләс була, Әйткән сүзе аңлашылмый кала...» — дип икърар итә икенче бер аксакалыбыз Г. Афзал. Өлкәнәю белән бергә килә торган мондый халәт, әлбәттә, Н. Арсланов кебек алып шагыйрьне дә читләтеп үтмидер. Әмма чичәннәр картаюны белми. Халык уллары, югары түрәләр төсле, отставкага чыкмый.

*«Халкын сөеп зар иде,*
*Киң дөньялар тар иде...*
*Яныл көлләргә әйләнгән*
*Нури бабай бар иде».—*
*Диярләр, диме калмаслар.*
*Үз булгач, оныта алмаслар!*

Узган елгы шигъриятгә, әйе, сәясәтләшү көчәеп китте. Шигырьне сәясәттән аерман шагыйрьләр иҗатында әлеге сыйфатның бермә-бер көчәеп китүе сизелә. «Чәчәк, күбәләкләр турында дөресен җырлау гына — батырлык түгел»,— дип, Р. Харис укучысы алдында үзенең иҗат кагъбәсен тагын бер мәртәбә ачыклап куя. Егерме биш еллык иҗатын йомгаклап куючы «Хәбәр» исемле китабында шагыйрьнең әлеге инануы, әчке кайтавазыдай, үтәли яңгырап тора төсле. Яшәешкә сәясәттән аерылгысыз лирика аша карау, әйтик, Р. Фәйзуллинга да моңарчы чит-ят күренеш булмады. Бу урында сәясәтләшү дию гадиләштерү булыр күк. Кырыс дөреслекне күзгә төртеп әйтү, газиз милләтнең чире белән авыру, язганың белән халык хакын даулау... Шагыйрь сәясәте шуннан гыйбарәт. Хөр фикер тантана иткән чакта, билгеле инде, теге вакытта тыелганнары күбрәк чыга. Менә шагыйрьнең «Шайтан каласы»ннан КамАЗларга карап» исемле шигыре:

*Чал Чулманның яшел ярына*
*җәелеп ятты зур Кара Сыер.*
*Корчаңгылы килмешәк Сыер!..*
*Тояклары тимер — җирне изә,*
*мөгезләре күккә terәлгән!*

*Тургайлар куркынып сибелде*
*Агыйдел, Нократ ягына...*

*...Өстәвенә, Хайван бикәч икән!*
*Җыелды янына исле Үгезләр...*

*Болганды дөнья. Җыелды халык.*
*Артты зиналык. Басты төтен...*
*Чишмәләрнең якты күзенә*
*сиде Вәхшәт.*
*чапырдатып...*

Шигырьне күңел чәчәге итеп күрүчеләр өчен, әлбәттә, мондый әсәрләр артык «эшлекле» булып тоеладыр. Нишләмәк кирәк — чоры шундый. Яшәешнең тымызыклыгы бозылды. Тын шигърият арткарак күчте. (Вакытлыча дип уйлыйк.) Кулдан каләмне сугып төшерүләр акрынлап кына үтеп бара. Эчтә җыелып килгәнне әйтеп калырга кирәк. Гасырлар буена хәләль өлешеннән мәхрүм калып килгән халык гакылын җыйсын өчен ачы хакыйкать җимеше күбрәк сораладыр. Бу җәһәттән егерме еллап элек «Космополит түгел» кебек һөҗүмчән монологлар бастыра алган Р. Фәйзуллиннан, милләтебез ышанычлысы буларак илкүләм танылган шагыйрьдән, киләчәктә халык рухы офыкларын киңәйтергә ярдәм итәрдәй әсәрләрне күбрәк көтәргә тулы хакыбыз бар.

Безнең тәнкыйтьтә Зөлфәт белән М. Әгъләмов турында, гадәттә, исемнәрен янәшә куеп фикер алышырга яраталар. Мондый «игезәклек»кә аларның әдәбиятка бергә килүләре һәм икесенең дә көчле шагыйрь булуы сәбәптер. Югыйсә бит әлеге каләм ияләрен аерып торучы сыйфатлар да байтак. Халкыбыз хәлиткеч сынау кичергән чакта кемнең нинди булуы ачыграк сизелә. Күркәм мәгънәдәге фетнәлек Мөдәррискә күбрәк бугай. Җәрәхәтле бәгыре үзгәрешләргә сизгеррәк. Нерв җепселләре ачык.

Кыл-җеп өстеннән атларга ярата. Чәчрәп чыгу да ят түгел үзенә. Тукайча турылыгы белән дә ул кордашыннан аерылып торадыр. Мөнбәрләргә ешрак күтәрелә. Язган бер шигырен «сулап» кына ятмый, халкыбыз мәнфәгатьләрен кайгыртып, матбугатта һәртөрле мәкаләләр белән дә чыга. Зөлфәт исә соңгы вакытта, иҗтимагый темперамент җәһәтеннән, күпмедер дәрәҗәдә сүрелә төште. Балладалары, дөрес, Зөлфәтчә! Әмма барыбер ул тынычрак яши. Элекке гыйсьянчылыгы сизелми. Халыкны «гәҗит кыштырдавы» белән уятыр заманда үзенең саллы сүзен әйтергә ашкынып тормый. Сынау вакытында, авызына су капкандай, либераллык күрсәтә. Әдәби хуҗалыкның кайбер мәсьәләләре уңаеннан да принципсызлыкка тартым чыгышлар ясаштырып куя. Фикерләрем катгыйрак әйтелгән булса, шагыйрь дустым миңа үпкәләмәс. Ике шәхесне үлчәүгә салып чагыштырырга омтылуым да табигать кануннарына туры килеп бетми кук. (Гомумән, әдипләрнең популярлык индексын ачыклауны максат итеп куймадым.) Һәркемнең шагыйрьлеге үзенчә. Әмма трибун кыяфәтле Зөлфәтне мин көрәшнең үзәгендә күрергә телим. Шагыйрьнең иҗат мөмкинлекләре зур, димәк, аннан күбрәкне көтәргә хаклыбыз. Һәм тәнкыйть сүзеннән өстен булмасын ул. Югыйсә, көне-төне әдәбият белән яшәүче сәях дустына караганда, яшьли сөекле булып танылган Зөлфәт ничектер почеттарак йөри. Монысы, әлбәттә, сәеррәк. Әйдәүче шагыйрьләребезнең берсе булган М. Әгъләмовны да милләтебез каһарманы итеп танырга өндәмим. Аны әле торгынлык тоткыны исемлегенә кертеп калдырырга теләүчеләр дә бар. «Хак-нахак» дип исемләнгән мәкаләсендә тәнкыйтьче Ф. Зөлкарнәев, әйтик, шагыйрьгә карата «реабилитация» сүзен дә куллана. Арттырмыйк әле, егетләр! Аннан Б. Пастернак ясамыйк. Ничек кенә туры сүзле егет булмасын, М. Әгъләмов һәрчак табигать иркәсе өммәтендә калды. Һәм тормышта әллә нинди гамәлләр кылып ташласа да... Тукайча әйткәндә: «Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул — табигать иркәсе!..» Язганнары ташка басылды. Һәртөрле җыелышларда сүзне бугазлап алды, теләгәнен батырып әйтергә мөмкинлек бирелде. «Акылыбызга китерүче Черек күл»гә дә Батулладан күбрәк йөрмәгәндер... Ясарсың Мөдәрристән торгынлык тоткыны! Үз дәүләте белән яши бирә ул! Аны, мөгаен, утыз җидедә дә алып китмәгән булырлар иде. Чөнки... паспорты юктыр. (Монысы, әлбәттә, шаяру.) «Даһига да парадокслар ят түгел...» Пушкин шулай әйтеп калдырган. Минем өчен М. Әгъләмов та аңлашылып бетмәгән шәхес. Каршылыклы зур шагыйрь. Шундый ук сыйфатларның кайберләре Роберт Әхмәтҗановта да бардыр. Һәрхәлдә, аларны чын шагыйрьлек берләштерә. Коньюнктура җименә капмыйлар. Сәясилекне йөрәкләре аша үткәрергә омтылалар. Шул ук вакытта «табигать иркәсе» булу әлеге каләм ияләренең соңгысына да хас. Мондый шигъри юлларда бу аеруча ачык чагыла:

*Патша да һәм*
*президент та була алмыйм,*
*хәер, булалсам да*
*булмас идем —*
*иркем бетә,*
*мин — табигать улы,*
*аерылмыйм табигатем карыныннан!..*

Хәрбиләр телендә мондый тәгъбир барлыгын беләсездер: сугышып разведка ясау... Шундый ук көрәш алымы шигъри сүздә дә күзәтелә. Шигъриятнең сугышчанлыгы артканда, сәясәтләшү башлангычы көчәйгәндә... Хәзерге инкыйлаб заманында шигърият, әйе, сугышчан разведкасыз яши алмый. Шундый бурычлы әсәрләрне без бәяли белергә тиешбез. Әмма бу җәһәттән дә көрсенергә генә кала. Әлеге дә баягы: әдәбияттагы табигый төрлелекне бәяләү культурабыз җитенкерәми. Көрмәкләнгән телебезне чишеп җибәргән үзгәртеп коруның беренче елында М. Шабаев тарафыннан язылган «Ачыктан-ачык» исемле поэманың язмышын хәтерләгез. Әй ябырылдылар шуңа! Югыйсә сугышчан разведка алымында иҗат ителгән әлеге әсәр, әйтик, «Йосыф кыйссасы» кебек җәүһәр булырга дәгъва кылмый иде. Мәңгелеккә төбәлгән максаттан гайре аңа фанирак бурыч йөкләтелгән. Һәм әлеге әсәр үзенең иҗтимагый бурычын үтәде дә. Русның бөек шагыйре В. Маяковский үз заманында маршлар һәм лозунглар язуны алга сөргән. Шулай кирәк булуын җаны белән тойган. Безнең исә җаһиллек көчле, өстәвенә, әле күңелебез дә таррак. Төрлелекне кабул итә алмыйбыз. Кирәкмәскә сүз көрәштерәбез. Югыйсә, беткәнме мөһимрәк мәсьәләләр?! Укучының барлы-юклы зәвыгы бозыла, шагыйрь шагыйрьгә каршы куела. Соңгысына аеруча маһирбез. Тау-кыялар турындагы шигырь уңаеннан файдасыз бәхәс кузгалуын хәтерлисездер. Мәгълүм тәнкыйтьчебез әлеге әсәрне хупламавын әйтеп, аны үзәнгә багышланган шигырьгә каршы куйды: «...Кыялар алар — үле таш, тораташ!..» Шигырьне ничек наив аңлату! Безнең фикерләү дәрәҗәсе менә шундый инде. Явыз патша татар халкын зур елгалар тирәсеннән сөргән, димәк, безгә дәрьялар турында язу да гайре табигый була?! Тау-кыя, янәсе, үле таш... Бу сүзләрне таудай горур Р. Гамзатов ишетсә, мәкалә авторының шундук җанын алыр иде. Ярый әле татар тәнкыйтьчеләренең язганнарын даими укып бармый. Инде ише-

тә калса, тауны тәкә сөзеп җимерә алмый, дияр иде кебек.

Хәрбиләр тәгъбиреннән башлаган сүземне нигә шулай озаккарак суздым? Сәбәбе моннан гыйбарәт: бүгенге шигъриятә сәясәтләшү сыйфаты сизелерлек көчәеп китте, һәм табигый ки, сугышчан разведка максаты белән язылган әсәрләр күбәйде. Мондый төр шигырьләр киләчәктә дә булыр. Аларга кашыбызны җыерып карамыйк. Яшьләргә хокуклы әдәби күренешләргә зыялыларча бәя бирергә өйрәник.

Сәясәтләшү... Лирик табигатьле шагыйрьләрнең әсәрләрен дә мин шушы күзлектән карап укыдым. Бүгенге көннең бер билгесе аларда ни дәрәҗәдә чагыла? Кешеләрнең иҗтимагый фикерләү рәвеше метаморфозалар кичергән чакта, әлбәттә, эчке монолог буларак күзалланган лирика үзгәрешсез калмастыр. Һәр әсәрнең нигезендә, хрестоматия өйрәткәнчә, ялгансыз хакыйкать ята. Ничәмә дистә еллар буена без ярымйорты хакыйкать белән яшәдек. Хәбәрдарлык шлюзлары ачылган заманда исә, ачы булса да, дөреслекнең күзенә карарга өйрәнеп барабыз. Кан-яшьле риясыз хакыйкать күзендә, әлеге дә баягы, халкыбыз язмышын күрергә омтылабыз.

*...Югыйсә гасыр ахыры,*
*Бихисап тәҗрибәсе...*
*Синең дә, халкым, рухыңның*
*Якынча тәрҗемәсен*

*Укыйлар түгелме?*
*Уйлан...*
*Ни булыр нәтиҗәсе?*
*Әй, гасыр хакыйкате!*

Лирик җанлы шагыйрь Р. Гатауллин әсәрләрендә дә иҗтимагый яңгыраш күпмедер көчәя төште. Күңелдә казынып чакмыни! Хакыйкатьне «дөресләр» вакыт якынлашты. Кайнар романтиклыгы белән аерылып торучы әлеге шагыйрьнең элеккерәк иҗатын мин ничектер борынгы Бабилның (Вавилон) асылмалы бакчаларына охшатып куйгалый идем. (Билгеле инде, фараз ярдәмендә.) Бу бакчада һәммәсе бар: агачлар чәчәк ата, оҗмах кошлары сайрый, күбәләкләр очып йөри, чишмәләр агып ята... Әмма бакча асылмалы, җирдән өстәрәк тора. Кояшка якын булу әйбәттер. Тик менә тамырга җир кирәк шул. Җирсегән тамырларны туктатып булмыйдыр. Бакча акрынлап җиргә якыная... Җырга да җир кирәк. Моны Р. Гатауллин яхшы белә. Әмма шагыйрь романтиклыгын барыбер югалтмасын иде. Аһәңнәр төрле булсын. Безнең гомум шигъриятқә дә кирәктер андый бизәк. Иҗатчыларга стереотип аша инде җитәрлек карадылар. Бу сыйфат килешә аңа. Аның шигырьләре буйлап сибелгән төрле исемнәрне дә күпчелек очракта табигый рәвештә кабул итәсең. Тик кайсы вакытта сүзләр күбәеп китә. Язу карасына су кушылган кук. Аз сүзленең гаебе аз. Моны шагыйрь онытмасын иде.

Бу уңайдан шуны да әйтеп үтәсем килә: без үзебезнең шигырьләрне дөньяга чыгарган чакта гафу ителмәслек дәрәҗәдә талымсызлык күрсәтәбез икән. Шушы хакта тирәнтен уйлап караганыгыз бармы? Югыйсә һәрбер шагыйрь үзенең уңышсызрак әсәрен шактый яхшы сиземли. Әмма чираттагы яңа китабына бөтенесен дә дыңгычлап тутыра. Күбебез шулай эшлидер. Әгәр иң-иң яхшы әсәрләрне генә туплап чыгарсак, шигъриятнең абруе да бермә-бер югарырак булыр иде. Башка милләт шагыйрьләренең дөньядан киткәчтен дә архивында калган әсәрләре чыккалап тора. (Мондый чакта уртакул әсәрнең дә бәһасе күпкә артып китә.) Безнең кырыгыбызны билгеләргә дә басылмаган шигыребез калмый. Тукаебыз «чүпләр»дән арынуны соңгы көннәренә калдырган, безләргә иртәрәк башларга кирәк мондый чистартуны.

*Лирик җырлар гына языйм, дисәм,*
*Килеп чыга тагын сәяси...*

«Мөлдерәмә күңелле» Л. Шакирҗанова шулай күрсенә. Үзенең халәтен аңлата. Бүгенге заманда шагыйрәләрдән дә шундыйрак сүзләр ишетәсең. Әлегрәк «ирләр сүзе»нә кысылмаган чагыштырмача басынкы саналучы кавемнән... Гыйффәт Туташлар кайтавазы көчәяме? Җәрәхәтле күңелләрендә калган тоткын сүзләрне алар бүгенге варисларына әйтеп яздыралармы? Төче «поэтессалык»тан ваз кичкән хатын-кыз шагыйрьләр, шигъриятне «ирләр эше» итеп санаучылар заты... Хәзерге көндә андыйлар күбәеп китте шикелле. Аларның шигъри дөньялары да һәрьяклап яңарыш кичерә. Бездә генә түгел, бөтен илдә шулай. Дәрт ирләрдә бер өлеш булса, хатыннарда җиде өлеш була. Халкыбызның әлеге катгый әйтемендә дәртнең нинди күздә тотылгандыр?! Әмма хәзер хатын-кыз иҗатчыларның шагыйрьлек дәртләре арткан вакыт. Бу уңайдан Х. Шаммасова (1875-1949) сүзләре хәтергә килә: «Ирләрнең яганнары да аяте корьән түгел, Шәпләре күп булса да, бар бит арада чаклысы...» Ышанып әйтергә мөмкин: бездә хәзер шулай әйтердәй «нәзакәтле» каләм ияләре шактый. Һәм Л. Шакирҗанова — шундыйларның берсе. Соңгы берничә елда ул күзгә күренеп үсте. Газиз халык төркемен үзенең артыннан ияртеп барырлык, кирәк чакта гаскәр туплый алырлык, милләт язмышыннан аерып булмаслык шагыйрь икәнен расләды.

Көнкүреш кысаларында гына калмаучы Б. Рәхимовада да иҗтимагый фикерләү ягыннан тирәнәю күзәтелә. Итәккә сарышучан тормыш ваклыкларыннан ул өстенрәк булып калырга тырыша. Көчле затларча фикер йөртергә омтылыш, барыннан да элек, халыкка хезмәт итү юнәлешендә бара. Әсәрләренә сәясәт аһәңен иңдерү, әлбәттә, хатын-кыз шагыйрьләргә авыррак биреләдер. Күңелдәге серләре күбрәк булганга күрәме, алар тәмам ачылып бетүне өнәмиләр. Ә шигъри памфлетлар телендә сөйләшкәндә серлелеккә хыянәт итмәү кыенрак шул. Кемнең шәрә каласы килсен. Әмма шунысы да безгә мәгълүм: халыкның үзаңын уятуга юнәлдерелгән әсәрләр ничектер хатын-кыз җылылыгына мохтаҗлык кичерәләр. Хәзер халыкны уята торган бишек җырлары күбрәк сорала. Үтемлерәкләре! Хатын-кыз затының кулына алынган каләм йөрәк җылысын кәгазьгә мулрак күчерүчән. Хәтта «Реквием»нар да башкачарак чыга. (Ахматованы күзаллап әйтүем.)

*Мескенгә кайчан көн булсын?*
*Кыюлык көтә Дөнья.*
*Бу кайнап торган тормышның*
*Мәгънәсе бары шунда.*

Коллонтай күк «кысан күлмәк»тән чәчрәп чыгарга омтылу моңарчы тынычрак булып күренгән К. Булатовада да тоемлана. Күңелләрне каплабрак торган ниндидер груһ пәрәнҗәсе йолкып алынган заманда Э. Шәрифуллина, Ф. Гыйззәтуллина, Н. Измайлова, Р. Хәлиуллина, Ф. Зыятдинова, Ш. Җиһангирова, С. Гәрәева кебек шагыйрәләрнең соңгырак әҫәрләрендә дә «торгынлыкның үчен кайтару» сизелә. Аларның язганын укыганда шундый инануга киләсең: шигърият җенесләргә бүленмидер. Санап кителгән каләмияләре иҗатында искитмәле кызык образлар очрап куя. Ерак Көнчыгышта яшәп алган чакта серле урынны күрүем хәтергә килә. Янар тау итәге. Җылылык бөркеп торган җыйнак кына шарлавык. Ниләр генә үсми шунда! Биредәге яшеллек дөньясының үзгәрәк булуы, валлаһи, миндә аңлата алмаслык тәэсирләр уятты. Әлегәчә гадәти булып тоелмаган бүгенге шартларда да шагыйрьләрдән гаять үзенчәлекле гыйбарәләр ишетеп куясың. Иске авыздан өр-яңа сүздәй... Болары инде — хөрлек хикмәте. Фикерләү хөрлеге. Шундый үзгә шартларга, минемчә, шагыйрәләр сизгеррәк сыман. Аларның бүгенге иҗатында мин шуның чагылышын күрдем. Айны итәк белән каплап булмый. Анысы хактыр. Әмма соңгы вакытта аеруча куәтләнгән шагыйрәләребез янында кайбер ир-атларның тоныкланып калуы табигый күренергә мөмкин.

Шагыйрь шәхесенең зурлык перспективасын аеруча ачык күрсәтүче поэма жанры, икеләнмичә расларга мөмкиндер, соңгы елларда иҗтимагый яңгыраш мөмкинлекләрен эзлекле рәвештә киңәйтә төште. Гомумән, сөенечле күренеш: поэма эзләнү юлыннан барып, төрле яктан яңарыш кичерә. Һәм политик идеологиягә мөнәсәбәт җәһәтеннән дә. Монда җитди сәбәпләрнең берсе шуннан гыйбарәт булса кирәк: шагыйрь эчендә утыручы «общественный деятель» соңгы унъеллыкларда күпмедер калкынып куйды. Узган хисап елында поэмалар, дөрес, чагыштырмача азрак дөнья күрде. Кинәтрәк чыккан хөррият кояшының башыбызга сугуыннан айный алмыйбызмы?! Зуррак әсәргә алынмыйча, нәрсәдер көтеп ятабызмы?! Кистереп әйтү кыенрак. Ярый инде, шөкер итик: хикмәт санда түгел. Газета һәм журналларның былтыргы саннарында исә Х. Әюповның «Авыл җаны», «Көй эзләү», Р. Бохарайның «Мәскәү мулласы», Р. Шәриповның «Йорт иясе», Рәшит Әхмәтҗановның «Карачкы» исемле поэмалары укучыларга барып иреште. Моңарчы безгә таныш булмаган поэмалар К. Сибгатуллин, Р. Юныс, Ә. Рәшитов, С. Муллагалиевнең аерым китапларында да дөнья күрде. Бу әсәрләрне берәм-берәм «сүтеп җыярга» максатым юк. Әмма кыскача гына булса да шуны әйтеп үтәргә телим: төрле каләм белән язылган әлеге поэмаларда, тарихиларын исәпкә алмаганда, рухыбызның көнүзәк мәсьәләләре уртак җептәй сузыла. Әле генә телгә алып үтелгән поэмалар арасында, минем карашымча, «Карачкы» шигъри гомумиләштерү тирәнлеге белән аерылып тора. Кешеләр күңелендәге изге хәзинәне югалтуга дучар ителү әсәрдә фаҗигале аерым язмышлар аша күрсәтеп бирелә. Җаныбыздагы иманны без Карачкыдай сөргәнбез. Тормышта азая баручы фәрештәдәй Әменнәрне катыйльлек битарафлыгы белән җәзалап үтергәнбез. Вөждан хөкеме күзалламасын сызып ташлаганбыз да, акылыбызны кыйммәтле халәттән мәхрүм иткәнбез. Буш кешеләрнең күбәюе шуннан киләдер дә. Әсәрнең иҗтимагый яңгырашы колакны ертырлык түгел. Җетерәк җепләр эчкәрәк яшерелгән. Монысы әдипнең чын халыкча фикерләү куәсенә ия булуыннан киләдер. Кыскасы, шагыйрь бүгенге яшьләргә аерата кирәкле «Иман шарты»н үзенчә, шигъри күзаллый белүче йөрәге таләп иткәнчә язуга ирешкән. Форсат чыккан чакта тагын шуны әйтеп үтәргә кирәктер: Рәшит Әхмәтҗанов соңгы вакытта поэма өлкәсендә шактый нәтиҗәле эшләп алды. Шушы жанрда язган әсәрләрен төр-

ләчә кабул итүчеләр булды. Кашларын җыеручылар да күренгәләп китте. Әлбәттә инде, үзебезнең арада. Монысы да кабатланмас шигъри дөньясы булган шагыйрьне зыялыларча танып җиткерә алмау галәмәтедер дип уйлыйм.

Милли уяц үскән заманда, табигый рәвештә, тарихка игътибар нык артты. Поэмалар да язгалыйбыз. Һәм кечкенә парчалар да. Монысы, әлбәттә, яхшы. Әмма әлеге катлаулы темага талант иялә́ренә алыну җитми. Тарихны сай сөрәбез. Болгар тәрәккыен, ялкау археолог төсле, өстенрәк эзлибез. Кайчакта башын комга тыккан тәвә кошыннан узмыйбыз. Күп кенә әсәрләребездән дилетантлык аңкып тора. Геннар авазын тыңлый алу сәләте, күрәсең, бездә әле житәрлек дәрәҗәдә түгелдер. Күпмедер тарихка кагылышлы булган шигырьләрдә Иван Грозный, Канашевич, Ильминский, Ишми Ишан кебек таушалган исемнәр «сәйярлык» итәләр. Зуррак күләмле тезмә әсәрләргә дә тарихның үзендә яшәү җитми. Шулай да омтылыш юк түгел. Бу җәһәттән соңгырак елларда дөнья күргән. «Ант суы» (Р. Харис), «Аяз көнне яшен» (Г. Рәхим), «Алтын кашбау» (Ә. Баянов), «Казан ятиме турында баллада» (Р. Кутуй), «Сөенбикә» (Ә. Рәшитов), «Ерактагы кәккүк авазы» (И. Юзеев) кебек әсәрләрдә шундый теләкне күрергә мөмкин. Канбыбыз авазын ишетергә омтылыш... «Алтын кашбау» шигъри трагедиясенең керешендә укучыларга искәртеп үтелгәнчә: «Ишетә белсәң, сөйли белә таш та. Телсез хәтер күпме чорлар узган! Тыңлап карыйк, инде аңлап карыйк, Исән калган булса җан һәм вөждан».

Сәяси мәсьәләләр моңарчы күрелмәгәнчә өскә калыккан заманда башлыча лирик жанрлардан саналучы баллада активлаша төште. Берәр хикмәте бармы? Хәер... Безнең татар шигърияте тарихында баллада традициясе электән килә. Рух чишмәләрен сафландырып торучы үзгә табигатьле кушылдык ул. Заман идеологиясе үз тамгасын, әлбәттә, аларга да сеңдерел үткән.

*Кыйбла якка авышкан ул, дибез,—*
*Кыек тора, бәлки, заманасы?*

«Сөенбикә манарасы» исемле шигырендә куелган әлеге сорауга Р. Низамиев «Миләш турында баллада»сында җавап бирәдер шикелле. «Кыек тора, бәлки, заманасы?..» Әлеге сүзләр башка балладаларның да эпиграфы булып яңгырый ала. Аерым гыйбрәтле язмышлар аша шушы сорауга җавап эзләнә. Һәрхәлдә, балладалар белән чыгыш ясаган Зөлфәт, Х. Әюпов, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов, Н. Әхмәдиевнең мин рухсызлык фаҗигасына китергән космополитик диктат хакимлеген ләгънәтләүче шигъри сүзләрен ишеттем. Баллада кебек үтемле жанр, әйтер идем, бу очракта оста файдаланылган.

...Яшьләр иҗаты турында уйланып утырганда, искәрмәстән, шундый хатирә искә төшеп куйды. Икенче класста укыган чагым. Кышкы чиллә иде бугай. Мәктәбебезнең ишек алды уртасына усак агачы кайтарып аудардылар. Ботаклары да боталмаган. Кар юрганы өстендә ята. Яңа киселгән шушы усакның борынны ярып кергән исе! Сүз белән тасвирлап бирә алмаслык үзгә ис... Күңел төбендә ул гомерлеккә калды. Шигърияттә кайбер яшьләрнең пәйда булуы да күңелдә менә шундыйрак халәт тудыра. Әмма соңгы вакытта андыйлар булмады төсле. Инде русларда үзгәртеп кору дулкыны белән мәйданга чыккан каләм ияләре бар. Бездә исә хәтергә томырылып керердәй яшьләр әлегә күренми. Милли тамырлары киселгән мәктәп фаҗигасы күңелсез нәтиҗәләрен әле озак сиздерер. Бар булган яшьләргә шөкер итәргә кала. Аларның эзләнүле иҗаты, куанып әйтәм, җанда ышаныч уята. Мәсьәләләре дөрес сайланган. Халыкларның үз яшәешләре өчен кискен көрәш барган чакта сәяси битарафлыкның җинаять булуын алар тирәнтен аңлыйлар. Бүгенге көндә кулга каләм алу, Р. Зәйдуллин искәрткәнчә, үтә вөҗданлы булуны таләп итә:

*Сиңа орыну — бөек җаваплылык!*
*Килдең безгә кара чорлардан.*
*Соңлап күрдек: син бит Усмановның*
*Күзе карасына чыланган.*

Шундый ук иҗтимагый кайнарлык Г. Моратов шигырьләрендә дә сизелә. Тирәнәя бара шагыйрь. Кайчак «китапчалык» та сизелеп киткәли. Булсын. Мондый хәлне инкарь итмик. Хәтта кайбер классикларда да сизелгәли андый чалым. Чамасын гына югалтмыйк. Эзләник. Әмма иманга һәрвакыт тугры калырга тиешбез. Әлеклелек мәсьәләсенә килгәндә... АЭСлар төзүгә каршы чыгып язылган «Атом-кирмән» исемле әсәрен укыганда, очраклы рәвештә, Г. Моратовның «Казан утлары» журналында алданрак басылып чыккан мәкаләсенә юлыктым. Анда мондый юллар бар: «Кама аръягында — КамАЗ һәм Түбән Кама нефтехимия янында — тагын бер баһадир күтәрелеп килә. Хезмәт эстафетасы, дәверләр эстафетасы дәвам итә. Ат һәм

Атом... Кызык, бу сүзләр бер үк тамырдан ясалганга охшый...» Мондый каршылыкка керүләр, әлбәттә, шагыйрьгә килешеп бетми. Җил тегермәннәре белән көрәшкән Дон-Кихот, әгәр бүген исән булса, АЭСларга каршы сугыш ачар иде.

Яшь шагыйрьләребез, билгеләп үткәнемчә, иҗтиһат итә. Шунысы да куанычлы: яшьләребез элитар шигърияткә дә өлешләрен кертергә омтылалар. Без кемнән ким? Акыл культурасы гына рух культурасына китерә. Икмәккә чагыштырмача туграк булган буын әлеге хикмәт асылын башкачарак аңлыйдыр. Минем үземә шулай тоела. Аларның акыллы булырга тырышуын, кайберәүләр кебек сукранмыйча, табигый күренеш итеп таныйм. Метафорик фикерләүләре ягыннан, әйдә, башкалардан аерылыбрак торсыннар. Әмма шунысын да онытмаска кирәк: шигъриятнең иң югары түбәсендә, кайсыдыр классик искәрткәнчә, метафоралар бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Купшы фикерләү шагыйрьне икенче чиккә ташларга, йөрәктән ерак нәрсәләргә китереп чыгарырга мөмкин. Метафорик фикерләүнең дә, кыскасы, үз хәтәрлеге җитәрлек. Бу җәһәттән Л. Зөлкарнәйне кайчак аңлап та бетерә алмыйм, әмма шуны ачык тоям: талантлы шагыйрь ул. «Йомарлам» исеме астында бирелгән цикл авторы Л. Лерон да югары зәвыклы укучыларга исәп тотадыр. Һәм Г. Сәлимов та. («Дәрвиш коңгыз» бәйләмен күздә тотып әйтәм.) «Учтагы песнәк» исемендә гаять кызыклы җыентыгын чыгарган Р. Юныста да уйчан-моңсу шигърият вәкиле булып калырга омтылу сизелә. Кызганыч: безнең тәнкыйтьчеләр шигърият ташкыныннан үзенчәлекле китапларны танып ала белмиләр. Уйчан укучыны яратарак төшкән талантлы буын вәкиле Акъегет турында да беренче тәпле бәяләү сүзен хөрмәтле прозаигыбыз М. Юныс әйтеп чыкты. Шигъриятне бөтен нечкәлегендә аңлавы белән ул безнең күбебездә соклану хисләре уяткандыр. Колакка ничек кенә сәер ишетелмәсен, татар тәнкыйте графоманнарга игътибарлырак кебек. Теге вакытта Р. Байтимеровны хәтта үзәк матбугатка өстерәп чыгучылар булды. Шундый вакыт аралыгын беләм: аның исеме Дәрдмәндтән дә күбрәк телгә алынды. Үзәктәге әдәби басмаларга чыгып, нигә яшьләребезгә бәя бирмәскә?! Алар бит моңа бик тә лаек. Без соңгы вакытта милли байлыкларны Кабанның төбеннән күбрәк эзлибез шул...

Дөреслек, моң, хикмәт... Шигърияткә шундый шартларның кирәклеге турында без форсат чыккан саен тәкрарларга яратабыз. Мондый зарур сыйфатлар, әлбәттә, шартлы рәвештә аталган. Сезне тагын бәхәскә чакырырга теләмичә, шуны гына исегезгә төшереп үтәм: соңгы вакытта иҗат ителгән шигъри әсәрләрне мин әлеге өчлекнең беренче өлешен үзәккәрәк алып күзәттем. Башкарак күзлектән дә карап булгандыр. Оппонентлар ташланырга әзерләнмәсен. Мәсьәләнең болай куелышын мин бүгенге көндә кулайрак санадым. Чөнки... Шигърият дөреслек күзенә, алдарак әйткәнемчә, турырак карый башлады. Иҗтимагый яңгырашның көчәюе дә шушы җирлектән киләдер. Хәзер һәрбер мәсьәлә сәяси төс ала. Сәясәтләшү замана билгесенә әверелде. Бүгенге шигъриятнең иҗтимагый яктан тирәнәюе, нигездә, халкыбыз хакыйкатен ачыклау юнәлешендә барадыр. Чөнки милләтара мөнәсәбәтләр дә сәясәт өлкәсенә керә. «Уянгач беренче эшем...» Халык язмышы хакында борчылу — хәзер әдипләрнең кичектергесез эшедер. Кайсыдыр яклары белән бүгенге көннәрне хәтерләтүче чорларда иҗат иткән Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев кебек фидаи җаннарның арабызда булуын моңарчы күрелмәгәнчә ачыграк сиземли башладык. Аларның язганнары шул дәрәҗәдә яңа, хәзер генә иҗат ителеп, әле карасы да кипмәгәндер шикелле. Әсәрләренә халык игътибарын юнәлтә генә белмибез. Шунысын да онытмыйк: безнең татар халкында профессиональ политиклар узган гасырда бөтенләй диярлек булмаган. Мондый мөһим ихтыяҗны әдипләребез тутыра килгән Хәзер дә хәл шулайрак.

Чакырулы очкын сүзләр, әйе, хәзер ешрак яңгырый. Мөхтәрәм тәнкыйтьче әфәнделәр, кашыгызны җимермичә, күңелегезне киңрәк тотыгыз. Бер-беребезне гаепләргә ашыкмыйк. Чоры шундый бит. Әлек кулдан ычкынган кирмәннәрне алыр вакыт! Татар шигърияте үзенең «солдатлыгы»н көрәштә янәдән раслап алсын. Милләтебез фанилыгын бераз чигендергәч, Туфанилык хакында ныклап кайгыртырбыз. Якын киләчәктә кодрәтле рухыбызның мәңгелек казанышлары тумыйча калмас. Сыйфат үзгәрешенә дә өметләнәсе килә. Активлаша да төшәрбез. Хәзер күбрәк укып, азрак язучылар байтак. Сәяси хәбәрләр ташкыны тиздән туйдыра башлар. Өстән тагылган «соцзаказлар» кимер, «каләм ләббәйкәлеге» яклаучысыз калыр. Теләсә нәрсә уңаеннан төкрек чәчүне саллы тарихи караш кысрыклап чыгарыр. Халык рухы, әлбәттә, исән булса. Әдәби тылыбыз нныклыгын кайгырта алган, лаек варислар тәрбияләүгә ирешкән чакта. Милләтнең мөбарак тәсбихы өзелеп китмәгән очракта!.. Егерменче гасырның соңгы унъеллыгын мин шундыйрак ышаныч белән каршылыйм. Һәм узган чорларда тормышка ашып җитмәгән кешелек өметен алгарак күчерергә мәҗбүрмен: «Киләчәктә дөнья белән шагыйрьләр идарә итәр...» Мондый символик максатка якынаю өчен барыгызны да Тукаебыз чакыруына кушылырга гына өндисем кала:

*Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән...*

**Ширияздан Сарымсаков,**
РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

# ӘЙБӘТ КЕШЕ, ОЛЫ ДРАМАТУРГ



*Композитор Салих Сәйдәшев белән Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль спектаклен иҗат иткән еллары.*

Таҗи аганың үзен яхшы белү — аның иҗатын дөрес аңларга да ярдәм итә дип уйлыйм.

1938 елның җәендә Түбән Осланда Әхмәт Фәйзи, әле генә язып бетергән «Тукай» драмасын укыды (ул елларда язучыларның кайберләре шунда — Түбән Осланда ял итәргә гадәтләнгән иде). Уку крестьян йортының бакчасында булды. Без шунда җиргә утырып тыңладык. Анда Шәриф ага Камал, Таҗи ага Гыйззәт, Риза Ишморат, Фатих Хөсни һәм ул вакытта республикабызның сәнгать идарәсе начальнигы булган Хәиров дигән иптәш бар иде. Әсәрнең яртысын укып, бераз ял итәргә туктагач, Таҗи ага миңа «Әйдә, Ширияздан, татарча көрәшеп алыйк, син Казакъстан кешесе, татарча көрәшнең серләрен белмисеңдер әле», диде. Без шунда ук алыша башладык. Анда булган кешеләр моны кызык күреп, көлешеп, кемдер көч биреп, озак кына карап тордылар. Алышу бер якның да җиңелмәве белән бетте. Ләкин Таҗи абый көрәшеп туктагач, миңа карап торды да: «Син дөрес көрәшмисең бит» дип, яңадан минем билдән алып, татарча көрәшнең алымнарын күрсәтә башлады. Ул моны шундый мавыгу белән эшләде, башкалар да сүзсез генә калмадылар, һәркем үзе белгәнчә, репликалар биреп, миңа ярдәм итәргә тырышты кебек. Ул аларны күрсәткәндә, аның өчен дөньяда иң матур, иң кызыклы көрәш алымнары татарча көрәштә тупланган дип уйларга мөмкин иде. Мин шунда Таҗи абыйның авыз тутырып, рәхәтләнеп халыкча сөйләвен ишеттем. Кайбер сүзләрне әйткәндә ясаган иркен хәрәкәтләре, тавышының яңгыравы, интонациясе хәзер дә хәтердә. Аның «алагаем» дигән сүзе (бәлки минем беренче ишетүем булгангадыр) бигрәк тә истә калган. Ул аны киерелә биреп, рәхәтләнеп, шул сүздән тәм табып әйтте шикелле.

Таҗи абый авылны, аның кешеләрен, аларның гореф-гадәтләрен яхшы белә иде, күп кенә якларына ихтирам белән сокланып карады. Ул гомере буена авыл кешесенең хезмәтенә, тырышлыгына, чисталыгы-сафлыгына мәхәббәт саклаган кеше. Мин 1927 елның көзендә Татарстанга килеп, елга якын Олы Мәңгәрдә торып, көзен, кышын, язын шул тирә авылларында булмаган, аның карав[illegible]йләрен, каз өмәләрен, аулак өйләрен, әвен сугуларын, яз үткәрелә торган сабан туйларын, бәйрәм төсле базарларын күрмәгән булсам — Таҗи абый Гыйззәтнең иҗатын якын итеп күрә дә алмаган булыр идем, бәлки.

Җәй көннәрендә Таҗи ага, аз гына мөмкинлек булган саен, авылга, үзенең туган якларына кайтып килергә тырышты. Аның табигатьне яратуы да шуннан: авыл тынлыкларыннан, аның чишмә, инеш-елгаларыннан, урман-кырларының, болыннарының күз алдында торуларыннан, күңелендә саклануындадыр дип уйлыйм.

Миңа Таҗи абый белән күп тапкырлар балыкка барырга, Идел буйларында кунгаларга туры килгәне бар. Ул анда чалбар балакларын күтәреп, изүләрен чишеп җибәреп, шул табигатьнең эченә «чума» иде шикелле. Бер җәйне без гаиләләребез белән

Обсерваториядән Иделгә таба китеп, шул юлдагы таллыклар белән уратылып алынган зур, тыныч күлләрнең берсе янына урнашып балык тоттык. Кичке чәйне эчә-эчә озак кына сөйләшеп утыргач, Таҗи абый белән кечерәк кенә ике сал ясап, күлнең уртасына ук кереп утырдык. Җәйнең җылы көннәре, кыска төннәре вакыты иде. Салларыбызның арасы 15—20 метрдан артык булмагандыр. Ләкин Таҗи абыйның бер генә авазын да ишетмәдем. Балыкларны куркытырга теләмәве булдымы, шул тынлыкны бозасы килмәве булдымы, гаҗәеп бер «онытылу» белән утыра бирде. Төне, чыннан да, тыныч, җилсез, җылы иде. Таң якынлашты. Аның салкыны артыннан акрынлап күл өстеннән куе пар күтәрелеп, бөтен дөньяны томанга күмде. Калкавычны күрер өчен аны салга якын ук тартып китереп куярга туры килде. Таҗи абыйның моңа исе китеп тормады, тып-тын утыра бирде. Томанның, парның тәнгә юеш салкынлык бирүенә әһәмият бирмәде шикелле. Балык эләккәч кенә аны судан чыгарган вакыттагы чапылдаудан башка берни дә ишетелмәде.



*Сугыш алды елларында Таҗи Гыйззәт белән Шәйхи Маннурга ясалган дусларча шарж.*

Таҗи абый тормышта иҗат эше белән бәйләнгән вакытларда эмоциягә дә бирелеп киткәли торган кеше, бирәдә шуның киресен күрсәтте.

Көн ачылып, кояш кыздыра башлагач без ярга чыктык. Таҗи абыйның беренче сүзе — «Әйбәт булды төне, көне дә шәп булыр төсле» дию булды. Күл өстендә төн үткәрүеннән бик канәгать икәне күренеп торды. Таҗи абыйны якыннан торып яхшы белгән саен, аның табигатьне бик гади итеп кабул итүен күрә бардым.

Иҗатта шәхеснең кайбер яклары чагылмыйча мөмкин түгел. Таҗи абый кешедә үзенә ошаган яхшы сыйфатларны күрсә, ул аңа хөрмәт белән карап, аны һәрвакыт якларга әзер торды. Кемдәдер әшәкелек күрсә, кешелек ягы начар икәнен белсә, андый кеше турында кискен рәвештә үзенең нәфрәтен белдерүдән тарсынып тормады. Ул тормышта да, иҗатында да ачык карашлы, тулы тавышлы булды. Урталык та, үтә нәзакәтлелек тә аңа хас сыйфат булмады, минемчә. Ул тормышта була торган, сәнгать өчен «натуральныйрак» дип каралганны сәхнәгә күчерә белде. Менә «Мактаулы заман». Баштарак әсәр театрда күп кенә кешегә ошамады, бозауларның әче китүе турында уйнау театр эстетикасы ягыннан, бик үк күңелле түгел булып күренде. Мин үзем дә шундый фикердәге кешеләр арасында идем. Ләкин әсәр театрда уңыш белән барды. Тамашачы (бигрәк тә авыл тамашачысы) яхшы кабул итте.

Әлбәттә, әсәрдә күтәрелгән төп мәсьәлә бозаулардагы авыру түгел, монда авторның ул вакыттагы колхоз тормышында килеп чыга торган проблемаларны якыннан белүендә, алар турында үткен итеп әсәрендә әйтә алуында. Таҗи ага әсәрләрендә конфликтны, вакыйгаларны ачык итеп, кискен итеп бирергә яратты, артист уенында да шуны күрергә теләде. Ул үзе дә, артист буларак, сәхнәдә яшәвендә шул ук алым белән эш итте. Мица аның «Чаткылар» спектаклендә Орлов, «Бишбүләктә» урта хәлле крестьян Әхтәм, «Ялкын»да слесарь Кондрат рольләрендә күрергә туры килде. Орловны башкарганда, аның урядник белән очрашкан сәхнәләрендә, Таҗи абый Орловны кискен чаралар кулланып алып барды. Орловның урядникка булган карашын яшермичә, араларында дошманлык бар икәненә басым ясап уйнады. «Бишбүләк»тә Әхтәмне бигрәк тә, аның Кызыл армия ягыннан торып сугышырга карар кылган өлешендә яшь егетләрчә дәртләндереп уйнады. Әхтәм образын, аның шәхси сыйфатларын ачуга караганда, Таҗи абый үзенең Әхтәмгә булган мәхәббәтен күбрәк ачты. Крестьян Әхтәмнең күтәрелеп, кабынып, хәтта дулап к[illegible]п, зур эшләр кылырга сәләтле икәнен әйтәсе килде.

Таҗи Гыйззәт, драматург буларак, театрда туды, театрда үсте, камилләште, театрның серләрен практикада үзләштерде. Ул, театрның үз кешесе, аның шатлыкларын да, кайгы-хәсрәтләрен дә бергә кичерде. Артистлар, режиссерлар белән аралашып яшәде. Татар академия театры артистлары арасыннан аның иң яратканы Зәйни ага Солтанов булды. Зәйни ага сәхнәгә килеп керсә, сәхнә тулып киткән шикелле буладыр иде. Ул тудырган образларның барысы да диярлек яшәүләре белән киң, иркен хәрәкәтлеләр. Зәйни ага тормышта да ваксынмый торган, киң күңелле, юморга бай кеше. Сәхнәдә образның яшәвендә аның бу сыйфатлары тагын да калкурак булып үсеп киткәндәй була. Артистның уйнаган саен сәхнәдә рухлана барып, күтәренкелек белән яшәве Таҗи

абыйның күңеленә бигрәк тә хуш килгәндер дип уйлыйм.

Зәйни ага Таҗи Гыйззәт әсәрләренең байтагында катнашканы бар. Драматургның үз әсәрендә уйнаган артист турында кайбер фикерләр, шул җөмләдән тәнкыйть фикере әйтүе табигый. Зәйни ага уены турында Таҗи абыйның сокланып кына сөйләвен ишетергә туры килә иде.

Таҗи абый үзен Кәрим ага Тинчуринның шәкерте дип горурланып әйтә иде. «Наемщик», «Бишбүләк» әсәрләренең музыкалы булуы өчен генә түгел, аларның рухы белән дә, театраль алымнар ягыннан да Кәрим Тинчурин тәэсире белән язылгандыр дип әйтәсе килә. Бу, Тинчурингә сукыр ияру түгел, бу аның Тинчуринның иҗади алымнарын, аның үзенчәлеген, яратып, яшермичә, кабул итүе иде. Әлеге ике кешегә карата Таҗи аганың хөрмәте, мәхәббәте аерата көчле булды. Бәлки бу Самарадан ук башлангандыр. Таҗи ага Самара театр студиясенә алар тарафыннан кабул ителеп, театр иҗатының башлангыч белемнәрен алар җитәкчелек иткән мәктәптән ала бит. Сәбәбе ул гына түгел, театрның төп терәкләреннән булган, барыбыз тарафыннан хөрмәт ителгән, яраткан бу кешеләрнең сафлыгы, эчкерсезлеге, эчтән яктырып торган мөлаемлыгы, аларның иҗаттагы югарылыгы үзенә тартып, сокландыргандыр дип уйлыйм.

Кәрим Тинчурин шикелле шәхеснең йогынтысы көчле булуга карамастан, Таҗи Гыйззәт үзенә генә хас булган иҗат юнәлешендә нык тора. Ул, әсәрләрен кайта-кайта эшләгәндә дә шул хәлне күреп тора. «Талир тәңкә»не «Чаткылар»га әйләндергәндәге, «Ташкыннар»ны трилогия итеп эшләгәндәге хезмәтләре шуны күрсәтә.

«Ташкыннар»ның театрда уйналуы минем хәтеремдә нык сакланган. Ул әсәр тыңлаучыларның барысына да бик ошады. Аны Октябрь революциясенең 20 еллыгына куярга кирәк дигән бердәм фикер булды. Ул Гомәр Исмәгыйлов тарафыннан яхшы итеп куелды. Артистлар коллективы спектакльне зур энтузиазм белән әзерләде. Тамашачы бик әйбәт кабул итте. Шуңа да карамастан, берничә ел үткәч, Таҗи ага «Ташкыннар»дан трилогия эшләде. Автор революциягә килүче крестьянның юлын тагын да төгәлрәк нигезләргә тырыша иде.



*«Чаткылар» спектакленнән бер күренеш. Уңда — Орлов ролендә Таҗи Гыйззәт үзе, ә урәтник ролендә — Касыйм Шамил.*

Таҗи абыйның уй-фикерләре, кайтып-кайтып үзенә тартып торган темасы — татар крестьяннарының зур восстаниесен күрсәткән әсәр язу иде. «Ул «Ташкыннар», «Ялкын» аша шуңа юл тотты. Крестьяннарның зур күтәрелешен, аларның, хәтта берничә губерна кузгалышларын бер үк вакыт чагылдырырга уйлады. Моның тормышка ашмый калуы — кызганыч. Ул крестьянның революцион күтәрелешләргә килүенә үзенә күрә бер романтик төс биреп, крестьян катлавыннан чыккан кеше буларак, моның белән горурлана да иде шикелле.

Минем хәтеремдә Таҗи абый образы халыктан чыккан, җиргә нык басып торган талант булып калган. Аның кешелеге турында бер генә фактны искә төшереп китәсем килә: 1939 елгы көзнең соңгы айлары иде. Минем өстемдә юка гына, җылы тотарлык хәле калмаган кичерәк бер плащ иде. Ничек кенә туңарга тырышмасам да, туңганлыгым башка кешеләрнең дә күзенә ташланган күрәсең. Студентлык хәленнән әле чыгып өлгермәгән кешедә җылырак яңа кием алып киярлек хәл булмагандыр — моны Таҗи абый да күрми калмаган. Бер көнне репетициядән кайтышлый (без алар белән Островский урамында янәшә йортта тора идек) Таҗи абый миңа карап: «Миндә бер көзге пальто бар, әле киелмәгән, сиңа ярарга тиеш», диде. Минем тиз генә җавап бирмәвемне күреп, «акчасын соңыннан бирерсең, ул турыда уйлама» диде. Шундук мине үзләренә алып керде дә, әлеге пальтоны кигерде. Әйтерсең, миңа үлчәп тегелгән, пальто миңа бик таман иде. Шундук җылы булып китте. Мин аны ике ел буена көзен дә, кышын да кидем. Аның йомшаклыгын, җылылыгын хәзер дә өстемдә тоям шикелле.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЛӘРДӘ «ТАШКЫННАР»

Таҗи Гыйззәтнең бөтен иҗаты миңа Бөек Ватан сугышы алды чорында, яки сугыш елларында сеңде. Ул язучы минем өчен бик зур иде — Кәрим Тинчурин, Ф. Бурнаш юк заман — Таҗи Гыйззәт безнең буынга бала чакта сәхнә тәрбиясе биргән бердәнбер кеше булды.

Мин эшлекле, һөнәрле авылда туып үстем, андый эшлекле авылга культура чаткылары соңрак керә. Авылда башлангыч мәктәп, ул әле дә булса шунда — 19 йөз ахырында ук салынган мәчет бинасында. Әнә шул бинаны 1936 елдан башлап кичләрен, мәктәп мөдиренең рөхсәте белән «вечер уйнарга» алып торалар иде. Ара-тирә шул ук бинада өстәл-парталарны тезеп сәхнә ясыйлар да, концерт, сирәк кенә спектакль куялар. Безгә культура каян килә? Алты чакрым ераклыктагы, республикада мәшһүр Сеҗе урта мәктәбеннән. Укытучылар-укучылар бер булып оешалар да, безгә килеп дер селкетеп бер концерт куеп китәләр. Авыл халкы өнсез кала: концерт куючы кызлар зәңгәр юбка, ак кофта кигәннәр (авылга «куфтеюфты» дигән исем керде), кызыл галстук такканнар, чәч кистергәннәр (авыл халкы боларның татар кызлары икәненә ышанмый, бөтенесе «марҗа» дип утыра), болар җырлыйлар, бииләр, трубада уйныйлар, пирамида ясап лозунг әйтәләр... Авыл «дөньяда мондый могҗиза да була икән» дип хәйран калып, атналар буе яши. Ул арада көзге кичләрнең берсендә каравыл өенең бүрәнәсендә чыра кисәген шәмәхә карага манып обой кәгазенә язылган афиша күренә: Сикертән мәктәбе укытучылары бүген кич «Ак баш вакыйгасы»н куялар. Авыл дөрт итә. Бу спектакльгә мине алмыйлар, миңа әле алты гына яшь. Апалар, абый җыелып шунда китә. Мин елыйм, минем Сикертән мәктәбе укытучылары уйнаганны бигрәк тә күрәсем килә, чөнки ул мәктәптә туганнан туган абыем — шулай ук Мөхәммәт Мәһдиев һәм сеңлесе Гандәлиф Мәһдиева эшли, болар минем өчен дөньяда иң чибәр, иң затлы кешеләр. Спектакль тәмамлангач алар безгә керәләр, мин йоклый алмыйм газапланып ятам, әти тышкы бүлмәдән коштабакка салып, утырган бал алып керә, идәндә самавыр дөрли, әни (җиңги кеше!) кайне белән каенсеңелгә ошар өчен самавыр торбасына утлы күмер өстенә лимон кабыгы сала, өйгә затлы хуш ис тарала, кемдер такта чәй вата, өй эче гөж килә, ә бераздан җырлап та җибәрәләр...

*Акбашкаем, башмаккаем*
*Күрмәдеңме, балакаем*
*Ач бүрегә тәмле азык*
*Булганмәллә яшь малкаем...*

Бу — безнең өйдә Таҗи Гыйззәт яши икән. Миңа куркыныч: көзге кич, төн, томан. Без — урманлы, бүреле халык. Абзар түбәләре салам. Әле бер кешенең, әле икенче кешенең абзар түбәсен тишеп, явыз бүреләр сарык буалар. Мин йоклый алмыйм, мине чәй янына да чакырмыйлар, хәзер инде эти үзенең сеңлесен — калын ике толымлы, гүзәл апабыз, көмеш тавышлы Гандәлиф апаны җырлата. Ни гаҗәп, хатын роленә кеше тапмаганнар да, авылның мир көтүчесе Ибәт абзыйны киендереп сәхнәгә чыгарган-

нар. Ә ул һәр көнелле, табигать баласы (ногыт борчагы тәгәрәтеп фал ача, кешеләрнең алданганына үзе үк шаккатып сөйли иде) чыккан да, болай җырлаган:

*Килгән идем чиратка*
*Яшь баламны калдырып,*
*Имезләгән суыра-суыра,*
*Котәр инде тилмереп...*

Аннан безнең өйдә атналар, айлар буе Котбетдин җыры яшәде:

*Кайгырмала, Сәрбиҗамал,*
*Баш сау булса, малның җаен*
*Үзебез табарбыз.*
*Барын тар-мар китерик тә,*
*Сатып-эчеп бетерик тә*
*Читкә таярбыз...*

Мин бу җырларны бала вакытта ничек хәтерләп калсам, шулай яздым. Т. Гыйззәт әсәрләренең 1976 елда чыккан икенче томындагы текстлар белән чагыштырып караганда кайбер аермалар бар. Әмма, мин хәтерләгәне шомарак, иплерәк. Халык, димәк, текстны үз эченә алып эреткән, әшкәрткән. Хәзер уйлап куям: күпме еллар узган! Бу пьесада уйнаган кешеләрдән дөньяда бер Гандәлиф апа исән әлегә. Укытучы-пенсионер. Биектау районы Тимерче авылында төпләнеп калды. Безнең өйдә Т. Гыйззәт җырларын калдырып, 1936 еллар тирәсендә ул шул авылга китеп барган иде.

Тагын бер истәлек. Утызынчы елларның ахырында «Татшвеймехпромсоюз» дигән, исемен шайтан да әйтеп бетерә алмаслык бер оешма Арча якларында тегү артельләре ачып җибәрде. Бик акыллы, тирәнтен уйланган бер адым булган ул, кызлар җәй-көз колхозда эшлиләр дә, кыш буе тегү артелендә булалар, акчага кинәнәләр иде. Безнең һөнәрле, эшлекле авылга бик тә мач килде бу. Артельнең үзәге Г. Камал энисе авылында — Иске Масрада. Шул елларда ук белгәннәр, уйлаганнар: тегү артеленең филиалы урнашкан безнең караңгы авылга бервакыт мандолина җибәрәләр. Артель кызларына! Авыл — өнсез! Авылга номерланган гап-гади бер нота да язып җибәрәләр. Имеш, «Тамчы» көе. Тегендә, Иске Масрада «культорг» дигән хикмәтле бер кыз бар икән, бары да шуның эше. Бераздан ул кызның үзен дә күрәбез: безнең авылларда, безнең төбәктә сирәк очрый торган тавышлы (чишмә, сандугач, көмеш телле Вараксин тавышларын үзенә туплаган) кара күзле, матур чәчле Тәскирә Фазылҗанова икән. Дөрес, минем үз апаларымны да авылда матур кызлар разрядына кертәләр иде, әмма бит алар минем үз апаларым, үз апаң, ни әйтсәң дә башка авылдан килгән культорг төсле үк матур була алмый инде ул... Тәскирә апа бер килүендә минем нәни бармакларны тимер чыбыклар өстенә баса-баса «авыл нотасын» аңлатып, «Тамчы» көен өйрәтеп китте. Шуннан бирле гомерем буе өйдә мандолина тотам, хәтта кешене җырлатырлык итеп уйныйм да. Рәхмәт әйтергә иде аңа, Тәскирә апага, әмма ни кызганыч — дөньяда ул юк инде. Тәскирә апа көннәрдән бер көнне безнең мәчет-клуб коймасына шәмәхә кара белән язылган белдерү элде: иртәгә, фәләненче февральдә, Иске Масра авылы яшьләре Гөберчәк авылында театр куялар. Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» әсәре. Башлана...

Һи-и, ул башлануларны беләбез инде. Мал карап, керосин лампасына керосин салып, лампа пыялаларын чистартып, вак-төяк баланың тамагын туйдырып, ятар алдыннан абзар артына алып чыгып илэк йолдызлар, җидегән йолдызлар турында сөйли-сөйли бераз көтеп торулар, шуннан соң аларны сәкедәге тун өстенә тәгәрәтәсе, толып белән каплап, кече учакларны тикшереп, мич алдына күмер төшмәгән икәненә ышанып, лампаны кыса төшеп, ишекне тыштан терәтеп чыгып йөгерүләр инде ул... Әле капкадан кире абзарга колак саласың: теге мүкләк сарыкның җилене бик кызган иде бүген, бәтиләп куймасын без театр караганда... Шулай, шыгырым тулып, морҗа артларына, ишек-тәрәзә өсләренә кунаклап, сәхнәгә янкне терәп, сәхнә-парта асларына кереп, бер-беребезне төрткәләп, мышлап (булса — кесәдән ипи алып капкалап), һәм — котылгысыз инде — бүрек белән бер-беребезне бәргәләп, тузан, ыгы-зыгы чыгарып «Наемщик»ны карыйбыз. «Наемщик» сүзенең мәгънәсен авылда им өчен бер кеше белми. Ләкин ирләр чамалыйлар. Налоглар заманы ул. Заем, самообложение, авыл хуҗалыгы налогы, ит, бәрәңге, сөт налогы, культсборы... («Брынза» налогы ул вакытта әле юк, аннсы сугыш вакытында керде, йомырка налогыннан соң керде). Агайлар чамалыйлар: наемщик — шәп сүз түгел, бу әлеге недоимщик дигән сүзгә охшый. Налог түләгән заманда «недоимщик» дигән сүз бар иде (түләвен соңга калдырган кеше).

Инде сәхнәдәге чынлык... Камиләтти белән Кәшифәттинең берсе кызыл эре шакмаклы, икенчесе зәңгәр эре шакмаклы чаршавын кер бавы буенча шудырып ачтылар... Чын аркылы пычкы белән чын арканы (Казан артында агач кәүсәсен озынлыгы дүрт метрдан да ким булса, бүрәнә дип түгел, арка дип йөртәләр) ике егет гөжелдәтеп кисмәсен-

ме... Кисәләр — җырлыйлар. Кисүе безгә таныш, газиз. Бу — безнең көндәлек, көндезге тормышыбыз. Җырлавы — Таҗи Гыйззәттән. Анысы инде «театр» дип атала, хәзер уйлыйм,— сәнгать. Шул кадәр чынлык: балта, пычкы, чалгылар — бөтен урамнан җыйдылар. Текстны кыскарту юк: әсәрдә (китапны ачмаган көе язам) күрше алпавыт Абалинский образы бар. Ул — чукрак. Аңа иң аз «нагрузка» бирелгән. Иске Масраның бер егетен алпавыт Абалинский итеп киендереп тире кисәгеннән (Иске Масра артелендә тире күп — бүрек, бияләй тегәләр) мыек тарттырып куйганнар да, бер почмакка бастырганнар. Әсәрдә Шәрифә бикә дә, Бикташ та, Аскәрик та гел сөйләшәләр, гел хәрәкәттә, әмма, Таҗи Гыйззәт теге чукрак алпавытка бер генә мөмкинлек биргән: үзе ишетмәгән фразага реакция. Чукрак кешенең иң беренче реакциясе билгеле инде:

— А?

Теге егет, бичара, сәгать буе бер урында басып, суфлер әйткән саен кабатлап торды:

— А?

Кырык өч елдан соң тикшереп карадым (Т. Гыйззәт, әсәрләр, дүрт томда, 1 том, 1975 ел)— нәкъ шулай икән. Алты чакрымлы авылдан кышкы буранда шул «а»ны әйтер өчен генә бер егетне борчымасалар да буласы икән инде! Әмма, сәнгать! Сәнгать! Сәнгать ул — авылда үзенчә яши. Шәһәрдәгечә түгел!

Берзаман сәхнәгә Гөлйөзем чыга. Җыр. Арттан тальян ишетелә. Гөлйөзем — муенына чыршы бизәкле торган ялтыравык пыяла көпшәләр таккан Тәскирә апа! Чәчләр, күзләр, тавышлар... Агай-эне шыгырдап ала, урынын җайлаган була (янда юантык хатын утыра, тәҗрибәле агай-эне сизә: Батырҗан белән Булат агай утын кискәндә, җырлаганда хатын тынычрак иде).

Менә бервакыт сәхнәдән моң агыла. Гөлйөзем-Тәскирә җырлый икән:

*Егет күңеле җилкенә,*
*Яхшы ат күргәч.*
*Бар нужасы онытыла*
*Янда сөйгәне булгач...*

...Ул кышны авыл «Наемщик» белән генә яшәде. Авылда ул спектакльдән ике җыр, бер мәзәк калды. Җырлар: «Сау бул инде, минем туып-үскән илем...» һәм «Егет күңеле җилкенә...» Мәзәк: Иманкол мулланың ярлы крестьянга шәригатьне яшел тышлы һәм кызыл тышлы китап буенча аңлатуы. Утызынчы-кырыгынчы еллар, әдәбиятта язучыларның рәхәтләнеп мулла сүккән еллары иде. Бу, әйтергә кирәк, бик отышлы материал, моңа еш кына әдәбият-сәнгатьтә әзерлеге, таланты җитмәгән каләм әһелләре тотына һәм зур гына уңышка да ирешәләр иде. «Наемщик» үзенең социаль эчтәлеге белән болай да бай, тирән фикерле иде, «яшел тышлы китап» белән мавыгу тамашачының игътибарын читкә алып китә язды. Отышлы материалдан талант иясе дә баш тартмый...

«Яшел тышлы китап» дигәннән, егерменче, утызынчы еллар татар әдәбиятының бер үзенчәлеге инде ул. Бездә кулына каләм алган һәр кеше мулла сүкте, мәчет сүкте. Әйтерсең, дөньядагы бөтен явызлык шуларда гына иде. Авылда социаль-сыйнфый үзгәреш бара, яңа культура ясала-туа, анда әллә никадәр проблемалар бар иде. Ә бездә һәр әсәрдә диярлек мулланы корткыч, контрреволюционер итеп сурәтләп бетерделәр, ә ул катлаудан тәмам сыйныф ясадылар. Оныттылар: шагыйрьләр, прогрессив галимнәр, прозаикларның бер төркеме — Ш. Зәки, Г. Кандалый, Ш. Мәрҗани, З. Һади, З. Бигиев — мулла иделәр. Муллаларның аерым төбәкләрдә бөтен-бөтен мәгърифәт учаклары тотканы (Бубилар), Колчак бандалары тарафыннан «кызыллыгы» өчен җәзалап үтерелгәннәре (Д. Гобәйди) дә булды. Г. Ибраһимов, Ш. Камал кебек язучылар беркайчан да бу катлауга бер бөтен итеп, яман күз белән карамадылар.

«Наемщик» кебек тирән социаль-эстетик фикерле, киң полотнолы, музыкаль әсәрдә «яшел тышлы китап» вакыйгасы, әлбәттә, шул еллардагы бер шаукым иде һәм ул эпизодның әсәрне мәзәккә әйләндерү куркынычы бар иде.

Хәер, ничек кенә булмасын, сугыш башланганчы безнең күңелләрдә Батырҗан, Гөлйөзем арияләре булды, явыз көчләр — алпавытларга, надан муллаларга, стражникларга нәфрәт кайнады. Батырҗан ариясе шул меңүдән соң сәхнәдән инде төшмәде. Аны хәтта яңартып та җырлый башладылар. Якынча хәтерләвем буенча менә болай:

*Без үтибез, дуслар, зур тырышлык белән*
*Партиянең кушкан корыч карарын.*
*Киртәләрне җимереп зур көрәшкә таба*
*Якты көнгә таба алга барабыз.*
*Кушымта:*
*Алма агачлары зур булмас,*
*Хезмәт иясе хур булмас!*

Менә сиңа наемщик Батырҗан! Халык моны шулкадәр яратмаса, алай тиз генә советлаштырыр идемени! Нәкъ коммунист булган да куйган бит!

Иске Масра авылы яшьләре әнә шулай итеп бер көнне безнең авылны Таҗи Гыйззәтле, Салих Сәйдәшевле иттеләр дә куйдылар. Моның тәэсире шулкадәр зур булды ки, 1940—41 елның кышында үз авылыбызның яшьләре дә тәвәккәлләп Таҗи Гыйззәткә тотындылар. Кичен «вечер уйнаулар» бетте, ярты авыл репетициягә йөри иде.

1941 елның сигезенче мартында яшьләр Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасын әзерләп, авыл сәхнәсендә «театр куйдылар». Өлкәннәрнең аяк араларына кача-кача клубка кереп, морҗа артларына, сәхнә кырына тулган малайларның берсе мин идем — безгә ул елны нибары унберенче яшь иде. Сәхнәгә никадәр якынрак килү, уйнаучының аяк башына никадәр ешрак иягең белән бәрелү — безнең өчен ул чорда зур дәрәҗә, мактанырлык бер «батырлык» иде.

Ул елдан соң илдә, дөньяда зур хәлләр булып узды. Җир шары үз балаларын күп, авыр сынаулар аша үткәрде. Сәхнә кырына иягең терәп «Ташкыннар»ны караган малайлар инде өлкән ирләр булдылар (революциягә кадәр безнең яшьтәге кешеләрне «фәлән карт» дип кенә атап йөрткәннәр)— болар хәзер колхозның, заводның, мәктәпләр, учреждениеләрнең тәҗрибәле эшчеләре, җитәкчеләре, хезмәткәрләре. Тормыш законнары шулай — без олыгаябыз.

Әмма кулга каләм алуның төп этәргече һич тә әлеге фикер түгел. Төп этәргеч — дәһшәтле сугыш башланырга өч-дүрт ай кала авыл сәхнәсендә шул драманы уйнаган яшьләр язмышы, шулар турында уйлануларым булды.

...Аларның бик күбесе хәзер дөньяда юк инде. Шулай туры килде — «Ташкыннар» драмасында катнашкан егет-кызларның барсы да диярлек сугыш елларында һәлак булдылар. Хәзер ул авыл кечерәйде, йорт саны, димәк, егетләр-кызлар саны азайды, анда инде «Ташкыннар»ны куярлык көч юк. Ә кырык беренче елның язында безнең күңелләрне тетрәткән драма һәм анда уйнаучылар халык хәтерендә әле дә яши. Уйнаучылар — балаларының, оныкларының тормышында яшиләр... Кемнең биографиясеннән башлыйм икән?

Хәсәнев Габдрахман 1939 елда Көнбатыш Украинаны азат итүдә катнашкан артиллерист егет иде. Кырыгынчы елның көзендә демобилизацияләнеп кайткач, кичләрен көндезләрен безгә ул күп нәрсә сөйләде: нәрсә ул сугыш, һөҗүм, снаряд ничек шартлый, кеше ничек батырлык күрсәтә, ничек үлә... «Ташкыннар»да ул Биктимер картны уйнады, авылда бер генә скрипкачы да юк иде — безнең авылда сугышка кадәр бик абруйлы, вәкарь белән гегә йөргән өч-дүрт гармунчы егет булса да, скрипкачы юк иде. Артиллерист Хәсәнев Габдрахман утын лапасында скрипка, смычок ясады. Хәсәневнең әнә шул сөян бүкәненнән юнып эшләгән «скрипкасы» белән спектакль башланып киткән иде. Халык шыгырым иде. Биктимер картны тын да алмыйча тыңладылар. Биктимер картны уйнаган Габдрахман 23 июнь көнне үк тагын сугышка чыгып китте. Һәм безнең авылда иң беренче үлем хәбәре аның турында килде.

Тагын кем? Биктимер картның мәлайлары — Нургали, Мирхәйдәр, Мирвәлине уйнаган егетләр истә калган. Нургалине безнең укытучыбыз — чибәр, мәһабәт Рәшит Әхәтев дигән егет уйнаган иде. Ул сугышка кадәр бер ай алдан армиягә китте, лейтенант дәрәҗәсендә Берлинга кадәр барып җитте һәм кырык бишенче елның августында эшелон белән Көнчыгышка узды. Аның эшелоны туган авылыннан нибары алты чакрым ераклыктагы разъездда туктап торган һәм ул, вагоннан чыгып, авылдашлары күренмәсме дип, чабулап йөргән. Аннан Квантун армиясе белән көрәштә лейтенант Әхәтев Маньчжурия далаларында ятып калды. Ул укытучы Рәшит абый булып та, «Ташкыннар»дагы Нургали солдат булып та безнең күңелләрдә калды...

Ә «Ташкыннар»дагы Мирхәйдәр? Аның җан тетрәткеч җырын, юеш окоптан язган җырын тыңлагач, безнең клубта күпме генә кешенең яше түгелмәде?

*Миннән калган түбәтәйне*
*Төсем итеп тотың кучкарда;*
*Дөньялыкта кауша*
*алмасак —*
*Кавышырбыз мәхшәрдә.*

Авыл халкы ул чакта мәхшәр, кучкар сүзләрен әле бик яхшы аңлый иде һәм ат карауčы таза егет Шәймуллин Хәкимулланың сәхнәгә сыя алмыйча башын бөгә-бөгә, суфлер утырган якка колагын сала-сала: «Нишләп бирәү дә күренми?» — дип сәхнәгә килеп чыгуы (үз гомерендә беренче һәм соңгы мәртәбә!)— халыкны тетрәтте. Мирхәйдәрнең үлгән хәбәре әнә шул көнне — кырык беренче елның сигезенче март көнне сәхнәдән яңгыраса, Хәкимулланың үлгән хәбәре соңрак булды. Сталинград сугышында авыр яраланып, чир әләктереп кайткач, ул зур газаплардан соң, туган нигезендә — ян сәкегә ятып үлде. Күрше буларак, мин аларга еш керә идем, һәм, йөзенә үлем сарысы

коелган Хәкимулла солдат авыр сулап, кырык беренче елның сигезенче март кичәсен — үзенең беренче тапкыр сәхнәгә чыккан кичәсен искә ала, сагышлый иде. Хәкимулла солдатны кырык дүртенченең салкын, шыксыз кышының бер көнендә аргы яктагы агачлыкка илтеп урнаштырдылар. Ә безнең күңелләрдә ул юаш, басынкы Мирхәйдәр солдат булып һаман яши бирде.

Ә Мирвәли? Монысын авыл егете Галәвиев Шәяхмәт уйнаган иде. Әйе, ул да вафат. Шәяхмәт җырчы иде. Төннәрен ялгыз җырлап узарга ярата иде. Хәтерлим, аларның ирләр тулы гаиләләрендә төпчек кыз Оркыя бар иде, ул кызчык чәчәкме-кызамыкмы авыруыннан үлеп китте. Өлкән абыйсы Шәяхмәт шул елда еш кына төннәрен урамнан җырлап уза иде:

*Сеңлем, сине төштә күрдем —*
*Караватта ятасың.*
*Йөрәгемнең уртасында*
*Алсу сачәк атасың.*

Биктимер карт малае большевик Мирвәлине ни өчен Галәвиев Шәяхмәт уйнаганын беләм. Мирвәли кебек ул да ил-җир күргән, шахта, Мәскәү йөргән егет иде, һәм ул Мирвәлине нәкъ бүгенге төсле — камалчылар төсле уйнады: аягында хром итекләр, өстендә кара спай пиджәк, ак күлмәктән иде. Кырык икенче елның кыш башында Шәяхмәт авыр яраланып кайтып төште. Күпмедер вакытлар газап чигеп яткач, дөнья куйды.

«Ташкыннар»да Хөрмәтулла, Басари, Ясәви, Әхтәрине уйнаган егетләр барысы да Ватан сугышы фронтларында ятып калдылар. Хәзер исәпләп карыйм: аларга ул язны 17—19 яшь булган икән, ә фронттан егерме икенче, егерме өченче елгылардан бик аз кеше кайтты. Егетләр генәме?

«Ташкыннар» пьесасында «Кислатабану» (Зәмзәмбану) ролен авылның иң чибәр, иң елдам кызы Гандәлип уйнаган иде. Хөрмәтулланың хатыны Мөршидәне минем апам Ракига уйнады. Яшь җаннар... Аларга кырык беренче елның язында егерме тулган иде. Оборона эшендә катнашып, шунда каты авыру эләктереп, апам Ракига дөньядан китте. Аңарчы Гандәлипне җирләгәннәр иде.

1941—45 еллар авылыбыздан бик күп корбан сорады. Корбаннар бирелде. Хәзер «Ташкыннар» драмасында катнашкан безнең авыл яшьләреннән нибары ике кеше исән: Гөлчирәне уйнаган Закирова Кафия — ул бик әйбәт җырлый иде, аны Казанда яши, пенсиядә дип сөйлиләр. Басарины уйнаган Дәүләтшин Фатих, Ватан сугышы ветераны, җиде бала үстереп пенсиягә чыкты, Казанда яши.

Еллар, аккан сулар, узган гомер...

«Ташкыннар», гомумән, бик тормышчан әсәр, ул — безнең халыкның тәрҗемәи хәле. Сигезенче март көнне куелган ул пьесаның финалында Әхтәри староста туй мәҗлесенә килеп кереп:

— Патша хәзрәтләренең фәрманы бар: герман сугыш башлаган!— дип бөтен залның йөрәген тетрәтте.

Дүрт ай узгач, безнең авылга телефонлы Сикертән авылыннан чапкын килде:

— Совет хөкүмәтенең белдерүе бар: фашистик Германия безгә сугыш башлаган!

Әхтәри, Басари, Нургали, Мирвәли, Мирхәйдәр, Биктимерләрне уйнаган егетләр шул ике-өч көн эчендә җырлап авылдан чыгып киттеләр. Юллар озын, газаплы иде. Күбесе шул китүдән кайтмады. «Ташкыннар»— аларның тормышында соңгы спектакль булса, алда торган зур имтиханның беренчесе иде. Бу имтиханны безнең авыл яшьләре намус белән, егетләрчә тапшырдылар. Бу авыр сугышка, авыр имтиханга аларны Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ы әзерләште.

Безнең күңелләрдә «Ташкыннар» драмасы ил, халык язмышының якты да, аянычлы да, гыйбрәтле дә тарихы буларак сакланып калды.

Теге, Иске Масралар ачкан артель филиалы безнең авылда сугыштан соң да яшәде. Егетләрсез гомер чигәргә дучар ителгән кызлар сөйләделәр: теге елны «Наемщик»та Аскәрикне уйнаган егет сугышта беткән икән. Бикчәнтәй картны уйнаганы аягын өздергән икән. Батырҗанны уйнаган, егет, бичара, анасына бер генә малай булган икән, ул да сугышта беткән. Һәм башкалар...

...Г. Камал театрында «Ташкыннар» спектаклен караганда, мин һәрвакыт Ватан сугышы кырларында һәлак булган якташларым белән очрашкан сыман булам. Бу драма яшьләр яки өлкәннәр өчен, эшче яки колхозчы өчен, татар яки рус өчен генә язылган әсәр түгел. «Ташкыннар»— халык язмышы, хезмәт халкының тарихы турындагы әсәр. Ул безнең буынны тәрбияләп үстергән әсәр. Безнең күңелләрдә «Ташкыннар» драмасы әнә шулай мәңгегә калды.

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре докторы

# СУОМИ ИЛЕНЕҢ ТАТАР КИТАПЛАРЫ

Татар басма сүзенең тарихын өйрәнү мине мәктәп-мәдрәсәләребез дөньясына да алып керде. XVIII—XIX гасырда, бигрәк тә XX йөз башында, кайларда гына булмаган ул мәктәп-мәдрәсәләр: Себердә һәм Урал якларында, Идел буенда һәм Донбасста, Казахстанда һәм Ерак Көнчыгышта... Шулай ук Мәскәү һәм Петербург, Чита һәм Иркутск, Харбин һәм Киев, Одесса һәм Харьков һәм башка шәһәрләрдә... Берәр җирдә ун-унбиш татар гаиләсе яши башласа, алар балаларын укырга-язарга өйрәтү өчен үз хисапларыннан мәктәп ачу эшенә керешкәннәр. Беренче рус революциясеннән соң йөзләп, меңләп татар кешеләре яшәгән зур һәм кечкенә шәһәрләрдә нәшриятлар ачарга, газит-журнал чыгаруга сукмак эзли башлыйлар. Күп кенә төбәкләрдә татар китапханәләре, үзешчән сәнгать түгәрәкләре эшли. 1920—1930 елларда хәтта Кронштадт, Находка кебек җирләрдә дә үзешчән татар драма түгәрәкләренең татарча спектакльләр куюы билгеле!

Безнең халыкта укый-яза белүнең электән киң таралуы, ерак гасырлардан башланган мәдәни, әдәби традицияләр татар басма сүзенең чагыштырмача иртә барлыкка килүенә төп сәбәпче булган.

Билгеле ки, тарих җилләре безгә аерата рәхимсез булган. Ул безнең халыкны илебезнең төрле почмакларына илтеп ташлаган. Алай гына түгел, дөньяның төрле илләренә чәчкән. Соңгы елларда матбугат битләрендә татарларның Польша һәм Румыния, Япония һәм Төркия, Кытай һәм Австралия, Бразилия һәм АКШта шактый күп яшәүләре турында хәбәрләр күренгәләде. Шунысы игътибарга лаек: ерак чит илләр, ят халыклар арасында яшәүгә карамастан, алар анда да югалып калмаганнар, ассимиляцияләнеп бетмәгәннәр. Алар үз телләрен, үз моңнарын онытмаганнар, гореф-гадәтләрен югалтмаганнар.

Хәзер чит илләргә таралган милләттәшләребезнең анда ничек яшәве, теле һәм культурасы белән кызыксыну арта башлады. Чөнки аларның язмышы — ул бит халкыбыз тарихының аерылгысыз бер өлеше.

Без биредә бары бер илдә, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез турында гына сүз алып барырга уйлыйбыз. Киләчәктә башка илләрдә яшәүче татарлар турында да хезмәтләр дөнья күрер дип ышанабыз.

Билгеле булганча, революциягә хәтле Финляндия Россия империясе составына керә. Шуңа күрә моннан гасыр ярым элек Россиянең Финляндиядәге армиясендә хезмәт иткән татар солдатларының бер өлеше шушы якта кала башлаган. Биредә төпләнеп калгач, алар үзләре янына туганнарын, якыннарын чакыруга керешәләр. Биредә җир күп, фин җире урман-суларга, киек-балыкларга, болыннарга бай, табигате йомшак, тормыш итү әллә ни авыр түгел.

Бу якка вак сәүдә белән көн күрүче башка татарлар да килә башлый. Күчеп килүчеләр арасында Петербург һәм Мәскәүдән, Нижний Новгород һәм Сергач якларыннан чыккан татар-мишәрләр төп өлешне тәшкил иткән. Фин халкы татарларны ачык күңел, якты йөз белән каршы алган. Аларның диненә тимәгән, телен, гореф-гадәтләрен кыерсытмаган, кысмаган.

Финляндиягә килеп утырган татарлар хәзер, нигездә, шәһәрдә яши. Аларның төп өлеше — Хельсинки, Тампере, Котка, Ярвинпээ дигән шәһәрләрдә. Финляндиядә барлыгы бер мең чамасы татар яши, дип санала. Алар үзара тыгыз элемтәдә торалар. Халыкның күпчелеге сәүдә белән шөгыльләнә. Соңгы берничә дистә елда татарлардан интеллигенция вәкилләре дә арта башлады. Хәзер Финляндиядә юрист, врач, инженер, экономист, укытучы булып эшләүче татарлар да бар. Татарлардан галимнәр дә күренә башлады.

Финляндия татарлары үзләренең телен, гореф-гадәтен, җыр-моңын, диннәрен саклап калу өчен күп төрле эшләр башкаралар. Аларның төрле-төрле җәмгыятьләре бар. 1925 елны оештырылган «Исламия

җәмгыяте» халыкның дин эшләре белән идарә итә. Хельсинкида «Финляндия төркиләре бердәмлеге» дигән икенче җәмгыять эшләп килә. Бу җәмгыять халык арасында әдәбият-сәнгать мәсьәләләре буенча эш алып бара: милли җыр, музыка кичәләре, спектакльләр һәм концертлар оештыра, татар җырларыннан торган пластинкалар чыгара, китап бастыру белән шөгыльләнә.

1967 елның апрелендә Хельсинкида «Габдулла Тукай җәмгыяте» эшли башлый. Хәзер бу җәмгыятьнең җитәкчесе Гомәр Таһир — Хельсинки университетының төрки телләр укытучысы, филология фәннәре докторы. Бу җәмгыятьнең төп максаты — СССРда яшәүче татарлар белән культура элемтәләрен ныгыту, фәнни элемтәләр урнаштыру, СССР-Финляндия дуслыгына өлеш кертү. Бу җәмгыятьнең чакыруы буенча татар галимнәре, сәнгать осталары берничә мәртәбә Финляндиядә булдылар, андагы татарларга концертлар бирделәр, лекцияләр укыдылар. Үз чиратында Финляндия татарлары берничә мәртәбә Казанда булып китте. Алар татар театрларында булдылар, шәһәрнең фән, культура үзәкләре белән таныштылар, Сабан туйларында катнаштылар.

Финляндиядә татар халык мәгарифе, мәдәнияты белән шөгыльләнүче башка җәмгыятьләр дә бар.

Безнең максатыбыз — Финляндия татарлары арасында матбагачылык эшенең тарихы белән тулырак танышу. Финляндия татарларының тулаем тормышы, аларның әдәби һәм культура элемтәләре белән тирәнрәк танышырга теләүчеләр исә Илбарис Надировның бу темаларга багышланган мәкаләләренә мөрәҗәгать итсеннәр.

Югарыда без татарларның белемгә, яңалыкка, укый-язуга, басма сүзгә хиреслеген күрсәтеп үткән идек. Шундый ук хәлне Финляндиягә килеп чыккан татарлар арасында да яхшы күрәбез. Инде без аларның әдәби-музыкаль кичәләр, спектакль һәм концертлар куеп килүен искәртеп үттек. Финляндия татарларының 3—6 яшьлек балаларга кече яшьтән үк ана телен өйрәтү өчен мәктәп-бакчасы да бар. 1970 елларга хәтле Хельсинкида махсус татар мәктәбе эшләп килде. Финляндия татарлары туган телгә мәхәббәт үстерү, яшь буынга тел өйрәтү буенча хәзер дә зур эш алып баралар.

Менә шушы максатлардан чыгып, биредә яшәүче татарлар туган телдәге басма сүзгә зур игътибар итәләр.

Финляндия татарларының матбагачылык тарихын тулырак күзаллау өчен без биредә басылган китаплар һәм башка төр хезмәтләрне библиографик характерда бирүне кирәк таптык. Бу мәкаләнең киләчәктә Финляндия татарлары мәдәниятын, әдәбиятын өйрәнү өчен чыганак булачагын истә тотып, һәр басма турында библиографик белешмәне тулырак китерү файдалы булыр дип саныйбыз.

Китапларның бер өлешен авторлар үзләре чыгарган. Андый басмаларны без аерым авторлар исеме астында туплыйбыз. Ул авторның аерым китаплары башка кеше яки аерым җәмгыять хисабына басылса да, барысы да шул автор исеме астында китерелә. Авторның үз әсәрләре артыннан аның хисабына яки аның редакциясендә чыккан басмалар китерелә.

**Хәсән Низаметдин улы Хәмидулла.** Финляндия татарлары арасында иң актив автор, шул ук вакытта нәшир һәм редактор да. Төп кәсебе — сәүдә эше. Ул 1895 елда Россиядә Яңапар дигән авылда туган. 1915 елны Финляндиягә килеп урнашкан. Ишетүебез буенча, хәзер вафат инде. Басылган әсәрләре түбәндәгеләр:

1. **Хәерниса.** Пьеса. 4 пәрдәле. Кеми, 1943. 90 б.

2. **Милчәче белән пәри карчыгы.** Шигырьләр мәҗмугасы. Кеми, 1945. Илһам җимешләре. 1—2 кыйсем. 32 б.

3. **Ватансызлык.** Көнлек халык сүзләре: 1946 елда язылган тәнкыйть шигырьләре. Кеми, 1946. Илһам җимешләренең өченче кыйсме. 10 б.

4. **Күңел шәүләсе.** Җитди, милли вә әдәби шигырьләр. Кеми, 1946. Илһам җимешләренең дүртенче кыйсме. 10 б.

5. **Йөрәк ялкыннары.** Җитди, милли вә әдәби шигырьләр. Кеми, 1948. Илһам җимешләренең бишенче кыйсме. 16 б.

6. **Пикау.** Шигъри хикәя. Кеми, 1948. Илһам җимешләренең алтынчы кыйсме. 15 б.

7. **Моңлы таңнар.** Җитди, милли вә әдәби шигырьләр. Хельсинки, 1949. Илһам җимешләренең җиденче кыйсме. 35 б.

8. **Сүнүгә таба.** Җитди, милли вә әдәби шигырьләр. Хельсинки, 1951. Илһам җимешләренең сигезенче кыйсме. 20 б.

9. **Кулыйк дәртләре.** Җитди, милли вә әдәби шигырьләр. Хельсинки, 1956. Илһам җимешләренең тугызынчы кыйсме. 16 б.

10. **Илһам җимешләре.** 1—10 кыйсем: 1925—1945 елларда язылган шигырьләр җыентыгы. Хельсинки, 1969—1970. 308 б.

11. **Йолдызларга сәяхәт.** Хикәят. 1 кыйсем. Кеми, 1947, 77 б.

12. Шул ук. 2 нче басма. Хельсинки, 1974. 77 б.

13. **Тәкъдир каршында.** Беренче дөнья сугышы вакыйгаларыннан. Хельсинки, 1950. 69 б.

14. Шул ук. 2 нче басма. Хельсинки, 1973. 57 б.

15. **Борынгы картлар сүзе.** Хельсинки, 1951. 31 б.

16. Шул ук. 2 нче басма. Хельсинки, 1977. 37 б.

17. **Мөһаҗир бәете.** Роман. Хельсинки, 1953. 64 б.

18. **Яңапар тарихы.** (Авторның туган авылы тарихы). Хельсинки. 1954. 71, IV б. илл. белән.

19. **Өзелгән өмет.** 5 пәрдәле драма. Хельсинки. 1960. 90 б.

20. Шул ук. 2 нче басма. Хельсинки, 1973. 74 б.

21. **Ник алай?** Язучының үз тәрҗемәи хәленнән. Финляндия татарларының тарих материаллары. Хельсинки, 1962—1974. 7 кисәк. 250 б. илл. белән.

22. **Хаҗ хатирәләре.** 2 кыйсем. Хельсинки. 1978—1971.
1 кыйсем. 1968. 100 б.
2 кыйсем. 1971. 97 б.

23. **Тормыш моңнары.** Шигырь. Илһам җимешләре шигырьләре җыентыгының дәвамы. Хельсинки, 1971. 32 б.

24. **Карак.** Пьеса 3 пәрдәле. Хельсинки, 1974. 14 + 12 б.

25. **Вөҗигият эчендә.** Шигырьләр. Илһам җимешләре шигырьләр җыентыгының дәвамы. Хельсинки. 1973. 40 б.

26. **Татар халык җырлары һәм моңнары.** 1. Хельсинки, 1975. 67 + 17 б.

27. **Алдым-бирдем.** Авыл туе. 3 пәрдәле. Хельсинки, 1976. 24 б.

*Болардан тыш авторның басылмый калган ике әсәре бар:*

28. **Бәхетсезләр.** Драма, 5 пәрдәле. Хельсинки, 1973.

29. **Мохтар бабай.** 3 пәрдәле көлке. Хельсинки, 1973.

1974—1975 елларда авторның Хельсинкида «Хәсән Хәмидулла әсәрләре» дигән алты томнан торган җыентыгы басыла.

Югарыда күрсәтелгән әдәби, фольклор, тарихи әсәрләрдән тыш Хәсән Хәмидулла үзе төзеп түбәндәге китапларны бастырып чыгара: 1. татарча-финчә **«Исем көннәре календаре»** (Кеми, 1948. 52 б.). 2. **«Финляндия мөселманнарының телефон каталогы»** (Хельсинки, 1971—1977. 4 мәртәбә). 3. **«Хәбәрче»** (Стокгольм, 1952) — татар кибетләре турында белешмә китабы.

1909 елда Казанда Солтан Рахманколый тәрҗемәсендә атаклы рус мәгърифәтчесе һәм китап белгече Н. Рубакинның фәннипопуляр хезмәте «Телләр тарихы» басылган була. Шушы әсәрне Хәсән Хәмидулла үз хисабына 1960 елда Хельсинкида яңадан бастырып чыгара.

Күрсәтелгән әсәрләр һәм китаплардан тыш Хәсән Хәмидулла 1925 елда **«Мәгърифәт»** исемле газета, ә 1945—1977 елларда **«Шимал очкыннары»** дигән еллык календарь җыентыклар бастыра. Бу газета һәм җыентыкларның ул — редакторы да, төзүчесе дә, авторы да.

Дөньяви әсәрләр белән бергәттән, Хәсән Хәмидулла — дини, дини-дидактик әсәрләр авторы, Коръән һәм аерым догалыкларның нәшире. Бу тармакта Хәсән Хәмидулла чыгарган түбәндәге басмалар билгеле: икешәр тапкыр «Коръән», «Яңа иман шарты һәм белешмәләр», «Исме Әгъзам», «Вак сүрәләр һәм догалар», биш тапкыр «Вәгазьләр һәм хөтбәләр» басыла. Шулай ук «Тәбарәк», «Намаз», «Җомга хөтбәләре», «Ясин шәриф», «Тәүбә догасы», «Латинча дөрес укыр өчен намаз сүрәләре», «Рамазан ае хөрмәтенә» дигән басмалар да бар. Дини характердагы әсәрләрне басу һәм редакцияләүдә Хәсән Хәмидулланың хатыны Гөлсем ханым да ярдәм итә.

Хәсән Хәмидулланың библиографиясе белән танышкач, без аның төрле-төрле өлкәләрдә актив эшләп килгән әдип булуын күрәбез. Аның исеме Финляндия язучылар исемлегенә кертелүе әдипнең Суоми илендә танылган каләм остасы булуын күрсәтә. Шуның өстенә ул — фольклорчы һәм тарихи хезмәтләр авторы да.

**Садри Хәмит** — Хәсән Хәмидулланың авылдашы. 1905 елда туган, һөнәре буенча ул да сәүдәгәр. Шигырьләр, поэмалар, хикәяләр авторы. Телгә һәм тарихи темаларга караган хезмәтләр дә язган. Күләме белән чирек яки ярты табактан торган әсәрләрен, нигездә, үз хисабына бастырып, бушлай тараткан. Басылган әсәрләре:

1. **Дәфтәр.** Шигырьләр. Оулу, 1946. 5 дәфтәрчектән тора. Барлыгы 35 бит. 1975 елга хәтле әсәрләре Оулу дигән шәһәрчектә, ә 1976 елдан башлап Хельсинки шәһәрендә басыла.
2. **Татар теле.** Поэма. 1946. 8 б.
3. **Закир.** Шигъри хикәя. 1946. 11 б.
4. **Без.** Поэма. 1947. 8 б.
5. **Хәким.** Шигъри хикәя. 1947. 123 б., илл. белән.
6. **Үткән елдагы хәбәрләр.** Юмористик шигырьләр. 1947. 7 б.
7. **Яз хәбәрләре.** Шигырьләр. 1948. 12 б.
8. **Мәче һәм тычканнар.** Шигъри хикәя. 1948. 28 б. илл. белән.
9. **Ярлылык.** Поэма. 1950. 8 б.
10. **Фәкыйрьлек.** Хикәя. 1950. 8 б.
11. **Үткән елның хәбәрләре.** Юмористик шигырьләр. 1950. 32 б.
12. **Дәҗҗаллар.** Шигырьләр. 1951. 8 б.
13. **1950 нче ел хәбәрләре.** 1951. 20 б.
14. **Ялгызлык.** 1951. 5 б.
15. **Яз башы хәбәрләре.** 1951. 5 б.
16. **Исерек ир белән тычкан.** 1951. 7 б.
17. **Олимпия (уеннары).** 1952. 7 б.
18. **Ахырзаман галәмәтләре.** 1953. 5 б.
19. **Кыш хәбәрләре.** 1953. 5 б.
20. **Сатучы-язучы.** 1954. 6 б.
21. **Язучы 50 яшендә.** 1954. 8 б.
22. **Кайсы як уйный.** 1954. 7 б.
23. **Утыз ел Финляндиядә.** 1954. 12 б.

24. **Калдык.** 1954. 7 б.
25. **Актык.** 1956. 6. б.
26. **Кыска шигырьләр.** 1956. 7 б.
27. **Шигырьләр дәфтәре.** 1957. 5 б.
28. **Авыл тормышы.** 1966. 6 б.
29. **Дуслык кичәсе.** 1974. 3 б.
30. **Хельсинки шәһәре.** 1976. 6 б.
31. **Мәхәлләнең өч еллык җыелышы.** 1976. 4 б.
32. **Төрле хәбәрләр.** 1976. 6 б.
33. **Җомга намазын укучылар.** 1976. 3 б.
34. **1920 еллардагы кыш көннәре авылларда.** 1976. 3 б.
35. **Ир белән хатын.** 1977. 4 б.
36. **Хайваннар дөньясы.** 1977—1979. 1—6 кисәкләр.

*Сүзлекләр:*

37. **Кушымлы сүзләр.** Идиомалар. Оулу. 1968. 5 б.
38. **Туган илдәге сүзләр.** Якынча 1700 сүз. Оулу. 1973. 7 б.

Садри Хәмит 1967 елда **«Тавыш»** исеме белән Оулу шәһәрендә 6 саннан торган газета чыгара, ә 1967—1977 елларда Оулу һәм Хельсинки шәһәрләрендә **«Ак юл»** исемле газета чыгара. Шушы еллар эчендә бу газета 63 сан булып чыкты.

**Габәйдулла (Гибадулла) Мортазин.** 1895 елда Төркстанда туган, 1968 елда Хельсинкида вафат. Укытучы. Хельсинкидагы үзешчән театр җитәкчесе.

Басылган китабы: **Тел сабаклары** — 1 кисәк. Хельсинки, 1950. 29 б. Төрки халык мәктәбе һимая куруму басмасы.

**Хөсәен Садыйк** — 1906 елда Россиядә туа, 1973 елда Хельсинкида вафат. Кәсебе буенча сәүдәгәр.

Басылган китабы: **Милли әдәбият парчалары.** Ярвенпәә, 1953. 5 б.

Хөсәен Садыйк редакциясендә Госман Али хисабына 1969 елда Хельсинкида **«Габдулла Тукай шигырьләре»** басыла. (102 б.)

**Заһир Таһир.** 1900 елда Ташкентта туа, 1961 елда Хельсинкида вафат. Кәсебе буенча сәүдәгәр.

Басылган китабы: **Финляндия төркиләре.** Хельсинки, 1955. 16 б., 10 б. илл. белән. 1956 елда шушы әсәрнең тулыландырылган икенче басмасы чыга. Күләме 29 бит. 24 илл. белән. Шушы ук әсәре 1959 һәм 1960 елларда ике тапкыр инглиз телендә дә басыла.

**Гайса Хәкимҗан.** 1896 елда Актукта туа, 1972 елда Тампереда вафат. Кәсебе буенча сәүдәгәр.

Басылган китабы: **Милли шигырь һәм җырлар.** Финляндия төрек-татар халкы арасында кулланыла торган. 3 кисәктән. Тампере, 1956—1966. 1 кисәк 32 б. 2 кисәк 38 б. 3 кисәк 34 бит.

Г. Хәкимҗан шушы елны Тампереда үз хисабына Шакир Мостафаның революциягә хәтле Казанда чыккан **«Ислам дине хак диндер»** дигән китабын бастырып чыгара (20 бит).

**Хәбибрахман Шакир.** 1903 елда Казанда туа. 1975 елда Тампереда вафат. Тампереда имам булып эшли.

**«Финляндия ислам мәхәлләсе»** исеме астында 1949 елда Тампереда алты саннан торган информацион бюллетень бастыра. Редакторы Фатыйх Арат. 1950—1951 елларда шушы бюллетеньне **«Ислам мәхәлләсе»** исеме астында Тампереда бастыра. Редакторы В. Сали. Бу бюллетень 1950 елда 7, 1951 елда 4 сан басылып чыга.

Х. Шакир редакциясендә түбәндәге китаплар басылуы билгеле:

1. **Мостафа Шиһаби әл-Асни.** Зөбәдәт әл-әхлак. Балаларга укытмак өчен гаять файдалы гыйльми әхлакдан бер рисаләдер. Тампере, 1957. 26 б.

Революциягә хәтле Казанда басылган китапның басмасы.

2. **Якуб Хәлили.** Гыйлем хәл. Тампере, 1958. 42 б.

Бу китап та Казанда (1910) басылган була. Тампереда ул Имад Җамалетдин хисабына чыгарылган.

3. **Дин дәресләре һәм ислам тарихчысы.** Тампере, 1912. 25 + 29 бит. Китапны редакцияләүдә Сәмигулла Вафин да катнаша.

4. **Габдулла Тукай.** Татар шагыйре Габдулла Тукай. Шигырьләр. Тампере, 1961. 1 кисәк. 24 б. Китапны редакцияләүдә Гайсә Хәкимҗан да катнаша.

**Сания Гыйффәт (Кадыйри)** — 1899 елда Чистайда туа. 1957 елда Әнкарада вафат. Шагыйрә, үзешчән театр эшлеклесе. Закир Кадыйри хатыны.

Басылган китабы: **Тормыш көзгесе.** Драма 4 пәрдәле. Хельсинки, 1927. 64 б. Финляндия төрекләре берлеге җәмгыяте нәшер иткән.

**Закир Кадыйри** 1877 елда Самарада туа. 1955 елда Әнкарада вафат. Хельсинкида татар башлангыч мәктәбе укытучысы.

Басылган китаплары:

1. **Төрек (төрки) тарихи сабаклары.** 1. Элек мәктәпләренең дүртенче сыйныфы һәм курсларының дүртенче бүлеме өчен дәреслектер. Хельсинки. Финляндия төрки нәшрият ширкәтенең басмасы. 1938. 34 б.

2. **Дин сабаклары.** 1. Инану (Иман). 2. Арулык (Тәһарәт). Элек мәктәпләренең өченче сыйныфлары өчен. Хельсинки. Финляндия төрки нәшрият ширкәте басмасы, 1938. 34 б.

3. **Дин сабаклары.** Намаз. Дүртенче сыйныфлар өчен дәреслек. Хельсинки. Фин-

ляндия төрки нәшрият җәмгыяте басмасы. 1938. 54 б.

**Фәридә Бикчури.** 1944 елда Харбинда туа. Укытучы.

Басылган китабы:

**Кемнәргә Казан төркиләре дип әйтелә.** Хельсинки. 1969. 7 б.

Ф. Бикчури редакциясе һәм тәрҗемәсендә «Финляндия җәмгыяте исламия» хисабына түбәндәге мәктәп китаплары басыла.

1. **Уку китабы.** 1. Төрекчәдән тәрҗемә. Беренче вә икенче сыйныфлар өчен. Хельсинки. 1969. 40 б.

2. **Уку китабы.** 2. Төрекчәдән тәрҗемә, икенче вә өченче сыйныфлар өчен. Хельсинки. 1969. 71 б.

3. **Уку китабы.** 3. Төрекчәдән тәрҗемә. Хельсинки, 1970. 45 б.

**Гәүһәр Туганай.** 1911 елда Самарада туа. Сәүдә эше белән шөгыльләнә. Шагыйрә. Берничә шигыре 1969 елда Казанда «Азат хатын» журналында басылды.

Басылган китаплары:

**Гәүһәр Туганайның шигырь мәҗмугасы.** 2 кисәк. Тампере, 1976. 1 кисәк, 92 б. 2 кисәк, 104 б.

**Наилә Бинарк.** 1940 елда Кореяда туа. Укытучы.

Басылган китаплары:

1. **Ана теле һәм уку китабы.** 3 кисәк. Хельсинки, 1972—1974. 1 кисәк. 1972. 74 б. 2 кисәк. 1973. 89 б. 3 кисәк, 1974. 42 б.

2. **Бераз уйла, бераз көл.** Уеннар, юмористик хикәяләр. Хельсинки, 1973. 35+5 б.

3. **Аталар сүзе.** 1500 мәкаль һәм әйтем. Хельсинки, 1976. 112 б. Сәүдәгәр Осман Али хисабына басылган.

**Фәйзи Әхсән Бүре.** 1917 елда Финляндиядә туа. 1974 елда Истамбулда вафат. Һөнәре буенча сәүдәгәр.

Басылган китабы:

**Төркичә-финчә, финчә-төркичә чеп (кесә) сүзлеге.** Истамбул, 1972, 97—114.— 6 б.

**Зиннәтулла Имаметдин Әхсән Бүре.** 1886 елда Акәтук дигән авылда туа. 1945 елда Тампереда вафат. Кәсебе буенча сәүдәгәр. Ислам һәм Финляндия татарлары турында берничә хезмәт авторы. Әсәрләре инглиз телендә Лондонда басылган.

Басылган китабы:

**Төрки теле өчен профессор Садри Максуди вә төркиләр берлекләре хакында уртак фикерләр.** Тампере, 1945. 19 б.

З. И. Әхсән Бүре хисабына басылган китап:

Гали бай — тәрҗемәи хәле, мәктүпләре вә аның хакында хатирәләр. Гарәп хәрефләреннән латин хәрефләренә күчерүче З. И. Әхсән Бүре. Тампере, 1945. 90 б. Революциягә хәтле Оренбургта чыккан басма буенча әзерләнгән.

*Финляндия җәмгыяте Исламия* дә төрле басмалар чыгару белән шөгыльләнә. Бу оешма каршында китап басу эшләре белән шөгыльләнүче аерым нәшрият — «Финляндиядә төрки нәшрият җәмгыяте» дә эшләп килә. Исламия җәмгыятенең бер өлеш хезмәтләре шушы нәшрият (ФТИҖ) исеме астында дөнья күрә.

Исламия җәмгыяте бастырган китаплар:

1. **Әлифба.** Финляндия җәмгыяте Исламия янында дәреслекләр хәзерләү һәйәте. Хельсинки, 1935. 51 б.

Икенче басма. Хельсинки, 1970. 51 б.

2. **Уку китабы.** Финляндия җәмгыяте Исламиясе янында дәреслекләр хәзерләү һәйәте. Хельсинки, 1935. 52 б.

3. **Уку китабы.** (Сания Гыйффәт ред.). Хельсинки, 1938. 60 б.

4. **Мәхәллә хәбәрләре** (Заһир Таһир, Хөсәен Сөҗәйк ред.). Хельсинки, 1949. № 1.

5. **Остазшәһәр Муса Ярулла хәзрәтләре хакында мөләхазәләр.** Хельсинки. 1950. 33 б. М. Я. Биги рәсеме белән.

6. **Мәхәлләнең өч еллык туплануы.** Хельсинки, 1975, 1 дәфтәр.

7. **Финляндия җәмгыяте Исламия башкармасының 1932 елгы бәянаты.** Хельсинки, 1933. 6 б.

8. **Финляндия җәмгыяте Исламия мөтәвәллиләр һәйәтенең 1933 елгы бәянаты.** Хельсинки, 1934. 8 б.

9. **Финляндия җәмгыяте Исламия мөтәвәллиләр һәйәтенең 1934 елгы изаһәте.** Хельсинки, 1935. 6 б.

10. **Финляндия җәмгыяте Исламия мөтәвәллиләр һәйәтенең 1938 елгы рапорты.** Хельсинки, 1939. 12 б.

11. **Финляндия җәмгыяте Исламия мөтәвәллиләр һәйәтенең 1940 нчы ел рапорты.** Хельсинки, 1941. 10 б.

**Төрки халык мәктәбе һимая җәмгыяте** (куруми). Бу җәмгыять 1948 елдан алып 1969 елга хәтле Хельсинкида эшли. Төрки башлангыч мәктәп эшләре белән җитәкчелек итә.

Бу җәмгыять чыгарган басмалар:

1. **Фин-төрки халык мәктәбен һимая җәмгыяте даһили низамкамәсе.** Тампере. 1933. 8 + 8 б. Татар һәм фин телендә.

2. **Фин-төрки мәктәп һимая җәмгыятенең 1943 сәнәсенең хисабыдыр.** Тампере, 1944. 22 б.

3. **Тарихи әнбия.** (Мөхәммәдрәхим Хәнәфи ред.). Хельсинки, 1951. 22 б. Җумабикә Җамалетдин хисабына басыла.

4. **Шәһәр Шәрәф.** Гашыйри сәгадәт. Пәйгамбәремезнең әүвәле вә исламның зохуры хакында. Хельсинки, 1951. 64 б. Революциягә хәтле Казанда басылган.

5. **Әхмәдһади Максуди.** Руза, зәкят вә хакк. Ибтидаи Исламия мәҗмугасының би-

шенче күзе. Хельсинки, 1952. 45 б. Революциягә хәтле Казанда басылган.

6. **Габдулла Тукаев.** Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Хельсинки, 1953. 187 б., илл. белән. Исмагил Арифулла хисабына басыла. Революциягә хәтле Казанда басылган.

7. **Төрки халык мәктәбе һимая куруминың 1957 нче елгы фәгалисте.** (Хөсәен Садыйк ред.). Хельсинки, 1958. 11 б. Гимад Җамалетдин хисабына басыла.

*Финляндия төркиләре берлеге җәмгыяте* 1935 елда оештырыла. Финляндия татарлары арасында әдәбият-сәнгать кичәләре, спектакльләр кую, нәшрият эшләре белән шөгыльләнә. Һәр елны диярлек Хельсинкида, башкаланың зур театрлары бинасында спектакльләр куя, милли кичәләр үткәрә, аларның программаларын бастыра. Бу җәмгыять тарафыннан М. Фәйзинең «Асылъяр», Г. Камалның «Хуҗа һәм Приказчик», «Кызыма кияү эзлим», «Беренче театр», Г. Исхакиның «Җан буявыч», Мольерның «Саран» һәм башка әсәрләр куела. Бу җәмгыять Финляндиянең татарлар яши торган башка шәһәрләрендә дә әдәби-музыкаль кичәләр оештыра. Күп кенә кичәләрнең, спектакльләрнең программаларын бастырып чыгарып килә.

Бу җәмгыять татар моңнарын пропагандалау йөзеннән җыр, нота китаплары да бастырып тора. Бу оешма чыгарган җыр җыентыклары:

1. **Халык көйләре.** Пианино вә кеман өчен. Юко Толонең аранжировкасы. Хельсинки, 1952. 16 б.
2. **Җырлар.** Хельсинки, елы билгеле түгел. 21 б. 67 җыр тексты.
3. **Җырлар.** Хельсинки, 1967. 17 б. 57 җыр.
4. **Җыр дәфтәре.** Хельсинки, 1974. 50 б. 77 җыр.
5. Шул ук. 2 басма. Хельсинки, 1976. 50 б. 77 җыр.
6. **Җыр кичәсе.** (Фәридә Низаметдин ред.). Ярвенпәә, 1977. 16 б. 16 җыр.
7. **ФГБ кичәсе программы.** З. V 75. Ярвенпәә, 1975. 15 б. Җыр текстлары белән.

Болардан тыш, татар теленә кергән гарәп һәм фарсы телләре «сүзлеге»н дә чыгара. (Хельсинки, 1969. 28 б.)

Финляндия төркиләре берлеге җәмгыятенең **Тампере төркиләре берлеге** бүлеге 1935 елда оеша. Спектакльләр, җыр-музыка кичәләре оештыру белән бергә, бу бүлек тә җыр текстлары бастыру белән шөгыльләнә. Аның безгә өч басмасы билгеле:

1. **Җырлар.** Тампере, елы билгесез. 11 б. 45 җыр.
2. **Җырлар.** Тампере, 1959. 11 б. 51 җыр.
3. **Җырлар.** Тампере, 1969. 5 б. 12 җыр.

*Башка басмалар:*

1. **Чабата.** Юмористик шигырьләр. Нәширләре — Ахир Бәшар, Окан Даһер, Зәкия Хәмид, Фазилә Насретдин, Шамил Насретдин. Ярвенпәә-Хельсинки, 1977. 8 б.
2. **Гүзәл килен Фәүзиянең туй җырлары.** (Фәридә Низаметдин ред.). Хельсинки, 1978. 20 б.

Бу библиографик күзәтүгә Финляндиядә 1978 елга хәтле чыккан басмалар кертелде. Безгә билгеле булганча, анда татар телендә китап басу әле дә дәвам итә. Моннан бернечә ел элек Хельсинкида зур күләмле «Безнең җырлар» дигән җыентык басылып чыкты. 1987 елда Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһирның юбилеена багышланган «Татарика» дигән фолиант дөнья күрде. Бу җыентыкка Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан дистәгә якын галимнең хезмәтләре кергән, аларның күпчелеге татар телендә басылган (бу китап турында журналда И. Надировның махсус мәкаләсе дә булды.)

1978 елдан соң Финляндиядә чыккан татар басмалары әле махсус ачыкланмаган, шуңа күрә бу күзәтүдә аларга тукталмыйбыз*.

Күзәтүгә Финляндия татарларының фин, инглиз һәм башка телләрдә дөнья күргән хезмәтләре кермәде. Аларның 1978 елга хәтле татар телендә чыккан барлык басмалары тулысынча ачыкланып бетте дип әйтүе кыен.

Финляндиядә чыккан бу китапларның, брошюраларның бер өлеше машинкада күбәйтелгән, бер өлеше мимеографта басылган. Басмаларның калган өлеше типографик ысул белән чыгарылган. Татарча китап басу башта гарәп хәрефләре нигезендә алып барыла. 70 еллар башында Финляндиядә татар китапларын латин графикасында басу эше җайга салына.

Финляндиядә татарлар китап басу эшенә беренче булып егерменче еллар уртасында керешәләр. Аңа хәтле алар биредә, инде йөз елга якын яшәсәләр дә, китап басу белән шөгыльләнмәгәннәр. Моның сәбәбе аңлашыла. Финляндия Россия составында вакытта татарлар үзләренә кирәк булган татар басмаларын Казан, Оренбург, Әстерхан, Петербургтан алып торганнар. Октябрь революциясеннән соң, Финляндия мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыккач, татар китапларын алу кыенлаша. Менә шуның аркасында Финляндия татарлары үзләре матбагачылык эшенә керешергә мәҗбүр булалар.

---

* 1978 елга хәтле чыккан татар басмалары турындагы мәгълүматлар фин китап белгече һәм библиографы Гарри Гален мәкаләсеннән алынды. Бу басмаларны барлау һәм туплауда безгә Әнкарада яшәүче Мәхмүт әфәнде Таһир да ярдәм итте. Аларга үзебезнең рәхмәтләребезне белдерәбез. *(Автор).*

Финляндиядә татар китабын басуның төп ихтыяҗы — мәктәпләрне уку китаплары белән тәэмин итү. Бирeдә чыккан беренче басмаларның әлифба һ. б. мәктәп китаплары булуы шул турыда сөйли.

Электән үк татар китабының бай традицияләрендә тәрбияләнгән һәм революциядән соң фин җирендә калган татарлар арасында басма сүзгә мохтаҗлык зур булган. Тора-бара Финляндия татарлары арасыннан әдәби, фәнни әсәрләр язу буенча каләм тибрәтеп карауч ылар да үсеп чыккан. Шигырьләр, поэмалар, хикәя һәм драмалар, повестьлар язылган, тел һәм тарих буенча хезмәтләр иҗат ителгән, фольклор әсәрләрен җыеп бастырып чыгару башланган.

Финляндия татарлары, үзләре язган әсәрләр белән беррәттән, революциягә хәтле Казан, Оренбург, Уфа татар нәширлары чыгарган басмаларны кабат басып чыгаруга да игътибар бирәләр. Хельсинки, Тампере, Оулуда дистәләп татар халык җырлары, мәкаль-әйтемнәр җыентыклары басылуын без югарыда күреп уттек.

Финляндия татарлары матбугат, мәктәп, сәхнә аша үзләренең милли культураларын, телен, гореф-гадәтләрен саклау өчен көрәшәләр. Шул ук вакытта милли культурабызны үстерүгә өлеш тә кертәләр. Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең әдәбият һәм сәнгать, мәктәп һәм матбагачылык, тел һәм тарих өлкәсендәге эшчәнлеге, уңышлары турында без аларның китап репертуарыннан чыгып кузаллый алабыз. Киләчәктә аларның рухи мирасы тарихы, эшчәнлеге махсус өйрәнелер, дип ышанасы килә.

Фин татарларының иҗатын өйрәнү дөньяга сибелгән халкыбыз тарихын ачыклау өчен дә кирәк. Инде татар халкының тарихын, мәдәниятын Татарстанда яшәгән татарлар тормышы белән генә чикләү заманнары узып бара. Халкыбызның аерым группалары кайсы якларда, кайсы илләрдә яшәүләренә карамастан, алар тудырган рухи, мәдәни байлык казанышлары — бөтен татар халкының уртак мирасы.

Моңа хәтле укучылар Финляндиядә татарлар яшәвен матбугат аша ишетеп белә иделәр. Алар чыгарган басмалар белән танышкач, без аларның рухи тормышларын тулырак күз алдына китерә алабыз. Чыннан да, китап — халык тормышының көзгесе икәненә ышанасың.

Илебезнең төньяк-көнбатышында чиктәш булган, урман, күлләр иле буларак билгеле Суоми илендә нибары меңгә якын татар кешесе, инде гасыр ярым үз халкыннан аерылып яшәүгә карамастан, телен, гореф-гадәтләрен, милли аңын саклап калган. Әнә шундый ерак җирдә әдәби әсәрләр тудыра, тарихи хезмәтләр яза, туган телендә җырлый, сөйләшә, үз моңнарын дәвам итә, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрә...

Без туган илебездә телебез юкка чыга, әдәбиятыбыз бетә, милләтебез ассимиляцияләнә дип күп сөйлибез. Менә шундый хәвефле хәлләр заманында Финляндиядәге татарларның тарихтан төшеп калмыйча, ассимиляциягә бирешмичә милли аңын, культурасын саклап яшәве — безнең өчен үрнәк булып тора. Шәхес культы, террор еллары, торгынлык чорында милли культурабыз югалтуларын бөтен тирәнлеге белән аңлаган бу көннәрдә безгә милли культура экологиясе өчен нык лап торып көрәшергә юллар ачыла башлады. Пессимизмга бирелүдән котылу өчен Финляндия татарлары эшчәнлегеннән үрнәк алу зыян итмәс.

Мең елдан артык гомерле әдәбияты, рухи мирасы, тарихы булган халкыбызның потенциаль көче зур әле. Телен, тарихын, рухи мирасын кадерли белгән, онытмаган халыкның киләчәге өметле. Нинди генә ачы җилләр иссә дә, манкортлык, милли нигилизм алга сөрелсә дә, без әле телебез, рухи мирасыбызның кадерен югалтып, онытып бетермәдек. Шәт, югалтмабыз, онытмабыз, диясе килә.

Финляндия татарларының матбагачылык тарихы белән танышкач, күңелдә әнә шундый фикерләр туа.

**Фоат Вәлиев,**

тарих фәннәре докторы.

# СЕБЕРДӘ БЕЛЕМ УЧАКЛАРЫ

Бүген илебездә барган үзгәртеп кору СССР халыкларында үзләренең тарихын, тел һәм мәдәният үсешен өйрәнүгә зур кызыксыну уятты, һәр милләт вәкилләрендә үзаң югары дәрәҗәгә күтәрелде. Бу хәл Татарстаннан читтә — СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче татарларга да хас.

Мәкаләдә сүз революциягә кадәрге чорда Себердә ачылып эшләп килгән, себер татарлары мәдәнияте тарихының мөһим бер өлешен тәшкил иткән мәдрәсәләр тарихы турында барачак. Минем бу теманы сайлавым очраклы хәл түгел. Шәхес культы һәм торгынлык елларында СССР халыкларының, шул исәптән татар халкының да тарихына, мәдәниятенә кагылган күп кенә мәсьәләләр бары тик ак яки кара төсләргә буяп күрсәтелә килде. Мәсәлән, Россиянең төрле төбәкләрендә булган мәдрәсәләр, шул исәптән себер мәдрәсәләре дә бары тик дин учаклары дип кенә саналды. Мәдрәсәләрнең халыкка белем бирүе, аның мәдәниятен үстерү өлкәсендәге эшләре инкяр ителеп килде. Шунлыктан мәдрәсәләр тарихын өйрәнү мәгънәсе булмаган, файдасыз бер эш дип исәпләнде. Хәлбуки, мәкаләдә каралган чорда Казан, Оренбург, Троицк, Уфа, Буби, Манчыл (Төмән), Томск, Тара, Тубыл һ. б. татар мәдрәсәләре, дин укыту белән беррәттән, татарлар өчен белем учаклары булып, халыкны агартуда зур әһәмияткә ия иделәр. Үз вакытында мәдрәсәләр хәзерге югары уку йортлары вазифасын үтәгәннәр. Күп кенә атаклы шәхесләребез — өлкән буын язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, укытучылар мәдрәсә калыбыннан үсеп чыктылар. Димәк, татар мәдрәсәләре тарихын өйрәнү, аларның революциягә кадәрге чорда халкыбызның рухи халәтен үстерү, баетү өлкәсендә эшләгән эшләрен фәнни нигездә тикшерү, аларга дөрес бәя бирү хәзерге үзгәртеп кору чорында җәмгыятьне өйрәнү фәне эшлекләренең мөһим бурычларыннан берсе.

Себердә мәдрәсәләр тарихы анда ислам диненең таралу тарихына бәйле. Себер татарлары арасында ислам дине, Идел буе татарларына караганда, берничә гасырга соңрак тарала башлый. Тубыл-Иртеш татарлары (хәзерге административ бүленеш буенча Төмән һәм Омск өлкәләрендә яшәүче татарларның ата-бабалары) арасында ислам якынча XIV гасыр азагында Бохара ханлыгыннан килгән шәехләр тарафыннан таратыла. Ә Бараба татарлары исә исламны бары XVIII гасырда гына кабул иткәннәр. Кайбер үзәк һәм җирле (Себер) архивларда сакланган материалларга караганда, XVIII-XIX гасырларда мәчете булган һәрбер Себер татар авылында ир балалар өчен башлангыч мәктәп тә булган. Мөгаллим вазифасын урындагы имам (мулла) үтәгән.

Себердә беренче мәдрәсә буларак, XVII гасырның 60 елларында Тубыл шәһәрендә ачылган мәдрәсәне санарга мөмкин. Голландияле галим Витзенның[1] мәгълүматына караганда, шул чорда Тубыл шәһәрендә «гарәп мәктәбе» булып, анда укучыларга «Коръән гарәп телендә» укытылган, ә укытучылык вазифасын Бохара хаҗиларыннан берәү алып барган. Рус совет тарихчысы С. В. Бахрушин бу мәдрәсәнең Тубыл шәһәре татарлары өчен мәгърифәт учагы булуы турында яза.[2]

XIX гасыр урталарында, бигрәк тә аның азагында һәм XX гасыр башында, Себердә капитализм үсүе чорында, анда мәдрәсәләр саны шактый үсә. Бу мәдрәсәләрне, Казан, Уфа, Оренбургтагы кебек, халык — Себердәге татар һәм XV—XVII гасырларда Урта Азиядән шушында күчеп урнашкан бохаралы байлар тоткан. Мәсәлән, Төмән шәһәреннән ерак булмаган Манчыл авылында 1841 елда ачылган мәдрәсә 1871 елга кадәр Габделниязов дигән сәүдәгәр хисабына, ә инде 1871 елдан алып 1917 елга чаклы абыйлы-энеле сәүдәгәрләр Нигъмәтулла, Рәхмәтулла һәм Хәбибулла Сәйдуковларның матди ярдәмендә яши. Мәдрәсәне матди яктан тәэмин итүдә, шәкертләрне укыту, тәрбияләү өлкәсендә Нигъмәтулла Сәйдуков (1829-1901) аеруча зур роль уйнаган. Ул халыкка аң-белем бирү мәсьәләсенә алдынгы карашы белән башка себер татар байларыннан аерылып торган. Башлангыч белемне Н. Сәйдуков Манчыл мәктәбендә ала. Даими рәвештә сәүдә белән

---

[1] Витзен Николай-Корнелий (1641—1717)— голландияле галим, Амстердам бургомистры. Ул 1664 ел башында И. Борель торган Голландия илчелеге составында Мәскәүгә килә. Россиядә өч ел сәяхәт итә: Каспий диңгезе буйларында һәм Себер якларында була. Мәскәүдә рус теле өйрәнә. 1692 елда Витзен, Россиядә туплаган мәгълүматлар нигезендә, Амстердамда «Төньяк һәм Көнчыгыш Татария» исемле хезмәтен бастырып чыгара.

[2] Бахрушин С. В. Научные труды. Т. IV.— М., 1955, 2126.

шегыльләнүе сәбәпле, аңа урта һәм югары уку йортларында укырга туры килми, ләкин үсеп буйга җиткәч, ул гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнә, рус телен өйрәнүгә зур игътибар бирә, даими рәвештә русча һәм татарча газета-журналлар укып бара. Кырымда Исмәгыйль Гаспринский тарафыннан чыгарылган «Тәрҗеман» газетасының даими укучысы була. Үзлегеннән белемен күтәреп, заманы өчен югары культуралы кеше дәрәҗәсенә күтәрелә.

Сәйдуковлар мәдрәсәсенә элекке Тубыл губернасының татарлар яшәгән өязләреннән башлангыч мәктәпне яхшы күрсәткечләр белән тәмамлаган ир балалар кабул ителгән. Мәдрәсәдә 80 еллар азагында шәкертләр саны 260 кешегә җиткән[3], ә инде 1910 еллар башында, Р. Фәхретдинев язуынча, монда 300 гә якын шәкерт даими укыган. («Шура». 1913.— 17 сан, 516 б.). Шәкертләр мәдрәсәдә рәсми җиде ел укырга тиеш булалар, ләкин кайбер шәкертләр, уку программасыннан тыш, өстәмә рәвештә үз теләкләре белән фарсы һәм рус телләрен тирәнрәк өйрәнү өчен мәдрәсәдә ун елга кадәр укыган. Мәдрәсә һәрберсе киң генә өчәр бүлмәдән торган өч бинада урнашкан, читтән килгән шәкертләр өчен алар торак вазифасын да үтәгән.

Манчыл мәдрәсәсендә укытучылыкка дәгъва итүчеләргә зур таләпчәнлек күрсәтелгән. Кагыйдә буларак, монда югары белемле, демократик рухлы укытучылар эшләгән. Алар арасында Казан, Оренбург, Уфа, Бохара мәдрәсәләрендә, шулай ук Истанбул, Мәккә, Мәдинә мәдрәсәләрен тәмамлаганнары да очрый[4] XIX йөзнең сиксәненче елларында монда себер татарлары вәкиле, шагыйрь Мөлкәй (Мәүлекәй) Юмачиков та укыткан.

Сәйдуковлар мәдрәсәсендә шәкертләр һәм укытучыларны җитәрлек дәрәҗәдә дәреслекләр, гомумән, уку процессында зарур булган әдәбият һәм уку әсбаплары белән тәэмин итүгә зур игътибар иткәннәр. 1884-88 елларда Манчыл авылында ике катлы таш мәчет салдыралар, ә аның эчендә китапханә өчен махсус бүлмә булдырылган. Китапханәдә, 1913 елгы мәгълүматка караганда, 2200 томлык кульъязма һәм басма китаплар саклангән. Кульъязма китаплар арасында бик борынгы уникаль тарихи истәлекләр дә булган, алар Нигъмәтулла Сәйдуков тарафыннан Бохара һәм Төркестаннан алдырып, кайберләрен исә 1880 елны хаҗга барганда үзе белән алып кайткан булган. Мөхид Богһаниның өч томлык кульъязма әсәрен Н. Сәйдуков 700 сумга Бохарадан алдырган икән. («Шура».— 1913.— 18 сан.— 545-546 бб.). Мәдрәсә химаячеләре шәкертләрнең өлгерешләрен күтәрү буенча төрле ысуллар кулланганнар. Мәсәлән, яхшы укучы шәкертләр кием-салым (форма) белән беренче чиратта тәэмин ителгәннәр, соңгы җиденче ел укучыларга Сәйдуковлар фондыннан унар сум ярдәм биреп торганнар, ә мәдрәсәне аеруча яхшы нәтиҗә белән тәмамлаган шәкертләрне, укуларын дәвам иттерү өчен, Казан, Уфа, Оренбург мәдрәсәләренә, хәтта чит илләргә — Истанбул, Каһирә, Мәккә һәм Мәдинә мәдрәсәләренә үз хисапларына укырга җибәргәннәр.

XIX йөзнең туксанынчы еллар азагында Манчыл мәдрәсәсендә төрле предметлар буенча дәресләр, Казан, Оренбург, Уфа мәдрәсәләрендәге төсле, бер тәртиптә укытылган.

1905-07 еллар революциясеннән соң элекке Тубыл губернасының байтак зур татар авылларында мәдрәсәләр ачыла. Шулар эчендә белем бирүне оештыру, укуны файдалы хезмәт белән берләштерә алып баруда Торбы һәм Саускан авыллары мәдрәсәләре алдынгылардан саналган.

Берничә ел Тара шәһәре мәдрәсәсендә мөдәррис булып, соңыннан үзенең иҗтимагый-политик эшчәнлеге белән танылган, публицистик характердагы байтак әсәрләр авторы, редактор һәм нашир Рәшит Ибраһимов эшләгән.

Революциягә кадәр Себер мәдрәсәләренең үсеше Россиядә яшәүче татарлар арасында уку-укыту өлкәсендә ике ысул — кадимчелек һәм җәдидчелек арасында күзәтелгән көрәш процессында барган. Иске ысул буенча эшләгән мәдрәсәләрдә шәкертләрне укыту Коръәннең аерым өлешләрен, шулай ук башка дини китапларны татар балалары өчен ят гарәп һәм фарсы телләрендә аңламыйча ятлаудан гыйбарәт иде. Бу типтагы мәдрәсәләр дә укучыларны язарга өйрәтүгә һәм дөньяви белемнәр белән сугаруга бик аз игътибар бирелгән. Ләкин XIX гасыр азагында Россиядә мөселман динен тоткан халыклар, шул исәптән татарлар арасында да дини уку йортларында үзгәртеп-коруны таләп иткән яңа агым, яңа хәрәкәт барлыкка килә. Бу хәрәкәтнең себер татарлары арасында да таралуы Себердә капитализмның һәм бу җәмгыять тудырган буржуазиянең үсүенә бәйле. Билгеле булганча, буржуазия мәктәп эшен үзенең сыйнфый таләпләренә буйсындыруны үтә мөһим бурычларыннан санаган. Буржуазия «мәктәп эшенең нигез ташы итеп, үзенең буржуаз сәясәтен куйды һәм мәктәп эшен буржуазия өчен кундәм һәм өлгер ялчылар әвәләп чыгаруга кайтарып калдырырга тырышты, түбәннән югарыга кадәр хәтта гомуми укытуны да буржуазия өчен күндәм һәм өлгер хезмәтчеләр, капитал ихтыярын үтәүчеләр һәм капитал кол-

---

[3] Патканов С. К. Материалы для изучения экономического быта государственных крестьян и народцев Западной Сибири. Вып. 1.— СПб., 1888, 326 б.

[4] Төмән өлкәсе дәүләт архивы, 152 ф., 1 тасв., 41 эш, 7 б.

лары хәзерләүгә кайтарып калдырырга тырышты».[5]

Бу чорда үсеп чыккан себер буржуазиясенә, шул исәптән себер татар буржуазиясе вәкилләренә дә, белемле, мәдәниятле инженерлар, бухгалтерлар, приказчиклар, гомумән үз эшендә төпле фикерле булган төрле кадрлар кирәк була. Ә яңа тарихи, социаль-экономик шартларда иске ысул нигезендә эшләп барган уку йортлары бу таләпләргә җавап бирә алмыйлар иде. Менә шул сәбәптән Себер татарлары яшәгән төбәкләрдә, аеруча Себернең административ һәм экономик үзәкләрендә, шулай ук зур авылларда яңа ысул мәдрәсәләр барлыкка килә. Бу мәдрәсәләрдә шәкертләрне укыту Европа илләрендә кулланылган тавыш методы буенча, нигездә, татар телендә алып барылган. Боларда тарих, география, математика, биология, физика, химия һ. б. гомуми белем бирә торган фәннәр даими өйрәтелә, ә 1905—07 еллар революциясеннән соң бу мәдрәсәләрдә парталар, кара такта, акбур, географик карталар кулланыла башлый.

Манчыл һәм Тара мәдрәсәләрендә, аларны үз карамакларында тотучы байлар (Сәйдуковлар һәм Әйтикиннәр) теләге буенча, шәкертләр хисап эшләре буенча да мәгълүмат алганнар.

Яңа ысул мәдрәсәләрендә шәкертләрне рус телен өйрәтүгә аеруча зур әһәмият бирелгән. Бу аңлашыла да, чөнки алдынгы караштa булган укытучылар һәм шәкертләр рус телен, әдәбиятын яхшы өйрәнүнең рус мәдәниятенә һәм гомумән бөтен дөнья халыкларының кыйммәтле рухи хәзинәләренә киң юл ачачагын аңлаганнар.

Югарыда искә алынган мәдрәсәләр үз вакытында яңа ысул мәдрәсәләре булып саналганнар. Аларда дин сабаклары һәм дөньяви фәннәр белән беррәттән, хезмәт дәресләре дә укытылган. Мәсәлән, Сәйдуковлар һәм Торбы авылы мәдрәсәләрендә шәкертләр күн эшләү, агач эшкәртү, киез каталар әвәләү кебек һөнәрләргә өйрәнгәннәр. Р. Фәхретдиневнең язуына караганда, Сәйдуковлар мәдрәсәсе яңа ысулга күчкән вакытта Россиянең башка урыннарында яшәгән мөселманнарның бу ысул турында төшенчәләре дә булмаган. (Шура.— 1913.— 17сан.— 517 б.). Димәк, Манчыл мәдрәсәсе яңа ысул буенча укытуга бөтен Россиядәге мәдрәсәләр арасында беренче буларак күчкән икән.

1905-07 еллар революциясе чорында һәм аннан соңгы елларда Себер татарлары арасында мәгариф эшләрен оештыруны яхшырту өчен көрәштә демократик рухта тәрбияләнгән. Казан, Оренбург, Уфа мәдрәсәләрен тәмамлап килгән яшь мөгаллимнәр зур өлеш керткән. Моны исбатлау өчен бер генә мисалга тукталыйк. 1913 елны Тара шәһәренә укытырга Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән Хәкkый Исхаков килә.[6] Ул халыкны агартуны камилләштерү өлкәсендә булган алдынгы фикерләрен тизрәк гамәлгә ашырырга тырыша. Аның җитәкчелегендә Тара мәдрәсәсе тулысынча яңа ысул мәдрәсәсенә әйләнә. Яшь укытучы тырышлыгы аркасында моңа кадәр бирелдә укытылмаган байтак яңа фәннәр буенча дәресләр татар әдәби телендә алып барыла. Ул үзенең шәкертләрен Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Коләхмәтов һ. б. татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре белән таныштыра. Тара татарлары һәм аңа якын урнашкан татар авылларыннан килгән тамашачылар өчен мәдрәсә бинасында шәкертләр көче белән еш кына концертлар үткәрелә. Бу концертларда татар, казакъ, башкорт җырлары яңгыраган, татар, рус шагыйрьләренең шигырьләре укылган. Мондый концертларны тамашачылар бик яратып каршы ала торган булганнар.

Билгеле булганча, кешелек җәмгыятенең һәрбер дәверендә алдынгы фикер дөньяга иске караштa торган реакцион көчләрнең каршылыгына очрый. Яңа ысул татар мәдрәсәләре дә үзләренең үсешендә бу закончалык тәэсиреннән читтә калмадылар. Мәдрәсәләрдә уку-укытуны иске ысул буенча алып бару ягында торган руханилар яңа ысул мәдрәсәләренә һәм аларда эшләгән алдынгы карашлы укытучыларга каршы кискен көрәш ачтылар. Алар яңа ысулчыларның гарәп әлифбасына үзгәртеп-кору ясауның кирәклеге турындагы тәкъдимнәрен Коръәннең бөтенлегенә һөҗүм итү дип саныйлар, ә кара тактаны «урыс тәресе» дип атыйлар. Яңа ысул мәдрәсәләре укытучыларын хөкүмәткә каршы хәрәкәттә гаепләп, өсләреннән патша администрациясе исеменә донослар язалар. Бу хакта кулымда байтак фактик материаллар булса да, мәкаләнең күләме чикле булуы сәбәпле, аларга тукталмадым. Бу чордагы Россиянең Европа өлешендәге мәдрәсәләргә характеристика биреп Р. И. Нәфиков болай яза: «Бигрәк тә яңа ысул татар мәктәбе, демократик настроениелы укытучылар һәм укучы яшьләр җәберләнде».[7] Моңа дәлил итеп түбәндәге фактны китерергә мөмкин. 1907 елны Петропавловск (хәзерге Төньяк Казахстан өлкәсе үзәге.— Ф. В.) шәһәрендәге мәдрәсәдә алдынгы шәкертләр «Җәмгыяте хәйрия» исемле җәмгыять төзиләр. Аның рәисе итеп мәдрәсәнең алдынгы фикерле шәкерте Хәмзә Шәехов сайлана. Мәдрәсә әле иске ысул белән эшләп бара, аның җитәкчеләре шәкертләрне

---

[5] Ленин В. И. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. Т. 28, 418 б.

[6] Исхаков Х. З. (1890-1971), Башкортстанда туган, 1913-1935 елларда Көнбатыш Себердә укытучы һәм халык мәгарифе органнары хезмәткәре. 1935 елдан башлап, пенсиягә чыкканга кадәр, Ташкент шәһәр мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләгән. Авторның Х. Исхаков белән булган әңгәмәләре 1962 елның июнендә Ташкент шәһәрендә булды.

«яңалык җилләре»ннән саклап калырга тырышалар. Бу җәмгыять әгъзалары башта Хәмзә Шаехов җитәкчелегендә татар һәм рус телләрендә чыга торган демократик юнәлештә булган газета-журналлар укыйлар, соңрак мәдрәсә администрациясеннән укытуны яңа ысул буенча алып баруны таләп итәләр. Ләкин иске ысулчы мәдрәсә җитәкчеләре оешма әгъзаларын мәдрәсә кануннарын бозуда гаепләп төрлечә җәзалау, ә Х. Шаеховны судка тарту һәм мәдрәсәдән чыгару фикерен алга сөрәләр. Тик мәдрәсә шәкертләренең күпчелеге һәм кайбер укытучыларның Хәмзәне яклап чыгулары аркасында гына ул судтан котылып кала, ләкин аны мәдрәсәдән барыбер чыгаралар. Ул үзенең туган авылына кайтып яңа ысулдагы башлангыч мәктәп оештыра һәм анда укытучылык итә.[8]

Россиядә яшәүче татарлар арасында халык мәгарифе өлкәсендә ике агым көрәшен патша хөкүмәте зур дикъкать белән күзәтә. Миңа Төмән өлкә дәүләт архивында бу мәсьәләгә кагылган бер документ белән танышырга туры килде. Ул, патша хөкүмәте эчке эшләр министрлыгының полиция буенча 1900 елның 31 декабрендә төзелеп, Тубыл губернаторына адресланган 13433 номерлы яшерен циркуляры. Циркулярда шулай диелгән: «Ике агым тарафдарлары арасында барган политика бик тиз арада кискенләште һәм шул ук вакытта милли, иҗтимагый һәм культура характеры алды; мөселманлык искеләре («староду-мы магометанства»), күбесенчә муллаларны, иске традицияләрне бик көчле яклап чыктылар, моны тик яңа хәрәкәт аларның элекке көчен һәм тәэсирен тартып алуыннан курку һәм дулкынлану тәшвише белән генә аңлатырга мөмкин, яңа ысулчылыкны алар татарларның ислам диненнән төшеп калу һәм динсезлеккә алып бару куркынычы тудыручылык, яңадинчелек (нововерие) дип карыйлар, шуның белән бергә, алар үзләренең «Яңататарлар» (новотатары) белән барган гаугаларында хәтта администрацияне дә (патша администрациясен — Ф. В.) «үз якларына аудару турында уйлыйлар».[9] Циркулярда урындагы патша администрациясенә Россия мөселманнары арасында барлыкка килгән һәрбер хәрәкәткә саклык һәм сизгерлек белән карау, ул хәрәкәтләр белән алдан һәм мөмкин кадәр тулырак танышып бару мөһим бурыч итеп куела. Чынбарлыкта патша хөкүмәте татарлар өчен мәктәп һәм мәдрәсәләр ачуга яхшы карамаган, чөнки «рус булмаган халыкларны агарту царизм исәбенә иң аз кергән мәсьәлә иде».[10] Димәк яңа ысул татар мәдрәсәләренең үзләренә юл салу өчен көрәшләре, тик татар кадимчеләренә генә каршы көрәш булмыйча, бәлки патша самодержавиесенә дә каршы көрәш иде. Революция алдындагы соңгы унъеллыкта бары Тубыл губернасында гына яңа ысул мәктәп һәм мәдрәсәләр саны шактый арткан. Мәсәлән, 1909 елда Тубыл өязендәге зур татар авылларында 12 мәдрәсә эшләгән, боларда 615 ир һәм 185 кыз бала укыган. Гомумән, Себернең төрле төбәкләрендә ачылган татар мәктәп һәм мәдрәсәләре себер татарларын укырга-язарга өйрәтү, аларның культура дәрәҗәләрен күтәрүдә зур роль уйнадылар. XIX гасыр азагында Тубыл губернасында яшәгән татарларның укый-яза белүчеләре проценты монда яшәүче остяклар, казахлар, вогуллар һәм зыряннарга караганда байтак югары булуы моның ачык дәлиле булып тора.

Себер татарлары арасында татарча укый-яза белүчеләр проценты Себердә яшәүче рус булмаган аз санлы халыкларга, хәтта регионлагы русларга караганда да югарырак булуы Себер мәдрәсәләренең шиксез тәкъдиргә лаеклы эшләреннән саналырга хаклы. Ул чорда Себер мәдрәсәләре татарлар өчен генә түгел, Себердә яшәгән казах һәм башкорт халыклары өчен дә чын-чынлап белем учаклары булган. Шунлыктан шәхес культы чорында һәм торгынлык елларында мәдрәсәләргә бары тик дин тарату үзәкләре генә дип каралган ялгыш фикер бөтенләйгә кире кагылырга тиеш.

Себердә революциягә кадәр яңа ысул мәдрәсәләрен тәмамлап чыккан татар яшьләре арасыннан совет чорында халыкка зур хезмәт күрсәткән укытучылар, алар арасында Тара өязеннән Хәмзә һәм Мансур Шаеховлар, Мөнзир Исхаков, Һади Бәширов, Тубыл өязеннән Ваһап Әхмәтов һ. б., совет һәм партия хезмәткәрләре Садыйк Баязитов, Хафиз Рәхмәтуллин, Әхмәт Ильясов, Галим Рябков, А. Надирбагин, галимнәр Мидхәт Булатов, Хәмит Ярмөхәммәтов һ. б. үсеп чыкты.

Себер мәдрәсәләре тарихы, себер татарларының бай рухи культурасы тарихының мөһим бер өлеше буларак, бүгенгә кадәр әле өйрәнелмәгән мәсьәлә булып тора. Бу мәсьәләне һәрьяклап тирәнтен өйрәнү — татар халкы тарихын, мәдәниятен өйрәнүче галимнәр каршында торган мөһим бурычларның берсе.

---

[7] Нафигов Р. И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли.

[8] Шаехов Х. М. (1881-1966) Себер бохаралыларыннан Еланлы авылында (хәзерге Большеречье районы Омск өлкәсе тимерче гаиләсендә туган. Гомеренең күбрәк өлешен шул ук районның Үланкүл авылында уздырды. Авторның Х. М. Шаехов белән югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр буенча әңгәмәсе 1937, 1958 һәм 1961 елларда Үланкүл авылында һәм Омск шәһәрендә булды.

[9] Төмән өлкәсе дәүләт архивы, 152, ф., 1 тасв., 41 эш, 1-2 бб.

[10] Эфиров А. Ф. Нерусские школы Поволжья, Приуралья и Сибири.— М., 1948. 14 б.

# ЮГАЛМАСКА ҺӘМ ЮГАЛТМАСКА!

*Татарстан укытучылар белемен камилләштерү институты курсларында катнашкан татар теле һәм әдәбияты, татар башлангыч класс укытучыларының СССР һәм дөньядагы барлык татар мөгаллимнәренә һәм тәрбиячеләренә мөрәҗәгате.*

Мөхтәрәм хезмәттәшләр, кардәшләр! Без, рухи мәркәзебез Казанга илебезнең төрле төбәкләреннән белемебезне камилләштерү өчен килгән татар теле һәм әдәбияты, башлангыч класс укытучылары, сезгә — СССРдагы һәм дөньядагы татар укытучыларына һәм тәрбиячеләренә мөрәҗәгать итәргә булдык.

Кадерле хезмәттәшләр! Узган гасырларда үзенең дәүләте булган, милли мәктәбен саклап килгән халкыбыз бүгенге көндә зур афәт — үзенең телен, гореф-гадәтләрен онытып башка халыклар арасында йотылып юкка чыгу куркынычы астында калды. Без — укытучылар бу афәттән бары тик илдә татар милли мәктәбен яңадан торгызу һәм аны тулысы белән татар халкына, аның дәүләте карамагына тапшыру белән генә котылып була дип уйлыйбыз.

СССРдагы өч меңнән артык татар балалары укыган мәктәпнең меңнән артыгы гына Татарстан территориясенә туры килә, калган күпчелек татар мәктәпләре РСФСРның автономияле республика халык мәгарифе министрлыкларына, край, өлкә идарәләренә карый, Татарстандагы югары уку йортларының берсе дә республиканың халык мәгарифенә буйсынмый. Татар баласына үз республикасында да, аннан читтә дә балалар бакчасыннан алып югары уку йортын тәмамлаганчы үз телендә өзлексез белем алу мөмкинлеге юк диярлек. Мәгариф системасында әлегә кадәр яшәп килгән бу аянычхәл татар халкының милли үсешен тоткарлый, рухи һәм интеллектуаль мөмкинлекләрен кимсетә. Соңгы ун елда Казан югары уку йортларының байтагында, башка халыклар белән чагыштырганда, татар студентларының саны кимү — моның ачык мисалы. Хәзер Татарстанда барлык татар укучыларының утыз проценты, ә бөтен илдәге татар балаларының җиде проценты гына ана телендә белем ала. Халкыбыз арасында рухи гариплек чире, милли нигилизм котырып чәчәк атты. Бер миллионнан артык милләттәшебез татар телен ана теле итеп санамый.

Без халкыбызның бу рухи бөлгенлектән чыгуын илебездәге һәм башка илләрдәге барлык татар балалар бакчалары, мәктәпләре, урта махсус белем бирү һәм югары уку йортларының билгеле бер системасын булдыруда һәм аның белән идарә итүне, милли-мәдәни автономия шартларында, татар халкының үз дәүләте — Татарстан вәкаләтенә кертелүдә күрәбез. Ләкин бу системаны тудыру һәм хәрәкәткә китерер өчен Татарстанның экономик һәм рухи потенциалы ягыннан көчле, үз дәүләт теле булган, мөстәкыйль республика булуы беренче шарт. Шуның өчен без — татар укытучылары — Татарстанга союздашлык, ә татар теленә дәүләт теле статусы бирү идеясен кайнар хуплыйбыз. Һәм сезне дә шуңа чакырабыз. Боларга без милләтнең исән калуына соңгы ышаныч, өмет итеп карыйбыз.

Без татар төбәкләрендәге милли мәктәпләрдә ана теленең фән буларак кына укытылуына каршы. Милләтнең яшәве өчен укыту һәм тәрбия эше ана телендә алып барылырга, ә башка телләр фән буларак кертелергә тиешле.

Безне Татарстан мәгариф органнары белән республикадан читтә урнашкан милли мәктәпләр, ясле-бакчалар арасындагы бәйләнешләрнең начар булуы һәм аның конституцион нигезгә куелмавы бик борчый. Шунлыктан без ашыгыч рәвештә татар милли мәктәбенең бөтен ил күләмендә яшәеш механизмнарын булдыру кирәк дип саныйбыз. Шушы механизмның башлангычы буларак, татар иҗтимагый үзәге һәм милли зыялыларыбыз күтәреп чыккан Татар укытучылары һәм тәрбиячеләренең Бөтенсоюз ассоциациясен төзү идеясен яклыйбыз. Аның үзәге милләтебезнең мәркәзе Казанда булуын телибез. Сезне аны төзүдә катнашырга чакырабыз.

Мөхтәрәм хезмәттәшләр, без дөньяның кайсы җирендә генә яшәсәк тә омтылышларыбыз бер: үз илен, үз милләтен, туган телен, мәдәниятен табигый хәлдә дәвам иттерүче, үстерүче алмаш әзерләү, буыннар арасындагы рухи чылбырның өзелүенә юл куймау. Хәзергә хәлебез бик аянычлы. Милләт язмышы куркыныч астында. «Татар халкы киләсе гасырларга бара алырмы, әллә башка халыклар арасында эреп юкка чыгармы?» — дигән катгый сорау күз алдыбызга килеп баскан хәлиткеч вакытта сезгә эндәшәбез, туганнар.

Халкыбызны бу афәттән саклап калыйк. Милли мәктәбебезне аякка бастырыйк, мөмкин булган һәр җирдә татар мәктәпләре, татар балалар бакчалары, югары уку йортларында милли бүлекләр ачу өчен тырышыйк. Укыту эшендә халкыбызның тәрбияви традицияләрен киңрәк кулланыйк. Шуны онытмыйк: милләтебезне саклап калуда иң җаваплы кеше без — татар укытучылары, татар тәрбиячеләре. Милләтебез исән калсын, башка халыклар белән тигезлектә яшәсен дисәк, эшкә тотыныйк, хезмәттәшләр!

Мөрәҗәгать 2 һәм 4 июльләрдә Татарстан укытучыларының белемен камилләштерү институты курсларында катнашкан РСФСР, Үзбәкстан, Казахстан татар теле һәм әдәбияты, татар башлангыч класслары укытучыларының йомгаклау җыелышларында бертавыштан кабул ителде.

## Б. Н. ЕЛЬЦИН БЕЛӘН ОЧРАШУ

9 августта РСФСР Югары Советы Рәисе Б. Н. Ельцин үзенең Татарстанга ясаган визиты вакытында республикабызның иҗат интеллигенциясе белән дә очрашты. Очрашу Татарстан Язучылар берлегенең Әдәбият йортында булды.

Сүз, нигездә, үз җире, үз тарихы булган халыкның үзенчә яшәргә хокуклы булуы турында барды. Татарстанга, һичшиксез, мөстәкыйльлек кирәклеген яклап сөйләүчеләргә Б. Н. Ельцинның җавабы ачык булды: үз язмышыгыз — үз кулыгызда, Татарстан нинди мөстәкыйльлек алса, Россия шуны хуплар, диде ул. РСФСР Югары Советы Рәисе уннарча сорауларга җавап бирде.

Әлеге очрашуда Татарстан Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев, Республика Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабиров катнашты. Очрашуны Татарстан Язучылар берлеге рәисе, РСФСР халык депутаты Р. Мөхәммәдиев алып барды.

## ТАТАРСТАНГА — МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК!

26 июльдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры алдындагы мәйданда «Татарстанга — союздашлык статусы» дигән мәсьәләгә багышланган зур митинг булып узды.

Татар иҗтимагый үзәге уздырган әлеге политик җыенда халык депутатлары, халкыбызның зыялылары, язучылар, шагыйрьләр чыгыш ясап, халыкка республиканың бүгенге хәлен, үткәнен һәм киләчәген дөрес итеп аңлатырга тырыштылар. Мәйданга җыелган халык шагыйрьләр М. Хөсәен, Рәшит Әхмәтҗанов, Ә. Рәшитов, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, Ә. Мәхмүтов чыгышларын көчле алкышларга күмделәр.

Митинг бертавыштан «Татарстанга — союздашлык статусы» дигән резолюция кабул итте. Дөрт сәгатькә якын барган митинг-концерт Тукайның «Туган тел» җырын җырлап тәмамланды.

* * *

7 августта шул ук мәйданда Татар милли азатлык партиясе «Иттифак» Татарстанга союздашлык статусы таләп иткән зур митинг үткәрде. Митингта сөйләүчеләр, татарларның бәйсезлек өчен көрәш тарихына таянып, республикабызның мөстәкыйльлеккә тулы хокукы барын кире кагылгысыз мисаллар белән исбатлап сөйләделәр. Митингта танылган галим Ә. Кәримуллин, язучы Ф. Бәйрәмова, шагыйрь Р. Зәйдулла һ. б. чыгыш ясады.

## БӨЕК РӘССАМ БЕЛӘН ХУШЛАШУ

6 августта, РСФСРның һәм Татарстанның халык рәссамы, халкыбызның газиз улы, күпмилләтле совет сәнгатен үстерүгә бөтен гомерен, иксез-чиксез рухи көчен багышлаган талант иясе Бакый Урманче вафат булды. Халкыбызның йөз аклыгы, халыкка хезмәт итүнең ничек булырга тиешлелеген тормышта Тукайча раслаган олы иҗатчы безнең арабыздан китте.

9 августта Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында мәрхүм белән хушлашу мәрасиме булды.

Матәм митингысын Татарстан Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, Язучылар берлеге әгъзасы, күмүне оештыру комиссиясе рәисе М. Хәсәнов ачты.

Татарстан рәссамнар берлеге рәисе Ә. Мәҗитов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, танылган әдипләрдән Ә. Еники, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин, Татарстан театр эшлеләре берлеге рәисе, РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов һ. б. хушлашу сүзе әйттеләр.

Гомер буе халык гаме белән яшәгән халык улы — үз халкы белән бергә мәңгелеккә атлар.

## ЯЗУЧЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАП

Танылган татар язучысы Хәсән Сарьянның 60 еллык юбилей тантанасы Башкортстанның Илеш районы, Кызыл Яр авылында уздырылды. Кичәгә язучының якташлары — район хезмәт ияләре җыелган иде. Биредә шулай ук Башкортстан язучылары Мансаф Гыйләҗев, Суфиян Поварисов, Тамара Ганиева, Ринат Хәйри, татар галиме Сәгыйть Хафизов, Казаннан Роберт Миңнуллин катнашты. КПССның Илеш район комитеты беренче секретаре И. Т. Шәяхмәтов Кызыл Яр мәктәбенә, Кызыл Яр авылының яңа бер урамына Хәсән Сарьян исеме биреләчәген игълан итте.

Шушындый ук кичә Казанның Актерлар йортында да булды. Язучының тормышы һәм иҗаты турында Гариф Ахунов сөйләде. Аннары Х. Сарьянның дуслары һәм каләмдәшләреннән М. Шабаев, К. Тимбикова, В. Нуруллин, Р. Гатауллин, Ә. Гадел һ. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

## ЯШЬ ТАЛАНТЛАР СЕМИНАРЫ

«Яшь ленинчы» газетасы иҗат белән шөгыльләнүче укучылар семинары уздырды. Анда төрле районнардан килгән унбиш баланың әсәрләре тикшерелде. Семинарда катнашкан Ш. Галиев, Л. Исханова,

А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Мингалим, Р. Миңнуллин, Г. Садә, Хәйдәр, Җ. Дәрзаман яшь талантларга әдәбиятның нечкәлекләре, шигъриятнең серләре турында сөйләделәр, иҗатларына анализ ясадылар.

## МӘДӘНИЯТ ҮЗӘКЛӘРЕНДӘ

### МӘСКӘҮ

Быел халкыбызның олуг бәйрәме — сабантуй Мәскәүдә зурлап уздырылды. Башкаланың Измайлово паркында аны татар яшьләре элегрәк тә үткәрә иде. Әмма шәһәр властьларының ризалыгыннан тыш, ярым-яшерен рәвештә.

Мәскәү татар иҗтимагый үзәге дүртенче ел инде сабантуйны рәсми төстә үткәрә. Мәскәүнең 1 Май район башкарма комитеты быел сабантуй үткәрү өчен хәтта меңсум акча да бүлеп бирде.

Бәйрәмгә Татарстаннан, Башкортстаннан, Пенза, Горький, Әстерхан, Тамбов өлкәләреннән кан-кардәшләр дә килде.

Татарстан АССРның Министрлар Советы рәисе М. Г. Сабиров сабантуйны ачып, милләттәшләрен берләшергә, алда торган мәсьәләләрне күмәкләшеп хәл итәргә чакырды.

Мәскәү мәчетенең имам хатибы Р. Гайнуллин динебезне, мәдәниятебезне, телебезне саклап калырга өндәде, ә Бохараның «Мир-араб» мәдрәсәсе шәкерте С. Голәмов Коръән укып ишеттерде. Аннан соң төрле ярышлар башланды. Бәйрәмнең башыннан ахырынача татарча җыр-моң яңгырады.

* * *

Соңгы елларда Мәскәүдә егермедән артык милли клуб төзелде. Алар арасында иң активларының берсе — «Туган тел» татар мәдәнияте җәмгыяте. Аңа Ленин һәм Азәрбайҗан ССР Дәүләт премияләре лауреаты, күренекле физик-академик К. Ә. Вәлиев җитәкчелек итә. Даими бинасы, акча фонды булмауга карамастан, җәмгыять халкыбызның телен һәм мәдәниятен аякка басты-ру буенча актив эш башкара. Аларның тырышлыгы белән Мәскәүнең 12 мәктәбендә һәм алты балалар бакчасында татар теле өйрәтелә.

Яңарак тагын бер олы вакыйга булды — биш мең данә белән «Туган тел» дигән газетаның беренче саны дөнья күрде. Ул татар халкының тарихын, мәдәниятен, бүгенге проблемаларын яктырта. Беренче сан әлегә русча басылган, киләчәктә аны татар телендә чыгару күздә тотыла.

* * *

Мәскәү вузларында егерме меңнән артык татар студенты укый. Алар башлангычы белән татар яшьләре клубы ачылды. Аның төп максаты — яшьләрнең милли үзаңын, мәдәни яңарышны үстерү. Клубның рәисе итеп бертавыштан «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» дигән популяр телевизион тапшыруда актив катнашучы Нурали Латыйпов сайланды.

Чираттагы җыелышта клубның уставы кабул ителде. Анда шулай ук клубны регистрацияләү һәм бәшкала яшьләре ассоциациясенә кертүне сорап, Мәскәү шәһәр Советы башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә, дигән карар кабул ителде.

### ЛЕНИНГРАД

Карл Маркс исемендәге мәдәният йортында татарларны берләштерә торган үзәк бар. Шунысы сөенечле: күптән түгел биредә татарлар өчен «Нур» дип исемләнгән газета да чыга башлады.

Ленинград татарлары атнага бер тапкыр, җомга көнне, мәчеткә җыела. Биредә, гыйбадәт кылу белән бергә, милләттәшләр җыелып фикер алыша, бер-берсе белән таныша. Биредә чит мәмләкәтләрдән Ватаныбызга килгән мөселманнарны да күрергә мөмкин.

* * *

К. Маркс исемендәге мәдәният йортында филология фәннәре докторы Ә. Г. Кәримуллин белән очрашу булды. Галим үзенең фәнни эшләре турында сөйләде, татар фәнни хезмәткәрләре алдында торган проблемалар хакында үз фикерен әйтте. Ул шулай ук очрашуда катнашучыларны кызыксындырган бик күп кенә сорауларга җавап бирде.

Тәнәфестә татар китаплары сату оештырылды. Сатуда Ә. Г. Кәримуллинның татар этносы һәм этнонимы турындагы мәгълүм хезмәте дә бар иде.

### КИЕВ

«Вечерний Киев» газетасының язуына караганда, бу шәһәрдә өч мең ярым татар кешесе яши. Узган ел Украина культура фонды каршында төрки телдә сөйләшүче халыкларның Республика мәдәният үзәге оештырылган иде. Бу Үзәк каршында татар балаларына татар телен өйрәтү һәм өлкәннәр өчен гарәп әлифбасын өйрәнү түгәрәкләре оештырылды. Биредә шулай ук татарларның фольклор ансамбле эшләп килә.

### СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕ

Өлкәнең Ревда шәһәрендә былтырдан бирле «Дуслык» татар ансамбле һәм «Тургай» дигән балалар ансамбле эшләп килә. Шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге аларның концертларына бәйрәмгә килгән шикелле килә. Бу ансамбльләрне Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап бирегә яшәргә һәм эшләргә килгән Нуретдин Камалиев оештырды.

### КУЙБЫШЕВ

Куйбышев шәһәренең яңа төзелгән Ленин мемориалы залында музыка мәктәпләрендә укучылар башкаруында беренче тапкыр татарча зур концерт булып үтте. Аны «Туган тел» татар милли мәдәният үзәге һәм Куйбышев шәһәр башкарма комитетының мәдәният бүлеге вәкилләре оештырды.

### ВОРКУТА

Воркута шәһәрендә узган ел бер төркем татар яшьләре үзешчән җыр һәм бию ансамбле оештырган иде. Коллектив житәкчесе Фаиз Мәйдуллин бу ансамбльне оештыруда күп төрле каршылыкларга очрады, тамашачыларны сөендерү өчен байтак көч куйды. «Яшьлек ялкыны» ансамбле быел үзенең бер еллык юбилеен үткәрде. Юбилей тамашасы Шахтерлар мәдәният сараенда үтте. Бу көн бөтен шәһәр күләмендә «Татар мәдәнияты көне» дип игълан ителде.

### ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ

Төмәннең «Тәзүче» мәдәният сараенда «Идегәй» үзешчән җәмәгать оешмасының оештыру җыелышы булды.

Идегәй — Себер татарлары фольклорына үзенең тапкырлыгы, осталыгы, батырлыгы белән кереп калган милли герой. Шуңа күрә дә элеге оешма башлыча татарлардан тора. Оешма татар мәктәпләре челтәрен киңәйтүне, милли кадрлар әзерләү белән җитдирәк шөгыльләнүне планлаштыра, Төмән шәһәре һәм өлкә халкын татар мәдәнияте белән якыннанрак таныштыруны күздә тота.

Оешманың җитәкчесе итеп фәнни-методик үзәк редакторы Г. Ниязова сайланды.

### ПЕНЗА

Пензаның ял паркында төрле милләт халыклары катнашында дуслык бәйрәме уздырылды. Анда Пенза, Архангельск өлкәләреннән, Татарстан, Бурятия, Мордва АССРлардан фольклор коллективлары катнашты. Чүпрәле районыннан килгән «Таң» ансамбле чыгышы аеруча уңышлы булды. Бу һәвәскәрләр язучы Заһир Бигиевның туган төбәгендә дә (Каменка районы, Кикин авылы) чыгыш ясады.

### ӘСТЕРХАН

9 июньдә Әстерханда «Ислам яңарышы» партиясенең оештыру съезды булып узды. Илебезнең төрле төбәкләрендәге мөселман җәмгыятьләреннән 183 вәкил яңа партиянең уставы һәм программасын кабул итте. Шулай ук координацион совет сайланды. Аның әгъзалары үз араларыннан партия әмирен билгеләделәр. Бу исемне Әхмәт-кади Октаев алды. Съездга Татарстаннан да делегат килгән иде.

### УНИВЕРСИТЕТ ГАЛИМНӘРЕ — ПЕКИНДА

Пекин университетында кытай-совет әдәбиятлары арасында элемтәләргә багышланган гыйльми конференция булды. Бу — ике ил арасы җылынгач үткәрелгән беренче конференция иде. Анда, Мәскәү һәм Кытай гыйльми үзәкләре галимнәре белән бергә, Казан дәүләт университетының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасы мөдире В. Н. Коновалов, профессор Н. А. Асанова һәм журналистика факультеты деканы Ф. И. Әгъзамов катнаштылар. Ф. И. Әгъзамовның «Кытай әдәбиятын татар телендә пропагандалау» дигән докладын тыңлаучылар да зур кызыксыну уятты.

### ЯПОНИЯ ГАЛИМНӘРЕ — КАЗАНДА

Июль азагында Токио университеты профессоры Масауки Ямаучи белән Хоккайдо университеты профессоры Такео Кюрюцава Казанда булып киттеләр. Без аларны халкыбызның бөек улы М. Солтангалиев һәм Вәисовлар, вәисовчылар хәрәкәте турында язылган фәнни мәкаләләре, «Казанны алу», «Казан — рус дәүләтендә» дигән китаплары аша беләбез.

Япония галимнәре халкыбызның бүгенге хәле, мәдәният яңалыклары, яңа чыккан фәнни китаплар белән таныштылар, Татарстан галимнәре белән әңгәмә кордылар.

### ХАЖГА СӘЯХӘТ

Быел безнең илдән байтак мөселманнар Хаҗга барды. Илебездән — 1500, шулардан СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәтеннән 440 кеше, Татарстаннан 200 ләп, Казанның үзеннән 80 ләп кеше Хаҗда булып кайтты.

### КОРЪӘН КӘРИМНЕҢ ҮЗБӘКЧӘ ТӘРҖЕМӘСЕ

Үзбәкстан Язучылар берлегенең 1989 елдагы карары буенча, 1990 елның март аеннан башлап, Коръән кәримнең үзбәк теленә кылынган тәрҗемәсе Үзбәкстан Язучылар берлеге органы — «Шәрек йолдызы» журналында басылып чыга башлады.

Коръән кәримне үзбәк теленә Әлаведдин Мансур тәрҗемә иткән. Тәрҗемә теленең җиңеллеге, мәгънә ягыннан коръәндәге аятьләрне тулырак чагылдыра алуы белән аерылып тора. Аңлаешсыз урыннарга махсус аңлатмалар бирел барыла, ягъни ул тәфсир рәвешендәрәк тәрҗемә ителгән.

# ӘҖЕМ МӘЧЕТЕ

Казан мәчетләре арасында чын сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрелгән гүзәл корылмалар бар. Һәм безнең игътибарны үзенә беренче чиратта Казан мәчетләренең солтаны — Әҗем мәчете җәлеп итәр (Фәтхуллин урамы, 15).

Бераз гына бу архитектура һәйкәленең тарихына күз салыйк. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар» әсәреннән күренгәнчә, бүгенге мәчет урынында һиҗри елы белән 1225 (1810) елда хаҗи Габделмәҗид бин Әбүбәкер тарафыннан манарасыз гына бер агач мәчет салына.

Шулай кырык еллап вакыт узып китә, мәчет тузып, яраксыз хәлгә килә. 1268 (1851) елда Әҗимовлар токымыннан килгән хаҗи Мостафа бин Нәзир бин Әҗем аның урынына агач, әмма инде манаралы мәчет салдыра.

К. Насыйри үзенең 1882 елда чыккан календаренда: «Әҗем мәхәлләсе яки завод мәхәлләсе һәм диярләр, монда хәзерендә икенче агач мәсҗедтер, әүвәлге мәсҗедне Мәҗид хаҗи дигән адәм салдырган иде, әүвәлге мәсҗед тузгач, моны Әҗемнәр салдырдылар, кадим монда мәхәллә юк иде», дип яза. Ашыгыбрак салынганмы, яңа мәчетнең михрабы көнчыгышка таба көньяктан 7, кыйбладан 8 градуска авышрак килеп чыккан, 1280 (1873) елда Мортаза бин Мостафа Әҗимов мәчетне яңарта, ягъни сипли, түбәсен һәм түшәмен тимердән эшләтә. Соңрак мәчетнең кайбер урын уңайсызлыкларын искә алып, Мортаза Әҗимов бинаны Лаеш өязенең Чыты авылына күчерә. 1304 (1886) елда тирә-яктагы күп кенә йортларны сүттереп, киңәйтелгән яңа мәйданга зур итеп, төзек итеп таш мәчет салдыруга ирешә. Мәчетнең идәне һәм түшәме эшләнеп беткәч, Мортаза Әҗимов вафат була. Мәчетне инде бер-ике ел эчендә аның варислары тәмам итә.

Әҗем мәчете — шәһәрнең иң матур, иң нәфис мәчете дияргә мөмкин. Көнчыгыш мавритания стилендә салынган булса да, манарасының ян кырыйга урнашканлыгы белән ул татар гыйбадәтханәләренең традицион типтагы таш вариантын гәүдәләндерә. Мәчетнең төньягыннан күтәрелгән шәмдәй төз манара төгәл пропорцияләре, бинасының купшы формасы, зәвыклы архитектура эшләнеше әлеге һәйкәлгә аерым нәфислек, камиллек, кабатланмас үзенчәлек бирә, аның шәрык чалымнарын калку итеп күрсәтә. Кызыл кирпечтән салынган мәчет бинасы майолика һәм уелма таш белән матур итеп нәкышланган.

Төзүчеләрнең осталыгы да хәйран калдыра: «кәүсә»нең диаметрын 3 метрдан арттырмаган хәлдә, алар манараны 52 метрлы итеп күтәрүгә ирешәләр. Җитмәсә аның эченә 106 басмадан торган бормалы баскыч та иркенләп сыйдырылган. Манараның кирпеч стенасы эченнән чүкелгән металлдан гыйбарәт вертикаль бәйләвеч-ялганмалар үтә. «Кәүсә»не ныгытулары белән бергә алар яшен уздыргыч вазифасын да үтиләр.

Мәчет түбәсендә зәвык белән эшләнгән сигезкырлык урын алган. Аның өстенә вертикаль валиклар белән бизәлгән нечкә һәм биек цилиндр утыртылган. Цилиндр өстә очлаеп торган аркалар белән төгәлләнгән, алары исә бизәлгән кирпечтән эшләнгән «пута» белән уратылган. «Пута» өстендәге манара баганасын ак ташлы челтәрле таянычлар (консольлар) били. Алар стеналарның кызыл өслегеннән матур булып аерылып тора. Таянычлар челтәр бизәкле җиңел тимер рәшәткә белән әйләндерелгән мәзин мәйданчыгын иңнәрендә тота. Манара ай белән бизәлгән шактый биек кырлы шпиль белән төгәлләнгән. Барлык бу элемент, детальләрнең искиткеч нәфис, геометрик төгәллеге, төрле төсләр уены мәчетне сәер иткән кеше күңелендә гаҗәеп бер канәгатьлелек, тәмамланганлык, чиге күрелмәгән камилият хисе уята.

Мәчетнең гомуми композициясен бина архитектурасы белән стиль ягыннан тыгыз бәйләнгән нәфис киртә тулыландыра.

Намаз йорты буларак 30 нчы елларда халыктан читләштерелгән Әҗем мәчете озак вакытлар төрле оешмалар карамагында булды. Җинаятьчел «файдалану» нәтиҗәсендә бу гүзәл сәнгать әсәре зур зыян күрде, формаль төстә үткәрелгән төзәтү эшләре бинаның аяныч хәлен тагын да авырлаштырды. Һәм, ниһаять, армый-талмый көрәшү нәтиҗәсе буларак, 1989 елда мәчет дин тотучыларга кайтарып бирелде, үзенең законлы хуҗаларына хезмәт итә башлады.

Шул ук вакытта бу корылма шәһәр силуэтының бер күрке, «ташта гәүдәләнгән музыка» сыйфатында казанлыларның тарихи горурлыгы булып тора.

Равил ӘМИРХАН,
тарих фәннәре кандидаты.

Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

*«Казан утлары» 1991 елда*

## Фоат Садриев

# ТАҢ ҖИЛЕ

РОМАН

Кеше гомере — уянып килүче табигатьне сизелер-сизелмәс кенә сыйпап үткән таң җиле кебек... Ул шулкадәр кыска ки, әйләнеп карарга һәм нәрсәдер аңларга да өлгерә алмыйсың, утларында яндырып, сагыш-моңга салып уза да китә гомер дигән кадерле мизгел... Әгәр шулай кыска икән, ул хәйран калырлык гүзәл булырга, ләззәтшатлыктан гына торырга, искиткеч асылташтай балкырга тиештер шикелле...

Ә чынбарлыкта ничек соң?

Бу сорауга җавап биргәнче авыр сулап куярга туры килә. Дөнья яралганнан бүгенге көнгәчә адәм балаларын кан һәм күз яшьләре, кайгы-хәсрәтләр, газап-михнәтләр озата килә. Тарих җир йөзенә начарлык кылу өчен килгән бер генә буынны да белми. Кешеләрнең зур күпчелеге изге нияттә яшәгән, яши һәм яшәячәк.

Алайса нишләп соң кылган изгелекләр яманлыкны тыя алмый, ул гына да түгел, күп кенә очракта башкалар өчен начарлык булып әверелә? Ни өчен тугрылык артына хыянәт яшеренә? Ни сәбәпле без теләгәннәрнең, без өметләнгәннәрнең нәкъ киресе килеп чыга?

Бу сорауларга минем романның героинясы Нуриасма болай дип җавап бирер иде кебек:

— Кеше тормышта үз-үзе булып калган очракта гына башкаларга изгелек кыла ала. Бу — йөрәк тавышыңны тыңлый белү һәм эш-гамәлләреңне берникнди рияланусыз шуңа буйсындыру дигән сүз. Әгәр кеше уйный башласа, чын хисләр белән яшәмәсә, ничекләр генә изгелеккә омтылса да, нияте барып чыкмаячак, ул хакыйкатьтән, гаделлектән һаман ныграк ерагая барачак.

Нуриасма — гади авыл кешесе. Тыштан тыныч, басынкы күренсә дә, ул гаять катлаулы, киеренке рухи тормыш кичерә. Аның аллага табынгандай табына торган «мәңге саф калырга» дигән принцибы бар, ул аңа беркайчан да хыянәт итми, аны бозмый, башкалардан да шуны таләп итә. Болай яшәү җиңел түгел. Ул үтә нечкә сизгерлек, йөрәк кайнарлыгы, тәкатьсезлек һәм вөҗдан сорый. Шуңа күрә Нуриасма гомере буе каршылыклар, газап-борчылулар, икеләнүләр эчендә яна...

Тормышыбызда әнә шулай яшәүче татар хатын-кызларын, аналарын күрү «Таң җиле» романының язылуына сәбәп булды да инде. Мин әллә нинди яңа нәрсәләр эзләмәдем. Мин җирдә буыннарны буынга бәйләгән, милләтне саклаган, яшәешне тотрыклы, мәгънәле иткән, изгелеккә һәм бәхеткә китергән мәңгелек кыйммәтләрнең кайберләрен барларга омтылып карадым. Ниятем барып чыкканмы, юкмы — анысын укучы хөкем итәр.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

# ЖУРНАЛ УКУЧЫЛАРГА АЧЫК ХАТ

Мөхтәрәм кардәшләр, журнал алдыручылар, укучылар!

Илебездәге гаять катлаулы икътисади һәм сәяси шартлардан һәм үзебезнең реаль хәлләрдән чыгып, редакция исеменнән Сезгә турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә булдык. Белгәнебезчә, экономик кризис, аннан чыгу юлларын эзләү, базар мөнәсәбәтләренә күчү чоры бәяләрнең тотрыксызлыгына, акчаның кыйммәтсезләнүенә китерде. Бу хәл безнең журнал язмышына да тискәре йогынты ясамый калмады, әлбәттә.

1991 нче елдан кәгазь бәяләре, мәсәлән, уртача 80 процентка арта. Элемтә оешмалары, шулай ук, журналны тараткан өчен түләүне берничә мәртәбәгә арттыруны таләп иттеләр. Шуның өстенә, типография чыгымнары да сизелерлек күтәрелде. Болар барысы да безнең журналның финанс хәлен катлауландырды, аның киләчәк язмышын куркыныч астына куйды. Эш шунда: әгәр без журнал бәясен гамәлдәгечә калдырсак, подпискадан кергән акча аны бастыру һәм тарату чыгымнарын каплауга да җитмәячәк. Почта чыгымнарына гына да якынча ярты миллион сум кирәклеге мәгълүм булды. Ә яңа шартларда үз-үзен финанс ягыннан тәэмин итә алмаган басмаларның яшәү мөмкинлеге шик астында.

Газиз кардәшләребез! 70 елга якын халкыбызга хезмәт итеп килгән, рухи дөньябызны баету, милли үзаңны уяту юлында армый-талмый эшләгән, юл башында Г. Ибраһимов кебек бөек шәхесләр торган журналыбызны исән калдыру өчен, киләчәктә дә аның утлары күңел йолдызыбыз булып балкысын өчен Сезнең ярдәмегез кирәк. Якынча исәпләүләргә караганда, журналның бер нөсхәсе 1 сум 50 тиен булса һәм тиражы кимүгә йөз тотмаса — аның алдагы язмышы өметле, ул үсү юнәлешендә үз эшен дәвам иттерәчәк.

Тарихи язмыш тәкъдирендә безнең халык гомер бакый диярлек яшәештә, бигрәк тә мәгърифәт-мәдәният өлкәсендә, фәкать үз хәләл көченә таянган, үз иманына инанып, үз өмет йолдызына ышанып хәят кичергән. Хәзер, ниһаять, Татарстан үзенең дәүләт мөстәкыйльлеген игълан иткәч, изге максатыбызга ирешү юлында алга таба да нык һәм бердәм була алсак, хәлләребез күп тапкырга яхшырыр дип ышанабыз.

Хөрмәтле укучыларыбыз, дуслар, якыннарыбыз! Ә хәзергә әдәбиятыбызның бердәнбер калын журналының сүнүенә юл куймау — милли рухы сынмаган, күңелен мүк басмаган һәрбер татар кешесенең намус эше дип саныйбыз. Бәяләр үсүгә карамастан, аңа язылсагыз, журналның патриотлары булып, күп миллионлы халкыбыз арасында киң пропагандаласагыз, Сез милләтебезнең тулы канлы яшәвенә, әдәбият һәм сәнгать үсүшенә зур өлеш кертер идегез.

Дуслыгыбыз өзелмәсенә ышанып, төрле төбәкләргә сибелгән кардәшләребезнең бердәмлегенә өмет тотып, тормышыгызда, гаиләгездә, эшегездә һәм укуыгызда бәхет һәм уңышлар, барчагызга сәламәтлек теләп —

Журналның баш мөхәррире,
Татарстан халык депутаты

Равил ФӘЙЗУЛЛИН.

Журналның бер елга язылу хакы — 18 сум, ярты елга — 9 сум.

КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)